ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

**Ә.М. Закирҗанов**

# ТАТАР ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ: ТРАДИЦИЯЛӘР ҺӘМ ҮСЕШ ТЕНДЕНЦИЯЛӘРЕ

## (XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы)

Казан
2018

**УДК 821.512.145**
**ББК 83.3(2Рос.Тат)**
**З 18**

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

**Фәнни редактор**

филология фәннәре докторы, профессор **Р.К. Ганиева**

**Рецензентлар:**

филология фәннәре докторы, профессор **Р.К. Әмиров,**
филология фәннәре докторы, профессор **Х.Й. Миңнегулов**

**Закирҗанов Ә.М.**
**З 18** Татар әдәбият белеме: традицияләр һәм үсеш тенденцияләре / Ә.М. Закирҗанов. – Казан: ТӘһСИ, 2018. – 352 б.
ISBN 978-5-93091-261-6

Монографиядә татар әдәбияты белеменең фәнни-теоретик һәм методологик нигезләре, аның торышы һәм үсеш перспективалары билгеләнә. Әдәбият фәненә караган мөһим төшенчәләрне аңлау һәм бәяләүнең үсеш-үзгәреше ачыклана. Әдәбият тарихын өйрәнүнең нигез принциплары, төрле чорлар арасындагы күчемле бәйләнеш мәсьәләләре, әдәби тәнкыйть өлкәсендә барган эзләнүләр тикшереп бәяләнә.

**УДК 821.512.145**
**ББК 83.3(2Рос.Тат)**

**ISBN 978-5-93091-261-6**

© Закирҗанов Ә.М, 2018;
© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2018

## КЕРЕШ

XX гасыр ахыры – XXI гасыр башында татар әдәбият белеме үз үсешенең яңа этабына керә. Җәмгыятьтәге үзгәрешләр нәтиҗәсендә яулап алынган демократик күренешләр (сүз иреге, хәбәрдарлык, фикер төрлелеге һ.б.) әдәби мирасны бөтен тулылыгында киң катлау укучыга кайтару, аерым чорлардагы сүз сәнгатен һәртөр идеологик кысалардан арындырып, объектив өйрәнү таләбен көн тәртибенә куя. Шул ук вакытта әдәбият турындагы фәннең моңа кадәр калыплашкан мөһим категорияләре (партиялелек, сыйнфыйлык, соцреализм һ.б.) кире кагылу бу өлкәдә фикер каршылыкларына, җитди бәхәсләргә юл ача. Сүз сәнгатенең җәмгыятьтәге урыны үзгәрү, чынбарлыкны чагылдыруның яңа төр-формаларына, алым-чараларына актив мөрәҗәгать итү белән бергә, аларны бәяләүдә кулланылган традицион принциплар әдәби барышны берьяклы аңлатуга китерә. Шундый шартларда әдәбият турындагы фәннең үсеш шартларын, методологик һәм теоретик нигезләрен, өйрәнү-тикшеренү юнәлешләрен, табыш-казанышларын һәм перспективаларын билгеләү мөһим бурыч булып алга чыга. Ике гасыр чигендә бу өлкәдә барган эзләнүләр, татар әдәбиятына хас закончалыкларны берләштерерлек карашлар системасын булдыру омтылышлары да эзлекле рәвештә тикшерелергә, бәяләнергә тиешле мәсьәлә булып калка. Ул исә үткән фәнни мирас традицияләренә таяну һәм дөнья әдәбият белеме казанышларын үзләштерү, үзара бәйләнеш-йогынтыны ачыклау белән үрелеп бара. Шул рәвешле, әдәбият белеменең XX гасыр ахыры – XXI гасыр башындагы торышын ачыклау, ягъни әдәбият теориясендәге табыш-нәтиҗәләрне, күпгасырлык әдәбият тарихына заман биеклегеннән чыгып бирелгән караш-мөнәсәбәтләрне һәм әдәби тәнкыйтьтә барган эзләнүләрне бәяләү иҗтимагый аңның бер формасы булган сүз сәнгатенең җәмгыятьтә тоткан урынын, әдәби-эстетик һәм әхлакый-фәлсәфи функцияләрен тулырак аңлауга да җирлек әзерли.

Әдәбият белеменең ике гасыр чигендәге торышы турында сүз алып барганда, аның үсеш-үзгәреш юлын, тарихын күз алдында тоту сорала. Татар әдәбият фәне тарихын системалы рәвештә өйрәнүдә билгеле бер нәтиҗәләргә ирешелсә дә, бурычлар тагы да күбрәк. Бу өлкәдәге эзләнүләрнең башлангычында XX гасыр башы аеруча мөһим урын алып тора. Әлеге чордагы татар иҗтимагый-фәлсәфи фикере, әдәби-эстетик карашлар үсеше татар әдәбият теориясен, тарихын һәм тәнкыйтен фәнни нигездә өйрәнә башлап, аның формалашуын һәм беренче адымнарын тәэмин иткән шәхесләрне тарих аренасына чыгара.

Җ. Вәлиди, Г. Сәгъди, Г. Баттал, Г. Ибраһимов һ.б., Шәрык-мөселман һәм рус-Европа әдәби-фәлсәфи фикеренә таянган хәлдә, татар сүз сәнгатенең тарихына, үсеш закончалыкларына, үзенчәлекләренә бәйле фәнни-теоретик карашларга нигез салалар һәм аның үсеш юлларын билгелиләр. Совет хакимияте урнашканнан соңгы беренче унъеллыкта Җ. Вәлиди, Г. Ибраһимов, Г. Сәгъди, Г. Нигъмәти, Г. Гобәйдуллин (Г. Газиз), Г. Рәхим, Г. Гали һ.б.ның хезмәтләрендә әдәбият тарихының яңа сәхифәләре тикшерелеп, теоретик һәм тәнкыйди фикер өлкәсендә җитди казанышларга ирешелә. Әмма 30 нчы елларда вульгар социологизм, соңрак репрессияләр шаукымы сәбәпле социалистик реализм иҗат методының әдәби күренешләрне берьяклы, идеологик кысаларда аңлатуы бу өлкәдәге эзләнүләрне бик нык чикли. Сугыштан соңгы елларда әдәбият белеменең тернәкләнүе М. Гайнуллин, Х. Госман, Г. Халит, Я. Агишев, Б.Яфаров, Ш. Абилов, И. Нуруллин, Б. Гыйззәт, Н. Гыйззәтуллин һ.б. исеме белән бәйле. Ә инде 1960–1980 елларда Х. Госман, Г. Халит, Н. Юзиев, И. Нуруллин, М. Хәсәнов, Ф. Мусин, А. Сайганов, Т. Галиуллин, А. Әхмәдуллин, Ф. Хатипов, Й. Нигъмәтуллина, Р. Ганиева, Н. Хисамов, М. Гайнетдинов, М. Бакиров, Х. Миңнегулов, Ш. Садретдинов һ.б.ның әсәр поэтикасы, иҗат методы һәм агымнары, милли эстетика, татар әдәбиятының Шәрык һәм Гареб әдәбиятлары белән бәйләнеше һ.б. буенча тикшеренүләренә бәйле рәвештә татар әдәбият теориясе, тарихы, тәнкыйте җитди хезмәтләр белән байый. Гомумән, татар әдәбият белемендә бүген дә кыйммәтен югалтмаган тикшеренүләр алып барыла, бай теоретик материал туплана, әмма аларны гомумиләштерү, закончалыклар, принциплар рәвешендә нигезләү артка калып килә.

XX–XXI гасыр чикләрендә әдәбият белеменең төрле өлкәләрендә, аерым алганда, әдәби юнәлешләр һәм агымнар, стиль һәм поэтика, шулай ук әдәбият тарихының төрле чор-этаплары, әдәби тәнкыйть үсеше һ.б. мәсьәләләр буенча уңышлы тикшеренүләр алып барыла (М. Хәсәнов, Ф. Мусин, Й. Нигъмәтуллина, Т. Галиуллин, Ф. Хатипов, Р. Ганиева, Х. Миңнегулов, М. Әхмәтҗанов, А. Әхмәдуллин, Н. Хисамов, Н. Ханзафаров, М. Бакиров, Ә. Шәрипов, З. Рәмиев, Ф. Галимуллин, Р. Салихов, А. Яхин, Ә. Сибгатуллина, А. Саяпова, Д. Заһидуллина, Р. Исламов, Ф. Яхин, Ф. Бәширов, Ә. Закирҗанов, В. Макарова һ.б.). «Татар әдәбияты тарихы»ның алты томлыгы (1984–2001) сүз сәнгате тарихына, әдәби-эстетик фикергә, жанрлар теориясенә, аерым әдипләр иҗатына бәйле җитди эзләнүләр нәтиҗәсе буларак дөнья күрә. Зур коллектив көче белән язылган хезмәт күпгасырлык татар әдәбиятын эзлекле һәм комплекслы тикшерүнең матур үрнәге булып тора. Ул әдәбият белеме казанышларына нигезләнеп языла һәм, аерым кимчелекләрдән азат булмаса да, көчле идеологик басым шартларында татар сүз сәнгатенең милли үзенчәлекләрен ачуга, халык тарихы, иҗтимагый

фикер үсеше белән тыгыз бәйләнешне күрсәтүгә, авторлар иҗатын рухи тормыш, яшәү рәвеше, традицияләр, теләк-омтылышлар аша сурәтләүгә ирешелә. Шуның белән бергә, марксистик-ленинчыл методологиягә нигезләнеп эшләнгән алтытомлыкта татар әдәбияты тарихы бөтен тулылыгында һәм эстетик байлыгында ачылмый һәм бәяләнми (моннан бары соңлабрак чыккан 6 нчы том гына котыла). Шунлыктан сигезтомлык «Татар әдәбияты тарихы»н эшләү бурычы алга килеп баса. Аның методологик һәм концептуаль нигезен рухи мирасны бөтен тулылыгында, бербөтен күренеш буларак, халыкның яшәү рәвеше белән тыгыз бәйлелектә һәм сүз сәнгатенең эчке закончалыкларына бәйле үсеп-үзгәреп торучы иҗтимагый күренеш итеп өйрәнү тәшкил итә. Аны тормышка ашыру буенча җитди эшчәнлек алып барыла.

Татар әдәбиятының Шәрык әдәбияты һәм рус-Европа әдәби-эстетик фикере белән тыгыз бәйләнеше Р. Ганиева, Й. Нигъмәтуллина, Х. Миңнегулов, Э. Нигъмәтуллин, Н. Хисамов, Ж. Зәйнуллин, О. Кадыйров, Ә. Сибгатуллина, Д. Заһидуллина, А. Саяпова, Ф. Яхин, В. Әминева һ.б.ның хезмәтләрендә киң чагылыш таба. Шигырь теориясе мәсьәләләре, шулай ук гомумтөрки поэзиянең яралуы-генезисы һәм аның иң борынгы формалары М. Бакиров хезмәтләрендә тикшерелә. Әдәбият белемендә герой концепциясе чагылышы үзенчәлекләренә нисбәтле җитди яңалыклар Р. Салихов монографиясендә урын ала. Әдәбият белеменең үсеш-үзгәреш тарихы, аерым алганда, татар теоретик фикеренең формалашу һәм аякка басу үзенчәлекләре Д. Заһидуллина тарафыннан ачыклана, бәяләнә. Гасыр башы һәм 1920–1930 еллар әдәбият фәнендәге эзләнүләр Ф. Галимуллин, Э. Галиева, Г. Азизова, Л. Хәйдәров, Ч. Гыйлаҗева, Т. Гыйләҗев һ.б. тарафыннан алып барыла.

Әдәбият тарихын өйрәнүдә метод-мәктәп-юнәлешләргә бәйле эзләнүләрнең җанлануы да җитди казаныш буларак кабул ителә (Й. Нигъмәтуллина, А. Саяпова, Д. Заһидуллина, Ч. Зарипова-Четин, Л. Йөзмөхәммәтова һ.б.). Әдәбият белеме буенча чыгарылган сүзлекләр, дәреслекләр һәм методик кулланмалар фәннең эчке закончалыкларына бәйле үсеш-үзгәрешен, әдәби-тарихи процессны өйрәнү принципларын билгеләүгә, өйрәнүгә ярдәм итә. Классик әдипләр, танылган замандаш язучылар һәм әдәбият галимнәренең (Г. Тукай, Г. Исхаки, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Г. Камал, Х. Такташ, Ш. Камал, М. Гафури, К. Тинчурин, Ә. Еники, Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Р. Миңнуллин, Х. Миңнегулов, Т. Галиуллин, Н. Хисамов, З. Рәмиев һ.б.) юбилейлары уңаеннан дөнья күргән күпсанлы җыентыклар да әдәбият белеме һәм сүз сәнгате тарихына бәйле тикшеренүләр өчен зур әһәмияткә ия.

Әдәбият белеменең төрле тармаклары буенча эзләнүләр нәтиҗәсе буларак басылып чыккан тематик һәм күзәтү җыентыкларында (авторлары – А. Әхмәдуллин, Т. Галиуллин, Х. Миңнегулов, Ф. Галимуллин,

Н. Хисамов, Ф. Мусин, Ф. Хатипов, Р. Сверигин, Д. Заһидуллина, Р. Исламов, Ә. Закирҗанов, В. Әминева, М. Юныс, Р. Рахмани, А. Хәлим, Р. Шәрәфиев, А. Шәмсутова, В. Макарова, И. Госманов, М. Ибраһимов һ.б.), шулай ук югары уку йортлары укытучылары, Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре чыгарган китапларда аерым әдипләрнең, тәнкыйтьчеләрнең әдәби-эстетик карашлары, газета-журнал битләрендә барган әдәби бәхәсләргә бәйле мәсьәләләр урын ала. Шуның белән бергә, XX гасыр ахыры – XXI гасыр башында татар әдәбият белеме буенча билгеле бер тикшеренүләр алып барылса да, милли әдәбиятның теориясенә, тарихына, тәнкыйтенә караган мәсьәләләрне өйрәнү, аларның әдәби процесс белән бәйләнешен системалы һәм бөтенлекле рәвештә ачу, төп тенденцияләрен билгеләү мөһим бурыч булып кала бирә.

Хезмәтнең төп максаты булып ике гасыр чигендә татар әдәбият белеменең барлык өлкәләрендә барган эзләнүләрнең теоретик, методологик нигезен ачыклау, аларның торышын, киләчәктә үсеш-үзгәреш юлларын, перспективаларын билгеләү тора. Ул исә, бер яктан, әдәбият белеменең күпгасырлык тәҗрибәсенә, традицияләренә нигезләнсә, икенче яктан, фәнни-теоретик фикернең милли үзенчәлекләрен ачыклау белән үрелеп бара.

Хезмәтнең фәнни яңалыгы ике гасыр чиге әдәбият белеменең төп тармакларында барган тикшеренүләрне бер системага нигезләнеп өйрәнү, бәяләү һәм табыш-нәтиҗәләрен ачыклау, шулай ук үсеш-үзгәреш юлларын күрсәтү белән билгеләнә. Теоретик һәм методологик нигез булып әдәбият белеме фәненең үз принциплары, шулай ук герменевтика, ягъни текстларның эчтәлеген аңлату-шәрехләү теориясе һәм әдәбият теориясенә нисбәтле сорауларны ачыклауда Ю.М. Лотман, Н.А. Гуляев, А.С. Бушмин, В.Е. Хализев, Л.В. Чернец, А.Б. Есин, В.И.Тюпа, Н.Д. Тамарченко, С.Н.Бройтман, А.Я.Эсалнек, Г.М. Халит, Й.Г. Нигъмәтуллина, Н.Г. Юзиев, И.З. Нуруллин, Ф.М. Хатипов, М.Х. Бакиров, Д.Ф. Заһидуллина, Р.Г. Салихов, Э.Р. Галиева һ.б., сүз сәнгате тарихының әдәби-эстетик, мәдәни-фәлсәфи асылын аңлатуда Б.В. Томашевский, В.М. Жирмунский, М.М. Бахтин, Ю.Б. Борев, Н.А. Гуляев, М.Б. Храпченко, Р.К. Ганиева, Й.Г. Нигъмәтуллина, Х.Й. Миңнегулов, Ф.М. Мусин, Н.Ш. Хисамов, А.Г. Яхин, А.Т. Сибгатуллина һ.б., ә инде әдәби тәнкыйтьнең үсеш-үзгәрешен бәяләүдә А.П. Скафтымов, Ю.Н. Тынянов, А.Б. Есин, Б.Ф.Егоров, В.Н. Коновалов, М.Г. Зельдович, Т.Н. Галиуллин, А.Г. Әхмәдуллин, Р.Х. Сверигин, Ф.М. Миңнуллин, Т.Ш. Гыйләҗев, Р.Ф. Харрасова һ.б. ның хезмәтләре игътибарга лаек.

## I бүлек

# ИКЕ ГАСЫР ЧИГЕНДӘ ТАТАР ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕНЕҢ АКТУАЛЬ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

## 1.1. Татар әдәбият белемендәге үзгәрешләрнең социаль-мәдәни шартлары

Әдәбият белеме матур әдәбиятны сүз сәнгате, рухи иҗат нәтиҗәсе буларак өйрәнә, шуңа да аның үзәгендә әдәби әсәрнең идея-эстетик кыйммәте, эчтәлек-формасы, төзелеше, сурәт чаралары байлыгы һәм үткәндәге, бүгенге әдәби процессның үсеш-үзгәреш закончалыклары һ.б. аспектлар тора. Әлеге гаять мөһим бурыч-вазифаларны үтәү өчен әдәбият турындагы фән үзенә хас фәнни-теоретик һәм методологик принципларга таяна. Аларны ачыклау исә, бер яктан, өйрәнү объекты булган сүз сәнгатенең даими үсеп һәм үзгәреп торуына, икенче яктан, әдәбият белеменең хәрәкәттә булуына, ягъни эчке үсеш логикасына нигезләнә. Әдәбият белеменең үсеш-үзгәрешенә үткәндәге һәм хәзерге сүз сәнгате үзенчәлекләрен яңача бәяләү ихтыяҗы белән моңа кадәр калыплашкан фәнни-теоретик фикернең әлеге максатны үти алмавы аркасында туган каршылык этәргеч бирә. XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы әдәбият фәнендә гаять кызыклы эзләнүләр, фәлсәфи һәм әдәби-эстетик карашлар, парадигмалар үзгәреше белән характерлана. Соңгысы, дөнья картинасын аңлауда нигез төшенчәләрнең берсе рәвешендә, фәлсәфәчеләрне һәм сәнгатькярләрне мөһим тикшеренүләргә этәрә[1].

«Күчеш чоры» термины бер төрле хәл-торыштан икенчесенә, ягъни тормыш-чынбарлыкны аңлауда яңа баскыч-үлчәүгә күчүне аңлата. Аны тормышның әдәби картинасы үзгәрү рәвешендә бәяләү дә бар.

---

[1] Моны дәлилләүче күпсанлы хезмәтләр дөнья күрә: *Нигматуллина Ю.Г.* Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. Казань: Фэн, 1997. 190 с.; Искусство в ситуации смены циклов: Междисциплинарные аспекты исследования художественной культуры в переходных процессах / отв. ред. Н.А. Хренов. М.: Наука, 2002. 467 с.; Переходные процессы в русской художественной культуре: Новое и Новейшее время / отв. ред. Н.А. Хренов; Гос. ин-т искусствознания М-ва культуры РФ; Науч. совет «История мировой культуры» РАН. М.: Наука, 2003. 495 с.; *Заһидуллина Д.Ф.* Дөнья сурәте үзгәрү: XX йөз башы татар әдәбиятында фәлсәфи әсәрләр. Казан: Мәгариф, 2006. 191 б.; *Богаткина М.Г.* Теория литературы: Формирование новой научной парадигмы: учебное пособие. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2007. 56 с.; *Крылов В.Н.* Русская символистская критика (1890–1910-е гг.): генезис, типология, жанровая поэтика: дис. ... докт. филол. наук. Казань, 2007. 508 с. һ.б.

А.Н. Хренов фикеренчә, «күчеш дөньяның бер картинасы таралу һәм альтернатив дөнья картинасы урнашуны аңлата»[1]*. Бу урында дөнья картинасының төрле контекстта каралуын да билгеләп үтәргә кирәк. Аерым алганда, төрле дәверләрне (Яңарыш, Урта гасырлар, Яңа заман), әдәби юнәлешләрне (классицизм, романтизм, реализм һ.б.), шулай ук милли һәм шәхси-иҗади дөнья картиналарын аерып чыгаралар. Аларны билгеләүдә нигез итеп яшәеш (бытие) һәм аңның үзара мөнәсәбәте алына. Гуманитар фәннәр өлкәсендә дөньяның классик һәм классик булмаган картиналарын аерып чыгару кабул ителгән. Беренчесе, ирекле һәм җаваплы шәхес идеясенә таянып, кешене күпгасырлык мәдәни кыйммәтләр дәвамчысы итеп карый, шуңа да ул гармонияне, тынычлык һәм тигезлекне, яшәештә тәртипне яклый һәм саклый. Икенчесе исә тарихи үткәнне кире кагучы, үзенә генә таянучы актив шәхесне үзәккә куя, шуңа да аңа җимерү, үзгәртергә омтылу һәм тәмамланмаганлык идеясе хас. Кешелек тарихында алар бер-берсен алыштырып киләләр, шул ук вакытта үзара бәйләнештә һәм янәшә яшиләр. 1990 еллар чигендә дөньяның классик картинасының (совет чорында җәмгыять тигез, тыныч, гармоник яшәешкә омтылды) классик булмаган картина белән алышынуы башлана. Аны дөньяның классик булмаган картинасының соңгы дәвере (постнеклассическая) дип атыйлар[2].

Н.А. Хренов, күчеш процессларын шәрехләүгә бәйле рәвештә, дүрт төрле парадигманы аерып чыгара. Аның берсе үсеш-үзгәрешне эзлекле, тигез рәвештә камиллеккә таба баручы эволюцион хәрәкәт буларак билгели, икенче төрле әйткәндә, үсеш монда – тигез вакыт аралыгында, ягъни күчемлелек, эзлеклелек һәм дәвамлылык принциплары буенча баручы эволюция синонимы. Икенчесе күчешне «циклик парадигма» рәвешендә аңлата. Сүз социаль төркем яисә җәмгыять дәрәҗәсендәге гади күчеш турында гына түгел, бәлки, яшәп килүче берәр мәдәният эчендә генә калмыйча, универсаль, цивилизацион, бөтен кешелеккә йогынты ясый торган тоталь күчеш турында бара. Өченче парадигманы «бифуркация моменты» дигән төшенчә белән атый. Андый момент өчен элекке тәртипнең һәм, аңлашылганча, детерминизмның таркалуы характерлы. Әлеге хәлиткеч нокталарда закончалык түгел, ә очраклылык, тәртип түгел, ә хаос өстенлек итә. (...) Тарихи вакытны шәрехләгәндә күчеш тәртиптән хаоска һәм соңгысыннан яңа тәртипкә күчүне

[1] *Хренов Н.А.* Опыт культурологической интерпретации переходных процессов // Искусство в ситуации смены циклов: Междисциплинарные аспекты исследования художественной культуры в переходных процессах / отв. ред. Н.А. Хренов. М.: Наука, 2002. С. 20.

* Русча чыганаклардан алынган барлык өземтәләр дә татарчага автор тәрҗемәсендә бирелә.

[2] *Богаткина М.Г.* Теория литературы: Формирование новой научной парадигмы: учебное пособие. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2007. С. 5–6.

аңлата. Дүртенче парадигма нигезендә мәдәният үсешен медиацион һәм инверсион типларга бүлеп карау ята. Әгәр медиацион тип үсешне эзлекле баручы, ягъни кискен үзгәрешләрне кире кагучы күренеш итеп каралса, инверсия исә «инкарьны инкарь итү» логикасына нигезләнә. Әлеге карашлар алдагы кыйммәтләр системасын кире кагуга, җимерүгә йөз тота[1]. Күчеш чорын аңлатучы әлеге карашларның кайсына да булса өстенлек бирү шактый кыен. Шул ук вакытта, алар арасында билгеле бер якынлык, үзара керешеп китү дә күзәтелә. Озак вакытлар дәвамында, бигрәк тә совет чорында өстенлек иткән караш – культура тарихында тигез-тыныч үсеш күзәтелү – җитди каршылыкка очрый. Н.А. Хренов язганча, «үсешне тулы аңлатуга йөз тотучы эволюцион доктрина кризисы үсешнең альтернатив теорияләре, ягъни цикллар теориясе белән кызыксынуны тудырды. Әлеге теория буенча үсеш туры рәвештә түгел, ә түгәрәк буенча бара. Үзенең потенциален бетергәч, тарих процесс башлангычына кайта ала. Әлеге доктрина нигезендә, күчеш циклдан циклга күчеш буларак кабул ителә»[2]. Күчеш чоры төшенчәсенең асылын аңлатучы әлеге үзенчәлекләр XX гасыр ахыры татар әдәбият белеменә хас сыйфат-билгеләрне, үткәннең аерым казанышларын ни дәрәҗәдә кабул итүен, традицияләрнең трансформацияләнүен, шулар нигезендә яңа тенденцияләр, табыш-яңачалыклар барлыкка килүен аңларга мөмкинлек бирә. XX гасыр ахыры – XXI гасыр башының XX йөз башындагы әдәби-мәдәни ситуация белән аваздашлыгын, охшашлыгын күпләр билгеләп үтә[3]. Ул дәвердә әдәбият белеме ирешкән, ә совет чорында читкә кагылган казанышларның бер өлеше (модернга хас эзләнүләр, «идеяләр романтизмы» (Нигъмәтуллина) һ.б.) хәзер «реабилитацияләнә», кире кайта. Шундый шартларда татар әдәбият белеменең торышы, бер яктан, җәмгыятьтәге иҗтимагый, социаль-мәдәни шартлар, икенче яктан, әдәби хәрәкәт, әдәби процессның гомуми үзенчәлекләре һәм фәннең үзенә хас эчке сыйфат үзгәрешләре белән билгеләнә.

---

[1] *Хренов Н.А.* Опыт культурологической интерпретации переходных процессов. С. 15–24.

[2] *Хренов Н.А.* Переходность как следствие колебательных процессов между культурой чувственного и культурой идеационного типа // Переходные процессы в русской художественной культуре: Новое и Новейшее время / отв. ред. Н.А. Хренов; Гос. ин-т искусствознания М-ва культуры РФ; Науч. совет «История мировой культуры» РАН. М.: Наука, 2003. С. 24.

[3] *Нигматуллина Ю.Г.* Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. Казань, Фэн, 1997. 190 с.; *Нигматуллина Ю.Г.* «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. Казань: Фэн, 2002. 176 с.; *Ганиева Р.К.* Татарская литература: традиции, взаимосвязи. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. 272 с.; *Заһидуллина Д.Ф.* Дәресләрдә әдәби-тарихи күзаллау // Мәгариф. 2004. № 11. Б. 35–37; *Загидуллина Д.Ф.* Современная татарская проза (1986–2016 гг.): основные тенденции историко-литературного процесса. Казань: Изд-во Академии наук РТ, 2017. С. 66. һ.б.

XX гасыр ахыры – XXI гасыр башында гаҗәеп үзенчәлекле яңа социаль-мәдәни ситуация урнаша. Җәмгыятьнең барлык өлкәләрендә барган үзгәрешләр тормыш-чынбарлыкка караш-мөнәсәбәтне тамырдан үзгәртә. Демократия күренеше буларак, сүз иреге, матбугат иреге яулап алыну нәтиҗәсендә, бик күп мәсьәлә-проблемалар турында ачыктан-ачык сөйләшү мөмкинлеге туа. Акрынлык белән халыкның үзаңы үзгәреше, ягъни совет чоры карашларыннан арыну, «дөньяга яңача карый, яңача фикер йөртә»[1] башлау күзәтелә. Сүз сәнгатенә мөнәсәбәттә ул заманның әдәби процессын чагылдыруда һәм күпгасырлык әдәбият тарихын яктыртуда, бәяләүдә күренә. «Туксанынчы еллар һич уйламаганда, көтмәгәндә бәхәс иреге, фикер төрлелеге, уйлану киңлеге алып килде, – дип яза Т. Галиуллин. – Азатлык, хөррият җилләре һәм төрлечә карашлар сыешуы әдәби үткәнебезне, хәзергебезне киңрәк җирлектә һәм яңачарак бәяләргә, элек тирәндәрәк яткан яисә олы сәясәт таләпләренә җавап биреп бетермәгән хәзинәләрне, матурлыкларны билгеләргә мөмкинлек ачты»[2]. Әдәби ядкәрләребезне барлау, бәяләү, халыкка кайтару мәсьәләсе игътибар үзәгендә булып, аеруча совет чоры – Октябрьдән соңгы дәвер – әдәбият тарихы, аерым әсәрләр, авторлар иҗаты кызу бәхәсләр тудыра. Т. Миңнуллин Татарстан Язучыларының XI съездында (1989) болай дип чыга: «Хәзер бездә үткәннәрне тәнкыйть күзлегеннән уздыру, аларга яңача төшенү процессы бара. Бу закончалыклы хәл. Чөнки моңарчы илебездәге хәлләрне үз вакытында һәрьяклап, хәбәрдарлык һәм демократия шартларында фикерләү мөмкинлегебез булмады. Тәнкыйть фикерләре барыбызда да тупланып килде, һәм алар менә хәзер (...) тышка бәреп чыкты»[3]. Шуның белән бергә, әдәбият теориясенең какшамас булып тоелган төшенчәләрен – социалистик реализм иҗат методын, әдәбиятның сыйнфыйлыгын, партиялелеген һ.б.ны кире кагу күзәтелә. Дөрес, әлеге мәсьәләләр буенча фикер алышуларда бер чиктән икенчесенә ташлану да урын ала. Мисал өчен, социалистик реализм әдипне хакимият идеологиясенә буйсындыруга гына хезмәт итте дип, 1930–1950 елларда яшәп иҗат иткән әдипләр иҗатына «кара мөһер» сугу омтылышлары булды. Мондый караш-фикерләр җәмәгатьчелектә киң урын ала алмый. Совет идеологиясен чагылдырган әсәрләргә каршылыклы мөнәсәбәт сакланса да, татар әдәбияты яулаган биеклекләр символы булган, иҗатларында милләт язмышын чагылдырган, аның киләчәге өчен җан аткан олы затларыбыз (мисал өчен, Һ. Такташ, М. Җәлил һ.б.) хаклы рәвештә яклау таба.

[1] *Еники Ә.* Хәерле сәгатьтә! ( Татарстан язучыларының XI съездын ачканда сөйләгән сүзе) // Казан утлары. 1989. № 11. Б. 127.

[2] *Галиуллин Т.Н.* Татар поэзиясе тарихын яңача өйрәнү мәсьәләләре // Шигърият баскычлары. Казан: Мәгариф, 2002. Б. 9.

[3] *Миңнуллин Т.* Каләмебез, сүзебезне эшкә җигик! // Казан утлары. 1989. № 11. Б. 128.

Шуның белән бергә, XX гасыр ахырында әдәбиятның җәмгыятьтәге урыны җитди үзгәреш кичерә, ул алдагы унъеллыкларда тоткан урынын, ролен җуя. Сүз сәнгате үзенең күпсанлы укучыларын югалта. Әле XX гасырның 80 нче елларында гына йөзәр мең тираж белән чыккан әдәби журналлар биш-алты меңгә кала, әдәби китапларның уртача тиражы да ике-өч меңнән артмый, шуның өстенә аларны сату да бермә-бер авырлаша. Шул рәвешле, әдәбиятның «тормыш дәреслеге» сыйфаты бермә-бер кими. Моның сәбәбе җәмгыятьтә яңа мәдәни хәл урнашу белән аңлатыла: мәдәният милли-локаль үзенчәлекләрен югалтып, массачыл товар сыйфатлары ала һәм ул торган саен күбрәк формулалы, «бер тапкыр гына файдаланулы» була бара, сүзле образдан бигрәк, күреп, ишетеп кабул итүгә йөз тота. Әдәбиятның традицион функцияләре масс-медиа чараларына күчә[1]. Бу, үз чиратында, җәмгыятьтә язучының урыны, дәрәҗәсе бик нык кимүгә китерә. Бу турыда ачынып, З. Мансуров болай ди: «Егерменче гасырда әле беркайчан да, хәтта рәхимсез тоталитар хакимият вакытында да мәдәниятнең бүгенге кебек бөлгенлек хәленә төшкәне юк иде. Каләм әһеленең төп коралы булган сүз күзгә күренеп кадерсезләнде, кешеләр күңеленә нур иңдерүче китап, бигрәк тә милли китап «дәүләткә зыян китерә торган товар»га әверелде, язучы профессиясенең яшәү-яшәмәве куркыныч астына куелды»[2].

Үзгәртеп коруларның башлангыч чорындагы кызулык сүрелә төшкәч, әдәби-мәдәни торышны аңлау-бәяләү һәм акрынлык белән киләчәккә юл-юнәлешләр билгеләү вакыты җитә. Ул исә төрле юнәлештәге эшчәнлек белән бәйле була. Берсе – сүз сәнгате тарихындагы классик мирасның кайтарылуы. Арада аеруча зур әһәмияткә ия булганы, һичшиксез, Г. Исхакый иҗаты. Аның янәшәсендә Г. Рәхим, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, М. Хәнәфи һ.б. әдипләрнең төрле сәбәпләр аркасында әдәбият тарихыннан алып ташланган әсәрләре дөнья күрә. Әдәбият тарихы бөтен асылында күз алдына бастырылу белән бергә, «безнең тарихи аңыбыз да тулылана төште»[3]. Икенчесе – данлы һәм фаҗигале тарих сәхифәләрен яңарту, аларга объектив бәя бирү. Ул исә гаять каршылыклы үткәнебезне, горурланырлык тарихи шәхесләрнең эшчәнлеген ачу, аларның классик сүз сәнгатендәге образларын барлау һәм шул рухта яңа әсәрләр иҗат итү белән бәйле була. Өченчесе – чит илләрдәге татар әдәбияты һәм публицистикасының кире кайтуы. Билгеле булганча, Октябрь инкыйлабыннан соң эмиграциягә китүче күпсанлы милләттәшләребез арасында әдәбият-сәнгать белән якыннан кызыксынучылар

---

[1] *Кабанова В.* Введение // Современная литературная теория. Антология / сост. И.В. Кабанова. М.: Флинта: Наука, 2004. С. 7.

[2] Язмышның ачы шаяруы (Р. Аймәтнең З. Мансуров белән әңгәмәсе) // Шәһри Казан. 1994, 18 ноябрь.

[3] *Мостафин Р.Ә.* Чорлар чатындагы үзгәрешләр // Казан утлары. 2004. № 5. Б. 147.

да була. Милләтпәрвәр җанлы әлеге шәхесләр тырышлыгы белән күп илләрдә татар телендә газета-журналлар чыгарыла, аерым очракларда китап-хезмәтләр дөнья күрә. Әмма башка телләргә тәрҗемә ителмәгәнлектән, алар киң яңгыраш тапмый, чит илләр матбугатында аерым язмалар гына дөнья күрә. Ә совет илендә яшәүче татарларга килеп ирешүгә башка юл булмый. Шул ук вакытта әлеге әдәби әсәрләр, фәнни һәм публицистик хезмәтләр чит илләрдә яшәүче татарларның байтагына таныш була. Ниһаять, әлеге шактый бай, кызыклы, үзенчәлекле мирас, 1990 еллардан башлап, киң катлам татар укучысына да кайтарыла. Бу өлкәдә аеруча Х. Миңнегулов, И. Надиров, Ә. Кәримуллин, Т. Әйди, М. Госманов, Л. Гайнанова, Т. Насыйров, Ә. Сәхапов һ.б. зур хезмәт куя. Дүртенчесе – дингә карашның уңай якка үзгәрүе. Ислам диненең халык тормышындагы урынын тирәнтен аңлаган хәлдә, шул ук вакытта бу мәсьәләгә бик сак килеп, күпгасырлык рухани әдәбиятны кайтару, аның идея-эстетик эчтәлеген объектив ачу процессы башлана. XX гасыр ахырында дини, ярымдини эчтәлекле күпсанлы фәнни, публицистик хезмәтләр, трактатлар китап булып басылып чыга, укучыларга килеп ирешә. Җәмгыятьтә дингә карашның үзгәрүе, халыкның бер өлеше дингә килү һ.б. сәбәпләр татар әдәбиятында үзенчәлекле бер тармакның җанлануына юл ача. XX гасырның 90 нчы еллары уртасына таба Ф. Бәйрәмова, А. Хәлим, Г. Сәлимов һ.б. иҗаты белән әдәбиятта рухани юнәлеш җирләшә башлый. Бишенчесе – татар халкын берләштерерлек милли идея булдыру, аның эчтәлеген киң җәмәгатьчелеккә җиткерү. Газета-журнал битләрендә кызыклы фикер алышулар, бәхәсләр булып үтә. Ф. Мусин язганча, «милли идея халыкның күпгасырлык яшәү рәвеше, уй-хыяллары, тормыш һәм хезмәт тәҗрибәсе сөземтәсен» тәшкил итеп, аны хәзерге яшәешебездә, дәүләт идарәчелегендә һәм сәясәтендә файдалану күздә тотыла[1]. Алтынчысы – хәзерге татар сүз сәнгатендә гаять кызыклы сәнгати эзләнүләр башлану. Х. Миңнегулов билгеләп үткәнчә, «матур әдәбиятның яңарышы, күтәрелеше теге яисә бу дәрәҗәдә фәнни-тәнкыйди фикернең үсешен дә тәэмин итә»[2]. Татар әдәбиятының үзәген – магистраль юлын тәшкил иткән реализм һәм романтизм юнәлешләре эчендә «кайнау» күзәтелә. XX гасырның 60–80 нче елларындагы традицияләргә таянып, әдипләр актив рәвештә психологизм алымнарына, мифопоэтик чараларга һ.б.га мөрәҗәгать итәләр. Кешенең күңел дөньясына үтеп керү шәхси һәм иҗтимагый мәнфәгатьләр мәсьәләсенә башка яссылыкта карауга, бәяләүгә этәрә. Совет чоры тормышына мөнәсәбәттә тәнкыйди

---

[1] *Мусин Ф.М.* Рухи әләм менсен биеккә // Шәһри Казан. 1996, 24 май.

[2] *Миннегулов Х.Ю.* Основные проблемы в современном татарском литературоведении // Записки разных лет (Татарская литература: история, поэтика и взаимосвязи). Казань: Идел-Пресс, 2010. С. 339.

катлам яңа баскычка күтәрелә. Әсәрләргә символик образлар, метафорик күренешләр, шартлылык алымнары күпләп үтеп керә. Үзгәрешләрнең аеруча зур өлеше реализм һәм романтизм юнәлешләренә сыеп бетмәгән, бәлки модернизм һәм постмодернизм юнәлешләренә хас алымчараларга, формаларга нигезләнгән күзаллау, чынбарлыкны бәяләү белән бәйле була. «Постреализм» әсәрләре яшәешнең моңа кадәр читтәрәк калып килгән хәл-күренешләрен алга чыгара, кеше шәхесен тормышның үзәгенә куеп тикшерә, еш кына аның чиктәш халәтенә мөрәҗәгать итеп, яшәү – үлем, бәхет – бәхетсезлек, мәхәббәт – нәфрәт, бөеклек – түбәнлек, саташу – аңсызлык һ.б. шундый халәтләрне үзәккә куя. Модернизм һәм постмодернизмга хас булган чара-алымнардан фрагментлы хикәяләү; «бүлгәләнгән аң»ны тасвирлау; күптөрле шәрехләүләргә урын калу; төрле модернистик стильләрнең синтезы; әдипләрнең актив рәвештә архетипларга, мифологемнарга, фантастик һәм шартлы формаларга, символларга мөрәҗәгать итүе; әдәби алым һәм сурәтләү предметы буларак «уен» ны һ.б. куллану күзәтелә. Шуның белән бергә, әдәбият белеме, шул исәптән әдәби тәнкыйть әдәбият тарихын бәяләүгә, хәзерге әдәби процесс үзенчәлекләрен ачуга әзер булмый. Үткән чорларга хас теоретик принциплар, анализ юллары әдәбият тарихын һәм хәзерге әдәби күренешләрне берьяклы аңлатуга китерә. Шул рәвешле, әдәбият белемендә каршылыклы хәл – торгынлык барлыкка килә. Ул исә хаклы рәвештә ризасызлык тудыра. Шундый шартларда сүз сәнгатенең ерактагы һәм якындагы дәверләрен, ике гасыр чигендәге торышын аңлатуга, төп тенденцияләрен, үсеш-үзгәреш үзенчәлекләрен бәяләргә нигез булырлык фәнни-теоретик һәм методологик мәсьәләләргә ачыклык кертү, аларның эзлекле системасын булдыру кирәклеге җитди бурыч булып калка.

Шулай итеп, татар әдәбият белеменең торышы, бер яктан, җәмгыятьтәге социаль-мәдәни шартлар, икенче яктан, әдәби процессның гомуми үзенчәлекләре һәм фәннең үзенә хас эчке сыйфат үзгәрешләре белән билгеләнә. XX гасыр ахыры дөньяның әдәби картинасы үзгәрүгә бәйле күчеш чоры буларак характерлана. Шуңа нисбәтле күзәтелгән үзенчәлекләр (әдәбиятның җәмгыятьтәге урыны үзгәрү, классик мирасның кайтарылуы, фаҗигале тарих сәхифәләрен яңарту һәм аларга объектив бәя бирү омтылышлары, чит илләрдәге татар әдәбияты һәм публицистикасы кайту, дингә карашның уңай якка үзгәрүе һәм әдәбиятта рухани юнәлеш җирләшә башлау, авангард сүз сәнгатендә кызыклы сәнгати эзләнүләр башлану һ.б.) үткәндәге һәм хәзерге сүз сәнгате үзенчәлекләрен яңача бәяләү ихтыяҗы тудыра, әмма моңа кадәр калыплашкан фәнни-теоретик фикер әлеге максатны тулысынча үти алмый. Әлеге җитди каршылык хәзерге татар әдәбият белеменең фәнни-теоретик һәм методологик мәсьәләләрен, үсеш-үзгәреш тенденцияләрен, эзләнү юнәлешләрен билгеләүне алгы планга чыгара.

### 1.2. Әдәбият фәненең теоретик һәм методологик мәсьәләләре

Җәмгыятьтәге социаль-мәдәни һәм идеологик үзгәрешләр татар әдәбият белемендә дә чагылыш таба. Әлеге фәннең һәр тармагында җитди эзләнүләр кирәклеге, әдәбият тарихы, әдәбият теориясе, әдәби тәнкыйтьнең үсеш-үзгәреш этапларын, татар галимнәре таянган нигез концепцияләрне, методларны билгеләү белән бергә, аларның хәзерге торышын, теоретик һәм методологик бурычларын ачыклау һәм үсеш-үзгәреш юлларын билгеләү дә җитди мәсьәлә рәвешендә алга чыга. Үткән мираска тәнкыйди караш, аны яңача бәяләү дә мөһим сорауларның берсе буларак куела. Рус һәм Көнбатыш Европа, шулай ук Көнчыгыш әдәбият белеме казанышларын үзләштерү, татар әдәбият белеменең дөньякүләм процесстагы урынын, үзара бәйләнеш-йогынтысын ачыклау мәсьәләсе дә калкып чыга.

Татар әдәбият белеме методологиясенә караган мәсьәләләр, әлеге фән барлыкка килү белән бергә, конкрет тикшеренүләрдә, аеруча әдәбият тарихына һәм теориясенә караган хезмәтләрдә билгеле бер дәрәҗәдә чагылыш таба. XX йөз башында гына формалашу процессы кичергән татар әдәбият белеме тизләтелгән үсеш юлы үтә һәм әдәби тәнкыйть, әдәбият теориясе, әдәбият тарихы кебек төп тармакларының нигез ташларын сала. Моңа йогынты ясаган сәбәпләр – алар, бердән, татар әдәбиятының тирән тамырлары булу, аларның иҗтимагый фикергә, халыкның рухи тормышына гаять зур тәэсир ясавы һәм әлеге бай мирасны барлау, өйрәнү, системага салу юлларын эзләү, икенчедән, беренче рус революциясеннән (1905–1907) соңгы елларда татар җәмгыятендә башланган Яңарыш дулкынының яшәешнең барлык катламнарын иңләп үтүе, өченчедән, Көнчыгышның мөселман дөньясы белән булган зур традицияләрне саклаган хәлдә, рус-Көнбатыш дөньясының, бигрәк тә әдәби-эстетик һәм фәлсәфи казанышларын үзләштерүгә алынуы һ.б. тора. Шундый шартларда әдәбият белеме җитди алгарыш кичерә һәм мөһим методологик мәсьәләләрне тикшерүгә килә. Җ. Вәлиди, Г. Баттал, Г. Ибраһимов, Н. Хәлфин, Г. Сәгъди һ.б. шәхесләрнең бүген дә кыйммәтен җуймаган хезмәтләре дөнья күрә. Д. Заһидуллина тикшеренүләре күрсәткәнчә, бу чорда татар әдәбият белемендә «җәмгыятьчеләр» һәм «рухиятчеләр» дип атарга мөмкин булган мәктәпләр барлыкка килә. Әдәбиятның эчтәлеген, формасын, тормышны чагылдыру үзенчәлекләрен, милли асылын аңлау-аңлатуда бәхәсләргә урын калса да, бу мәктәпләр асылда берсен-берсе тулыландыруга, баетуга хезмәт итә[1].

1917 елгы вакыйгалардан соң илдә урнашкан сәяси-тарихи, иҗтимагый-мәдәни шартларда татар әдәбият белеме каршылыклы үсеш

[1] *Заһидуллина Д.Ф.* Әдәбият кануннары һәм заман. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. Б. 65–66.

чорына керә. Нәкъ менә методология мәсьәләләрендә кискен бәхәсләр бара. Әдәбиятның чынбарлыкка, яңа тормыш төзүгә якын булырга тиешлеген яклау культура-тарих мәктәбе принципларын алга чыгара. Дөрес, 1920 елларның беренче яртысында әле күптөрлелек сакланып, «рухиятчеләр»нең нигез принципларыннан булган геройның рухи дөньясына игътибар кебек мәсьәлә, шулай ук формаль һәм социологик мәктәп тарафдарлары яклаган әдәби әсәрнең эчтәлеге һәм формасы мөнәсәбәте, тирәлек йогынтысы һ.б. кызыксыну уята. Әнә шундый катлаулы шартларда Г. Ибраһимов, Г. Сәгъди, Г. Нигъмәти, Г. Гали, Г. Гобәйдуллин, Г. Рәхим һ.б., XX йөз башындагы традицияләргә таянган хәлдә, фәнни-теоретик эзләнүләрен дәвам итәләр. Әмма акренләп әлеге төрлелек бетерелә, үзәккә марксистик методология куела. Ул исә әдәбият белеме мәсьәләләрен партиялелек, сыйнфыйлык төшенчәләренә нигезләнеп ачыклауны, төп иҗат методы итеп соцреализмга таянуны, әдәбият һәм аның турындагы фән тарихын марксистик-ленинчыл концепциягә буйсындыруны күздә тота.

1940–1950 еллар дәвамында татар әдәбият белеменең үсешүзгәрешендә үзара керешеп киткән ике тенденция чагыла. Берсе – методологик мәсьәләләр буенча тикшеренүләрнең аз булуы, шуңа да әдәбият тарихына, аерым әдипләр иҗатына караган хезмәтләрдә, дәреслекләрдә теоретик сорауларның рус әдәбият белеме казанышларына нигезләнеп ачыклануы; икенчесе – татар әдәбияты тарихының Урта гасырлар һәм XX йөз башы дәверләре буенча эзләнүләр башлану, шуңа нисбәтле сүз сәнгатен иҗтимагый фикер тарихы белән бәйләнештә өйрәнү, аның милли үзенчәлекләрен билгеләү, күпсанлы яңа ядкәрләрне әйләнешкә кертү, сәнгати табышларны билгеләү омтылышы ясалу. Г. Халит, Я. Агишев, Б.Яфаров, Ш. Абилов, М. Гайнуллин, Н. Гыйззәтуллин, Б. Гыйззәт һ.б.ның бу чорларда басылып чыккан хезмәтләрендә әлеге үзенчәлекләр чагылыш таба.

Татар әдәбият белемендә 1960 еллардан башлап методология мәсьәләләре белән кызыксыну арта. Аерым алганда, әдәби әсәр поэтикасы (Н. Юзиев, Х. Госман, М. Бакиров), иҗат юнәлеше һәм иҗат методы (М. Хәсәнов, И. Нуруллин, Т. Галиуллин, А. Әхмәдуллин), милли эстетика һәм фәлсәфә (А. Сайганов, Й. Нигъмәтуллина, Р. Ганиева, Ф. Мусин), шулай ук әдәбият тарихының төрле дәверләре, традицияләр дәвамчанлыгы, Шәрык һәм Гареб әдәбиятлары белән чагыштырып өйрәнү (Х. Миңнегулов, Н. Хисамов, Э. Нигъмәтуллин, О. Кадыйров) белән бергә, әдәбият белеменең теоретик мәсьәләләре дә тикшеренү өлкәсе булып тора. Бу мәсьәләдә аеруча Х. Госман, Г. Халит, Н. Юзиев, И. Нуруллин, Й. Нигъмәтуллина, Р. Ганиева хезмәтләре алдагы тикшеренүләргә юл ача. «Татар әдәбияты тарихы»ның алты томлыгы (1985–2001) әдәбият тарихының, эстетик фикернең, жанрлар теориясенең, сүз сәнгатенең танылган вәкилләре иҗатының, классик

һәм фольклор әсәрләренең мөһим проблемалары буенча эзләнүләр нәтиҗәсе буларак дөнья күрә. Әдәби тәнкыйтьнең аерым чорлардагы (нигездә, ХХ гасырның беренче чиреге) үсешенең теоретик һәм методологик мәсьәләләре буенча тикшеренүләр алып барыла (М. Мәһдиев, Э. Бариева, Р. Мөхәммәдиев һ.б.). Гомумән, бу чор татар әдәбият белеменең нигезен тәшкил иткән өч тармак буенча да бай фактик һәм теоретик материал туплана, бүген дә кыйммәтен югалтмаган тикшеренүләр алып барылып, методик алымнар, гипотезалар тәкъдим ителә, әмма аларны гомумиләштерү, закончалыклар, теоретик категорияләр рәвешендә нигезләү артка калып килә. Бу исә тикшеренүләрдә, сыйфаттан бигрәк, сан артыннан кууга, эмпирик характердагы эзләнүләрнең үсүенә китерә. Шул рәвешле, бер яктан, татар әдәбият фәнендә эчке каршылыкларның үсүе, аның заман таләпләреннән артка калуы, икенче яктан, ХХ гасыр ахырында социаль-мәдәни шартлар, әдәби процесстагы җитди үзгәрешләр татар әдәбият белеме методологиясенә караган мәсьәләләрнең көн тәртибенә куелуына һәм эзләнүләр башлануына этәргеч бирә.

Шуңа бәйле без сүз сәнгате белемендә фәнни-теоретик карашлар үзгәрешен ачыклауга киләбез. Әдәбият теориясендәге үзгәрешләрне тикшергән М.Г. Богаткина аны парадигмалар үзгәреше дип атый һәм әлеге терминга мондый аңлатма бирә: «Фәннең конкрет этапы үсешендә фәнни белемнең структурасын билгеләүче төшенчәләрнең, принципларның теоретик һәм методологик бергәлеге»[1]. Ул исә, беренче чиратта, яңа методологиягә нигезләнү белән бәйле булып, бер яктан, күчеш чоры үзенчәлекләре, икенче яктан, традицияләрнең дәвамчанлыгы, ягъни эчке закончалыклары һәм аларның үзгәрешенә нисбәтле яңа тенденцияләр барлыкка килү белән аңлатыла. Шул рәвешле, әдәбият турындагы фәннең үткән дәверләренә альтернатив булган фәнни теориясе формалашу процессы күзәтелә. Әлеге үзгәрешләргә китергән аеруча мөһим мәсьәләләрне карап үтик.

*Берсе* – ХХ гасыр ахыры татар әдәбият белеме методологиясенең нигез принципларын, тикшеренү юлларын, чараларын билгеләүдә күчеш чоры үзенчәлекләренә нигезләнү белән бәйле. Югарыда билгеләп үтелгәнчә, билгеле бер чиктәш халәтне, аңны чагылдыручы әлеге күренеш иске белән яңаның очрашуы, үзара керешүе, шул ук вакытта, алдагы күчеш чоры үзенчәлекләрен яңа баскычта кабатлавы, шуңа бәйле ул чорда читкә кагылган, «онытылган» сыйфат-билгеләрнең калкытылуы, аларның трансформацияләнүе белән характерлана. А.Н. Хренов күчеш чорларына кабатланып торучы түбәндәге сыйфатлар хас дип саный: 1. Дөнья картинасы алышынуы буларак, кешенең вакыт һәм урынны кабул итүе үзгәрү, ягъни күчешне әдәби вакыт һәм

[1] *Богаткина М.Г.* Теория литературы: Формирование новой научной парадигмы: учебное пособие. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2007. С. 11.

урын структурасындагы радикал үзгәрешләр озата бара. 2. Миф һәм архетип активлашу. 3. Иҗат культы күзәтелү, икенче төрле, күчеш – ул һәрвакыт озак вакытлар дәвамында җыелып килгән һәм чагылыш таба алмаган иҗат энергиясе шартлавы. 4. «Мәңгелек кайту» логикасы ачылу. Хаос ситуациясендә киләчәккә ыргылыш, прогресс кына түгел, бәлки кайчандыр булганның кабатлануы, яңаруы, ягъни регресс та була. 5. Тарихны эсхатологик кичерү. Ул халыкның менталь сыйфатлары белән бәйле күренеш. Әйтик, шәхеснең көнбатыш тибы яшәешкә тәртип кертергә омтылса, рус кешесе, максималист буларак, тормышны тамырдан үзгәртергә омтыла. Беренчеләр революциядән качса, икенчеләр шуңа омтыла. Татар кешесен әлеге ике төрле тип арасында торучы дип бәяләргә мөмкин. Аңа сабырлык, булган белән канәгатьләнү хас, ул кискен үзгәрешләргә дә омтылмый, шул ук вакытта, бер кузгалса, җитди үзгәрешләргә китереп чыгарырга да сәләтле. Милләт язмышына янаган «инкыйраз», этнос буларак юкка чыгу куркынычы әсәрләрдә ахырзаман җитү, катастрофа күренешләрен чагылдыру үрнәкләренең, эсхолатик образларның әледән-әле урын алуына китерә. 6. Шәхеснең маргиналь тибы активлашу. Күчеш чорларында ике дәвер һәм культура арасында калган иҗатчы ялгызлык халәтен кичерә, шуңа да ул еш кына маргинал тип сыйфатын ала. 7. Коллектив бертөрлелек кризисы. Җәмгыятьтә үзара ярдәмләшү, бергәлек күренеше бик нык кими. 8. Сәнгать төрләренең аерымлашуы һәм эстетик синтез теорияләре яңарышы. Сәнгать төрләренең бер-берсенә керешүе яңа дөнья картинасы өчен җирлек әзерли, соңгысы исә хаосны тәртип-яңарышка таба үзгәртә[1].

*Икенчесе* – XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы әдәбият белемендә, югарыда билгеләп үтелгәнчә, 1920 еллар ахырыннан башлап бөтен совет әдәбиятларында өстенлек иткән, марксизм-ленинизм идеологиясенә нигезләнгән берьяклы методологик карашлардан арыну тора. Озак вакытлар дәвамында бер идеалга ышанып, инанып яшәгән яисә бер төрле уйлап икенче төрле сөйләргә, язарга мәҗбүр ителгән язучы өчен ул нинди рухи газаплар алып килсә, сүз сәнгатен өйрәнүчеләрнең дә шундый ук хәлдә калуын аңлау кыен түгел. 1990 еллар дәвамында һәм әдәбиятның, һәм аның турындагы фәннең каршылыклы үсеш-үзгәрешенә китергән сәбәпләрнең берсе шул иде.

*Өченче* мәсьәлә әдәбият белеменең үткән мираска, традицияләргә мөнәсәбәтен билгеләү аша чагыла. Ул да җитди бәхәсләргә юл ача. Бер яктан, марксизм-ленинизм эстетикасы белән бәйле рәвештә тикшеренүләрдә берьяклылык, бертөрлелек, субъектив карашлар,

---

[1] *Хренов Н.А.* Опыт культурологической интерпретации переходных процессов // Искусство в ситуации смены циклов: Междисциплинарные аспекты исследования художественной культуры в переходных процессах / отв. ред. Н.А. Хренов. М.: Наука, 2002. С. 25–53.

купшы, аерым очракларда дәлилләнмәгән фикерләр урын ала. Шуның өстенә чит илләрдәге әдәбият белеме казанышларын кире кагу, тәнкыйтьләү күзәтелә. Икенче яктан, совет чорында дөнья күргән тикшеренүләрнең әһәмиятен күрми мөмкин түгел. Идеология басымын тойган хәлдә, вакыт сынавын үткән фәнни-теоретик нәтиҗәләргә ирешелә, шуңа да алардагы табышларга таяну мөһим бурычлардан санала. Ә инде 1917 елга кадәрге һәм 1920–1930 еллардагы күпсанлы хезмәтләр җитди өйрәнү объектына әйләнә: текстология эшләнә, яңалык-табышлары билгеләнә, әдәбият фәнендәге урыны һәм бүгенге өчен кыйммәте ачыклана[1]. Совет чорында әдәби тәнкыйть еш кына әдәби барышка яисә аерым әсәрләргә тема-проблема ягыннан бәя бирергә омтыла. Шул рәвешле «әһәмиятле темага», «актуаль темага», «көн кадагына сугып» дип аталган төшенчәләр активлаша. Шулар белән янәшә «авыл темасы», «производство темасы», «интеллигенция темасы», «сугыш темасы» һ.б. рәвешендә тематик бүленеш күзәтелеп, шуның сурәтләнеш дәрәҗәсе бәяләнә. Гасыр чигендәге әдәбият белемендә тема-мотивларны ачыклау урын алса да, сәнгатьчәлек мәсьәләсе алга чыгарыла.

Фәнни-теоретик фикердәге үзгәрешләрнең *дүртенче* сәбәбе китап укучы белән бәйле. Югарыда атап үтелгән күренешләр, билгеле инде, китап укучыга да көчле йогынты ясый. Совет чорында, бигрәк тә 1960–1980 елларда әдәбиятта ике юнәлеш барлыкка килә: берсе – җәмгыятьне, аның җитәкчеләрен, төзелешләрне һ.б.ны мактауга хезмәт итсә, икенчесе – гади халык мәнфәгатен, милли сыйфатларны чагылдыруны, кешенең шәхси тормышын кайгыртуны һ.б.ны алга куя, шуңа да төп фикерләр еш кына «эзоп теле» белән әйтелә, икенче катламга яшерелә. Шуларга бәйле китап укучылар да төрле була. Берәүләр вакыйга-күренешләргә бәйле чыгарылган объектив нәтиҗәләр, хәл-төшенчәләр белән чикләнсә, зәвыклы укучы исә икенче юнәлеш әсәрләрдәге төп фикерне юл араларыннан эзли. 1990 еллардан соңгы әдәбият китап укучының да үзгәрүен таләп итә,чөнки хәзер инде язучының позициясе турыдан-туры, әмма күптөрле сурәт чаралары ярдәмендә чагыла. Яшәешнең ямьсез яклары сурәтләнгән әсәрләрдә дә вакыйгалар, гадәттә, чынбарлыкка каршы куелмый, бәлки аның дәвамы булып кабул ителә, укучыны шул дөньяга алып кереп, күңелендә әрнү, борчылу хисе тудыра, аннан котылу юлын эзләүгә китерә.

Татар әдәбият белеменең методологиясе үзгәрешенә китергән сәбәпләрнең *бишенчесе* чит илләрдәге әдәбият белеме казанышлары

[1] *Галимуллин Ф.Г.* Эстетика һәм социологизм: 20–30 нчы еллар татар әдәбиятында эстетика кануннарының һәм социологизм таләпләренең үзара мөнәсәбәте. Казан: Мәгариф, 1998. 223 б.; *Заһидуллина Д.Ф.* Әдәбият кануннары һәм заман. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. 255 б.; *Галиева Э.Р.* Татар әдәбият белемендә культура-тарих мәктәбе. Казан: Фән, 2002. 360 б.; *Хайдаров Л.И.* Вопросы арабской литературы в татарском литературоведении начала XX века: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2004. 27 с.; *Гыйлаҗева Ч.* Әдәбият фәне һәм Габдрахман Сәгъди. Казан: Школа, 2012. 208 б. һ.б.

белән танышу мөмкинлеге тууга бәйле. Бигрәк тә Көнбатыш Европада һәм Америкада сүз сәнгате өлкәсендә алып барылган һәм аеруча әдәби мәктәпләр, әдәби концепцияләр, әдәби методлар өлкәсендәге эзләнүләр әдәбият белеменең барлык тармаклары турындагы карашларыбызны, тикшеренү объектларының асылын аңлатуны киңәйтеп җибәрә. Рус әдәбият белеме әлеге яңалык-табышларны кабул итүгә әзер булып, фәнни эзләнүләрнең яңа баскычына күтәрелә. Татар әдәбият белеме исә аларга шактый каршылыклы мөнәсәбәттә була. Моның берничә сәбәбе бар. Берсе – татар әдәбият фәненең үсеш-үзгәреш тарихы, ул билгеле бер традицияләре белән аңлатыла. XX йөз башы әдәбият белемендә реализм һәм романтизмның төп сыйфатлары ачыкланып, модернистик эзләнүләрнең нигезе барлана. Совет чорында (1990 елларга кадәр), нигездә, реализм һәм романтизм юнәлешләренә караган сәнгати фикерләү үзенчәлекләре өйрәнелә, ә инде бу кысалардан чыккан юнәлеш, агым, форма, чаралар я тискәре бәя ала, я читләтеп үтелә. Икенчесе – 1930 еллардан башлап әдәбият белеме марксистик-ленинчыл идеология кысаларына кертелә. Милләтчелектә гаепләнүдән куркып, әдәбиятчылар милли сыйфат-билгеләр, үзенчәлекләр турында гомуми планда гына язарга тырыша. Шундый шартларда рус фәненең йогынтысы бик нык үсеп, күп кенә мәсьәләләрдә татар әдәбият белеме ияреп бару яисә тәрҗемә итү юлына күчә. 1990 еллар башында, милли идея үсүгә бәйле, читләр тәэсиреннән котылу омтылышы да көчәя. Бу исә татар әдәбиятына, шул исәптән әдәбият фәненә хас сыйфатларны өйрәнү, калкытып кую, аларны алгы планга чыгару омтылышына китерә. Шул рухта рус һәм чит ил әдәбият белемендәге термин-төшенчәләрне, теоретик караш-фикерләрне кабул итүгә сак килү күзәтелә. Өченчесе – әдәбият белеме өлкәсендә эшләүчеләрнең караш-мөнәсәбәте, яңалыкларны кабул итәргә әзерлеге белән бәйле. Башкаларда урын алган күренеш-билгене яңа җирлеккә турыдан-туры күчереп куеп булмый. Ул, гадәттә, ясалмалылыкка китерә. Бу уңайдан Р. Сверигин фикерләре кызыклы: «Хәзер кайбер галимнәребез татар язучыларының аерым әсәрләрен дөнья әдәбиятындагы күренешләр, хәрәкәтләр, агымнар, методлар яктылыгына куеп карарга, аңлатырга тырыша башладылар. Бу – гомумән алганда, игътибарга һәм мактауга лаеклы күренеш. (...) Яшь тәнкыйтьчеләрне модага кереп килүче, әмма эчтәлекләре күпләргә бигүк ачык булмаган ялтыравыклы терминнар ныграк кызыксындыра торгандыр. Һәм менә шуннан соң инде татар әдипләре әсәрләреннән көчәнеп, тырышып модернизм яисә постмодернизм күренешләрен хәтерләткән элементлар табып, аларны бөтендөнья әдәбиятындагы шаукымнарның татар әдәбиятына килеп җитүе, аны баетуы, дип аңлатулар китә»[1]. Гомумән алганда, үткән чорларның

[1] Тарихыбыз тулымы? («Татар әдәбияты тарихы»ның 6 нчы томы басылып чыгу уңаеннан фикер алышу) // Казан утлары. 2003. № 5. Б. 134.

методологик прицпипларында тәрбияләнгән белгечләрнең бер өлеше авангард характердагы матур әдәбият әсәрләрен һәм аларны аңлап-бәяләргә омтылган фәнни-теоретик карашларны кабул итәргә әзер булмый. Мисал өчен, Т. Галиуллин реализм һәм романтизм юнәлешләре белән чикләнмичә, үзенчәлекле алым-чараларга, метафорик һәм символик күренешләргә, шартлылык һәм мифопоэтика алымнарына актив мөрәҗәгать иткән авторларның әсәрләрендә сурәтләү объекты булып торган «албастылар, убырлы карчыклар, канатсыз акчарлаклар, оча торган кешеләр, бичуралар, сары йортлар даирәсен»[1] кабул итмәвен белдерә. Дөрес, бу мәсьәләдә ике сорауны аерып кую кирәк: берсе – әлеге әсәрләрне кабул итү, уку, өйрәнү, әдәби процесстагы урынын билгеләү, икенчесе – аларны әдәбиятның өлге-үрнәге буларак тәкъдим итү. Югарыдагы язма авторы реалистик традицияләрдән үзгә әлеге төр иҗатның татар әдәбиятына җитди яңалык алып килүенә шикләнеп карый. Әмма яңа социаль-мәдәни шартларда тәрбияләнгән укучыларның күп булуын онытмыйк. Рус һәм чит ил әдәбиятлары әсәрләрен укып үскән әлеге укучылар татар әдәбиятыннан да күңеленә якын әсәрләр көтә. Шуңа да яңа төр әсәрләрне кире какмыйча, традицияләр һәм яңачалыкларга нисбәтле җентекле өйрәнү сорала.

Шундый шартларда алмашка нинди методологияне нигез итеп алырга соң? Фәнни эзләнүләрнең нигезендә әдәбият белеменең үзенә хас эчке закончалыклары үсеш-үзгәрешен, әдәби-тарихи процессны өйрәнүнең яңа эчтәлек белән баетылган принципларын берләштергән система булырга тиеш дип саныйбыз.

XX гасыр ахыры – XXI гасыр башында сүз сәнгате турындагы фәннең үз методологиясен эшләү кирәклеге дә көн тәртибенә куела. М. Хәсәнов билгеләп үткәнчә, «иң зур проблемаларның берсе – әдәбият белеменең, гомумән, татар әдәбият белеменең хосусан үз методологиясен булдыру зарурлыгы»[2]. Әлеге гаять катлаулы мәсьәләгә нисбәтле ике мөһим үзенчәлекне аерып кую кирәк. Берсе – әдәбият белеме фәненең дөньяви күренеш булуы белән бәйле. Сүз сәнгате кешенең иҗади эшчәнлеге нәтиҗәсе булып тора һәм ул аерым кешегә, халыкка гына түгел, бөтен кешелеккә хезмәт итә. Әдәби әсәрне иҗат итү һәм аның эчтәлек-төзелеше, яшәү рәвеше билгеле бер закончалыкларга нигезләнә. Шуның кебек үк, аларны фәнни тикшерү, бәяләү юллары, алымнары да, нигездә, уртак, бертөрле. Татар әдәбият белеме үзенең башлангычыннан алып хәзергәчә барлык халыклар өчен уртак булган иҗат закончалыклары, категорияләре һәм аларны өйрәнү принциплары белән эш итә. Икенчесе – матур әдәбият халыкның бер талантлы вәкиле тарафыннан

[1] *Галиуллин Т.Н.* Онытмадык сине, Фәрваз дус! // Мәдәни җомга. 2009, 7 авг.

[2] *Хәсәнов М.* Татар әдәбияты тарихын өйрәнүнең кайбер методологик мәсьәләләре // Казан утлары. 1992. № 1. Б. 142.

иҗат ителеп, үзендә аңа хас сыйфат-билгеләрне, ягъни халык тарихын, менталитетын, яшәү рәвешен яклаган һәм саклаган рухи кыйммәтләрен чагылдырган кебек, аларны тикшерү барышында да әлеге үзенчәлекләр исәпкә алынырга тиешлеге калкып чыга. Мисал өчен, Урта гасырлар татар әдәбияты үзенә хас тема-мотивлар, сурәт чаралары, жанрлар системасы булдыра. Бу яктан ул христиан дөньясы белән бәйле рус әдәбиятыннан кискен аерыла. Мисал өчен, Й. Нигъмәтуллина монографиясендә аларны төрле культура типлары буларак аерып тикшерә һәм гаять әһәмиятле нәтиҗәләр ясый[1]. Шуңа да татар әдәбият белеменең үзенә хас методологиясе дигәндә без бөтендөнья казанышларын файдалануны, аларны милли әдәбият үзенчәлекләре, сыйфат-билгеләр белән кушып-үреп баруны, билгеле бер дәрәҗәдә синтезлашуны күздә тотабыз. Ул исә, үз чиратында, түбәндәге җитди мәсьәләләргә ачыклык кертүне сорый.

Әдәбиятның милли үзенчәлекләрен ачу юлларына бәйле мөһим методологик мәсьәлә әдәбият белеменең *үсеш-үзгәреш тарихын* өйрәнүгә кайтып кала. Хәзерге татар әдәбият фәне буш урында барлыкка килми, ул үзенең башлангычыннан алып үткән чорлардагы табышларны һәм югалтуларны, яңарыш һәм торгынлыкны белеп-өйрәнеп кенә хәзергесенә дөрес бәя бирә һәм киләчәк үсеш перспективаларын билгели ала. Бу яктан ул традиция һәм яңачалык төшенчәләре белән тыгыз бәйле. Д. Заһидуллинаның татар әдәбият теориясенең формалашу чорын тикшергән «Әдәбият кануннары һәм заман» (2000) хезмәте бу өлкәдә җитди алгарыш була. Автор XX йөз башында татар әдәбият белеменең милли үзенчәлекләрне тикшерүгә алынуын, үзебезгә хас термин-төшенчәләр эшләнә башлавын ача. Ф. Галимуллин, Э. Галиева, Т. Гыйләҗев, Г. Азизова, Ч. Гыйлаҗева тикшеренүләрендә 1917 елдан соңгы әдәбият фәне, аерым алганда, аның 1920–1930 еллардагы хәл-торышы ачыклана. Л. Хәйдәров исә XX йөз башы әдәбият фәнендә гарәб әдәбияты мәсьәләләрен өйрәнә. Ә инде XX–XXI гасырлар чигендә дөнья күргән хезмәтләрдә (Й. Нигъмәтуллина, Р. Ганиева, Т. Галиуллин, Н. Хисамов, А. Әхмәдуллин, Х. Миңнегулов, Ф. Хатипов, Ә. Шәрипов, Р. Салихов, Н. Ханзафаров, Ф. Яхин, Ф. Бәширов һ.б.), шулай ук академик басма буларак «Татар әдәбият тарихы» ның алты томлыгында, сигезтомлык «Татар әдәбияты тарихы»ның 1–5 нче томнарында, әдәбият белеме буенча сүзлекләрдә, «Татар энциклопедиясе»ндә, мәктәп һәм югары уку йортлары дәреслекләрендә әдәбият фәне тарихына караган мәгълүматлар да урын ала.

Үзенең формалашуыннан алып үткән вакыт эчендә тупланган тәҗрибә, фәнни-теоретик карашлар, методологик принциплар хәзерге әдәбият белеменең ныклы җирлеге булып тора. Тикшерү объекты булган сүз сәнгате кебек үк, аның фәне дә үткән чорларның актуаль һәм

[1] *Нигматуллина Ю.Г.* Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. Казань: Фэн, 1997. 190 с.

кыйммәтле дип кабул ителгән, үзләштерелгән яисә иҗат ориентиры итеп алынган тәҗрибәсен файдалана. Шул рәвешле традицияләр дәвамчанлыгы барлыкка килә. Ул исә яңачалык белән турыдан-туры бәйле. Икенче төрле яңачалык озак вакытлар дәвамында формалашкан фәнни традицияләрне иҗади дәвам итүдән һәм үстерүдән аерылгысыз күренеш булып тора. Традиция һәм яңачалык, үзара диалектик бәйләнештәге төшенчәләр буларак, әдәбият турындагы фәннең эчке үсеше логикасына нигезләнә, шуның белән алар фәннең юнәлешен, тарихи үсеш закончалыкларын да билгели.

Әлеге мәсьәлә татар әдәбият белеме өчен аеруча мөһим, чөнки ул үзендә Көнчыгыш һәм Көнбатыш әдәбиятларыннан килүче традицияләрне саклый һәм үстерә. Әгәр фән тарихына мөрәҗәгать итсәк, үзенең башлангычында татар әдәбият белеме Көнчыгышның фәнни-теоретик карашларына нигезләнгән булуны күрәбез. Ә инде XX йөз башында рус-Европа эстетик фикере көчле агым булып килеп керә һәм фәндә үзенчәлекле синтез күзәтелә[1]. Бу чорда шактый киң урын алган «Шәрыкме? Гаребме?» бәхәсе 1920 елларда да дәвам итә[2]. Әмма идеология басымы һәм социаль-мәдәни шартлар йогынтысында Шәрык канаты читкә кагыла, өстенлек Гаребкә, беренче чиратта, рус әдәби-эстетик фикеренә бирелә. Алдагы чорларда татар әдәбият белеме, уртак рухи-мәдәни мохиттә яшәгәнлектән, рус фәне казанышларына йөз тота. Аның аша безгә дөнья әдәбият белемендәге яңалыклар да (нигездә Көнбатыштан) үтеп керә. Шул ук вакытта Көнчыгышның әдәби-мәдәни фикере тәэсире дә арта бара. Бер яктан, 1917 елга кадәрге фәнни мирасның кайтуы, дини, ярымдини трактатлар, әдәби әсәрләр, фәнни хезмәтләр, дәреслекләр аша Шәрыктан кергән фикер-карашларны өйрәнүгә юл ача, икенче яктан, татар әдәбиятының борынгы һәм урта гасырларына игътибар арту, аларның асылын билгеләгән дини, суфичыл һәм дөньяви-ренессанс карашларны яңа фәнни-эстетик принциплар яссылыгында бәяләү омтылышы әлеге дәвер әсәрләрен Шәрык-мөселман дөньясы белән тыгыз бәйләнештә өйрәнүгә китерә, өченче яктан, Шәрык әдәбиятының классик һәм хәзерге үрнәкләре бөтен дөньяда кызыксыну уятып, Гаребтә, шул исәптән рус фәнендә һәм күпгасырлык багланыш-

---

[1] *Халит Г.М.* Кешегә һәм чынлыкка мәхәббәт белән. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. 375 б.; *Халит Г.М.* Яңа гасыр поэзиясе: XX йөз башы (1905–1917 еллар) татар поэзиясендә иҗат методы, лирик герой, традиция һәм новаторлык мәсьәләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 166 б.; *Нуруллин И.З.* XX йөз башы татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. 288 б.; *Нигматуллина Ю.Г.* Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. Казань: Фэн, 1997. 190 с.; *Ганиева Р.К.* Татарская литература: традиции, взаимосвязи. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. 272 с.; *Заһидуллина Д.Ф.* Әдәбият кануннары һәм заман. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. 255 б. һ.б.

[2] *Галиева Э.Р.* Татар әдәбият белемендә культура-тарих мәктәбе. Казан: Фән, 2002. Б. 25–31.

ларны торгызу рәвешендә татар әдәбият белемендә өйрәнелүгә китерә. Бу исә фәнни-теоретик терминнарның, төшенчәләрнең кулланылуына һәм таралуына юл ача. Гомумән алганда, рус һәм Көнбатыш филологиясенең, шулай ук Көнчыгышның фәнни-теоретик фикерләрен, күптөрле концепцияләрне иҗади үзләштерү һәм аны татар әдәбият фәне белән кушу татар әдәбиятын өйрәнүнең яңа баскычына нигез булып тора.

Әлеге мәсьәлә әдәбият белемендә зур кызыксыну уяткан төшенчәне калкытып куя. Ул – әдәбиятны чагыштырма планда өйрәнүнең принципларын, методларын, юлларын ачыклауны максат иткән *чагыштырма-тарихи* әдәбият белеме белән бәйле. Сүз сәнгатен чагыштырма планда өйрәнүнең зур тарихы булып, ул теоретик һәм гамәли яктан шактый тулы ачылган[1]. Соңгысы исә, бер яктан, әдәби процесста урын алган төрле авторларны, шулай ук төрле дәверләрдә яшәп иҗат итүчеләр иҗатын, икенче яктан, төрле халыклар әдәбиятын, аерым әдипләрен үзара чагыштырып тикшерүне, үзара бәйләнешләрне ачыклауны күздә тота. XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы татар әдәбият белемендә аның уңышлы үрнәкләре дөнья күрә[2]. Әлеге төр тикшеренү милли әдәбиятның үзенчәлекләрен яңа яссылыкта ачарга, эзләнүләрнең төрен, тирәнлеген, төп тенденцияләрен чагыштырып бәяләү аша, аның кардәш халыклар, илкүләм, шулай ук гомум әдәби процесстагы урынын билгеләргә, табышларны һәм югалтуларны ачыкларга мөмкинлек бирә. Соңгы елларда чагыштырма әдәбият белеменең яңа якларын ачу омтылышлары ясала. Әлеге мәсьәләне максатчан өйрәнгән М.Г. Богаткина фикеренчә, бер яктан, күчеш чоры үзенчәлекләре, икенче яктан, әдәбият үсеш-үзгәреше закончалыкларын өйрәнүдә диахрон аспекттан аларның синхрон диалогик табигатен ачуга күчү, өченчедән, тарихи принципның аерым сыйфат-билгеләре үзгәрү моңа этәргеч бирә. Чагыштырма әдәбият белеме компаративистиканың яңа этабы булып оешып килә. Ул термин-төшенчәләрнең яңаруы, заманча, аерым алганда интертекстуальлек күренешен ачуга бәйле методикаларны үзләштерү

[1] Русско-татарские литературные связи (проблемы сопоставительного исследования): Библиографический указатель / сост А.З. Хабибуллина, М.М. Сидорова. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1999. 184 с.; Основы сравнительного и сопоставительного литературоведения: учеб. пособ. по спецкурсу для студентов специализации «Русский язык и лит-ра в межнациональном общении» / авт.-сост. В.Р. Аминева; научн.ред. Д.Ф. Загидуллина. Казань: Казан. гос.ун-т, 2007. 48 с.

[2] *Миннегулов Х.Ю.* Татарская литература и Восточная классика (Вопросы взаимосвязей и поэтики). Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1993. 384 с.; *Нигматуллина Ю.Г.* Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. Казань: Фэн, 1997. 190 с.; *Ганиева Р.К.* Татарская литература: традиции, взаимосвязи. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. 272 с.; *Кадыров О.Х.* Роль Л.Н. Толстого в становлении и развитии татарской реалистической литературы: дис. ... д-ра филол. наук. Казань, 1996. 330 с.; *Харрасова Р.Ф.* Әдәби бәйләнешләр яктылыгында. Казан: Изд-во РПФ «Гарт», 2002. 261 б.; *Ибрагимов М.И.* Миф в татарской литературе XX века: проблемы поэтики. Казань: Гуманитария, 2003. 64 с. һ.б.

һ.б. белән аңлатыла[1]. Киң планда караганда, татар әдәбият белемендә әлеге мәсьәлә аз өйрәнелгән өлкә булып кала, шуңа да, перспективалы юнәлеш буларак, алга таба җитди тикшеренүләр алып бару бурычы тора. Д. Заһидуллина билгеләп үткәнчә, «әдәбиятларны чагыштырма-янәшә куеп өйрәнү, рус һәм татар әдәбиятларын гына түгел, бәлки татар әдәбиятын төрки әдәбиятлар белән чагыштырып тикшерү»[2] заман таләбе булып тора.

Сүз сәнгатенең табигатен, сыйфат-билгеләрен, үсеш закончалыкларын, төзелешен, аны бәяләү принципларын, шулай ук әдәби иҗат үзенчәлекләрен һәм әдәби процесс закончалыкларын өйрәнүче әдәбият теориясенең төрле аспектлары җитди үзгәреш кичерә. Югарыда билгеләп үтелгәнчә, идеологик ориентирлар юкка чыгу белән тарихта гына калган партиялелек, сыйнфыйлык кебек төшенчәләр иҗат тибы, иҗат методы, иҗат юнәлеше кебек мәсьәләләр буенча бәхәсләргә, фикер алышуларга китерә. Аерым алганда, татар әдәбиятының тарихи үсешендә читтә калдырып киленгән классицизм, сентиментализм һәм модернизм кебек иҗат юнәлешләрен өйрәнүдә эзләнүләр башлана. Татар әдәбиятында аларның билгеле бер урын алуы, әмма алдагы чорларда аерым сәбәпләр, нигездә, фәнни-теоретик фикернең артка калуы аркасында тиешенчә тикшерелмәүләре билгеләнә. Шул уңай белән хәзерге татар әдәбият белемендә бер мөһим принцип алга чыга: ул – әдәби күренешләрнең *кабатланып килүе*, яңа баскычта үсеп яңаруы. Югарыда тукталып үтелгән күчеш чоры үзенчәлекләре дә әлеге фикерне тулыландыра. Аны татар әдәбиятындагы мөһим тенденцияләрнең кабатланып килүендә дә күрергә була. Р. Ганиева фикеренчә, татар әдәбияты Урта гасырларда (XIII–XV йөзләр), Шәрык классик әдәбиятының көчле йогынтысында, беренче яңарыш (ренессанс) чорын кичерә[3]. XX йөз башында ул яңарышның икенче дәверенә керә. Кызганыч ки, тарихи-сәяси сәбәпләр (XVI гасырда рус дәүләтенең басып алуы һәм 1917 елда пролетариат диктатурасы урнашу) аркасында әлеге үзгәрешләр тукталып кала. Галимнәр фикеренчә, XX гасыр ахырында татар әдәбиятының өченче яңарышы башлана[4].

---

[1] *Богаткина М.Г.* Теория литературы: Формирование новой научной парадигмы: учебное пособие. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2007. С. 30.

[2] *Загидуллина Д.Ф.* Изучение истории татарской литературы в XXI веке // Татарская культура в контексте европейской цивилизации. Казань: Ихлас, 2010. С. 11.

[3] *Ганиева Р.К.* Восточный Ренессанс и поэт Кул Гали. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1988. С. 139–140.

[4] *Ганиева Р.К.* Ф. Бәйрәмова иҗатына лаеклы хезмәт // Шәмсутова А.А. Фәүзия Бәйрәмова прозасы. Казан: Гуманитария, 2004. Б. 5–10; *Миңнегулов Х.Й.* Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 367 б. *Заһидуллина Д.Ф.* Яңа дулкында (1980–2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык). Казан: Мәгариф, 2006. 255 б.; *Шәмсутова А.А.* Хәзерге татар әдәбиятында яңарыш. Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. 205 б.

Фикер алышуларда иҗат методына бәйле карашларның трансформацияләнүе билгеләнә: тәнкыйди реализм төшенчәсеннән баш тартып, аны «классик реализм» белән алыштыру омтылышы; соцреализмнан соңгы реалистик әдәбият үрнәкләрен билгеләүдә төрлелек булып, күчеш чорына хас атама рәвешендә «постреализм»ны куллану; әдипләрнең эзләнүләренә нигезле «милли реализм», «мифик реализм», «психологик реализм» һ.б. терминнарга мөрәҗәгать итү һ.б.

Әдәбият теориясенең үзәген тәшкил иткән поэтика компонентлары да яңа эчтәлек белән байый. Әдәби әсәрнең гаять мөһим элементы булган әдәби образ, аның төр һәм төркемнәре, төзелеше даими игътибар үзгендә торса да, хәзерге әдәбият белемендә эстетик функцияләрен, шулай ук аерым методларга, юнәлеш-агымнарга нисбәтле эчтәлеген һәм әсәрнең башка элементлары белән бәйләнешен ачу, аларны яңа төшенчәләр белән белдерү аеруча активлашты. Әлеге һәм башка (пафос, жанр һәм жанр төрләре, интертекстуальлек һ.б.) компонентларның үзгәрешен өйрәнү дә җитди мәсьәлә булып тора.

Методологиягә караган мөһим мәсьәләләр арасында татар әдәбият белеменең үзенә хас *принципларын* аерып чыгару үзгә урын тота. Билгеле инде, үзара якын әдәби-мәдәни мохиттә яшәгәнлектән, татар әдәбият белеме рус һәм башка халыклардагы фәнни казанышларны үзләштерә, аларга йөз тота. Әдәбият теориясенә, әдәбият тарихына, әдәби тәнкыйтькә караган хезмәтләрдә характерлы билге-күренешләрне билгеләү, тенденцияләрне аерып чыгару өчен дөньякүләм кабул ителгән методологик принципларга нигезләнү табигый күренеш. Шуның белән бергә, соңгы ике дистә елда татар әдәбият белеменең үзенә хас методологик принципларын ачыклау буенча аерым хезмәтләр дөнья күрде[1]. Алар, нигездә, әдәбият тарихын яңача өйрәнүне күздә тотсалар да, методологик планда бөтен әдәбият белеменең нигезен билгеләүче сыйфатлар булып ачыла. Ф. Мусин болай дип яза: «Инде халыкның иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни-рухи үткәнен милли идея яссылыгында

[1] *Хәсәнов М.* Татар әдәбияты тарихын өйрәнүнең кайбер методологик мәсьәләләре // Казан утлары. 1992. № 1. Б. 141–147; *Әхмәдуллин А.* Татар совет драматургиясен яңача өйрәнү мәсьәләләре // Дөреслеккә ирешү юлында. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. Б. 7–16; *Галиуллин Т.* Татар поэзиясе тарихын яңача өйрәнү мәсьәләләре // Шигърият баскычлары. Казан: Мәгариф, 2002. Б. 9–19; *Мусин Ф.* Әдәбиятны ничек өйрәнергә? // Мәдәни җомга. 1995. 22 декабрь; *Мусин Ф.* Татар әдәбияты тарихы һәм заман // Мирас. 1996. № 1–2. Б. 18–29; *Мусин Ф.* Әдәби хәрәкәт // Мирас. 1996. № 5–6. Б. 104–124; *Мусин Ф.* Әдәбият фәне һәм тәнкыйть // Мирас. 1996. № 12. Б. 38–47; *Мусин Ф.* Вакыт үзе куя бәһане // Мәдәни җомга. 2004, 7 май; *Хисамов Н.* Яңача фикерләү һәм татар әдәбияты концепциясе // Хәтер сагында. Казан: Мәгариф, 2004. Б. 9–12; *Миннегулов Х.* Основные тенденции развития современной татарской литературы // Фәнни язмалар – 2004. Казан: РИЦ «Школа», 2005. Б. 165–173; *Миңнегулов Х.* Мөнәсәбәтебезне ачык белдерик // Мәдәни җомга. 2006, 1 сентябрь; *Заһидуллина Д.Ф.* Милли реализм юлыннан // Казан утлары. 2003. № 6. Б. 134–147; *Заһидуллина Д.Ф.* Дәресләрдә әдәби-тарихи күзаллау // Мәгариф. 2004. № 11. Б. 35–37 һ.б.

өйрәнүнең төгәлрәк методологик принциплары мәсьәләсенә килсәк, монда, безнең карашча, барыннан да элек, тарихилык һәм миллилек турында сүз алып барырга кирәктер»[1]. Дөрес, әлеге принциплар яңа түгел. *Тарихилык* сүз сәнгате тарихына мөнәсәбәттә XX йөз башында ук куела һәм ул әдәбиятны эзлекле үсеп-үзгәреп торучы, җәмгыять тормышы белән тыгыз бәйләнештә булган, билгеле бер закончалыкларга буйсынучы, традицияләрнең яңачалыклар белән үрелеп баруына нигезләнүче күренеш буларак аңлатыла. А. Веселовский, А. Бушмин, Ю. Борев һ.б.ның хезмәтләрендә ул теоретик һәм гамәли ачылышын таба[2]. Күчеш чоры үзенчәлекләре тарихилыкны яңа эчтәлек белән баета. Ике гасыр чигендә яшәүче китап укучы төрле чор әсәрләрен кабул иткәндә, үз заманына хас социаль-мәдәни һәм фәлсәфи-эстетик сыйфатларга нигезләнеп, яңа диалогик бәйләнешкә, мөнәсәбәткә килеп керә. Бу исә әсәр язылган чорның укучы өчен яңа мәгънәләр ачуына китерә. Шул ук вакытта «башлангыч» фикерләрнең дә әһәмияте юкка чыкмый. Киресенчә, әлеге ике төрле караш, бер яктан, үзара берсен берсе баетып, яңадан яңа мәгънәләргә юл ача, икенче яктан, әсәрнең үз вакытындагы һәм хәзерге өчен кыйммәтен ачып, вакыт сынавына мөнәсәбәтен, эчтәлегенә салынган фикерләрдә авторның күрәзәчелеген билгеләргә мөмкинлек бирә. Билгеле инде китап укучының активлыгы, әсәрне кабул итү, бәяләүдәге төрлелек тарихилыкның чикләрен киңәйтүгә хезмәт итә. Гомумән, тарихилык яңа эчтәлегендә әдәби әсәрнең авторы белән, сурәтләнгән вакыйга-күренешләрнең рухи-мәдәни тормыш белән, тема-мотивларның эзлекле үсеше һ.б. белән бәйләнешен туларык аңларга ярдәм итә. Мисал өчен, Ф. Мусин әлеге принципның мәгънәләрен тагы да киңәйтеп, бер яктан, әдәбиятның аерым чорлары арасындагы үзара бәйләнешнең асылын нигезләсә, икенче яктан, «халкыбыз тарихы белән рухының үзенчәлекле елъязмасы һәм көзгесе булуы сәбәпле, әдәбиятны үзалдына гына карау җитми, аны милли тарих, тел, халык иҗаты, иҗтимагый-фәлсәфи фикер үсеше һәм башкалар белән бәйләнештә дә өйрәнергә кирәк»[3], дип саный.

*Миллилек* принцибы 1917 елга кадәрге әдәбият белемендә киң урын алса да, Совет чорында аның эчтәлеге, гадәттә, соцреализм эстетикасы эчендә генә билгеләнә иде. Шуңа да, гаять әһәмиятле принцип булудан бигрәк, теге яки бу халык әдәбиятының бер үзенчәлеге рәвешендә күрсәтелеп килде. Хәзер исә миллилек принцибы әдәбият турындагы

---

[1] *Мусин Ф.* Татар әдәбияты тарихы һәм заман // Мирас. 1996. № 1–2. Б. 18.

[2] *Веселовский А.Н.* Историческая поэтика. М.: Высшая школа, 1989. 404 с.; *Бушмин А.С.* Наука о литературе: Проблемы. Суждения. Споры. М.: Современник, 1980. 334 с.; *Борев Ю.Б.* Введение в теорию литературы // Теория литературы. Т. 1. Литература. М.: ИМЛИ им. М. Горького РАН, 2005. С. 3–27 һ.б.

[3] *Мусин Ф.* Татар әдәбияты тарихы һәм заман // Мирас. 1996. № 1–2. Б. 20.

фәнне халык язмышы, аның бүгенгесе һәм киләчәге, менталь сыйфатлары белән тыгыз бәйләнештә һәм милли идеягә нигезләнеп өйрәнүне күздә тота.

Әдәбият мәдәни-тарихи чынбарлыкны аның күппланлылыгында һәм байлыгында сурәтли. Бу – төрле халыклар, милләтләр, диннәр һ.б. тормышын үзләренә хас үзенчәлекләрдә чагылдыру белән бәйле. Теге яки бу милләт яшәешенең сүз сәнгатендә сурәтләнеше, әлеге халыкның мәдәни байлыгын барлауга, аны яклауга һәм саклауга хезмәт итә. Нәкъ менә милләт, тел, ватан мәсьәләләренең киң чагылышы әсәрләрне үзара охшашлыктан азат итә һәм, киресенчә, яңа, еш кына, экзотик тормыш рәвеше, үзгә йола-гадәтләр, традицияләр алып килүе белән кызыклы, мәгънәле булуын, димәк, бүгенге һәм киләчәк өчен әһәмиятен билгели.

1990 еллардан татар әдәбияты тарихын өйрәнү, теге яки бу әдип иҗатын, киң планда әдәби процессны бәяләү, нигездә, миллилек төшенчәсенә нисбәтле алып барыла. Халыкның киң катламында милли үзаң уяну милләт язмышына, аның үткәненә, бүгенгесенә игътибарны арттырып, киләчәге турында уйлануны үзәккә куя. Шундый шартларда әдәби мирас белән кызыксыну артып, бер яктан, борынгы, урта гасырларның күпсанлы ядкәрләрен укучыга кайтару, совет чорында хасил булган «ак таплар»ны бетерү башланса, икенче яктан, төрле чорлардагы рухи мирасны марксистик-ленинчыл идеологиядән арындырып, асылда миллилек идеясен калкытып куеп өйрәнү алга чыга. Әлеге мәсьәләгә бәйле әдәби-публицистик һәм фәнни телгә «инкыйраз» һәм «маңкорт» төшенчәләре килеп керә. Әгәр беренчесе Г. Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрендә сурәтләнгән вакыйгаларга нисбәтле булып, милләткә янаган куркынычны, бетү, юкка чыгу, ассимиляцияләшүне аңлатса, икенчесе Ч. Айтматовның «И дольше века длится день» («Буранный полустанок») романында сурәтләнгән акылын югалту аркасында үз анасын үтергән егеткә бәйле милләтеннән баш тартучы, телен, традицияләрен, гореф-гадәтләрен белмәүче, алардан йөз чөерүче кешене белдерә. Ике гасыр чигендә күпсанлы әсәрләр дөнья күреп, аларда милли яшәү рәвеше үзәк урынны били. Миллилек бөтен әсәрне иңләп үтүче лейтмотивка әйләнә, геройлар характерын сугара (Р. Мөхәммәдиев «Сират күпере», Р. Батулла «Сөембикә», М. Хәбибуллин «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный», Ф. Садриев «Таң җиле», Ф. Латыйфи «Хыянәт» һ.б.). Аерым авторлар милли идеяне әсәрнең кыйммәтен билгеләүче төшенчә итеп тә карыйлар. Танылган язучы А. Гыйләҗев болай дип яза: «Әдәбият, асыл әдәбият, тарихка багана булып басарлык әдәбият бары тик милли генә була ала»[1].

---

[1] *Гыйләҗев А.* Көндәлекләр (1992–1993) // Сайланма әсәрләр: 6 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. Б. 115.

Әдәбият белеменә караган миллилек принципбы берничә аспектны үз эченә ала. Беренчесе – милли әдәбият тарихының төзек, эзлекле системасын булдыру. XX гасыр дәвамында татар әдәбиятының, борынгы чорларыннан алып, якынча 1990 елларына кадәрге дәверен үз эченә алган тарихы эшләнә. Ул «Татар әдәбияты тарихы»-ның алты томлыгы (1984–2001), «Средневековая татарская литература (VIII–XVIII вв.)» (1999), «История татарской литературы нового времени (XIX – начало XX вв.)» (2003) кебек академик басмаларда һәм күпсанлы монографик тикшеренүләрдә чагылыш таба. Гаять зур, җитди эш башкарылса да, бу өлкәдә хәл итәсе, өйрәнәсе мәсьәләләр күп әле. XX гасырның 90 нчы елларына кадәрге хезмәтләрдә әдәбият тарихы, нигездә, диахроник планда, ягъни чор-дәверләр, этаплар, әдипләр иҗаты хронологик тәртиптә өйрәнелде. Әдәби мирасны синхроник планда, ягъни иҗат юнәлешләре, агымнары, стиль үзенчәлекләре һ.б.га нисбәтле тикшерү аның яңа якларын, үзенчәлек-тенденцияләрен ачу мөмкинлеге бирә. Ике гасыр чигендәге аерым хезмәтләрдә (Р. Ганиева, А. Саяпова, Д. Заһидуллина, А. Шәмсутова һ.б.) бу өлкәдә җитди яңалыклар булса да, бурычлар тагы да зуррак. Ә инде Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнә торган татар әдәбияты тарихының яңа сигезтомлыгы әлеге мәсьәләдә алгарыш булыр дип ышанасы килә. 1 нче томның «Кереш»ендә әйтелгәнчә, «бер яктан, үсеп килгән буыннарның игътибарын милләтебезнең меңьеллык асыл рухи хәзинәсенә юнәлтү, әдәбиятыбызга бүгенге фән югарылыгыннан торып бәя бирү һәм, икенче яктан, әлеге кыйммәтләр янәшәсендә яңа заман тудырганнарны кушу, рухи мирасыбызны бөтен тулылыгында күрсәтү кичектергесез бурыч булып көн тәртибенә басты»[1].

Икенче аспект – милли үзенчәлекләрне калкытып куюга, аерып чыгаруга, аларны вакыйга-күренешләргә, образ-характерларга үреп бирүгә хезмәт итә торган алым-чараларны билгеләү һәм бәяләү. Язучы, теге яки бу милләтне кайсы да булса җир-төбәккә бәйле яшәү рәвешендә формалаштыручы буларак, үзенә якын булган, үзе яхшы белгән, уй-хыялында йөрткән этнографик детальләрне, йолаларны, гореф-гадәтләрне, үзара мөнәсәбәтләрне чагылдыра. Ягъни, ул, бер яктан, аларның кирәклеген, мөһимлеген ачса, икенче яктан, шулар ярдәмендә әсәр үзәгендә торган концепцияне аңлата, автор позициясен билгели, геройларны шуларга «төреп» бирә. Халыкның милли сыйфат-билгеләре бик борынгыдан, аның башлангычыннан ук формалаша. Бу исә әдәби әсәрләрдә мифология һәм фольклордан килүче образларга, хәл-күренешләргә, символ-билгеләргә һ.б.га актив мөрәҗәгать итүгә китерә. Г.Д. Гачев язганча, «милли табигать һәм рух үз балалары-

[1] *Рахмани Р.* «Татар әдәбияты тарихы»ның сигезтомлыгына гомуми күзәтү // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 1 т.: Борынгы чор һәм Урта гасырлар. Казан: 2014. Б. 7.

ның интеллектын һәм иҗади хыял дөньясын сугара, үзгә архетиплар, үзенчәлекле интуицияләр, кабатланмас образлар, гадәттән тыш ассоциацияләр белән тәэмин итә»[1]. Өченче аспект – үткән чордагы һәм хәзерге әдәби процесска бәя биргәндә сүз сәнгате әсәренең милли үзенчәлекләрен аерып чыгаруга хезмәт итүче методларга, мәктәп-юнәлешләргә нигезләнү. Әдәби әсәрне анализлау юллары күптөрле, шулай да гасырлар дәвамында тупланып килгән тәҗрибәгә нигезләнеп, соңгы ике гасырда әдәбият белеме «сәнгать төре буларак әдәбиятны һәм әдәби әсәрне билгеле бер теоретик караш ноктасыннан»[2] тикшерүнең фәнни юнәлешләрен, мәктәпләрен, методларын формалаштыра. Аларның һәрберсенең үзенә хас фәнни-теоретик нигезе булып, шул яссылыкта әдәби әсәрнең яңадан-яңа якларын ачу мөмкинлеге туа. Шуңа да киң планда һәрбер юнәлеш-мәктәп-метод әсәр эчтәлегенә салынган милли сыйфат-билгеләрне аерып чыгарырга һәм бәяләргә ярдәм итә. Шуның белән бергә, әсәрнең эчке хасиятләрен ачу, милли үзенчәлекләрне сурәтләү максатында автор кулланган алым-чараларны максатчан анализларга этәргеч бирә торган юнәлеш-методлар булуын да күрми мөмкин түгел. Карашыбызча, бу мәсьәләдә өстенлек культура-тарих мәктәбенә, мифопоэтикага, психоаналитик методка, чагыштырма анализга бирелә. Аларның фәнни нигезләрен искә төшерсәк, культура-тарих мәктәбенең мәдәният эзләренә, тарихи катламнарга мөрәҗәгать итүе, шуларда урын алган тема-мотив-образларны алга чыгаруы әсәрдә урын алган милли билгеләрне игътибар үзәгенә куя. Мифопоэтика исә мифологик күзаллауларны, архетипларны барлый, шуңа нисбәтле милли башлангычтагы мифик образлар, символлар миллилек төсмере булып китә. Психоаналитик метод кешенең аң төпкелендә күмелеп яткан, әмма билгеле бер шартларда аның эш-гамәле белән идарә итүче билгеләрне ача. Бу исә кешенең милли сыйфатларын калкуландырырга, ментальлеген ачу һәм бәяләүгә җирлек тудыра. Чагыштырма метод төрле шартларда, чорларда, халыкларда туган әсәрләрне чагыштырып бәяләүне алга куя. Бигрәк тә соңгысына бәйле милли үзенчәлекләрне, аларның чагылышын, геройларны характерлаудагы урынын билгеләүгә шартлар тудыра. Гомумән, юнәлеш-метод-мәктәпләргә нигезле гамәли эзләнүләрнең башлануы уңай күренеш. Д. Заһидуллина, В. Әминева, М. Ибраһимов тарафыннан чыгарылган методик кулланмада[3] әлеге эшнең уңышлы үрнәге тәкъдим ителә. Кабаттан искәртеп үтик, бу

---

[1] *Гачев Г.Д.* Национальные образы мира: курс лекций. М.: Академия, 1998. С. 12–13.

[2] *Заһидуллина Д.Ф. һ.б.* Әдәби әсәр: Өйрәнәбез һәм анализлыйбыз: урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма. Казан: Мәгариф, 2007. Б. 3.

[3] *Заһидуллина Д.Ф. һ.б.* Әдәби әсәр: Өйрәнәбез һәм анализлыйбыз. Казан: Мәгариф, 2007. 112 б.

башка методларны читләтү дигән сүз түгел. Мисал өчен, без биографик методны атамадык, әмма аның асылын билгеләгән карашлар, аерым алганда, әдипнең тормыш юлы, нәсел-нәсәбе, туган җире, күптөрле биографик фактлар әсәрнең язылуына, эчтәлек-структурасына гына түгел, бәлки миллилек төшенчәсенә, автор позициясен аңлауга да хезмәт итә. Д у р т е н ч е   а с п е к т миллилекнең диалогик характеры белән бәйле. Кешелек җәмгыятен, тормыш-чынбарлыкны әдәби танып-белү милли һәм гомумкешелек кыйммәтләрен ачу, аңларга омтылу булып тора. Чөнки әлеге ике төшенчә үзара керешеп, бер-берсен тулыландырып килә. Милли хис халыкның күпгасырлык тәҗрибәсенә, яшәү рәвешенә, язылмаган, әмма буыннан-буынга күчеп килә торган рухи-әхлакый кануннарына нигезләнә икән, кешеләр арасындагы үзара мөнәсәбәтне билгеләүче әлеге кануннарның төп өлеше бөтен халыклар өчен уртак. Л. Толстой һәм Ф. Достоевский, В. Шекспир һәм А. Дюма, Ч. Айтматов һәм О. Сөләйманов һ.б. бик күпләрнең иҗаты гомумкешелек кыйммәтләрен яклавы, саклавы һәм үз халыкларына хас гаҗәеп серле, үзенчәлекле милли дөньяларны ачулары өчен бөтен кешелек дөньясы тарафыннан югары бәяләнә. Алар янәшәсендә Кол Гали һәм Мөхәммәдъяр, Г. Тукай һәм Г. Исхакый, Һ. Такташ һәм М. Җәлил, Х. Туфан һәм С. Хәким кебек дистәләрчә әдипләребезне милли җанлы булулары, шул ук вакытта һәркем өчен изге булган төшенчәләрне яклавы өчен хөрмәт итәбез, аларга сокланабыз.

Әдәбият турындагы фәннең *термин-төшенчәләрен* куллануда да төрлелек күзәтелә. Бу, бер яктан, татар сүз сәнгатенә бәйле методологик мәсьәләләрнең аз өйрәнелүе, икенче яктан, өстенлекле рәвештә рус әдәбият белеменә нигезләнү, фәнни терминнарны шуннан алу, өченчедән, борынгы чорлардан килүче, ягъни Шәрык белән бәйле төшенчәләрнең дә кулланылышта булуы белән аңлатыла. 1990 еллардан соң дөнья күргән хезмәтләрдә терминологияне системага салу, татар сүз сәнгатенә хас үзенчәлекләрне атау-аңлату омтылышлары ясала. «Әдәбият белеме сүзлеге»н (1990) казаныш буларак билгеләп үтү кирәк. Х. Миңнегулов, Й. Нигъмәтуллина, Р. Ганиева, М. Бакиров, А. Саяпова, Д. Заһидуллина, Э. Галиева, Ф. Хатипов, Ч. Зарипова, В. Макарова, А. Саттарова, А. Шәмсутова, Т. Гыйләҗев, Н. Йосыпова һ.б.ның китаплары, дәреслекләре дә терминнар мәсьәләсен ачыклауга җитди өлеш кертә. XXI гасыр башында басылып чыккан «Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге»ндә (2007) татар әдәбияты тарихын, теориясен, тәнкыйтен дөнья әдәбият белемендә кабул ителгән һәм үзебезгә хас милли сыйфатларга ия терминнар ярдәмендә ачу-аңлату максат итеп куела. Әлеге хезмәтләрдә, бер яктан, татар әдәбиятына хас милли үзенчәлекләрнең терминологиясен эшләү буенча җитди адым ясала, икенче яктан, XX йөз башы татар әдәбиятында үзенчәлекле юнәлеш булып үсә

башлаган, совет чорында исә өзелеп калган модернизм агымнарының, аларга хас алым-чараларның, мотивларның һ.б.ның милли җирлеккә бәйле сыйфат-билгеләре күрсәтелә, әйләнешкә кертелә, өченчедән, татар әдәбиятын өйрәнүдә төрле методларга, концепцияләргә нигезләнү үрнәкләре барлана, аның башка халыклар әдәбиятларында урын алган үзенчәлекләрне, аерым тенденцияләрне ят итмәве, ягъни татар сүз сәнгатенең дә төрле юнәлеш-агымнарга нисбәтле эзләнүләр алып баруы билгеләнә. Шуның белән бергә, татар әдәбият белеме терминологиясе буенча эзләнүләрнең дәвам ителергә тиешлеге дә бәхәс уятмый. Мисал өчен, термин-төшенчәләрне куллануга бәйле әдәби күренешләрне «күчереп утырту» күзәтелмиме дигән сорау әледән әле калка. Аңлатмаларны ничек кулланырга: тәрҗемә итепме, әллә алынган телдәгечәме? Әйтик, «интерпретация» терминын шул рәвештә дә, татарчага тәрҗемә итеп «шәрехләү» дип тә куллану очрый. Борынгыдан бирле татар сүз сәнгатенә нисбәтле кулланылып килгән «шәрехләү» төшенчәсенең мәгънәсе үзгәрәк. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә ул «аңлату», аңлатып бирү», «төшендерү» дип бирелә[1]. «Интерпретация» төшенчәсе әсәр текстын сайлап, иҗади кабул итүне, аңлатуны белдерә, шуңа да рухи активлык белән бәйле. Ул танып-белүгә һәм аның субъективлыгына юнәлгән, чөнки үз карашын, мөнәсәбәтен белдерүне таләп итә. Башкача әйткәндә, интерпретация һәм танып белүгә, һәм «яңача иҗат итүгә» (досотворение) юнәлгән. Өйрәнүче аңланыла торган текстка өстәмә ачыклык кертә, билгеле әйбернең яшерелгән мәгънәсен таба. Шуңа да «шәрехләү» төшенчәсен әлеге фикерләр белән баетып аңлау сорала. Икенче яктан, әдәбият белеменең әлеге терминнар белән аталган төшенчә-категорияләре эчтәлеге дә үзгәреш кичерә. Билгеле инде, нигез принциплардан саналган партиялелектән, сыйфныйлыктан баш тарту эзсез калмый. Соңгысына бәйле иҗат методы, иҗат тибы, иҗат агымы кебек төшенчәләрне ничек бәяләргә, аңлатырга дигән сораулар калка. Сүз әлеге төшенчәләрнең трансформацияләнүе, ягъни чорга хас яңа эчтәлек белән баюы турында барырга тиеш. Соңгы елларда фәнни әйләнешкә кергән категорияләрдән автор образы һәм аның әсәрдә чагылышы, әдәби иҗатның диалогик характеры, «герменевтик түгәрәк», «көтү сызыгы», дискурс һ.б. әдәби әсәрне бәяләүне бермә-бер киңәйтеп җибәрә. Аңлашылса кирәк, әлеге һәм башка төшенчәләрне куллану үзара бәйлелектә, бер системада гына тулы максатына ирешә. Ул исә, үз чиратында, яңа теоретик категорияләрне, бигрәк тә татар әдәбиятына хас күренешләрне ачык-төгәл аңлатуга хезмәт итү юлларын эзләүне таләп итә.

---

[1] Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: өч томда. III том. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. Б. 535.

Әдәбият белеменең фәнни-теоретик мәсьәләләре арасында әдәби тәнкыйть, аның асылы, функцияләре, әдәби процесстагы урыны, төрләре һәм типлары, жанрлар системасы һ.б. мөһим урын алып тора. Ул аеруча күп бәхәсләр уяткан һәм тәнкыйтькә дучар булган тармак булып кала. Бу, беренче чиратта, аның үз вазифаларын үтәп җиткермәве белән аңлатыла. «Китап дөньясы үзе бик чуарланды, художество-эстетик кыйммәте булмаган чүп-чар чын җәүһәрләр белән бер шүрлеккә менде. (...) Критерийларның югалуы, әдәби тәнкыйтьнең юк дәрәҗәсендә булуы, әдәбият белән кызыксынучыларны, бигрәк тә яшьләрне авыр хәлгә куйды»[1], – дип яза Р. Фәйзуллин.

Ике гасыр чигендә татар әдәби тәнкыйте дә, җитди каршылыклар аша үтеп, үсеш-үзгәреш юлларын барлауга килә. Шуңа нисбәтле хәзерге тәнкыйтьнең методологик нигезен, төп тенденцияләрен, тикшеренү методларын, поэтик үзенчәлекләрен өйрәнү җитди бурыч булып калка. Әдәби тәнкыйть өлкәсендә эшләүче Т. Галиуллин, А. Әхмәдуллин, Ф. Галимуллин, Д. Заһидуллина, Р. Сверигин, Ә. Закирҗанов, И. Вәлиулла, Р. Харрасова, Р. Фәтхрахманов һ.б.ның соңгы елларда дөнья күргән хезмәтләрендә[2] әлеге мәсьәләләргә билгеле бер ачыклык кертелсә дә, алда җитди бурычлар тора.

Шулай итеп, социаль-иҗтимагый тормыштагы үзгәрешләр әдәбимәдәни өлкәгә дә көчле йогынты ясый. Татар әдәбият белеме үсешенең яңа этабына керә һәм, үз чиратында, фәнни-теоретик һәм методологик нигезләрен яңарту мәсьәләсен алга куя. Ул, бердән, фәнни тикшеренүләрне марксизм-ленинизм тәгълиматының берьяклы, бәхәсле фикерләреннән арындыру, икенчедән, татар әдәбият белеменең үзенә хас фәнни-теоретик принципларын булдыру, өченчедән, үзенең тамырларын, формалашу һәм үсү этапларын барлау, традицияләрен яңарту аша, рус һәм чит ил әдәбият белемендәге казанышларны файдалану, аларга таяну, шул рәвешле, әдәбият тарихы, теориясе, тәнкыйте тармакларындагы табышларны, проблемаларны ачыклауга, үсеш сукмакларын, яңа тикшеренү юлларын билгеләүгә йөз тота.

---

[1] *Фәйзуллин Р.* Яңа елда яңарган уйлар // Казан утлары. 2002. № 1. Б. 6.

[2] *Галиуллин Т.Н.* Шәхесне гасырлар тудыра. Казан: Татар. кит. нәшр. 2003. 192 б.; *Әхмәдуллин А.Г.* Эзләнүләр дәвам итәме, алар бәрәкәтлеме? // Офыклар киңәйгәндә. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. Б. 16–26; *Сверигин Р.Х.* Гасырлар чатында // Казан утлары. 2002. № 4. Б. 145–154; *Заһидуллина Д.Ф.* Тәнкыйтьсез үсеп булмас // Казан утлары. 2003. № 8. Б. 146–152; *Заһидуллина Д.Ф.* Яңа дулкында (1980–2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык). Казан: Мәгариф, 2006. 255 б.; *Закирҗанов Ә.М.* Рухи яңарыш. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 287 б.; *Фәтхрахманов Р.Г.* Кальбеңдә ни сер бар, каләм? (Прозаикның иҗат лабораториясе). Казан: Мәгариф, 2009. 175 б.; *Хисамов Н.Ш.* Татар шагыйрьләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. 287 б.; *Рахман (Харрасова) Р.* Тәнкыйть – кирәксез шәйдер. Казан: Бриг, 2016. 76 б.; Харрасова Р. Әдәби тәнкыйть нигезләре. Казан: ТӘһСИ, 2017. 312 б.

## I бүлек нәтиҗәләре

1. Икътисади, сәяси өлкәдәге үзгәрешләр мәдәни тормышка да җитди тәэсир итеп, үз чиратында, сүз сәнгатендә һәм аны өйрәнүче фәндә киң чагылыш таба. Татар әдәбият белеменең торышы җәмгыятьтәге социаль-мәдәни шартлар, әдәби хәрәкәт, әдәби процессның гомуми үзенчәлекләре һәм фәннең эчке сыйфат үзгәрешләре белән билгеләнә. Ул исә төрле юнәлештә барган түбәндәге рухи-мәдәни күренешләр белән бәйле була: сүз сәнгате тарихындагы классик мирасның кайтарыла башлавы; әдәбиятның җәмгыятьтәге урыны үзгәрү; тарих сәхифәләрен яңарту, аларга объектив бәя бирү; чит илләрдәге татар әдәбиятын һәм публицистикасын кире кайтару; дингә карашның уңай якка үзгәрүе һәм әдәбиятта рухани юнәлеш җирләшә башлау; сүз сәнгатендә гаять кызыклы сәнгати эзләнүләр башлану һ.б.

2. Әдәбият белеменең үсеш-үзгәрешенә үткәндәге һәм хәзерге сүз сәнгате үзенчәлекләрен яңача бәяләү ихтыяҗы белән моңа кадәр калыплашкан фәнни-теоретик фикернең әлеге максатны үти алмавы аркасында туган каршылык этәргеч бирә. Әлеге үзгәрешләргә нигез булып түбәндәгеләр санала: 1) хәзерге татар әдәбият белеме методологиясенең нигез принципларын, тикшеренү юлларын, чараларын билгеләүдә күчеш чоры үзенчәлекләренә нигезләнү; 2) 1920 еллардан башлап берьяклы идеологик таләпләргә буйсындырылган методологик карашлардан арыну; 3) әдәбият белеменең үткән мираска, традицияләргә мөнәсәбәтен билгеләүдә дәвамчанлык, эзлеклелек һәм кабатланып тору принципларына таяну; 4) әдәбиятның җәмгыятьтәге урыны үзгәрү һәм яңа буын китап укучы барлыкка килү; 5) чит илләрдәге әдәбият белеме казанышлары белән танышу мөмкинлеге туу, татар әдәбият белеменең исә аларга шактый каршылыклы мөнәсәбәттә булуы.

3. Яңа методологик эзләнүләрнең нигезендә әдәбият белеменең эчке закончалыклары үсеш-үзгәрешен, әдәби-тарихи процессны өйрәнүнең яңа эчтәлек белән баетылган принципларын берләштергән система булырга тиеш дип саныйбыз. Ул татар әдәбият белеменең үзенә хас методологиясен эшләү белән дә бәйле булып, нигезендә бөтендөнья казанышларын файдалану, аларны милли әдәбият үзенчәлекләре, сыйфат-билгеләре белән кушып-үреп бару, билгеле бер дәрәҗәдә синтезлашу тора. Шул рәвешле, татар әдәбият фәне теоретик һәм методологик характердагы түбәндәге җитди мәсьәләләрне тикшерүгә алына: 1) әдәбият турындагы фәннең термин-төшенчәләрен куллануда төрлелек күзәтелә. Соңгы елларда бу юнәлешкә караган аерым мәсьәләләрне өйрәнү башланса да, татар әдәбият белеме терминологиясе буенча эзләнүләрнең дәвам ителергә тиешлеге бәхәс уятмый. Икенче яктан, аерым төшенчә-категорияләрнең эчтәлеге дә үзгәреш кичерә; 2) үзенең формалашуыннан

алып үткән вакыт эчендә тупланган тәҗрибә, фәнни-теоретик карашлар, методологик принциплар әдәбият белеменең ныклы җирлеге булып тора. Шул рәвешле, традиция һәм яңачалык, үзара диалектик бәйләнештәге төшенчәләр буларак, әдәбият турындагы фәннең эчке үсеше логикасына нигезләнә һәм аның тарихи үсеш закончалыкларын да билгели; 3) рус һәм Көнбатыш филологиясен, шулай ук Көнчыгышның фәнни-теоретик фикерен, күптөрле концепцияләрне иҗади үзләштерү татар әдәбият фәненең яңа баскычына нигез булып тора. Әлеге мәсьәлә чагыштырма-тарихи әдәбият белеменең активлашуы белән бәйле. Шуның белән бергә, татар әдәбиятының тарихи үсешендә читтә калдырып киленгән аерым иҗат юнәлешләрен, агымнарын өйрәнү башлана; 4) күчеш чоры үзенчәлекләре тарихилык принцибын яңа эчтәлек белән баета. Ике гасыр чигендә яшәүче китап укучы төрле чор әсәрләрен кабул иткәндә, үз заманына хас социаль-мәдәни һәм фәлсәфи-эстетик сыйфатларга нигезләнеп, яңа диалогик бәйләнешкә, мөнәсәбәткә килеп керә. Бу исә әсәр язылган чорның укучысы күрмәгән яңа мәгънәләрне ачуга китерә. Шул ук вакытта «башлангыч» фикерләрнең дә әһәмияте юкка чыкмый. Киресенчә, әлеге ике төрле караш, берсен берсе баетып, яңадан-яңа мәгънәләргә юл ача. Китап укучының активлыгы, әсәрне кабул итү, бәяләүдәге төрлелек тә тарихилыкның чикләрен киңәйтүгә хезмәт итә; 5) 1917 елга кадәрге әдәбият белемендә киң урын алган миллилек принцибы, совет чорында, гадәттә, социалистик реализм эстетикасы эчендә генә билгеләнә. Хәзер исә ул әдәбият турындагы фәнне халык язмышы, аның бүгенгесе һәм киләчәге, менталь сыйфатлары белән тыгыз бәйләнештә һәм милли идеягә нигезләнеп өйрәнүне күздә тота. Миллилек принцибы берничә аспектны үз эченә ала: а) милли әдәбият тарихының төзек, эзлекле системасын булдыру; ә) милли үзенчәлекләрне калкытып куюга, аерып чыгаруга, вакыйга-күренешләрдә, образ-характерларда эретеп бирүгә хезмәт итә торган алым-чараларны билгеләү һәм бәяләү; б) үткән чордагы һәм хәзерге әдәби процесска бәя биргәндә сүз сәнгате әсәренең милли үзенчәлекләрен аерып чыгаруга хезмәт итүче методларга, мәктәп-юнәлешләргә нигезләнү; в) миллилекнең диалогик характерына таяну, ягъни тикшеренү объектындагы милли һәм гомумкешелек кыйммәтләрен ачу, аңлату. Шул рәвешле, әдәбият турындагы фәннең үткән дәверләренә альтернатив булган фәнни теориясе формалашу процессы күзәтелә.

## II бүлек

# ӘДӘБИЯТ ТЕОРИЯСЕ: ТРАДИЦИЯЛӘР ҺӘМ ЯҢА ТЕНДЕНЦИЯЛӘР

### 2.1. Татар әдәбият теориясен өйрәнү мәсьәләләре

Әдәбият белеменең аеруча мөһим тармагы булган әдәбият теориясе әдәби әсәрнең табигатен, аны иҗат итүнең төп закончалыкларын һәм сүз сәнгатенең тарихи үсешен, социаль-эстетик функцияләрен, сәнгатилеген, шулай ук аны кабул итүнең үзенчәлекләрен өйрәнә. Әдәбият теориясе әдәбият тарихы һәм тәнкыйте белән тыгыз бәйләнештә яши һәм үсеш-үзгәреш кичерә. Аларның үзара мөнәсәбәтен Ю.Б. Борев болай билгели: «теория белән шөгыльләнүче үсеп-үзгәреп торучы системаның асылын ачыкларга омтыла, тарихчы исә әлеге системаның аерым формалары оешуы һәм үсүе процессын бәяли». Моннан аңлашылганча, «теория әдәбиятның шундый структур бүленешен бирә ала ки, ул вакытта логик бәйләнешне ачыклау сүз сәнгате үсешенең тарихи процессын яңартып күзаллау формасы булачак»[1]. Кайвакыт теоретик фикерләр әдәби текстның төп асылыннан читкә алып китә, яисә аны кабул итүнең «тәмен», беренчел йогынтысын киметә дигән карашлар да очрый. Әмма аларның нигезе юк. Бердән, әсәр текстын эмоциональ һәм интеллектуаль кабул итү бер-берсен алыштырмый да, аларны каршылыкка да кертми, бары тулыландыра гына, икенчедән, фәнни анализга бәйле әдәби күренешнең үзенчәлекләре билгеләнү, аларны классификацияләү, башка күренешләр белән чагыштырып карау сүз сәнгатенең асылын, функцияләрен, закончалыкларын аңлауны тулырак итә, бер системага сала. «Идеалда әдәбият теориясе – аның әйтерсең лә төшерелгән һәм ачык күренгән үсеш-үзгәрешенең тулы картинасы»[2], – дип яза А.В. Михайлов.

Ике гасыр чигендә татар әдәбият теориясе өлкәсендә барган үзгәрешләр, гомум әдәбият белеме кебек үк, *күчеш чоры үзенчәлекләре* белән аңлатыла. Алдагы бүлектә билгеләп үтелгәнчә, күчеш чоры әдәбият турындагы фәннең методологик нигезләре үзгәрү белән характерлана. Аңа йогынты ясаган *тышкы факторлар* җәмгыятьтәге иҗтимагый, социаль, мәдәни шартлардан гыйбарәт. Татар әдәбият теориясенең торышы моңа кадәр калыплашкан традицияләрнең яңа шартларда

[1] *Борев Ю.Б.* Введение в теорию литературы // Теория литературы. Т. 1. М., 2005. С. 18.
[2] *Михайлов А.В.* Методы и стили литературы // Теория литературы. Т. 1. М., 2005. С. 145.

үзгәреше һәм фәнни-теоретик эзләнүләр белән тыгыз бәйле. Күчеш чоры үзенчәлекләренә нисбәтле барлыкка килгән яңа тенденцияләр үткәндәге тәҗрибәгә таянып һәм аны үстереп кенә барлыкка килә. Ул исә әдәбият теориясе тарихының *үсеш-үзгәреш эволюциясен* ачыклау-бәяләүгә нигезләнә.

Татар әдәбият теориясенең тулы тарихы әлегәчә өйрәнелмәгән. Әмма аның фәнни-теоретик нигезләре, әдәбият тарихына һәм әдәби барышка бәйле мөһим сораулар, теге яки бу чорда теоретик фикернең торышы һ.б. мәсьәләләр, шулай ук аларны өйрәнгән шәхесләрнең эшчәнлеге билгеле бер дәрәҗәдә тикшерелгән. Аерым хезмәтләр әдәбият теориясе тарихын гомумиләштереп күзаллау, системага салып өйрәнүгә нигез булып тора.

XX йөз башында формалашу һәм аякка басу процессы кичергән татар әдәбият белеме синкретик характерда булып, әдәбият теориясенә караган мәсьәләләргә дә игътибар итә. Җ. Вәлиди, Г. Баттал, Н. Хәлфин, Г. Ибраһимов, Г. Сәгъди һ.б.ның хезмәтләрендә әдәби процесс, аерым бер автор иҗатын һ.б.ны өйрәнүгә бәйле әдәби әсәрнең эстетик табигате, төр һәм жанрлар, термин-төшенчәләр турында да теоретик фикерләр урын ала. Ә инде аларны теоретик планда бәяләү омтылышлары булмый диярлек. 1917 елдан соң теоретик фикер каршылыклы үсеш кичерә. Үткән әдәбиятка уңай булмаган мөнәсәбәт шартларында, әдәбиятның иҗтимагый вазифасы калкытып куелу, вакыйга-күренешләргә, шул исәптән әдәбият мәсьәләләренә дә сыйнфый көрәш ноктасыннан якын килү теоретик мәсьәләләр буенча эзләнүләрнең саегуына, берьяклы бәяләнүгә китерә. Г. Ибраһимов, Г. Сәгъди, Г. Нигъмәти, Г. Рәхим, Ф. Борнаш һ.б.ның теоретик пландагы тикшеренүләре марксистик теория җирләшү шартларында бара. Ул исә, «әдәбиятның милли теориясен эшләү фикереннән баш тартуга, нәтиҗә буларак, әдәби-теоретик фикернең кризисына китерә»[1]. Татар әдәбият теориясе буенча җитди эзләнүләр XX гасырның 60 нчы елларында башлана. Әдәбияттагы җанлану, милли һәм гомумкешелек идеалларына йөз тоту тенденциясе белән бергә, үткән мирасны өйрәнү, аңа объектив бәя бирү мәсьәләсе дә алга килеп баса. Борынгы һәм Урта гасырлар сүз сәнгате буенча алып барылган тикшеренүләр нәтиҗәсе буларак дөнья күргән «Борынгы татар әдәбияты»нда (1963) әдәби күренешләргә бәйле теоретик нәтиҗәләр ясала. XX гасыр башы татар әдәбиятының күренекле вәкилләре иҗаты, шул исәптән фәнни-теоретик характердагы хезмәтләр дә бәяләнеп, соңгыларының теоретик фән үсешенә керткән өлешен билгеләү омтылышлары ясала (М. Гайнуллин, М. Хәсәнов, Х. Госман, Г. Халит, Н. Юзиев, И. Нуруллин, Ф. Мусин, Й. Нигъмәтуллина,

[1] *Загидуллина Д.Ф.* Формирование и этапы становления теории татарской литературы (первая треть XX века): автореф. дис. ... докт. филол. наук. Казань, 2001. С. 60.

Т. Галиуллин, А. Әхмәдуллин, Х. Миңнегулов, Р. Ганиева, Н. Хисамов, М. Бакиров, О. Кадыров, Э. Нигъмәтуллин, М. Мәһдиев, С. Хафизов, Р. Мөхәммәдиев һ.б.). Алдагы елларда тикшеренү объекты итеп алынган проблеманың өйрәнелү тарихына бәйле уңышлы күзәтүләр ясалып, татар әдәбияты һәм тәнкыйте тарихын әдәби-теоретик фикер белән тыгыз бәйләнештә өйрәнү буенча билгеле бер казанышларга ирешелә. Аерым алганда, әдәбиятның төрле чорлардагы үсеш-үзгәреше, иҗтимагый фикер, дини карашлар, Коръән тәгълиматы белән тыгыз бәйләнеше даими игътибар үзәгендә була. Төрле чорларда өстенлек иткән иҗат типлары, методлары, аларның татар сүз сәнгатендә чагылыш үзенчәлеге ачыклана (М. Хәсәнов, Х. Госман, Г. Халит, Й. Нигъмәтуллина, Р. Ганиева, Н. Хисамов һ.б.). Татар әдәбиятының бай тәҗрибәсенә йөз тотып, рус әдәбият белемендәге казанышларга нигезләнеп тикшерелгән реализм һәм романтизм эстетикасы, сәнгати фикерләүдәге эволюцияне билгеләү омтылышлары (О. Кадыров, Э. Нигъмәтуллин, Т. Галиуллин, А. Сайганов, А. Әхмәдуллин һ.б.) әдәбият тарихын синхроник планда өйрәнүләргә нигез булып тора. Татар сүз сәнгатен башка халыклар әдәбияты белән булган багланышлар җирлегендә өйрәнүдә (Х. Миңнегулов, Р. Ганиева, Й. Нигъмәтуллина, Э. Нигъмәтуллин һ.б.) җитди яңалыкларга ирешелә. Күпгасырлык татар әдәбияты тарихында әйдәп баручы лириканың үсеш тенденцияләрен өйрәнү аңа хас үзенчәлекләрне поэтик тел, стиль, жанр системасы һ.б. яктан тикшерүгә юл ача (Х. Госман, Н. Юзиев, Х. Курбатов, М. Бакиров һ.б.). Татар әдәбияты тарихының алты томлыгы да аерым чорларда әдәбият теориясенең торышын, үсеш-үзгәрешен шактый тулы күзалларга мөмкинлек бирә.

Татар теоретик фикере рус фәненең көчле йогынтысында булып, аның казанышларын, аерым алганда, термин-төшенчәләрен иркен файдалана. Әдәбият теориясе буенча татар телендә дөнья күргән дәреслекләр[1] Г.Н. Поспелов, Л.И. Тимофеев, Н.А. Гуляев һ.б. теоретикларның караш-фикерләренә таянып языла. Шул рәвешле, татар әдәбиятының милли теориясен эшләү мәсьәләсе читтәрәк калып килсә дә, төрле дәверләр сүз сәнгатенең үсеш-үзгәреш тенденцияләрен, аерым авторларның иҗат казанышларын өйрәнү барышында милли әдәбият төшенчәсенә караган мәсьәләләр – татар әдәбиятының сәнгатьнең башка төрләре белән бәйләнеше, үзенчәлекле жанрлар системасы, образ-характерлар, милли әдәбиятның асылын билгеләүче күптөрле сурәтләү чаралары, алымнары һ.б.га бәйле җитди тикшеренүләр башкарыла, рус фәненә нигезләнгән хәлдә, билгеле бер система формалаша.

[1] *Нуруллин И.З.* Әдәбият теориясе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 89 б.; *Лаисов Н.Х., Мәһдиев М.С., Ганиева Ф.Ә.* Әдәбият теориясе: сәнгать төре һәм идеология формасы буларак матур әдәбият. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 189 б.; *Госман Х.Г., Мәҗитов З.М.* Әдәбият теориясе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. 126 б. һ.б.

XX гасыр ахырында җәмгыятьтә урнашкан социаль-мәдәни шартлар йогынтысында фәнни-теоретик фикердә җитди үзгәрешләр барлыкка килә. Аның сәбәпләре арасыннан тышкы һәм эчке факторларның тәэсирен билгеләп үтәргә кирәк. Алда әйтеп үтелгәнчә, күчеш чоры үзенчәлекләре тормыш-чынбарлыктагы кыйммәтләрнең үзгәрүенә китерә, икенче төрле әйткәндә, дөнья картинасы үзгәрү күзәтелеп, рухи-әхлакый төшенчәләрне аңлау-аңлату зур үзгәреш кичерә. Шуның белән бәйле моңа кадәр нигез булып саналган традицион принциплар, төшенчәләр тәнкыйтькә дучар була яисә, еш кына, кире кагыла. Әлеге шартларда әдәбият белеменең, шул исәптән әдәбият теориясенең яңа шартларга тәңгәл тикшеренү юлларын, методларын, алым-чараларын эзләү процессы көчәя. *Эчке факторларга* килгәндә, беренче чиратта, теоретик фикернең эчке үсеш закончалыкларына бәйле хәрәкәтен билгеләп үтү кирәк. Тупланып килгән тәҗрибә, *традиция* билгеле бер шартларда (күчеш чорында) яңалык буларак чагылыш тапкан сыйфат үзгәрешләренә китерә. Икенче яктан, татар әдәбияты, җәмгыятьтәге үзгәрешләрне әзерләүгә дә зур өлеш кертүче буларак, яңа шартларга тизрәк җайлаша һәм *төрле юнәлештә эзләнүләр* алып бару юлына чыга (Р. Мөхәммәдиев, И. Салахов, М. Хәсәнов, Ф. Садриев, Н. Гыйматдинова, Т. Миңнуллин, Р. Харис, Р. Гаташ, Л. Шагыйрьҗан, Р. Зәйдулла, Г. Морат һ.б.). Модернизм һәм постмодернизм агымнарына, аларның нигез билгеләрен чагылдыручы алым-чараларга йөз тоткан язучыларның (Ф. Бәйрәмова, З. Хәким, Н. Гыйматдинова, Г. Гыйльманов, М. Кәбиров һ.б.) күпсанлы әсәрләре дөнья күрә. Алар исә яңа эзләнүләргә туры килә торган бәяләүнең яңа юлларын, методларын таләп итә. Өченче яктан, рус һәм чит ил *әдәбият теориясе казанышлары* белән танышу мөмкинлеге барлыкка килеп, алардагы табышларны, термин-төшенчәләрне үзләштерү башлана. Дүртенчедән, татар әдәбият теориясендә билгеле бер *тикшеренүләр* даими бара. Бу өлкәдә эшләүчеләр тырышлыгы белән теоретик фикердәге эзләнүләрне гомумиләштерү, әдәби процесска объектив бәя бирү һ.б. омтылышлар ясала. Әдәбият теориясенең формалашу һәм үсеш этапларына, шулай ук хәзерге әдәбият теориясендәге бәхәсле сорауларга ачыклык кертүгә, бәяләүгә хезмәт иткән хезмәтләргә киңрәк тукталып үтик.

М. Бакиров «Шигърият дөньясына сәяхәт» исемле монографиясендә[1] гаять катлаулы теоретик мәсьәләне – шигырь төзелешенең иҗат процессындагы урынын, әһәмиятен тирән аңлап эш итә, чөнки «ритмик-интонацион үзенчәлекләреннән башка поэтик әсәрнең формасын да, телен дә, стилен дә, образлар системасын да тулы итеп күз алдына китереп булмый». Болар исә, үз чиратында, рифма һәм строфа ком-

[1] *Бакиров М.Х.* Шигърият дөньясына сәяхәт. Казан: ТГҖ нәшр., 1999. 237 б.

позициясе, метрика, шигырьнең эчке структурасы, силлабик системаның ритмик үзенчәлекләре, цезура кебек мәсьәләләрне калкытып куюны, алар буенча җентекле тикшеренүләр алып баруны, үз караш-фикерләреңне ачык белдерүне таләп итә. Галим татар шигырь фәне үсешенә зур өлеш керткән шәхесләрнең мирасына, бигрәк тә Г. Сәгъди, Г. Баттал, Г. Ибраһимов, Х. Вәли, Х. Курбатов, Х. Госман, Г. Халит, Н. Юзиев хезмәтләренә нигезләнеп, яңа эзләнүләр юлына чыга. Аның тикшеренүләре фәнни-теоретик нигезе белән генә түгел, бәлки полемик характерда булуы, бәхәсле булып саналган мәсьәләләргә кыю рәвештә үз мөнәсәбәтен белдерүе белән дә зур кызыксыну уята.

Татар шигыренең үзенчәлекләрен аңлау өчен автор хаклы рәвештә төрки-татар шигъриятенең елга башы булган Орхон-Енисей язмаларына мөрәҗәгать итә һәм танылган галим И.В. Стеблева белән бәхәскә керә. Соңгысы әлеге ядкәрләрне тоник-темпораль дигән ритмга корылган тарихи-героик поэмалар дип саный. М. Бакиров исә бу фикерне кире кага һәм «Орхон-Енисей язмалары юлларга да, башка шигъри берәмлекләргә дә бүленмәгән чәчмә текст» дигән карашны нигезле дәлилли. Шуның белән А. Щербак, В. Жирмунский, Л. Грибичек карашларын тагы да үстерә. Ә инде фольклор белән борынгы язма поэзия арасында яткан эволюцион үсеш процессын тикшерү барышында шигырьнең ул чорда интонацион-синтаксик системага нигезләнүен билгели. Аның фикеренчә, борынгы лирик поэзия, ритмик яктан көйләүгә нигезләнгән булса да, үзенең формасы өчен төп өлгеләрне тел сөрешеннән һәм мәкальләрдән алган. Гомумән, борынгы фольклор шигыренең нигезендә башлангыч хәлендә берничә ритмик принцип булган, дигән нәтиҗәгә килә М. Бакиров. Алар, әкренләп, камил шигъри формалар өчен җирлек әзерләгәннәр. Шул рәвешле, метрик чаралар башта фольклор шигырендә тусалар да, аларны нормага салу, система дәрәҗәсенә күтәрү эшен язма шигырь башкара.

Фольклордан язма поэзиянең аерылып чыгуы һәм мөстәкыйль тармакка әверелүе ритмик эволюциянең зур җиңүе була. Борынгы төрки язма шигыренең төзелешен ачыклау максатында, автор М. Кашгариның «Диване лөгатет-төрк» (XI) хезмәтен тикшерә һәм анда синтаксик тәңгәллекнең – ритмик принцип буларак, әмма камилләшеп, синтагмаларның санын, зурлыгын, урынын үзенә буйсындыран хәлдә саклануын ача. М. Бакиров метрик ачык иҗекләрнең хасиятен тикшерә барып, галимнәр арасында төрлелек булуын искәртә һәм төрки поэзиягә моңа кадәр аерым күрсәтелмәгән үзенчәлекле шигырь төзелеше («көчәйтелгән басымлы шигырь») хас булуын ачыклауга килә. Ә инде көчәйтелгән басымлы шигырь белән төрки гаруз мөнәсәбәтенә килгәндә, галим төрки шигырь үсешендә алар икесе ике баскыч булып тора дип саный. Вакытлар үтү белән беренчесенә алмашка төрки гаруз килә,

ягъни көчәйтелгән басымлы шигырь гарузны тудыруда актив катнаша. Автор фикеренчә, Ә. Ясәви шигырьләре халык иҗаты һәм көчәйтелгән басымлы шигырь традицияләреннән силлабик шигырьгә күчү эзләрен гәүдәләндерсә, Кол Гали әсәрендә инде ачык иҗекләр системасы юк. Язма әдәбиятта буынара ачыклыкларга гына корылган силлабик система нигездә өлгереп җиткән була.

М. Бакиров хезмәтендә җитди урынны гарузның килеп чыгуын һәм табигатен аңлату алып тора. Галимнәр арасында күп бәхәсләр уяткан әлеге мәсьәлә буенча авторның инанган карашы шуннан гыйбарәт: «төрки поэзиянең яңа системаны үзләштерү өчен җирлеге, (...) гаруз элементлары белән керешеп китәрлек ритмик казанышлары бар иде. Менә шуңа күрә дә төрки гаруз – асылда гарәп-фарсы йогынтысы белән үзебездәге җирлекнең бергә кушылу нәтиҗәсе ул». Ә инде төрки гарузның табигатенә, үзенчәлекләренә килгәндә, галим төрле чорларга караган күпсанлы әсәрләрне эксперименталь юл белән тикшерү аша төрки гарузда ике башлангычның (гарәп-фарсы һәм төрки) элементлары очрашкан һәм үзара ярашкан дигән фикерне яклый.

М. Бакиров тикшеренүләренең тагын бер мөһим өлкәсе төрки гарузның үзенчәлекләре белән бәйле. Мәсьәләнең катлаулылыгын искә алып, автор төрки гарузга хас сыйфатларны гарәп-фарсы гарузы белән чагыштыру аша ачыклый, һәм уртак закончалыклар булса да, төрки гарузның гарәп-фарсы гарузыннан билгеле бер дәрәҗәдә аерылуын дәлилли. Татарлар этнос буларак формалашкан чордан башлап, гаруз системасының үсеше үз шагыйрьләребез белән бәйле. Аерым алганда, Мөхәммәт Әмин, Мөхәммәдъяр кебек әдипләрнең әсәрләре «гаруз системасының ныклап урнашканлыгы хакында сөйли». Галим әлеге мәсьәләне классик музыка һәм мәкам төшенчәләре белән бәйләп өйрәнә һәм классик поэзиягә шулар нигез булып торган, аны сугарган дигән караштә тора. Ул мәкамнәр белән бәйләнеше булмаган көйләрнең дә ролен таный. Аерым алганда, «Зиләйлүк», «Тәфтиләү», «Әллүки», «Сәлим бабай көе» кебек җырларның мелодикасы квантитатив-вакыт үлчәү характерында булуына, ритмнары гаруз ритмикасы белән тулысынча диярлек тәңгәл килүенә игътибар итә.

Төрки-татар гарузын борынгы традицияләр белән тоташтыручы да һәм аның эчендә ритмик борылыш әзерләүче дә цезуралар булган. Автор бу үзенчәлекне Г. Кандалый иҗатында күзәтә, Г. Тукай әсәрләрендә исә тагы да үстерелүен, баетылуын күрә. Ә менә Дәрдемәнд һәм С. Рәмиев иҗатларында ачык иҗекләре дә, цезуралары да һәм табигый басымнары да сакланган шигырьләр белән очрашабыз. Шуларга нигезләнеп, М. Бакиров XX гасыр башында гаруз булмаган шигырь төзелешенә күчү өчен шартлар да, зәвыклар да әзерләнеп җиткән булуны ачыклый. Монда шуны да искәртеп үтәргә кирәк, көйләм шигыреннән сөйләм шигыренә

көчү һич тә бертөрле генә булмаган. Автор искәрткәнчә, бер шагыйрьдә ул көчәйтелгән басымлы шигырьне активлаштыру рәвешендә барса, икенчесендә силлабик шигырьгә юл алу рәвешендә чагылыш тапкан, өченчесендә «ирекле» асимметрик шигырьнең төрле үрнәкләрен булдыру рәвешендә бара. Шулай итеп, «татар шигырен моңарчы кабул ителгәнчә, сүз аралы (цезуралы) һәм ачык иҗекле төрләргә генә бүлеп йөртү җитми икән, чөнки алар үзара кушылган хәлдә дә очрыйлар, ягъни бу ике төр кысасыннан читкә чыгалар. Икенчедән, монысы аеруча мөһим, ачык иҗекле шигырьләр үзләре дә икегә бүленә: төрки гаруз һәм көчәйтелгән басымлы шигырь. Галимнең бу яңалыгы татар шигырь теориясен бермә-бер баетуы белән аны яңа баскычка күтәрә һәм яңа тикшеренүләргә юл сала.

Татар әдәбият теориясенең формалашуын һәм үсеш баскычларын максатчан тикшергән беренче хезмәт – ул Д. Заһидуллинаның «Әдәбият кануннары һәм заман» монографиясе[1]. Автор «бездә әдәбият теориясе булмаган» дигән фикерне катгый кире кага, һәм татар әдәбиятын, фәлсәфи-эстетик фикерен тикшерү аша, татар әдәби-теоретик карашларның эзлекле рәвештә җирләшүен, шулай ук, фән буларак, әдәбият теориясенең милли үзенчәлекләрен ачуга килә. Галимә фикеренчә, татар әдәби-теоретик фикере үсешендә өч баскыч-чор күзәтелә: 1) борынгы заманнардан алып XX йөз башына кадәрге чор; 2) XX йөз башында татар әдәбият теориясенең формалашу чоры; 3) 1920 еллардан башлап 1990 елларга кадәр сузылган чор. Беренчесе – борынгы заманнардан алып XX йөз башына кадәр – әдәбият нәзариясе барлыкка килүгә әзерлек чоры. Белгәнебезчә, Урта гасырлар әдәбияты, ислам дине таралуга бәйле, гомуммөселман мәдәнияте белән бәйләнештә үсә һәм гарәп-фарсы телендәге китаплар төрки халыкларда әдәби иҗатка юнәлеш бирүче ролен үти. Теоретик фикерләр, автор билгеләгәнчә, әдәби әсәр эчендә яши, ә соңгыларының синкретик характерда булуы моңа мөмкинлек бирә. Икенче төрле әйткәндә, әдәби әсәр үзе фәнни-тикшеренү бурычларын үти. Билгеле, бу чорда әле нәзари фикердә мөстәкыйль фән турында сүз алып барып булмый, әмма үзенең тамырлары белән юнан (грек) фәлсәфи-эстетик казанышларына барып тоташкан гарәп-фарсы әдәби нәзариясендәге карашлар, шактый тулы система буларак, төрки-татар әдәби-нәзари фикерен формалаштыра.

Д. Заһидуллина татар әдәбияты белән генә чикләнеп калмыйча, татар иҗтимагый фикеренә, Шәрык һәм Гаребнең әдәби-фәлсәфи карашларына иркен мөрәҗәгать итә һәм шуларга таянып, үзенең күзәтүләрен төзек фәнни системага сала. Теоретик эзләнүләрдә XIX йөзнең икенче яртысы әһәмиятле урын алып тора. Иҗтимагый тормыштагы

[1] *Заһидуллина Д.Ф.* Әдәбият кануннары һәм заман. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. 255 б.

үзгәрешләр әдәбиятның да сыйфат үсешенә китерә һәм, үз чиратында, әдәбиятны тикшерү өчен яңа нигезләр табуны таләп итә. Шулай да, Д. Заһидуллина фикеренчә, бу чорның иң зур яңалыгы татар теоретик фикерен җирле материал белән кушудан гыйбарәт һәм ул милли теория булдыру юнәлешендә зур адым санала.

Башлангычы Идел Болгарстанына барып тоташкан мәктәп-мәдрәсәләрнең рухи-иҗтимагый тормыштагы һәм әдәби-теоретик мәгълүмат чыганагы буларак роленә дә хезмәттә җитди игътибар бирелә. Автор кадими уку йортларының эчтәлеген, асылын билгеләп, әдәбият белән бәйле юнәлешләрне тикшерә, күптөрле китап-рисаләләрне күзәтә һәм аларның теоретик мәгълүмат чыганагы булуы турында нәтиҗә ясый. XIX йөз ахыры – XX йөз башында кадими уку йортлары урынына җәдиди мәдрәсәләр оеша башлый. Бу чорда инде мәгариф милли күтәрелешне, яңарышны әйдәп баручы көчкә әйләнә, ягъни Европа үрнәгендә мәдрәсәләр төзүгә, программаларга дөньяви фәннәр кертүгә бәйле яңа этап башлана. Әгәр Ф. Әмирхан әдәбиятның тәрбияви вазифасын алга чыгарса, Г. Исхакый моның белән генә чикләнмичә, милли тәрбияне беренче планга куеп, яңа методикага нигез сала. Хезмәттә җәдит мәдрәсәләрендә нәрсә укыту, ничек укыту мәсьәләсе турында бәхәсләр баруга бәйле бай фактик материал файдаланыла. Д. Заһидуллина фикеренчә, Г. Сәгъди эшчәнлегендә әдәбиятны система буларак укытуга һәм уку планына теория кертүгә юнәлеш токтан яңа агым барлыкка килә.

Яңа гасырның беренче ун елында әдәбият теориясе формалашу өчен шартлар өлгереп җитә. Бу, бер яктан, әдәби казанышлар һәм шуңа бәйле теорияне үстерүгә ихтыяҗ туу белән аңлатыла, икенче яктан, татар әдәби тәнкыйте дә формалашу чорын кичерә һәм нәзари мәсьәләләр тәнкыйть белән бергә күтәрелә, өченче яктан, татар дөньясына Европаның фәлсәфи, эстетик карашлары үтеп керә. Автор раслаганча, чорның теоретик фикер үсешенә бәйле иң югары ноктасы булып Г. Ибраһимовның «Әдәбият мәсьәләләре» тора.

Татар әдәбиятының кызу темплар белән үсеше, анда реализм һәм романтизмга нисбәтән төрле юнәлешләр барлыкка килү әдәбият фәне белән шөгыльләнүчеләр арасында бәхәсләр, фикер каршылыклары китереп чыгара. Соңгысы исә әдәбиятны аңлатуда билгеле бер принципларга таянган кешеләрне бергә туплаган фәнни-әдәби мәктәп оешуга китерә. Европа теоретик фикере һәм рус мәдәни-тарихи мәктәбе йогынтысында әдәбиятның иҗтимагый ягын алгы планга чыгаручыларны автор *«җәмгыятьчеләр»* дип атый. Әлеге мәктәпне оештыручы булып, эстетик һәм фәлсәфи карашларны көрәш идеясе белән бәйләгән Г. Исхакый тора. «Җәмгыятьчеләр»нең әдәбияттагы иҗтимагый якны югары күтәреп, сәнгатьлелекнең төп критерие миллилек диюләре күп тармаклы татар әдәбиятын бөтен тулылыгында ача алмый. Шуның өстенә торган саен

киңрәк мәйдан яулый барган романтизм әдәбиятында кешенең эчке дөньясын тасвирлау, яшәешнең психологик нигезләрен аңлату-күрсәтү алга чыга. Шундый шартларда «җәмгыятьчеләр»гә капма-каршы планда *«рухиятчеләр»* мәктәбе формалаша. Аның башлангычында торган Г. Ибраһимов үзенең «Татар шагыйрьләре» дигән хезмәтендә яңа мәктәпнең төп идеясен билгели: әсәрдә иҗатчының рухы, күңеле, хис-хыялы сурәтләнә. Икенче төрле әйткәндә, Г. Ибраһимов «җәмгыятьчеләр»нең «әдәбият тормыш-чынбарлыкны сурәтли» дигәненә «әдәбият кешенең, авторның рухын, эчке дөньясын чагылдыра» дигән фикерне каршы куя. «Рухиятчеләр» Гегель, Белинский хезмәтләренә таяналар. Әнә шул рәвешле, әдәбият фәне алга таба зур адым ясый: әдәбиятның сурәтләү объекты итеп кешенең эчке дөньясы, психологиясе билгеләнә, ә милли рухка тәэсир итүе, хис-кичерешләрне баетуы аның вазифасы буларак карала.

Модернистик юнәлешләр буларак символизм, экзистенционализм, импрессионизм һәм экспрессионизмның чыганагы, татар әдәбиятындагы җирлеге үтеп керү сәбәпләре һәм аларның асыл сыйфатлары Дәрдемәнд, С. Рәмиев, Н.Думави, М. Хәнәфи, Ф. Әмирхан һ.б.ның әсәрләренә бәйле тикшерелә. Яңа агым тарафдарлары эшчәнлегенең әһәмиятен Д. Заһидуллина әдәбиятка гомумкешелек фәлсәфәсен тәкъдим итүдә һәм моңа кадәр тар милли кысаларда фикер йөрткән әдипләрне бөтендөнья әдәбияты масштабына алып чыгарга теләүдә күрә. Д. Заһидуллина монографиясе татар әдәбият белеме тарихына яңача карарга этәрә. Автор аерым китап булып яисә күпсанлы газета-журналларда сакланып килгән, моңа кадәр игътибардан читтә калган бай әдәби-теоретик мирасыбызны барлый, җентекле анализ ясый һәм татар әдәбияты теориясенә XX гасыр башында гаять талантлы шәхесләр тарафыннан нигез салынуын дәлилләп, соңгыларының (Г. Исхакый, Г. Ибраһимов һ.б.) фәнни-гамәли табышларын ача, әдәбият фәнендәге урынын билгели.

1920–1930 елларда сүз сәнгате һәм аны өйрәнү фәне гаять каршылыклы үсеше белән характерлана. Үткән мираска мөнәсәбәт, яңа әдәбият тудыру омтылышы, фәнни тикшеренүләрдә марксистик методологияне көчләп диярлек тагу, шуның өстенә вульгар-социологик карашларның киңәя баруы һ.б. теоретик фикердә дә тирән эзен калдыра. Г. Сәгъди, Г. Гобәйдуллин, Г. Рәхим, Г. Гали, Г. Нигъмәти һ.б.ның әдәбият дәреслекләрендә, сүз сәнгате тарихына, тәнкыйтькә һәм аерым теоретик сорауларга караган хезмәтләрендә, шул исәптән аларда урын алган теоретик фикер тарихына бәйле карашларда без моның белән очрашабыз. Шуңа да әлеге чор сүз сәнгате тарихын өйрәнүчеләрнең (Х. Госман, Т. Галиуллин, А. Әхмәдуллин һ.б.) һәм әдәби тәнкыйть белән кызыксынучыларның (М. Мәһдиев, Р. Мөхәммәдиев, Э. Галиева, Т. Гыйлаҗев, Ч. Гыйләҗева, Г. Азизова һ.б.) игътибарын җәлеп итә. XX гасыр ахыры – XXI гасыр

башында да бу дәвер әдәбият белеме, шул исәптән теоретик фикер җитди тикшеренүләр предметы булып тора.

Татар әдәбият белеменең үсеш-үзгәрешенә, андагы эзләнүләргә билгеле бер ачыклык керткән хезмәт булып Р. Салиховның «Герой и эпоха (концепция героя в татарском литературоведении)» китабы[1] тора. Әдәбият фәнендә «герой» үзәк төшенчәләрнең берсе булып санала, шуңа да ул даими игътибарда булып, җитди бәхәсләргә, тикшеренүләргә этәрә. Автор татар әдәбият белемендә герой концепциясе бирелешен, нигездә, Октябрьдән соңгы сүз сәнгатенә бәйле тикшерә. Рус һәм татар телендәге күпсанлы фәнни хезмәтләрдә «герой», «уңай герой», «заман герое» кебек терминнар белән бергә, совет чоры әдәбиятында даими әйләнештә булган «иҗат методы», «тәнкыйди реализм», «социалистик реализм», «партиялелек», «халыкчанлык» һ.б. төшенчәләр дә өйрәнү объекты булып тора. 1917 елдан соңгы әдәбият белемендә герой яктыртылышы эзлекле рәвештә аерым этапларга бәйле киң планда, барыннан да элек әдәби процесс белән тыгыз бәйлелектә бәяләнә. Әлеге тикшеренүләрнең кыйммәте, безнең карашыбызча, түбәндәгеләр белән аңлатыла: 1) әдәбият фәне үсешенә нисбәтле аерым чорларның чикләре билгеләнеп (гәрчә бәхәсләргә урын калса да), иҗтимагый-сәяси, әдәби-мәдәни мохит характерлана; 2) һәр чорга хас әдәби хәрәкәт үзенчәлекләре, төп әйдәүче көчләр, иң уңышлы әсәрләр билгеләнеп, әдәби тәнкыйтьнең аларга мөнәсәбәте ачыклана; 3) автор әдәбият фәненең үз юлын, тикшеренү методларын, принципларын эзләүдәге каршылыкларны, бу өлкәдә эшләүчеләрнең дөньяга карашын, идеология белән бәйләнешен бөтен каршылыкларында бирергә омтыла; 4) совет чоры дип аталган зур дәвердә дөнья күргән күпсанлы хезмәтләрне бәяли, табыш-югалтуларын билгели һәм шуңа бәйле традицияләр дәвамчанлыгына, яңа эзләнүләргә юл салыну тенденцияләренә килеп чыга; 5) татар әдәбият белеменең үзенә хас методологик һәм фәнни-теоретик принципларын эшләү омтылышын кире какмыйча, бу мәсьәләләрдә рус әдәбият фәненә нигезләнүне күрсәтә; 6) социалистик реализм иҗат методының әдәби-эстетик принциплары, аларның билгеле бер үзгәреше рус әдәбият белемендә барган бәхәсләр белән тыгыз бәйләнештә ачыклана; 7) әдәбият белеменең җитди мәсьәләләре бер системага салып өйрәнелү белән бергә, автор яңа тикшеренүләргә дә уңышлы нигез сала, аның аерым юнәлешләрен билгеләп калдыра.

Э. Галиеваның «Татар әдәбият белемендә культура-тарих мәктәбе» дип аталган монографиясендә[2] XX гасырның 20–30 нчы еллары татар әдәбият белемендә культура-тарих мәктәбе формалашу, аның шартлары һәм сәбәпләре, милли, дөньяви чыганаклары, структурасы һәм

[1] *Салихов Р.Г.* Герой и эпоха (концепция героя в татарском литературоведении). Казань: Мастер Лайн, 1999. 352 с.

[2] *Галиева Э.* Татар әдәбият белемендә культура-тарих мәктәбе. Казан: Фән, 2002. 360 б.

татар академик әдәбият белемен нигезләүдәге, алдагы этапларда үсеш мөмкинлекләрен тәэмин итүдәге роле ачыклана. Тагын шунысы игътибарга лаек, автор әлеге гаять катлаулы сорауларны татар-рус һәм гомумевропа фәне үсешендәге казанышлар яктылыгында тикшерә. Галимә фикеренчә, 1920–1930 елларда татар әдәбият белемендә кызыклы эзләнүләр бара һәм, нәтиҗә буларак, культура-тарих мәктәбе синтетик вариантта формалаша. Төп сыйфатлары буларак милли үзенчәлеккә, тирәлек йогынтысына һәм әсәрнең язылу вакыты, мәдәни тормыш һ.б.га нигезләнгән әлеге күренеш татар әдәбият белемендә милли идеягә һәм системалылыкка таяна. Г. Сәгъди, Ж. Вәлиди, Г. Гобәйдуллин, Г. Рәхим, Г. Ибраһимов, Г. Нигъмәти һ.б. аның төп әйдәүче көчләре була.

1920–1930 елларда яңа тарихи-идеологик һәм мәдәни шартлар йогынтысында татар әдәбият белемендә ике юнәлеш формалаша дип күрсәтә Э. Галиева: берсе – рус-Европага, икенчесе – Көнчыгышка ориентация ясау. Беренче юнәлешнең башында торучы Г. Нигъмәти хезмәтләренә җентекле бәя бирү аша төп концептуаль карашлары билгеләнә. Алар: 1) сүз сәнгатенең тарихи үсеш закончалыкларына нигезләнү; 2) әсәрләрне тарихи чор, эпоха контекстында карау; 3) сәнгати күренешнең объектив нигезен ачыклауны сәбәпле бәйләнештә өйрәнү, ягъни әдәбиятны тормыш белән тыгыз мөнәсәбәттә тикшерү.

Бу чор әдәбият белемендә Көнчыгышка ориентация ясау юнәлеше Г. Сәгъди исеме белән бәйле. Э. Галиева фикеренчә, ул татар әдәбиятын Көнчыгыш әдәбиятлары системасында һәм шул ук вакытта үзенә хас үзенчәлекләре белән үсеп-үзгәреп торучы сүз сәнгате контекстында тикшерә. Г. Сәгъди «Татар әдәбияты тарихы» (1926), «Символизм турында» (1932) кебек хезмәтләрендә тарихилык принцибын нигез итеп, әдәби иҗатны чор, эпоха һәм җәмгыять белеме белән рухи бәйләнештә өйрәнә. Аның хезмәтләре нигезендә Көнчыгыш мәдәнияте материаллары торса да, ул әдәбият-сәнгать күренешләрен тикшерүдә Европа һәм рус культура-тарих мәктәбе принциплары белән эш итә, дип күрсәтә Э. Галиева.

Монографиядә билгеләп үтелгәнчә, татар әдәбияты галимнәре әдәби процессны һәм аерым язучы иҗатын тикшерүнең түбәндәге типларын алгы планга куялар: 1) теоретик фикерләргә таяну; 2) аерым стиль-агымнарны бүлеп чыгару; 3) теге яки бу идеологик проблемаларны ассызыклау; 4) әдәби төр-жанрлар сыйфатына таяну; 5) катнаш. Язучылар иҗатын тикшергәндә, гомумән, культура-тарих мәктәбе методологиясенә нигезләнү белән бергә, Г. Нигъмәти, мәсәлән, фәлсәфи-эстетик аспектка өстенлек бирсә, Г. Сәгъди исә культурологик күренешләргә таянып эш итә.

Э. Галиева хезмәтендә тикшерүгә алынган метод, юнәлеш, стиль, иҗат психологиясе мәсьәләләре, шуларга бәйле Җ. Вәлиди, Г. Рәхим, Г. Гобәйдуллин, Г. Баттал, Х. Вәли, Г. Толымбайский, Ф. Мөсәгыйть,

Х. Наум һ.б.ның әдәби-теоретик карашлары турындагы фикерләре, шул чор әдәбият белемендәге эзләнүләр юнәлешен билгеләү белән бергә, XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы әдәбият теориясендәге сорауларны тикшереп бәяләүгә дә нигез булып торалар.

XX гасырның 20–30 нчы еллары теоретик фикер торышын Г. Азизова һәм Ч. Гыйлаҗеваның аерым шәхесләр эшчәнлегенә нисбәтле тикшеренүләре игътибарга лаек. Г. Азизова танылган әдәбиятчы Г. Рәхим хезмәтләрендә татар әдәбияты мәсьәләләре чагылышын әлеге чор әдәбият фәнендә барган эзләнүләргә нигезләп тикшерә[1]. Бу исә татар әдәбияты тарихын өйрәнүнең теоретик җирлеген, Г. Рәхим тикшеренүләренең кыйммәтен эзлекле ачарга мөмкинлек бирә. XX йөз башы татар әдәбият белемендә гарәп әдәбияты мәсьәләләре чагылышын тикшергән Л. Хәйдәров хезмәтенең[2] әһәмияте түбәндәгеләр белән аңлатыла: а) татар сүз сәнгате күп гасырлар дәвамында Шәрык әдәби-мәдәни йогынтысында яши һәм ул, әдәбиятта киң чагылыш табу белән бергә, татар әдәбият фәненең нигезен тәшкил итә. Автор әлеге багланышларның аерым сәхифәләрен өйрәнү белән җитди яңалык алып килә; ә) татар әдәбият фәнендә кулланылган күп кенә термин-төшенчәләргә («әдәп», «әдип», «әдәбият» һ.б.) ачыклык кертелә; б) гарәп-фарсы әдипләренең татар әдәбиятына һәм фәненә тәэсирендә географик, тарихи, милли һ.б. үзенчәлекләрнең роле, шуңа бәйле фәндә культура-тарих методы, биографик метод, герменевтика һ.б. мәктәпләргә хас принципларның формалашуы билгеләнә; в) гарәп әдәбияты чор-этапларының, аерым әдипләр иҗатының татар әдәбиятчылары тарафыннан бәяләнүе, зур бәхәсләр уятуы тикшерелә һәм бу чорда «Шәрыкмы – Гаребме?» соравы куелып, аңа җавап эзләү күпсанлы мисалларга бәйле ачыклана һ.б.

Ч. Гыйлаҗева танылган әдәбият галиме Г. Сәгъди эшчәнлеген татар әдәбият белеме формалашу һәм үсеше яктылыгында тикшерә[3]. Г. Сәгъди хезмәтләре, аларда әдәбият тарихын өйрәнүнең алшартлары, сүз сәнгатенең чор-этапларга бүленеше, аерым теоретик мәсьәләләргә бәйле концептуаль карашлар ачыклану белән бергә, автор татар милли әдәбият белемен иҗтимагый фикер үсеше белән тыгыз бәйләнештә карый. Г. Сәгъди хезмәтләрен эзлекле һәм билгеле бер системада тикшерә барып, галимнең татар әдәбиятының үзенә хас үсеше турындагы карашына нәтиҗә ясый. Хезмәттә җитди урынны әдәбият тарихын өйрәнүдә Г. Сәгъди мөрәҗәгать иткән методлар, аларның фәнни-теоре-

[1] *Азизова Г.А.* Вопросы истории татарской литературы в трудах Гали Рахима: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2001. 21 с.; *Азизова-Хөснетдинова Г.* Гали Рәхим – әдәбият тарихчысы. Казан:, 2005. 160 б.

[2] *Хайдаров Л.И.* Вопросы арабской литературы в татарском литературоведении начала XX века: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2004. 27 с.

[3] *Гилазова Ч.М.* Проблемы литературоведения в историко-литературном наследии Г. Сагди: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2006. 31 с.

тик нигезе һәм эволюциясе, шулай ук традиция һәм яңалык мәсьәләләре алып тора. Ч. Гыйлаҗева фикеренчә, Г. Сәгъдинең сүз сәнгате тарихын өйрәнүгә диахрон һәм синхрон яссылыкта килүе, тикшеренү методлары ярдәмендә әдәби юнәлеш һәм агым кебек теоретик төшенчәләрне ачыклавы, шулар аша әдипнең иҗат концепциясе, стиле, алым-чаралар төрлеге һ.б. мәсьәләләргә чыгуы, бер яктан, әдәби-тарихи процессны тулы аңларга, бәяләргә мөмкинлек бирсә, икенче яктан, алдагы тикшеренүләрнең нигезен дә салып калдыра. Әдәбият галименең совет чорында кире кагылган, әмма әһәмияте һич тә кимемәгән тикшеренүләренең мөһим тармагы булып реализм һәм романтизмга хас сәнгати фикерләүгә сыймаган, рус һәм Европа әдәбият белемендә модернизм дип аталган күренешне татар әдәбиятының чит итмәвен күрсәтүе һәм билгеле бер эзләнүләр алып баруы тора. Әлеге караш-фикерләр «реабилитацияләнү» белән бергә, яңа эчтәлек белән байый, шуңа Г. Сәгъди эшчәнлеге бүген дә зур кызыксыну уята.

XX гасырның 30 нчы елларыннан башлап, бигрәк тә сугыштан соңгы елларда татар һәм башка халыклар әдәбият белеме рус әдәбият фәненә нигезләнеп үсә. Шуңа бәйле әдәби-теоретик термин-төшенчәләрне тәрҗемә итү күренеше көчәя[1]. Соңрак дөнья күргән «Әдәбият теориясенә кереш», «Әдәбият белеме сүзлеге» китапларында да[2] әлеге күренеш шактый саклана әле. Шулай да әдәби барыш, иҗат методы, әдәби юнәлеш-агым, жанрлар системасы, шулай ук татар әдәбиятының башка халыклар сүз сәнгате белән бәйләнешен шәрехләү һ.б. сорау-мәсьәләләрне милли әдәбият үсеше белән тыгыз бәйләнештә карау урын ала. Әдәбият белеме белән турыдан-туры бәйле булмаса да, аның аеруча мөһим термин-төшенчәләрен, бу өлкәдә эшләгән һәм эшләүче шәхесләрне билгеләү ягыннан «Татар энциклопедик сүзлеге» һәм «Ислам на европейском Востоке: Энциклопедический словарь» дип аталган хезмәтләр дә[3] әһәмияткә ия.

Әдәбият теориясенә караган хезмәтләр арасында «Әдәбият теориясенә кереш», «Әдәбият белеме сүзлеге» һәм Ф. Хатиповның «Әдәбият теориясе», «Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге» мөһим урын алып тора. Казан дәүләт университетының татар әдәбияты

---

[1] *Лаисов Н.Х., Мәһдиев М.С., Ганиева Ф.Ә.* Әдәбият теориясе: Сәнгать төре һәм идеология формасы буларак матур әдәбият. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 189 б.; *Нуруллин И.З.* Әдәбият теориясе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 89 б.; *Госман Х.Г., Мәҗитов З.М.* Әдәбият теориясе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. 126 б. һ.б.

[2] Әдәбият теориясенә кереш: урта мәктәпнең тел–әдәбият укытучылары өчен кулланма. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 303 б.; Әдәбият белеме сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. 239 б.

[3] Татарский энциклопедический словарь. Казань: Институт ТЭ АН РТ, 1998. 703 с.; Ислам на европейском Востоке: энциклопедический словарь. Казань: Магариф, 2004. 383 с.; *Нуруллин И.З.* Әдәбият теориясе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 89 б.

кафедрасы укытучы-галимнәре тарафыннан төзелгән «Әдәбият белеме сүзлеге» «әдәбиятның фәнни-теоретик нигезләрен аңлатучы иң актив атамаларны һәм төшенчәләрне үз эченә ала»[1]. Ул моңа кадәр татар телендә чыккан дәреслекләргә, төрле сүзлекләргә, рус әдәбият белеменә караган сүзлек һәм энциклопедияләргә, шулай ук татар әдәбият белемендәге табышларга нигезләнә. Марксизм-ленинизм тәгълиматының берьяклы карашларыннан тулысынча арынып җитмәсә дә, «Сүзлек» иҗтимагый аңның бер төре булган әдәбиятның эчке закончалыкларын, эчтәлек-формасын, традицияләр дәвамчанлыгын, теге яки бу чорга хас яңачалыкларны тулы, эзлекле күзалларга мөмкинлек бирә. Аның методологиясендә төп урынны әдәбиятны эчке закончалыклары нигезендә үсеп-үзгәреп торучы сүз сәнгате буларак бәяләү, аның эстетик, иҗтимагый, тәрбияви вазифаларын ачу, дөнья мәдәниятенең бер өлеше итеп күзаллау, шуңа бәйле уртаклыкларны һәм үзенә хас сыйфатларын билгеләү һ.б. алып тора. Шул рәвешле теге яки бу закончалык, термин-төшенчә төрле халыклар әдәбиятына караган үрнәкләр-мисаллар нигезендә аңлатыла. «Әдәбият белеме сүзлеге»нең җитди яңалыгы булып, бер яктан, күпгасырлык әдәбиятыбызның бай традицияләренә, Шәрык әдәбиятлары белән бәйләнешенә һәм сүз сәнгатенең аеруча Борынгы, Урта гасырлар дәверенә караган термин-төшенчәләрне күчемле бәйләнештә аңлату (мәкаләләр авторы – Х.Й. Миңнегулов), икенче яктан, рус һәм дөнья әдәбияты белемендәге казанышларны үзләштерү, ягъни озак вакытлар дәвамында тәнкыйди рухта бәяләнеп килгән модернизм юнәлешен, агымнарын аңлаткан төшенчәләрне бай фактик материалга нигезләнеп тәкъдим итү (мәкаләләр авторы – Р.К. Ганиева) тора.

Белем бирү оешмаларында полилингваль белем бирүне тәэмин итү һәм киң катлам җәмәгатьчелекне әдәбиятка караган төшенчәләр белән таныштыру максатында «Татарча-русча-инглизчә әдәбият белеме терминнары сүзлекчәсе»[2] дөнья күрә. Сүзлекчәдә әдәбият тарихына, әдәби тәнкыйтькә, әдәби төр һәм жанрларга, иҗат юнәлеше һәм агымнарына кагылышлы терминнар тупланып, аларга кыскача аңлатма бирелә. Аңлатмаларның татар әдәбиятыннан мисаллар белән ныгытылып баруы сүз сәнгатебез турында мәгълүмат бирүгә дә хезмәт итә.

Ф. Хатиповның «Әдәбият теориясе» татар әдәбият белеме ирешкән казанышларны бер системага салуның уңышлы үрнәге буларак дөнья күрде[3]. Студентлар һәм укучылар өчен атап чыгарылган дәреслек булуы эчтәлеккә йогынты ясаган. Профессиональ филологлар әзерләүгә йөз

[1] *Әхмәдуллин А.Г.* Төзүче-редактордан // Әдәбият белеме сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. Б. 3–4.

[2] Татарча-русча-инглизчә әдәбият белеме терминнары сүзлекчәсе. Казан: Казан. ун-ты нәшр., 2014. 160 б.

[3] *Хатипов Ф.М.* Әдәбият теориясе. Казан: Мәгариф, 2000. 351 б.

тоту әдәбият теориясенә караган төшенчәләрнең асылын, үзара бәйләнешен аңлатуны, әдәби әсәр, аның компонентларын тикшерүне алгы планга чыгара. Шуңа да әдәбият теориясенә караган мәсьәләләрдән әдәби әсәрнең бөтенлеге, аның төрләре, жанрлары һәм жанр формалары, эчтәлек һәм форма, сюжет һәм композиция, иҗат тибы, стиль, метод кебек төп төшенчәләрен ачыклауга киң урын бирелә.

Хезмәтнең методологик нигезе булып татар, рус, чит ил әдәбият белеме туплаган күпгасырлык традицияләр, әдәби-эстетик, фәлсәфи карашлар системасы тора. Бу исә авторга киң планда Аристотель, Гегель һәм В. Белинский белән Н. Чернышевский кебек классикларның хезмәтләренә таянып фикер-карашларын үстерү мөмкинлеге бирә. Ф. Хатипов әдәби әсәрне өйрәнүнең киң таралган методларына (биографик, чагыштырма-тарихи, социологик һ.б.) нигезләнә, әдәби процессны бәяләгәндә һәм нәтиҗәләр ясаганда аларның алым-формаларына таяна. Шуның белән бергә, автор әдәбият теориясенең бәхәсләр уяткан сорауларын – әдәбиятның яшәү рәвеше, әдәби барыш закончалыклары, әдәби юнәлешләр, агымнар һ.б.ны читләтеп үтә. Ә бит алар әдәбиятны системалы рәвештә әдәби-тарихи барыш эчендә өйрәнү, бәяләү мөмкинлеге бирә. Гомумән, Ф. Хатиповның ике гасыр чигендә басылып чыккан «Әдәбият теориясе» хезмәтендә, А. Әхмәдуллин билгеләп үткәнчә, автор билгеле бер кимчелекләрдән котыла алмаса да, аның татар әдәбият белемендәге казанышларны исәпкә алуын, аларга нигезләнүен күрәбез[1].

XX гасыр ахырында татар әдәбият белемендә барган үзгәрешләргә бәйле заман ихтыяҗы, фәннең үсеш таләбе буларак, «Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге» дөнья күрә. Әлеге хезмәт алдагы тәҗрибәләргә таянып төзелгән. Аның методологик нигезен татар әдәбият белеменең Шәрык һәм Гареб халыклары әдәбияты фәне йогынтысында булуына, аларның казанышларын үзләштерүенә нигезләнгән карашлар тәшкил итә. Әмма «Шәрык һәм Гареб чикләре арасында тирбәлгән, төрле халыклар нәзари фикеренең шифалы йогынтысын тоеп тамырланган, ныгыган»[2] татар әдәбият белеменең игътибар үзәгендә, беренче чиратта, татар сүз сәнгатенең үсеш үзенчәлекләрен, үзенә хас милли сыйфатларын ачу тора. Ә ул, билгеле инде, әдәби-тарихи мәгълүматларны шактый киң планда аңлату, аларны хәзерге фәндәге яңалыклар белән кушып, үреп бару аша гына мөмкин. Шуңа да хезмәттә термин-төшенчәләрнең гарәп-фарсы әдәбият белеме белән бәйле нигезләрен ачу-аңлатуга киң урын бирелә. Ул аеруча сүз сәнгатенең күпгасырлык мирасын тәшкил иткән шигърияттә, аның асылын билгеләүче

---

[1] *Әхмәдуллин А.Г.* Әле нокта куймыйбыз // Казан утлары. 2001. № 7. Б. 141–147.

[2] *Галиуллин Т.Н.* Кереш // Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. Казан: Мәгариф, 2007. Б. 3.

төшенчәләрдә (шигырь төзелеше, тел-сурәт чаралары, жанр атамалары һ.б.) киң урын алып тора.

XX йөз башындагы яңарыш дулкынында формалашып, киң кулланышка кергән татар әдәбият белеме термин-төшенчәләре әдәбиятның закончалыклы үсеш дәверендә тупланып, җыелып килә. Шуңа бу чорда Шәрык белән бәйлелек өстенлек итә. Шул ук вакытта, тормыш-яшәеш якынлыгы, татар капиталының рус капиталы белән тыгыз бәйләнеше, һаман саен арта барган иҗтимагый, социаль уртаклыклар һәм рус-Европа әдәбият фәненең алга китеше, җитди казанышларга ирешүе һ.б., мөһим шартларның берсе буларак, рус әдәбият белеменә киң рәвештә мөрәҗәгать итүгә китерә. Ул исә татар әдәбияты фәне үсешен тизләтеп кенә калмый, күпсанлы термин-төшенчәләрнең үтеп керә башлавына да юл ача. Сүзлек редакторы Т. Галиуллин билгеләп үткәнчә, «Шәрык һәм Гареб йогынтысы татар әдәбият төшенчәләрен аңлату системасын калыплаштыра, бу системаны тарихи җирлектән аерып карарга ярамый»[1].

Хезмәт авторлары моңа кадәр татар әдәбият белемендә аталып үтелгән яисә гомуми планда гына күзәтү ясалган күпсанлы терминнарны әдәби әйләнешкә кертә. Алар арасыннан фәнни мәктәп, метод, юнәлешләргә караганнарын (культура-тарих мәктәбе, формаль мәктәп, структурализм һәм постструктурализм, модернизм һәм постмодернизм, психологик мәктәп, мифологик мәктәп һ.б.), аерым методика һәм алымнар белән бәйле төшенчәләрне (уен, сюрреализм, концептуализм, концепт, интерпретация, интертекстуальлек, дөнья сурәте һ.б.) аерып чыгарырга мөмкин. Әлеге үзенчәлек татар әдәбиятын, аның фәнен дөнья әдәбият белеме фонында карарга, аларны милли сүз сәнгатенә караган сыйфатлар белән кушып-үреп барырга, аңлатырга, бәяләргә юл ача. Болар барысы да татар әдәбиятын өйрәнүнең яңа катламнарын билгеләүгә, перспективалы эзләнүләр башлауга да нигез булып тора. Яңа сүзлек билгеле бер кимчелекләрдән дә азат түгел. Аерым алганда, авторларның фәнни термин-төшенчәләр белән мавыгуы, татар сүзләре белән аңлату мөмкинлеге булганда да, рус яисә чит илдән алынган сүз-терминны кулланулары, икенче бер төшенчәләрнең татар әдәбиятыннан мисаллар белән тиешенчә дәлилләнмәве (мисал өчен, *аналогия, детектив, диалог, интерпретация, интертекстуальлек* һ.б.) күзгә ташлана. Тулаем алганда, яңа сүзлек әдәбият белемендәге казанышларны барлау, әйләнешкә кертү, әдәби күренешләрне аңлату ягыннан, һичшиксез, яңа бер адым булып тора.

Шул рәвешле, XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы татар фәннитеоретик фикере җитди сыйфат үзгәрешләре кичерә. Аңа йогынты ясаган тышкы факторлар (социаль-мәдәни шартлар) күчеш чоры үзенчәлекләре белән аңлатыла. Эчке факторларга килгәндә, беренче чиратта,

[1] *Галиуллин Т.Н.* Кереш // Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. Казан: Мәгариф, 2007. Б. 4.

теоретик фикернең эчке үсеш закончалыкларына бәйле хәрәкәтен билгеләп үтү кирәк. Шуңа нисбәтле барлыкка килгән яңа тенденцияләр үткәндәге тәҗрибәгә таянып һәм аны үстереп кенә барлыкка килә. Ул исә әдәбият теориясе тарихының үсеш-үзгәреш эволюциясен ачыклау-бәяләүгә, традицияләргә, татар әдәбиятында төрле юнәлештәге эзләнүләргә һәм әдәбият теориясендә алып барылган тикшеренүләргә нигезләнә. Фәнни фикернең әдәби практика белән дәлилләнгән, вакыт сынавын узган традицияләренә таянган хәлдә, рус һәм чит ил әдәбият теориясендәге табыш-яңалыкларны иҗади файдаланып, шулай ук татар әдәбият фәнендә эзлекле рәвештә алып барылган тикшеренүләр нигезендә татар әдәбият теориясендә традицион төшенчәләрнең һәм фәнни эзләнүләрнең үрелеп баруына, үзара синтезына нигезләнгән яңа фәнни карашлар формалаша.

Без татар әдәбият теориясендә барган эзләнүләрнең төп юнәлешләрен аңларга ярдәм иткән, бәхәсләр уяткан мәсьәләләреннән түбәндәгеләренә тукталабыз: әдәби юнәлешләр һәм татар әдәбият белеменең аларга мөнәсәбәте; иҗат методы һәм аның трансформациясе; әдәби барыш үзенчәлекләре һәм аның әдәби агымнарда, жанр һәм жанр формаларында, әдәби образда чагылышы.

### 2.2. Татар әдәбият теориясендә әдәби юнәлешләр мәсьәләсе

Хәзерге татар әдәбият теориясендә бәхәсләр уяткан, тикшеренүләргә этәргән проблема булып әдәби юнәлешләр, агымнар, аларның төрле чорлардагы чагылыш үзенчәлекләре, традицияләре һәм бүгенге әдәби барыштагы урыннарын билгеләү тора. Мәсьәләгә киңрәк планда якын килик.

Кешелек җәмгыяте кебек үк сүз сәнгате дә һәрвакыт үсеп-үзгәреп тора. Белгәнебезчә, борынгы язма истәлекләрдән алып бүгенге көнгә кадәрге татар әдәбиятының үсеше бертөрле, тигез генә түгел. Ул тарихи, социаль, мәдәни һ.б. шартларга бәйле төрле дәверләр, этаплар, чорлар аша үтә. Әлеге зур вакыт аралыгында әдәбиятның һәм эчтәлеге, һәм формасы җитди үзгәрешләр кичереп тора. Сүз сәнгатенең башлангычы мифологиягә һәм фольклорга барып тоташа һәм алдагы чорларда, бер яктан, аларга таянуын дәвам итә, икенче яктан, соңгылары үзләренә кадәр иҗат ителгән әсәрләргә, авторлар тәҗрибәсенә нигезләнә, әмма аларны кабатламый. Беренчел әсәрләр дә мөстәкыйль әһәмиятен югалтмый. Шул рәвешле әдәбиятның закончалыклы рәвештә үсеп-үзгәреп торучы һәм чорлар, этаплар рәвешендәге бергәлеге – әдәби процесс оеша.

Әдәбият үсеш-үзгәрешенең мөһим үзенчәлеге – аның билгеле бер дәверләр аша үтүе. В.Е. Хализев фикеренчә, ул кешелек җәмгыятенең үсеш этаплары белән дә туры килә – Борынгы һәм Урта гасырлар, аннары Яңа заман әдәбияты, ул үз эчендә барокко, классицизм, мәгърифәтчелек,

сентиментализм, романтизм, реализмны тудыра. XX гасырда модернизм мәйданга чыга һәм үз урынын яулый бара[1]. Шул ук вакытта, әдәбият тарихының дәверләргә әлегечә бүленеше, аерым алганда, аларның чикләрен билгеләү бәхәсләргә китерә. Чөнки алар, нигездә, Көнбатыш Европага хас мәдәни-тарихи үзенчәлекләргә таянып билгеләнәләр. Бөтендөнья әдәбияты процессын дәверләр аша күрсәткәндә төрле халыкларның, төбәк-регионнарның тәҗрибәсен исәпкә алу кирәклеге калкып чыга. XX гасырның соңгы чирегендә әлеге бүленешнең яңа концепциясе тәкъдим ителә. Аның нигезендә бөтендөнья әдәбияты өч дәвергә бүлеп өйрәнелә[2]. Беренче дәвер – архаик чор. Анда фольклор традицияләре һәм мифопоэтик әдәби аң киң урын били. Ул сәнгать формалашу чорын колачлый, антик чорга кадәр сузыла; икенче дәвер – б.э.к. I меңьеллыктан алып XVIII гасыр урталарына кадәрге дәвер (б.э.к. VII–VI гасырларда Грециядә формалаша дип тә күрсәтәләр). Ул әдәби аңда традиционализм өстенлек итү белән характерлана. Әдипләр, еш кына, әзер сөйләм формаларына, жанр кануннарына, охшатып язуга нигезләнәләр. Татар әдәбиятының урта гасырлардан алып XIX гасыр урталарына кадәрге мирасы шушы чорга карый; өченче дәвер – мәгърифәтчелек (романтизм барлыкка килү) чорыннан башлап (XVIII гасыр) хәзергәчә дәвам итүче чор. Ул «индивидуаль-иҗади әдәби аң» алга чыгу белән характерлана. Хәзер инде автор фикере, идеясе, «автор поэтикасы» өстенлек итә. Әдәбият кеше шәхесенә йөз белән борыла, якыная. Гомумән, автор индивидуальлеге көчәя. Татар әдәбиятында әлеге дәвер Яңа заман әдәбиятына туры килә, ягъни XIX гасыр урталарыннан башланып китә.

Әлеге дәверләр эчендә әдәби бергәлекләр барлыкка килә һәм вакытлар үтү белән алар бер-берсен алыштыра. Әдәбият белемендә үзара тыгыз бәйләнештәге мондый әдәби бергәлекләрне аерып чыгаралар: иҗат тибы, иҗат юнәлеше, иҗат методы, иҗат агымы. Әлеге төшенчәләр татар әдәбият белемендә аз өйрәнелгән өлкә булып кала, шуңа да алар белән еш кына бер үк күренешләрне атауга китерә[3]. Иҗат тибы кешенең тормышны танып-белү үзенчәлеге белән бәйле булып, Ф. Хатипов язганча, «матур әдәбиятның буеннан-буена сузылып килүче, иҗат ысулындагы, чынбарлыкны чагылдыру рәвешендәге үзенчәлекләргә нигезләнгән аеруча киң колачлы уртаклыкны»[4] белдерә. Аның ике төре гасырлар дәвамында ачыкланып, кулланылып килә – романтизм һәм реализм. Әлеге ике иҗат тибы иҗтимагый, мәдәни һәм эстетик шартлар тугач, чынбарлыкны танып белүнең уртак принципларына нигезлән-

---

[1] *Хализев В.Е.* Теория литературы: учеб. 2-е изд. М.: Высш. шк., 2000. С. 358.

[2] *Аверинцев С.С., Андреев М.Л., Гаспаров М.Л., Гринцер П.А., Михайлов В.В.* Категории поэтики в смене литературных эпох. М., 1994. С. 3–9.

[3] *Заһидуллина Д.Ф.* Дәресләрдә әдәби-тарихи күзаллау // Мәгариф. 2004. № 11. Б. 36–37.

[4] *Хатипов Ф.М.* Әдәбият теориясе. Казан: Мәгариф, 2000. Б. 240.

гән бердәмлек төсендә иҗат юнәлеше булып формалаша. Дөньяны романтик, реалистик һәм модернистик танып белү әдәби әсәр кысаларында конкретлаша, язучы яклаган концепцияләр чагылышы буларак иҗат юнәлеше, иҗат агымы, иҗат методы рәвешен ала. Урта гасыр татар әдәбиятында, иҗат тибы буларак, өстенлекле рәвештә романтизм һәм реализм яши. Иҗтимагый һәм мәдәни шартлар өлгереп җиткәч, XIX гасырда реализм һәм XX йөз башында романтизм һәм модернизм иҗат юнәлешләре буларак формалаша. Беренчесе, закончалыклы үсә барып, мәгърифәтчелек, тәнкыйди, социалистик дип аталган иҗат методларын мәйданга чыгара. Ә инде романтизмга бәйле иҗат тибы белән иҗат юнәлешен (иҗат методын) аерып кую өчен, еш кына, «урта гасыр романтизмы» һәм «Европа тибындагы романтизм» төшенчәләре кулланыла. Модернизм исә рус һәм Европа әдәбиятларында символизм, импрессионизм, экзистенциализм, экспрессионизм һ.б. агымнар рәвешендә үсә. Татар әдәбият белемендә модернизм, озак вакытлар читкә кагылып, бездә аерым үрнәкләре генә күзәтелә дип бәяләнә. Соңгы еллардагы тикшеренүләр (Р. Ганиева, А. Саяпова, Д. Заһидуллина, Ч. Зарипова-Четин, В. Әминева, Т. Мирсияпова, Л. Йөзмөхәммәтова һ.б.) күрсәткәнчә, XX йөз башында модернизмның төрле агымнарына караган күпсанлы үрнәкләр дөнья күрә. Фәнни-теоретик фикернең артка калуы сәбәпле, алар үз вакытында да, совет чорында да тиешенчә өйрәнелми. Хәзер инде модернизм әдәбиятының XX йөз башында ук җирләшүе турында нәтиҗә ясарга мөмкин.

Әдәби юнәлеш әдәби фикерләү тибы һәм иҗат агымы белән үзара якын әдипләр иҗатыннан оеша. Әдәби-эстетик гомумилекнең зур бер күренеше буларак, юнәлешләр закончалыклы рәвештә алышынып тора. Шуңа бәйле алар әдәби чорның төп үзенчәлекләрен үзләрендә чагылдыра. Шул ук вакытта, бөтен әдәби процесска хас билгеләрне әдәби юнәлешләргә нисбәтле генә аңлатуга да сак килергә кирәк. Бу очракта әдәби әсәрнең барлык үзенчәлекләре дә ачылып бетмәскә мөмкин. Шуның өстенә әдәби төркем-оешмалардан читтәрәк яшәгән, әмма бик яхшы әдәби үрнәкләр калдырган әдипләрне дә беләбез (Г. Исхакыйның чит илләрдәге иҗаты да шулай бәяләнә ала). Бу урында В.Е. Хализев сүзләрен хәтердә тоту да урынлы булыр: «Әдәби агымнар һәм юнәлешләрнең алышынуы турындагы карашлар әдәби процесс закончалыкларына “ачкыч” түгел, бәлки аның якынча схемасы гына...»[1].

Билгеле, әдәби юнәлешләр буш урында барлыкка килми. Иҗтимагый һәм әдәби тормышның билгеле бер мәдәни баскычка җитүе, иҗат тәҗрибәсе туплану, аларның тәнкыйтьтә һәм теориядә чагылыш табуы гына яңа әдәби юнәлешкә нигез әзерли. Әдәби юнәлеш барлыкка

[1] *Хализев В.Е.* Теория литературы. Учеб. 2-е изд. М.: Высш. шк., 2000. С. 371.

килүнең икенче бер шарты булып эстетик теориянең үсеш дәрәҗәсе тора. Бөтендөнья әдәбиятында классицизм юнәлеше бары XVII гасырда гына барлыкка килә. Гәрчә кешелек дөньясына, борынгы грек әдәбиятыннан алып, берничә гасыр дәвамында иҗат ителгән сүз сәнгатенең гүзәл үрнәкләре таныш булса да, алар, әдәби-эстетик фикер үсешенә бәйле үзләштерелмәү сәбәпле, ниндидер юнәлеш-агым буларак оешып җитмиләр[1].

XX йөз башында гына формалашкан татар теоретик фикере әдәби барыштан артта калып килә, шуңа да дөнья әдәбиятында урын алган Яңарыш, классицизм, сентиментализм, реализм, романтизм, модернизм юнәлешләре турындагы фикерләр совет чорында рус һәм Европа әдәбият белеменә таянып үстерелә. Ә инде реализмнан һәм романтизмнан башкалары, гомумән, татар сүз сәнгатенә ят күренешләр буларак яисә татар әдипләре әсәрләрендә аларның аерым үрнәкләре генә урын алуы билгеләнеп киленә[2]. XX гасыр ахырында җәмгыятьтәге үзгәрешләр һәм күчеш чоры үзенчәлекләре йогынтысында татар теоретик фикере татар әдәбиятын бөтен тулылыгында өйрәнү юлына чыга, аның югарыдагы юнәлешләргә дә шактый актив мөрәҗәгать итүен ачыклавы белән җитди яңалык алып килә.

Төрки-татар сүз сәнгате үзенең беренче Яңарышын Шәрык Ренессансы нигезендә Урта гасырларда (XIII йөз башы – XVI йөз уртасы) кичерә. Бу чор әдәбиятының төп сыйфат-билгеләре Г. Сәгъди, М. Гайнуллин, Х. Госман, Ш. Абилов, Г. Таһирҗанов, Н. Хисамов, Х. Миңнегулов һ.б. тарафыннан ачыкланса да, Яңарыш дәвере буларак билгеләргә мөмкинлек биргән яңа сыйфатлары Р. Ганиева хезмәтләрендә аеруча тулы нигезләнә[3]. Татар әдәбиятында икенче Яңарыш дәвере XIX йөз урталарыннан башлап XX гасырның 20 нче еллары урталарына кадәр дәвам итә. Бу чорда сүз сәнгате реализм юлына чыгып, бер-бер артлы мәгърифәтчелек һәм тәнкыйди реализм иҗат методларын үзләштерә. Урта гасыр романтизмы мәгърифәтчелек романтизмы, соңрак исә (XX гасыр башында) Европа тибындагы романтизм белән алышына. «Татар язучылары да сәнгатьчә фикерләүдә яңалыкка омтылып, символизм, натурализм, импрессионизм, экспрессионизм, экзистенциализм, акмеизм, аң агышы, неоклассицизм, психоанализ

---

[1] *Федотов О.И.* Основы теории литературы: учеб. пособие для студ. высш. учеб. заведений: в 2 ч. М.: Гуманит. изд.центр ВЛАДОС, 2003. Ч. 2. С. 185.

[2] Әмма шуны да ачыклап үтик: Р. Ганиева, Г. Халит, Н. Юзиев кебек галимнәрнең хезмәтләрендә XX йөз башы татар әдәбиятының модернизм агымнарына хас алымчараларны, сәнгати фикерләүне ят итмәве күрсәтелә.

[3] *Ганиева Р.К.* Восточный Ренессанс и поэт Кул Гали. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1988. 172 с.; *Ганиева Р.К.* Татарская литература: традиции, взаимосвязи. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. 272 с.; *Ганиева Р.К.* Традиции Восточного Ренессанса в тюркских литературах Средневековья и Нового времени. Казань: Фән, 2014. 272 с.

(фрейдизм) кебек әдәби-фәлсәфи агымнар өчен хас алымнарга, стиль чараларына мөрәҗәгать итә башлыйлар»[1]. Дөрес, XX гасыр башында формалашып, ныклап урнашу чорын кичергән татар теоретик фикере әлеге матур әдәбиятны тулаем иңләп, әдипләрнең сәнгати фикерләүдәге эзләнүләрен, әдәби-эстетик, фәлсәфи караш-фикерләрен, чынбарлыкны чагылдырудагы алым-чаралар байлыгын бөтен тулылыгында аңлатып, бәяләп бетерә алмый. Шулай да моңа җитди әзерлек бара.

### *2.2.1. Татар әдәбиятында классицизм традицияләре турында*

Белгәнебезчә, Европа сүз сәнгатендә беренче әдәби юнәлеш булган классицизм – XVIII гасырларда Яңарыш дәвереннән соң мәйданга килә. Европа илләрендә феодаль таркаулыктан чыгып, акрынлык белән милли дәүләтчелеккә омтылу вакытына туры килгән әлеге күренеш чынбарлыкны эстетик кабул итүнең үзенчәлекле моделен тәкъдим итә. Бу юнәлешне классицизм исеме белән атауның нигезе борынгы грек һәм рим әдәбиятларының классик үрнәкләренә йөз тоту белән бәйле. Әдәбият-сәнгатьтә антик чорга табыну, иярү, ул дәверләрдәге вакыйгаларны, атаклы шәхесләрне сурәтләү омтылышы киң урын ала. XVII–XVIII гасырлар Европа классицизмының теоретик базасын Ф. Малерб һәм Н. Буало-Депрео тарафыннан яңа тарихи шартларга яраклаштырылган хәлдә Аристотель һәм Горационың эстетик һәм поэтик карашлары тәшкил итә. Ә инде Н. Буалоның «Поэтическое искусство»(1674) исемле поэма-трактаты әлеге юнәлешнең манифесты буларак кабул ителә. Бу урында шуны да билгеләп үтәргә мөмкин: классицизм эстетикасы һәм поэтикасы бу чорның атаклы фәлсәфәчесе Рене Декарт идеяләренә нигезләнә. Аның «рационализм» һәм «метафизика» турындагы карашлары гаять актуаль булып, киң яңгыраш ала. Р. Декартның «Мин фикер йөртәм, димәк, мин яшим» дигән тезис-гыйбарәсе, асылда идеяне матди яшәештән алга кую белән идеалистик булса да, фәлсәфә белән бергә, әдәбият-сәнгатькә дә зур йогынты ясый. Дөнья картинасының нигезен тәртипсез хәлдәге кешеләр тормышы белән төзек, гармоник, идеал тәртипкә нигезләнгән дәүләт төзелеше тәшкил итә. «Нәкъ менә дөньяның әлеге фәлсәфи картинасы XVII–XVIII йөзләрдә классицизм эстетикасының Европадагы теләсә кайсы әдәбият классицизмы өчен универсаль характерда булган (тарихи-мәдәни вариантлар белән) шәхес концепциясе һәм конфликт типологиясе кебек эчтәлек аспектларын билгели»[2]. Аңлашыла ки, әдәбиятта кеше күңелендәге ике төрле башлангыч каршылыгы урын ала, ягъни, бер яктан, шәхси теләкләр алгы планга

---

[1] *Ганиева Р.К.* Ф. Бәйрәмова иҗатына лаеклы хезмәт // Шәмсутова А.А. Фәүзия Бәйрәмова прозасы. Казан: Гуманитария, 2004. Б. 6.

[2] *Лебедева О.Б.* История русской литературы XVIII века: учебник. М.: Высш. шк., 2003. С. 40.

чыгып, *хис-кичерешләргә* нигезләнгән эгоистик омтылыш чагыла, икенче яктан, җәмгыять тормышын кайгыртуга, хистән бигрәк, *акылга* өстенлек бирүгә китерә. Соңгысы исә кеше рухының иң югары чагылышы буларак, аның җәмгыятьтә үз урынын табу җирлеген тәшкил итә. Шуңа да классицизм әсәрләрендә кеше күңелендә барган көрәш төп конфликтны билгели. Н. Буало «Поэтическое искусство» хезмәтендә болай яза:

По скользкому как лед опасному пути
Вы к смыслу здравому всегда должны идти.
Кто путь покинул сей – немедля погибает:
Путь к разуму один, другого не бывает[1].

Классицизмның тагын бер мөһим принцибы булып табигатькә охшату тора. Табигать матурлыгын, андагы идеал гормонияне алар үрнәк итеп саныйлар. Әлеге үзенчәлек классицистларны борынгы әдәбиятка мөрәҗәгать итүгә, аны иҗаттагы эстетик идеал буларак бәяләүгә китерә. Бу урында шуны да искәртеп үтәргә кирәк, Д.С. Лихачев язганча, «гамәлдә исә шулай килеп чыга, классицистлар антик авторлар һәм рәссамнар артыннан түгел, аларны аңлауга нигезләнеп, табигатькә охшатып түгел, ә матурлык турында үзләренең күзаллауларына таянып баралар»[2].

«Классицизм эстетикасының канунлаштырылган һәм рационалистик булуы жанрларның катгый иерархиясендә дә чагылыш таба. Ул да бинар оппозиция принцибына (югары – түбән) буйсындырылган. Тормышның нәкъ менә югары һәм түбән чикләр арасында күзаллануы классицистларга һәр өч әдәби төр кысаларында югарыны мактаган һәм түбәннән көлгән әдәби әсәрләр тудырырга кирәклеген искәртә»[3]. Шул рәвешле әдәбиятта ике баскычта торучы жанр системасы барлыкка килә. «Түбән» жанрларга сатира, комедия, мәсәл, ә «югары» жанрларга ода, трагедия, эпопея кертелә. Әгәр беренчеләрендә кеше көндәлек яшәеш ыгы-зыгыларында һәм түбән сыйфатлар аша сурәтләнсә, икенче төр әсәрләрдә зур рухи, иҗтимагый омтылышлар белән яшәүче һәм үрнәк сыйфатларга ия шәхес буларак урын ала.

Классицизмда драматургия һәм театр өстенлек итә. Бу шулай ук борынгы әдәбият үрнәкләрен поэтик яктан гамәлдә үзләштерү омтылышы белән аңлатыла. Борынгы грек һәм рим әдәбиятларында сәхнә әдәбияты «югары гражданлык идеаллары һәм «ватан уллары» әзерләүче рәсми оешма булып санала һәм урта гасырларда үзәкләште-

[1] *Буало Н.* Поэтическое искусство // Литературные манифесты западноевропейских классицистов. М.: Изд-во Моск. ун-та, 1980. С. 425–426.

[2] *Лихачев Д.С.* Сады Классицизма // Поэзия садов. К семантике садово-парковых стилей. Сад как текст. М.: «Согласие», ОАО «Типография «Новости», 1998. С. 106.

[3] *Әминева В.Р.* Классицизм // Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. Казан: Мәгариф, 2007. Б. 74.

релгән феодаль дәүләт төзү шартларында мөһим берләштерүче көч булып тора»[1].

Классицизм юнәлешенең әдәби-эстетик асылын билгеләүче үзенчәлекләр булып түбәндәгеләр санала: 1) урын, вакыт һәм хәрәкәт бердәмлеге саклану; 2) стильнең жанр үзенчәлегенә төгәл туры килүе; 3) идеянең ачык һәм аңлаешлы булуы; 4) характер сыйфатларының тотрыклы булуы һәм бертөрле кабул ителүе; 5) әсәр композициясенең ачыклыгы һәм төгәллеге; 6) текст бөтенлеген тәэмин итүче барлык өлешләрнең гармоник берлеге. Әсәрләрдә төп конфликтның нигезен хис һәм бурычның үзара килештереп булмый торган көрәше билгели. Шуңа да әлеге каршылык, гадәттә, хисне тыю һәм бурычның җиңүе, өстен чыгуы, яклануы белән хәл ителә. «Иҗтимагый шартларның кеше характерына басымы элекке чорларда ук урын алган бурыч формасында аңлашыла. (...) Бу исә классицистларны борынгы әдәбиятка, аның кирәклелек пафосына йөз тотуга китерә»[2].

Классицизм аеруча француз әдәбиятында тулы чагылыш таба һәм аның дөньякүләм танылган вәкилләре булып П. Корнель, Ж.-Б. Мольер, Ж. Расин һ.б. санала. Рус әдәбиятында әлеге юнәлеш XVIII гасырның 30–50 нче елларында В. Тредиаковский, М. Ломоносов, А. Сумароков, Я. Княжнин, Г. Державин һ.б. иҗатында формалаша. Аның теоретик базасы булып А.П.Сумароковның «Эпистола о русском языке» һәм «Эпистола о стихотворстве» хезмәтләре тора. Француз классицизмыннан йөз елга соңрак мәйданга килүе һәм иҗтимагый-социаль, мәдәни шартлар рус классицизмының үзенчәлекле урын алуына китерә. Аерым алганда, «рус классицизм әдәбиятында конфликт, сюжетның тышкы гәүдәләнеше буларак, акыл һәм акылсыз хис арасындагы сайланышны саклаган хәлдә, үзенең социаль-сәяси табигатендә чагыла. Рус классицизмының уңай герое гомуми уңайлылык өчен үзенең шәхси хисен тыймый, шул ук вакытта, шәхсилеген тираник басымнан сакларга омтылып, гадәти хокукларын яклый»[3]. Әлеге фикерне үстерә барып, Й. Нигъмәтуллина болай дип яза: «Классицистларның күтәренке герое булып, үзенең халык каршындагы бурычларын аңлаган, гражданлык, патриотлык хисләренә ия булган иҗтимагый кеше – сугышчылар, полководецлар, “мәгърифәтле патша” тора»[4].

Татар әдәбият белемендә озак вакытлар дәвамында классицизм юнәлеше әдәби күренеш буларак урын алмаган, аның үрнәкләре татар

---

[1] *Федотов О.И.* Основы теории литературы: учеб. пособие для студ. высш.учеб. заведений: в 2 ч. М.: Гуманит. изд.центр ВЛАДОС, 2003. Ч. 2. С. 187.

[2] *Хализев В.Е.* Теория литературы: учеб. 2-е изд. М.: Высш. шк., 2000. С. 75.

[3] *Лебедева О.Б.* История русской литературы XVIII века: Учебник. М.: Высш.шк., 2003. С. 46.

[4] *Нигматуллина Ю.Г.* Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. Казань: Фэн, 1997. С. 86–87.

укучысына XX йөз башында тәрҗемә әсәрләр (Ж.-Б. Мольерның «Саран»ы һ.б.) аша гына ирешеп, әдәби барышка бераз йогынты ясаган дип санала. Татар һәм рус әдәбиятларын төрле мәдәни типлар буларак тикшергән Й. Нигъмәтуллина болай дип яза: «Татар әдәбиятында классицизм чоры урын алмый, чөнки татар халкының ул вакытта дәүләтчелеге булмаганлыктан, нәтиҗә буларак, әлеге әдәби күренешкә ихтыяҗ да булмый»[1]. Хәзерге әдәбият фәнендә бу мәсьәләгә үзгә карашлар да пәйда булды. Бу урында шуны да искәртеп үтик, әдәбият белемендә «классицизм – һәрбер милли мәдәният үсешенең табигый дәвере, гәрчә үзәкләштерелгән дәүләтнең гомуми социаль моделе барлыкка килүнең индивидуаль милли вариантына бәйле классицистик чорны милли мәдәниятләр төрле вакытта үтсәләр дә»[2] дигән караш өстенлек итә. Р. Ганиева, үзенең шәкерте Э. Галимҗанова белән берлектә, классицизм юнәлешенең милли әдәбиятлардагы үзенчәлекләрен тикшерүгә алына. Алар «классицизм элементлары татар әдәбиятында урта гасырларда ук яшәгән» дигән фикергә киләләр һәм мисал итеп Х. Госман тикшергән XVII гасыр әдибе Кадыйргали иҗатын һәм XIX йөзнең беренче яртысы әдибе Гомәр Мөхәммәт улының «Сәфәрнамәи шаһзадә Александр» (1837) әсәрен китерәләр[3]. Классицизм эстетикасының асылын билгеләгән хис һәм бурыч каршылыгы татар әдәбиятында шәхси теләк-омтылыш һәм милләт язмышы өчен җаваплылык рәвешендә үзгәртелеп урын ала. Э. Галимҗанова фикеренчә, XX гасыр башы татар әдәбиятының күренекле вәкиле Ф. Туйкин иҗатында дәүләтчелек, патриотизм һәм милли яңарыш мотивлары неоклассицизм эстетикасына нигезләнеп язылган. «Сугышчы Сатыш әфәнде» хикәясе классицизм һәм романтизм әдәбиятына хас үзенчәлекләрне эченә алса, «Ватан каһарманнары» комедиясе исә XX гасыр башы татар әдәбиятында классицизмның соңарган күренеше буларак бәяләнә. Автор, әдәби-эстетик күренеш буларак, классицизм дөнья әдәбиятының барлык этапларына хас күренеш саналып, төрле формаларда XX гасыр ахырына кадәр яши, дигән фикергә таяна. Әлеге пьесада хисләр һәм дәүләт өчен җаваплылык көрәше, төп конфликтны билгеләү белән бергә, Ватан каршындагы гражданлык бурычының төп идеясе буларак та ачыла, һәм аның бөтен текстны иңләп үтүенә һәм урын, вакыт, хәрәкәт бердәмлеген саклау кебек үзенчәлекләренә нигезләнеп, Э. Галимҗанова әсәрне классицизм юнәлешенең соңарган үрнәге дип

[1] *Нигматуллина Ю.Г.* Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. Казань: Фэн, 1997. С. 86.

[2] *Лебедева О.Б.* История русской литературы XVIII века. С. 37–38.

[3] *Ганиева Р.К., Галимҗанова Э.М.* Фазыл Туйкинның «Ватан каһарманнары» комедиясе – классицизм әдәбияты үрнәге // Проблемы развития татарской нации (языковой, литературно-фольклорный и искусствоведческий аспекты). Казань: Фән, 2004. Б. 119.

бәяли[1]. Ә инде әдипнең «Тормыш корбаннары» трагедиясе неоклассицизм әсәре буларак билгеләнә. Моңа, автор фикеренчә, пьесаның пафосы, геройларның эш-гамәлләре һәм аның фаҗигале тәмамлануы (исемгә үк чыгарылган), өч бердәмлек принцибы саклану, көчле, кискен конфликтның аталар һәм балалар арасында үзара бурыч проблемасы рәвешендә чагылуы нигез булып тора. Классицизм теориясе һәм поэтикасының билгеле бер үзгәреш кичерүе турында Н.П. Козлова болай дип яза: «Классицизмның берничә гасыр дәвамында трансформацияләнүе бәхәс тудырмый, шуңа да классик художество системасының генезисы һәм аерым этапларда үсеше турындагы мәсьәләне читләтеп үтеп булмый. Бу классицизм теориясенә дә карый»[2].

Р. Ганиева һәм Э. Галимҗанова тикшеренүләре татар әдәбияты тарихының яңа катламнарын, үзенчәлекле әдәби-эстетик карашларга нигезләнгән агымнарын өйрәнүгә этәргеч бирә. Нәтиҗәдә, танылган классик язучы Г. Исхакый иҗатын классицизм традицияләре чагылышына нисбәтле тикшеренүләр дөнья күрә[3]. Шуның белән бергә, әлеге катлаулы сорауларны ачыклауга гаять җитди якын килеп, теоретик һәм фактик әдәби материалны җентекләп тикшереп кенә нәтиҗәләр ясау – уртак таләп булып тора. Классицизм әдәбиятындагы хис һәм бурыч каршылыгын геройның шәхси теләкләре белән милләте каршындагы бурычы арасындагы конфликт чагылышына гына кайтарып калдыру, алар арасына гади тәңгәллек билгесе кую дөрес булмас иде. XVI гасыр уртасында дәүләтчелеген югалткач, халкыбызның этник үзенчәлекләре, алдагы чор әдәбиятындагы әхлакый, фәлсәфи һәм эстетик карашлары фольклорда һәм суфичылык әдәбиятында сакланып кала. Соңгысындагы тән һәм җан, фани һәм бакый каршылыгы яисә шуңа бәйле бер катлам әсәрләрдә урын алган аскетлык күренеше шактый киң таралыш ала. Шуның белән бергә, кеше җәмгыятьтә яши һәм рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерүнең үз халкы мәдәни яктан алга китүе белән бәйле булуын яхшы аңлый. Шуңа да төрле чор әдәбиятында шәхси теләк-омтылыш һәм җәмәгать (авылдашлар, бер этнос кешеләре, мөселманнар һ.б.) каршындагы җаваплылык мәсьәләсе теге яки бу формада, сурәттә, бәйләнештә куелып килә. Аның үрнәкләрен Кол Гали, Котб, Мөхәммәдъяр, М. Акъегетзадә һ.б. иҗатында күрәбез. XX гасыр башындагы Яңарыш әдәбиятында шәхси теләк һәм милләт мәнфәгате аеруча җитди яңгыраш ала. Күпсанлы әсәрләрдә милләт язмышын кайгыртуны

[1] *Галимзянова Э.М.* Творческое наследие Фазыла Туйкина: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2004. С. 15–19.

[2] *Козлова Н.П.* Ранний европейский классицизм (XVI–XVII вв.) // Литературные манифесты западноевропейских классицистов. М.: Изд-во Моск.ун-та, 1980. С. 6.

[3] *Абдулбариева Т.А.* Традиции классицизма в драматургии Гаяза Исхаки (к проблеме мотивов государственности): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2010. 27 с.

яшәү максаты иткән геройлар алгы планга чыга. Мисал өчен, Г. Исхакый «Мөгаллимә» (1913) пьесасында, «мәхәббәтме, әллә милләт өчен вазифа үтәүме өстен»[1] мәсьәләсен куюы белән, драматургиягә яңалык алып килә. Мондый әсәрләрне бәяләгәндә, аерым алганда, аларны классицизм әдәбияты белән чагыштырып тикшергәндә, әлеге әдәби күренешнең формалашу шартларын, эстетик асылын җентекләп өйрәнү һәм тикшерелә торган текстагы сыйфат-билгеләрнең сәбәп-максатларын тирәнтен ачу зарурлыгы һәркемгә аңлашыла. Әдәби әсәрнең (бигрәк тә XX йөз башына караган), гадәттә, синкретик характерда булуын да онытмаска кирәк. Һәр әдип иҗат эволюциясе кичерә. Әдәби һәм тормыш тәҗрибәсенә бәйле ул яклаган әдәби-эстетик карашлар төрле әдәби агым-юнәлешләргә караган әсәрләр язылуга нигез була (Г. Тукайда – мәгърифәтчелек реализмы һәм тәнкыйди реализм; Г. Исхакыйда – мәгърифәтчелек реализмы, тәнкыйди реализм һәм романтизм һ.б.). Аерым әсәр текстында да үзара кушылып китү – синтезлашу күзәтелә. Шуңа күрә әсәр жанрын билгеләгәндә төрле карашлар булу табигый күренеш. Мисал өчен, Г. Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәре жанрын Р. Ганиева «фантазия», «әдәби хөтбә», «вәгазь», «тарихи нотык», «нәсер», «шашкынлы бер сүз куәте», «сентименталь юл белән шашып язылган әсәр», «хыялый хикәя», «фантастик-публицистик хезмәт», «тарихи роман» һ.б. атамалар белән билгели. Галимә аны «төрки-татар әдәбиятлары тарихындагы беренче антиутопия»[2] дип атый. Әдәбият белемендә әлеге әсәрнең жанр атамасы буенча бәхәс дәвам итә[3]. Шул ук вакытта югарыдагы терминнарны билгеләүче әдәбиятчыларның әдәбият тарихын һәм теориясен бик яхшы белүләрен исәпкә алу әсәрнең төрлечә шәрехләүгә мөмкинлек бирүе турында сөйли. Югарыда сүз алып барган Ф. Туйкин иҗатына да синкретизм хас. «Ватан каһарманнары» пьесасында реализм (тормышны чынбырлыктагыча сурәтләү; шул чор геройларын үзәккә алу һәм эш-гамәлләрен мотивлаштыру; характерларны үсеш-үзгәрештә бирү), романтизм (хис-кичерешләрне шактый тулы һәм психологизм алымнары белән бирү; финалның ачыклыгы; урын һәм вакытның үзенчәлекле, хәтта экзотик булуы) һәм классицизмга хас билгеләр урын алган. Соңгысының асылын билгеләгән үзенчәлекләрнең (урын, вакыт һәм хәрәкәт бердәмлеге, хис һәм гражданлык бурычы каршылыгы; әсәрнең төп пафосы һ.б.) киң урын алуы авторның әдәби-эстетик карашларын тулырак ачуга хезмәт итә, Э. Галимҗановага әсәрнең классицизм традицияләренә нигезләнеп язылуы турында нәтиҗә ясарга таяныч бирә.

Э. Галимҗанова тикшеренүләренә бәйле тагын бер сорау туа – ул «классицизм» һәм «неоклассицизм» терминнарының үзара мөнәсәбә-

[1] *Ганиева Р.К.* Гаяз Исхакый иҗаты. Казан: КДУ, 2005. Б. 21.
[2] Шунда ук. Б. Б. 11.
[3] *Сәхапов М.Җ.* Баш редактор сүзе // Мирас. 2007. № 10. Б. 3–14

тенә карый. Авторның «Ватан каһарманнары»н классицизм үрнәге дип атавында әсәрдәге дәүләтчелек, Ватанны саклау идеясенең хис һәм бурыч каршылыгында бирелүенә нигезләнүе күренә. Ә инде «Тормыш корбаннары»н «неоклассицизм»га нисбәтле билгеләвендә «классицизм»ның XX гасыр башы вакыйгаларына бәйле эчтәлеге яңару искәртелә. Безнең карашыбызча, ике әсәр турында сүз алып барганда да «неоклассицизм» төшенчәсен куллану уңышлы булыр иде, чөнки беренче пьесадагы рус-француз сугышына мөнәсәбәтле вакыйгаларны сурәтләгәндә авторның XX гасыр башындагы татар иҗтимагый тормышына бәйле карашлары, димәк, XVII–XVIII гасырлардагы классицизм тәҗрибәсе үзләштерелеп, яңа әдәби-эстетик эчтәлек алган хәлдә чагылыш таба. Шуңа күрә бу очракта «яңа классицизм», ягъни «неоклассицизм» терминын куллану сорала кебек.

Авторларның әлеге тикшеренүләре яңа эзләнү-уйлануларга нигез булып тора, дигән идек. Шул уңайдан кайбер фикерләребез белән уртаклашып китик. Төрки-татар әдәбиятының гүзәл бер ядкәре булган халык дастаны «Идегәй»дә (XV йөз) XVII – XVIII гасырларда классицизм төшенчәсе белән атаган әдәби күренешкә хас сыйфатларның үзенчәлекле урын алуын күрәбез. Билгеле, әсәр шул яссылыкта җентекләп тикшерүне таләп итә (урын, вакыт, хәрәкәт берлеге сакланмый), бу очракта кайбер күзәтүләрне генә билгеләп үтәбез. Бердән, теоретик планда соңрак эшләнгән классицизм үзеннән алдагы күпгасырлык әдәбият тәҗрибәсенә таянган. Икенчедән, классицистлар борынгы грек һәм рим әдәбиятына теләп мөрәҗәгать итәләр, ягъни аларда киң урын алган шәхси теләк һәм дәүләт мәнфәгатенә бәйле каршылык һәр дәвер өчен хас күренеш. Өченчедән, игътибарны әлеге әсәргә җәлеп итүнең төп сәбәбе шунда, аны классицизм эстетикасы таләпләреннән чыгып бәяләгәндә тагы да тирәнрәк катламнарын – үзенчәлекләрен билгеләү мөмкинлеге туа. «Идегәй»дә Урта гасыр феодаль дәүләте булган Алтын Урданы саклау, дөресрәге, күптөрле сәбәпләр йогынтысында аны саклап кала алмау, таркалу процессы сурәтләнә. Төп конфликт шәхси теләк, хис-кичерешләр белән дәүләт мәнфәгате арасындагы каршылыкка нигезләнә һәм барлык геройларның эчке каршылыгын да билгели. Төп герой Идегәй генә түгел, Туктамыш хан фаҗигасе дә шәхси сыйфатлары (әйтик, артык горур булуы) һәм якыннарына мөнәсәбәте белән ил-ханлык каршындагы җаваплылык конфликтында бөтен тулылыгында ачыла. Идегәйнең Аксак Тимер ягына качып китүен никадәр авыр кичерүен генә искә төшерик. Тагын шуны гына искәртеп үтик, төп конфликт турында уйланганда, әсәрнең махсус заказ белән язылган булуы ихтималын да онытмыйк.

Ә инде Ю. Сафиуллинның халык дастанына һәм Н. Исәнбәтнең «Идегәй» пьесасына нигезләнеп XX гасыр ахырында язылган «Идегәй»

трагедиясендә классицизм традицияләре тагы да киңрәк урын алган. Моның сәбәпләрен билгеләп үтик: бердән, XX гасыр ахырында татар халкында дәүләтчелек идеясе бик нык үсеп, милләт (дәүләт) һәм шәхси мәнфәгать мәсьәләсен шактый кискенләштерә. Автор әлеге әсәрне иҗат итүгә халыкның рухи теләкләрен дөрес аңлап алына; икенчедән, халык дастанында сурәтләнгән вакыйгалар татар халкы тормышына аеруча якын, дөресрәге аның фаҗигале язмышы чагылышы булып тора. Ул исә шәхси һәм иҗтимагый теләк-омтылышны заман биеклегеннән торып аңлауга, ачуга, бәяләүгә юл күрсәтә; өченчедән, дәүләтебез бик күптәннән юкка чыгу сәбәпле, ул идеяне чагылдырган әсәрләр юк диярлек. Шуңа да Ю. Сафиуллин трагедиясе нәкъ менә классицизм эстетикасы традицияләреннән чыгып тикшерелгәндә тулы ачыла. XV гасыр әсәре белән уртак җирлеге күп булса да, пьесаның әдәби-эстетик концепциясендә җитди үзгәрешләр бар, асылда ул заман рухы белән сугарылган (моңа А. Әхмәдуллин һәм А. Саттарова да игътибар итәләр[1]).

Трагик жанрда язылган пьесада вакыйгалар Җүчи Олысында – XIV йөз ахыры – XV йөз башларында Сарай шәһәрендә һәм аның җирләрендә бара. «Башлам» өлеше булачак, сурәтләнәчәк вакыйга-хәлләрне, каршылык-көрәшләрне аңлауда әһәмиятле урын алып тора. Аксакал чичән Субра карт әсәрдә берничә вазифа үти: беренчедән, ул халыкның үлемсез Хәтерен символлаштыра, ерак гасырлардан килүче гомумиләштерелгән образ буларак, үзенең җырларында халык язмышын, кайгы-хәсрәтен, шатлык-куанычын чагылдыра һәм бүгенге буынга җиткерә; икенчедән, вакыйгаларда актив катнашучы, аларның тере шаһите; өченчедән, аларга бәя бирүче һәм бу яктан автор позициясен чагылдыручы да булып тора.

Пьесада вакыйгалар Хансарайдагы көндәлек хәлләр белән башлана. Драматургның игътибар үзәгендә котылгысыз каршылыкка кергән Туктамыш белән Идегәйнең һәм якыннарының максат-омтылышын, шуңа бәйле эш-гамәлләрен ачыклау тора. Авторның табышы шунда ки, аның төп геройлары билгеле бер кысаларга сыймый: һәрберсе үз характеры, үз йөзе, рухи дөньясы белән һәм гаять каршылыклы шәхесләр булып ачыла.

Туктамыш хан беренче күренешләрдә үк ил белән идарә итүне үз кулында нык тотучы, таләпчән, каты куллы һәм акыллы, үткән белән бүгенгене һәм киләчәкне үзара бәйләнештә күрә белүче хөкемдар булып ачыла. Ханише, Җанәкә, киңәшчесе Җанбай кебекләрнең Кобыгыл бине (Идегәйне) каралтып-түбәнәйтеп һәм ханга һәрдаим каршы куеп күрсәтүләрен тиз туктата. Моны ул Кобыгылның сәләтле гаскәр башлыгы,

[1] *Әхмәдуллин А.Г.* Күңелләрне уятыр: Хәзерге татар драматургиясе. Казан: Мәгариф, 2007. Б. 140; *Саттарова А.М.* Современная татарская драматургия (1985–2000 гг.): Концепция эпохи и героя. Казань: Гуманитария, 2003. С. 45–63.

кыю-батыр сугышчы булуы белән аңлата. Аксак Тимер белән орышта үзен әлеге батыры саклап калуын да хәтерендә тота Туктамыш хан. Кобыгыл улы Норадынга карата да ул шундый мөнәсәбәтне саклый.

Трагедиянең төп герое буларак Идегәйнең эш-гамәлләрен, әйләнә-тирәдәгеләр белән мөнәсәбәтен, хыял-омтылышларын, каршылыклы характерын ачуга киң урын бирелә. Авторның игътибар үзәгендә, беренче чиратта, әлеге герой фаҗигасенең сәбәпләрен ачу омтылышы тора. Баштагы күренешләрдә Кобыгыл белән Туктамыш хан арасындагы ачык күренеп тормаган каршылык шәхси яссылыкны гына үз эченә ала. Кобыгыл күңелендәге ачу-ярсуны басып, иленә тугры хезмәт итә. Аның шәхси үчлектән өстен торуын драматург төрле күренешләр аша күрсәтә. Туктамыш хан да гаскәр башлыгының халкына, җиренә, ханына бирелгәнлеген, үз-үзен җәлләмичә хезмәт итүен югары бәяли. Кобыгыл би пьесада ил-халык улы буларак калка. Ул яшь вакытта ук үзенең һәм көче, һәм тапкырлыгы белән дан казана. Хәзер дә хан йомышларын үтәгәндә гаделлек, дөреслек ягында тора. Икенче яктан, Кобыгыл ил-дәүләтнең көче бердәмлектә, дуслыкта икәнен яхшы аңлап эш итә. Илнең эчке һәм тышкы сәясәтен яхшы белгән Кобыгыл би күңелендә Туктамыш ханның һәм аның төрле төбәкләрдәге баскакларының кара халыкны талавына, җәберләвенә ризасызлык үсә. Драматург Кобыгыл-Идегәй күңелендәге көрәшне, каршылыкны, аның икеләнүле уйларын бөтен тирәнлегендә ача алган. Гаделсезлек, халыкның яклаучысыз калуы, бер яктан, шәхси үч алу теләге, икенче яктан, аны Туктамыш ханга һәм аның хакимлегенә каршылыкка этәрсә дә, ул ашыгыч адымнан саклана. Дөрес, якыннары арасында Кобыгыл-Идегәй күңелендәге ачу-нәфрәтне саклап кала алмый. Әмма, әйтелгәнчә, ил белән идарә итүгә гаять зур йогынты ясаучы кеше буларак, үзенең эш-гамәле белән Җүчи Олысында таркаулык тудыру, аннан ил дошманнарының файдаланырга омтылачагын яхшы аңлый. Шуңа да шәхси мәнфәгать һәм ил өчен җаваплылык мәсьәләсендә Кобыгыл-Идегәй икенчесенә өстенлек бирә. Әмма тормышта мәкер һәм хыянәт, әләк һәм золым йогынтысыннан кеше котыла алмый. Субра карт Кобыгылның асылда Котлыкыя улы булуын әйткәч, Идегәйгә үлем куркынычы туа, һәм ул Аксак Тимер ягына качып китә. Төрле төбәкләрдә яшәүчеләрнең үзен азатлык алып килүче буларак көтүләрен ишеткәч, Идегәй аңлавы һәм аңлатуы да гаять катлаулы булган адым ясый: Аксак Тимер гаскәре белән Алтын Урдага яу белән чыга. Идегәй үзен-үзе болай дип акларга омтыла: «... Бу ике дошман – Аксак белән Туктамыш – гаскәрләре бәрелсеннәр маңгайга – маңгай! Менә шунда без дә үзебезнекен итәрбез!» Ул теләгенә ирешә. Сугышта Туктамыш хан үтерелә, гаскәре тар-мар ителә. Идегәй, үзенең улы Норадын ярдәме белән, Аксак Тимерне куып җибәрә. Әмма әлеге җиңү аңа шатлык та, җан тынычлыгы да китерми. Эш-гамәлләренең

илгә кайгы-хәсрәт алып килүенә Идегәй тирән сызлана. Шәхси теләк һәм ил-халык мәнфәгатенә нигезләнгән конфликт ата-бала каршылыгы, мәхәббәт коллизияләре, аерым кешеләрнең мәкер-хыянәте аша тагын да үстерелә, тирәнәйтелә.

Трагедиядә вакыйгалар дәүләтнең җимерелүе, төп геройларның берберсен үтерүе белән тәмамлана. Күп газап-әрнүләр, фаҗигаләр кичергән халыкның ялган-мәкергә йөз тоткан Җанбай кебекләр кулына калуы искәртелә. Шулай итеп, XIV–XV гасырлар чигендә барган вакыйгалар һәр чорга, һәр заманга хас яңгыраш ала. Драматург төрки-татарның фаҗигале тарихы аша сабак бирә, милли рухны уята, үзаң тәрбияли. Кешелек җәмгыятендә формалашкан кыйммәтләр – гаделлек, намус, миһербанлылык, ил-халык мәнфәгатен кайгыртып яшәү, дуслык-бердәмлек, шәхес азатлыгы һ.б. өчен җаваплылык тойгысы тәрбияли.

Шулай итеп, тарихи, социаль, мәдәни һ.б. шартларга бәйле әдәбият, җитди үзгәрешләр кичереп, төрле дәверләр, этаплар, чорлар аша үтә. Әлеге зур вакыт аралыгында күләмле әдәби бергәлекләр оеша: иҗат тибы, иҗат юнәлеше, иҗат методы, иҗат агымы. Кешенең тормышны танып-белү үзенчәлеге белән бәйле булган иҗат типлары, иҗтимагый, мәдәни һәм эстетик шартлар тугач, чынбарлыкны танып белүнең уртак принципларына нигезләнгән бердәмлек рәвешендәге иҗат юнәлеше булып формалаша.

Әдәби юнәлеш әдәби фикерләү тибы һәм иҗат агымы белән үзара якын әдипләр иҗатыннан оеша. Дөнья әдәбияты тарихында классицизм, сентиментализм, романтизм, реализм, модернизм кебек иҗат юнәлешләрен аерып чыгаралар. Татар әдәбият белемендә озак вакытлар дәвамында классицизм юнәлеше әдәби күренеш буларак урын алмаган, аның үрнәкләре татар укучысына XX йөз башында тәрҗемә әсәрләр аша гына килеп ирешкән дип санала. Соңгы еллардагы тикшеренүләр күрсәткәнчә, татар әдәбиятында классицизм эстетикасының асылын билгеләгән хис һәм бурыч каршылыгы шәхси теләк-омтылыш һәм милләт язмышы өчен җаваплылык рәвешендә үзгәртелеп урын алган әсәрләр дөнья күрә.

### *2.2.2. Татар әдәбият фәненең модернизм һәм постмодернизмга мөнәсәбәте*

Хәзерге татар әдәбият теориясендә әдәби процессны яисә аерым язучы иҗатын әдәби юнәлеш-агым тарафдары буларак бәяләү омтылышы көчәйде. Шуңа бәйле рус һәм дөнья әдәбият белемендә инде калыплашкан термин-төшенчәләр – модернизм, постмодернизм, символизм, сюрреализм, конструктивизм, экзистенциализм һ.б. – шактый киң рәвештә кулланышка керде. Дөрес, аларга караш бертөрле түгел. Берәүләр моны чит халыклар әдәбият белеменә мөкиббән китү, алардагы күренешләрне үзебезгә күчереп кую дип бәяләсә, икенчеләр татар

әдәбиятындагы эзләнүләрнең киңәюен, әдипләрнең реализм һәм романтизмга хас булмаган алым-чараларга мөрәҗәгать итеп, үзенчәлекле әдәби дөнья тудыру омтылышларын таныган хәлдә, мондый әсәрләрне хәзерге әдәби барыштагы төп тенденция рәвешендә тәкъдим итү яисә аларның сәнгатилек дәрәҗәсен бик югары күтәреп бәяләү белән килешмиләр. Мисал өчен, танылган галим-тәнкыйтьче Р. Сверигин «Гасырлар чатында» язмасында З. Хәким, Р. Сибат кебек авторларның үзләренә хас мөстәкыйль һәм кабатланмас иҗат мохитен табуларын билгеләп, «бу шәхесләрнең иҗади эзләнүләрен бер селтәнү белән ниндидер экзистенциализм, модернизм яки һ.б. «изм» дип йөртелүче башка тартмаларга урнаштырып куючылар да табылыр. Әмма бүген бу иҗат дөньяларының формаль классификациягә генә түгел, ә конкрет өйрәнүгә һәм махсус тикшерүгә мохтаҗ икәнлеге дә ачык күренә»[1] дип искәртә. Соңрак дөнья күргән мәкаләсендә XX гасырның икенче яртысында татар әдәбияты ирешкән казанышларның «милли реалистик күренешләр җирлегендә» үсеп чыгулары турында яза һәм болай дип дәвам итә: «реалистик нигездәге әдәбият заман укучысы өчен якынрак булып кала бирә, һәм бу әдәбиятның да үз яңалыклары, үз ачышлары, үз табышлары бар, тик аларның исемнәрен, атамаларын, категорияләрен әллә каян читтән түгел, ә милли әдәбият-сәнгатьнең үз җирлегеннән табасы иде. Шулай ук бу урында могтәбәр әдәбият белгечләренең кайбер хезмәтләрендә авангардизм әсәрләрен әдәбиятның гел гүзәл казанышлары рәвешендә тәкъдим итү, күңелдә, ким дигәндә, гаҗәпләнү һәм сәерсенү уята»[2]. Ул тәнкыйтьче З. Хәким, Ә. Гаффар һ.б. әдипләрнең «модернизм юнәлешендә кызыклы эзләнүләр» алып баруларын таный. Шуңа да аның «модернизм күренешләрен бәяләүгә, яңа модага санап кына, аның асылына, философиясенә төшенеп җитмичә, алынырга ашыкмаска кирәк» диюе белән, һичшиксез, килешергә кирәк.

Шулай да хәзерге татар сүз сәнгатендә модернистик һәм постмодернистик эзләнүләрнең асылы нидән гыйбарәт соң? Модернизм һәм постмодернизм, сәнгати фикерләүнең, дөньяга әдәби-эстетик карашның үзенчәлекле юнәлешләре буларак, бөтендөнья әдәбиятында шактый тулы өйрәнелгән[3]. Татар сүз сәнгате яшәешнең, кеше аңының каршылыклы якларын өйрәнү объекты саналган әлеге күренешләргә сак мөрәҗәгать итә. Әмма бу һич тә аны тулысынча кире кага дигән сүз түгел, бәлки

[1] *Сверигин Р.Х.* Гасырлар чатында // Казан утлары. 2002. № 4. Б. 154.

[2] *Сверигин Р.* Яңа замана, яңа геройлар // Казан утлары. 2004. № 11. Б. 166.

[3] *Ильин И.П.* Постмодернизм от истоков до конца столетия: эволюция научного мифа. М.: Интрада, 1998. 255 с.; *Данилова И.Л.* Модерн – Постмодерн? О процессах развития драматургии 90-х годов. Казань: Фэн, 1999. 96 с.; Современное литературоведение (страны Западной Европы и США): концепции, школы, термины. Энциклопедический справочник. 2-е изд., испр. и дополн. М.: Интрада. ИНИОН, 1999. 315 с.; *Скоропанова И.С.* Русская постмодернистская литература: учеб. пособие. 2-е изд., испр. М.: 2000. 608 с. һ.б.

татар әдәбиятының дөнья сүз сәнгатендәге яңа сыйфат-күренешләрне турыдан-туры күчереп кую белән шөгыльләнмичә, үзенең эчке закончалыкларына һәм милли традицияләргә таянып үзләштерүе яисә, заман таләбе буларак, яңа алым-чараларга мөрәҗәгать итүе. Соңгы еллардагы тикшеренүләр күрсәткәнчә, XX йөз башы сүз сәнгатендә модернизм әдәби юнәлеш булып формалашып җитә, татар әдипләре аның аерым агымнарын шактый тулы үзләштерәләр[1].

XX гасырның соңгы чирегендә, аерым алганда 60–70 нче елларда чынбарлыкны модернистик күзаллауның дөнья әдәбият белемендә кабул ителгән алым-формаларын, чараларын үзләштерү омтылышлары булса да, идеологик шартларга бәйле алар үсеш алмадылар, бәлки соцреализм эстетикасының яңартылуы, баетылуы дип кенә бәяләнделәр[2]. Хәзерге әдәбият фәнендә бу каршылыктан чыгуның уңышлы үрнәкләре пәйда булды. Аерым алганда, әлеге чор әдипләреннән И. Юзеев, Р. Гаташ, Р. Фәйзуллин һ.б. иҗатын әдәбият фәненең яңа казанышларына нигезләнеп тикшергән Й. Нигъмәтуллина аларның модернистик алымнарга актив мөрәҗәгать итүен, үз чоры тәнкыйтенең һәм фәненең әлеге яңалыкларны күреп тә, аңлатып та бирә алмавын дәлилли[3].

XXI гасыр башы татар әдәбият фәнендә ике гасыр чигендә дөнья күргән бер төркем әсәрләрне модернизм яисә постмодернизм концепцияләре белән бәйлелектә тикшерү үрнәкләре аларны аңлауда, кабул итүдә шактый каршылыклар булуын күрсәтә. Татар әдәбиятында реализм һәм романтизм кысаларына гына сыеп бетми торган әсәрләр булуын инкарь итеп булмый. Хәзерге әдәби барышта үзенчәлекле урын алып торган әлеге катламны Ф. Бәйрәмова, Н. Гыйматдинова, М. Гыйләҗев, З. Хәким, Р. Хәмид, Г. Гыйльманов һ.б. тарафыннан өйрәнүбәяләүнең каршылыклы булуы яисә әлеге авторларның әдәби-эстетик карашлары тулысынча ачылып җитмәү шуның белән аңлатыла. Татар әдипләре шактый иркен рәвештә яңа формаларга, үзенчәлекле метафорага, яңа әдәби дөнья тудыру алымнарына, аерым фрагментлар буларак аңлашылган күренешләрне бергә кушуга, монтажлауга, әдәби образлар буларак архетипларга, образ-мотив һәм образ-топосларга иркен мөрәҗәгать итәләр. Болар сүз сәнгатендә билгеле агымнарның

[1] *Ганиева Р.К.* Татарская литература: традиции, взаимосвязи. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. С. 92–100, 198–212; *Саяпова А.М.* Дардменд и проблема символизма в татарской литературе. Казань: Алма-Лит, 2006. С. 54–66; *Заһидуллина Д.Ф.* Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. Б. 11–45, 80–117; *Загидуллина Д.Ф.* Модернизм в татарской литературе первой трети XX века. Казань: Татар. кн. изд-во, 2013. С. 6–10 һ.б.

[2] *Мусин Ф.М.* Әдәбият фәне һәм тәнкыйть // Татар әдәбияты тарихы: алты томда: VI т.: 60–90 еллар әдәбияты. Казан: Раннур, 2001. Б. 458–479.

[3] *Нигматуллина Ю.Г.* «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. Казань: Фэн, 2002. С. 113–134.

яңаруы һәм яңаларының барлыкка килүе турында нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. Аларга хас сыйфат-билгеләрнең аерым автор иҗатында чагылышына бәйле тикшеренүләр белән Й. Нигъмәтуллина, Д. Заһидуллина, А. Шәмсутова, В. Әминева, М. Ибраһимов, Н. Йосыпова, А. Саттарова, И. Вәлиулла, Л. Йөзмөхәммәтова һ.б.ның хезмәтләрендә очрашабыз. Л. Йөзмөхәммәтова билгеләп үткәнчә, «татар фәнни җәмгыятендә шундый вакыт җитте, постмодернизм турында конкрет һәм киң итеп сүз алып бару кирәк, чөнки татар әдәби мохитендә һәм әдәбиятында әлеге күренешнең урын алуын кире кагып булмаган кебек, аның уңышлы һәм каршылыклы якларын да күрмәмешкә салышу мөмкин түгел»[1]. Сүз, нигездә, реалистик әдәбиятка хас булмаган алым-чаралар, иҗади фикерләү аша яшәешне үзенчәлекле танып-белү омтылышын, яңа бер тормыш моделен тергезү, уйлап табуны ачыклау турында бара. Татар әдәбият теориясе шактый ят, сәер күренешләрне, кешедә сызлану-кайгыру, гаҗизлек, төшенкелек яисә яшәү һәм үлемгә, аңсызлыкка бәйле чиктәш халәтләрне сурәтләгән әсәрләргә каршылыклы мөнәсәбәттә булды. Аның теоретик планда аз эшләнгән булуы хәзерге әдәби күренешләрне төрлечә бәяләүгә юл калдыра. Мисал өчен, Г. Гыйльмановның «Албастылар» роман-кыйссасын Д. Заһидуллина, А. Шәмсутова постмодернизм үрнәге дип бәяләсәләр[2], Й. Нигъмәтуллина әсәрне «соңарган модернизм» үрнәге буларак өйрәнә[3].

«Модернизм» төшенчәсенең сыйфат-билгеләре, аерым агымнарының XX йөз башы татар әдәбиятында урын алуы Г. Халит, Р. Ганиева, И. Нуруллин хезмәтләрендә билгеле бер дәрәҗәдә өйрәнелә. XX гасыр ахыры әдәбият белемендә Р. Ганиева, А. Саяпова, Ч. Зарипова-Четин хезмәтләрендә тагы да үстерелә, баетыла. Әлеге әдәби юнәлешкә хас агымнар фәнни-теоретик планда һәм шул чор әдәби барышына бәйле Д. Заһидуллинаның «Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы» хезмәтендә аеруча тулы чагылыш таба[4]. Яңарыш юлына чыккан XX йөз башы татар сүз сәнгатендә фани һәм бакый дөнья турында уйлану, җир тормышының чикләнгәнлеген, кеше гомеренең кыскалыгын аңлау, шуңа бәйле яшәү мәгънәсенә, Хакыйкатькә төшенү омтылышы һәм әлеге фәлсәфи карашларны әдәби чараларда чагылдыру теләге модернистик алымнар эзләүгә китерә. Автор билгеләгәнчә, модернизм «әдәбияттагы

[1] *Юзмухаметова Л.Н.* Постмодернизм в татарской прозе: диалог с западными и восточными художественными традициями: автореф. дис. канд. филол. наук. Казань, 2014. С. 4.

[2] *Заһидуллина Д.Ф.* «Албастылар» яки татар прозасында яңа сыйфатлар // Казан утлары. 2001. № 11. Б. 111–117; *Шәмсутова А.А.* Татар әдәбиятында «постмодернистик концепция» // Гыйльми язмалар. 2003. № 11. Б. 12–14.

[3] *Нигматуллина Ю.Г.* «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. Казань: Фэн, 2002. С. 144–150.

[4] *Заһидуллина Д.Ф.* Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. 255 б.

күнегелгән алым һәм ысулларны кире кага, әдәбиятның торышы-хәле белән риза булмаудан килеп чыга. Шул ук вакытта ул әдәбиятны камилләштерү-үзгәртүгә этәргеч бирә, үзгә юллар эзли». Шунысы игътибарга лаек, яңа алым-формаларда чагылыш тапкан югалту, кайгы, өметсезлек, курку мотивлары аша әлеге фаҗигалелекне булдырмау юллары эзләнә, Яшәешне хәрәкәткә китерүче көч буларак Өметкә йөз тотыла. Мондый сыйфат-үзгәрешләр яңа эзләнүләрнең, бер яктан, Коръән фәлсәфәсенә, аерым алганда, суфичылык әдәбиятындагы караш-фикерләргә барып тоташуын күрсәтсә, икенче яктан һәм өстенлекле рәвештә Европада киң таралган А. Шопенгауэр, Ф. Ницше, Вл. Соловьев карашларына таянуын ачыклый.

Тормыш-яшәеш катлаулы, каршылыклы булып, анда барган Яхшылык һәм Явызлык көрәше аерым кеше күңелендәге матурлык һәм ямьсезлек, өмет һәм өметсезлек, ышану һәм шикләнү тартышы-каршылыгына килеп тоташа. Еш кына әдәбиятта «ялгыз кеше трагедиясе» дип аталган сызлану яисә экзистенциализм фәлсәфәсенең нигезендә Яшәешнең камил булмавы, гомернең кыскалыгы, кеше ялгызлыгы һәм көчсезлеге хакындагы фикерләр ята. Шулар җирлегендә Яшәү һәм Үлем, Гөнаһ һәм Җәза, Өмет һәм Хакыйкать кебек төшенчәләргә бәйле бәхәсләр егерменче йөз башында күпсанлы әсәрләр иҗат ителүгә китерә. Аларны тирәнтен шәрехләү барышында Д. Заһидуллина сызлану фәлсәфәсенең төрлелеген, катлаулылыгын һәм гаять үзенчәлекле сәнгати фикерләүгә китерүен ача. Һәрбер яңа тип әдипнең иҗат йөзен, язу стилен күзалларга ярдәм итә.

Танылган әдәбият галиме Й. Нигъмәтуллина «“Запоздалый модернизм” в татарской литературе и изобразительном искусстве» исемле монографиясендә[1] хәзерге татар әдәбиятында һәм сәнгатендә барган яңа эзләнү-үзгәрешләрне «соңарган модернизм» дип атый. Автор фикеренчә, модернизм – XX йөз башы әдәбиятында чынбарлыкны әдәби чараларда чагылдыруның яңа юлларын эзләгән агымнарның (символизм, экспрессионизм, футуризм, кубизм һ.б.) гомум атамасы. Ә инде постмодернизм – XX йөз башы модернизмыннан соң барлыкка килгән һәм күпмедер дәрәҗәдә аңа каршы куелган төрле агым һәм мәктәпләрнең (магик реализм, неореализм, неоклассицизм, «абсурд театры» һ.б.) гомуми исеме. Әлеге ике төшенчәне аңлауда төрле караш-фикерләр булуны искә алып, автор аларның төп сыйфатларын чагыштырып бәяли. Й. Нигъмәтуллина постмодернизм әдәбиятының төп билгесе итеп реаль чынбарлыкны чагылдыруны түгел, бәлки үткән мәдәниятнең «эзләрен» яңадан тудыруны саный. Ә инде «натура»ны алыштырган «мәдәният» коллаж рәвешендә бирелә. Мәдәният

[1] *Нигматуллина Ю.Г.* «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. Казань: Фэн, 2002. 197 с.

өлкәсендә модернистлар киләчәккә йөз тоткан формалар эзләүне алга куйсалар, постмодернистлар хәзергене үткән белән бәйләү мөмкинлеге биргән синкретик формаларга омтылалар. Шуның белән бергә, автор әлеге ике юнәлешнең уртак билгеләрен дә аерып чыгара: тормышта һәм сәнгатьтә күзәтелгән кризисны тирәнтен һәм үткен тоемлау; әдәбият-сәнгать телен үзгәртү омтылышы; иҗатны программалаштыру; укучы-тамашачының ролен үстерү теләге һ.б.

Галимә фикеренчә, XX гасыр башы татар әдәбиятында модернизмның аерым күренешләре булса да (Дәрдемәнд һәм Такташ символизмы, Г. Кутуй футуризмы, К. Нәҗми имажинизмы), тулы агым рәвешендә урын алмый. Ә инде 1970–1980 елларда аның икенче тууы күзәтелә, шуның өстенә ул постмодернизм һәм реализмның аерым элементларын үзенә алып, алар белән янәшә яши. XX гасыр башындагы «идеяләр романтизмы» гасыр ахырында яңадан алгы планга чыга, дип саный автор. Милли үзаң үсү, үткән тарихка идея-эстетик бәя бирү, тормыш-яшәештәге идеаллар үзгәрү милләт язмышы, аның кешелек тарихындагы урыны, киләчәге һәм киң планда кеше һәм тарих, кеше һәм галәм, җәмгыять һәм табигать һ.б. турында уйлануларга китерә. Әлеге һәм башка әхлакый, фәлсәфи, эстетик сораулар әдәбият-сәнгатьтә дә форма, жанр, стиль өлкәсендәге эзләнүләргә юл сала. Хәзерге татар әдәбиятында модернизм мөстәкыйль агым буларак формалашып җитмәсә дә, аның аерым тенденцияләренең үтеп керүен инкарь итеп булмый, дип саный Й. Нигъмәтуллина.

Модернизм күренешенең табигатен аңлауга бәйле Л. Ибраһимованың «Модернизм в татарской и русской прозе 1900–1920 гг.: проблемы поэтики»[1] хезмәте игътибарга лаек. Автор XX йөз башы татар әдәбиятында урын алган модернизмның әдәби-эстетик үзенчәлекләрен, аның фәлсәфи һәм әдәби-эстетик тамырларын өйрәнеп, аларны рус әдәбиятындагы охшаш күренешләр белән чагыштыра. Татар әдәбиятында модернизм әдәби аңның экзистенциаль тибын алгы планга чыгара, дип күрсәтә тикшеренүче. Ул исә авторның менталь сыйфатлары, иҗат методында һәм стиленә хас үзенчәлекләрдә чагылыш таба.

Постмодернизмның үзенчәлекләре һәм аның татар әдәбиятында чагылу мәсьәләләренә Д. Заһидуллина «“Албастылар” яки татар прозасында яңа сыйфатлар» мәкаләсендә[2] туктала. «Бездә постмодернизм да һәм фәлсәфи-эстетик, һәм поэтик-стилистик яклардан билгеле бер милли сыйфатларга ия булып, Европа яки рус әдәбиятындагы шул исемдә аталган алымнардан аерылып торды», – дип яза ул. Мөһим

[1] *Ибрагимова Л.Г.* Модернизм в татарской и русской прозе 1900–1920 гг.: проблемы поэтики: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2014. 27 с.

[2] *Заһидуллина Д.Ф.* «Албастылар» яки татар прозасында яңа сыйфатлар // Казан утлары. 2001. № 11. Б. 111–117.

сыйфатларның берсе буларак татар авторларының парадоксальлеккә түгел, ә реальлеккә омтылуы, әсәрләрнең синтетик төсмерле булуы билгеләнә. Икенче бер үзенчәлек итеп «бер әсәр чикләрендә төрле темалар, әдәби алымнар, стильләр, төрле әдәби-тарихи традицияләрнең очрашуы» күрсәтелә. Болардан тыш, «әсәр чынбарлыгы һәм реаль чынбарлыкның аерып куелуы», «үз дөньясы хакында сөйләүче язучы-автор урынын язучы-скриптор (кәгазьгә төшерүче)» алу; үзенчәлекле Яшәеш моделен төзү һ.б. сыйфатлар күрсәтелә.

Д. Заһидуллина бу өлкәдәге тикшеренүләрен дәвам итеп, «ХХ гасыр татар әдәбияты тарихы» дәреслегендә[1] модернизм татар әдәбиятында ХХ йөз башында нигездә оешып җитә һәм тулы канлы әдәби юнәлеш буларак урын ала дигән фикерен ассызыклый. Ә инде постмодернизм күренешенең ХХ гасыр ахыры – ХХI гасыр башы әдәбиятында үзгә бер көчле агым тәшкил итүен конкрет мисалларда күрсәтә.

Инде әйтеп үтелгәнчә, Д. Заһидуллина Г. Гыйльмановның «Албастылар» романын постмодернизм үрнәге буларак тикшерсә, Й. Нигъмәтуллина әлеге әсәрне «соңарган модернизм» үрнәге дип саный һәм төп нигез сәбәп итеп әсәрнең идея-эстетик бөтенлеген тәэмин итүче Автор образы булуны һәм сурәтләнгән вакыйгаларда фрагментларга түгел, ә бөтенлекле тормыш күренешләренә йөз тотуны билгели. Гомумән, татар әдипләренең постмодернизмга сак килеп, аның төп принципларыннан берсе булган әсәрдән автор шәхесен «алу»ны кабул итмәүләре турындагы фикерне алга куя. Шуның белән бергә, авторның кайбер фикер-карашлары бәхәс-дискуссиягә урын калдыра. Галимә хәзерге татар драматургиясенең аерым үрнәкләрен «уен» төшенчәсенә бәйле тикшереп, «соңарган модернизм» чагылышы дигән нәтиҗәгә килә. Әдәбият белемендә «уен»ның, бер яктан, сурәтләү предметы, икенче яктан, әдәби алым буларак чагылыш табуы шактый тулы тикшерелгән. Й. Нигъмәтуллина Т. Миңнуллинның «Хушыгыз» пьесасын жанр формасы буенча «психологик драма», ә иҗат методы ягыннан «реалистик әсәр» дип күрсәтә. Ә инде «дуслар»ның күп еллар дәвамында дус булып уйнаулары сурәтләнгән булуны нигез итеп алып, аны «соңарган модернизм» кысаларында өйрәнә. Әлеге фикер тулысынча дәлилләнми кебек. Без пьесаны «яңа реализм» төшенчәсе белән аңлату ягында. Әсәрдә Миләүшәнең соңгы көннәре сурәтләнә. Ул гомере буе омтылып та чын мәхәббәткә, бәхеткә ирешә алмаганын аңлауга, үзенең генә түгел, «дуслар»ының да, Галиулланың да бәхетсез булуын ачкан Хакыйкатькә килә. Шул рәвешле сызлану фәлсәфәсе барлык геройларның язмышын иңләп үтә. Әлеге зур булмаган күзәтүгә нигезләнеп мондый нәтиҗә ясарга мөмкин: «Хушыгыз» төрле агым-юнәлешләр синтезы булып тора,

[1] *Заһидуллина Д.Ф., Йосыпова Н.М.* ХХ гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек. Казан: Казан ун-ты, 2011. 1 нче кит.: ХХ йөзнең беренче яртысында татар әдәбияты. 230 б.

ягъни анда реализм (геройларның эш-гамәлләре тулы мотивлаштырылган), романтизм (Миләүшә белән Галиулланың яшьлеге, мәхәббәте, истәлек-хатирәләре, хыял дөньясы романтик агым-катлам алып килә) һәм модернизмга хас алымнарның (югарыда әйтелгән сызлану фәлсәфәсенә китерүче чиктәш халәт һ.б.) кушылып, үрелеп баруын күрәбез.

Мәгълүм булганча, модернизмга хас сурәтлелек белән мәсьәлә азмы-күпме ачык булып, аның шактый тотрыклы алым-чаралары, сыйфат-билгеләре күрсәтелсә, постмодернизм белән эш күпкә катлаулырак. Д. Заһидуллинаның югарыда күрсәтелгән хезмәтеннән тыш, хәзерге татар сүз сәнгатендә барган әдәби-эстетик эзләнүләрне постмодернистик концепция белән бәйләп өйрәнүчеләрнең берсе – А. Шәмсутова. Югары уку йорты студентлары өчен чыгарылган «Татар әдәбиятында постмодернистик концепцияләрнең чагылышы» дип аталган махсус курс программасында ул постмодернизм күренешен «тәмамланмаган, үсеш-үзгәрештә булган һәм төрле мәдәниятләрдә чагылыш тапкан, мәдәниятнең һәм сәнгатьнең барлык төрләренә, формаларына йогынты ясаган, дөньяга карашның яңа төрен формалаштыруга китергән динамик (хәрәкәттәге) процесс буларак» карый[1].

А. Шәмсутованың бу мәсьәләгә бәйле караш-фикерләре «Татар әдәбиятында «постмодернистик концепция» мәкаләсендә тагы да үстерелә. Хәзерге әдәбиятта сурәтләүнең яңа формаларын эзләү язучының фикерләү рәвеше белән бәйлелегенә таянып, «әдәби әсәрдә туган яңа сурәтләү теле, образлар, формалар беренчел булып кала бирә», дигән карашны яклый. Автор татар сүз сәнгатендә постмодернизмның башлангычын XX гасырның «70 нче еллар ахыры – 80 нче еллар башында ук татар әдәбиятында яңача фикерләүгә, социалистик реализм методының катгый таләпләреннән читкә китәргә омтылу» көчәйгән чор белән бәйләп карый һәм шушы чорда «сәясилектән читкә китеп, шәхеснең психологиясен тагын да тирәнтен ачарга омтылган, галәм, яшәеш турында фәлсәфи планда уйлана торган әсәрләр барлыкка килә» дип билгели. А. Шәмсутова фикеренчә, әлеге агым татар әдәбиятында түбәндәге үзенчәлекләргә нигезле чагылыш таба: 1) әсәр геройларының «рухи кризис» кичереп, ялгызлыкта булуы, шуңа бәйле гаять тирән психологизм аша, үзәгендә хисчәнлек яткан «шизоанализ» алымы белән сурәтләнгән геройларның рухи халәте алгы планга чыгу; 2) яшәешнең аерым якларын фаш итү өчен әсәрләрдә пародия тудыру, шуның ярдәмендә тормышның абсурдлыгын, башкарган гамәлләрнең мәгънәсез, буш, көлке булуын күрсәтү; 3) «уен» категориясенә мөрәҗәгать итү; 4) әсәрдәге пародияне, уен атмосферасын көчәйтү өчен коллаж алымын файдалану; 5) классик әсәрләрдән алынган «цитаталар»ны куллану. Шуларга

[1] Татар әдәбиятында постмодернистик концепция чагылышы: махсус курсның уку-укыту һәм гамәли дәресләр программасы. Казан: Гуманитария, 2003. 36 б.

нигезләнеп, автор «яңа сурәтләү теле белән язылган әсәрләрдә дөньяның бербөтен булмавы, ниндидер конкрет бер сурәтләү алымы ярдәмендә генә чынбарлыкны тасвирлау мөмкин түгеллеге ачык чагыла», ә бу исә «яңа фәлсәфи-эстетик, социокультур концепция (төгәлрәк әйткәндә, постмодернистик концепция) туу турында сөйли» дигән нәтиҗәгә килә[1]. Әлеге үзенчәлекне үзенең тикшеренүләрендә И.С. Скоропанова болай күрсәтә: «Урнашып килүче постмодернистик эстетика төрле һәм каршылыклы, тотрыклы түгел. (...) Барлык эстетик категорияләр юыла, эстетикага караган чикләр җимерелә, эстетик таләпләрдән баш тарту күзәтелә. Сәнгать һәм матурлыкны традицион шәрехләү башка җиңелрәк формалар белән алышына»[2].

А. Шәмсутованың фикер-карашлары кызыклы булып, аерым авторлар иҗатына башка яктан якын килү, моңа кадәр игътибардан читтә калган сыйфат-үзенчәлекләрне ачу-аңлату мөмкинлеге бирә. Шуның белән бергә, аерым сораулар буенча эзләнүләрне дәвам итү кирәклеге күренә. Мисал өчен, әлеге агымга хас үзенчәлекләр буларак аерып чыгарылган алымнарга (ялгызлык, көчле психологизм, пародия, уен, коллаж) башка юнәлеш-агымнарның да кушылып китүен беләбез. Шуның өстенә постмодернизмның И.Ильин, И. Скоропанова, И.Данилова кебек тикшеренүчеләр билгеләп үткән мөһим сыйфат-билгесе – әсәрдә автор образы булмау – татар әдәбиятына хас түгел (бу турыда Й. Нигъмәтуллина фикерләрен китергән идек инде).

Соңгы елларда постмодернизмга игътибар артуның бер чагылышы буларак, Л. Йөзмөхәммәтова тарафыннан әлеге әдәби һәм мәдәни күренеш махсус тикшерү объекты итеп алына. Аның «Новые явления в татарской прозе рубежа XX – XXI веков: постмодернизм» монографиясендә[3] ике гасыр чигендә дөнья күргән бер төркем проза әсәрләренә постмодернизм концепциясендә бәя бирелә. Тикшеренүче фикеренчә, әлеге чорда татар әдипләре постмодернизм поэтикасын шактый уңышлы үзләштерәләр. Бу аеруча З. Хәким, Ф. Бәйрәмова, Г. Гыйльманов, М. Кәбиров кебек авторлар иҗатында киң урын алып, бер яктан, текст эчтәлегендә автор позициясен белдерү буларак чагылса, икенче яктан, поэтика алымнары рәвешендә башка юнәлеш элементлары белән кушылып китә.

Й. Нигъмәтуллина, Д. Заһидуллина, А. Шәмсутова, Л. Йөзмөхәммәтова кебек авторларның XX – XXI гасырлар чигендә татар әдәбиятындагы үзенчәлекле күренешләрне модернизм һәм постмодернизм

[1] *Шәмсутова А.А.* Татар әдәбиятында «постмодернистик концепция» // Гыйльми язмалар. 2003. № 11. Б. 12–14.

[2] *Скоропанова И.С.* Русская постмодернистская литература: учеб. пособие. 2-е изд., испр. М.: 2000. С. 66.

[3] *Юзмухаметова Л.Н.* Новые явления в татарской прозе рубежа XX–XXI веков: постмодернизм. Казан: Изд-во Казан. ун-та, 2016. 220 с.

төшенчәләренә бәйле тикшерүләре беренче адымнар гына булып тора. Авторлар үзләре дә моны таныйлар һәм хезмәтләрендә искәртәләр. Хәзерге татар әдәбиятындагы яңа күренеш-сыйфатлар турында сүз алдагы бүлекчәдә барачак.

Шулай итеп, хәзерге татар әдәбияты фәнендә ике гасыр чигендә дөнья күргән бер төркем әсәрләрне модернизм яисә постмодернизм концепцияләре белән бәйлелектә тикшеренү үрнәкләре аларны аңлауда, кабул итүдә шактый каршылыклар булуын күрсәтә. Реализм һәм романтизм кысаларына гына сыеп бетмәгән, әдәби барышта үзенчәлекле урын алып торган әсәрләр катламын өйрәнү-бәяләүнең каршылыклы булуы яисә әлеге авторларның әдәби-эстетик карашлары тулысынча ачылып җитмәү шуның белән аңлатыла. Сүз, нигездә, реалистик әдәбиятка хас булмаган алым-чаралар, иҗади фикерләү аша яшәешне үзенчәлекле танып-белү омтылышын, яңа тормыш «моделе»н уйлап табу турында бара. Й. Нигъмәтуллина, Д. Заһидуллина, А. Шәмсутова, Л. Йөзмөхәммәтова һ.б. авторлар хәзерге татар әдәбиятында *модернизмның* түбәндәге сыйфат-билгеләрен аерып чыгаралар: төрле стильләрнең синтезы һәм аларның реализм белән катлаулы мөнәсәбәт-бәйләнеше; урта гасырлар романтик әдәбиятының аерым традицияләре активлашу; әдипләрнең актив рәвештә архетипларга, мифологемнарга, фантастик һәм шартлы формаларга, символларга мөрәҗәгать итүе; әдәби алым һәм сурәтләү предметы буларак «уен»ны, шулай ук «нулевая композиция», ин-янь принцибын куллану; автор концепциясен шартлылык һәм билге-символ аша чагылдыру тенденциясе; милли теманың мөһим проблематика буларак алгы планга чыгуы; күптөрлелек, цикләнгәнлек һәм чиксезлек кебек фәлсәфи проблемаларга йөз тоту; әдипләрнең фәлсәфилеккә, хикмәтле сүз әйтүгә, притча жанрына теләп мөрәҗәгать итүләре һ.б. Ә инде хәзерге татар сүз сәнгатендә *постмодернизм* әдәбиятына хас түбәндәге билгеләрнең урын алуы күрсәтелә: үткән мәдәниятнең «эзләрен» яңадан тудыру; «натура»ны алыштырган «мәдәният»нең коллаж рәвешендә бирелүе; хәзергене үткән белән бәйләү мөмкинлеге биргән синкретик формаларга омтылу; авторларның парадоксальлеккә түгел, ә реальлеккә йөз тотуы; бер әсәр цикләрендә төрле темалар, әдәби алымнар, стильләр, төрле әдәби-тарихи традицияләрнең очрашуы күрсәтелү; әсәр чынбарлыгы һәм реаль чынбарлыкның аерып куелуы; үз дөньясы хакында сөйләүче язучы-автор урынын язучы-скриптор (кәгазьгә төшерүче) алу; рус яки Европа әдәбиятындагы мондый алымнардан аермалы буларак, лириклыкка омтылу; эпитетлар һәм детальләштерү алгы планга чыгу; үзәгендә хисчәнлек яткан «шизоанализ» алымына, коллажга, пародия тудыруга һ.б.га актив мөрәҗәгать итү. Шуның белән бергә, татар әдипләренең постмодернизмга сак мөрәҗәгать итүләре, аның төп принципларыннан берсе булган әсәрдән автор шәхесен «алу»ны кабул итмәүләре билгеләнә.

## 2.3. Әдәбиятта иҗат методы: аны аңлау-аңлатуның үзгәрүе

XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы татар әдәбият теориясе игътибар үзәгендә торган мәсьәләләрнең берсе булып «иҗат методы» төшенчәсе тора. Теоретик фикердә әлеге сорауның көн тәртибенә куелуы, бер яктан, җәмгыятьтәге социаль-мәдәни үзгәрешләргә, аерым алганда, марксизм-ленинизм тәгълиматына нигезләнгән методологиянең берьяклы булуын аңлауга һәм аңа тәнкыйди караш формалашуга, икенче яктан, күчеш чорында реализмның билгеле бер кризиска керүе һәм акрынлап аннан чыгу юлларын эзли башлавына нигезләнә. XX гасырның 90 нчы еллары дәвамында сүз сәнгатенең үсеш юллары, иҗат тибы, иҗат юнәлеше, иҗат методы, аеруча соцреализм методына мөнәсәбәт һ.б. бәйле фикер алышуларда әлеге терминның асылын билгеләүче байтак сораулар шактый тулы ачыкланса да, киң планда караганда, каршылыклы һәм бәхәсле мәсьәләләр хәл итүне сорый. Әйтик, «иҗат методы» төшенчәсенең асылы; татар әдәбият белемендә «иҗат методы» төшенчәсенә караш; төрле иҗат методларының, шул исәптән социалистик реализм иҗат методының эстетикасы, аларның үзгәреше һ.б.

Әдәбият белемендә «иҗат методы» төшенчәсен аңлатуда төрле карашлар яшәп килә. Берәүләр әлеге терминны әсәрнең эчтәлеге, төп проблематикасы белән бәйләп аңлатырга омтылса, икенчеләре исә әдәби юнәлеш яисә агым төшенчәсе белән тәңгәлләштереп кабул итә. Билгеле булганча, фәлсәфәдә кулланылып килгән әлеге термин 1930 еллар чигендә әдәбият фәненә күчерелә һәм, беренче чиратта, чынбарлык күренешләрен иҗади планда чагылдыру принциплары берлеге буларак, социалистик реализм, тәнкыйди реализм төшенчәләрен билгеләү өчен кулланыла башлый[1]. Татар әдәбиятына бәйле тикшеренүләрдә иҗат методына хас үзенчәлекләрне ачуда рус әдәбияты фәненең күренекле вәкиле Н.А. Гуляев һәм төрки халыклар әдәбиятын өйрәнүче А.А. Гаджиев хезмәтләре нигез булып тора. 1950 еллар ахыры – 1960 еллар башындагы «Хрущев җепшеклеге» әдәбият белеменең төрле тармакларында җитди эзләнүләргә юл ача. КДУда рус әдәбиятын өйрәнүне тикшергән Й. Нигъмәтуллина болай дип яза: «“Традицион” әдәбият белеме кысаларында моңа кадәрге елларда аерым язучылар иҗаты буенча тупланган бай фактик материалны типологик гомумиләштерү ихтыяҗы туа. Шуңа бәйле рәвештә язучының “әдәби методы” (“иҗат методы”), “әдәби юнәлеш” һәм “әдәби агым” төшенчәләренә генә түгел, бәлки “әдәби иҗат тибы”, “әдәби фикерләү тибы” кебек югарырак типологик төшенчәләргә дә җитди игътибар бирелә башлый»[2].

[1] *Нуруллин И.З.* Путь к зрелости: Формирование и развитие критического реализма в татарской литературе. Казань: Татар. кн. изд-во, 1971. 271 с.

[2] *Нигматуллина Ю.Г.* Изучение русской литературы в КГУ // Ученые записки Казанского государственного университета. Серия Гуманитарные науки. 2009. Т. 151, кн. 3. С. 9.

Әлеге төр эшчәнлекнең башында торучыларның берсе – профессор Н.А. Гуляев. Аның хезмәтләре (аеруча романтик иҗат тибы үзенчәлекләрен ачуга багышланганнары)[1] татар әдәбият белеме өлкәсендә эшләүчеләргә дә көчле йогынты ясый. И.З. Нуруллин беренчеләрдән булып татар әдәбият белемендә иҗат методы мәсьәләсен әдәбият белеме казанышлары яктылыгында тикшерүгә алына. Аның «Вопросы литературы» (1970) журналында, аннары аерым җыентыкта басылып чыккан мәкаләсе бу юнәлештә җитди алгарыш була. Әйтергә кирәк, галимнең әлеге язмасы бөтен төрки халыклар әдәбият фәнендә җитди тикшеренүләргә этәргеч бирә. Үзе билгеләп үткәнчә, «мәгърифәтчелек реализмы» төшенчәсе Урта Азия һәм Кавказ регионнарындагы тугандаш республикаларның әдәбият белеменә дә үтеп керә һәм «гражданлык хокукы яулый»[2]. Рус әдәбият белеме һәм төрки халыклар әдәбиятында иҗат методы мәсьәләләре буенча тикшеренүләр яңа эзләнүләргә китерә. Нәтиҗәдә Э. Кәримов (үзбәк), Р. Һади-Задә (азәрбайҗан) һәм С. Сәгъдиев (таҗик), Я. Карыев (азәрбайҗан) һ.б.ның фәнни хезмәтләре дөнья күрә. Мәгърифәтчелек реализмының татар әдәбиятындагы үзенчәлекләре М. Гайнуллин («Татар әдәбияты. XIX йөз», 1968), Ш. Садретдинов («Сәгыйть Рәмиев иҗаты», 1973) хезмәтләрендә тагы да үстерелә. Н. Гуляевның шәкерте Й. Нигъмәтуллина романтизмга хас әдәби фикерләү билгеләрен әдәбиятның милли сыйфатлары белән тыгыз бәләнештә өйрәнә, нәтиҗә буларак рус һәм татар әдәбиятларындагы уртак һәм аермалы сыйфатларын ачуга килә. Аның «Национальное своеобразие эстетического идеала» китабы татар әдәбият белемендә казаныш буларак кабул ителә[3]. Иҗат тибына һәм иҗат методына караган мәсьәләләрнең аерым якларын тикшерүгә алынган О. Кадыйров татар классигы Г. Ибраһимов иҗатында романтизмның эстетик табигатен, әдипкә йогынты ясаган шартларны тикшерү аша рус һәм татар әдәбиятларының, аерым вәкилләренең үзара бағланышын бәяләүгә килә[4]. Билгеле, әлеге гаять җитди мәсьәләләрне өйрәнү югарыда аталган исемнәр белән генә чикләнми. XX йөз башы һәм совет чоры татар әдәбиятында иҗат методы, аерым алганда, мәгърифәтчелек реализмы, тәнкыйди реализм, социалистик реализм методлары, аларның үзара һәм

[1] *Гуляев Н.А.* Теория литературы: учеб. пособие для филол. специальностей ун-тов и пед.ин-тов. М.: Высшая школа, 1977. 278 с.; *Гуляев Н.А.* Литературные направления и методы в русской и зарубежной литературе XVII–XIX веков: кн. для учителей. М.: Просвещение, 1983. 144 с.

[2] *Нуруллин И.З.* Агач аяклардан төшү хәерле (Төрки телле әдәбиятларда реализм мәсьәләсе) // Тормыш һәм сәнгать чынлыгы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. Б. 173.

[3] *Нигматуллина Ю.Г.* Национальное своеобразие эстетического идеала. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1970. 212 с.

[4] *Кадыров О.Х.* Романтизм Галимджана Ибрагимова (Творчество и эстетика): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1967. 31 с.

башка агым-юнәлешләр белән мөнәсәбәте, шулай ук төрки халыклар әдәбиятында формалашу һәм чагылу үзенчәлекләре Х. Госман («Бөек Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы чорында татар поэзиясе», 1960), М. Хәсәнов («Галимджан Ибрагимов», 1969), И. Нуруллин («Путь к зрелости: Формирование и развитие критического реализма в татарской литературе», 1971; «XX йөз башы татар әдәбияты», 1982), Г. Халит («Проблемы творческого метода в татарской литературе (1905–1932)», 1967); «Яңа гасыр поэзиясе: XX йөз башы (1905–1917 еллар) татар поэзиясендә иҗат методы, лирик герой, традиция һәм новаторлык мәсьәләләре»), А. Сайганов («У истоков эстетики реализма», 1982), Р. Ганиева («Тукайның иҗат методы (романтик тенденцияләр эволюциясенә карата)», 1976; Төрки әдәбиятларда иҗат методы мәсьәләләре», 1979), шулай ук Т. Галиуллин, А. Әхмәдуллин, Х. Миңнегулов, Н. Хисамов, Ә. Шәрипов һ.б.ның хезмәтләрендә эзлекле бәяләнә, мөһим нәтиҗәләр ясала.

Иҗат методы әдипләр эшчәнлеге, аларның чынбарлыкны иҗади үзләштерүнең уртак принципларына нигезләнүе белән бәйле. Әлеге төшенчә билгеле бер шартларда, тирәлектә яшәп, үзенчәлекле шәхес булып формалашкан кеше характеры белән тыгыз бәйле. Нәкъ менә социаль тирәлек аны шул җәмгыять, андагы билгеле бер нормалар, принциплар белән тыгыз бәйләнештә карау мөмкинлеге бирә. Икенче төрле әйткәндә, методның асылы кеше характерының, вакыйга-күренешләрнең шул чор реаль шартларына туры килүе, ышандыру дәрәҗәсе белән бәйле. Гомумән, иҗат методына нисбәтле жанрның конкрет тарихи чорга бәйлелеген һәм сәнгатьнең озын эволюциясе нәтиҗәсе булуын билгеләү сорала. Чөнки иҗат методы нигезендә кеше һәм аны әйләндереп алган дөнья белән аның әдәби-иҗади тәҗрибәсе арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләр ята. Билгеле булганча, әдип чынбарлык күренешләрен билгеле бер фәлсәфи-эстетик принципларга нигезләнеп сайлап ала һәм кабаттан тудыра.

Иҗат тибы һәм иҗат методы төшенчәләренә үзенчәлекле теоретик карашлар белән Ф. Хатиповның «Әдәбият теориясе» хезмәтендә очрашабыз. Алдагы бүлекчәдә әйтелгәнчә, югары уку йортларында укучыларга дәреслек буларак тәкъдим ителгән китап татар телендә моңа кадәр чыгарылган дәреслекләр традициясенә, рус һәм Европа әдәбият теориясе казанышларына һәм авторның үз тәҗрибәсенә нигезләнеп язылган. Аерым теоретик төшенчәләр буенча кызыклы күзәтүләр, уңышлы гомумиләштерүләр булу белән бергә, каршылыклы, бәхәсләр уяткан мәсьәләләр дә урын алган. Шуларның берсе булып иҗат тибы һәм иҗат методы төшенчәсен ачу-аңлату тора. Хезмәткә беренчеләрдән булып бәя биргән А. Әхмәдуллин болай дип яза: «“Иҗат тибы”, “иҗат методы” бүлекләре сораулар уята. Алар арасындагы аерма һәм үзен-

чәлекләр ачык итеп аңлатылмый. (...) Романтизм иҗат тибы буларак һәм романтизм иҗат методы төсендә ачык итеп аерып куелмаган»[1]. Автор матур әдәбиятта тормыш-чынбарлыкны танып белүнең ике тибын – романтизм һәм реализмны – аерып чыгара һәм җентекләп, күптөрле мисаллар ярдәмендә аларның эчтәлеген, асылын ача. Шул ук вакытта модернизм төшенчәсе гомумән читтә кала. Аңа бертөрле дә мөнәсәбәт белдерелмәгәнгә күрә, сәбәпләре дә ачыкланмый. Шул ук вакытта рус һәм чит ил әдәбият белемендә генә түгел, югарыда әйтелгәнчә, татар әдәбияты тарихына караган байтак хезмәтләрдә, махсус тикшеренүләрдә модернизмның XX йөз башында җирләшүе, кызыклы эзләнүләр юлына чыгуы, ә инде 1960 еллардан башлап яңаруы һәм, ниһаять, XX йөз ахыры – XXI йөз башы сүз сәнгатендә әдәби эзләнүләрнең үзенчәлекле юнәлеше буларак мәйдан били баруы җитди рәвештә билгеләнә.

Иҗат методын иҗат тибы белән чагыштырганда таррак, җыйнаграк гомумилек буларак карап, Ф. Хатипов аны әдәбиятның барлык чорларына хас күренеш дип бәяли һәм мондый билгеләмә бирә: «Иҗат методы ул эстетик идеал яктылыгында чынбарлыкны сәнгатьчә сурәтләү ысулындагы уртаклык»[2]. Автор дөнья әдәбияты тарихында «Мифологик метод», «Яңарыш реализмы», «Классицизм», «Сентиментализм», «Мәгърифәтчелек реализмы», «Классик реализм» кебек иҗат методларын аерып чыгара. Безнең карашыбызча, хезмәттә әлеге төшенчәләрне аңлау-аңлатуда җитди каршылык булу бәхәскә урын калдыра. Иҗат тибы һәм иҗат методы турындагы мәсьәлә мондый нәтиҗә белән тәмамлана: «Әгәр иҗат типлары сәнгать тарихының бөтен буена дәвам итеп барса, аерым дәверләрдә, бериш язучыларда теге яки бу як өстенлек алса, методлар исә бер-берсен алыштыра киләләр»[3]. Әгәр шулай икән, терминнарда ук буталыш килеп чыга түгелме соң? Мисал өчен, автор «Яңарыш реализмы», «Мәгърифәтчелек реализмы», «Классик реализм» төшенчәләрен куллана. Моннан исә «Яңарыш реализмы» булгач, «Яңарыш романтизмы» да булырга тиеш» дигән фикер туа. «Мәгърифәтчелек романтизмы» һәм «Классик романтизм» төшенчәләре белән дә шул ук хәл. Фикеребезне бер мисалда киңрәк ачыклап үтик. Мәгърифәтчелек реализмы хәзерге әдәбият белемендә, нигездә, калыплашкан иҗат методы (агымы) булып санала. XX гасыр дәвамында Җ. Вәлиди, Г. Ибраһимов, Г. Сәгъди, Г. Гали, Г. Гобәйдуллин, М. Гайнуллин, А. Сайганов, Г. Халит, И. Нуруллин, Ф. Мусин, М. Гайнетдинов, Ш. Садретдинов, Ә. Шәрипов, М. Госманов һ.б.ның хезмәтләрендә аның әдәби-эстетик асылы, методологик принциплары, төп әйдәүче көчләре һ.б. тагы да ачыклана, тулылана. Соңгы елларда

[1] *Әхмәдуллин А.Г.* Әле нокта куймыйбыз // Казан утлары. 2001. № 7. Б. 144.
[2] *Хатипов Ф.М.* Әдәбият теориясе. Казан: Мәгариф, 2000. Б. 250.
[3] Шунда ук. Б. 290.

әдәбият тарихының төрле чорларына, аерым авторлар иҗатына бәйле дөнья күргән хезмәтләрдә яисә мәктәпләр, югары уку йортлары өчен язылган программа-дәреслекләрдә мәгърифәтчелек реализмы төшенчәсе, бер яктан, әдипләрнең сәнгати фикерләү үзенчәлегенә бәйле эстетик планда, икенче яктан, татар иҗтимагый фикере белән бәйлелектә милли-фәлсәфи планда, өченчедән, Шәрык-Гареб әдәбиятларындагы сәнгати үзенчәлекләрне үз эченә алган күренеш рәвешендә тикшерелә. Аерым алганда, Х. Миңнегулов, Р. Ганиева, Н. Хисамов, М. Әмирханов, А. Юзиев, М. Гайнетдинов, Ә. Шәрипов, Ф. Бәширов, З. Шәйхелисламов, Г.Даутов, И. Гомәров һ.б.ның хезмәтләрендә әлеге иҗат методының түбәндәге сыйфат-үзенчәлекләре аерып чыгарыла: 1) татар иҗтимагый һәм әдәби фикеренең эчке сыйфат үзгәрешләре нәтиҗәсендә мәйданга килүе; 2) бер яктан, Шәрык, икенче яктан, рус-Көнбатыш әдәби-фәлсәфи фикеренә таянуы; 3) аның мәйданга чыгуының татар сүз сәнгатендә икенче Яңарыш чорына нигез салынуны аңлатуы; 4) урта гасырлар татар ренессанс әдәбиятының гуманистик карашларын яңа шартларда һәм үзенчәлекле алым-чараларда үстерүе, баетуы; 5) XX гасыр башы сүз сәнгатендәге тәнкыйди реализм (Г. Исхакый, Г. Камал, Ш. Камал һ.б.) һәм Европа тибындагы романтизм (Г. Ибраһимов, С. Рәмиев, М. Фәйзи һ.б.) тарафдарлары әсәрләрендә аерым сыйфат-билгеләренең үзгәрешләр кичергән хәлдә урын алуы һ.б. Гомумән, бу урында мәгърифәтчелек әдәбиятының гаять киң төшенчә булып, аның күптөрле агым-юнәлешләргә йогынты ясавын билгеләп үтү кирәк. Әлеге үзенчәлеккә игътибар итеп, Р. Ганиева, Н. Гуляев фикерләренә таянган хәлдә, мәгърифәтчелек идеяләренең Европа һәм рус әдәбиятларында классицизм, сентиментализм, романтизм, реализм кебек әдәби юнәлешләрдә һәм иҗат ысулларында чагылыш табуын күрсәтә[1].

Ф. Хатипов хезмәтендә мәгърифәтчелек реализмының XIX гасыр урталарында формалашып, XX йөз башы әдәбиятында да шактый киң урын алуын билгели һәм фикерләрен күпсанлы мисаллар ярдәмендә дәлилли. Без әлеге фикерләрне тагы да үстереп, романтизмның бер агымы буларак «мәгърифәтчелек романтизмы»н аерып чыгару ягында. Дөрес, бу фикер яңа түгел. Аның аерым сыйфатлары Г. Халит, Р. Ганиева, Й. Нигъмәтуллина, И. Нуруллин һ.б.ның хезмәтләрендә күрсәтеп үтелә. XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәбиятында мәгърифәтчелек романтизмы үрнәкләре дөнья күрә (Ф. Кәриминең «Морза кызы Фатыйма», Ш. Мөхәммәдевнең «Хан кызы» һ.б.). Аларны XIX йөз ахырында, бер яктан, мәгърифәтчел идеалларга зур өметләр баглау, икенче яктан, җитди сәнгати табышларга китергән урта гасырлар романтизмы

[1] *Ганиева Р.К., Рәмиева И.Р.* М.М.Херасковның «Россияда» поэмасында Сөембикә ханбикә образы // Татарская литература: традиции и взаимосвязи. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. Б. 232.

йогынтысы, өченче яктан, төрек әдәбиятының шифалы тәэсире нигезендә формалашкан иҗат агымы (иҗат методы) үрнәге буларак аерып чыгарырга түбәндәгеләр мөмкинлек бирә: 1) мәхәббәт тарихы мәгърифәтчелек мәсьәләләре белән үрелеп бара; 2) төп геройлар гадәти булмаган шартларга куела; 3) вакыйгаларга фон буларак этнографик һәм табигать күренешләренә киң урын бирелә; 4) авторлар үткән тарихның үкенечле якларын хәтердә яңарта; 5) уңай идеалны раслау начарлыкны тәнкыйтьләү һәм купшы сурәт чарлары, публицистик чигенешләр белән үрелеп бара; 6) геройларның лирик-психологик кичерешләрен сурәтләү зур урын ала; 7) әйләнә-тирәдәгеләр белән каршылыкка кергән геройлар читкә китә һ.б.

XX йөз башы татар әдәбиятындагы җитди казанышлар мәгърифәтчелек реализмына алмашка килгән тәнкыйди реализм белән бәйле. Әлеге иҗат методының асылы, әдәби-эстетик һәм фәлсәфи принциплары, татар әдәбиятындагы үзенчәлекләре, нигездә, XX йөз башы сүз сәнгатен өйрәнүче галимнәр (Г. Халит, И. Нуруллин, Н. Юзиев, А. Сайганов, Й. Нигъмәтуллина, Э. Нигъмәтуллин, Н. Хисамов, Р. Ганиева, Ә. Мәхмүдов, О. Кадыйров һ.б.) тарафыннан тикшереп бәяләнә. Соңгы елларда дөнья күргән хезмәтләрдә тәнкыйди реализмны язучының иҗат концепциясе белән бәйләп өйрәнү, милли сүз сәнгатенә хас эстетик асылын ачу, XX гасыр әдәбиятына тәэсирен тикшерү урын ала. Аерым алганда, «История татарской литературы нового времени (XIX – начало XX века)» кебек академик китапта, Й. Нигъмәтуллина, А. Саяпова Д. Заһидуллина, Ч. Четин-Зарипова монографияләрендә тәнкыйди реализмны башка иҗат юнәлешләре (романтизм, модернизм) һәм агымнары (символизм, экзистенциализм, экспрессионизм) белән бәйләнештә тикшерү аларның үзара йогынтысын тулырак аңларга һәм аерым сыйфат-билгеләрен тулыландырырга мөмкинлек бирә. Р. Ганиева, Ф. Бәширов, Ә. Мәхмүдов, Ф. Галимуллин, Т. Гыйлаҗев, З. Шәйхелисламов һ.б.ның хезмәтләрендә әлеге иҗат методына хас принципларның аерым автор яисә әсәр эчтәлегендә чагылыш үзенчәлеге үзәктә тора. Й. Нигъмәтуллина үзенең тикшеренүләрендә, татар һәм рус әдәбиятларын төрле мәдәни типлар буларак чагыштырып өйрәнү аша, татар сүз сәнгатендәге тәнкыйди реализм һәм романтизм формалашуга нигез булып мәгърифәтчелек реализмы торды, дип билгели. Галимә фикеренчә, XX йөз башы әдәбиятының мөһим сыйфаты булган «идеяләр романтизмы», ягъни милли-азатлык хәрәкәте идеаллары һәм шуның пафосы белән сугарылу романтизмда гына түгел, бәлки башка әдәби юнәлешләрдә дә (шул исәптән тәнкыйди реализмда да) чагылыш таба[1].

[1] *Нигматуллина Ю.Г.* Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. Казань: Фэн, 1997. С. 137.

Шуның белән бергә, әлеге иҗат методы һәм аның әдәби күренешләр белән бәйләнеше, дөресрәге аларны аңлата, бәяли алуы буенча бәхәсләр дәвам итә. Ф. Хатипов «Әдәбият теориясе» дәреслегендә озак еллар дәвамында рус һәм башка халыклар әдәбиятында нигез төшенчәләрнең берсе саналган «тәнкыйди реализм» иҗат методының булу-булмавын, атаманың дөресме-юкмы икәнен тикшерү объекты итеп ала. «Бу термин билгеле бер дәвердәге әдәбиятның асылын, бар байлыгын, катлаулылыгын анализлап нәтиҗә чыгару, дәлилләү җирлегендә тумады. Ул сүз сәнгатенә үтеп барышлый гына беркетеп куелды»[1], – дип, аны кире кага. Галим фикеренчә, «классик реализм» атамасы уңышлы, чөнки «классик реализмның яңа сыйфатлары турында сөйләр өчен фактлар бик күп, ә методның асылын тәнкыйтькә кайтарып калдыру өчен нигез ныклы түгел»[2]. Алга таба тәнкыйтьче татар, рус һәм чит ил әсәрләре мисалында үз карашларын дәлилләү омтылышы ясый. Галим үзе белән килешмәүчеләрне күздә тотып, оппонентлары алдына шундый сораулар куя: «XIX йөзгә кадәрге иҗат методларында җитешсезлекләр, тискәре геройлар сурәтләнгәнме? Әллә алар фәкать «тәнкыйть реализмы»нда гына күренә башлаганнармы? (...) «Тәнкыйть реализмы» дип йөртелгән ысул тик тәнкыйтьтән генә торамы?» Автор әлеге сорауларга үзе җавап биреп, тәнкыйди реализм терминының чорга бәйле генә урнашуын ассызыклый. Билгеле, галимнең караш-фикерләре шактый нигезле. Шулай да сорауларны бу рәвешле әдәби мохиттән аерып кую урынлы түгел. Әлеге бәхәсле фикерне күреп, А. Әхмәдуллин болай дип яза: «Элекке терминны уңышсыз санап кире какканда китап авторы шулай да шактый берьяклы фикер йөртә»[3]. Ф. Хатипов уку-укыту, тәрбия мәсьәләләрен калкытып куйган мәгърифәтчелек реализмының булу-булмавын, терминның дөреслеген шик астына алмый. Ә бит акыл, белем, әхлак мәсьәләләре урта гасыр әдәбиятында да, XX йөз башы яисә 1960–1980 еллар сүз сәнгатендә дә игътибар үзәгендә тора. Ни өчен соң андый әсәрләрне әлеге төшенчә белән атамыйбыз? Аңлашылганча, иҗат методы (агымы) әдипләрнең чынбарлыкны чагылдырудагы уртак принципларга нигезләнүе белән тыгыз бәйле. Урта гасырларда яисә хәзерге чорда мәгърифәтчел карашлар урын алса да, алар әдипләрнең сәнгати фикерләвендә үзәк урынны алмый, бәлки төп концепцияләрен ачуда бер җирлек, геройлар характерын билгеләүче бер төшенчә булып кына хезмәт итә. Ә инде XIX йөз урталары – XX йөз башы әдәбиятында акыл-белем-әхлак төшенчәләре язучыларның төп фикерен – шулар ярдәмендә кешене һәм, гомумән, җәмгыятьне үзгәртеп була дигән карашны яклауга нигезләнгән төп концепцияне раслауга хезмәт

[1] *Хатипов Ф.М.* Әдәбият теориясе. Казан: Мәгариф, 2000. Б. 278.
[2] Шунда ук.
[3] *Әхмәдуллин А.Г.* Әле нокта куймыйбыз // Казан утлары. 2001. № 7. Б. 146.

итә. Ф. Хатиповның тәнкыйди реализмны тулысынча кире кагу фикере бәхәсле. Беренчедән, әдәби юнәлеш, агым, иҗат тибы, иҗат методы кебек төшенчәләрнең асылы эстетик планда шактый тулы ачылган. Бу уңайдан рус әдәбият белемендә соңгы елларда дөнья күргән хезмәтләрдә дә «тәнкыйть реализмы» төшенчәсенең, ягъни ул аңлаткан әдәби күренешнең инкарь ителмәвен искәртеп китәргә була. Ф. Хатипов хезмәтендә тәнкыйди реализм эстетикасын тулысынча кире кагарлык дәлилләр җитми. Икенчедән, әдәбият, гаять катлаулы күренеш буларак, төрле чорларда чынбарлыкка мөнәсәбәттә, аны әдәби-эстетик чаралар аша чагылдыруда төрле сыйфат-үзенчәлекләрен алгы планга куя. «Тәнкыйди реализм» төшенчәсе билгеле бер чорга хас әдәби-эстетик билгеләрне аерып чыгара, аңлата. Аның нигезендә дөньяны объектив рәвештә яши торган феномен буларак аналитик күзаллау ята. И. Нуруллин язганча, реализмны тәшкил итә торган иҗат методларының барысында да кешене иҗтимагый тирәлек белән сәбәпле бәйләнештә сурәтләү принцибы үткәрелә һәм ул һәркайсында үзенчәлекле рәвештә тормышка ашырыла[1]. Төп принциплары булып типик характерларны типик хәлләргә бәйле чагылдыру, аларның тарихи, социаль һәм психологик детерминизмы, ягъни тарихи, социаль, психологик шартларга нигезләнүе тора. С. Казначеев язганча, «әлеге төр билгеләмә язучыларның аналитик бәясен, тормышны бөтен тулылыгында иңләп алу омтылышын, демократик идеологиягә хезмәт итүче сатирик үткенлекне, фаш итү пафосын чагылдыра»[2]. Иҗат тибы яисә иҗат юнәлеше буларак реализм бертөрле, үзгәрешсез күренеш түгел. Аның үсешендә мәгърифәтчелек мәсьәләләрен калкытып куйган чоры булган кебек, җәмгыятькә, гомумән яшәешнең төрле якларына тәнкыйди караш өстенлек иткән, заман таләбе буларак әлеге сыйфатны үзәккә алган күпсанлы әсәрләр язылу мөмкинлеген кем генә инкарь итәр икән. XIX йөз һәм XX йөз башы реализмы белән 1920–1930 еллар реализмы арасына да тигезлек билгесе куеп булмый бит. Шуны ук сугыштан соңгы еллар яисә хәзерге сүз сәнгатенә карата да әйтергә була. Дөрес, аларның барысын да классик реализм төшенчәсенә бәйләп аңлатырга мөмкин. Әмма теге яки бу чор әдәбиятының төп тенденцияләрен билгели башласак, реализмның билгеле бер үзгәреш кичерүен, яңа сыйфат-билгеләр белән баюын күрәбез. Шуларга бәйле реализмның ниндидер сыйфатын калкытып кую таләбе килеп туа. XX йөз башы татар әдәбиятында ул сатирик көлү, фаш итү, гомумән, *тәнкыйтьләү* рухы белән характерлана.

Ә менә социалистик реализм белән эш катлаулырак. Ул, иҗат методы буларак, СССР язучыларының I съездында (1934) кабул ителә

---

[1] *Нуруллин И.* Булган ул тәнкыйди реализм! // Казан утлары. 1995. № 2. Б. 177.

[2] *Казначеев С.М.* Проблема нового реализма: регенерация метода // Вопросы филологии. 2009. № 1. С. 28.

һәм XX гасырның 80 нче еллары ахырына кадәр әдәби барышта өстенлекле урын алып тора. Соцреализм XX гасыр дәвамында күптөрле бәхәсләргә, каршылыклы фикерләргә җирлек тудыра. XX гасыр ахыры татар әдәбият белемендә дә әлеге иҗат методына мөнәсәбәт бертөрле генә түгел. Й. Нигъмәтуллина язганча, соцреализмны тулысынча социалистик идеология догмаларына буйсындырылган, үзгәрми торган, катып калган һәм шуңа күрә гуманистик һәм әдәби-эстетик кыйммәте булмаган күренеш дип кабул итү белән килешеп булмаган кебек[1], аерым авторларның, мисал өчен, Р. Фәизовның Ф. Латыйфи әсәрләрендәге геройларны соцреализм геройлары дип бәяләве дә[2] гаҗәпләнү генә уята. Гомумән, социалистик реализмның җирлеге, әдәби-эстетик асылы, ярты гасыр вакыт эчендә әдәби барыштагы урыны һәм тарих аренасыннан китү сәбәпләре нәрсә белән аңлатыла соң? Шушы тарихка кыска гына күзәтү ясыйк.

Әдәбиятта социалистик реализм үрентеләре күренә башлауның нигезе XX гасыр башында пролетариатның үз хокуклары өчен көрәш юлына чыгуы белән бәйле. Әлеге иҗат методының әдәби-эстетик эчтәлеген аңлатучылар аның башлангычын М. Горькийның «Мещаннар» (1901), «Дошманнар» (1906) пьесаларына һәм аеруча «Ана» (1906) романына бәйләп карыйлар. Әлеге әсәрләрдә беренчеләрдән булып эшчеләрнең хокукларын яклап көрәшкә чыгуы һәм хакимиятне үз кулларына алып, социаль тигезлеккә нигезләнгән, сыйнфый каршылыклар булмаган җәмгыять төзү идеясе алга куела. Гасыр башында әлеге мәсьәләләрне әдәби сурәтләрдә чагылдырган әдәби агым киң яклау тапмый. Рус әдәбиятында бары М. Горький, А. Серафимович, Д. Бедный кебек авторлар иҗаты белән чикләнсә, татар әдәбиятында пролетариат әдәбияты башлангычы Г. Коләхмәтов исеме белән генә бәйле. Аның «Яшь гомер» пьесасында эшчеләр сыйныфы мәнфәгатьләрен яклау өчен көрәшкә килү фикере үткәрелә.

1917 елгы Октябрь инкыйлабыннан соң, пролетариат диктатурасы урнашу нәтиҗәсендә сыйныфсыз җәмгыять төзү, революцион көрәш идеяләре киң халык массаларын яулап ала һәм әдәбиятта төрле әдәби агым-юнәлешләр белән көрәштә алдынгылыкка омтыла. 1920 елларның икенче яртысыннан башлап, башка юнәлеш-агымнар хакимият тарафыннан кысрыклап чыгарылу нәтиҗәсендә, яңа идеология таләпләренә яраклашкан әдәби агым формалашу стадициясенә керә. ВКП(б) ҮК ның 1932 елда кабул ителгән «Әдәбият-сәнгать оешмаларын үзгәртеп кору турында»гы карары әлеге үзгәрешләрнең җитди һәм кире каккысыз булуын билгели.

---

[1] *Нигматуллина Ю.Г.* Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. Казань: Фэн, 1997. С. 146.

[2] *Фәизов Р.* Алар безнең арада // Казан утлары. 2004. № 2. Б. 152.

Социалистик реализмның билгеле бер дәрәҗәдә җәмгыять таләбе булуын да инкарь итеп булмый. XX гасыр башында Россиянең иҗтимагый-социаль хәле, сугышлар, инкыйлаблар, террор һ.б. катастрофалардан һәм билгесезлектән туйган җәмгыятьтә тәртипкә, авыл җирендә күптәннән яшәп килгән община төсендәге тигезлеккә, киләчәктә матур, бәхетле яшәешкә омтылу көчле була. Гасыр башында әдәбиятта (аеруча рус әдәбиятында) урын алган модернистик алымчаралар (шактый катлаулы тел, еш кына символ-метафораларга нигезләнгән сурәт чаралары, интеллектуаль көч сорый торган фәлсәфи эчтәлек һ.б.) кире кагылып, үзгәртеп коруларга тартылган аз белемле халык массалары гади, аңлаешлы тел белән язылган һәм аңа якын вакыйга-күренешләр сурәтләнгән әдәби әсәрләр таләп итә. Власть, билгеле, әлеге үзенчәлекләрдән оста файдалана. Шул рәвешле, социалистик реализм әдәби-тарихи үсешнең табигый нәтиҗәсе булып тора.

Татар сүз сәнгатендә соцреализм формалашуда югарыда күрсәтелгән тарихи, иҗтимагый, мәдәни сәбәпләр белән бергә милли шартларның да роле зур була. Яңа хөкүмәт 1920 елда, автономия кысаларында гына булса да, татар халкының дәүләтчелеген булдыра, милләтләрнең үзбилгеләнү хокукын таный, татар теле Татарстанда дәүләт телләренең берсе дип игълан ителә, меңләгән татар яшьләренә югары уку йортларының ишеге ачыла. Шундый шартларда партия һәм хөкүмәтнең әдәбият-сәнгать өлкәсендәге сәясәте аеруча милли республикаларда зур яклау таба. Дөрес, 1920 елларның беренче яртысында, бер яктан, модернистик агымнарга мөрәҗәгать итү (символизм, имажинизм, футуризм), икенче яктан, сүз сәнгатенең һәртөр басым-күрсәтмәләрдән азат булуын, эчке закончалыклары буенча гына үсүен яклаган фикерләр яңгыраса да, хакимият һәм киң җәмәгатьчелек басымы астында алар сүнеп, югалып кала.

Социалистик реализм иҗат методының билгеләмәсе СССР Язучылар берлегенең уставында ук язылган була: «Социалистик реализм, совет матур әдәбиятының һәм әдәби тәнкыйтьнең төп методы буларак, иҗатчыдан чынбарлыкны дөрес, тарихи конкрет һәм революцион үсешендә сурәтләүне таләп итә. Шул ук вакытта дөрес һәм тарихи конкрет әдәби сурәтләү хезмәт иясләрен социализм рухында идея ягыннан үзгәртү һәм тәрбияләү бурычлары белән туры килергә тиеш. Социалистик реализм әдәби иҗатка иҗади инициативаны ачу, төрле формалар, стильләр, жанрлар сайлау мөмкинлеге бирә»[1].

Иҗат методының асылын аңлау өчен, аның эчтәлегендәге ике аспектны билгеләү сорала, дип саный Й. Нигъмәтуллина. Берсе – методның теориясе, икенчесе – язучыларның әдәби эшчәнлеге. Галимә фикеренчә, нәкъ менә социалистик реализм теориясе аның иң догматик

[1] Русская советская литературная критика (1917–1934). Хрестоматия. М.: Советский писатель, 1981. С. 165.

өлеше була[1]. Социалистик реализмның әдәби барышка йогынтысы һәм әдипләр иҗатында чагылышы бер төрле генә булмый билгеле. Бер яктан, әдәбият идеологик кысаларга кертелә. Т. Галиуллин язганча, «ул елларда совет режимын мактаган, яклаган, сыйнфый көрәшкә, кан коюга чакырган, милләтчелекне фаш иткән, әдәби яктан түбән әсәрләр күп языла, күп басыла. Берәүләр исән-имин калу, икенчеләре тамак туйдыру хакына әхлаксыз, имансыз хакимиятне, «халыклар» атасы Сталинны мактау юлына басарга мәҗбүр булалар. Динсезлек дәүләт сәясәте дәрәҗәсенә күтәрелә»[2]. Вакыйга-күренешләрне тарихи нигездә һәм революцион үсештә бирү омтылышы, аларны бизәп, ал буяуларга манып сурәтләүгә һәм шуның белән заман чынбарлыгыннан читләшүгә китерә. Әсәрләрдә, еш кына, схематик конфликт (сыйнфый көрәшкә бәйле социалистик идеал белән иске гадәт арасында һ.б.) күзәтелә, шуңа бәйле рәвештә кеше характерлары, берьяклы һәм бертөрле генә сурәтләнеп, уңай һәм тискәрегә бүленә, үзара каршы куела. Иҗат методының нигез принципларыннан берсе буларак, кеше шәхесе иҗтимагый идеалга буйсындырыла һәм әлеге идеал алгы планга чыгарылып, чынбарлык буларак тәкъдим ителә. Икенче яктан, катлаулы һәм бай әдәби процесс соцреализм чикләренә генә сыймыйча, тормыш-яшәешне бөтен тулылыгында, каршылыгында сурәтләргә омтыла. Әлеге авыр шартларда да татар әдәбиятының үз йөзен саклап калу сәбәпләрен Т. Галиуллин түбәндәгеләрдә күрә: берсе – әдәбиятыбызның ерак гасырлардан килә торган бай традицияләре булу, бигрәк тә XX гасыр башындагы казанышлары бай җирлек бирә; икенчесе – гасыр башында татар әдәбиятының йөзен билгеләгән каләм ияләренең бай мирасы әдәби әйләнештә булу һәм байтагының 20–30 нчы елларда актив иҗатта калуы; өченчесе – татарлар күмәкләшеп яшәгән төрле төбәкләрдән әдәби иҗатка яшь көчләр килү[3].

Й. Нигъмәтуллина язучылар эшчәнлегендәге күптөрлелекнең сәбәбен түбәндәгеләр белән аңлата: беренчедән, күпмилләтле СССР халыкларының гадәт-традицияләре, мәдәниятләре, тарихи хәтерләре һ.б. белән соцреализмның мөнәсәбәте төрле була. Шуңа ул елларда да төрле халыклар әдәбиятында гомумкешелек һәм гомуммилли идеаллар чагылыш тапкан сәнгати югары әсәрләр языла; икенчедән, һәр милли әдәбиятта соцреализм таләпләренә туры килмәгән әсәрләр язылып (М. Булгаков, Б. Пастернак, Ә. Еники, Х. Туфан һ.б.), аның тар эстетик кысаларын җимерүгә ярдәм итә; өченчедән, совет әдәбияты үсеше-

[1] *Нигматуллина Ю.Г.* Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. Казань: Фэн, 1997. С. 147.

[2] *Галиуллин Т.Н.* Утызынчы еллар әдәбияты // Әдәбият (XX йөзнең 30–90 нчы елларында татар әдәбияты): унберьеллык урта мәктәпнең 11 нче сыйныфы өчен дәреслек. Беренче кисәге. Казан: Мәгариф, 1995. Б. 3–4.

[3] Шунда ук. Б. 3–4.

нең төрле тарихи этапларында соцреализм принципларының басымы бертөрле булмый. Аерым чорларда гомумкешелек кыйммәтләре сыйнфый көрәшнең көчәя баруы кебек таләп-карашларны каплап китә[1].

Й. Нигъмәтуллина татар әдәбиятында соцреализмның идеологик һәм эстетик таләпләре үзгәрү күренеше ике тапкыр була дип саный. Берсе 1920 еллар ахырында күзәтелә. Бу чорда рәсми идеология басымы астында татар әдипләре «идеяләр романтизмы»ннан баш тартырга, ягъни милли азатлык хыялыннан читләшергә мәҗбүр булалар. Әлеге идея урынын халыкларның тигезлеге, дуслыгы, интернационализмы турындагы карашлар ала. Икенчесе XX гасырның 80 нче еллар ахыры – 90 нчы еллар башы сүз сәнгате белән бәйле. Россиякүләм социалистик реализм әдәбияты тирән кризиска кергән вакытта татар әдипләре яңадан XX гасыр башындагы идеалларга мөрәҗәгать итәләр. Әмма ул инде совет чоры әдәбияты тәҗрибәсенә таянып, яңа эчтәлек ала[2]. Галимәнең татар әдәбиятында соцреализм эстетикасы 1930–1980 еллар аралыгында җитди үзгәреш кичерми дигән карашы бәхәсле булып тоела. 1950 елларның икенче яртысында җәмгыятьтә урын алган «җепшеклек» йогынтысында 60 нчы елларда татар әдәбиятында сыйфат үзгәрешләре күзәтелә. Ул – тема-проблемаларда, шәхес концепциясендә, гомумкешелек кыйммәтләренә һәм милләт язмышы мәсьәләләренә йөз тотуда һ.б.да күренә. Бу чорда заман сынавын үткән әсәрләр (Х. Вахит «Беренче мәхәббәт», А. Гыйләҗев «Өч аршын җир», Ә. Еники «Әйтелмәгән васыять», Н. Фәттах «Идел суы ака торур», Г.Афзал, Р. Фәйзуллин шигырьләре һ.б.) язылу социалистик реализм эстетикасының җитди үзгәрешләре турында сөйли. Әгәр сәясәттә демократия чаткылары 60 нчы еллар ахырына таба идеологик кысаларга кертелсә (тарихчылар аны «Прага язы» (1968) белән чиклиләр), әдәби иҗатта бу процессны инде тулысынча туктата алмыйлар. 1970–1980 елларда иҗтимагый-сәяси тормышта торгынлык хөкем сөрсә дә, миллилек, халыкчанлык концепциясенә нигезләнгән, сәнгати табышларга йөз тоткан күпсанлы әсәрләр (Т. Миңнуллин, Ш. Хөсәенов пьесалары, Ә. Еники, Ф. Хөсни хикәяләре, Ә. Баянов, М. Мәһдиев, Х. Сарьян, А. Гыйләҗев, Ф. Шәфигуллин повестьлары, И. Юзеев, Р. Фәйзуллин, Р.Харис, М. Әгъләмов, Роб. Әхмәтҗанов шигырьләре һ.б.) дөнья күрә.

XX гасырның 80 нче еллары уртасында җәмгыятьтә башланып киткән демократик үзгәрешләр нәтиҗәсендә коммунистик идеологиядән акрынлап арыну, милли үзаң үсү һ.б. социалистик реализмның эчтәлеге, урыны һәм роле турында җитди бәхәсләргә юл ача. Чор, заман рухына ияреп, берәүләр соцреализмны һәм шуның белән бергә совет

[1] *Нигматуллина Ю.Г.* Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. Казань: Фэн, 1997. С. 148.

[2] Шунда ук. Б. 149–150.

чоры татар әдәбиятын каралту, әдәби-эстетик әһәмияте булмаган күренеш итеп карау, кире кагу юлыннан китсә, икенчеләр әлеге иҗат методын, нигездә, тануларын, яклауларын, бары аерым канун-карашлардан арындыру кирәген яклап чыгалар. Газета-журнал битләрендә урын алган фикер-карашлар төрлелеге, бәхәсләр «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясен «Нәрсә ул партияле әдәбият һәм иҗат иреге?» дигән темага җитди сөйләшүне башлап җибәрергә этәрә. Дөрес, анда сүз В.И. Ленинның «Партия оешмасы һәм партияле әдәбият» (1905) дигән хезмәтенә бәйле партия һәм сүз сәнгате арасындагы мөнәсәбәт, иҗат иреге кебек мәсьәләләрне ачыклау юнәлешендә бара. Әмма марксистик-ленинчыл эстетиканың нигез ташы саналган әлеге хезмәт соцреализм методына турыдан-туры хезмәт итә.

Мәсьәләнең катлаулы, каршылыклы булуын, яшәп килгән дистә еллар дәвамында канун буларак кабул ителгән карашлардан арынуның кыенлыгын күз алдына китерү өчен берничә мәкаләгә тукталып үтик. Әлеге сөйләшүне башлап җибәргән әдәбият галиме, тәнкыйтьче И. Нуруллин «Акыл һәм күңел кушканча» исемле язмасында[1] хезмәт ияләре бәхете өчен көрәш идеясенә «хезмәт итә торган матбугат һәм әдәбият партиянең олы максатына, тик шуңа гына хезмәт итәргә, ягъни партияле булырга, партиялелек принцибын үткәрергә тиеш иде», – дип чыга. Тәнкыйтьче Сталин тоталитаризмы чорында Ленин яклаган партияле әдәбият принциплары бозылуын билгели. Иҗат иреге мәсьәләсен язучының шәхесе белән бәйләп карый һәм аны ил-көн алдында, халык каршында җаваплылык хис иткән хәлдә, үзең белгәнчә, акыл һәм «күңелең кушканча иҗат итү» рәвешендә төгәлләштерә. Нәтиҗәдә И. Нуруллин: «Ленинның «җәмгыятьтә яшәп тә, җәмгыятьтән азат булу мөмкин түгел» дигән сүзләренә чын күңелемнән кушылуымны белдерәсем килә», – дип яза. Ә менә М. Мәһдиев «Кыршауланган әдәбият» дигән мәкаләсендә[2] сүз сәнгатенең ниндидер партия мәнфәгатьләренә хезмәт итүен, димәк, соцреализмның нигез принципларының берсен кискен кире кага. «Партия мәнфәгатьләренә бәйле әдәбият вакытлар үтү белән юкка чыга, алай гына да түгел, кайвакытта җәмгыять өчен зарарлы күренешкә дә әйләнә башлый», – дип яза ул әлеге фикерен мисалларда дәлилләп. Иҗат иреге булмауның үлемгә тиң күренеш икәнен искәртеп, С. Есенин, В. Маяковский, Һ. Такташ язмышларын, аларның вакытсыз үлеме сәбәбен искә төшерә. «Ничек инде Ленин, Гогольне, Толстойны, Чеховны яратып укыган Ленин, хикәя, повесть, комедия, баллада «партияле булсын» дип әйтсен? – дигән сорауны куя М. Мәһдиев һәм аның публицистиканы күздә тотуын басым ясап әйтә.

[1] *Нуруллин И.* Акыл һәм күңел кушканча // Соц. Татарстан. 1990. 25 март.
[2] *Мәһдиев М.С.* Кыршауланган әдәбият // Соц. Татарстан. 1990, 1 апрель.

Ә. Еники «Язу ул – вөждан эше» мәкаләсендә[1] сүзне Ленин хезмәтенең ни сәбәпле һәм нәрсәне күздә тотып язылуын ачыклаудан башлый. Язучы фикеренчә, ул матур әдәбиятка мөнәсәбәтле язылмаган, чөнки Ленин язучының иҗат эшен һәм классик әдәбиятны яхшы аңлаган, «аларның бер-берсеннән никадәр аерылганын, һәркайсының үз йөзе генә түгел, үз кыйбласы, үз иманы булганын» яхшы белгән. Ә инде партиянең «әдәбият партияле булырга тиеш!» дигән таләбе турында: «Безгә тимер авызлыклы йөгән кидерү белән бер булды дисәм дә арттырып җибәрү булмас», – дип билгели. Шул ук вакытта Ә. Еники әдәбиятның партия диктатына тулысынча буйсынмавын, үз эчке закончалыкларына буйсынып яшәвен таный. Шуңа да «табигый иҗат процессына сыймый торган ят нәрсәнең» үзе өчен «бер вакытта да зарури кагыйдәгә әйләнмәвен» басым ясап әйтә. Иҗат иреге һәм партия таләбе турында уйланып, язучы соңгысының зарарлы күренеш икәнен, бервакытта да әдәбият файдасына була алмавын билгели – «иҗат иреге – ул фикер хөрлеге». Ә. Еники үзенең иҗат юнәлешен үзе ышанганны һәм кирәк дип тапканны язуда күрә, «әмма язу бит ул коры акыл эше генә түгел, ул әле беренче нәүбәттә вөждан эше дә. Акылым кирәк дип тапканны вөжданым кабул итәме – менә хикмәт нәрсәдә», дип нәтиҗә ясый.

Әлеге зур булмаган күзәтүләр социалистик реализм турындагы баштагы фикерләребезгә әйләнеп кайтуга этәрә. Иҗат методы буларак ул бертөрле, катып калган монолит булмаган. Үсеш-үзгәрешендә төрле чорлар булган кебек, соцреализм эстетикасында төрле стиль агымнары, милли психология, менталитет сыйфатлары, әхлакый кыйммәтләр һ.б. урын ала. Шулай да үз асылында әдәбият-сәнгатьне бер партия яклаган идеологик карашларга буйсындыруны күздә токан социалистик реализм иҗат методының аерым принциплары совет системасы җимерелү, компартиянең җитәкчелектән китүе белән катгый рәвештә кире кагыла. Шуның белән бергә, бүгенге көндә җәмгыятьтә социалистик идеяләр яши икән, аның әдәби-эстетик чагылышы буларак әсәрләр язылуын, хәтта тулы агым тәшкил иткән күренешнең мәйданга чыгуын, димәк, социалистик реализмның яңару мөмкинлеген тулысынча инкарь итеп булмый.

Шулай итеп, XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы татар әдәбият теориясе игътибар үзәгендә торган мәсьәләләрнең берсе булып «иҗат методы» төшенчәсе тора. Әлеге кызыксыну, бер яктан, җәмгыятьтәге социаль-мәдәни үзгәрешләргә, икенчедән марксизм-ленинизм тәгълиматына нигезләнгән методологиянең аерым фикерләренә тәнкыйди караш формалашуга, өченче яктан, көчеш чорында реализмның билгеле бер кризиска керүе һәм акрынлап аннан чыгу юлларын эзли башлавына

[1] *Еники Ә.* Язу ул – вөждан эше // Соц. Татарстан. 1990, 8 апрель.

нигезләнә. Иҗтимагый-мәдәни шартлар һәм сүз сәнгатенең эчке закончалыклары нигезендә иҗат методлары билгеле бер үзгәреш кичерә, яңа сыйфат-билгеләр белән байый. Фәндә даими кызыксыну тудырган мәгърифәтчелек реализмы, тәнкыйди реализм методларының поэтик планда әдәби-эстетик үзенчәлекләрен, яңа сыйфатларын ачу күзәтелсә, социалистик реализм иҗат методы сүз сәнгате үсешенең аерым дәверендә киң чагылыш тапкан әдәби күренеш буларак бәяләнеп, бер яктан, догматик нигезен, икенче яктан, гуманистик һәм әдәби-эстетик кыйммәтен объектив бәяләү урын ала.

## 2.4. Хәзерге әдәби процесс үзенчәлекләре

### *2.4.1. Әдәби агымнар яңарышы турында*

Җәмгыятьтәге үзгәрешләр традицион реализмның тармакланып үсеп китүенә, эзләнүләрнең тирәнәюенә, баюына китерә. Татар сүз сәнгате модернизм юнәлешенең төрле агымнарына да, романтизмның купшы сурәтлелегенә дә игътибар итә башлый. Әдәбияттагы үзгәрешләр, беренче чиратта, тематик төрлелектә һәм жанр байлыгына омтылуда күренә. 1990 еллар уртасына таба тормыш-яшәеш турында әхлакый һәм фәлсәфи уйланулар үзенчәлекле тел-сурәт чараларына, образ-формаларга, шартлы-метафорик сурәт-алымнарга иркен мөрәҗәгать итүгә китерә. Реализм, романтизм, модернизм юнәлешләренең үсеш-үзгәреше, әдәбияттагы урыны, алып килгән яңалыгы турында җитди нәтиҗәләр ясарга иртәрәк булса да, хәзерге әдәбият белемендә аерым тенденцияләрне билгеләү омтылышлары булып тора.

Күпгасырлык татар әдәбиятының «магистраль» үсеш юлы Урта гасырларда – романтизм, ә инде Яңа заман әдәбиятында реализм һәм романтизм булган һәм ул бүген дә шулай кала. Иҗатларында реалистик фикерләүгә йөз тоткан әдипләр дә төрлечә эзләнүләр алып барып, аны яңа сыйфат-күренешләр белән баета. Яңа сыйфат ул әле сәнгати табыш дигән сүз түгел. Укучылар тарафыннан яратып укыла торган шактый сандагы әсәрләр язылса да, татар әдәбияты заман рухына, таләбенә туры килә торган үсеш юлына чыкты дип әйтергә әле иртәрәк. Р. Сверигин билгеләп үткәнчә, «ничек тә булса фаҗигале сенсацияләр эзләү һәм табу, күпвакыйгалылык, хәл-вакыйгаларның бик тиз үзгәреп тору ыгы-зыгысын күрсәтү шаукымы»[1] үзен ачык сиздерә. «Капиталистик системага юл тоту икътисадны, җәмгыятьне тиз арада криминальләштерде, кешелексезләндерде... Гаҗәеп пародокс ачылды бу чорда: бер яктан илдә йөзләгән чиркәүләр, мәчетләр төзелүен, яңартылуын дәвам иттеләр, ә икенче яктан исә Рәсәй дөньяда кеше үтерү буенча икенче (Колумбиядән кала), балаларның үз-үзен үтерүе буенча беренче урынга чыкты, – дип

[1] *Сверигин Р.Х.* Гасырлар чатында // Казан утлары. 2002. № 4. Б. 153.

яза И. Вәлиулла. – Кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләре еш кына криминал, “законлы карак”лар төшенчәләре, кануннары нигезендә төзелә башлады... Изге, игелекле юлдан язган залимнәргә, әхлакның ни икәнен дә белмәгән кешеләргә үзләренең түбән инстинктларын тормышка ашыру өчен юллар ачылды»[1].

Күпсанлы тәнкыйть мәкаләләрендә һәм аерым фәнни тикшеренүләрдә билгеләп үтелгәнчә, хәзерге татар әдәбиятына хас бер тенденция булып яшәешнең караңгы якларын, «тормыш төбен» чагылдыру, чынбарлыктагы әхлаксызлык күренешләрен, кешенең түбән инстинктларын җентекләп, еш кына натуралистик сурәтләрдә бирү тора. Р. Раков язганча, «бүгенге көн яшәешен тасвирлау сылтавы белән матбугат битләрендә җиңел кулдан язылган төссез, әхлаксыз әсәрләр дә басылып килә әле»[2]. Ә инде Р. Фәтхрахманов тагын да кискенрәк: «Яңа, традицион булмаган агым тарафдарлары исә популярлык мәсьәләсенең чишелешен азгынлык һәм оятсызлык пропагандалау аша хәл итәргә омтылалар, шуның белән үзләренең барлык матди ихтыяҗларын канәгатьләндерү юлын эзлиләр...»[3]. Мондый әсәрләр бертөрле генә кабул ителмичә, капма-каршы фикер-карашларга җирлек тудыралар. Берәүләр, моны чынбарлыкны бөтен тулылыгында, дөреслегендә тасвирлау дип кабул итсә, икенчеләр әдәбият төп бурыч-вазифасыннан читләште дип бәяли. Шуның белән бергә, әлеге төр иҗатның асылын аңлаткан термин-төшенчә уйлап табу омтылышлары да була. А. Әхмәдуллин хәзерге драматургиягә ясаган күзәтүендә җәмгыятьтәге үзгәрешләргә бәйле яшәешкә үтеп кергән рухи түбәнлекне, ягъни «драмаларның эчтәлегенә генә түгел, форма-стиль үзенчәлекләренә дә тәэсир»[4] итүен аңлаткан бу күренешне «гаҗизлек мотивы» дип атый. Р. Шәрәфиев фикеренчә, «үзебез кебек вак интригалар белән яшәүчеләрне, уй-хыяллары көнкүреш ыгы-зыгысыннан, парлашу-аерылышу кичерешләреннән уза алмаган, әмма “уйлап чыгарылмаган” әдәби геройларның» чит ил телесериалларыннан безнең сүз сәнгатенә үтеп керүе һәм тиз арада түргә дә менеп утыруы матур әдәбиятыбыздагы эзләнүләрнең саегуын күрсәтә. Тәнкыйтьче андый әсәрләрнең тулы бер катлам тәшкил итүенә нигезләнеп, аларны «бозыклык реализмы» дип билгели[5]. Т. Галиуллин трилогиясенә мөнәсәбәттә әлеге төшенчәне Р. Мостафин да куллана[6]. А. Хәлим исә соңгы елларда иҗат ителгән байтак әсәрләрдә «бөек илаһи мәхәббәт юк, ә менә бөек бозыклык, бөек зина буа буарлык» дигән

[1] *Вәлиулла И.Ә.* Яңа маяклар эзләгәндә... // Казан утлары. 2004. № 8. Б. 138.

[2] *Раков Р.* Укыр җаннар бетмәсен! // Казан утлары. 2004. № 9. Б. 159.

[3] *Фәтхрахманов Р.Г.* Татарга сатма матбугат... // Казан утлары. 2004. № 3. Б. 142.

[4] *Әхмәдуллин А.Г.* Бүгенге татар драматургиясенең кайбер үзенчәлекләре // Мирас. 2004. № 2. Б. 88.

[5] *Шәрәфиев Р.* Киләме, күрәбезме? // Казан утлары. 2004. № 1. Б. 162–163.

[6] *Мостафин Р.Ә.* Чорлар чатындагы үзгәрешләр // Казан утлары. 2004. № 5. Б. 148.

нәтиҗә ясый һәм сүз сәнгатендәге әлеге тармакны «азгын әдәбият» термины белән бәяли[1].

Р. Сверигин тормыш шыксызлыгын, аның ямьсез якларын тасвирлаган әсәрләрне «негатив проза» буларак билгеләсә[2], С. Хафизов бу мәсьәләгә ачыклык кертергә омтылып, сурәтләнгән тормыш материалына һәм авторның әдәби-эстетик карашларына бәйле китапларны төгәл аерып куярга чакыра, ә инде Сталин тоталитаризмын фаш иткән әсәрләрне «каргышлы проза» дип атау ягында тора[3].

Аерым язмаларда хәзерге татар сүз сәнгатендәге үзгәрешләрне, үзенчәлекләрне билгеләү, гомуми әдәби барыш яисә аерым әдип иҗатын әдәби юнәлеш-агымнарга мөнәсәбәтле һәм теоретик планда ачыклау омтылышлары ясала. Әлеге сорауларга беренчеләрдән булып мөрәҗәгать иткән Д. Заһидуллина «Яңа дулкында» мәкаләсендә болай дип яза: «Татар әдәбиятында соңгы ун-егерме ел эчендә пәйда булган әсәрләрнең күбесе модернизм элементларын үзенә туплаган яңа дулкында язылган. Аңа кадәрге 1970–1980 еллар әдәбияты яңартылган реализмның (модернистик реализм) “авыл прозасы” дигән төрен формалаштырган һәм М. Мәһдиев, А. Гыйләҗев, Р. Төхфәтуллин һ.б. иҗатында шуның гүзәл үрнәкләрен биргән булса, 1980–1990 еллар чигендә исә Ф. Бәйрәмова “психологик реализм” агымына нигез салды. (...) Үзәккә татарлар өчен хас проблемалар куеп (Ф. Садриев, Ф. Латыйфи һ.б.) “милли реализм” аваз бирде. Соңгы елларда ялгызлык фәлсәфәсен күрсәтүче, яшәеш кануннарын анализлап тормыш хакыйкатен тапкан әсәрләр– “интеллектуаль реализм” үрнәкләре – күренә башлады (мәсәлән, Р. Сибат иҗатында). Татар әдәбиятында төрле мәдәни юнәлешләргә, иҗат типларына, методларга хас алымнарның, күренешләрнең бергә, янәшә урнашуы, керешеп-үрелеп китүе күзәтелә»[4]. Күрсәтелгәннәрдән тыш, автор фикеренчә, хәзерге татар әдәбиятында «сентименталь реализм», «натурализм» агымнарына хас билгеләр киң чагылыш тапкан әдәби күренешләр дә урын ала.

Мондый бүленештә билгеле бер шартлылык бар. Яңартылган реализм алымнары дигәндә, әдипнең язу стиле, әсәренең темасы, төп пафосы, шәхес концепциясе – образ-характерларның сурәтләнеш үзенчәлеге, авторның үз әдәби-эстетик карашларын чагылдыру дәрәҗәсе, әсәр нигезенә салынган идея һ.б. күздә тотыла. Дөресрәге, әлеге компонент-төшенчәләрнең калкытып куелган булуы искә алына. Әйтик, мәкалә авторы «психологик реализм»ның асылын әсәрдәге төп образларның характер сыйфатларын ачу, «уй-фикер, хис-кичереш

---

[1] *Хәлим А.* Сез беләмсез кая барганны? // Казан утлары. 2005. № 1. Б. 128–129.
[2] *Сверигин Р.* Яңа замана, яңа геройлар // Казан утлары. 2004. № 11. Б. 159.
[3] *Хафизов С.* Кайда безнең рыцарьлар? // Казан утлары. 2004. № 11. Б. 131.
[4] *Заһидуллина Д.Ф.* Яңа дулкында // Казан утлары. 2003. № 1. Б. 152.

үсешен үзәккә кую, кешенең рухи дөньясындагы үзгәрешләрне сурәтләү объектына әйләндерү» һ.б.ны билгели. Аңлашылганча, ул татар әдәбиятының барлык этапларына диярлек хас күренеш. Мисал өчен, Ә. Еникинең кешенең рухи дөньясын алга чыгарып, андагы үзгәрешләрне, күңел тибрәнешләрен җентекләп ачкан әсәрләрен «психологик реализм» төшенчәсе белән атый алабыз. Шул ук вакытта әлеге агым тарафдары булып танылган Ф. Бәйрәмова иҗатына (бигрәк тә соңгы чор) миллилек тә хас. Димәк, безгә аның әсәрләрен «милли тормыш моделен тергезүне, төп сюжет сызыкларындагы үзәк каршылыкларның милли яссылыкта күренүен, милли характер тудыруны» күздә тоткан «милли реализм» агымына да кертеп карау мөмкинлеге бар. Югарыда әйтелгәнчә, мәсьәлә тикшеренүченең позициясендә һәм әсәрдә кайсы мәсьәлә-компонентларның нинди яссылыкта калкытып куелуына бәйле. Ф. Латыйфиның «Хыянәт», «Бәйсез этләрне атарга» кебек әсәрләре «психологик реализм», «интеллектуаль реализм» агымнарына хас сыйфат-билгеләрне ят итмиләр. Милли тормыш картинасын тудыру калкытып куелган әсәрләрне «милли реализм» агымына нисбәтле тикшерү дә төп үзенчәлекләрне тулырак ачарга ярдәм итә.

Күргәнебезчә, термин-төшенчәләрдә шактый төрлелек күзгә ташлана. Әсәрләрнең идея-проблематикасына, жанр формасына, өстенлек иткән пафоска һ.б. сыйфат-компонентларга нигезләнү билгеле бер чикләнгәнлек тудыра. Әйтик, «милли реализм» миллилекне реалистик юнәлештәге әсәрләргә генә хас билге рәвешендә чикләп куя. Әлеге каршылыклардан чыгу юлы әдәби күренешләрне ачыграк билгеләүче атама куллану белән бәйле. Традицион реализмның яңа төр алым-чаралар, сурәт-формалар белән тулыландырылган, баетылган формасын без *«яңа реализм»* һәм *«яңа романтизм»* дип атау ягында. Беренче термин рус әдәбият белемендә актив кулланылып килә[1].

А. Шәмсутова татар әдәбиятында «яңа реализм» төшенчәсе соцреализм методы әдәбият мәйданыннан киткәч формалашты, дип саный һәм аның түбәндәге юнәлешләрен атый: 1) милли юнәлеш; 2) тәнкыйди юнәлеш; 3) дини юнәлеш; 4) психоаналитик юнәлеш. Ул, болардан тыш, хәзерге әдәбиятка хас мөһим билгеләрдән тарихи теманың активлашуын, прозада герой турында бәхәсләрнең артуын, «чор авазын» һәм дөньяны кабул итүне чагылдыру феномены буларак, постмодернизмның мәйданга чыгуын һ.б.ны билгели[2]. Аңлашылганча, А. Шәмсутова әлеге төшенчә белән социалистик реализмнан соңгы бөтен әдәбиятны

[1] *Насрутдинова Л.* «Новый реализм» в русской прозе 1980–90-х годов (концепция человека и мира): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1999. 21 с.

[2] Программа. 1980–2000 елларда татар әдәбияты (Проза һәм драматургия) / төзүчесе А. Шәмсутова. Казан: Гуманитария, 2002. 23 б.

билгели. Югарыдагыларга нигезләнеп, «яңа реализм»ның түбәндәге юнәлешләрен (тенденцияләрен) аерып чыгарырга мөмкин.

*Тәнкыйди юнәлеш.* Хәзерге әдәбиятның үзәгендә торган проблема кеше һәм яңа җәмгыять мөнәсәбәте белән бәйле. Әдип иҗатының заманчалыгы – чорның социаль-иҗтимагый сорауларын чагылдыруы һәм чишүе белән аңлатыла. 1990 елларда посттоталитар җәмгыять шартларында кешенең дөньяны күзаллавын ачу алга куела. Шуңа да әсәрләрдә, бер яктан, совет системасын тәнкыйтьләү киң урын алса, икенче яктан, чор яшәешенең кырыс шартлары нәтиҗәсендә авыр хәлдә калган шәхес фаҗигасен социаль-фәлсәфи планда чагылдыру күзәтелә (И. Салаховның «Колыма хикәяләре» («Тайгак кичү»), М. Хәсәновның «Язгы аҗаган», Ә. Баянның «Урланган ай», Г. Каюмовның «Мирас» («Упкын өстендә уен»), З. Хәкимнең «Кишер басуы» һ.б. әсәрләр). З. Хәкимнең «Кишер басуы» (1993) трагикомедиясендә 1980 еллар ахыры – 1990 еллар башы татар авылы тасвирлана. Вакыйга-күренешләр бер авыл белән генә чикләнмичә, татар тормышының төрле якларын ачып сала. Халкыбыз теле, гореф-гадәтләре сакланышын гомер-гомергә авыл белән бәйләп караган. Шуңа да авылларның хәле, хөкем сөргән шартлар, заман йогынтысында барлыкка килгән үзгәрешләр милләтнең бүгенгесе һәм киләчәгенә дә ишарә булып тора. Пьесада, кызганыч ки, кара төсләр өстенлек итә. Татар авылы авыр хәлдә яши: һәркайда хәерчелек, кияргә юньле кием, ашарга ризык юк, эчкечелек зур бер афәткә әйләнеп килә, урлашу да гадәти күренеш. Иң яманы шунда: халык боларга гадәтләнгән, үзгәрешләргә ышанмый, бөтен дөньясы ялганга корылган дип саный. Әлеге караңгылык-әхлаксызлыкта якты төсмер булып Фәрит-Галия сызыгы килеп керә. Яшәешкә янаган куркынычны ачык күрүче әлеге яшьләр күңелендә өмет-ышаныч, матурлыкка омтылыш сүнмәгән. Алар изге төшенчәләрне саклаучы, онытылып барган гадәтләрне кайтаручы булып күзаллана. Башка планетадан татар кардәшләр килү вакыйгасы метафора булып, халкыбызга янаган куркынычны ачуга хезмәт итә.

Автор халкыбызда милли үзаң түбән булуы өчен тирәнтен борчыла, суверенитет кебек изге төшенчәне ашау-эчү, кием-салым һәм башка кирәк-яраклар аша аңлауга җаны әрни. Тормыш-яшәештәге үзгәрешләрне драматург ике мәсьәлә белән бәйләп карый. Берсе – «Ә нигә соң без шундый?» дигән сорау куеп, һәркем күңелендә үзгәрешләргә омтылу, киләчәккә ышану хисләре булдыру; икенчесе – татар халкының таркаулыгы, үзара мөнәсәбәтләрдә көнчелеккә, хөсетлеккә, бер-береңә ышанмауга юл куелу. Шуңа да пьесаны татар халкының берләшүе генә киләчәк уңышларга нигез була ала дигән фикер иңләп үтә.

*Милли юнәлеш*. Хәзерге татар әдәбиятындагы төп тенденцияләрнең берсе миллилек төшенчәсе белән бәйле. С. Хафизов аның төп сыйфатларын болай билгели: «Беренчедән, бу – һичшиксез, халыкның холык-

фигылен, йола-гадәтләрен, тарихын ышандырырлык итеп гәүдәләндерү. Икенчедән, заманның кайгы-хәсрәтен, шатлыгын, рухын халыкча нечкәләп сиземләү һәм сурәтләү. Өченчедән, тойгыларын аерым төркем белән генә бәйләмичә, милләтне тәшкил иткән барлык катламнарның уртак мәнфәгатьләрен чагылдыруга ирешү һәм, ниһаять, зур, тәэсирле талант көче, сәнгатьчә осталык белән иртәме-соңмы ил каршында танылу»[1]. Халыкның үзаңы үсешенә бәйле әдәби иҗатның аерым чорларында миллилек аеруча калку куела. Аның гаять көчле күтәрелешен ХХ гасыр башында күрәбез. Й. Нигъмәтуллина «идеяләр романтизмы» дип атаган әлеге күренеш 1920 еллар ахырында социалистик идеаллар белән алышына. Ә инде 1980 еллар ахыры – 1990 еллар башында «әдәбиятның миллилеге» төшенчәсе яңадан үзәккә куела. «Милли әдәбиятның нигезендә милли идея ята. Ул, беренче чиратта, тарихи милли идея, – дип яза А. Хәлим. – Милли идея милләтнең умыртка сөяге, дөресрәге, умыртка сөяген ныгыта торган мәгъдән-витаминнар – Көч һәм Куәт, Гармония һәм Әдәп, Матурлык һәм Батырлык, Туган җир һәм Ватан, Милләт һәм Ходай Тәгалә, Ата һәм Ана, милли Горурлык һәм Ватанны Сөю, бар Дөньяны һәм аның Табигатен – барча милләт, барча җанвар, кош-корт, барча тереклекне сөю һәм башка бихисап «сөйдергеч зәм»нәрне үз эченә ала ул. Канун буларак һәрбер милләтнең милли идеясе изгелек белән сугарылган»[2].

Әсәрләрдә милләт язмышы чагылышында өч төрле тармаклану күзәтелә. *Берсе* – ерактагы һәм якындагы тарихка мөрәҗәгать итү һәм шуңа бәйле билгеле тарихи шәхесләрнең әдәби образын гәүдәләндерү (Р. Мөхәммәдиев «Сират күпере», Ф. Сафин «Саташып аткан таң» һ.б.). М. Маликованың «Сөембикә» пьесасында данлы һәм фаҗигале тарихыбызның аерым сәхифәләре аша хәзергебезне фәлсәфи планда аңлау омтылышы ясала. Соңрак язылган әсәрләр арасында Р. Батулланың Заһидә Тинчурина язмышын, шуның белән бергә татарның ХХ гасырдагы фаҗигасен үзәккә алган «Җимерелгән бәхет» драматик хикәясе аерылып тора. Милли тематиканың *икенче төр* чагылышы буларак, милли эчтәлекне халыкның асылын билгеләүче традицияләр, гореф-гадәтләр, тел-моң төшенчәләренең герой характерында, эшгамәлендә бирелеше аша ачу белән З. Хәкимнең «Телсез күке»сендә очрашабыз. Пьесада милли бердәмлек идеясе өстенлек итә. Бөек Ватан сугышы алды елларыннан алып хәзерге көннәргә кадәрге вакытны үз эченә алган вакыйга-күренешләрнең асыл мәгънәсе күпкә киң. Автор XVI гасырның икенче яртысыннан бирле колониаль шартларда яшәгән халкыбызның үз милли асылын саклап калуның нигезен ача. Бу – гаделлекнең җиңүенә ышану, миллилекне дин, гореф-гадәт аша гына түгел,

[1] *Хафизов С.* Әдәбиятта базар заманы // Казан утлары. 1998. № 8. Б. 157.
[2] *Хәлим А.* Сез беләмсез кая барганны? // Казан утлары. 2005. № 2. Б. 121.

бәлки җыр-моң буларак җанда урын алган яшәү рәвешендә саклау һәм нинди генә шартларда, кайда гына яшәгәндә дә бердәмлеккә омтылу. *Өченче төр* әсәрләрдә (Ф. Латыйфиның «Ишелеп төшкән бәхет»е, Ф. Садриевның «Таң җиле» һ.б.) милләт язмышы эчтәлектә «эретелеп» бирелә һәм герой характерын билгеләүче бер сыйфат булып килә.

*Интеллектуаль юнәлеш.* Интеллектуаль башлангыч алгы планга чыгарылган әсәрләрдә житди табыш-яңалык күзәтелә. Әлеге сыйфат тормыш-чынбарлыкны бәяләү аша яшәеш кануннарын ачуга нигезләнә. Авторлар уй-фикергә йөз тоткан эчтәлектә тормыш Хакыйкатен эзли. Әсәрләрдә (А. Гыйләҗевнең «Яра»сы, М. Галиевнең «Алтын тотка»сы, Р. Сибатның «Ялгызак»ы, Р. Харисның «Чехов базары», «Исемсезләр»е, Т. Миңнуллинның «Дивана»сы һ.б.да) үзәкне төп геройларның бәхәсе алып тора һәм ул, гадәттә, чынбарлыкның гаять мөһим әхлакый, фәлсәфи, милли һ.б. мәсьәләләрен үз эченә ала. Драматург И. Зәйниевнең «Суган чәчәге» драмасы яшәү мәгънәсен, бәхет төшенчәсен ничек аңлауга бәйле фикер көрәшенә нигезләнә. Күп төрле бәхәсләргә этәргән[1] пьесада әдәбият-сәнгать мәсьәләләре аша яшәешнең житди сораулары игътибарга алынса да, ике мәсьәлә аеруча калкытып куела. Берсе – язучы-драматург, режиссер, артистлар кебек театр сәнгатенең үзәген тәшкил итүчеләрнең үзара катлаулы, каршылыклы мөнәсәбәте, аның аерым шәхесләр язмышына йогынтысы, икенчесе – сәнгать дөньясында эшләүчеләрнең яисә шул даирәгә якын булучыларның шәхси тормышын, хыял-омтылышын, яшәү мәгънәсен ачыклау. Алар, билгеле, үзара кушылып та китәләр һәм башка мәсьәләләр, аерым алганда, чын һәм ялган кыйммәтләр, хакыйкатькә омтылу һәм битлек киеп яшәү һ.б. турында уйланырга этәрәләр. Вакыйга-күренешләрнең төп өлешен геройлар язмышына бәйле коллизияләр алып тора. Пьесаның «Суган чәчәге» дип аталуы да шуның белән бәйле. Әсәр геройлары бергәләп укыган пьесада катнашучыларның, димәк, үзләренең дә яшәешен Җәүдәт болай аңлата: «Тормышлары чәчәк кебек матур булса да, суган кебек ачы, күз яшьле. Матур тормыш өчен алар барысы да нәрсәдер корбан итәргә мәҗбүрләр...» Гомере буе үзе турында гына уйлап, башкалар тормышына, шул исәптән хатыны Ландышка, сеңлесе Галиягә, балаларына битараф булып яшәгән драматург Солтан Кадерхөрмәтов олы Хакыйкатьтән куркып кала. Ә инде улы Җәүдәтнең револьвер тотып чыгып китүе һәм бакчада ату тавышы яңгыравы (әлеге күренеш спектакльдә үзгәртелгән) Солтан корган яшәешнең, аның тормыш фәлсәфәсенең җимерелүенә ишарә итә. Шуның белән бергә, әсәрне кабул итүдәге кыенлыклар түбәндәгеләр белән аңлатыла кебек. Бердән, сәхнә закончалыклары буенча, геройның эш-гамәле ачык-аңлаешлы булырга

[1] *Рахман Р.* «Горький цвет» // Звезда Поволжья. 2007. 22–28 ноября; *Игламов Н.* Две реальности // Звезда Поволжья. 2007. 6–12 декабря.

тиеш. Пьесада исә ул һәрвакытта да сакланмый. Икенчедән, аерым геройларның рухи эволюциясе төгәлләнмәгәнлек турында фикер калдыра. Әйтик, Солтан Кадерхөрмәтов күңелендә башланган үзгәреш ни сәбәпле туктап калды? Яисә Булат Тимерланов әсәр дәвамында сәхнәгә кире кайтмаячагын белдерсә дә, ахырда премьерада катнашуы билгеле була. Әтисе белән аңлаша башлаган Җәүдәтнең атылуы сәбәбе дә бик томанлы. Дөресрәге, аны бу адымга этәрерлек сәбәп юк. Өченчедән, пьесаны «сагышлы комедия» дип атау да бәхәсле. Билгеле, авторның Солтан төзегән яшәү рәвешенә ироник карашы сизелә. Шулай да финалдан чыгып бәяләгәндә драматизм өстенлек итә.

*Психологик юнәлеш.* Әдәби әсәрдә геройларның рухи дөньясына, күңел кичерешләренә үтеп керү, аны әдәби сурәтләрдә тасвирлау язучыдан зур талант таләп итә, шуңа да ул әдәбиятның өлгергәнлек дәрәҗәсен билгеләүче төшенчәләрнең берсе булып тора. Татар сүз сәнгате психологизм белән сугарылган уңышлы әсәрләрнең зур циклын XX йөз башында ук бирә. 1917 елдан соңгы әдәбиятта, мәгълүм шарт-сәбәпләргә бәйле, аңа игътибар кимесә дә, теге яки бу дәрәҗәдә психологик төсмерләр барыбер саклана (М. Галәүнең «Мөһаҗирләр»е, Ф. Хөснинең «Йөзек кашы», Ә. Еникинең «Ана һәм кыз»ы, «Кем җырлады?»сы һ.б. әсәрләр). Ә инде 1960 елларда әдәбияттагы сыйфат үзгәрешләренең җитди чагылышы булып психологик башлангычның алга чыгуы тора. Хәзерге татар әдәбиятында кеше психологиясен ачуның яңа чара-юлларын, алымнарын эзләү көчәйде. Авторларның актив рәвештә «җан хәрәкәте», эчке монолог, үзанализ, төрле заттан бәя бирү һ.б. алымнарга мөрәҗәгать итүе күзәтелә (Ф. Бәйрәмова, М. Әмирханов, Ә. Гаффар, Т. Миңнуллин һ.б.). Г. Каюмовның «Сагынырсың әле син дә бер...» психологик драмасында әдәп-әхлак кануннарына кул селтәгән, тормыштагы беренче адымнарында ук сөрлеккән яшь геройлар белән очрашабыз. Әйләнмә композициягә нигезләнгән вакыйгалар үзәгендә Гөлсинә һәм Кәрим язмышы тора. Автор тормыш каршылыкларын ачуның яңа юлларын, чараларын эзли, әдәби-эстетик карашларын заманның әхлакый һәм социаль-иҗтимагый сораулары белән бәйли. Укучы-тамашачы каршында ике төрле яшәү фәлсәфәсенә таянган кешеләр язмышы ачыла. Гөлсинәнең эш-гамәлендә, фикерләү рәвешендә, акылдан бигрәк, хисләр өстенлек иткәнлеге күренә. Ул үзсүзле, үзенекен эшләргә гадәтләнгән һәм теләгенә ирешүдә башкалар бәхетен таптап үтәргә дә әзер. Аның капма-каршысы буларак, авылда туып үскән Кәрим – ярдәмчел, йомшак табигатьле һәм бик горур. Матурлыкка сокланып, рәссам булу теләге белән йөри. Әлеге ике төрле кешедә бер-берсенә карата сөю хисе тууын ничек аңлатырга соң? Гөлсинә күңелендә, күрәсең, ягымлы мөнәсәбәткә, рухи матурлыкка сусау булган. Кәрим исә Гөлсинә тупаслыгы-кирелегенең әйләнә-тирәсе, әнисе тәэсирендә барлыкка килгән тышкы чагылыш

икәнлеген аңлаган дип уйларга нигез бар. Кыз күңелендәге матур сыйфатларны да тоемлый ул. Икенче яктан, үзенең яшәү фәлсәфәсен, ягъни көчсезләргә, ялгышканнарга, үз урынын таба алмый азаплanучыларга ярдәм итеп һәм матурлык, хыял-өмет аша явызлык-усаллыкны, гаделсезлекне җиңеп була дигән карашларын тормышка ашыру мөмкинлеген дә күргән. Әмма әлеге гаилә ныклап аякка баса алмый. Гөлсинә иренә хыянәт итә, әкренләп әхлаксызлык сазына бата бара. Кәрим үзенең хаталануын аңлап, аерылып киткәндәге соңгы сүзендә олы йөрәген, чиста җанын күрә алмаганын Гөлсинәгә әйтә: «Сагынырсың әле син дә бер...» Бу сүзләрнең мәгънәсенә яшь хатын соңарып төшенә. Ул үз җанына урын таба алмый, үткән тормышы, яшәү мәгънәсе турында уйлана. Кәрим китү белән нәрсәнедер югалтуын сизә. Шул рәвешле драмага Ялгызлык мотивы килеп керә. Сызлану фәлсәфәсенең бер ысулы булган бу күренеш аша геройлар сыналу үтә. Мәхәббәтен югалтуы, бәхеткә омтылып та, аңа ирешә алмавы Гөлсинә күңелендә өметсезлек хисен үстерә, яшәешнең мәгънәсезлеге турында уйлануларга китерә. Әлеге геройның рухи түбәнлеккә төшүе, соңыннан үз-үзен һәм тормыштагы урынын аңларга омтылуы психологик яктан уңышлы мотивлаштырыла. Герой эволюциясе тормыш каршылыклары, күптөрле коллизияләр аша бара. Социаль-психологик тип буларак, ул төрлечә бәяләнә, дөресрәге җәлләү һәм борчылу, ачу һәм гаепләү, аңларга омтылу бергә кушылып китә. Пьесаның ике катламлылыгы, психолог белән сөйләшү барышында Гөлсинәнең ике ел гомерен күз алдыннан үткәрүе укучы-тамашачыга герой психологиясен тулы аңларга мөмкинлек бирә. Яшь хатынның рухи-әхлакый үзгәрүе әлегә эш-гамәлендә чагылыш тапмый, әмма аңа хәзер Саймә-Альбертлар кебек буш, мәгънәсез омтылышларга нигезләнгән тормышка кире кайту, акча-әйбер колы гына булу куркынычы янамый.

Драматургның әдәби-эстетик карашларын чагылдыруда Кәрим образы әһәмиятле роль уйный. Әлеге герой гадәти тип түгел. Күңел дөньясы лирик-фәлсәфи эчтәлек белән сугарылган шәхес, бер яктан, мескен, үз дөньясына бикләнгән, әйләнә-тирә тормыштан аерылган кебек күренсә, икенче яктан, андагы сабырлык сокландыра, җан тынычлыгына омтылып, матурлык көченә ышанып һәм таянып яшәве хөрмәт уята. Аның сәнгать дөньясына тартылуында, җаны-тәне белән яшәешнең вак бертөрлелегеннән, һәртөр ыгы-зыгысыннан өстен булырга омтылуында романтик күтәренкелек чагыла. Гомумән, пьесада төрле жанр элементларының кушылып килүе әдипнең үзенчәлекле стилен барлыкка китерә.

*Тормыш-көнкүреш юнәлеше*. Мондый төр әсәрләрдә гаиләгә һәм көнкүрешкә бәйле вакыйгалар, вакыт һәм пространство чикләрен үтеп, мәңгелек төшенчәләр турында уйлануга барып тоташа. Әсәрләрдә этнографик, милли билгеләр кешенең туган җирен, яшәү шартларын

ачу-аңлатуга хезмәт итә. (Г. Галиева, К. Кәримов, Р. Фәизов, А. Хәлим, Р. Хәмид, Д. Салихов һ.б. иҗатында аның матур үрнәкләре белән очрашабыз.) Р. Хәмид «Олы юлның тузаны» әсәрен драматик хикәя дип атый һәм моның белән аның, сәхнәгә куюдан бигрәк, укылу өчен язылуын искәртә кебек. Автор үзе үк сурәтләнгән вакыйганың реаль фактларга нигезләнүен әйтә. Үзәктә – улы янына шәһәргә китәргә җыенган Нәүхәбәр әбинең бер көне. Әбинең йорты, эчке бизәлеше, өй кирәк-яраклары, төрле этнографик детальләр гасырлар дәвамында сакланып, буыннан-буынга күчеп килгән яшәү рәвешен, гореф-гадәтләрне, йолаларны хәтерләтә. Бу өйгә дә заман шаукымы үтеп кергәнлеген сиздереп, түрдә телевизор утыра. Нәүхәбәр әби байтак еллар инде ялгыз яши. Сәхнә закончалыкларына буйсындырылганга, драматургиядә аны сурәтләү шактый кыен. Шәхес ялгызлыгы, нигездә, геройның психологик халәтен ачу, күңел каршылыкларын, башкаларга һәм җәмгыятькә мөнәсәбәттә фикер-карашлар төрлелеген бирүгә кайтып кала. Мисал өчен, Г. Камалның «Бәхетсез егет» ендә Закир, Г. Коләхмәтовның «Ике фикер»ендә Давыт, Г. Исхакыйның «Мөгаллим»ендә Салих, К. Тинчуринның «Соңгы сәлам»ендә Вахит, Ш. Хөсәеновның «Зөбәйдә – адәм баласы»нда Зөбәйдә, Т. Миңнуллинның «Хушыгыз»ында Миләүшә һ.б.ның монологлары әнә шуңа хезмәт итә. Р. Хәмид пьесасында ялгызлык мотивы бөтен эчтәлекне сугара. Әсәр тулысынча моңа буйсындырылган, чөнки ул монодрама, ягъни анда бер генә персонаж катнаша. Нәүхәбәр әбинең төрле әйберпредметларга мөрәҗәгать итеп сөйләшүендә бөтен язмышы ачыла, үткән һәм бүгенгебез, киләчәгебез турында, ата-бабадан калган гадәтйолаларыбызга, заман алып килгән үзгәрешләргә, авыллар язмышына, гаиләдәге мөнәсәбәтләргә карашы чагыла. Ул ялгызлыгыннан үткәндәге хатирәләре, истәлекләре ярдәмендә «котыла». Әбинең уйланусөйләнүләрендә үзенең, гаиләсенең генә түгел, бөтен халыкның каршылыклы, авыр, еш кына фаҗигале язмышы ачыла.

Р. Хәмид ана – бала каршылыгын иң югары ноктага әсәр ахырында гына җиткерә. Баштагы өлештә Нәүхәбәр әбинең туган җиреннән китүенә кайгыруы ачык сизелсә дә, өстенлек улы ягында. Тәфкил анасына ялгыз яшәү авыр икәнен аңлап, бөтен нәрсәсе булган бай, матур шәһәр фатирында үзләре белән яшәргә чакыра. Әби сыкранып булса да әйберләрен җыеп бетергәч, Тәфкилдән телеграмма килә. Улы кайтып ала алмаганын, әнисенең шәһәргә үзе килүен сораган. Борчылудан болай да җаны айкалган Нәүхәбәр әби, бу хәбәрдән соң, түзми, күңел төбендәге ачы хакыйкатьне беренче тапкыр теле белән әйтә. Ниһаять, пьесаның төп идеясен ачарга, ана – бала каршылыгын аңларга ярдәм иткән сорау яңгырый: «Ни өчен таш бәгырьле булып үсте икән Тәфкил?» Бала вакытта кече җанлы, нечкә күңелле улының характеры үзгәрү сәбәпләрен Нәүхәбәр әби үз тормыш юлыннан эзли. Югарыда

әйтелгәнчә, ана үзеннән дә гаепне төшерми. Тормыш нужасы белән изаланып, Тәфкилне үз юлынарак куюын, улының беренче абынуларыннан соң тиешле чаралар күреп бетермәвен аңлый ул. Шулай да төп сәбәпнең җәмгыятьтә, яшәп килгән тәртипләрдә икәнлеген дә ачык тоя ана. Тәфкил бик яшьли колхоздагы гаделсезлек, җитәкчеләрнең башбаштаклыгы белән очраша. Аларны үзгәртеп булмасын аңлагач, читкә китеп, сукно фабрикасына эшкә урнаша. Яшь егет монда эшләгәндә дә бюрократлык, әшнәлек белән йөзгә-йөз бәрелә. Дөреслекне яклап чыккач, аны сукно урлауда нахакка гаеплиләр һәм эштән куалар. Әлеге хәлләр егетнең бәгыренә каты җәрәхәт сала. Ул дөреслек юклыгына инана һәм үзе өчен, бары үзе өчен генә яши башлый. Әнә шул рәвешле Р. Хәмид җәмгыятебезгә килеп кергән рухи бушлык, миһербансызлык, байлык артыннан куу кебек әхлаксызлык күренешләре өчен тирәнтен борчыла. Шуңа да Нәүхәбәр әби язмышы аша автор милләт язмышы, аның бүгенгесе, киләчәге турында уйлануга алып чыга. Кеше тормышында рухи һәм матди байлыкның урыны, роле турында бәхәсләрнең бервакытта да тынып торганы юк. Рәхәт, матур яшәешкә омтылу һәр кешегә хас. Әмма матди байлык кына кешегә тулы канәгатьлек, бәхет китерми. Акыл һәм хискә ия булган адәм заты күңел байлыгы, әхлакый сафлыгы, вөҗданы белән матур.

Драматург кулланган әдәби детальләр арасында телевизор һәм мылтык та бар. Пьеса дәвамында телевизор кабызылмый да, әби аның белән сөйләшми дә. Түрдә утырган, үзеннән шыксызлык, салкынлык бәрелеп торган әлеге образ-деталь заман үзгәрешләрен аңлата. Әсәрдә күренмәгән, ләкин барлыгы һәрдаим сизелеп торган Тәфкил белән аның арасында охшашлык-якынлык ачык сизелә. Мылтык деталенә дә автор тирән мәгънә салган. Кайчандыр, Нәүхәбәр яшь килен вакытта, биатасы, икмәк талап йөрүчеләргә каршы тору өчен, өйгә мылтык алып керә. Хәзер исә әби-баба чорыннан калган шул мылтыкны өйне туздырырга – сатып алырга теләүчеләргә каршы тору өчен, әби кулына ала. Шул рәвешле автор буыннар арасындагы рухи бәйләнеш кимү, авыллар бетү кебек күренешләр аша үткәнебез, бүгенгебез һәм киләчәгебез турында уйланырга этәрә.

*Лирик-эмоциональ юнәлеш.* Хәзерге сүз сәнгатендәге эзләнүләрнең бер юнәлешен авторларның лирик-эмоциональ башлангычка йөз тотулары билгели. Әлеге әсәрләрдә хис-кичерешләр дөньясы хөкем сөрә. Мәхәббәт идеал дәрәҗәсенә күтәрелә һәм аңа тугрылык саклау-сакламау геройның бүгенгесен генә түгел, киләчәген дә билгеләүче күренешкә әверелә. Мондый тенденция, лирик һәм лиро-эпик әсәрләр белән бергә, проза һәм драма төрләрендә дә киң чагылыш таба (Ф. Садриев, М. Галиев, Р. Рахман, Р. Мулланурова, А. Әхмәтгалиева, Р. Габделхакова һ.б.). Лиризм, гомумән, татар сәхнә әдәбиятының бер үзенчәлеге булып

тора. Соңгы елларда дөнья күргән әсәрләрдә (Д. Салиховның «Өзелгән йөзем», Аманулланың «Моңлы ядкәр», Х. Ибраһимның «Ялгыз каен күзе», И. Зәйниевнең «Мәхәббәт турында сөйләшик» һ.б.да) ул җыр-музыка белән кушылып мелодраматик төсмерләр ала, тагы да байый. Д. Салиховның җыр-музыка белән үрелеп барган, мелодраматик әсәрләргә хас тирән эмоциональ кичерешләргә бай «Өзелгән йөзем» драмасында гаять гыйбрәтле, шул ук вакытта тормышчан вакыйгалар сурәтләнә. Автор Бөек Ватан сугышыннан калган тән һәм аннан да бигрәк күңел яраларының безнең көннәрдә дә тынгылык бирмәвен, җитди сынауларга, хәтта каршылыкларга китерүен чагылдыра. Әйе, язмыштан узмыш юк, диләр. Сәлимгәрәй, Мәрьям һәм Сәүбән мөнәсәбәте гади мәхәббәт «өчпочмагы» гына түгел, бәлки тормыш сынавы, язмыш дәрьясы, кеше мөнәсәбәтләренең иң нечкә кылларга кагылып чыңлавы, бәрелеше һәм дә үпкә, сагыш, сыкрану булып тынып калуы чагылышы. Әлеге тормыш каршылыкларыннан тыныч-сабыр һәм кешегә хас матур сыйфатларны саклап чыга алган геройларга автор үзенең хөрмәтен яшерми. Пьесадагы вакыйгаларның ике катламда баруы үткәннәр белән бүгенгенең тыгыз бәйләнешен бөтен тирәнлегендә аңларга булыша.

*Сентименталь юнәлеш*. Татар әдәбиятында ул шәхес һәм җәмгыять каршылыгына бәйле хис-кичерешләр байлыгын, кешенең көчсезлеген, кызгану һәм сабырлык күренешләрен алга чыгару белән характерлана. Билгеле инде, бу юнәлеш лирик-эмоциональ, лирик-психологик башлангычлар урын алган әсәрләргә дә бик якын. Татар әдәбиятында ул, еш кына, авыл тормышын, халыкның шунда сакланып калган матур сыйфатларын, акылын, хәтерен яклау, ә шәһәрне кабул итмәү булып та чагыла (М. Мәһдиевнең «Бәхилләшү», Н. Гыйматдинованың «Парлы ялгыз» һ.б. әсәрләрдә). Әлеге сыйфат-билгеләр Т. Миңнуллинның «Галиябану, сылуым-иркәм» пьесасында интертекстуальлек төшенчәсенә, тарихта билгеле әсәр текстына нигезләнеп ачыла. Пьеса 60 яшен узган театр артистларының драматург Туран Муллин язган «Галиябану, сылуым-иркәм» дип исемләнгән әсәрне укырга җыелулары белән башланып китә. Т. Миңнуллинның игътибар үзәгендә әдәбият-сәнгать дөньясы, аның кеше тормышындагы урыны, төрле буын кешеләрнең әдәби ядкәрләргә караш-мөнәсәбәте һәм, иң мөһиме, кеше яшәешенең, аның теләкләренең, борчу-мәшәкатьләренең тирән катламнарын ачу, шуларны аңларга омтылу тора. Әлеге катлаулы мәсьәләләрне укучы-тамашачыга җиткерү максатында автор интертекстуальлек форма-алымына мөрәҗәгать итә. Әсәрдә ул драматургның әдәби-мәдәни карашларын геройларның эш-гамәле, уены аша бөтен тулылыгында ачуын юнәлтелгән.

Т. Миңнуллин әсәренең исемендә үк интертекстуальлекнең эчтәлекне билгеләүче форма булуына ишарә бар – «Галиябану, сылуым-иркәм». Әлеге исемнең XX йөз башында яшәп иҗат иткән М. Фәйзинең

татар драматургиясендәге классик үрнәкләрнең берсе булган атаклы «Галиябану» мелодрамасына аваздаш булуын татар әдәбияты-сәнгате белән таныш кешегә сиземләү кыен түгел. Берничә буын укучы-тамашачыны тәрбияләгән әсәр турында Т. Миңнуллин геройларының бәхәсе телевизордан яшь буын артистлар уйнавында «Галиябану» спектаклен карау, аны бәяләү аша үстерелә. Гомерләрен сәхнәгә багышлаган татар артистлары өчен, дөньякүләм яңгыраш алган Шекспир әсәрләре кебек үк, татар драматургы М. Фәйзинең «Галиябану»ы да – соклангыч иҗат үрнәге. Яшьләр уенына җаны белән әрнегән Нәсимә Ришатны чакыра һәм алар өзекне икесе уйнап күрсәтә. Т. Миңнуллин беренче карашка ачык та, гади дә һәм гадел дә булып тоелган юлдан – өлкәннәр уенын идеаллаштырып, яшьләргә үрнәк итеп кую белән китми. Аның өчен әсәрдәге персонаж роленә керү барышында артистның рухи дөньясын, күңелендәге кичерешләрне ачу тагы да мөһимрәк. М. Фәйзинең «Галиябану» мелодрамасына мөрәҗәгать итү, яшьләр уйнавында спектакльдән өзекләр карау һәм өлкәннәрнең үзара уйнап күрсәтүе драматургның әдәби алым буларак «уен»ны файдалануын күрсәтә. Т. Миңнуллин, «уен»ны әдәби алым буларак кулланып, бер яктан, классик әсәргә бәя бирә, икенче яктан, геройларының рухи дөньясын ача. Драматург автор концепциясенең режиссер күзаллавында һәм артистлар уйнавында үзгәрешләр кичерү мәсьәләсенә килеп чыга. Шул уңайдан Т. Миңнуллинның, укучы буларак, Хәлил образына карашы да кызыклы. Әлеге геройга бәя биреп, ул болай дип язган иде: «Минем элек-электән Хәлилгә ачуым килә иде. Җебегән егет дип саный идем. Мәхәббәте өчен егетләрчә көрәшә белмәве миңа ошамый иде. Бүген дә мин Хәлилгә сокланмыйм, Галиябануга сокланам. Ул көчле натура»[1].

Артист, сәхнәдә нинди тормыш кичереп, нинди образлар иҗат итүенә карамастан, беренче чиратта, кеше булып кала. Драматургның әсәр үзәгенә куйган сорауларының берсе әнә шуның белән бәйле. Вакыйгаларда һәрберсенең диярлек каршылыклы рухи дөньясы, эчке фаҗигасе ачыла. Автор өчен, билгеле, яшьләр уенына башкаларның да мөнәсәбәте кызыклы. Галиябану белән Хәлил диалогын караганнан соң, хәзер инде Гөлли, түзми, барып телевизорны сүндерә. «Атлап йөрүләре татар кызы түгел. Артын марҗа кебек боргалый», – ди ул һәм әлеге эпизодны Ришат белән уйнап күрсәтергә алына. Әмма Галиябану ролендәге Гөллине Әнвәр кабул итми һәм кат-кат образ юклыгын, үзе күзаллаган образ тудырылмавын әйтә. Гөллинең борчылып елавы исә Әнвәр белән аңлашуга китерә.

Алдагы күренешләрдә геройлары теле белән драматург «Галиябану»га бәясен тирәнәйтә. Аеруча М. Фәйзи пьесасындагы образларның

[1] *Миңнуллин Т.* Хәлил әйбәт егетме? // Мәгариф. 2000. № 3. Б. 32–33.

янып-көеп яратуында, сызлану-борчылуында, аңлашу-аерылышуында татарның милли рухы, яхшы да, яман да сыйфатлары чагылуы искәртелә. Пьесаның тагын бер үзенчәлеге – сәнгать әһелләре тормышының «пәрдә»сен ачып күрсәтү белән бәйле. Сәнгать алымнары ярдәмендә чагылдыру шактый авыр булган мәсьәләгә Т. Миңнуллин беренче тапкыр гына мөрәҗәгать итми. Драматургның «Миләүшәнең туган көне», «Дуслар җыелган җирдә», «Хушыгыз» драмаларын эченә алган трилогиясе сәнгать өлкәсендә эшләүче тулы бер буын язмышын тасвирлавы белән җәмәгатьчелектә киң яңгыраш тапкан иде. «Галиябану, сылуым-иркәм»дә театр артистларының үзенчәлекле тормышы ачылып китә. Автор аларны сәнгать әһеле һәм кеше буларак аңларга омтыла. Бер яктан, интертекстуальлек һәм уен алымы, икенче яктан, вакыйгакүренешләрнең өч катламда бирелүе шул максатка хезмәт итә. Бер катлам булып, билгеле инде, яшь артистлар уены тора. Өлкәннәр аны «хиссез-кичерешсез» дип бәяли һәм пьесада ике буын арасындагы каршылык буларак та үстерелә. Ниһаять, вакыйгаларның өченче катламында артистларның шәхси, рухи дөньялары ачылып китә. Артистның сәхнәдәге уены белән бергә, яшәештәге «роле» дә бар. Ул исә күпкә катлаулырак, тирәнрәк, еш кына фаҗигалерәк тә. Нәкъ менә Әнвәр белән бергә-бер калганда Нәсимәнең дә, Гөллинең дә, Фираяның да тормышка ашмаган хыял-омтылышлары, үзенчәлекле язмышлары ачыла. Шунысы игътибарга лаек, алар күңелендәге хис-кичерешләр күзгалышына «Галиябану»ны уйнау йогынты ясый. Әлеге мелодрамадагы Галиябанунының тирән мәхәббәте, сөйгәнен югалту кайгысы югарыда исемнәре аталган хатын-кызларның рухи кичерешләре белән кушылып китә һәм пьесадагы психологизмны баета. Шул ук вакытта М. Фәйзи «Галиябану»ының популярлыгы сәбәбе дә тагын бер кат искәртелә: әлеге мелодрама һәркем күңелендәге хис-кичерешләрне кузгата һәм яңарта, шуның белән укучы-тамашачыны сафландыра, җанын иркәли, күңелендә матурлыкка, мәхәббәткә омтылу теләге тудыра.

Пьесада автор карашларын чагылдыручы үзәк герой юк. Дөрес, зур булмаган штрихлар ярдәмендә персонажлар һәрберсе үз йөзе, үз характеры белән ачыла. Шуның белән драматург артист тормышының гомумиләштерелгән сурәтен күз алдына бастыра. Әсәр «Хушыгыз» драмасындагы караш-фикерләрнең үстерелеше, дәвам итүе булып та тора. Белгәнебезчә, әлеге пьесада кайчандыр танылган җырчы булган Миләүшәнең гомере ахырында яшәешенең мәгънәсез булуын, бәхетсезлеген, чын тормышның янәшәдән үтеп китүен аңлауга килүе һәм драматургның укучы-тамашачы белән бергә моның сәбәпләре турында уйлануы үзәктә тора. Автор концепциясендә кеше һәм җәмгыять каршылыгы, сәнгать әһеленә булган караш, рухи бай тормышның нигезен табигать һәм авыл белән бәйлелектә карау мөһим урын алып тора. Гомумән,

Миләүшәнең үз бәхетсезлеге сәбәбен җәмгыятьтән, башкалардан эзләү омтылышы өстенлек итә. Шул рәвешле, үткән гомер, яшьлек хаталары, соңарып аңлашу күренешләренә бәйле тормышчан сораулар турында уйлану, бергәләп җавап эзләү пьесаның сюжет нигезен тәшкил итә.

*Дини-рухани юнәлеш*. Әлеге төр әсәрләрнең үзәгендә, традицияләрне яңартып, көндәлек вакыйгаларның дин фәлсәфәсе белән үрелеп баруы тора. Дини тәгълимат, караш-фикерләр, гадәттә, миллилек төшенчәсе белән тыгыз бәйләнеп, билгеле бер дәрәҗәдә аның эчендә эретелеп сурәтләнә (Ф. Бәйрәмова, Ф. Яхин, А. Хәлим һ.б.). «Әдәбиятның бер канаты – дин, икенчесе – миллият»[1], – дип яза С. Хафизов. Шуңа да хәзерге татар сүз сәнгатендә гаять үзенчәлекле, яшәеш мәсьәләләрен ислам идеологиясе белән үреп аңлаткан *рухани* әдәбият мәйдан яулый бара. Дөресрәге, меңьеллык әдәбиятыбызның 1920 елларга кадәр саклanып килгән традицияләрен кайтару омтылышын күрәбез. Тәнкыйтьче Р. Фәтхрахманов хәзерге әдәби процесста гомумән ике юнәлешне генә аерып чыгара: берсе – динле-иманлы эчтәлек белән өретелгән, милләт язмышын үзәккә алып, укучының милли үзаңын үстерүне максат итеп язылган әсәрләр. Тәнкыйтьче әлеге юнәлеш тарафдарлары буларак А. Хәлим, Ф. Бәйрәмова әсәрләрен атый. Икенчесе – яшәешнең шактый җитди проблемаларын кешенең гади-гадәти теләк-омтылышларына, хәтта инстинктлары белән бәйлелектә өйрәнү. Автор мондыйларны чынбарлыкның ямьсез күренешләрен чагылдырган яисә автор идеясе ачыкланып бетмичә, нindидер «симбиоз» карашлар якланган әсәрләр дип атый (Р. Сибат, Т. Галиуллин, З. Хәким романнары)[2]. Әлеге карашлар белән тулысынча килешеп булмаса да, дини-рухани әдәбиятның үсеш-үзгәрешенә ныклы нигез салына. А. Хәлим дә әдәбиятның киләчәген иманлы сурәтләүгә йөз тотуда күрә: «Үрнәк соклану һәм сокландыруның өч алтын баганасы бар: ул – Матурлык, Батырлык һәм Иманлылык»[3].

Хәзерге әдәбият белемендә игътибар үзәгендә торган сорауларның берсе романтизмның җанлануы яисә «яңа романтизм»ның мәйданга чыгуы белән бәйле. XIII–XVI гасырларда Урта гасыр романтизмының (Көнчыгыш романтизмының) гүзәл үрнәкләрен тудырган төрки-татар әдәбияты, XIX гасыр ахырларына таба мәгърифәтчелек идеяләре белән сугарылган романтизмны да (Ф. Кәрими «Морза кызы Фатыйма») үз итә һәм XX йөз башында әдәбиятыбыз казанышы булып саналырдай Европа тибындагы романтизмга нигезләнгән әсәрләрне (Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, М. Фәйзи һ.б. иҗатын) мәйданга чыгара. 1920 елларда да ул әле үз позицияләрен шактый саклап кала (мәсәлән, М. Фәйзинең «Асылъяр», Г. Рәхимнең «Идел»ендә һ.б. әсәрләрдә). Социалистик

[1] *Хафизов С.* Әдәбиятта базар заманы // Казан утлары. 1998. № 8. Б. 156.

[2] *Фәтхрахманов Р.Г.* Татарга сатма матбугат... // Казан утлары. 2004. № 3. Б. 160–161.

[3] *Хәлим А.* Сез беләмсез кая барганны? // Казан утлары. 2005. № 1. Б. 122.

реализм романтизм төшенчәсенә каршылыклы мөнәсәбәттә була, әмма җәмгыятьне, шул исәптән кеше характерларын революцион үсештә күрсәтү омтылышы әдипләрне әлеге әдәби юнәлеш алымнарына шактый иркен мөрәҗәгать итүгә этәрә. Бу урында 1930 елларда ук хезмәт (М. Җәлил «Хат ташучы»), сугыштан соңгы елларда сугыш батырлыгының (мисал өчен, Г. Әпсәләмов романнары) романтик чагылышын искә төшерү дә җитә. Бу чорны максатчан тикшергән А.М. Кашапова болай дип яза: «Романтизмның нигез принциплары булган субъективлык, индивидуальлек, актив шәхескә дан җырлау, геройларның һәм хәл-шартларның гадәттән тыш булуы, ике катламлылык «Алтын йолдыз», «Газинур» (Г. Әпсәләмов), «Язгы җилләр» (К. Нәҗми), «Намус» (Г. Бәширов), «Саф күңел» (М. Әмир) романнарын иҗатның романтик тибы кысаларында карарга мөмкинлек бирә»[1]. Бу урында мәсьәләгә ачыклык кертик: әлеге әсәрләрдә реалистик сурәтлелек өстенлек итә, әмма романтизм элементлары киң урын алып, романтик характерлы геройлар алгы планга куелган. 1960 еллардан соңгы сүз сәнгатендә И. Юзеев, Р. Гаташ, Ф. Яруллин һ.б.ның шигырь-поэмалары, Ә. Еники, М. Маликова, М. Хуҗин һ.б.ның хикәя-повестьлары романтик сәнгати фикерләүне яңа баскычка күтәрә.

Иҗтимагый идеалларның үзгәрүе хәзерге әдәбиятта романтизмның җанлануына китерә. Әдипләрнең әлеге юнәлештәге эзләнүләрен тикшереп, И. Вәлиулла түбәндәге сыйфат-билгеләрне аерып чыгара: «Бу елларда демократик романтизм белән үрелеп туган милли романтизм безнең төп Маягыбызга әверелде. (...) Милли романтизм дигәннән, татар язмышына караучы темалар бик тиз беленде: алар – 1552 ел, ягъни Казанның алынуы темасы; башта патша империясендәге, аннан сталинизм чорындагы милли-дини изелү темасы. Милли коллыкта татар яшәешенең деградацияләнүе, татар яшьләренең маңкортлаша баруы темасы; тоталитар коммунистик система җимерелгәч, яңа милли Яңарыш – Ислам диненең кайтуы, татар теленең күтәрелүе, татарның югалган дәүләтчелеген торгызу темасы һ.б.ш.»[2]. Тәнкыйтьче фикерләренә бер ачыклык кертергә кирәк: күрсәтелгән тематик төрлелек милли романтизмга гына хас дигән фикер калмасын. Алар реалистик эстетикага нигезләнгән әсәрләрдә (М. Хәбибуллин, А. Хәлим, Ф. Латыйфи һ.б. иҗатында) дә киң чагылыш таба.

Хәзерге әдәбиятта, романтик сурәтләү үзенчәлекләре буларак, геройның, еш кына, әхлакый сайлау алдына куелуын, иҗтимагый эчтәлекнең шәхси башлангыч белән үрелеп китүен, лирик башлангычны да ят итмәвен, тойгы-кичерешләрнең фәлсәфи уйланулар белән кушылып

---

[1] *Кашапова А.М.* Романтические культы в послевоенных татарских романах (1945–1960 гг.): Препринт. Уфа: РИО БашГУ, 2005. С. 36.

[2] *Вәлиулла И.Ә.* Яңа маяклар эзләгәндә... // Казан утлары. 2004. № 8. Б. 138.

баруын һ.б.ны билгеләп үтәргә була. Мөһим сыйфат рәвешендә «романтик рухлы әдип әдәби образда, барыннан да элек, үзен күрсәтергә»[1] тиешлеге дә игътибардан читтә калмый (И. Юзеевның «Гашыйклар тавы», Р. Батулланың «Сөембикә»се, Ф. Садриевның «Кыргый алма әчесе», Ә. Сәлахның «Соңгы вальс»ы һ.б. әсәрләр).

Аманулланың романтик эчтәлекле, тирән лиризм белән сугарылган «Әле кичә генә яз иде» драмасында урта мәктәпне тәмамлаучыларның олы тормышка беренче адымнары сурәтләнә. Вакыйга-күренешләрне яшьләрнең Идел буендагы дачада мәктәпне тәмамлау көнен билгеләп үтүләренә бәйле үткәндәге хатирәләренә, бүгенге чынбарлыкка мөнәсәбәтләренә һәм киләчәк турындагы уй-хыялларына, өмет-теләкләренә нигезләнгән әңгәмә-диалоглар тәшкил итә. Әсәрдә үтәли конфликт юк. Ул бәхет, мәхәббәт, яшәү мәгънәсе кебек сорауларга мөнәсәбәттә үзара фикер бәрелешләрендә, эчке каршылыкларда бирелә. Шуңа да хәрәкәт салмак үстерелә һәм элекке сыйныфташлары Әнәс белән каршылыкта иң югары ноктасына җитә. Яшьләрнең хис-кичерешләрен бәяләү пьеса ахырында яшәү мәгънәсе турындагы бәхәстә үстерелә. Пьесада вакыйгаларның куерып китүе, билгеле инде, яшьләрнең дачага килеп җитүе белән бәйле. Алар белән яшьлек рухы, романтика, җыр-музыка, көлү-шаяруның бетмәс-төкәнмәс мизгелләре килеп керә. Яңа гына кулларына өлгергәнлек аттестаты алган яшьләрнең халәтен автор сыйныф җитәкчеләре Альберт Равилевич ясаган, әмма Иделдә йөзә алмыйча төпкә баткан уенчык корабль белән чагыштыра. Укытучының «монда бит дулкын, шуңа күрә бара алмый. Ваннада әйбәт йөзә ул» дигәненә Заһид болай дип җавап бирә: «Идел ванна түгел шул, моның ише уенчыкларны бөтереп кенә ыргыта». Укучылар да әлегә ваннада гына йөзә ала торган, пьесада символ булып килгән уенчык корабль хәлендә түгелме? Иделдә, ягъни олы тормышта алар батып калмасмы, нәрсәне үзләренә таяныч итәрләр? Яшәеш дулкын-каршылыкларын исән-имин үтә алырлармы? Гомумән, гаять катлаулы, каршылыклы зурлар тормышына бу укучылар әзерме? Пьеса әнә шул турыда уйланырга этәрә.

Әсәрдәге интрига Әлфинурның укытучысы – сыйныф җитәкчесе Альберт Равилевичка булган мәхәббәтенә бәйле үстерелә. Әлеге үзенчәлекле күренеш һәркемгә яхшы таныш. Мәктәп елларында өлкән сыйныфларда укыганда бик күпләр укытучыларын хыялында йөрткән идеал кеше буларак кабул итә, гашыйк була, әти-әнисенең, якыннарының, хәтта сыйныфташларының эш-гамәлләрен дә шуның белән чагыштыра. Ә Альберт Равилевич уналты-унҗиде яшьлек кызларның хыялында йөрткән «принц»ка бик тә туры килә. Укучыларның һәм ата-аналарның тирән хөрмәтенә лаек булган укытучының гаять үзен-

[1] *Гуляев Н.А.* Литературные направления и методы в русской и зарубежной литературе XVII–XIX веков: кн. для учителей. М.: Просвещение, 1983. С. 4.

чәлекле, серле, матур һәм бай рухи дөньясы ачыла. Тормышка романтик күз белән карауч сыйныф җитәкчесенең саф, гөнаһсыз җаны һәртөр түбәнлек-пычраклыктан өстен. Кешеләрнең икейөзлелегенә аның җаны әрни. Романтикларга хас булганча, ул һәртөр шау-шудан, ыгы-зыгыдан качарга омтыла, чынбарлыкта да ике төрле төсне – ак һәм караны гына күрә. Альберт Равилевич әлегәчә хыялы белән яши. Үзенең башкалардан аерылып торуын, аларча уйламавын, яшәмәвен дә яхшы аңлый. «Мин башка заманнан. Пыяла калпак астында дөньяга килгән борынгы динозавр мин», – ди ул Әлфинурга. Укытучы ясаган уенчык корабльләрнең исемнәре дә шуңа ишарә итә. Үзе әйткәнчә, «Зурбаган – язучы А. Грин әсәреннән, Ольвия Шекспирда бар. (...) Эльдорадо – минем кебек сакаллы сабыйлар уйлап чыгарган нәрсә – бәхетлеләр иле».

Алдагы күренешләрдә драматург үз хезмәте белән көн күрүче, олы тормышның кырыс кануннарын шактый тулы, әмма берьяклы үзләштергән Әнәснең эш-гамәлләрен алга чыгара. «Бензозаправка»да эшләүче егетнең «кумирлары» булып, билгеле инде, чит ил машиналарында йөрүче, һәрнәрсәне я акча, я көч белән генә хәл итүче, ягъни үз теләкләренә ирешү өчен һәртөр чаралардан файдаланырга әзер «хуҗалары» тора. Аның яшәү фәлсәфәсе дә шуңа нигезләнә. Дөньяны танып белергә ашкынган әлегә каршылыкларны җиңеп үтәргә әзер, шуңа да киләчәген Иделдә йөзгән ак пароход белән тәңгәлләштереп күзаллаучы Вазыйхка Әнәс болай җавап бирә: «Агымга каршы йөзәргә ярамый, көчеңне генә әрәм итәсең».

Пьесада, таң атып, яңа көн туу олы тормыш башлану кебек күзаллана. Шуңа бәйле беренче җитди каршылык тудырыла. Күңелендәге хис-кичерешләр йогынтысында олы мәхәббәткә омтылып яшәгән Аниянең хисләрен салып таптап, аны үзенеке итәргә теләп, Әнәс зурлар тормышы гадәтләрен күрсәтә. Үзеннән көчлеләрне генә танучы егет үзе аңлаган, үзе табынган «хакыйкатьне» Альберт Равилевичка әйтә. Әсәрнең кульминациясе булган әлеге күренеш өч төрле яшәү фәлсәфәсен ачык итеп аерып куя. Аңлашылганча, берсе Әнәс белән бәйле. Икенче төрле яшәү рәвешенә йөз тоткан Альберт Равилевич Әнәснең кимсетүле сүзләрен романтикларча кабул итә. Үз яшәү фәлсәфәсенә тугры калып, бу егеткә укучылары каршында физик көч кулланып (соңыннан аңлашылганча, мөмкинлеге булса да) «сабак» бирми, бәлки сүз ярдәмендә тынычландыру белән чикләнә. Ә инде элекке мәктәп укучылары әлеге вакыйганы төрлечә кабул итә. Зурлар тормышына башкаларга караганда тизрәк яраклашкан Гүзәлия Әнәсне, аннан көчлерәк һәм йогынтылырак кеше белән кисәтеп, үз урынына утырта. Ә менә Әлфинурның хыял-идеалын әлеге күренеш чәлпәрәмә китерә. Үзе илаһилаштырган кешенең явызлыкначарлыкка тиешенчә җавап бирмәвен көчсезлек дип кабул итә һәм укытучысын, үзе әйткәнчә, яшьлек илендә калдырып китә.

Драматург геройларының күңел кичерешләрен, эчке халәтләрен оста тотып алган. Укытучы һәм укучы бәхәсендә хисләр бәрелеше дә, яшәеш фәлсәфәсе дә, кеше дигән затның гаять төрле, серле, катлаулы булуын аңлау, шуның сәбәпләренә төшенү теләге дә һәм, ниһаять, үз хыялына, яшәү рәвешенә, тормыш матурлыгына тугры калган, шуның белән хөрмәт уяткан олы җанлы Укытучыны аңлау да урын алган.

Хәзерге татар әдәбиятында, яшәешнең әхлакый, социаль-иҗтимагый, милли мәсьәләләре белән бергә, чынбарлыкның аңлап һәм аңлатып бетерү мөмкин түгеллеге һәм кешенең көчсезлеге, гомеренең чиклелеге, яшәү мәгънәсе кебек фәлсәфи мәсьәләләр дә өйрәнү объекты итеп алына. Традицион алым-чараларның бер төрен кире кагу һәм яңаларга мөрәҗәгать итү, билгеле, һич тә үзмаксат түгел, бәлки тормышны тулылыгында, күптөрлелегендә, каршылыгында чагылдыруның, шуларны укучыга җиткерүнең яңа юлларын эзләү омтылышы булып тора. Чынбарлыкка бәя бирү, яшәешнең кырыс каршылыкларын һәм социаль-экзистенциаль героен ачу максатында, әсәрләрдә реаль һәм мифологик дөнья күренешләренә, архетипларга, мифологемнарга мөрәҗәгать итү күзәтелә. Югарыда без андый әсәрләрнең *модернизм* һәм *постмодернизмга* хас элементларны үз итүләрен билгеләгән идек. Хәзерге әдәбияттагы тенденция һәм стиль үзенчәлеге буларак ике төр-юнәлешне күрсәтергә мөмкин: шартлы-метафорик һәм шартлы-мифологик.

*Шартлы-метафорик юнәлеш.* Татар әдәбиятында шартлылык алымнарына мөрәҗәгать итүнең, шулай ук метафора булып килгән вакыйга-күренешләр аша автор идеясен чагылдыруның матур традициясе бар (мәсәләгә, Г. Коләхмәтов, К. Тинчурин, Х. Туфан, Ә. Баян, Р. Фәйзуллин, Зөлфәт, Т. Миңнуллин һ.б. иҗатында). Хәзерге сүз сәнгатендә метафора булып килгән яисә шартлы-символик вакыйгаларга, алым-детальләргә мөрәҗәгать итүнең гаять активлашуы күзәтелә. Әлеге алым-чараларның әдәби функциясе бермә-бер киңәеп, алар, гадәттә, җәмгыятькә бәя бирүгә, герой характерын ачуга, гомумән, төп идеяне, автор позициясен билгеләүгә хезмәт итә (Ф. Бәйрәмованың «Канатсыз акчарлаклар», «Күл балыгы», Д. Салиховның «Алла каргаган йорт»ы, З. Хәкимнең «Җүләрләр йорты», М. Кәбировның «Сары йортлар сере» һ.б. әсәрләр). Ю. Сафиуллинның «Сукбай артистлар» комедиясендә спектакль куярга район үзәгенә барырга җыенган бер төркем артистлар белән булган хәл сурәтләнә. Көчле давыл-шторм аларның автобусын Африка ярларыннан ерак булмаган бер утрауга илтеп ташлый. Шуларга бәйле автор ике яссылыктагы проблемаларны укучы-тамашачы каршына куя. Берсе – артистлар тормышы, икенчесе – Татарстанның суверенитеты мәсьәләсе. Шул рәвешле көнкүреш мәсьәләләре сәяси сораулар, бәхәсләр белән үрелеп китә. Сәхнә әдәбиятында артистлар

турындагы тормыш материалына мөрәҗәгать итү һәрвакыт кызыксыну уята. Драматург геройлары итеп исемнәре бераз үзгәртелгән, әмма танылган, күпләргә билгеле шәхесләрне ала. Әйтергә кирәк, вакыйга-күренешләрдәге эш-гамәлләрендә, портретларында, сөйләмнәрендә, башкалар биргән характеристика-сыйфатларда әлеге артистларның прототиплары ачык шәйләнә. Бер яктан, артистлар уены сурәтләү объекты булса, икенче яктан, уен алымы, ягъни артистларның дөньякүләм билгеле «Дон Кихот», «Отелло» әсәрләре геройлары булып уйнау күренешләре, үзләрен шулар хәленә куеп караулары, яисә аларның эш-гамәлен татар тормышы белән бәйләп аңлату сәнгать әһелләренең җәмгыятьтәге урынын тулырак ачарга булыша. Әсәрдә ачык күренеп торган конфликт юк. Шулай да вакыйгалар үстерелеше дөньяга карашы белән аерылып торган Шәрәф Рәшәнең башкалар белән бәхәс-каршылыгына нигезләнә. Пьесаның беренче күренешләрендә автор безне артистлар тормышының, гадәттә, тамашачыдан читтә калып килгән яклары – теләк-максатлары, рухи дөньялары, үзара мөнәсәбәтләре белән таныштыра.

Драматург көнкүреш сорауларын Татарстанның суверенитеты, татар халкы язмышы мәсьәләләре белән бәйлелектә карый. Артистларның үз тормышларыннан канәгатьсезлеге Россиядә урнашкан идарә системасыннан, бу илдә халык мәнфәгатьләренең һәрвакыт икенче планда калуыннан, рус булмаган милләтләргә кимсетеп караудан ризасызлык булып үсә. Шуңа да артистлар автобусының ирекле утрауга эләгүе һәм шунда үзара мөнәсәбәтләрне җайга салып, тыныч-тату, килешеп яшәү омтылышы – үзен суверен дәүләт дип игълан иткән Татарстанга метафора булып тора. Бер яктан, утраудагы ирекле, тыныч тормыш Россиядәге һәртөр законсызлыкка, башбаштаклыкка капма-каршы куела. Шул рәвешле мөнәсәбәтләр сәяси төсмер ала. Драматург татар җәмгыятендә мөстәкыйльлек мәсьәләсендә барган тартышны ачык күзалларга ярдәм итә. Берәүләр, Шәрәф кебек тулы мөстәкыйльлек таләп итсә, икенчеләр Россия дәүләте составында милләт мәнфәгатьләрен яклауны һәм саклауны яклап чыга, өченчеләр исә шофер Наглый кебек бернинди суверенитетны да кирәксенми. Татарстанның сәяси тормышындагы кебек үк уртадагылар фикере өстен чыга. Алар әлеге утрауны ташлап туган җиргә кайтырга булалар. Автор милләтпәрвәр Шәрәф язмышын хәл итүнең кызыклы, шул ук вакытта көтелмәгән юлын тапкан. «Россия таралса гына кайтам» дип торучы Шәрәфкә шаккатырлык яңалык әйтәләр – Россия президенты итеп Шәймиев куелган. Күргәнебезчә, көнкүреш вакыйгалары белән башланган пьеса сәяси утопиягә үсеп әверелә. Әлеге хәлләрдән соң Шәрәф тә туган иленә кайтырга була. Пьесада чынбарлык күренешләре фантастик хәлләр, хыял агышы белән үрелеп бара. Төп герой буларак вакыйгаларны бер үзәккә туплап торучы Шәрәф Рәшәнең исеме дә игътибарга лаек. Белгәнебезчә,

рәшә ул мираж, хыялдагы әйбернең күзгә күренүе. Автор герой исеменә аның хыялый булуын чыгарган һәм ул пьесаның жанры белән дә тыгыз бәйләнгән.

*Шартлы-мифологик юнәлеш.* Әлеге төр әсәрләрдә геройлар ике яссылыкта – реаль-гадәти тормышта һәм серле-сихри дөньяда яши. Автор тудырган мифологик катлам, бер яктан, халыкның ышанулары, мифологиядән килүче серле затлар белән бәйле булса, икенче яктан, ул реаль чынбарлыкны бөтен тирәнлегендә ачарга, аңларга, аңа башка яссылыкта карарга мөмкинлек бирә. Әсәрләрдә мифологик образлар, фәлсәфи трактовка алып, кеше күңелендәге Ак һәм Кара, Яхшылык һәм Явызлык көрәшен чагылдыруга хезмәт итә (Н. Гыйматдинова, М. Гыйләҗев, Г. Гыйльманов һ.б. әсәрләре мисал була ала).

М. Гыйләҗевның «Бичура» исемле пьесасында кеше күңеленең капма-каршылыклы ике ягын – өмет һәм өметсезлек, яктылык һәм караңгылык, яхшылык һәм явызлык, тугрылык һәм мәкер чагылышын тикшерү максат итеп куела. Кеше күңелендә мәңгелек көрәш бара. Үзара каршылыкта булган көчләрнең Якты ягы өстенлек алса, кешедә киләчәккә ышану, бәхеткә омтылыш баш калкыта, Караңгы ягы җиңүе исә өметсезлек, ялгызлык, яшәешнең мәгънәсезлеге булып чагыла. М. Гыйләҗев драмада Яктылык-Яхшылыкны Бичура образы аша бирә. Бичура – халык мифологиясендә йорт иясен аңлатучы мифик зат. Әлеге шартлы мифик образ реалистик күренешләр белән бәйләнештә тасвирлана.

Бичурасыз 70 ел яшәгән Аксак, ниһаять, үз асылына кайта һәм Кара җаннарның күңелендәге куркаклык, битарафлык кебек начар сыйфатлар чагылышы булуын тирәнрәк аңлый бара. Мифик затның икенче функциясе – кеше күңелендә киләчәккә өмет, ышаныч, шатлык хисләрен торгызу – ачыклана. Шуңа да Аксак йорт нигезен генә саклап калмый, ә хуҗалыгын ныгыту буенча эш башлый: ат сатып ала, йортын да яңартырга уйлый.

Яшәешнең мөһим мәсьәләләре турында уйлана башлаган карт үзгәрешләрнең башкаларда да булуын тели. Әсәрдә метафора булып килгән кызыклы күренеш бар. Күршесе хуҗасы булмаган, адашып калган сарык табып кайта һәм, чалгы алып, печән әзерләргә керешә. Әмма әлеге эш-гамәле күңел, җан үзгәрешләренә китерми. Аксак никадәр генә ялынып сораса да, Күрше аның Бичурасы белән очрашырга теләми. Бераздан исә сарыгы да качып китә. Сәбәбе, ди автор, Күршенең читтән килгән булуында. Үз бәхетен, чын яшәешне кеше җаны-тәне белән үзе яшәгән җирне ratканда, шунда хезмәт иткәндә генә таба. Яңа тормышка чыгу өчен Кара җаннардан – рухыбызны кысып торучы идеология сөременнән, куркаклыктан, мескенлектән котылырга кирәк.

Пьесада Аксак реаль тормыштан мифологик дөньяга, һәм киресенчә, җиңел күчеп йөри. Бичура дөньясында ул Кара җаннарның

капка-койманы, сарайны җимерүләрен күрә. Баксаң, реаль тормышта инде алар күптәннән шундый хәлдә икән, әмма ул аларны «күрмәгән», акылы белән кабул итмәгән. Хәзер инде Аксакның идеология йогынтысында кешенең мескен хәлгә төшүен, коллык, куркаклык, булган белән канәгатьләнү яисә газапларга түзеп, матур киләчәкне көтеп яшәү психологиясе белән яшәвен аңлавы, аның әйләнә-тирәсенә башка күз белән каравына китерә.

Әмма шатланырга иртә әле. Бичура урынына чормага менеп утырган Аксакны төшерәм дип, Күрше, чорманы ишеп, йортны түбәсез калдыра. Аксакның Бичура вазифасын башкара алмавын автор символик формада күрсәтә. Хәзер инде ул күңелендәге өметне җуйган, һәрнәрсәгә битараф карт. Күрше карчыгы Хәмдиягә җиде улының, иренең сугышта үлеп калуын, җиде бәбкә белән ата казы да булмавын әйтеп, аның күңелендәге соңгы өметне сүндерә. Пьеса ахырында шулай да бер якты сызык килеп керә. Күрше үзенең Бичура белән очрашуы турында Аксакка әйтә. Бу – аның күңелендә үзгәрешләр башлану билгесе.

Шулай итеп, җәмгыятьтәге үзгәрешләр традицион реализм һәм романтизмның тармакланып үсеп китүенә, эзләнүләрнең тирәнәюенә, баюына китерә. Әлеге үзгәрешләрне ачу-аңлатуда төрлелек хөкем сөрә. Фәнни нигездә аңлату максатында әдәби барыш яисә аерым әдип иҗатын юнәлеш-агымнарга мөнәсәбәтле ачыклау омтылышлары ясала. Социалистик реализмнан соңгы әдәбиятны без «яңа реализм», «яңа романтизм» дип атау ягында. Әдипнең язу стиленә, әсәрләренең темасына, төп пафосына, шәхес концепциясенә, төп идеягә һ.б.га нисбәтле «яңа реализм»ның түбәндәге юнәлешләре (тенденцияләре) күзәтелә: тәнкыйди, милли, интеллектуаль, психологик, тормыш-көнкүреш, лирик-эмоциональ, сентименталь, дини-рухани. Иҗтимагый идеалларның үзгәрүе нәтиҗәсендә җанланып киткән «яңа романтизм»га хас үзенчәлекләр буларак геройның, еш кына, әхлакый сайлау алдына куелуы, иҗтимагый эчтәлекнең шәхси башлангыч белән үрелеп китүе, лирик башлангычны да ят итмәве, тойгы-кичерешләрнең фәлсәфи уйланулар белән кушылып баруы һ.б. билгеләнә.

Хәзерге татар әдәбиятында чынбарлыкны аңлап һәм аңлатып бетерү мөмкин булмавы, кешенең көчсезлеге, гомеренең чиклелеге, яшәү мәгънәсен шик астына алуы кебек мәсьәләләр чагылыш табып, яшәешнең кырыс каршылыкларын һәм социаль-экзистенциаль героен ачу максатында, реаль һәм мифологик дөнья күренешләренә, архетипларга, мифологемнарга мөрәҗәгать итү күзәтелә. Модернизм һәм постмодернизмга хас сурәтләү чараларын, алымнарын үз иткән мондый әсәрләрнең аеруча шартлы-метафорик һәм шартлы-мифологик юнәлешләре киң чагылыш таба.

### *2.4.2. Әдәби жанрлар трансформациясе турында (трагедия мисалында)*

Әдәбият белемендә мөһим категорияләрнең берсе булган жанр төшенчәсен аңлатуда әлегәчә төрлелек саклана. А.Ю. Большакова язганча, «әдәбият белеме категорияләренең берсе дә жанр кебек кызу бәхәсләр кузгатмавы ачык билгеле. Әмма башка бер генә категориянең дә шундый ук нәтиҗәле булмавы да яхшы билгеле»[1]. Моның сәбәпләре арасында, бер яктан, җәмгыятьтәге үзгәрешләргә бәйле даими рәвештә «яңа жанрлар туу, искеләре төшеп калуны»[2], икенче яктан, аерым жанрларның яңа сыйфатлар белән баюы, вазифалары үзгәрү күзәтелүен, өченче яктан, сүз сәнгатенең һәр чоры (бигрәк тә күчеш чорлары) үзенә хас жанрлар системасы булдыруын, дүртенчедән, аерым әсәрләрнең моңа кадәр билгеле булган теоретик аңлатмага туры килмәвен, бишенчедән, әдәбият кебек автор индивидуальлеге ачык чагылган иҗатта һәр язучының гомумилеккә таянган хәлдә, жанрларга үзенең иҗат үзенчәлеген өстәргә омтылуын һ.б.ны билгеләп үтәргә мөмкин. Әлеге катлаулы мәсьәләгә, әдәбият белемендә кат-кат күрсәтелгәнчә, тарихи планда якын килү сорала, чөнки «хәзерге әдәбият теориясенең нигезе булып һәртөр әдәби күренешләрнең тарихилыгы төшенчәсен һәм, нәтиҗә буларак, алар яшәешенең конкрет кабатланмаслыгын саный алабыз»[3]. Аңлашылганча, жанрлар әдәбиятның закончалыклы күренеше буларак барлыкка килә һәм даими үсеп-үзгәреп тора. Шул ук вакытта, аларны аңлау-аңлатуда каршылыклы фикерләр әйтелеп, кайбер галимнәрнең «жанр юкка чыга» дип раславын, икенчеләренең аны «мәктәп» яисә «юнәлеш» кебек категорияләрдән әһәмиятлерәк дип санавын да онытмаска кирәк[4]. Без әлеге мәсьәләне бөтен тулылыгында ачуны максат итеп куймыйча, жанрның эчке сыйфаты, аны бәяләүгә һәм шәрехләүгә килү юллары турындагы фикер-карашларны (еш кына каршылыклы, бәхәсле булуын белгән хәлдә) аерым бер жанр мисалында күзәтү омтылышы ясыйбыз.

Билгеле булганча, тормыш-чынбарлыкны чагылдыруның гомуми принциплары әдәби төрләр (эпос, лирика, драма) рәвешендә билгеләнеп, алар, үз чиратында, жанрларда һәм жанр формаларында чагылыш таба. Сүз сәнгатенең төрләргә һәм жанрларга бүленеше тарихи үсеш нәтиҗәсе булып санала һәм әдәбият белемендә ул шактый тулы өйрә-

[1] *Большакова А.Ю.* Современные теории жанра в англо-американском литературоведении // Теория литературы. Т. III. Роды и жанры (Основные проблемы в историческом освещении). М.: ИМЛИ им. М. Горького РАН, 2003. С. 99.

[2] Әдәбият белеме сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. Б. 53.

[3] Теория литературы. Т. III. Роды и жанры (основные проблемы в историческом освещении). М.: ИМЛИ им. М. Горького РАН, 2003. С. 4.

[4] Бу турыда тулырак мәгълүмат: *Большакова А.Ю.* Современные теории жанра в англо-американском литературоведении // Теория литературы. Т. III. Роды и жанры (основные проблемы в историческом освещении). М.: ИМЛИ РАН, 2003. С. 99–132.

нелгән[1]. Методологик һәм фәнни-теоретик планда төр төшенчәсен ачыклауга бәйле аеруча мөһим концепцияләр арасында, беренче чиратта, борынгы чорларда ук төрләрдә әдәби эчтәлек чагыла дип аңлау урын алуын күрсәтеп үтәргә кирәк. Аристотель үзенең «Поэтика»сында, поэзиянең өч төре буларак, эпос, лирика, драманы аерып чыгара һәм аларны сөйләүченең әсәрдәге вакыйгаларга мөнәсәбәте типлары буларак бәяли[2]. Төрләр төшенчәсенә мөнәсәбәттә җитди алгарыш романтизм эстетикасы белән бәйле. Бу чорда аларны әдәби эчтәлекнең типлары итеп карау өстенлек ала. Аерым алганда, Ф.В. Шеллинг «Философия искусства»[3] хезмәтендә лириканы – субъектив төр, эпосны – объективлыкка өстенлек бирүче, ә драманы – алдагы ике төрнең синтезы, ягъни субъективлыкның объектив чагылышы рәвешендә карый. Әдәбиятка әлеге карашның субъектив һәм абстракт булуына карамастан, нәкъ менә Шеллинг әдәби төрләрне тикшерү барышында беренче тапкыр субъект һәм объект фәлсәфи категорияләрен аерып чыгара, шулай ук драманы катнаш төр буларак характерлый. Әдәби төрләрне аерып чыгаруда Гегель тәкъдим иткән концепция яңа эзләнүләрнең нигезенә ята. Атаклы немец фәлсәфәчесе сүз сәнгатенә хас әдәби төрләрне танып белүнең объекты һәм субъекты буларак карау белән бергә, танып белү предметларына тулы характеристика бирә[4].

Алдагы чорларда әдәби төрләрне өйрәнү рус һәм Көнбатыш Европа әдәбият белемендә шактый активлашып китсә дә, Гегель карашларын үстереп, аны яңа эчтәлек-төсмерләр белән баетучы буларак В.Г. Белинскийның эшчәнлеген аерып чыгару кабул ителгән. Танылган тәнкыйтьче, теоретик сорауларга да актив кушылып, әдәби төрләрне чынбарлыкны чагылдыру ягыннан (объектив яисә субъектив) бәяли һәм аларның (бигрәк тә эпос белән лириканың) мөһим сыйфат-билгеләрен нигезли. Шул рәвешле, әдәби төрләрне аңлатуда ике концепция барлыкка килә: берсе, Платон һәм Аристотель хезмәтләренә барып тоташканы, әдәби төрне әдәби әсәрне оештыруның сөйләм тибы буларак карауга, икенчесе, Гегель, Белинский һ.б. эшчәнлеге белән бәйле булып,

---

[1] *Веселовский А.Н.* Историческая поэтика. М.: Высшая школа, 1989. 404 с.; *Хализев В.Е.* Драма как род литературы (поэтика, генезис, функционирование). М.: Изд-во МГУ, 1986. 260 с.; *Тамарченко Н.Д.* Методологические проблемы теории рода и жанра в поэтике XX века // Теория литературы. Т. III. Роды и жанры (основные проблемы в историческом освещении). М.: ИМЛИ РАН, 2003. С. 81–98; Теория литературы: учеб. пособие для студ.филол. фак. высш. учеб. зав.: в 2 т. Т. 1: Н.Д. Тамарченко, В.И. Тюпа, С.Н. Бройтман. Теория художественного дискурса. Теоретическая поэтика. М.: Академия, 2004. С. 361–442 һ.б.

[2] *Аристотель.* Сочинения: В 4-х т. Т. 4. М.: Мысль. 1983. С. 648.

[3] *Шеллинг Ф.В.* Философия искусства / под общ. ред. М.Ф. Овсянникова; пер.с нем. П.С. Попова. М.: Мысль, 1999. С. 345, 351, 398–400.

[4] *Гегель Г.В.Ф.* Эстетика : перевод с нем.. М.: Искусство, 1971. Т. 3: Лекции по эстетике . 1971 .С. 419–421.

чынбарлыкны объективлык һәм субъективлык төшенчәләре аша чагылдыруга кайтып кала. В.Е. Хализев фикеренчә, ике концепция дә яңа тикшеренүләргә җирлек бирә. Шулай да әдәби төрләрне сөйләм типлары аша аңлату, бәяләү киңрәк кулланылыш таба[1].

Әдәби төрләр, үз чиратында, поэтик структураның тотрыклы типларына – жанрларга бүленә. Әлеге төшенчәгә Ю.Б. Борев мондый билгеләмә бирә: «Жанр – әдәби текстларның зур төркемнәрен берләштерүче һәм жанрны формалаштыручы түбәндәге дүрт төрле фактор белән билгеләнүче әдәби әсәр тибы: тема; авторның карашы һәм мөнәсәбәте; әдәби әсәр темасының нигезендә ятучы тормыш материалының эстетик үзенчәлекләре; ныклы традицияләре булу һәм аларны дәвам итү»[2]. Әлеге сыйфатлар арасында галим өченчесен аерып куя, чөнки нәкъ менә эстетик үзенчәлек буларак автор эмоциональлеге чагылышы (бөеклек, фаҗигалелек, сентиментальлек, геройлык һ.б.) жанр табигатен билгеләүдә нигез булып тора. Әдәби әсәрнең аеруча әһәмиятле сыйфатлары, шулай ук гомуми һәм кабатланып килүче структур билгеләре бигрәк тә жанрда ачыклана. Танылган галим М.М. Бахтин болай дип яза: «Жанрлар аеруча әһәмиятле урын алып тора. Жанрларда (әдәби һәм сөйләм) гасырлар дәвамында дөньяның аерым якларын күрү һәм аңлау формалары туплана»[3]. Югарыда әйтелгәнчә, жанр – тарихи барлыкка килүче һәм үзгәреп торучы төшенчә. Дөнья әдәбияты тарихында озак вакытлар дәвамында урын алган аерым жанр төрләре вакытлар үтү белән төшеп кала (мистерия, эпопея һ.б.), икенчеләре исә чор үзенчәлекләренә бәйле барлыкка килә (эссе, «фэнтези», бәян һ.б.). Киң тарихи планда караганда әлеге үзенчәлек аеруча ачык күренә. Урта гасыр татар әдәбиятында киң чагылыш тапкан лирик жанрларның (мәдхия, мәрсия, касыйдә, фәрд һ.б.) күбесе хәзерге сүз сәнгатендә кулланылмый диярлек. Ә инде Шәрык традицияләрен яңарту рәвешендә аерым авторлар иҗатында урын алган жанр төрләренең (мисал өчен, Р. Гаташта робагый жанры) эчтәлеге шактый үзгәреш кичерә.

Теге яки бу әдәби төргә караган жанрлар системасын (классификациясен) булдыру кыен һәм каршылыклы эш. В.Е. Хализев билгеләп үткәнчә, жанрлар шактый күп, шуның өстенә төрле халыклар әдәбиятында үзләренә генә хас булганнары да байтак; аерым жанрлар борынгыдан бирле кулланылып килсә, икенчеләре аерым әдәби чорларда гына барлыкка килә; моңа жанр сыйфатларының үзгәреш кичерүен дә өстәргә кирәк. Әдәбият белемендә тагын ике үзенчәлек аерып карала: берсе – кулланылыштагы терминнар белән әсәрнең төрле яклары билгеләнү (мисал өчен, «трагедия» термины автор эмоциональлегеннән – өстенлек

[1] *Хализев В.Е.* Драма как род литературы (поэтика, генезис, функционирование). М.: Изд-во МГУ, 1986. С. 22–38.

[2] *Борев Ю.Б.* Жанр // Словарь литературоведческих терминов. М., 1998. С. 345.

[3] *Бахтин М.М.* Эстетика словесного творчества. М.: Искусство, 1979. С. 332.

иткән пафостан чыгып куелган булса, «повесть» төшенчәсе хикәяләп язу дигәнгә бәйләп аңлатыла); икенчесе – авторларның әсәр жанрын үзләре теләгәнчә, еш кына ашыгып куюы белән бәйле[1]. (Соңгысына мисал булып З. Хәкимнең «Чапты атым Казанга»ны, жанрын атамыйча, «ике пәрдәле пьеса» дип билгеләве тора.) Әсәр жанрын билгеләгәндә мондый каршылыклар очраса да, күп очракта жанр төре автор позициясен, ул яклаган, укучысына тәкъдим иткән концепциясен аңларга нигез булып тора. Гомумән, жанр – әдәбиятның үсеп-үзгәреп тору процессында күчемлелекне һәм шул ук вакытта тотрыклылыкны аңлата торган төшенчә. Шуңа да ул даими үзгәреп, яңарып тора һәм, үз чиратында, жанрлар арасындагы мөнәсәбәткә дә йогынты ясый.

Әдәби төр һәм жанр турындагы теоретик төшенчәләргә таянып, хәзерге татар әдәбият белемендә әсәрләрнең жанр табигатен ачуаңлатуда урын алган фикер-карашларны драматургиянең трагедия жанрына нисбәтле күзәтеп үтик.

Драма әсәрләренең жанрларын һәм жанр формаларын билгеләү мәсьәләсе әдәбият белемендә даими бәхәсләр тудыра. Билгеле инде, гаять катлаулы һәм күптөрле булган тормыш-чынбарлыкны аерым термин һәм төшенчәләргә сыйдырып бетереп булмый. «Кызганыч ки, хәзергә жанр процессының бөтен картинасын чагылдырган, субъективлыктан арынган һәм бәхәсләргә урын калдырмаган бер генә классификация дә юк», – дип яза С.Г. Гончарова-Грабовская[2]. Шул ук вакытта, драматургия жанрларын билгеләү мәсьәләсенең борынгы грек философы Аристотель хезмәтләреннән алып өйрәнелүен һәм төр-жанрларның төп сыйфатлары шактый тулы ачыклануын әйтеп үтәргә кирәк. Жанр һәм жанр формаларын билгеләүдә нәрсәне нигез итеп алырга соң? Монда да төрлелек күзәтелә, шулай да нигез төшенчәләрне аерып чыгару омтылышлары бар. «Драматургик жанрларның эчтәлек нигезе булып эмоциональ юнәлешнең өстенлекле, доминанта тибы яисә проблематика тибы тора, ул исә һәрбер әсәрнең жанрын билгеләүдә типологик төп нигез билге булып санала»[3]. Әлеге үзенчәлек «трагедия» жанрына да карый.

Билгеле булганча, трагедия – персонажларның трагик каршылыгына нигезләнгән һәм, гадәттә, фаҗига белән тәмамлана торган драматик жанр. Ул тормыштагы соң чиккәчә китереп җиткерелгән тирән конфликтны тасвирлый. Гуманистик идеаллар хакына көрәшүче герой, көчле рухи тетрәнүләргә һәм газаплануларга карамастан, үзеннән олырак көчләрне (табигать стихиясе, язмыш, власть яки башка кеше теләге һ.б.) җиңеп

[1] *Хализев В.Е.* Теория литературы: учеб. 2-е изд. М.: Высш. шк., 2000. С. 319–320.

[2] *Гончарова-Грабовская С.Г.* Комедия в русской драматургии конца XX – начала XXI века: учеб. пособие. М.: Флинта: Наука, 2006. С. 64.

[3] *Эсалнек А.Я.* Основы литературоведения. Анализ художественного произведения: практикум. 2-е изд. М.: Флинта: Наука, 2004. С. 158.

чыга алмый. Үзенең көчсез булуын, үлем алдында торуын белгәндә дә, трагедия герое социаль һәм милли тигезлек, ирек һәм дөреслек, Ватан азатлыгы һәм шәхси мәхәббәте өчен көрәшә һәм шуның белән соклану, горурлану хисе уята. Гадәттә, герой үлеме кеше шәхесен югалту буларак кабул ителсә дә, ул яклаган фикер-карашларның, идеалларның җиңүенә ышану һәм герой тормышының кешелек җәмгыятендә дәвам итү идеясе шатлык-куану мотивы тудыра. Ю.Б. Борев билгеләгәнчә, кайгы-борчудан шатлыкка күчү трагизмның бөек сере булып тора[1]. Трагик чишелеш укучы-тамашачы күңелендә курку, газаплану хисләре уятып, аны катарсиска китерә. Әлеге жанрның үзенә хас поэтик чаралары булып гадәттә үткән тарихка бәйле җитди тема алыну, монологларның күп булуы, еш кына тезмә формада язылу, күтәренке купшы стильнең фаҗигалелек пафосы белән үрелеп баруы һ.б. тора.

Борынгы Грециядә барлыкка килгән трагедия төрле дәверләрнең иҗтимагый-тарихи үсеш үзенчәлекләренә, кешелек җәмгыятенең рухи хәленә һәм иҗатчы индивидуальлегенә бәйле үсеш-үзгәреш кичерә, аерым сыйфат-күренешләр белән баеый. Ул конфликтның аерым билгеләренә дә, гомумкешелек кыйммәтләренә нигезләнгән фәлсәфи эчтәлеккә дә, герой характерына да һ.б.га нигезләнә. Мисал өчен, борынгы грек трагедияләрендә (Эсхил, Софокл) кеше ирегенең бөеклеге гомумкешелек кыйммәте дәрәҗәсенә күтәрелә һәм шуның белән алар гасырлар дәвамында искерми торган яңгырашка ия. Яңарыш чорындагы Шекспир трагедияләрендә кеше акылына дан җырлана, олы шәхеснең, герой-гуманистның явызлык дөньясы белән бәрелеше үзәккә куела. Классицизм чоры драматурглары (Расин, Корнель, Вольтер) борынгы чор әсәрләрен үрнәк итеп ала һәм аларның рационалистик драматургиясе композицион төзеклек, төгәлләнгәнлек белән бергә, хискә караганда, бурычка бәйле җаваплылыкны югары күтәрә. «Чынбарлыкны бөтенлекле сурәтләү аны бүлгәләү белән алышына, кеше тормышының аерым өлкәләренә поэтик жанрлар баскычының билгеле бер басмасы туры килә: конкрет, көндәлек, гадәти тормыш «түбән» жанрларга – комедия һәм сатирага бирелә; тарихи вакыйгалар, бөек шәхесләрнең эш-гамәле, фаҗигале хәлләр «югары» жанрга – трагедиягә туры килә»[2]. XVIII–XIX гасыр башында романтизм эстетикасына нигезләнгән трагедияләрдә (Шиллер, Гете, Гюго әсәрләрендә) рационализм үз урынын шәхси кичерешләр байлыгына, хис-тойгылар каршылыгына бирә. Рус әдәбиятында классицизм чорында барлыкка килгән трагедия жанры да иҗтимагый һәм мәдәни шартлар йогынтысында үсеш-үзгәреш кичерә.

---

[1] *Борев Ю.Б.* Эстетика. М.: Изд-во полит-й лит-ры, 1969. С. 70.

[2] *Большаков В.П.* Классицистическая теория жанров и ее преодоление // Теория литературы. Т. III. Роды и жанры (Основные проблемы в историческом освещении). М.: ИМЛИ РАН, 2003. С. 19.

Татар әдәбиятында драматургия шактый соңарып, XIX гасырның соңгы чирегендә генә мәйданга килә. Әмма иҗтимагый-мәдәни тормыштагы Яңарыш шартларында ул тизләтелгән үсеш кичерә һәм XX гасырның 10 нчы елларына, драма һәм комедия жанрларының уңышлы үрнәкләренә таянган әдәби төр буларак, формалашып җитә. Бу чорда татар әдәбияты, мәгърифәтчелек реализмы белән бергә, тормыш-чынбарлыкны тәнкыйди реализмга хас әдәби-эстетик күзаллауларга нигезләнеп чагылдыра башлый. Эзләнүләрнең тагын бер юнәлеше исә урта гасырлардан килүче үзенчәлекле романтик сурәтләү урынына Европа тибындагы романтизмга күчә бару белән бәйле. Татар сүз сәнгатендә трагедия жанрының беренче үрнәкләре дә нәкъ шундый шартларда языла. Әлеге жанрның асылын билгеләгән сыйфатларны һәм милли үзенчәлекләрне шул чор белән тыгыз бәйләнештә карау кирәк. XX йөз башы – татар халкы тормышында гаять әһәмиятле чор. XIX гасырның икенче яртысында башланып киткән мәгърифәтчелек хәрәкәте һәм аның яңа баскычы булган җәдитчелек, халык тормышының бөтен өлкәләренә үтеп кереп, җитди үзгәрешләргә юл ача. Бу аеруча мәгариф системасын үзгәртеп коруда, ягъни мәктәп-мәдрәсәләрдә дөньяви фәннәр укыта башлауда, ислам динен реформалаштыруда, ягъни аны заманга яраклаштыруда; язма татар телен җанлы сөйләм теленә якынайтуда, китап бастыру һәм тарату эшен җайга салуда, вакытлы матбугат булдыруда һ.б.да чагылыш таба. Болар янында тагын бер җитди күренеш калкып чыга: бу – милләт буларак формалашу процессы кичергән татар халкының сәяси партияләр төзеп («Иттифак» һ.б.), парламент юлы белән үз хокуклары өчен көрәшкә чыгуы. Әлеге һәм башка төрле чаралар, эшчәнлек халыкта милли үзаң үсүгә, аның үз тарихы, мәдәнияте белән кызыксынуга, рус-татар мөнәсәбәтләре турында уйлануга китерә.

Россия тарихында кан-яшь белән язылган күренешләрнең берсе – мөселман халыкларын, беренче чиратта татарларны көчләп чукындыру белән бәйле. Татар драматургиясе тарихындагы беренче трагедия әнә шул вакыйгаларга мөнәсәбәтле языла. Г. Исхакыйның «Зөләйха» пьесасында (1912) шәхес, гаилә трагедиясе милләт фаҗигасе буларак ачыла. «Трагедиянең төп герое тирәсендәге башка персонажлар, аларның аянычлы хәлләре, гасырдан-гасырга күчеп килә торган милли каршылык белән бәйле булып, әсәрнең финалы фаҗига белән бетә»[1]. Эстетик аспектта алгы планга кыюлык-батырлыктан бигрәк, әрнү һәм газаплану чыга. Гадәттән тыш рухи көчкә ия булган Зөләйха кичерешләрен укучы-тамашачының үзенеке итеп кабул итүе җан-рух хәрәкәтенә китерә, фаҗигале шәхескә соклану, хөрмәт хисе уята.

Ф. Борнашның «Таһир-Зөһрә» трагедиясендә (1918) чагылыш тапкан шәхеснең рухи азатлыгы һәм социаль-иҗтимагый идеалларның

[1] *Җәләлиева М.Ш.* Әдәбиятта тойгы катламнары. Казан: Мәгариф, 2005. Б. 104.

яклануы инкыйлаблар чорына аваздаш була. Уңай идеаллар белән яшәүче Таһир мәхәббәте хакына хан власте белән үтеп чыга алмаслык каршылыкка керә һәм һәлак була. «Кеше, иң югары кыйммәт буларак, кешеләр өчен яшәгән һәм иҗтимагый мәнфәгатьләр яшәвенең мәгънәсе булган урында гына шәхес үлеме трагик яңгыраш ала»[1]. Таһирның һәм сөйгәнен югалткан Зөһрәнең үлеме укучы-тамашачыга гаять көчле тәэсир итеп, шәхес иреге, саф мәхәббәт, тигезлек, гаделлек төшенчәләренең мәңгелек булуы турында уйлануларга этәрә.

Совет чоры татар әдәбиятында трагедия жанры акрын темплар белән үсә. Халык тарихы гаять фаҗигале булуга, Россия составында тарих каршылыкларының бөтен авырлыгын үз җилкәсендә татуга, XX гасырда гына да өч инкыйлаб, гражданнар һәм Бөек Ватан сугышлары, коллективлаштыру, репрессияләр кебек коточкыч хәлләрне кичерүгә карамастан, әлеге жанр яшәп килгән система таләпләреннән читтәрәк кала. Моның төп сәбәбе – әдәбиятның социалистик реализм кысаларында булуы, идеологик нормаларга буйсындырылуы. Һәрхәлдә, эстетик категория буларак трагизмны, бигрәк тә совет кешесе фаҗигасен сурәтләү гайре табигый хәл буларак кабул ителә. Шулай да талантлы каләм ияләре элеге жанрның сүнеп-бетеп калуына юл куймыйлар. Һ. Такташның «Җир уллары трагедиясе» (1922), К. Тинчуринның «Зар» (1923), Н. Исәнбәтнең «Спартак» (1939), «Идегәй» 1941), «Муса Җәлил» (1955), Н. Фәттахның «Кол Гали» (1973), Ә. Баянның «Алтын кашбау» (1974), И. Юзеевның «Соңгы сынау» (1968 ), «Мәңгелек белән очрашу» (1982), «Очты дөнья читлегеннән» (1980–1991) кебек әсәрләре сәхнә әдәбияты тарихында билгеле бер эз калдыра.

XX гасыр ахырында татар драматургиясендә трагедия жанры активлашып китә. «Соңгы елларда буа ерылды. Татар драматургиясенең бөтен тарихына караганда да күбрәк язылып, дистәгә якын әйбәт трагедияләр иҗат ителде»[2], – дип яза А. Әхмәдуллин. Җәмгыятьтәге үзгәрешләргә бәйле рәвештә драматургларның игътибары, бер яктан, үткән тарихның каршылыклы һәм гыйбрәтле якларына, танылган шәхесләрнең фаҗигале язмышына юнәлсә, икенче яктан, үзгәртеп корулар китереп чыгарган тормыш катаклизмнарын, «кыргый» капитализм шартлары тудырган шәхес фаҗигаләрен сурәтләүгә объектына юнәлтелә. Әлеге һәм башка мәсьәләләрне трагедия жанры кысаларында уңышлы чагылдырган әсәрләр рәтендә түбәндәгеләр бар: А. Гыйләҗевның «Өч аршын җир» (1987), Р. Хәмиднең «Актамырлар иле (1990), «Хан кызы» (1995), Ю. Сафиуллинның «Идегәй» (1994), «Йөзек һәм хәнҗәр» (1998),

---

[1] *Борев Ю.Б.* Эстетика. М.: Изд-во полит-й лит-ры, 1969. С. 75.

[2] *Әхмәдуллин А.Г.* Эзләнүләр дәвам итәме, алар бәрәкәтлеме? // Офыклар киңәйгәндә. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. Б. 23.

З. Хәкимнең «Шайтан куентыгы» (1999), М. Маликованың «Сөембикә» (2002) һ.б.

Әсәрләрдә, жанрның үткәндәге традицияләренә таяну белән бергә, җәмгыятьтәге үзгәрешләргә бәйле тарих-заман-шәхес проблемасын яңа иҗтимагый-эстетик планда ачу, шул максаттан форма-алымнар, сурәт чаралары байлыгыннан файдалануның яңа юлларын эзләү бара. Югарыда саналган пьесаларда трагик шәхес концепциясе чагылыш тапса да, аның бирелеш һәм чишелеш юллары бертөрле генә бәяләнми. Хәзерге рус драматургиясенең бер үзенчәлеген билгеләп, М.И. Громова болай дип яза: «Эстетик категория буларак фаҗигалелек күптөрле формаларда – тарихи һәм үткән әдәбият сюжетларын "эшкәрткән" пьесаларда, легенда һәм мифларны заманча шәрехләүдә урын алса да, "чиста" трагедияләр "традицион" сирәк»[1]. Әлеге күренеш белән татар сәхнә әдәбиятында да очрашабыз. Ерактагы тарихка мөрәҗәгать иткән пьесаларда тиранга каршы көрәш идеясе милли характер тудыру омтылышы, гомумән, милләт каршындагы җаваплылык идеясе белән кушылып китә.

А. Гыйләҗевның якындагы тарихыбызга мөрәҗәгать итеп язылган «Өч аршын җир» трагедиясендә заман каршылыкларында адашып калган, соңрак үз асылына кайта алмыйча газапланган Мирвәли һәм аның хатыны Шәмсегаян язмышы сурәтләнә. Әсәрне жанр үзенчәлеге ноктасыннан тикшергән А. Әхмәдуллин болай дип яза: «Авторның төп максаты: җиренә, авылына һәм авылдашларына хыянәт иткән кешенең фаҗигале язмышын күрсәтеп бирү. Моңа ирешү өчен ул әсәрнең гомум тәэсир көчен арттыруны беренче планга куя»[2]. Социаль-психологик эчтәлекле әсәрдә геройларның катлаулы, фаҗигале рухи дөньясы ачыла. Мирвәли образы татар сәхнә әдәбиятына яңалык алып килә. Ул моңа кадәр урын алган шәхес концепциясенә сыймый, чөнки ул совет чоры әдәбияты яклаган һәм мактаган уңай герой тибы түгел. Киресенчә, Мирвәли – колхозлашу чорының аяусыз, кешелексез кануннарын кабул итә алмыйча, туган җирен, авылдашларын каргап, йортына ут төртеп чыгып киткән һәм шуның белән үзен дә, хатынын да гомерлек хәсрәткә, борчуга салган фаҗигале шәхес. Авторның табышы шунда, ул Мирвәлине бөтен күзәнәкләренә кадәр аңлый, шуңа да укучы-тамашачы каршында туры сызык буенча хәрәкәт итүче түгел, бәлки җан газаплары кичерүче, артык горур, кызу табигатьле, көчле, шул ук вакытта чын хакыйкатьне, ягъни хаксызлыгын башкалардан гына түгел, хәтта үзеннән дә яшерергә омтылучы герой гәүдәләнә. Әлеге җан бәргәләнүләреннән котыла алмаган Мирвәли, бик соңарып, туган туфрактагы өч аршын җирнең

[1] *Громова М.И.* Русская драматургия конца XX – начала XXI века: учеб. пособие. 2-е изд., испр. М.: Флинта: Наука, 2006. С. 361.

[2] *Әхмәдуллин А.Г.* Яңалыкка омтылып // Дөреслеккә ирешү юлында. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. Б. 82.

кыйммәтен аңлауга килә. Бу исә күңелендәге үкенечне, зур, олы тормышның янәшәдән үтеп китүен тоемлауны тагы да тирәнәйтә, нечкәртә. Шуңа да авылдашларының хатынына булган олы хөрмәтен, үзен гафу итүләрен, кешелекле мөнәсәбәтләрен аның яралы йөрәге күтәрә алмый.

Мирвәли белән Шәмсегаянның үзара мөнәсәбәтләрен, бер-берсенә мәхәббәтен сурәтләүдә дә драматург яңа юлдан бара. Яшь чакта берберсенә гашыйк булуларын, егетнең кызны осталыгы, кыюлыгы, көче белән көрәшеп алуын белгән укучы-тамашачы аларның мәхәббәтенә шикләнми. Әмма... Мирвәли бит Шәмсегаянның чит җирдә тилмереп, сагынып-саргаеп яшәвен күрә. Яраткан кешеңне шундый газапларга салуны ничек бәяләргә? Тирә-якта матурлыгы, хезмәт яратуы, булдыклылыгы белән танылган Шәмсегаян читтә үзен гомерлек бәхетсезлеккә дучар итә. Җан мәхәббәте генә түгел, тән мәхәббәте дә булмаган ир белән хатын мөнәсәбәтен ничек аңларга? Моны Шәмсегаянның миллилеге, татар хатынына хас сабырлыгы, түземлеге, ирен ир итеп яшәве, үз язмышын яшь вакытта сайлаган кешегә бәйләп каравы белән генә аңлатып була. Шул рәвешле, Мирвәли һәм Шәмсегаян язмышы үз җирләреннән китеп, читтә – ят мәдәни-рухи мохиттә яшәүче меңнәрчә милләттәшләребезнең ачы язмышы чагылышы булып тора.

Алтын Урда таркалганнан соң барлыкка килгән Казан ханлыгы, аның ханнары, аеруча соңгы ханбикәсе Сөембикә гасырлар дәвамында татар һәм рус әдипләренең, тарихчыларының игътибарын җәлеп итеп килә. Тарихыбызның әлеге чоры белән кызыксыну соңгы елларда аеруча артты. Сөембикә-ханбикәнең яшьлек еллары анык кына билгеле түгел. Илнең иминлеге хакына дип, улы белән Мәскәү патшасына тоткын итеп җибәрелгән ханбикәнең язмышы да билгесезлек пәрдәсе белән капланган. Болар, үз чиратында, Сөембикә турында төрле риваять һәм легендаларның киң таралуына китерә. Соңгысы исә әдипләргә ул чор вакыйга-күренешләренә бәйле Сөембикә образын ачуда төрле фикер-карашларга этәрә, язмышын төрле юнәлештә ачарга мөмкинлек бирә. Р. Хәмид билгеле булган сюжетларны кабатламыйча, кызыклы да, гыйбрәтле дә һәм фаҗига белән тулы «Хан кызы» (1995) пьесасын иҗат итә.

Авторның яңалыгы шунда, ул вакыйга-күренешләрне халык арасыннан чыгып, халкы һәм ханлыгы өчен Сөембикә фаҗигасен үз фаҗигасе итеп кабул иткән, алар өчен үлемгә барудан курыкмаган Язгөленең романтик образы белән бәйли. Геройның эш-гамәлләрендә кешегә хас булган иң матур, иң изге башлангычлар тулы ачыла һәм пьесада аларның һәртөр караңгылык, түбәнлек, хыянәттән өстенлеге, җиңеп чыгачагы раслана. Пьесаның төп каршылыгы туган иленә, җиренә бирелгән, аның азатлыгын бар нәрсәдән өстен күргән шәхесләр белән үз мәнфәгатьләрен кайгыртып, бүгенге көннәре белән генә яшәүче, шуңа да хыянәт-мәкер белән эш итүче, төрле түбәнлеккә барырга әзер кешеләр

арасында булып, үзенең иң югары ноктасына – трагик чишелешенә Язгөле белән Шаһгали бәрелешендә җитә[1].

Вакыйга-күренешләрдә автор халык кызы Язгөлене һәм халыкның яраткан ханбикәсе Сөембикәне бербөтен буларак ачуга ирешә. Монда мәсьәлә аларның тышкы охшашлыгында түгел билгеле. Гәрчә анысы да җитди роль уйный. Иң мөһиме – әлеге ике хатын-кызны ил язмышы өчен тирәнтен борчылу, аның өчен теләсә нинди кыенлыкларны үтеп чыгарга, хәтта гомерен дә бирергә әзер булу берләштерә. Сөембикә белән Язгөленең рухи бердәмлегендә, якынлыгында халыкның ханбикәгә булган мөнәсәбәте, уртак максатка омтылышы чагыла. Р. Хәмид үзенең трагик геройларын халык бәхете, аның киләчәге өчен явыз көчләр белән бәрелешкә кереп һәлак булган олы характерлар итеп сурәтли. «Казан ханлыгы патшабикәсе Сөембикәнең башнядан сикереп үлүе турындагы мифларга һәм легендаларга, шулай ук тарихи фактларга нигезләнеп, Р. Хәмид ханбикәнең фаҗигале язмышын чагылдыручы неомиф иҗат итә»[2].

Тарихи эчтәлекле трагедия буларак, автор тарихи фактларга таяна, үзенең фантазиясе аша аларны үстерә, баета, ул чор вакыйгаларына карата яңа фикер-карашлар, уйланулар тудыра. Драматург тәкъдим иткән яңа легенда Сөембикә образын яңача күзалларга, бәяләргә, аның халык белән мөнәсәбәтен ачыграк билгеләргә мөмкинлек бирә. Трагедиянең төп идеясе – халык язмышын үз язмышлары иткән Сөембикә һәм Язгөленең үлемсезлеген раслауда. Автор Казан ханлыгы фаҗигасенең сәбәпләрен ачып, аны бүгенгебезгә китереп тоташтыра. Трагик геройлар омтылган якты идеалларның киләчәктә җиңеп чыгачагына ышаныч уята.

М. Маликованың «Сөембикә» пьесасында Казан ханлыгының гаять хәвефле вакыты тасвирлана. Хәрәкәтне тудыручы каршылык, бер яктан, ханлык эчендәге я ачыктан-ачык, я яшертен рәвештә барган бәрелеш, икенче яктан, Казан ханлыгы белән рус дәүләте арасындагы конфликт рәвешендә бирелә. Ул ханбикәне һәм улын Мәскәүгә алып китү белән тәмамлана. Вакыйгалар үзәгендә, билгеле инде, Сөембикә тора. Автор аны акыллы, булдыклы, белемле, сугыш эшен дә яхшы белүче, кырыс ханбикә итеп тә, шул ук вакытта ирен сагынып яшәүче, романтик рухлы, йомшак күңелле ана буларак та ача. Вакыйга-күренешләр аша Сөембикә фаҗигасенең төп сәбәпләре ачыла: берсе – ил эчендәге хыянәт, морзаларның үз мәнфәгатьләре белән генә яшәве, икенчесе – татар ханлыклары арасындагы таркаулык, өстен чыгарга тырышу, бер-берсенең көчен бетерү. Шуңа да автор кешенең рухи бөеклеге һәм түбәнлегенең асылын аңларга омтыла. Киләчәк тарих бирәчәк бәя дә

---

[1] *Закирҗанов Ә.М.* Хәзерге татар драматургиясенең актуаль мәсьәләләре. Казан: Казан ун-ты нәшр., 2010. Б. 25–28.

[2] *Саттарова А.М.* Современная татарская драматургия (1985–2000 гг.): Концепция эпохи и героя. Казань: Гуманитария, 2003. С. 68.

ачык сиземләнә: Сөембикә халкыбыз күңелендә азатлыкка омтылу символы булып урын алса, Шаһгали, Нурали морза кебекләр түбәнлек, хурлык, хыянәт үрнәген тәшкил итә. Шулай да пьеса зур яңгыраш алмый. Сәбәбе, күрәсең, төп геройларның бөек идеаллар өчен көрәшүдә эзлекле булмавында. Аларга югары романтик пафос, фаҗигане белә торып, көрәшкә ташлану рухы җитми.

XX гасыр ахырында иҗтимагый-социаль каршылыклар китереп чыгарган кризис күренешләре, аерым алганда, рухи кыйммәтләрнең үзгәрүе халыкның билгеле бер катламында киләчәккә ышануны бетерә, ризасызлык, җәмгыятьтән читләшү тудыра, бу исә яшәешнең мәгънәсезлеге турында уйлануларга һәм пьесаларда сызлану мотивының өстенлек алуына, субъективлыкка, кеше ирегең абсолютлаштыруга этәрә. Аерым әсәрләрдә социаль һәм милли яшәеш проблемалары каршында куркып, икеләнеп калган, яшәешнең асылын аңламаган, мәгънәсен тапмаган, авырлыклардан котылу юлы үлемдә дип санаган персонажларны мәйданга чыгара. XX гасыр ахырында халыкның кызу темплар белән бай-ярлыга бүленүе, гаделлеккә нигезләнүче принципларның бозылуы, еш кына кире кагылуы әдәбият-сәнгатьтә субъективлык, индивидуализм һәм нигилизм күренешләренең үзенчәлекле чагылышына китерә.

Р. Хәмиднең «Актамырлар иле» трагедия-реквиемында милләт язмышы, аңа янаган юкка чыгу, ассимиляцияләшү куркынычы гыйбрәтле күренешләрдә ачыла. Пьесаның төп конфликты өлкән буын белән милли яшәү рәвешен кире каккан яшь буын арасында. Шуларга бәйле автор авылларның таркалуы, гореф-гадәтләрнең юкка чыгуы, әхлаксызлык күренешләренең артуы, эчкечелекнең тирән үтеп керүе, ата-ана белән бала арасында рухи бәйләнешнең югалуы кебек гаять актуаль мәсьәләләрне алга куя. Әхлакый кыйммәтләрне санга сукмаган буын шундый ук нәсел калдыра дип саный драматург. Мөштәри картның кызы Фаягөл никахсыз бала табып, аны чүпрәккә төреп, чүплеккә ыргыткан булган. Очраклы рәвештә Борхан килеп чыгып, баланы коткарган. Анасы салган эздән улы Гәрәй дә атлый. Ул үз баласына ана дуңгыз имчәге каптырып кына калмый, улының тапталып үлүенә дә юл куя. Әлеге тетрәндергеч күренешләрнең нәтиҗәсе эпилогта бирелә. Балаларының ата-ана фатихасын санга сукмавы, өч кызының да рус егетләренә кияүгә чыгуы, кемнеңдер әтисенең баш сөягеннән ясалган тустаганнан аракы эчүе кебек хәл-күренешләрне күз алдыннан үткәргән Мөштәри картның йөрәге түзми – ул егылып үлә. Шул рәвешле әсәрдә милләт язмышы мәсьәләсе яшәү фәлсәфәсе буларак күтәрелә. Трагедиядә Актамырлар иле турындагы риваять катнаш никахның милләт язмышына куркыныч янавын ачуга хезмәт итә. Әсәр ахырында Кифая карчык белән яшь хатын Фәридәнең уенчык курчакны юындырулары, шул ук вакытта яңгыраган

халык җыры пьесада сурәтләнгән фаҗиганең сәбәбен аңларга һәм аны булдырмау юлларын эзләүгә булыша.

А. Саттарова фикеренчә, әсәр шәхес башлангычын фәлсәфи һәм милли планда ачу омтылышы белән кызыклы. Трагедия-реквием жанрында язылган пьесада аерым шәхесләр язмышы бөтен милләт фаҗигасе буларак кабул ителә. Моны аңлауда мифологиядән килүче образларга, символик күренешләргә, метафора булып килгән вакыйгаларга, урыны белән абсурдлыкка җиткән хәлләргә мөрәҗәгать итү нигез булып тора. Әсәр сюжетында урын алган Актамырлар һәм Күктамырлар илләре белән бәйле вакыйгалар, үзара кушылып, чынбарлыкның фаҗигале концепциясен тудыра[1].

Үткән гасыр ахырында җәмгыятьнең барлык өлкәләрендә күзәтелгән кризис тормыш мәгънәсе, анда үз урыныңны табу кебек мәсьәләләрне әхлакый-психологик планда чагылдыруга этәрә. Мондый әсәрләрнең конфликт характеры һәм трагик герой бирелеше ягыннан трагедия жанрының традицион принципларына туры килүе бәхәс тә уятырга мөмкин. Әмма алар арасында трагедия жанры кысаларында бәяләнергә хаклы булганнары да бар. Ю.Б. Борев язганча, «билгеле бер шартларда кешеләр арасындагы шәхси мөнәсәбәтләр дә трагедия тудыра ала. Кабул кылынмаган, бәхетсез мәхәббәт төрле җәмгыятьтә гаҗәеп тирән кичерешләр һәм фаҗигаләр чыганагы булып торырга мөмкин»[2]. З. Хәкимнең «Шайтан куентыгы» фаҗигасендә вакыйгалар ике образ-символга бәйле үстерелә. Берсе – елга, әсәр исеме дә шуңа бәйле: «шайтан куентыгы» – елганың билгеле бер урыны. Пьесада ул яшәешне, кеше гомерен аңлата. Әлеге елгада Шайтан куентыгы һәм шайтаннар да бар, ягъни кешене тормышында каршылык-киртәләр, сынаулар көтә. Берәүләр ул сынаулар аша үтеп, бәхетле яшәешкә ирешсә, икенчеләр өчен буй җитмәс хыял булып кала, гомерләре дә фаҗига белән тәмамлана. Икенче символ исә – әлеге елгадан әсәр герое Разим тотарга теләгән алтын балык. Ул кешенең хыялында тудырылган тормышка, бәхетле яшәешкә ирешү шарты булып аңлашыла.

Тормышның җитди каршылыгына очраган егет белән кыз ялгыш адым атлауларын, нәрсәнедер үзгәртергә кирәклеген, антларына тугры калырга тиешлекләрен дә аңлыйлар. Әмма яшәешнең кырыс кануннарын үтеп чыга алмыйлар. Бер-берсен яратышкан яшьләрнең бәхетле була алмаулары сәбәбе турында Разимның әнисе Гамирә болай ди: «Мин белмим, кайсыгыз гаепледер, ләкин шуны әйтәсем килә: антка тугры булмау кайчан да булса бәхетсезлеккә китерә. Ант бирмәскә кирәк. Ант итү кирәк нәрсә түгел». Разим да, Фәнзилә дә шайтан

---

[1] *Саттарова А.М.* Современная татарская драматургия (1985–2000 гг.): Концепция эпохи и героя. Казань: Гуманитария, 2003. С. 110–117.

[2] *Борев Ю.Б.* О трагическом. М.: Советский писатель, 1961. Б. 315.

котыртуыннан котыла алмыйча, этиләре кебек үк Шайтан куентыгында фаҗигале үлемгә дучар булалар.

Төп конфликт геройларның эчке каршылыгында. Аларның үзара аңлаша алмаулары да шуннан килеп чыга. Халык мифларында явызлык кылучы буларак күрсәтелгән шайтан яшьлек хыялларына хыянәт иткән егет белән кызның күңеленә үтеп керә. Явызлык якты якны – Яхшылыкны җиңүгә бик тиз ирешә. Яшьләрнең рухи йомшаклыгы белән бергә, моның тагын бер сәбәбе итеп автор яшәештәге гаделсезлекне, шул исәптән авыл кешесенә ярдәм-игътибар кимүен күрсәтә. Тормышка тирән үтеп кергән әхлаксызлык-имансызлыкның чагылышы булган эчкечелек, бозыклык, җиңел тормышка кызыгу, миһербансызлык, ата-ана һәм бала каршылыгы кебек күренешләр дә шуның нәтиҗәсе. Тормыш-көнкүреш вакыйгаларына нигезләнгән пьеса социаль-иҗтимагый яңгыраш ала.

Авторның сәнгати фикерләү үзенчәлекләрен аңлау ягыннан үзенчәлекле пьесаны максатчан тикшергән А. Саттарова яңалык-табышны түбәндәгеләрдә күрә: 1) яшьлек идеалына, хыялга тугрылык саклау омтылышы җимерелә, ә инде аларны тормышка ашыра алмау фаҗига китереп чыгара; 2) моңсу лиризм белән сугарылган пьеса кеше гомеренең фәлсәфи тирәнлеген ачуга ярдәм итә; 3) мифологик образлар, символик детальләр кеше күңеленең ике ягын ачуга хезмәт итә; 4) автор тамашачы һәм укучы хөкеменә дөньяның һәм рухи гармония тапмаган фаҗигале геройларның трагик концепциясен тәкъдим итә[1].

XX гасырның 90 нчы еллары икенче яртысындагы чечен сугышы җир йөзеннән юк ителгән авыллар, меңнәрчә корбаннар белән чечен халкының кан-яшенә әверелсә, үтерелгән яисә яраланган солдат-офицерлар аша Россиянең үзенә дә әйтеп бетергесез кайгы-хәсрәт алып килә. Россиядә яшәүче күпсанлы халыкларның канлы ярасына әверелгән чечен сугышы темасына татар әдәбиятында беренчеләрдән булып Ю. Сафиуллин мөрәҗәгать итә. Драматург «Йөзек һәм хәнҗәр» трагедиясендә сугыш вакыйгаларының, кайтаваз буларак, Татарстан җиренә килеп, кеше язмышларына гаять зур йогынты ясавын үзенчәлекле вакыйгалар, кабатланмас геройлар аша сурәтли.

Бер яктан, сугыш афәтен үткән егетләр белән әйләнә-тирәдәгеләр арасында, икенче яктан, Россия армиясендә командир приказын үтәп, чечен авылларын җимергән, кулларына корал тотып каршылык күрсәтүчеләргә генә түгел, бәлки хатын-кыз һәм бала-чагаларга каршы да танк белән барган Линар һәм Рәсим белән йорт-җирләрен, сөйгәннәрен югалтып, туган иленнән качып китәргә мәҗбүр булган Хания һәм Разия

[1] *Саттарова А.М.* Современная татарская драматургия (1985–2000 гг.): Концепция эпохи и героя. Казань: Гуманитария, 2003. С. 117–122.

арасында конфликт оеша. Боларга өченче төр каршылык – төп геройлар күңелендә барган рухи көрәш үрелеп бара[1].

Ю. Сафиуллин иҗатын монографик планда тикшергән Ф. Миңнуллина билгеләп үткәнчә, авторны аеруча Линар белән Рәсимнең җан бәргәләнүләре, тыныч тормышта үзләренә урын таба алмаулары борчый. Пьесаның «Йөзек һәм хәнҗәр» дип аталуы да шуңа ишарә итә. Йөзек – яшәү билгесе, ул мәхәббәтне, тормышта тынычлыкка өстенлек бирүне аңлата. Хәнҗәр исә – үлемне, кайгы-хәсрәт алып килүче, дошманлыкка илтүче төшенчәне белдерә. Егетнең мәхәббәт, тынычлык символын эзләве күңелендәге психологик тартышка, җанына тынычлык эзләвенә, «чечен синдромы»н җиңеп, гөнаһларыннан арынып, тыныч тормышка кайту өчен үз-үзе белән көрәшенә метафора булып тора. Фаҗигале төстә үлемгә дучар булган геройларны хезмәт авторы хөкүмәт алып барган сәясәт корбаннары дип атый[2]. Шул рәвешле, тыныч шартларда ике яшь кешенең гомере өзелә. Драматург гаепләү актын сугышка, аны башлаучыларга юнәлтә.

Шулай итеп, хәзерге татар драматургиясен тикшерүчеләр билгеләп үткәнчә, трагедия жанры, сан ягыннан күп булмаса да, әдәби процесста мөһим роль уйный, драматургларның тема һәм проблематика, жанр һәм жанр формасы, сәнгати сурәтләүдәге эзләнүләрен шактый тулы чагылдыра. Ерактагы һәм якындагы тарихка мөрәҗәгать итеп яисә төрле легенда-риваятьларга нигезләнеп язылган пьесаларда жанр таләпләре, төп сыйфатлары, нигездә, саклана. Бүгенге тормышның төрле якларына багышланган әсәрләрдә авторлар посттоталитар чынбарлыкның асылын ачу, шуңа бәйле аерым кешеләр һәм, гомумән, җәмгыять яшәешенең социаль һәм әхлакый аспектларын билгеләү омтылышы ясыйлар. Төп герой буларак тәкъдим ителгән образлар социаль-экзистенциаль характерда сурәтләнә, шуңа да аларны аңлауда һәм бәяләүдә төрлелек, хәтта каршылык күзәтелә. Фәнни һәм тәнкыйди хезмәтләрдә күрсәтелгәнчә, чор үзгәрешләре тәэсирендә, башка жанрлар кебек үк, трагедия дә билгеле бер трансформация кичерә. Алар түбәндәгеләрдә чагылыш таба: беренчедән, трагик конфликт табигатен аңлау үзгәреш кичереп, жанрның әдәби функциясе милләтне инкыйраздан саклап калу идеясенә юнәлтелә, бу исә пьесаларда фәлсәфилекнең милли һәм әхлакый кыйммәтләр белән тыгыз үрелеп баруына китерә; икенчедән, трагедияләрдә татар тамашачысы аеруча яраткан мелодрамага хас элементлар, аерым алганда лирик-эмоциональ һәм романтик катлам киң урын ала; өченчедән, хәзерге трагедияләрдә бурыч һәм шәхси теләк каршылыгы милләтнең бүгенгесе һәм киләчәге өчен борчылу төсмере тудыра һәм,

[1] *Игламов Р.* В пространстве трагедии // Идель. 1998. № 2. С. 77–78.

[2] *Миңнуллина Ф.Х.* Юныс Сафиуллин драматургиясе (Заман һәм герой). Казан, 2007, Б. 98–103.

гадәттә, мәхәббәткә бәйле сюжет линиясе белән үрелеп бара; дүртенчедән, трагик конфликт, геройның үзеннән өстен көч белән бәрелешеннән бигрәк, кешенең эчке табигатеннән, яшәп килгән тәртипләр белән килешә алмаудан үсеп чыга һәм тормышта үз урынын таба алмаган шәхес трагедиясен ачу төсмерен ала; бишенчедән, фаҗигале әсәрләрдә без үзенчәлекле милли геройлар белән очрашабыз: бер яктан, милләт азатлыгы өчен көрәш символы дәрәҗәсенә күтәрелгән тарихи шәхесләрнең олы образы тудырылса, икенче яктан, «үзен һәрвакыт кимсетелгән итеп хис итүче татар характерының фаҗигале халәте»[1] чагыла, өченче яктан, гадәттә татар авылы белән бәйле геройлар сайлаган юлларыннан, максатларыннан чигенмәүче олы милли характерлар дәрәҗәсенә үсеп җитми; алтынчыдан, төп трагик пафосны шәхес ирегенә омтылучы, матур хыяллар белән яшәүче геройның явызлык дөньясы, гаделсезлек белән бәрелеше китереп чыгара һәм ул еш кына кеше ялгызлыгы, экзистенциаль халәт-тоемлау белән кушылып китә.

## II бүлек нәтиҗәләре

1. XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы татар фәнни-теоретик фикере җитди сыйфат үзгәрешләре кичерә һәм ул, гомум әдәбият белеме кебек үк, күчеш чоры үзенчәлекләре белән аңлатыла. Әдәбиятны өйрәнүдә фәнни нигезләрнең үзгәрүенә этәргеч биргән эчке факторлар – тарихи күчемлелек, традицияләр һәм эчке үсеш закончалыклары. Рус һәм чит ил әдәбият белемендәге казанышларның үтеп керүе, яңа термин-төшенчәләр белән баю, шулай ук тикшеренүнең яңа юнәлешләре барлыкка килү дә әлеге процесска зур йогынты ясый. Алгы планга әдәбиятны эчке закончалыклары нигезендә үсеп-үзгәреп торучы сүз сәнгате буларак бәяләү, аның эстетик, иҗтимагый, фәлсәфи вазифаларын ачу, татар әдәбиятын дөнья әдәбиятының бер өлеше итеп күзаллау, шуңа бәйле уртаклыклар һәм милли әдәбиятның үзенә хас сыйфатларын билгеләү һ.б. чыга.

2. Әдәбият, төрле дәверләр, этаплар, чорлар аша үтеп, җитди үзгәрешләр кичерә һәм иҗат тибы, иҗат юнәлеше, иҗат методы, иҗат агымы кебек әдәби бергәлекләрне мәйданга чыгара. Кешенең тормышны танып-белү үзенчәлеге белән бәйле булган иҗат типлары иҗтимагый, мәдәни һәм эстетик шартларга нисбәтле һәм чынбарлыкны танып белүнең уртак принципларына нигезләнгән бердәмлек төсендә иҗат юнәлешләре булып формалаша. Әдәбият фәнендә озак вакытлар дәвамында классицизм юнәлеше әдәби күренеш буларак урын алмаган, аның үрнәкләре татар укучысына XX йөз башында тәрҗемә әсәрләр аша гына ирешеп, әдәби барышка аз йогынты ясаган дип санала. Соңгы еллардагы тикшеренүләр күрсәткәнчә, татар әдәбиятының төрле чорларында классицизм эстетикасының асылын билгеләгән хис һәм бурыч

[1] *Ахметов Р.Р.* Татарский театр // Звезда Поволжья. 2008, 27 марта – 2 апреля.

каршылыгы шәхси теләк-омтылыш һәм милләт язмышы өчен җаваплылык рәвешендә үзгәртелеп урын алган әсәрләр дөнья күрә.

3. Хәзерге татар әдәбият теориясендә әдәби процессны яисә аерым язучы иҗатын әдәби юнәлеш-агым тарафдары буларак бәяләү омтылышы күзәтелә. Шуңа бәйле рус һәм дөнья әдәбият белемендә инде калыплашкан термин-төшенчәләр киң рәвештә кулланышка керә. Татар әдәбиятындагы эзләнүләрнең киңәюен, әдипләрнең реализм һәм романтизмга хас булмаган алым-чараларга мөрәҗәгать итеп, үзенчәлекле әдәби дөнья тудыру омтылышларын таныган хәлдә, мондый әсәрләрне модернизм һәм постмодернизм үрнәге буларак кабул итүгә һәм хәзерге әдәби барыштагы урыннарын билгеләүгә әдәбият фәне сак килә. Хәзерге әдәбияттагы бер агым буларак, постмодернизм үрнәкләрендә реалистик әдәбиятка хас булмаган алым-чаралар, иҗади фикерләү аша яшәешне үзенчәлекле танып-белү, яңа чынбарлык тудыру омтылышы ясала. Теоретик фикер хәзерге татар әдәбиятында модернизмның түбәндәге сыйфат-билгеләрен аерып чыгара: төрле стильләрнең синтезы һәм аларның реализм белән катлаулы мөнәсәбәт-бәйләнеше; урта гасырлар романтик әдәбиятының аерым традицияләре активлашу; әдипләрнең актив рәвештә архетипларга, мифологемнарга, фантастик һәм шартлы формаларга, символларга мөрәҗәгать итүе; әдәби алым һәм сурәтләү предметы буларак «уен»ны, «нулевая композиция», кеше күңелендә урын алган ике башлангычка нигезләнү (ин-янь принцибы); автор концепциясен шартлылык һәм билге-символ аша чагылдыру тенденциясе; милли теманың мөһим проблематика буларак алгы планга чыгуы; күптөрлелек, чикләнгәнлек һәм чиксезлек кебек фәлсәфи проблемаларга йөз тоту; әдипләрнең фәлсәфилеккә, хикмәтле сүз әйтүгә, притча жанрына теләп мөрәҗәгать итүләре һ.б. Ә инде хәзерге татар сүз сәнгатендә постмодернизм әдәбиятының төп билгеләре буларак түбәндәгеләр күрсәтелә: үткән мәдәниятнең «эзләрен» яңадан тудыру; «натура»ны алыштырган «мәдәният»нең коллаж рәвешендә бирелүе; хәзергене үткән белән бәйләү мөмкинлеге биргән синкретик формаларга омтылу; авторларның парадоксальлеккә түгел, ә реальлеккә омтылуы; бер әсәр чикләрендә төрле темалар, әдәби алымнар, стильләр, әдәби-тарихи традицияләрнең очрашуы күрсәтелү; әсәр чынбарлыгы һәм реаль чынбарлыкның аерып куелуы; үз дөньясы хакында сөйләүче язучы-автор урынын язучы-скриптор (кәгазьгә төшерүче) алу; лиризмга омтылу, эпитетлар һәм детальләштерү алгы планга чыгу; үзәгендә хисчәнлек яткан «шизоанализ»ны, пародия тудыруны һ.б.ны файдалану. Гомумән, татар әдипләренең постмодернизмга сак караулары, аның төп принципларыннан берсе – әсәрдән автор шәхесен «алу»ны кабул итмәүләре күзәтелә.

4. XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы татар әдәбият теориясе игътибар үзәгендә торган мәсьәләләрнең берсе булып «иҗат методы» төшен-

чәсе тора. Әлеге кызыксыну, бер яктан, җәмгыятьтәге социаль-мәдәни үзгәрешләргә, икенчедән, марксизм-ленинизм тәгълиматына нигезләнгән методологиянең берьяклы булуын аңлауга һәм аңа тәнкыйди караш формалашуга, өченче яктан, күчеш чорында реализмның билгеле бер кризиска керүе һәм, акрынлап, аннан чыгу юлларын эзли башлавына нигезләнә. Иҗтимагый-мәдәни шартлар һәм сүз сәнгатенең эчке закончалыклары нигезендә иҗат методлары билгеле бер үзгәреш кичерә, яңа сыйфат-билгеләр белән байый.

5. Җәмгыятьтәге үзгәрешләр традицион реализмның тармакланып үсеп китүенә, эзләнүләрнең тирәнәюенә, баюына китерә. Әдәбият фәне әлеге үзгәрешләрне тиз генә ачып-аңлатып бирә алмыйча, җитди каршылыкларга керә. Моннан чыгу юлларын эзләүдә әдәби барыш яисә аерым әдип иҗатын юнәлеш-агымнарга мөнәсәбәтле ачыклау омтылышлары ясала. Социалистик реализмнан соңгы әдәбиятны без «яңа реализм», «яңа романтизм» дип атау ягында. Әдипнең язу стиленә, әсәрләренең темасына, төп пафосына һәм идеясенә, шәхес концепциясенә һ.б.га нисбәтле «яңа реализм»ның түбәндәге юнәлешләре (тенденцияләре) күзәтелә: тәнкыйди, милли, интеллектуаль, психологик, тормыш-көнкүреш, лирик-эмоциональ, сентименталь, дини-рухани һ.б. Иҗтимагый идеалларның үзгәрүе нәтиҗәсендә җанланып киткән «яңа романтизм»га хас үзенчәлекләр буларак, геройның, еш кына, әхлакый сайлау алдына куелуы, иҗтимагый эчтәлекнең шәхси башлангыч белән үрелеп китүе, лирик башлангычны да ят итмәве, тойгы-кичерешләрнең фәлсәфи уйланулар белән кушылып баруы һ.б. билгеләнә. «Яңа реализм» һәм «яңа романтизм» төшенчәләре, вакытлы күренеш буларак, күчеш чоры әдәбиятының үзенчәлекләрен аңлауга хезмәт итәләр. Шуңа да хәзерге әдәби процессның әйдәп баручы иҗат методын билгеләү, аңлату һәм бәяләү филология фәне алдында торган бурычларның берсе булып кала бирә.

Хәзерге татар әдәбиятында чынбарлыкның аңлап һәм аңлатып бетерү мөмкин булмаган, кешенең көчсезлеге, гомеренең чиклелеге, яшәү мәгънәсе шик астына алыну, чиктәш халәт һ.б. мәсьәләләр чагылыш табып, яшәешнең кырыс каршылыкларын һәм социаль-экзистенциаль героен ачу максатында, реаль һәм мифологик дөнья күренешләренә, архетипларга, мифологемнарга мөрәҗәгать итү күзәтелә. Модернизм һәм постмодернизмга хас сурәт чараларын, алымнарын үз иткән мондый әсәрләрнең аеруча шартлы-метафорик һәм шартлы-мифологик юнәлешләре киң чагылыш таба.

6. Теоретик фикердә зур кызыксыну уяткан «жанр» төшенчәсе әдәбиятның закончалыклы күренеше буларак барлыкка килә һәм даими үсеп-үзгәреп тора. Әлеге үзенчәлек хәзерге әдәби процесста мөһим роль уйнаучы, драматургларның тема һәм проблематикадагы, жанр һәм жанр формасындагы, сәнгати сурәтләүдәге эзләнүләрен шактый тулы

чагылдыручы трагедия жанрында ачык күренә. Фәнни һәм тәнкыйди хезмәтләрдә күрсәтелгәнчә, чор үзгәрешләре тәэсирендә, трагедия билгеле бер трансформация кичерә. Алар түбәндәгеләрдә чагылыш таба: 1) трагик конфликт табигатен аңлау үзгәреш кичереп, жанрның әдәби функциясе милләтне инкыйраздан саклап калу идеясенә юнәлтелә, шуңа нисбәтле пьесаларда фәлсәфилекнең милли һәм әхлакый кыйммәтләр белән тыгыз үрелеп баруы күзәтелә; 2) трагедияләрдә татар тамашачысы аеруча яраткан мелодрамага хас элементларның, аерым алганда, лирик-эмоциональ һәм романтик катламның киң урын алуы; 3) хәзерге трагедияләрдә бурыч һәм шәхси теләк каршылыгы милләтнең бүгенгесе һәм киләчәге өчен борчылу төсмере ала һәм, гадәттә, мәхәббәткә бәйле сюжет линиясе белән үрелеп бара; 4) трагик конфликт, геройның үзеннән өстен көч белән бәрелешеннән бигрәк, кешенең эчке табигатеннән, яшәп килгән тәртипләр белән килешә алмаудан үсеп чыга, бу исә тормышта үз урынын таба алмаган шәхес трагедиясен ачуның киң урын алуына китерә; 5) фаҗигале әсәрләрдә без үзенчәлекле милли геройлар белән очрашабыз: а) милләт азатлыгы өчен көрәш символы дәрәҗәсенә күтәрелгән тарихи шәхесләр, ә) үзен кимсетелгән итеп хис итүче персонажлар, б) татар авылы белән бәйле, олы милли характерлар дәрәҗәсенә үсеп җитмәгән образлар; 6) төп трагик пафосны шәхес ирегенә омтылучы, матур хыяллар белән яшәүче геройның явызлык дөньясы, гаделсезлек белән бәрелеше китереп чыгара һәм ул, еш кына, кеше ялгызлыгы, экзистенциаль халәт-тоемлау белән кушылып китә.

7. Иҗтимагый һәм мәдәни шартлар йогынтысында сүз сәнгатенең эчтәлегендә, төзелешендә, образлар системасында гына түгел, бәлки поэтикасында да җитди үзгәрешләр бара. Аеруча мөһим теоретик категорияләрнең берсе булган «әдәби образ», сүз сәнгате тарихына яисә җанлы әдәби процесска мөнәсәбәтле төрле караш-фикерләргә этәреп, үзенчәлекле яклары белән ачыла. Шуның бер чагылышы булып, образ-символларның актив кулланылышы һәм түбәндәге яңа сыйфатлар белән баюы тора: 1) төп мәгънә эчтәлеген саклаган хәлдә, үзенчәлекле фәлсәфи яңгыраш, иҗтимагый эчтәлек алып, авторның гражданлык позициясен чагылдыру рәвешендә трансформацияләнү; 2) традицион образ-символларның яңа мәгънә төсмере алуы; 3) реаль һәм идеал дөньяларның бәйләнешен чагылдырган чынбарлыкның ике төрле моделен төзүгә нигез булып тору; 4) кешенең экзистенциаль халәтен чагылдыруга хезмәт итүче символлар активлашу; 5) кеше язмышын символлаштыручы сурәт буларак, өр-яңа индивидуаль мәгънә төсмерләре белән баетылу һ.б. Гомумән, хәзерге татар әдәбиятында образ-символлар аша тормыш-яшәешне образлы кабул итү, яңа әдәби дөнья тудыру, укучыга тәэсир итү, эмоциональлекне арттыру һәм, иң мөһиме, автор идеясен тагы да тулырак ачу омтылышы күзәтелә.

## III бүлек

# ТАТАР ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫН ӨЙРӘНҮГӘ ЯҢАЧА ЯКЫН КИЛҮ

## 3.1. Әдәбият тарихын өйрәнүнең теоретик һәм методологик нигезләре

Матур әдәбият ядкәрләре үткән гасырларда яшәгән кешеләрнең тормышы, уй-фикерләре, хис-кичерешләре белән таныштырып, тарихи кызыксыну уяту белән бергә, күзаллауны тирәнәйтә, акылны баета, рухи-әхлакый сыйфатлар тәрбияли, гомумән, шәхес буларак формалашуга ярдәм итә. Әдәби мирас китап укучының күңел дөньясын баета, рухына көч өсти, эстетик зәвыгын, хис-кичерешләрен үстерә, илһамландыра, канәгатьлек-рәхәтлек бирә. Дөнья әдәбиятының танылган осталары әсәрләрендә кешегә хас фикер һәм хис-кичерешләрнең гаҗәеп тирәнлеге, матурлык һәм яхшылык күренешләре, сүз дигән серле дөньяның мөмкинлекләре, эстетик кыйммәте чагылыш таба.

Матур әдәбият, чынбарлыкны әдәби образларда чагылдырып, дөньяны танып белергә ярдәм итә. Нәкъ менә образлылык, нәфислек, күптөрле эстетик категорияләр (матурлык, ямьсезлек, бөеклек, түбәнлек, фаҗигалелек һ.б.) сүз сәнгатенең асылын билгели. Аның төп сурәтләү предметы – кеше, кешене әйләндереп алган тормыш чынбарлыгы. Гасырлар дәвамында иҗади һәм интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәсе буларак барлыкка килгән сүз сәнгате закончалыклы система тәшкил итә. Аның үсеш-үзгәрешен, төп сыйфат-үзенчәлекләрен, аерым чорларга хас тенденцияләрен, әдипләрнең иҗат мирасында чагылыш тапкан традиция һәм яңачалыкларны, чынбарлык һәм иҗтимагый-мәдәни күренешләр белән бәйләнеш-мөнәсәбәтен әдәбият тарихы өйрәнә.

Татар әдәбиятының мең елдан артык тарихы булса да, аны өйрәнү, тикшереп бәяләү рәвешендә махсус хезмәтләр бик соңарып – XX йөз башында гына дөнья күрә. Шулай да әдәбият белеменең башлангычы борынгы һәм урта гасырларга ук кайтып кала. Һәр яңа чор әдәбияты вәкилләре үзләреннән алда иҗат ителгән әсәрләр турында фикер-карашларын белдерә. Моңа исә ул чорларда киң таралган нәзыйрә алымы, күчмә сюжетлар күренеше дә зур мөмкинлек бирә. Д. Заһидуллина билгеләгәнчә, «татар әдәбиятының дини-дидактик эчтәлекле ядкәрләре эчендә, еш кына, дөньяви гонсыр-компонентлар төп урынны ала булып чыга, бу әсәрләрдә авторлар иҗтимагый карашларын да бәян итәләр, дөньяны аңлау да, фәлсәфи уйланулар да языла, астрономия яки

медицина, алгебра яки тарихка караган тикшеренүләр һәм теорияләр исбатлана. Үз әсәрендә әдип башка фикер ияләре белән бәхәскә керә, аларны яклый я кире кага»[1].

XIX йөз ахырында иҗтимагый-мәдәни тормыштагы үзгәрешләр, мәгърифәтчелек хәрәкәтенең зур дулкын булып күтәрелүе, дини реформаторлык, китап басу эшенең колач җәюе сүз сәнгатенә булган игътибарны бермә-бер арттыра. Яңа заман әдәбияты мәйданга килә. Әмма әдәбият тарихы әле аерым фикер-мөнәсәбәт рәвешендә кала. Бу эшкә беренчеләрдән булып атаклы фикер иясе Ш. Мәрҗани алына. Аның хезмәтләрендә, аеруча «Мөстафәдел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» («Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр») китабында татар әдәбияты тарихын бер тәртипкә салу омтылышы ясала[2]. Әдәбият тарихы турында тотрыклы күзаллау булдыруда К. Насыйри хезмәтләре тагын бер адым була. Мәгърифәтченең халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю, туплау, фәнни эшкәртү эшен башлап җибәрүчеләрнең берсе булуын һәм татар фольклор үрнәкләре белән рус телле укучыларны даими таныштырып баруын билгеләп үтәргә кирәк. «Халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю һәм бастыру этабыннан аларны фәнни нигезләрдә өйрәнүгә күчү, ягъни татар фольклористикасының мөстәкыйль фән буларак формалаша башлавы нәкъ менә аның эшчәнлеге белән бәйләнгән иде»[3]. Дин галиме, әдип, әдәбиятчы, фәлсәфәче Р. Фәхретдин хезмәтләре, аеруча, «Асар» биобиблиографик характердагы китабы үзенә кадәрге һәм үз чорында яшәп иҗат иткән байтак шагыйрьләрнең тормыш юлы, әсәрләренә хас кайбер сыйфатлар, әдәби-мәдәни мохит турында мәгълүмат бирү белән татар әдәбияты тарихын өйрәнүгә дә өлеш кертә[4].

Яңарыш юлына баскан татар әдәбияты XX йөз башында яңа баскычка күтәрелеп, җитди сыйфат үзгәрешләре кичерә. Ул әсәрләрнең эчтәлегендә, тематик киңлегендә, жанр төрлелегендә, яңа әдәби юнәлеш-агымнарны үзләштерүдә, сәнгатилек үсүдә һ.б.да чагылыш таба. Бу чорда татар әдәбият белеменең өч тармагы үзара кушылып, үрелеп үсә. Ә инде әдәбият тарихына караган хезмәтләр арасында Г. Тукайның «Шигырьләремез хакында» (1907), Ф. Әмирханның «Әдәбиятка гаид» (1908), Ф. Кәриминең «Моталәга» (1908), Г. Тукайның «Халык әдәбияты» (1910), Р. Фәхретдиннең «Әдәбиятыбызның нигезләре» (1911), Г. Ибраһимовның «Әдәбият мәсьәләләре» (1913) һ.б.

---

[1] *Заһидуллина Д.Ф.* Әдәбият кануннары һәм заман. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. Б. 24.

[2] *Мәрҗани Ш.* Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 142–149, 275–276, 290–292, 314–317.

[3] *Мәхмүтов Х.Ш.* Каюм Насыйри һәм татар фольклористикасы // Насыйри К. Сайланма әсәрләр. 4 томда. 3 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. Б. 14.

[4] *Фәхреддин Р.* Асар. 2 т. Казан: Рухият, 2009. 309 б.; Фәхреддин Р. Асар. 3 һәм 4 томнар. Казан: Рухият, 2010. 648 б.

аерым игътибарга лаек. Шулай да әдәбият тарихын чагыштырмача тулы, эзлекле яктырту омтылышы ясалган тикшеренүләр булып Җ. Вәлидинең «Татар әдәбиятының барышы» (1912), «Әдәби хәрәкәт» (1915) хезмәтләре санала. Аларда, әдәбиятның шул чордагы торышын билгеләү белән бергә, тарихи үсеш-үзгәреш закончалыкларына, традицияләр дәвамчанлыгына, аерым алымнарга мөнәсәбәт белдерелеп, җитди нәтиҗәләр чыгарыла. Гомумән, Җ. Вәлиди, Г. Баттал, Г. Ибраһимов, Г. Сәгъди, Н. Хәлфин, Г. Рәхим һ.б.ның әдәбият теориясенә, әдәбият һәм мәдәният тарихына, әдәби тәнкыйтькә караган язмалары татар әдәбияты тарихының нигез ташларын тәшкил итә.

1917 елдан соң, Совет властеның беренче елларында, рухи һәм мәдәни тормышта үсеш-үзгәрешләргә уңай шартлар туа: автономия кысаларында булса да дәүләтчелек торгызыла, татар теле дәүләт теле дип игълан ителә, Академик Үзәк оеша, рус һәм Көнбатыш Европа телләреннән тәрҗемә итү арта һ.б. Татар әдәбият белемен, шул исәптән әдәбият тарихын өйрәнүгә Г. Ибраһимов, Г. Нигъмәти, Г. Сәгъди, Җ. Вәлиди, Г. Рәхим, Г. Гобәйдуллин, Г. Гали, Ф. Борнаш кебек әдипләр, галимнәр, тәнкыйтьчеләр тартыла. Э. Галиева фикеренчә, бу чорда татар әдәбият белеме культура-тарих мәктәбе принципларына нигезләнеп үсә. Аның үзенчәлеген билгеләп, галимә болай дип яза: «20–30 нчы елларда татар әдәбият белеме үсешендәге фәнни юнәлешләрнең рус, Гареб, Шәрык фәнни мәктәпләре белән уртак яклары, уртак позицияләре булуы ачыкланды. (...) Г. Нигъмәти рус әдәбият галимнәренең һәм тагын да киңрәк планда Көнбатыш әдәбият теориясенең фәнни нигезләренә юнәлеш тотса, Г. Сәгъди хезмәтләрендә Көнчыгыш (төрек) әдәбият фәненә ориентация тоту ачык чагылды»[1]. Г. Нигъмәтинең «Әдәбият мәйданында» (1925), «Революция елларында әдәбиятыбыз» (1929), «Әдәбият һәм тормыш» (1931), «Татар совет әдәбияты күтәрелештә» (1934), Г. Сәгъдинең «Татар шагыйрьләре арасында Габдулла Тукай» (1923), «Татар драма әдәбияты һәм аның тарихи үсүләре» (1926), «Фатих Әмирхан» (1926), «Кандалый турында» (1927), «Символизм турында» (1932), Җ. Вәлидинең «Очерк истории образованности татар» (1923), шулай ук Г. Сәгъди, Г. Рәхим, Г. Гобәйдуллин дәреслекләрендә, Г. Ибраһимовның телгә, әдәбиятка, тарихка караган язмаларында, Ф. Борнашның «Фатих Әмирхан» (1926), «Тукай шигырьләренә караш» (1926), «Революция һәм татар әдәбияты» (1929) хезмәтләрендә татар әдәбияты тарихын иҗтимагый фикер үсеше тарихы белән тыгыз бәйләнештә, әдәби метод, әдәби стиль мәсьәләләренә йөз тотып өйрәнү үзәктә тора. Э. Галиева фикеренчә, асылда культура-тарих мәктәбе концепциясенә нигезләнгән татар әдәбият фәне белән шөгыльләнүчеләрнең

[1] *Галиева Э.Р.* Татар әдәбият белемендә культура-тарих мәктәбе. Казан: Фән, 2002. Б. 30.

хезмәтләрендә биографик, социологик, эстетик, чагыштырма-типологик пландагы тикшеренү алымнарыннан файдалану күзәтелә[1]. Бу урында шуны да билгеләп үтик, Г. Нигъмәти хезмәтләренең үз вакыты өчен генә түгел, бүген дә кыйммәтен билгеләп, «Галимҗан Нигъмәти: тормышы, фәнни-методик эшчәнлеге»[2] дигән китап дөнья күрде. Хезмәттә, галимнең җәмәгатьчелеккә аз таныш булган тикшеренүләре белән бергә, аның турындагы язмалар да урын алган.

1930 елларда илдәге иҗтимагый-сәяси мохит – «шәхес культы», репрессияләр, сыйнфый дошман эзләү белән мавыгу, партиянең иҗат оешмалары белән турыдан-туры җитәкчелек итәргә алынуы һ.б. – әдәбият белеме үсешенә дә җитди тоткарлык ясый. Алдагы чорда актив иҗатта булган Г. Нигъмәти, Г. Сәгъди, Г. Ибраһимов, Җ. Вәлиди, Г. Гобәйдуллин, Г. Рәхим кебек әдәбият галимнәренең төрлечә эзәрлекләнүе, иҗаттан читләштерелүе әдәбият фәне өчен зур югалту була. Бу чорда шактый киң тамыр җәйгән вульгар-социологик карашлар әдәби тәнкыйтьне дә читләтеп үтми. Мисал өчен, Г. Галинең «Әдәбият фронтында бүгенге бурычлар» (1931), «Пролетариат әдәбияты өчен көрәшкәндә» (1931), «Драматургның үсү юлы» (1935) һ.б. хезмәтләрендә теоретик мәсьәләләр буенча кызыклы эзләнүләр булса да, автор сыйнфый көрәш белән мавыгудан, әдипләр иҗатына берьяклы бәя бирүдән котыла алмый. Мондый шартларда әдәбият белеме яшь тикшеренүчеләрне көтә. Гасырның 30 нчы еллар ахыры – 40 нчы еллар башында Г. Халитнең «Халык шагыйре Габдулла Тукай» (1939), «Мәҗит Гафури иҗаты (Критик очерклар, 1941), Г. Кашшафның «Шәриф Камал (тормыш һәм иҗат юлы)», 1941) кебек хезмәтләре басылып чыгу фән үсешенә уңай йогынты ясый. Аларда әдәбият үсешен күчемле бәйләнештә өйрәнү, сыйнфый көрәш позициясеннән арыну, объективлыкка һәм идея-эстетик анализга омтылу урын ала.

Бөек Ватан сугышы шартлары әдәбият белеме өлкәсендәге тикшеренүләрне тоткарлый. Ә инде ВКП(б) ҮК 1944 елның 9 августында кабул ителгән «Татарстан партия оешмаларында масса-политик һәм идеологик эшнең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында»гы карары татар тарихының ерак тамырларын өйрәнүгә, шул исәптән Урта гасырлар әдәбиятының аерым чорларын тикшерүгә киртә куя. Шуңа да татар галимнәренең игътибары XVIII–XIX йөз әдәбияты тарихына юнәлтелә. Л. Җәләйнең «Татарларда мәгърифәтчелек хәрәкәте һәм Каюм Насыйри» (1945), М. Гайнуллинның әлеге чорларны өйрәнүгә багышланган мәкаләләр циклы һәм «Каюм Насыйров и просветитель-

[1] *Галиева Э.Р.* Татар әдәбият белемендә культура-тарих мәктәбе. Казан: Фән, 2002. Б. 56–67.

[2] Галимҗан Нигъмәти: тормышы, фәнни-методик эшчәнлеге / Т.Ш. Гыйләҗев редакциясендә. Казан: Бриг, 2018. 252 б.

ское движение среди татар» (1955), шулай ук «Каюм Насыйри (1825–1945)» (тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары, 1948) кебек хезмәтләрнең дөнья күрүе татар мәгърифәтчелек хәрәкәте һәм шуңа бәйле мәгърифәтчелек әдәбияты буенча эзләнүләргә зур этәргеч бирә. Сугыштан соңгы елларда борынгы һәм урта гасырлар сүз сәнгате мирасына игътибар арта. Бу чорда «урта гасыр татар әдәбияты буенча тикшеренүләрне беренчеләрдән булып Б. Яфаров башлап җибәрә»[1] һәм, нәтиҗәдә, аның «Литература Камско-Волжских булгар в X–XIV веках и «Нахдж-ал-Фарадис» (1949) дигән тикшеренүе дөнья күрә. Я. Агишев, М. Гайнуллин, Г. Таһирҗанов, Г. Халит, Х. Хисмәтуллин һ.б.ның хезмәтләрендә Урта гасырлар, XIX йөз, XX йөз башы татар әдәбияты буенча җитди нәтиҗәләр ясала.

XX гасырның илленче елларында рухи-мәдәни тормыштагы җанлану сүз сәнгатенә, бигрәк тә аның тарихына игътибарны арттыра. Репрессияләнгән әдипләрнең (Г. Ибраһимов, К. Тинчурин, Ш. Усманов, Ф. Борнаш, Г. Рәхим, Г. Нигъмәти, М. Галәү һ.б.) мирасын халыкка кайтару буенча җитди чаралар күрелә. Алдагы елларда Борынгы һәм Урта гасырлар әдәбиятын текстологик һәм әдәби-эстетик планда тикшерүгә бәйле «Борынгы татар әдәбияты» (1963), Г. Таһирҗановның «Тарихтан – әдәбиятка» (1979), Н. Хисамовның «Поэма Кысса-и Йусуф Кул Али» (1979), «Олы язмышлы әсәр» (1984) китаплары һәм күпсанлы тикшеренүләрнең нәтиҗәсе буларак «Татар әдәбияты тарихы»ның беренче томы (1984) дөнья күрә. Монографияне әзерләүдә күпсанлы мәкаләләре белән катнашкан һәм аны редакцияләүгә зур көч куйган Ш. Абилов төрки дөньяда Борынгы һәм Урта гасырлар әдәбияты белгече булып танылa. Әлеге хезмәтләрдә дәвернең иҗтимагый-мәдәни мохите, татар әдәбиятының Шәрык дөньясы белән бәйләнеше, ислам дине һәм әдәбиятка мөнәсәбәте, әсәрләрдә дини-әхлакый һәм суфичыл карашларның чагылышы үзенчәлеге һ.б. тикшерелә.

XIX йөз әдәбиятын киң планда өйрәнүдә М. Гайнуллин эшчәнлеген билгеләп үтү кирәк. Аның «Татар әдәбияты. XIX йөз» (1957, 1968), «Татарская литература XIX века» (1975), «Татар әдәбияты тарихы»ның икенче томындагы мәкаләләре концептуаль нигезе, фәннилеге, фактик материалга бай булуы белән бүген дә кыйммәтен саклый. Я. Абдуллинның «Татарская просветительская мысль» (1976), Ә. Кәримуллинның «У истоков татарской книги» (1971), «Китап дөньясына сәяхәт» (1979), «Татарская книга пореформенной России» (1983), С. Михайлованың «Формирование и развитие просветительства среди татар Поволжья» (1972) кебек хезмәтләр сүз сәнгатенең иҗтимагый фикер, мәгариф, фән үсеше, китап басу мәсьәләләре белән тыгыз бәй-

[1] *Исламов Р.М.* Әдәбият гыйлемендә эзлебез // Мәдәни җомга. 2009. 23 октябрь, 30 октябрь.

ләнешен тикшерү ягыннан әһәмиятле. Аерым авторларның иҗат үзенчәлеге, жанрлар үсеше, сәнгать чаралары төрлелеге һ.б. мәсьәләләр М. Гайнуллин («Каюм Насыйри», 1975), Ф. Мусин («Чор белән аваздаш», 1983), И. Нуруллин («Реализм турында», 1974) җыентыкларында урын ала. Х. Миңнегулов һәм Ш. Садретдиновларның «XIX йөз татар хрестоматияләре» (1982), «XIX йөз татар әдәбияты ядкәрләре» (1982) хезмәтләре бу чор әдәбиятын өйрәнүдә җитди өлеш булып тора. М. Гайнетдиновның «Татар әдәбияты тарихы»ның икенче томында урын алган һәм вакытлы матбугатта басылып чыккан мәкаләләре, М. Госмановның текстологик һәм әдәби-эстетик тикшеренүләре, М. Әхмәтҗановның кульязма китапларны өйрәнүгә бәйле нәтиҗәләре – болар татар әдәбият белеменең казанышлары буларак бәяләнергә хаклы.

XX йөзнең беренче чиреге әдәбияты, 1960 еллардан башлап, махсус тикшеренүләр объекты булып тора һәм шул нисбәттән Х. Госманның «Бөек Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы чорында татар поэзиясе» (1960), «Социалистическая революция и татарская поэзия (1914–1930)», 1964), Г. Халитнең «Герои, рожденные революцией» (1967), «Проблемы творческого метода в татарской литературе (1905–1932)», 1968), «Шагыйрь. Чор. Герой» (1971), «Яңа гасыр поэзиясе» (1979), «Поэзия дерзаний: творчество Хади Такташа и вопросы метода, героя и стиля в татарской поэзии 20-х годов» (1980), И. Нуруллинның «XX йөз башы татар әдәбияты» (1966, 1982), «Путь к зрелости: Формирование и развитие критического реализма в татарской литературе» (1971), М. Гайнуллинның «Татарская литература и публицистика начала XX века» (1966), М. Хәсәновның «Галимҗан Ибраһимов» (1964), «Эволюция творчества Г. Ибрагимова в послеоктябрьский период» (1971), Р. Ганиеваның «Сатирическое творчество Тукая (1964)», Э. Нигъмәтуллинның «Татарская литература начала XX века (до 1917 г.) в ее отношении к западноевропейской литературе и философско-эстетической мысли» (1972), «Раздвигая века и границы: к вопросу о связах татарской литературы первой трети XX в. с литературами Западной Европы» (1977), М. Мәһдиевнең «Мәҗит Гафури (1880–1934). Тормышы һәм иҗат юлы турында кыскача очерк» (1980), «Фатих Әмирхан: тормышы һәм иҗат юлы турында кыскача очерк» (1986) кебек монографияләре, фәнни язмалары басылып чыга. Хезмәтләрдә әдәбият тарихын диахрон рәвештә генә түгел, бәлки синхрон система буларак та өйрәнү омтылышы ясала. Авторлар теоретик сорауларны калкытып куеп, моңа кадәр читтәрәк калып килгән мәсьәләләрне – иҗат методлары, Европа тибындагы романтизм үзенчәлекләре, модернизм һәм аның агымнары, инкыйлаблар һәм татар әдипләре һ.б.ны алгы планга куеп тикшерәләр.

XX гасырның беренче яртысында әдәбиятның үсеш-үзгәреш сыйфатлары, аерым алганда, социалистик реализм эстетикасы мәсьәләләре

Т. Галиуллинның «Дыхание времени: вопросы становления и развития социалистического реализма в татарской советской поэзии до 1941 года» (1979), А. Әхмәдуллинның «Татарская драматургия: истоки и формирование социалистического реализма» (1983) хезмәтләрендә яктыртыла.

Сугыш чоры әдәбияты, бигрәк тә М. Җәлил иҗаты 1960–1980 еллар әдәбият белемендә игътибар үзәгендә була. Г. Кашшаф, Р. Бикмөхәммәтов, В. Воздвиженский, Н. Юзиев, Р. Мостафин һ.б.ның тикшеренүләрендә герой-шагыйрь тормышы һәм аның шәхесенә бәйле татар әдәбияты тарихының мөһим бер чорына хас сыйфат-билгеләр ачыклана.

Әдәбият тарихының теге яки бу чоры үзенчәлекләре, аерым төр һәм жанрлар үсеш-үзгәреше, олы әдипләрнең иҗат дөньяларын ачу һ.б. мәсьәләләр Ш. Абилов, Н. Юзиев, Й. Нигъмәтуллина, М. Гайнетдинов, М. Госманов, Г. Халит, Х. Хәйри, Ф. Мусин, Р. Ганиева, Т. Галиуллин, А. Әхмәдуллин, Х. Миңнегулов, Н. Ханзафаров, Н. Хисамов, Ф. Хатипов, Н. Гыйззәтуллин, Ш. Садретдинов, О. Кадыйров, З. Рәмиев, Э. Нигъмәтуллин, Ә. Шәрипов һ.б.ның хезмәтләрендә төрле планда чагылыш таба.

Әлеге зур булмаган күзәтү татар әдәбияты тарихының, нигездә, хронологик тәртиптә өйрәнелүен күрсәтә. Рус әдәбият белемендә 1960 еллардан башлап әдәбият тарихын аерым әдәби юнәлешләр һәм агымнар, методлар үзгәрешенә нисбәтле өйрәнү шактый киң урын алса да, татар әдәбият белеменә ул авыр үтеп керә[1]. Шуның белән бергә, татар әдәбиятының эчке закончалыкларын ачу, мөһим тенденцияләрен билгеләү омтылышы һәм рус, дөнья әдәбият белеме йогынтысы татар әдәбияты тарихын билгеле бер методларга нигезләнеп өйрәнү кирәклеген көн тәртибенә куя. Й. Нигъмәтуллина билгеләп үткәнчә, 1920–1930 еллардагы фәнни эзләнүләр 1960 елларда профессор Х. Госман тарафыннан дәвам иттерелә. Ул үзенең остазлары тәҗрибәсен әдәбият фәненең яңа казанышлары белән бәйләп үстерергә алына. Ә инде 1970 еллардан башлап, Й. Нигъмәтуллина җитәкчелегендә әдәбият тарихын комплекслы өйрәнү буенча максатчан эшчәнлек башлана. Аның нәтиҗәләре галимәнең «Национальное своеобразие эстетического идеала» (1970), «Методология комплексного изучения художественного произведения» (1976), «Комплексный анализ художественного творчества» (1976) һ.б. хезмәтләрендә чагылыш таба. Эзләнүләрнең алдагы этабы булып әдәбиятны комплекслы анализлау юлын системалы метод белән кушу тора. Сүз сәнгате әсәрләрен системалы-комплекслы юл белән тикшереп бәяләүнең уңышлы үрнәге буларак, Н. Юзиевның «Шигырь гармониясе» (1972) һәм «Хәзерге татар поэтикасы» (1981) монографияләре дөнья күрә. Әдәбият тарихын өйрәнүне фәнни-теоретик нигезгә салу

[1] *Заһидуллина Д.Ф.* Дәресләрдә әдәби-тарихи күзаллау // Мәгариф. 2004. № 11. Б. 35–36.

омтылышларын Ф. Мусин болай күрсәтә: «Р.Бикмөхәммәтов фәнни тикшеренүендә чагыштыру методының ролен теоретик һәм практик планда нигезләде. Г. Халит, Ш. Абилов, Р. Ганиева, Ф. Мусин төп игътибарларын иҗат методын тарихи яссылыкта, аның теге яки бу дәвер әдәбиятында ничек гәүдәләнүен, метод белән стильнең үзара мөнәсәбәтләрен ачыклауга юнәлттеләр»[1].

Шулай итеп, XX йөз башында беренче фәнни нигезләре салына башлаудан алып 1980 еллар уртасына кадәр татар әдәбият белеме әдәбият тарихын өйрәнүнең билгеле бер системасын булдыра. Әдәбият фәне үсеш-үзгәрешендә төрле чорлар, югалту-табышлар булуга карамастан, күпгасырлык сүз сәнгатенең тулы картинасы эшләнеп, дәвер-этаплары, төп тенденцияләре, әйдәп баручы көчләре, сәнгати фикерләүгә бәйле формалашкан иҗат методлары, аерым юнәлеш-агымнар, сурәт чаралары байлыгы һ.б. ачыклана, халыкның рухи тормышындагы урыны, иҗтимагый фикер үсеше, мәдәният тарихы белән тыгыз бәйләнеше билгеләнә. Шуның белән бергә, сүз сәнгате тарихын бөтен тулылыгында ачу, фәнни-теоретик нигезле тикшеренүләрне арттыру, аеруча әдәби-тарихи барышка мөнәсәбәтле мәсьәләләрне көн тәртибенә кую киләчәк бурычы булып кала. Совет чорында марксистик-ленинчыл тәгълиматка нигезләнеп алып барылган тикшеренүләр, әдәбият тарихының аерым мәсьәләләре буенча ясалган нәтиҗәләр фикер каршылыклары, бәхәсләр уята. Болар барысы да татар әдәбият тарихын яңача өйрәнү, бәяләү кирәклеген, шуңа нисбәтле аның фәнни-теоретик һәм методологик нигезләрен яңарту, тулыландыру мәсьәләсен алгы планга чыгара. Бу эштә, Х. Миңнегулов язганча, «без үз элгәреләребезнең тикшеренүләрен, моңа кадәр язылган мәкалә-хезмәтләрне һәрчак искә алырга, аларга таянырга, ихтирамлы тәнкыйди мөнәсәбәттә торырга, элеккеге тәҗрибә-казанышларны яңа шартларда үстерергә, баетырга бурычлыбыз»[2].

Рус һәм дөнья әдәбият белеме буенча соңгы елларда дөнья күргән хезмәтләрдә әдәбияттагы төп тенденцияләрне күләмле тарихи-әдәби системалар эчендә карау күзәтелә. Алар икәү: берсе – диахрон системалар, ягъни әдәби процессны хронологик эзлеклелектә өйрәнү (мәдәни эра – әдәби дәвер, әдәбият үсешенең этабы – тарихи-әдәби чор). Мәсәлән, татар әдәбиятына мөнәсәбәттә болай күрсәтеп булыр иде: мәдәни эра – гомумтөрки һәм төрки-татар рухи-мәдәни мирасларына

[1] *Мусин Ф.М.* Әдәбият фәне һәм тәнкыйть // Татар әдәбияты тарихы: алты томда: VI т.: 60–90 еллар әдәбияты. Казан: Раннур, 2001. Б. 476–477.

[2] *Миңнегулов Х.Й.* Татар әдәбияты тарихын өйрәнүнең кайбер мәсьәләләре // Югары һәм урта һөнәри уку йортларында татар әдәбиятын укытуның мөһим мәсьәләләре (Г. Тукайның тууына 120 ел тулуга багышланган фәнни-гамәли конференция материаллары, 6–7 апрель, 2006 ел, Яр Чаллы). Казан: Казан ун-ты, 2006. Б. 10.

нигезләнгән күпгасырлык татар әдәбияты; әдәби дәвер – Яңа заман татар әдәбияты (XIX йөз урталарыннан башлап бүгенгегә кадәр); әдәби этап – Яңарыш әдәбияты (XIX йөз урталарыннан 1917 елга кадәр) яисә совет чоры (1917–1990 еллар); тарихи-әдәби чор – XX гасыр башы (1905–1917 еллар) яисә Бөек Ватан сугышы чоры (1941–1945 еллар). Икенчесе – синхрон системалар, ягъни әдәби процессны әдәбиятның эчке закончалыкларына бәйле барлыкка килгән төзелмәләргә (художественные образования) нигезләнеп өйрәнү (мәдәният тибы[1] – әдәби юнәлеш – әдәби агым – жанр һәм стильнең төп тенденцияләре). Мәсәлән, мәдәният тибы – мәдәниятнең семантик тибы (Урта гасыр әдәбияты); әдәби юнәлеш – романтизм яисә реализм; әдәби агым – мәгърифәтчелек реализмы яисә символизм. Югарыда аталган ике система арасында билгеле бер якынлык, үзара керешү дә бар. Әйтик, тарихи-әдәби чорны өйрәнгәндә алгы планга жанр һәм стиль мәсьәләләре чыкса, зур чорларны тикшергәндә әдәби юнәлешләр, агымнар белән эш итү уңайлырак.

Ә инде теоретик мәсьәләләргә килгәндә, беренче чиратта, шәхес концепциясе алга чыга. Нәкъ менә кешенең асылы, үз-үзенә, башкаларга, җәмгыятькә, табигатькә, метафизик феноменнарга (үлемгә, Аллага, Мәңгелеккә һ.б.га) мөнәсәбәтендә чорның социаль, сәяси, идеологик үзенчәлекләре чагыла һәм ул, билгеле инде, герой образына, конфликт характерына, поэтикага, гомумән, әдәби процесска йогынты ясый. Әдәби үсешкә тәэсир итүче икенче «инструмент» – иҗат методы, стиль, жанр. Аларның үзара бәйләнеше әдәби системаның структур нигезен билгели.

Татар әдәбият белемендә әдәбият тарихын өйрәнгәндә диахроник системага, ягъни әдәби процессны хронологик эзлеклелектә өйрәнүгә өстенлек бирелә. Безгә яхшы таныш булган «Татар әдәбияты тарихы»ның алты томлыгы да асылда шуңа нигезләнә. Әдәбият тарихының төрле чорларына караган хезмәтләрдә дә[2] без әлеге тенденцияне күрәбез. Дөрес, теге яки бу әдәби чорда өстенлек иткән сәнгати фикерләү тибына яисә әдипләрнең иҗат үзенчәлегенә нисбәтле әдәби юнәлеш, әдәби агым, иҗат методы, поэтика мәсьәләләре дә игътибардан читтә калмый. Әлеге мәсьәләләрне беренчеләрдән булып танылган әдәбият галиме Г. Халит тикшерүгә

---

[1] Й. Нигъмәтуллина монографиясендә, Ю. Лотман һәм Ю. Степанов фикерләренә таянып, мәдәният тибының төп ике төрен аерып чыгара: семантик (кешенең әйләнә-тирәсен символлаштырып күзаллау) һәм синтаксик (бөрәмлекне гомумилекнең бер өлеше итеп карау). Болардан тыш, башка төрләрне һәм төркемнәрне аерып чыгару да күзәтелә. Бу турыда тулырак мәгълүматны кара: *Нигматуллина Ю.Г.* Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. Казань: Фэн, 1997. С. 5–22.

[2] Борынгы татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. 576 б.; *Гайнуллин М.Х.* Татарская литература XIX века. Казань: Татар. кн. изд-во., 1975. 307 с.; *Нуруллин И.З.* XX йөз башы татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. 288 б. һ.б.

алына[1]. Профессор И. Нуруллин исә, XX йөз башында татар әдәбиятында мәгърифәтчелек һәм тәнкыйди реализмның, шулай ук Европа тибындагы романтизмның эчке хасиятләрен ачу белән бергә, аерым авторлар иҗатында модернизмга хас алым-чаралар урын алуын, татар әдипләренең әлеге иҗат юнәлешен дә кире какмауларын билгели[2]. XIX йөз әдәбиятын өйрәнгән М. Гайнуллин, М. Гайнетдинов, Х. Миңнегулов һ.б. галимнәр мәгърифәтчелек реализмының асылын, әдәби-эстетик принципларын төрле яклап ачалар[3]. Т. Галиуллин, А. Әхмәдуллин, Ф. Хатипов, Ф. Мусин, Н. Хисамов монографияләрендә поэтика мәсьәләләре җитди урын алып тора. Татар әдәбият белемендә әдәбият тарихының аерым чорларын яисә әдипләр иҗатын әдәбиятның эчке закончалыкларына бәйле сәнгати фикерләү тибын, әдәби юнәлеш һәм агым сыйфатларын алгы планга чыгарып тикшерү үрнәкләре дә дөнья күрә. Бу өлкәдә Г. Халит һәм Й. Нигъмәтуллина хезмәтләре зур әһәмияткә ия.

Татар әдәбиятында гарәп-фарсы, төрек, рус-Европа әдәбиятлары традицияләре һәм үзара бәйләнешләр мәсьәләләре Р. Ганиева тикшеренүләре үзәгендә тора. Ул шулай ук Борынгы һәм Урта гасырлар, бигрәк тә XX йөз башы татар әдәбиятын фәлсәфи-эстетик планда тикшерә. Соңгысын Яңарыш чоры буларак бәяләп, татар әдәбиятының, Шәрык белән бергә, рус һәм Европа әдәби-фәлсәфи фикере казанышларын да үзләштерүен дәлилли. XX гасыр башы татар әдипләренең иҗат эволюциясен реалистик һәм романтик тенденцияләргә, импрессионизм, экспрессионизм, символизм кебек модернистик агымнарга нисбәтле өйрәнеп, яңа җитди эзләнүләргә юл сала[4].

[1] *Халит Г.М.* Кешегә һәм чынлыкка мәхәббәт белән. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. 375 б.; *Халит Г.М.* Яңа гасыр поэзиясе: XX йөз башы (1905–1917 еллар) татар поэзиясендә иҗат методы, лирик герой, традиция һәм новаторлык мәсьәләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 166 б.; *Халит Г.М.* Портреты и проблемы. Казань: Татар. кн. изд-во, 1985. 344 с.; *Халит Г.М.* Поэзия дерзаний: творчество Хади Такташа и вопросы метода, героя и стиля в татарской поэзии 20-х годов. Казань: Татар. кн. изд-во, 1980. 258 с.

[2] *Нуруллин И.З.* XX йөз башы татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. Б. 131–138; 236–260.

[3] *Гайнуллин М.Х.* Татар әдәбияты. XIX йөз. Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. 687 б.; *Гайнуллин М.Х.* Татарская литература XIX века. Казань: Татар. кн. изд-во., 1975. 307 с.; *Гайнетдинов М.В.* Татарская литература XIX века (Идейно-художественный генезис и исторические судьбы): дис. в виде научного доклада ... докт. филол. наук. Казань, 2000. 101 с.; *Миңнегулов Х.Й.* Гасырлар өнен тыңлап... Казан: Мәгариф, 2003. 335 б.; *Миңнегулов Х.Й.* Дөньяда сүземез бар... Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 336 б. һ.б.

[4] *Ганиева Р.К.* Тукайның иҗат методы (романтик тенденцияләр эволюциясенә карата) // Татар әдәбияты мәсьәләләре. Казан, 1972. Б. 51–72.; *Ганиева Р.К.* Проблемы творческих методов в тюркоязычных литературах начала XX века. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1973. Ч. 1. 28 с.; *Ганиева Р.К.* Проблемы творческих методов в тюркоязычных литературах начала XX века. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1976. Ч. 2. 26 с.; *Ганиева Р.К.* Төрки әдәбиятларда иҗат методы мәсьәләләре // Хәзерге татар әдәбият белеменең актуаль мәсьәләләре. Казан, 1979. Б. 97–105. һ.б.

Җәмгыятьнең төрле өлкәләрендәге җитди үзгәрешләр йогынтысында, татар әдәбият тарихын өйрәнүдә яңа этап башланып, әдәбият белеме, үзенең традицияләренә, тупланып килгән казанышларына таянган хәлдә, дөньякүләм сүз сәнгате тарихы яңалыкларына йөз белән борылып, яңача өйрәнүнең фәнни-теоретик нигезләрен эзләү, шуларга таяну юлына чыга. Бу күренешнең бөтен филология фәненә хас булуын билгеләп үтәргә кирәк[1]. Сүз сәнгате тарихын өйрәнүнең теоретик һәм методологик мәсьәләләренә беренчеләрдән булып А. Әхмәдуллин, М. Хәсәнов, Ф. Мусин, Т. Галиуллин, Н. Хисамов, Х. Миңнегулов һ.б. мөрәҗәгать итә.

Татар әдәбият белеменең нигез проблемалары М. Хәсәновның «Татар әдәбияты тарихын өйрәнүнең кайбер методологик мәсьәләләре» дигән хезмәтендә аеруча тулы һәм эзлекле рәвештә чагылыш таба. Җәмгыятьтәге үзгәртеп коруларга бәйле, «эстетиканың һәм мәдәният теориясенең бик мөһим, фундаменталь нигезләмәләре, милли мәдәниятнең, әдәбият һәм сәнгатьнең тормыштагы, халык язмышындагы роле, миллилек һәм интернациональлек төшенчәләренең мәдәнияттә, сәнгатьтә, гомумән рухи тормышта үзара мөнәсәбәте мәсьәләләре яңадан карала, тарих фактларына, мәдәният күренешләренә, милли мираска бәя биргәндә ясалган хаталар, гаделсезлекләр төзәтелә, тарихи шәхесләрнең, язучыларның, сәнгать ияләренең, аерым талантларның урыны һәм роле ачыклана»[2], дип билгели ул. Әдәбият фәне алдында торган бурычларны ачыклау аша сүз сәнгате тарихын өйрәнүнең түбәндәге төп принципларын һәм мәсьәләләрен аерып чыгара: 1) әдәбиятны сәясәткә иллюстрация рәвешендә түгел, бәлки дөньяны образлы танып белү объекты буларак һәм эчке үсеш закончалыкларына нигезле өйрәнү; 2) милли әдәбият төшенчәсен ачыклау һәм әдәбиятны милли үзенчәлекле, хасиятле сәнгать буларак тикшерү, ягъни алгы планга миллилек һәм тарихилык принципларын кую; 3) әдәби чыганакларның фактик базасын киңәйтү һәм тирәнәйтү, ягъни әдәби мирасны бөтен тулылыгында күз алдына китерү; 4) татар әдәбиятына, иҗтимагый фикер үсешенә ислам дине тәэсирен ачу, күп гасырлар дәвамында аларның үзара бәйләнешбагланышын билгеләү; 5) төрле чорлар һәм дәверләр әдәбиятын үзара бәйләнештә һәм күчемлелектә тикшереп бәяләү; 6) Октябрьгә кадәрге әдәбиятта милли азатлык һәм сыйнфый көрәш мәсьәләләре чагылышын, аларның үзара мөнәсәбәтен өйрәнү; 7) татар әдәбиятының СССР да, хәзер исә Россия халыклары һәм дөнья әдәбияты тарихында тоткан урынын билгеләү; 8) татар әдәбиятының, бер яктан, Көнчыгыш, төрки

[1] *Богаткина М.Г.* Теория литературы: формирование новой научной парадигмы: учебное пособие. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2007. С. 14.

[2] *Хәсәнов М.* Татар әдәбияты тарихын өйрәнүнең кайбер методологик мәсьәләләре // Казан утлары. 1992. № 1. Б. 141.

халыклар, гарәп һәм фарсы әдәбиятлары белән булган тарихи-әдәби багланышын, икенче яктан, рус-Европа әдәби-эстетик фикерләрен үзләштерүен бөтен тулылыгында һәм объектив чагылдыру һ.б.[1]

Татар әдәбияты тарихын өйрәнүнең М. Хәсәнов билгеләгән төп принциплары, сорау-мәсьәләләре алдагы елларда төрле яктан баетыла, тулыландырыла. А. Әхмәдуллин «Татар совет драматургиясен яңача өйрәнү мәсьәләләре» дигән мәкаләсендә татар әдәбияты, аерым алганда драматургия тарихын бөтен тулылыгында, «ак тапларсыз» тикшерүне (беренче чиратта, Г. Исхакый әсәрләре белән баетылган хәлдә) алга куя[2]. Ә инде «Татар драматургиясе тарихын өйрәнү мәсьәләләре» язмасында драматургия тарихына бәйле тема-жанр өлкәсендәге, сәнгатьчә сурәтләү алымнарына бәйле казанышларны күрсәтү белән бергә, алдагы тикшеренүләр өчен җитди мәсьәләләр күтәрә: үзебездәге сәхнә әдәбияты белән чит илләрдә иҗат ителгән пьесаларның (Г. Исхакый, Х. Хәмидулла һ.б.) әдәби-эстетик бәйләнешен ачу; совет чорында трагедия жанрының уңышларга ирешмәү һәм сатирик комедиянең төссезләнү сәбәпләре; психологик драманың XX йөз башы югарылыгыннан әллә ни күтәрелә алмавы; аерым тема-проблемаларның артык күпертелүе; Шәрык традицияләре дәвамчанлыгы; шәхес концепциясен аңлауда һәм сәнгати чагылдыруда берьяклылык һ.б.[3] Ә инде «Татар әдәбияты тарихын өйрәнүнең кайбер нәзарый-методологик принциплары» дигән мәкаләсендә алдагы фикерләрен тагы да үстерә. А. Әхмәдуллин – тарихы мең елдан артып киткән әдәбиятыбызның үсеш-үзгәреш этапларын, аңа йогынты ясаган фәлсәфи-эстетик карашларны, халык тормышы белән тыгыз бәйләнешен, традиция һәм яңачалыкларның үзара мөнәсәбәтен, әдәби әсәрне анализлау критерийларын бары тик ныклы теоретик һәм методологик принципларга таянып кына объектив ачыклап була, дигән фикер тарафдары. Аның фикеренчә, октябрь инкыйлабына кадәрге әдәбиятыбызны ислам фәлсәфәсе ноктасыннан карап кына аңлап була. Гомумән, әдәбият үсешенең төп тенденцияләрен билгеләгәндә, аерым әдипләр иҗатына бәя биргәндә милли мәнфәгать чагылышы һәм гомумкешелек кыйммәтләре нигез булырга тиеш, дип саный автор.

Т. Галиуллин XX гасыр ахыры әдәбият белемендә сүз сәнгате тарихын бәяләүдәге яңарышның төп асылын болай билгели: «Әдәби үткәнне бары тик сыйнфый көрәш күзлегеннән бәяләү алымыннан баш тартып, бөтенкешелеккә хас шәфкатьле, игелекле кыйммәтләргә таяну, шуларны нигез, өлге итеп алу». Шул нигездә ул 1917 елга кадәрге

---

[1] Шунда ук. Б. 141–147.

[2] *Әхмәдуллин А.Г.* Татар совет драматургиясен яңача өйрәнү мәсьәләләре // Дөреслеккә ирешү юлында. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. Б. 7–19.

[3] *Әхмәдуллин А.Г.* Татар драматургиясе тарихын өйрәнү мәсьәләләре // Офыклар киңәйгәндә. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. Б. 7–16.

әдәбият белән совет чоры сүз сәнгатен рухи уртаклык, эчке кануннар берлеге нигезендә өйрәнүне яклап чыга. Әдәбият тарихын бәяләү әдәбият фәне өлкәсендә эшләүчеләрнең әзерлеге, дөньяга карашы, шәхси позициясе белән тыгыз бәйле. Т. Галиуллин фикеренчә, галим-тәнкыйтьчеләрнең озак еллар дәвамында калыплашкан фикерләрдән арынып, карашлар төрлелегенә омтылуы, әсәрләргә сәяси-җәмгыяви күзлектән чыгып кына бәя бирүдән арынуы сүз сәнгате булган әдәбиятны бөтен тулылыгында ачу мөмкинлеге бирә[1].

Әдәбият тарихын фәнни-теоретик нигездә өйрәнү мәсьәләләренә аеруча күп мөрәҗәгать иткән галимнәрнең берсе – Ф. Мусин. Аның берфер артлы диярлек басылып чыккан мәкаләләрендә әдәбият тарихына, аны чорларга бүлү, әдәби юнәлеш һәм агымнар үсеш-үзгәрешенә, аерым әдипләр иҗатының тарихтагы урынын билгеләүгә кагылышлы мәсьәләләр теге яки бу дәрәҗәдә чагылыш таба[2]. Тикшеренүләренең төп асылын һәм юнәлешен Ф. Мусин «Вакыт үзе куя бәһане» мәкаләсендә тагын бер кат ачыклый, тулыландыра, системага сала. Әдәбият тарихын яңача өйрәнүнең фәнни максатын билгеләп болай дип яза: «Хәзер әлеге тарихны күбрәк үткәндәге идеологик чикләүләрдән һәм бәяләрдән арынып, ниһаять, реаль барлыгында күрсәтү күздә тотыла». Аеруча күп бәхәсләр, фикер каршылыклары тудырган XX гасыр татар әдәбияты тарихын язганда бөтен дөньяга таралган милләттәшләребезнең милли-рухи ихтыяҗлары исәпкә алынырга тиеш, дип саный ул. Ә инде әдәбият тарихын өйрәнүгә заман куйган төп таләп итеп, узган гасыр әдәбиятын милли аң-белем һәм тәрбия чарасы буларак тануны һәм фән тарафыннан милли юнәлештә тикшерелергә тиешлекне билгели. Ф. Мусин фикеренчә, төп методологик принциплар рәвешендә тарихилык һәм миллилек алгы планга чыгарга тиеш[3].

Н. Хисамов «Яңача фикерләү һәм татар әдәбияты тарихы концепциясе» язмасында озак вакытлар дәвамында идеологик стереотиплар әдәби-тарихи күренешләргә бәя биргәндә сыйнфый якын килүне таләп итеп, әсәрләрдәге дөньяви эчтәлек кенә кыйммәткә ия дигән фикергә китерде, шуның аркасында Октябрьгә кадәрге әдәбиятның шактый өлеше игътибардан төшеп калды, дип билгели. Әдәби мирасны яңартып өйрәнүнең магистраль юлын галим түбәндәгеләрдә күрә: беренчедән, «әдәби дәверләр күпкырлы идея-эстетик эзләнүләрдән торган, эзлекле, кануниятле һәм бердәм процесс рәвешендә яктыртылырга тиеш. Ул

---

[1] *Галиуллин Т.Н.* Татар поэзиясе тарихын яңача өйрәнү мәсьәләләре // Шигърият баскычлары. Казан: Мәгариф, 2002. Б. 9–19.

[2] *Мусин Ф.М.* Әдәби хәрәкәт // Мирас. 1996. № 5–6. Б. 104–124; *Мусин Ф.М.* Әдәбиятны ничек өйрәнергә? // Мәдәни җомга. 1995. 22 декабрь; *Мусин Ф.М.* Әдәбият фәне һәм тәнкыйть // Мирас.1996. № 12. Б. 38–47.

[3] *Мусин Ф.М.* Вакыт үзе куя бәһане // Мәдәни җомга. 2004. 7 май.

аерым күренеш һәм ядкәрләрнең бер-бер артлы тезелгән эзлекле гади хронологик чылбыры гына булмаска тиеш»; икенчедән, «әдәбият үсешен дөньяви һәм дини-рухани эчтәлекнең бердәмлеге рәвешендә тикшерергә кирәк»; өченчедән, әдәби күренешләрне объектив-тарихи бәяләү, ягъни «әдәбият тарихының борынгы катламнарын тикшергәндә аларны безнең заманга хас сыйфатлар тагудан, ә яңа чор әдәбиятын анализлаганда субъективлыктан һәм дәшми узудан качарга» тиешбез[1].

Татар әдәбияты тарихының аерым чорларына, автор-әсәрләренә, өйрәнү принципларына, бәяләү критерийларына әдәбият белеме казанышлары биеклегеннән һәм, заман таләбе буларак, караш-мөнәсәбәтләр чагылышы ягыннан Х. Миңнегулов мәкаләләре дә аерым игътибарга лаек. Автор әлеге мөһим мәсьәләләрне татар әдәбиятын урта мәктәптә һәм югары уку йортында өйрәнү, шулай ук халыкның рухи тормышындагы урыны, милли яшәеш чагылышы белән тыгыз бәйләнештә карый. Җитди методологик мәсьәлә буларак, фәнни тикшеренүләрдә үзебезнең табышлар тиешенчә өйрәнелмичә «күпьеллык гыйльми мирасны санга сукмыйча, башкалардагы фәнни хезмәтләр, фикер-күзәтүләр, «измнар», чит-ят термин-атамалар белән кирәгеннән артык мавыгу, алардагы «ачыш-казаныш»ларны безнең филология фәненә механик рәвештә күчерүгә омтылыш» көчәюен билгели. Икенче бер җитди мәсьәлә итеп Х. Миңнегулов башка халыклар әдәбияты белән булган бәйләнешләрне өйрәнгәндә чорның иҗтимагый-мәдәни шартларын, әдәбиятның торышын һәм, иң мөһиме, «типологик хосусиятне күз уңыннан ычкындырырга ярамавын» искәртә. Галим фикеренчә, әдәбият тарихын, аерым алганда, чорларга бүленеш, традиция һәм новаторлык, жанрлар системасы, тел-стиль мәсьәләләрен тикшергәндә миллилек һәм тарихилык принцибы, сүз сәнгатенең эчке хосусиятләре, шулай ук тышкы факторлар, иҗтимагый-социаль көчләр һ.б. үзәктә торырга тиеш. Тишеренүчеләр күз уңында тоткан мәсьәләләр арасында әдәбият тарихын бөтен тулыгында, объектив өйрәнү дә бар. Ул исә, бер яктан, борынгы ядкәрләрне кайтару, текстология эшен көчәйтү белән бәйле булса, икенче яктан, чит илләрдәге татар әдәбияты үрнәкләрен киң катлам укучыларга җиткерү, фәнни әйләнешкә кертүгә килеп тоташа. Авторның XIX йөз һәм XX йөз башы әдәбиятында мәктәп-мәдрәсәләрне, дин әһелләрен тәнкыйтьләгән, шулай ук татар хатын-кызын хокуксыз итеп сурәтләгән әсәрләргә иҗтимагый-мәдәни шартларны исәпкә алып якын килүне искәрткән фикерләре дә зур кызыксыну уята[2].

[1] *Хисамов Н.Ш.* Яңача фикерләү һәм татар әдәбияты тарихы концепциясе // Хәтер сагында. Казан: Мәгариф, 2004. Б. 9–12.

[2] *Миңнегулов Х.Й.* Урта гасырлар татар әдәбияты: нәтиҗәләр, бурычлар // Дөньяда сүземез бар... Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. Б. 8–25; Мөнәсәбәтебезне ачык белдерик // Мәдәни җомга. 2006. 1 сентябрь; *Миңнегулов Х.Й.* Татар әдәбияты тарихын өйрәнүнең кайбер мәсьәләләре // Югары һәм урта һөнәри уку йортларында татар әдәбиятын укытуның мөһим мәсьәләләре. Казан: Казан дәүләт университеты, 2006. Б. 10–13.

XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы әдәбият фәнендә сүз сәнгате тарихын өйрәнүдә яңа фәнни-теоретик карашлар формалашу мәсьәләсе Й. Нигъмәтуллина, А. Саяпова, Д. Заһидуллина, Х. Миңнегулов, Ә. Закирҗанов, Ч. Зарипова-Четин, А. Шәмсутова һ.б.ның хезмәтләрендә чагылыш таба. Аларны түбәндәгечә гомумиләштерергә мөмкин: 1) татар әдәбияты бөтендөнья әдәбиятының бер өлеше, ул төрле әдәбиятлардагы казанышларны милли үзенчәлекләр белән тыгыз бәйләнештә үзләштерә һәм байый; 2) татар сүз сәнгатен әдәбият фәне казанышларына нигезләнеп өйрәнү, аның яңадан-яңа агымнарга нисбәтле сыйфат-билгеләрен, эзләнү юнәлешләрен ачу мөмкинлеге бирә; 3) яңарыш дәвере булган XX йөз башы әдәбияты, Шәрык һәм Гареб әдәби-эстетик фикере синтезы рәвешендә, реализм, романтизм һәм модернизм юнәлешләренең үзенчәлекле агымнарына иркен мөрәҗәгать итә һәм җитди казанышларга ирешә. Аларны барлау, әдәби әйләнешкә кертү, фәнни нәтиҗәләр ясау әле башлангыч этабында гына, бу эшнең алга таба дәвам итәргә тиешлеге бәхәс уятмый. Татар әдәбияты тарихын өйрәнүгә нисбәтле, Д. Заһидуллина өч мәсьәләне аерып чыгара: методология проблемасы; әдәбият тарихын өйрәнү методикасы; татар әдәбиятының дөнья әдәби мохитендәге урынын билгеләү[1]. Ә инде әдәбият тарихын өйрәнүнең җитди методологик мәсьәләсе итеп, галимә татар әдәбиятын өйрәнүгә синхрон планда якын килү кирәклеген ассызыклый.

Шулай итеп, әдәбият белемендә барган фикер алышуларда татар әдәбияты тарихын өйрәнүнең фәнни-теоретик һәм методологик нигезләре һәм алда торган мөһим сорау-мәсьәләләрнең асылы шактый тулы ачыклана. Яңа караш буларак сүз алып бару мөмкинлеге биргән әлеге система, бер яктан, марксизм-ленинизм фәлсәфәсенә нигезләнгән методологиянең берьяклы карашларыннан баш тартуны аңлатса, икенче яктан, үткән чорларда тулы калыплашкан эзлеклелек, бердәмлек, объективлык, системалылык кебек принциплардан иркен файдалана, өченчедән, әдәбият тарихын өйрәнүнең үзәген тәшкил иткән тарихилык һәм миллилек принциплары, тышкы һәм эчке факторлар йогынтысында җитди сыйфат үзгәрешләре кичерә, дүртенчедән, Шәрык һәм Гареб әдәбиятларының тирән йогынтысын тойган хәлдә, татар әдәбияты тарихын эчке сыйфат үзгәрешләре нигезендә хәрәкәт итүче, үзенә генә хас сыйфат-билгеләре булган күренеш итеп аңлау һәм бәяләү алга чыга; бишенчедән, әдәбиятның җәмгыятьтәге урыны үзгәрү, шулай ук фәндә яңа терминнар һәм төшенчәләрнең кулланышка керүе, аны сәнгать төре буларак аңлауга, кабул итүгә, бәяләүгә тәэсир итә.

---

[1] *Загидуллина Д.Ф.* Изучение истории татарской литературы в XXI веке // Татарская культура в контексте европейской цивилизации: материалы международной научной конференции. Казань: Ихлас, 2010. С. 9.

### 3.2. Әдәбият тарихын чорларга бүлү мәсьәләсе

Әдәбият тарихын заман таләпләреннән чыгып өйрәнү мәсьәләсендә җитди сорауларның берсе булып аны чорларга бүлү тора. Ул исә, әдәбият тарихының үсеш-үзгәрешен билгеләү белән бергә, халыкның сүз сәнгатендә чагылган иҗтимагый яшәешен, дөньяга карашын, фәлсәфәсен тулырак аңларга ярдәм итә. Х. Миңнегулов әдәбият тарихын чорларга бүлүнең түбәндәге принципларын аерып чыгара: иҗтимагый-икътисади; хронологик принцип; сәяси-дәүләти; тарихи-әдәби; династияле принцип; дини принцип; тел принцибы; язу графикасы буенча; әдәбиятның төрләргә, юнәлешләргә, агымнарга, методларга бүленеше буенча; мәдәни-интеллектуаль бергәлекләр буенча; әдәби-иҗади мәктәпләр, түгәрәкләр, берләшмәләр буенча; тематик принцип; классик принцип; генетик принцип; биологик принцип һ.б.[1] Әдәбият кебек катлаулы күренеш әлеге принципларга гына сыеп бетми, шуның өстенә һәр халык әдәбиятының үзенә хас күптөрле үзенчәлекләре, үсешенең объектив һәм субъектив сәбәпләре урын ала.

XX йөз башында дөнья күргән хезмәтләрдә аерым авторларны татар әдәбияты тарихының теге яки бу чорына нисбәтле өйрәнүләр булса да, сүз сәнгате тарихын чорларга бүлү мәсьәләсе киң планда 1920–1930 елларда куела. Бу уңайдан Э. Галиева болай дип яза: «20–30 нчы елларда татар әдәбият белемендә периодизация – методологик әһәмияткә ия булган проблемаларның берсе, алай гына да түгел, безнең карашыбызча, әдәбият турындагы фәннең иң мөһим, төп проблемаларыннан берсе булып торды, чөнки ул әдәбият тарихын билгеле бер тәртипкә салып чыгу белән генә чикләнеп калмыйча, әдәби процесс концепциясенең чагылышын да күрсәтеп тора иде»[2]. Фикер көрәше татар әдәбияты тарихын дәверләргә бүлү буенча Җ. Вәлиди, Г. Сәгъди һәм Г. Ибраһимов тәкъдим иткән юлларга нисбәтле бара. Җ. Вәлиди «Очерк истории образованности и литературы татар (до революции 1917 года)» хезмәтендә чорларга бүленеш мәсьәләсен махсус тикшермәсә дә, әдәбиятның үсешенә бәйле күзәтүләрендә ике чорны аерып куя: берсе, борынгыдан алып XIX йөз урталарына кадәр булып, иске әдәбият – кадими әдәбият рәвешендә бирелә, икенчесе, уяну хәрәкәте буларак, XIX йөз урталарыннан башланып, яңа әдәбият – җәдиди әдәбият рәвешендә тәкъдим ителә[3]. Татар әдәбияты тарихы, аның чор-дәверләргә бүленеше мәсьәләләрен Г. Ибраһимов махсус хезмәтләрендә

---

[1] *Миннегулдов Х.Ю.* Этапы развития тюрко-татарской, античной и русской литератур. Казань: Ихлас, 2014. С. 7–23.

[2] *Галиева Э.Р.* Татар әдәбият белемендә культура-тарих мәктәбе. Казан: Фән, 2002. Б. 91.

[3] *Валидов Дж.* Очерк истории образованности и литературы татар. Казань, 1998. 159 с.

күтәрә[1]. Ул «татар әдәбиятының өч дәвере камил ачылып җитте» дип саный һәм аны түбәндәгечә күрсәтә: «Беренче дәвер – кадим әдәбият». Әдип бу чорга караган әсәрләрне югары бәяли: «безнең әдәбиятыбыз тарихында мәңге онытылмый торган кадерле җәүһәрләребез». «Икенче дәвер – җәдит әдәбият (...). Әһәмияте, кәгъбәсе: иске, каткан кадимлекне җимереп, (буржуазный) Европа мәдәниятен, бөтен капитализмны, эксплуатациясе, икътисади тигезсезлеге белән бергә, бөтен көенчә татар дөньясына кертү, кыскача әйткәндә, бездә мәдәни капитализмны җирләштерергә тырышу (...). Өченче дәвер (...). Февраль моңа юл ача. Октябрь аякка басарга ярдәм итә. (...) Монда төп рух – сыйнфый көрәш аңа кушыла; бер яктан, коллективизм рухы, икенче яктан, материализм нигезләре. Бу коллективизм, материализм нигезендәге авыр, канлы сыйнфый көрәш эчендә күтәрелгән нур – алдагы якты коммунизм кәгъбәсенә таба бара»[2]. Әлеге мәсьәлә уңаеннан Г. Газиз һәм Г. Рәхим карашлары да кызыклы. Алар урта гасырлар әдәбиятын XIX йөз ахырына кадәр дәвам итә дип саныйлар һәм шул әдәбият эчендә XVIII йөз ахырларыннан башлап Яңа заман әдәбияты формалаша башлавын искәртәләр[3]. Г. Сәгъди мондый бүленешне күрсәтә: 1) борынгы дәвер, 2) караңгылык дәвере, 3) уяну дәвере, 4) милли хәрәкәт дәвере, 5) социализм-коммунизм дәвере. Моңа аңлатма да бирә: Казан алынып, татарлар туздырылганчы булган дәвер – «борынгы», XIX йөзнең икенче яртысына кадәрге дәвер – «караңгылык», 1905 елгача булган дәвер – «уяну», аннан Октябрьгәчә булганы – «милли буржуазия хәрәкәте дәвере», Октябрьдән соңгы дәвер – «социализм-коммунизм»[4]. 1920 елларда әдәбият галимнәренең күпчелеге Г. Ибраһимов тәкъдимен яклый. Г. Сәгъди дә соңрак язылган хезмәтләрендә Г. Ибраһимов юлыннан китә. «Татар әдәбиятын чорларга бүлү мәсьәләсен көнүзәк проблема буларак» киң җәмәгатьчелек алдына куюы белән гаять мөһим эзләнүләргә юл салса да, – дип билгеләп үтә Ч. Гыйлаҗева, – Г. Ибраһимовның аерым карашлары бәхәсле булып, аның иҗтимагый-икътисади формацияләрне төп бизмән итеп алуы белән аңлатыла[5].

Әдәбият тарихының чорларга бу рәвешле бүленеше югары уку йортлары һәм мәктәп дәреслекләренә дә үтеп кереп, озак вакыт саклана.

---

[1] *Ибраһимов Г.* Татарның соңгы тарихында өч дәвер (эпоха) // Милләт. Тел. Әдәбият: Сайланма хезмәтләр. Казан: Мәгариф, 2007. Б. 127–131; *Ибраһимов Г.* Татар әдәбиятында өченче дәвер // Милләт. Тел. Әдәбият: Сайланма хезмәтләр. Казан: Мәгариф, 2007. Б. 132–136.

[2] *Ибраһимов Г.* Татарның соңгы тарихында өч дәвер (эпоха) // Милләт. Тел. Әдәбият: Сайланма хезмәтләр. Казан: Мәгариф, 2007. Б. 127–131.

[3] *Азизова Г.А.* Вопросы истории татарской литературы в трудах Гали Рахима: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2001. 21 с.

[4] *Галиева Э.Р.* Татар әдәбият белемендә культура-тарих мәктәбе. Казан: Фән, 2002. Б. 91–92.

[5] *Гыйлаҗева Ч.М.* Г. Ибраһимов иҗатында татар әдәбиятын чорларга бүлү мәсьәләсе // Фәнни язмалар – 2001. Казан: Школа, 2002. Б. 214–218.

Бары 1963 елда дөнья күргән «Борынгы татар әдәбияты» китабында гына ул конкретлаштырыла. Аерым алганда, борынгы һәм урта гасырлар әдәбиятын «VIII–XIII йөзләр», «XIII–XV йөзләр», «XV йөзнең икенче яртысы – XVI йөзнең беренче яртысы», «XVI–XVIII йөзләр» кебек чорларга бүлеп өйрәнү күздә тотыла[1]. Ә инде «Татар әдәбияты тарихы»ның 1 нче томы мондый бүленешкә нигезләнә:

– Болгар чоры әдәбияты (IX–XIII йөзләр);
– XIII йөз уртасы – XV йөз башы әдәбияты;
– XV–XVI йөзләрдә татар әдәбияты;
– XVII йөз татар әдәбияты;
– XVIII йөз татар әдәбияты[2].

Алдагы елларда ул тагы да камилләшеп, түбәндәге формада мәктәп һәм югары уку йортлары дәреслекләрендә урын ала:

– Борынгы һәм урта гасырлар татар әдәбияты (V–XVIII йөзләр);
– XIX йөз әдәбияты;
– XX йөз башы әдәбияты;
– 1917 елдан соңгы әдәбият (үз эчендә берничә этапка бүленә).

Киң планда караганда, «Татар әдәбияты тарихы»ның алты томлыгы әлеге бүленешкә нигезләнеп төзелгән: 1 нче том – Урта гасырлар дәвере; 2 нче том – XIX йөз әдәбияты; 3 нче том – XX гасыр башы әдәбияты; 4 нче том – татар совет әдәбияты (1917–1941); 5 нче том – Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы еллар әдәбияты (1941–1960); 6 нчы том – 60–90 нчы еллар әдәбияты[3].

Әдәбият халык тормышы белән тыгыз бәйләнештә яши, үсешүзгәреш кичерә. Җәмгыятьтәге тарихи-сәяси вакыйгалар, иҗтимагыймәдәни хәл-күренешләр сүз сәнгатендә теге яки бу дәрәҗәдә гәүдәләнеш таба. Халыкның рухи тормышы елъязмасы буларак әдәбиятны иҗтимагый фикер үсеше, аның белән тыгыз бәйләнештә булган милли үзаң торышыннан аерып карап һәм өйрәнеп булмый. Шуңа да татар әдәбияты тарихының дәвер, этап, чорларга бүленеше ил-халык тормышындагы вакыйгаларга нигезләнә. Шуның белән бергә, тарихи вакыйгаларның ролен, йогынтысын абсолютлаштырырга да кирәкми. Әйтик, теге яки бу әдип иҗатын бербөтен итеп карыйбыз икән, аның һәртөр этап-чорлар аша үтеп чыгып, һәрберсенә хас үзенчәлекләрне теге яки бу дәрәҗәдә үзендә чагылдыруын да күз алдында тотабыз. Моңа Г. Исхакый, Х. Туфан, С. Хәким һ.б. иҗаты мисал булып тора

[1] Борынгы татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. 576 б.

[2] Татар әдәбияты тарихы: алты томда. 1 т. Борынгы һәм урта гасырлар дәвере. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 567 б.

[3] Татар әдәбияты тарихы: алты томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 1 т. Борынгы һәм урта гасырлар дәвере. 567 б.;1985. 2 т. XIX йөз әдәбияты. 563 б.; 1986. 3 т. XX гасыр башы. 598 б.; 1989. 4 т. Татар совет әдәбияты (1917–1941). 567 б.; 1989. 5 т. Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы еллар әдәбияты (1941–1960). 543 б.; 6 т. Казан: Раннур, 2001. 544 б.

ала. Әдәбият тарихының дәвер-баскычларга бүленешендә аеруча мөһим шарт булып аның эчке үсеш закончалыклары, шуларга нигезле теге яки бу этап-чорга хас үзенчәлекләр булу санала. Әдәбият, җанлы организм кебек, һәрвакыт үсеш-үзгәрештә яши. Ул тормыш-чынбарлыкны чагылдыруның яңадан-яңа юлларын, чараларын эзли. Монда традицияләр дәвамчанлыгы белән яңачалыкларның үзара мөнәсәбәте дә мөһим роль уйный. Вакыты белән әдәби-эстетик эзләнүләр тараеп, бер урында таптану яисә билгеле бер яуланган үрләрне, позицияләрне югалту да булырга мөмкин. Мисал өчен, XVI гасыр уртасында Казан яулап алынганнан соң, татар әдәбияты озак вакытлар торгынлык кичерә. Ә инде XX гасырның 30 нчы елларында әдәбиятта вульгар-социологик карашлар өстенлек итү тема-проблемаларның охшашлыгына, шаблонлыкка, сурәт чараларының саегуына китерә һ.б.

XX йөзнең 90 нчы елларында дөнья күргән мәктәп һәм вуз программа-дәреслекләрендә традицион бүленеш (зур булмаган үзгәрешләр белән) саклана. Билгеле бер фикер-карашлар аерымлыгы 1917 елдан соңгы әдәбият тарихын чорларга бүлүгә бәйле күзәтелә. «Татар урта мәктәпләре өчен әдәбият программалары»нда тәкъдим ителеп, дәреслекләрдә чагылыш тапкан бүленеш түбәндәгечә: 1) «Совет хакимияте башланганда татар әдәбияты», 2) «20 нче еллар әдәбияты»; 3) «30 нчы елларда совет әдәбияты»; 4) «40–50 нче еллар әдәбиятында Бөек Ватан сугышының чагылышы»; 5) «Яңа сыйфат үзгәрешләренә күчеш чорында (1945–1970)»; 6) «Хәзерге татар әдәбияты» [1]. Төзүче-авторлар, билгеле, чор-этапларга аерып чыгаруның каршылыклы булуын аңлыйлар, шуңа да эчтәлектә, аеруча күзәтүләрдә ачыклау-аңлату омтылышы ясыйлар. Шуның белән бергә, тәкъдим ителгән бүленешне камилләштерү кирәклеге дә ачык күренә. Мисал өчен, «40–50 нче еллар әдәбиятында Бөек Ватан сугышының чагылышы» шактый берьяклы атама. Ул әдәби хәрәкәтнең бер тармагын, әдәби төрләрдә урын алган бер теманы, әле анда да сугыш тәмамланганнан соңгы елларга бәйле үзенчәлекне күздә тота. Шул ук вакытта Бөек Ватан сугышы еллары әдәбиятының төп сыйфат-билгеләре, сугыштан соңгы әдәбияттагы тематик төрлелек, эстетик эзләнүләр һ.б. мәсьәләләр әлеге атамага сыешып бетми.

«Яңа сыйфат үзгәрешләренә күчеш чорында (1945–1970)» дип аталган этап та сораулар уята. Бердән, 1945–1955 еллар әдәбиятта бертөрлелек көчәйгән, әдипләр соцреализм кысаларына көчләп куып кертелгән, «конфликтсызлык» теориясе чәчәк аткан чор буларак билгеле. Шуңа да әлеге елларны «яңа сыйфат үзгәреше» төшенчәсе белән бәйләп карау урынлы түгел. Икенчедән, чорның чиген 1970 ел белән

[1] Татар урта мәктәпләре өчен әдәбият программалары (5–11 сыйныфлар) / төзүчеләре: А.Г. Әхмәдуллин, Ф.М. Хатипов. Казан: Мәгариф, 2000. 55 б.

билгеләү дә бәхәсле, чөнки «хәзерге әдәбият» дигәндә 1985 елдан соңгы сүз сәнгатен күздә тотабыз. 1970 еллар һәм 1980 елларның беренче яртысы әдәбиятында, аерымлыктан бигрәк, охшашлык өстенлек итә. Моңа Н. Фәттах, А. Гыйләҗев, М. Мәһдиев, Ш. Галиев, Ф. Яруллин, Р. Фәйзуллин, Т. Миңнуллин һ.б.ның иҗаты мисал була ала.

Мәктәпләр өчен альтернатив программа һәм дәреслекләрне төзүче А. Яхин 1917 елдан соңгы әдәбиятны «Совет әдәбияты» дип атый, ә инде инкыйлаблар, гражданнар сугышы чорын «Яңа идеал» төшенчәсе белән аңлата. 20–30 нчы елларны аерым чор буларак билгели, әдәбиятның эчтәлегенә нигезле дүрт тематик-проблематик юнәлешне аерып чыгара. А. Яхин Бөек Ватан сугышы елларыннан соңгы әдәбиятны аерым чорларга бүлмичә, links бербөтен итеп карау ягында. Төзүче-автор бу дәвер әдәбиятын «Илдә сөргән хакыйкать», «Хакыйкатьне тарихтан эзләү», «Әхлак нигезләрен өлкән буын вәкилләреннән эзләү», «Хаксызлыкка яраклашуның холыкка әйләнүе», «Тормышта үз урыныңны эзләү» кебек тема-проблемаларга нисбәтле өйрәнүне алга куя. Әдәбияттагы аерым тенденцияләрне билгеләү, стиль эзләнүләренең яисә әсәрләрнең табышларын, үзенчәлекләрен ачу ягыннан А. Яхин тәкъдим иткән юл киң мөмкинлекләр бирә[1]. Шуның белән бергә, ил-халык тормышындагы җитди вакыйгалар, алар белән тыгыз бәйләнештә сүз сәнгатендәге сыйфат үзгәрешләре аерым чорларга бүлеп карауны таләп итә. Мисал өчен, Н. Фәттахның «Ител суы ака торур» романы «Хрущев җепшеклеге»ннән соңгы демократик үзгәрешләр йогынтысында гына языла алды. И. Салаховның «Тайгак кичү» романы да XX гасырның 80 нче еллары уртасында башланып киткән үзгәрешләр нәтиҗәсендә дөнья күрде. Төзүче-автор яклаган бүленеш әлеге сәбәп-шартларга тиешенчә нигезләнми.

Казан дәүләт педагогика институты (соңрак Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты) галимнәре Ф. Галимуллин һәм Р. Сверигин төзегән «Татар әдәбияты (1917–1990)» программасында Октябрьдән соңгы әдәбиятны түбәндәгечә өйрәнү күздә тотыла:

– 1917–1930 еллар әдәбияты;

– Утызынчы еллар әдәбияты (1930–1941);

– Бөек Ватан сугышы еллары татар әдәбияты (1941–1945);

– Бөек Ватан сугышыннан соңгы чорда татар әдәбияты (1945–1964 еллар);

– 1965–1985 елларда татар әдәбияты;

– хәзерге татар әдәбияты (1985 – туксанынчы еллар)[2].

---

[1] V–XI класслар өчен татар әдәбияты программасы / төз. А.Г. Яхин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. 40 б.

[2] Татар әдәбияты (1917–1990): программа / төзүчеләре: Ф.Г. Галимуллин, Р.Х. Сверигин. Казан: КДПИ, 1994. 46 б.

Ә менә КДУ укытучылары А. Даутов һәм Г. Гайнуллина төзегән «Хәзерге татар әдәбияты программасы (1941–2000 еллар)»нда мондый бүленеш белән очрашабыз:

– 1940–1960 еллар әдәбияты: а) 1941–1945 еллар (Ватан сугышы чоры әдәбияты); ә) 1945–1960 еллар (тыныч тормышка күчү чоры әдәбияты);

– 1960–2000 еллар әдәбияты: а) 1960–1985 еллар (торгынлык чоры әдәбияты); ә) 1985–2000 еллар (үзгәртеп кору чоры әдәбияты)[1].

Алдагы елларда татар әдәбиятын чорларга бүлү һәм шуңа нигез булып торган принципларны ачыклау, тулыландыру, системага салу буенча җитди эшчәнлек алып барыла. Мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен чыгарылган яңа әдәбият программалары, нигездә, югарыда күрсәтелгән бүленешкә таяна.

Әлеге мәсьәләләргә бәйле фикер алышуларның гамәли нәтиҗәсе буларак Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында XX гасыр татар әдәбиятының яңартылган тарихын эшләүнең концепциясе булдырылып, 3 томнан торачак хезмәтнең проекты әзерләнә. Ф. Мусин «Вакыт үзе куя бәһане» мәкаләсендә XX гасыр татар әдәбиятын чорларга бүлү принципларына ачыклык кертә. Ул болай дип яза: «Тарихилык һәм миллилек принципларына нигезләнеп, XX йөз татар әдәбияты тарихын өч чорга бүлеп һәм өч томда язу тәкъдим ителә:

1 нче том. Милли үзаң уяну һәм үсү чоры әдәбияты (1886–1917 еллар).

2 нче том. Тоталитаризм чоры әдәбияты (1917–1950 еллар).

3 нче том. Милли яңарыш чоры әдәбияты (1960–1990 еллар)»[2].

Яңалыкларның берсе XX йөз башы әдәбиятының чикләрен башкача билгеләү белән бәйле. Галимнәр аны XIX йөз урталарыннан, ягъни татар дөньясында башланган милли үзаң уяну һәм милли идея формалашу хәрәкәтеннән башлап өйрәнү ягында. Чөнки XIX йөзнең урталарында (төгәлрәк әйткәндә, соңгы чирегендә) татар әдәбияты реализм юлына чыгып, милли идеяне, шәхеснең һәрьяклап үсешен алга куя һәм шуның белән Яңа заман әдәбиятына нигез салына. XX йөз башында яңа иҗтимагый-тарихи һәм мәдәни шартлар (инкыйлаб нәтиҗәсендә сүз, матбугат иреге яулап алыну, сайлау хокукы бирелү, милли хокуклар өчен көрәшнең көчәюе һ.б.) йогынтысында татар әдәбияты сәнгати эзләнүләрдә, эчтәлек һәм формада яңа биеклекләргә, табышларга ирешә.

Үткән гасыр татар әдәбиятында үзенчәлекле этап итеп 1917–1950 еллар әдәбияты аерып чыгарыла. Ф. Мусин: «Тарихилык һәм

---

[1] Хәзерге татар әдәбияты программасы (1941–2000 еллар) / төзүчеләре: А.И. Даутов, Г.Р. Гайнуллина. Казан: КДУ, 2000. 35 б.

[2] *Мусин Ф.М.* Вакыт үзе куя бәһане // Мәдәни җомга. 2004. 7 май.

миллилек принциплары иң әүвәл бу чорны гасыр башы белән күчемле бәйләнештә карауны сорый», – дип яза. Татар әдәбиятында «романтик хасият, ягъни тормышта булырга мөмкинне инде булды дип күрсәтү» төп тенденциягә әверелә. Социалистик реализм иҗат методы тормышны берьяклы гына күрсәтүгә, чагылдыруга китерә. Галим фикеренчә, 1920 һәм 1930 еллар әдәбияты бер-берсеннән шактый аерыла, шунлыктан аларга мөстәкыйль якын килү кирәк.

XX гасырның 60 нчы елларында башланган яңарыш татар әдәбиятында мөһим бер этапны билгели. Бу чорда әдәбиятта ике әдәби-эстетик юнәлеш яшәп килә. Берсе – рәсми характерда булып, төрле төзелешләрне, илкүләм вакыйгаларны, хезмәт җиңүләрен раслау белән күбрәк мавыга, интернациональлек, милләтләрнең үзара якынаюы идеяләрен яклый. Икенчесе – милләт мәнфәгатьләре турында тирәнтен уйланып, үткән тарихыбызны, бүгенге тормышта шәһәрләшү процессы, авылларның бетүе, милләткә хас гореф-гадәтләрнең, традицияләрнең кимүе, хәтта юкка чыгуы, ассимиляция күренешләре һ.б. турында борчылу. Шулай да 1960–1990 еллар сүз сәнгатен «Милли яңарыш чоры әдәбияты» дип атау белән килешәсе килми. XX гасырның 60 нчы еллары башында ил тормышында демократия җилләре «исеп» куйса да, ул шактый тиз «сүндерелә». Бу елларда кечерәк санлы халыклар, шул исәптән татар халкы да партия-административ системасының җитди басымына дучар була: халыкның күпчелеге яшәгән авыл мәктәпләренең байтагы рус телендә укуга күчә, шәһәрләрдә татар мәктәпләре бетерелә, катнаш никахлар һәрдаим хуплана, Татарстандагы зур төзелешләргә чит җирләрдән башка милләт кешеләре күчерелә һәм бу титул милләтнең күпчелек хасил итүен чикли һ.б. Милләт сан ягыннан азаюга, телнең кулланылыш даирәсе кимүгә йөз тоткан еллар «милли яңарыш чоры» атамасы белән билгеләнә алмый, дөресрәге, ил-халык торгынлык халәтендә яши. Ә менә әдәбият, киресенчә, 1960 еллар башында милли нигезләргә кайту халәте кичереп, алдагы елларда да иң яхшы әсәрләрдә әлеге сыйфатын саклый һәм нәтиҗәдә сәнгати планда бик югары бәяләнә торган күпсанлы әсәрләр дөнья күрә.

Татар сүз сәнгате тарихын аерым дәвер-этапларга бүлеп өйрәнүгә бәйле Ф. Яхин да үз фикерләре белән уртаклаша. «Әдәбият тарихын этапларга бүлеп өйрәнү аның төп үсеш тенденцияләрен ачыклау белән бәйле, – дип яза ул. – XIX гасырның икенче яртысына кадәр татар әдәбияты Шәрык (Көнчыгыш) әдәбиятлары кысасында үсеш алган. 1860 еллардан башлап ул европалаша башлый һәм бу процесс XX йөзнең 20 нче еллар башына кадәр дәвам итә. Шулай итеп, татар әдәбияты тарихы ике зур этапка бүленә:

1. Шәрыкчелек дәвере.
2. Европачылык дәвере.

Аның беренчесен фәндә кадим әдәбият, икенчесен җәдид әдәбият дип билгеләү дә кабул ителгән»[1]. Тормыш-чынбарлыкны сәнгати чагылдыруда кадим һәм җәдид әдәбиятлары арасындагы аерымлыкларны эзлекле билгеләгәннән соң, галим мондый нәтиҗә ясый: «татар халкының вәкилләре тарафыннан тудырылган борынгы, урта гасырлар һәм XVII–XIX йөзнең беренче яртысы әсәрләре уртак төрки әдәби мирас сыйфатында каралынып, уртак әдәби традицияләр нигезендә тикшерелергә тиеш булып чыга»[2]. Ул әлеге юлдан баручы төрек галимнәрен үрнәк итеп куя. Бу очракта шуны билгеләп үтәргә кирәк: беренчедән, Борынгы һәм Урта гасырлар татар әдәбиятын шәрык-мөселман дөньясы белән бәйләнештә өйрәнү инде байтактан алып барыла (Ш. Абилов, Р. Ганиева, Х. Миңнегулов, Н. Хисамов һ.б. хезмәтләре моңа мисал була ала); икенчедән, XIX йөзнең урталарына кадәрге әдәбиятыбызны уртак төрки мирас буларак карау, Алтын Урда чоры әдипләрен генә түгел, бәлки Мөхәммәдъяр, Кол Шәриф, М. Колый, Утыз Имәни, Г. Кандалый һ.б. язучыларны да татар әдибе дип түгел, ә «төрки әдипләр» рәвешендә бәяләүгә кайтып кала түгелме?

Әдәбият тарихын этап-чорларга бүлүдә үзгә нигезләмәләр дә булырга мөмкин. Бу очракта, эзләнү-тикшеренү таррак кысаларда алып барылу нәтиҗәсендә, зур булмаган чорларның әдәбият үсеш-үзгәрешендәге ролен, йогынтысын ачыклауга юл ача. Т. Галиуллин югарыда күрсәтелгән мәкаләсендә совет чоры әдәбиятының ил-дәүләт үсешендәге тарихи-иҗтимагый вакыйгалар йогынтысында булуын билгеләп, болай дип яза: «Катгый бер сәясәт хакимлек иткәндә, иҗат ирекге, шигъри үзгәлек, чи тире төсле, соң чиккәчә кысыла, сәнгать икътисади үсешнең, димәк ки, заманның шәүләсе, колы, вассалы дәрәҗәсенә төшә. Сәяси дилбегә йомшаган, мундирның берничә сәдәбе ычкындырылган, йөгәннең тимере авыздан алынган дәверләрдә әдәбият ыргылып алга үтә, үлмәс әсәрләрен мәйданга чыгара, талантларын бәйгегә күтәрә»[3]. 1917 ел октябрь инкыйлабыннан соңгы татар шигърияте үсешендә аерым биеклекләр яуланган чорлар буларак, ул түбәндәгеләрне аерып чыгара: 1917–1921 еллар, 1941–1945 еллар, 1956–1970 еллар, сиксәненче еллар ахырыннан башлап гасыр ахырынача. Әлеге бүленеш Октябрьдән соңгы татар әдәбият тарихын өйрәнүне тагы да конкретлаштыра, табыш-югалтуларның сәбәбен тулырак ачарга мөмкинлек бирә.

Танылган шагыйрь Р. Фәйзуллин Татарстан язучылар оешмасы төзелгәннән соңгы әдәбиятыбызга күзәтү ясаган хезмәтендә, аны

[1] *Яхин Ф.З.* Татар әдәбияты тарихын өйрәнү мәсьәләсе // Гыйльми язмалар. Казан: Татар дәүләт гуманитар институты, 2003. Б. 120.

[2] Шунда ук. Б. 121.

[3] *Галиуллин Т.Н.* Татар поэзиясе тарихын яңача өйрәнү мәсьәләләре // Шигърият баскычлары. Казан: Мәгариф, 2002. Б. 11.

нинди принциптан чыгып, нинди периодларга бүлү мәсьәләсенең кыенлыгын һәм каршылыгын билгеләп, болай дип яза: «Бу мәсьәлә галим-голәмә өчен дә, әлбәттә, актуаль булып килә. Әйтик, «Татар әдәбияты тарихы»ның 6 томлыгын карасаң, анда үзенчә бер тәртип: дистәелларны иҗтимагый-сәяси вакыт берәмлегенә карап бүлү һәм бәһаләү күзгә ташлана. Ә әдәбиятның үз үсеш-торгынлык чорларын исәпләп системалаштырсаң, бүтәнчәрәк бүленеш килеп чыга. Чоры катлаулы һәм болганчык булгач, бернинди бүленеш тә фәнни объектив кысаларга сыеп бетә алмый» [1]. Соңгы 70 елгы әдәбият тарихын 4 дәвергә бүлеп бәяли: 1) 1934 елдан сугыш ахырына кадәрге еллар; 2) сугыш соңыннан башлап 50 нче еллар ахырына кадәрге еллар; 3) 1960–1990 еллар; 4) 90 нчы еллардан бүгенге көнгә кадәрге еллар. Әлеге бүленештә берничә мәсьәлә игътибарны җәлеп итә. Беренчедән, гадәттә «30 нчы еллар әдәбияты» дип йөртелгән чорны хезмәт авторы 1945 елга кадәр озайта. Нигезе турында уйланганда, Р. Фәйзуллин шуларны искәртә: а) 30 нчы елларның төп көчләре сугыш елларында да иҗат активлыгын киметми; ә) «татар язучыларын 37 нче еллар бер «чабып» ташлаган булса, икенче бер афәт – сугыш янә байтагын кырып салды». Ш. Мостафин фикеренә нигезләнеп, 104 татар язучысы һәм журналистының 31 е сугышта корбан булуын искәртә. Икенчедән, әдәбияттагы үзгәрешләрне 30 нчы еллар башыннан түгел, ә 1934 елдан, ягъни Язучылар оешмасы төзелгән, аннан да бигрәк социалистик реализм иҗат методы канунлаштырылган вакыттан дип күрсәтә.

Күргәнебезчә, татар әдәбиятын дәвер-чорларга бүлү мәсьәләсендә фикер төрлелеге яшәп килә. Шулай да бу мәсьәлә белән тирәнтен шөгыльләнүчеләр төп этапларны билгеләгәндә уртак фикердә торалар. Югарыдагы карашларга нигезләнеп, татар әдәбияты тарихының чорларга бүленешенең түбәндәге вариантын (билгеле бер үзгәрешләр белән) аерып чыгарырга мөмкин[2]:

I. Борынгы әдәбият.

Гомумтөрки әдәбият (V–XII йөзләр).

II. Урта гасырлар әдәбияты.

1. Болгар чоры әдәбияты (IX–XIII гасырның I чиреге).

---

[1] *Фәйзуллин Р.Г.* Гыйбрәтләр алырлык үткән юл: фәнни-публицистик язма. Казан: Идел-Пресс, 2004. 20–21.

[2] *Закирҗанов Ә.М.* Яңарыш юлыннан (Хәзерге татар әдәбият белеме мәсьәләләре). Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. Б. 51–52; *Закирзянов А.М.* Основные направления развития современного татарского литературоведения (кон. XX – нач. XXI в.). Казан: Ихлас, 2011. С. 144–145; *Миннегулов Х.Ю.* Этапы развития тюрко-татарской, античной и русской литератур. Казань: Ихлас, 2014. С. 24–73; *Миннегулов Х.Ю.* Тюрко-татарская словесность в контексте межлитературных связей. Казань: Ихлас, 2017. С. 8–114. һ.б.

2. Алтын Урда чоры әдәбияты (XIII гасыр урталары – XV гасыр урталары).

3. Казан ханлыгы чоры әдәбияты (XV гасыр урталары – XVI гасыр урталары).

4. XVII–XIX йөз уртасы әдәбияты (XVI гасыр урталары – XIX гасыр урталары).

III. Яңа заман әдәбияты.

1. Милли Яңарыш чоры әдәбияты (XIX гасыр урталары – 1917 ел).
   1) Милли реалистик әдәбият формалашу (XIX гасыр урталары – 1905 ел);
   2) XX гасыр башы әдәбияты (1905–1917 еллар).
2. Совет чоры әдәбияты (1917–1950 еллар уртасы).
   1) Инкыйлаб һәм Гражданнар сугышы чоры әдәбияты (1917–1921 еллар);
   2) 20 нче еллар әдәбияты (1921–1932 еллар);
   3) 30 нчы еллар әдәбияты (1932–1941 еллар);
   4) Бөек Ватан сугышы чоры әдәбияты (1941–1945 еллар);
   5) Сугыштан соңгы еллар әдәбияты (1945–1950 еллар уртасы).
3. 1960 – 1980 еллар әдәбияты (1956–1985 еллар).
4. Хәзерге әдәбият (1980 еллар уртасы – XXI гасыр башы).
   1) Үзгәртеп корулар чоры әдәбияты (1980 еллар уртасы – 1990 еллар ахыры);
   2) XXI гасыр башы әдәбияты.

Әлеге бүленешкә аңлатма биреп үтик. Татар әдәбият белемендә «Борынгы әдәбият»ны V–XII йөз чикләрендә билгеләү кабул ителгән. Безнең көннәргә килеп җиткән иң борынгы рун язулы истәлекләр V гасырга карый. «Борынгы төрки әдәбият милли төрки әдәбиятлар үсешендә нигез, мөһим чыганак булып тора. Хәзерге төрки халыклар халыкча буларак формалашканчы туган бу рухи мирас уйгурларның, үзбәкләрнең, татарларның, төрекләрнең, азәрбайҗаннарның һәм кайбер башка төрки халыкларның уртак хәзинәсе дип тә йөртелә»[1]. Борынгы әдәбият үз эченә синкретик, ярым фольклор, ярым әдәби истәлекләрне ала. Гомумтөрки характердагы мондый язмаларның соңгылары XII гасыр белән чикләнә. Әлеге дәвер ахырында аерым дәүләтләр барлыкка килү процессы башланса да (мәсәлән, халкы этник яктан төрле булган Болгар дәүләте), Идел-Урал буенда, Урта Азия төбәгендә төрле төрки халыкларга уртак булган хезмәтләр язылу дәвам итә: М. Кашгарыйның «Диване лөгатет-төрк»е (XI гасыр), Й. Бала-

[1] *Миңнегулов Х.Й., Садретдинов Ш.А.* Әдәбият: урта мәктәп һәм гимназияләрнең 9 нчы сыйныфы, урта махсус уку йортлары, педагогия училищелары, колледж һәм лицей укучылары өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 1994. Б. 11.

сагунлының «Котадгу белек»е (XI гасыр), Ә. Йүгнәкинең «Һибәтел-хәкаик»ы (XII гасыр), Ә. Ясәвинең «Диване хикмәт»е (XII гасыр), С. Бакырганиның «Бакырган китабы» (XII гасыр)[1] һ.б.

Татар әдәбияты тарихының иң зур этабын «Урта гасырлар әдәбияты» дип йөртелгән дәвер алып тора. Тарихчылар тарафыннан кабул ителгән вакыт аралыгына туры килмәсә дә, IX гасырдан алып XIX гасыр уртасына кадәр дөнья күргән сүз сәнгате әсәрләре, дөньяны әдәби-эстетик күзаллау ягыннан уртаклыкка нигезләнеп, әлеге исем белән атала. Ул үз эчендә дүрт чорга бүленә: Болгар чоры әдәбияты (IX – XIII гасырның I чиреге); Алтын Урда чоры әдәбияты (XIII гасыр уртасы – XV гасыр уртасы); Казан ханлыгы чоры әдәбияты (XV гасыр уртасы – XVI гасыр уртасы); XVII–XIX гасыр уртасы әдәбияты (XVI гасыр уртасы – XIX гасыр уртасы).

Төньяк Кавказ һәм Азов диңгезе төбәгендәге Бөек Болгар төрки дәүләте җимерелгәннән соң, халыкның бер өлеше Идел-Чулман елгалары кушылган җиргә күчеп килә һәм Идел Болгарстанына нигез сала. Әлеге дәүләт халкы этник яктан төрле була. Алмыш хан җитәкчелек иткән чорда – 922 елны – Идел болгарлары рәсми төстә ислам динен кабул итә[2]. Тиз арада Евразия киңлегендә икътисади һәм мәдәни яктан алга киткән дәүләтләрнең берсенә әйләнә. Анда Биләр, Болгар кебек мәдәни үзәкләр барлыкка килеп, үзенең шагыйрьләре, чичәннәре, фәлсәфәчеләре, хокук белгечләре белән дан тота. Кызганыч ки, бу чорның азсанлы әдәби ядкәрләре генә бүгенгегә килеп җитә алган. Әмма Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре әлеге төбәктә көчле үскән әдәби-мәдәни мохит булуын раслый. Әлеге атаклы дастан бай халык авыз иҗатына, төрки язма әдәбиятның уңышлы үрнәкләренә, гарәп-фарсы әдәбиятының шифалы йогынтысына нигезләнгән иҗат җимеше булып тора. Гомумән, IX–XIII гасырның I чиреге аралыгын үз эченә алган Болгар чоры әдәбияты, аның иң күренекле әсәре булган «Кыйссаи Йосыф» алдагы чорларда татар әдәбиятының үсеш-үзгәрешенә – эчтәлек-формасына, поэтикасына, сурәт чараларына һ.б.га гаять зур йогынты ясый.

1236 елда Идел Болгарстаны Батый хан тарафыннан яулап алына һәм Үзәк Азиядән алып Карпат тауларына кадәр территориядә оешкан Алтын Урда дәүләте составына керә. Аның Урта Идел төбәгенәчә җирләрендә төрки халыклар яши. Әлеге дәүләттә уртак әдәби язма тел кулланыла. Шул нисбәттән XIII гасыр уртасыннан алып XV гасыр уртасына

[1] *Миңнегулов Х.Й.* Татар әдәбияты тарихына бер караш // Гасырлар өнен тыңлап... Казан: Мәгариф, 2003. Б. 5–6.

[2] Тарих фәнендә Алмыш ханның ислам динен кабул итү вакыты төгәл билгеле булмаса да, унынчы гасырның беренче ун елына нисбәтле карыйлар (бу турыда тулырак: История татар с древнейших времен: в семи томах. Т. II. Волжская Булгария и Великая Степь. Казань: РухИЛ, 2006. С. 552.

кадәр дөнья күргән Котб, Харәзми, Х.Кятиб, С. Сараи һ.б.ның әсәрләре, «Идегәй» халык дастаны «Алтын Урда чоры әдәбияты» дигән этапка кертеп өйрәнелә[1].

Күпсанлы эчке һәм тышкы факторлар тәэсирендә XV гасыр урталарында Алтын Урда дәүләте таркалу процессы кичерә һәм аның урынына аерым ханлыклар барлыкка килә. XV гасыр уртасында Олуг Мөхәммәд хан Казан ханлыгын оештыра. «Казан ханлыгы чоры әдәбияты» XV гасыр уртасыннан алып XVI гасыр уртасына кадәр чорны үз эченә ала. Чикләрнең болай билгеләнүе, аңлашылганча, әлеге татар дәүләтенең яшәгән еллары белән бәйле. Шул ук вакытта «Казан ханлыгы чоры» дигән исемнең һәм чикләрнең шартлы булуын искәртеп үтәргә кирәк. Чөнки, беренчедән, Алтын Урда таркалганнан соң барлыкка килгән ханлыкларда (Казан, Кырым, Әстерхан, Касыйм, Нугай, Себер) төп халыкны татарлар тәшкил иткән һәм рәсми дәүләт теле булып татар теле йөргән. Икенчедән, әлеге ханлыкларның яшәү вакыты төрлечә булып, мөстәкыйль дәүләтнең әдәбияты да яшәп килә.

Бу чорның йөзен билгеләүче әдипләр нәкъ менә Казан ханлыгына карый – Мөхәммәдъяр, Кол Шәриф, Өмми Камал, Мөхәммәд Әмин. Әдәбият галиме Х. Миңнегулов XV-XVI йөзләрдә төрле төбәкләрдә Казтуган (Әстерхан), Хәсән Кайгы (яшәгән урыны Казан һәм Нугай ханлыклары белән бәйле), Дүсмәмбәт (Кырым), Чалгиз җырау (Идел буенда яшәгән) кебек әдипләрнең яшәп иҗат итүен билгели[2]. «Казан ханлыгы чоры әдәбияты»ның кайбер идея-эстетик үзенчәлекләре: Идел Болгарстанында киң урын алган Яңарыш (Ренессанс) күренеше бу чорда да дәвам итеп, кеше шәхесен зурлауда, гуманизм идеяләрен яклауда чагыла; тормыш-яшәеш турында фәлсәфи уйлану әсәрләрдә яхшылык-явызлык антиномиясен алга чыгара; үгет-нәсыйхәт, дидактика киң урын алып, чын кешегә хас сыйфатлар буларак гаделлек, юмартлык, сабырлык һ.б. яклана һәм мактала; дини-суфичыл эчтәлек өстенлек итә, шуңа да, гадәттә, кешенең рухи дөньясы, күңеле сурәтләү объекты булып тора. Аллаһы Тәгаләгә мәдхия уку, иң матур сыйфатларын мактау, яшәештәге золымны, һәртөр начарлыкны тәнкыйтьләү, укучыны ваемсызлыктан арындыру теләге белән бәйләп бирелә һ.б.

Рус дәүләте Казан ханлыгын яулап алган вакыттан (1552 елдан) алып XIX йөз урталарында мәгърифәтчелек хәрәкәте башланганга кадәрге дәвер әдәбият фәнендә «XVII–XVIII йөзләр әдәбияты» буларак өйрәнелә. XVI гасыр уртасында дәүләтчелекне югалту халыкка әйтеп бетергесез золым-җәфа, югалту-михнәт алып килә: бик күп кеше үте-

[1] *Миннегулов Х.Ю.* Тюрко-татарская словесность в контексте межлитературных связей. Казань: Ихлас, 2017. С. 14–35.

[2] *Миннегулов Х.Ю.* Татарская литература и Восточная классика (Вопросы взаимосвязей и поэтики). Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1993. С. 33–35.

реләә, әсирлеккә алып кителә; чит җирләргә күчереп утырту башлана; зур шәһәрләр, елгалар янында яшәү тыела; яхшы җирләр тартып алына; ислам дине эзәрлекләнә, көчләп чукындыру башлана; рухи һәм матди байлак талана, юк ителә һ.б. Татар халкы иҗтимагый-мәдәни яктан зур югалту кичерә. Ислам дине коточкыч эзәрлекләүгә дучар булып, аның халыкка йогынтысын киметү, таркату, хәтта юкка чыгару өчен 1555 елда ук архиепископ Гурий җитәкчелегендә Казанда махсус епархия оештырыла һәм ул татар, чуваш, мари, удмурт халыкларын чукындыру, христиан диненә күчерү белән шөгыльләнә. Шул ук вакытта татар авылларында мәчетләрне җимерү, дин әһелләрен эзәрлекләү бара. Бу сәясәткә каршылык рәвешендә татар-мөселманнарның рухи дөньясында дини башлангыч арта. Әнә шундый шартларда ислам дине татар этносын саклап калу, берләштерү вазифасын үти.

Югалтуларга сүз сәнгате дә дучар була. Өч гасырга якын вакытны үз эченә алган чор олы исемнәргә, тарихта калырлык әсәрләргә бай түгел. Асыл улларын-кызларын югалту, рухи чыганакларның таркалуы яисә эзәрлекләнүе халыкның эчке потенциале бик нык кимүгә китерә. Бу чорда фольклор жанрлары белән бергә, ярымәдәби, ярымтарихи характердагы, дини эчтәлек белән сугарылган хезмәтләр языла: «Җәмигъ-әттәварих» («Гомуми тарихлар», XVII йөз башы), «Дәфтәре Чыңгызнамә» («Дастаннар мәҗмугасы», XVII йөз ахыры), «Тәварихе Болгария» («Болгар тарихы», XVIII йөз). Болардан тыш, васыятьнамәләр, сәяхәтнамәләр («Исмәгыйль сәяхәтнамәсе», XVIII йөз), хатлар («Батырша хаты», XVIII йөзнең II яртысы), хикәят-җыентыклар («Мәҗмугыл хикәят», XVIII йөз) һ.б. таралыш ала.

XVII йөздә Мәүла Колый, Габди, XVIII йөздә Габдессәлам, Габделмәннан Мөслим углы, Әхмәдбик, Таҗеддин Ялчыгол, XIX йөзнең I яртысында Г.Утыз-Имәни, Ә. Каргалый, Ш. Зәки, Һ. Салих, Г. Кандалый кебек әдипләр иҗат итә.

Колониаль изелү, түбәнсетелү, җәберләнү шартларында халык ислам динендә таяныч, өмет-ышаныч таба, ә инде сүз сәнгатендә фольклор һәм алдагы әдәбият традицияләрен дәвам иткән хәлдә дини-суфичыл идеяләр яклана һәм үстерелә. Р. Ганиева әлеге чорны дөньяга үзенчәлекле карашны һәм эстетик күренешне аңлаткан декадентлыкның татар әдәбияты тарихында чагылышының беренче этабы дип саный. Галимә фикеренчә,суфичылыкка һәм Коръәннән килүче сабырлык фәлсәфәсенә нигезләнгән декадентлык татар халкын юкка чыгудан һәм ислам мәдәниятенең традицион кыйммәтләрен югалтудан саклап калырга ярдәм итә[1]. Әлеге күренешнең мөһим бер сыйфатын И. Вәлиулла «Татар моңы» төшенчәсе белән аңлата һәм аның халык авыз иҗаты әсәрләрендә, язма

[1] *Ганиева Р.К.* Гаяз Исхакый иҗаты. Казан: КДУ, 2005. Б. 10.

әдәбиятта чагылыш үзенчәлеген болай билгели: «Татар Моңының нигезендә Яхшылык һәм Яктылык җиңәчәгенә тирән бер эчке ышаныч ята»[1].

Татар әдәбиятының өченче зур дәвере «Яңа заман әдәбияты» дип билгеләнә. Мәгърифәтчелек чоры, бигрәк тә XX йөз башы әдәбиятының төп үсеш тенденцияләрен билгеләгәндә бу чорларда Яңа заман әдәбиятына нигез салыну фикере Г. Ибраһимов тарафыннан әйтелеп, Г. Халит, И. Нуруллин, Р. Ганиева хезмәтләрендә, соңрак М. Хәсәнов, Й. Нигъмәтуллина, Ф. Мусин, Х. Миңнегулов, Н. Хисамов, Ә. Сәхапов, Ф. Бәширов, Д. Заһидуллина, Ә. Закирҗанов һ.б. монографияләрендә билгеләп үтелә. «Яңа заман әдәбияты» дүрт зур этапка бүленә: «Милли Яңарыш чоры әдәбияты (XIX гасыр уртасы – 1917 ел)»; «Тоталитаризм чоры әдәбияты (1917–1950 еллар ахыры)»; «Торгынлык чоры әдәбияты (1960–1980 еллар уртасы)»; «Хәзерге әдәбият (1980 еллар еллар уртасы – XXI гасыр башы»).

«Милли Яңарыш чоры әдәбияты» үз эченә ике чорны ала – «Милли реалистик әдәбият формалашу (XIX гасыр уртасы – 1905 ел)» һәм «XX йөз башы әдәбияты (1905–1917 еллар)».

Озак вакытлар колониаль изелү, милли һәм социаль кимсетелү хәлендә булган татар халкының алдынгы карашлы вәкилләре торгынлык хәленнән чыгу юлларын эзли башлый[2]. Г. Курсави, Г. Утыз Имәни кебек шәхесләрнең дини, ярымдини эчтәлекле хезмәтләрендә, әдәби әсәрләрдә ислам динен реформалаштыру һәм халыкны мәгърифәтле итү мәсьәләләре күтәрелә. Аларның караш-фикерләре торган саен киңрәк катлау кешеләрдә яклау таба. Шул рәвешле, XIX гасыр урталарында, аеруча 80 нче елларда татарларда мәгърифәтчелек хәрәкәте кузгала. Ул, яшәешнең бөтен өлкәләренә үтеп кереп, җәмгыятьтә җитди үзгәрешләргә юл ача. Матур әдәбият яңа фикерләрне кеше күңеленә, аңына сеңдерүдә үтемле чара булганлыктан, мәгърифәтчелек хәрәкәте аны үз идеяләрен тарату-үткәрүдә киң файдалана. Тормышны акыл, белем, әхлак ярдәмендә үзгәртеп коруны максат иткән мәгърифәтчелек идеологиясе әдәбиятның тематикасын, идея юнәлешен, жанр төрлелеген, иҗат алымнарын һәм иҗат методын билгели. Халыкка якынрак булу өчен әдипләр чынбарлыктагы реаль күренешләргә активрак мөрәҗәгать итәләр. Бу исә реализмның торган саен киңрәк урын алуына китерә. Шул рәвешле, кешене көнкүреш яшәеш белән тыгыз мөнәсәбәттә һәм белем-тәрбиягә нисбәтле сурәтләүгә нигезләнгән мәгърифәтчелек реализмы мәйданга чыга. Аның мөһим сыйфатлары булып чынбарлыкка мөрәҗәгать итү, «табигый кеше»не (Ж. Руссо) үзәккә алу, халык тормышын яхшыртуны гыйлемгә, әхлак тәрбиясенә һәм тирәлек шартла-

[1] *Вәлиулла И.Ә.* Мәңгелек бәхет эзләреннән… Эсселәр. Казан: Школа, 2004. Б. 17.

[2] *Миннегулов Х.Ю.* Этапы развития тюрко-татарской, античной и русской литератур. Казань: Ихлас, 2014. С. 56–73.

рына бәйләп карау, искелек һәм яңалык көрәшен чагылдыру, рационализмга нигезләнү һ.б. тора. Мәгърифәтчелек реализмы XX йөз башы әдәбиятында да саклана, әмма иң зур казанышлар тәнкыйди реализмга, Европа тибындагы романтизмга нисбәтле язылган әсәрләр белән бәйле.

Беренче рус инкыйлабы йогынтысында яулап алынган гражданлык хокуклары Яңарыш хәрәкәтен яңа баскычка күтәрә. Иҗтимагый һәм мәдәни тормышта җитди үзгәрешләргә юл ачыла. XX йөз башында күпсанлы газета-журналлар чыгу, профессиональ театр оешу, дини реформаторлык, мәгариф системасын үзгәртеп кору, милли партияләр төзелү һ.б. татар әдәбиятына да уңай тәэсир итә. Ул үзенең «алтын чор»ына керә. Милли сүз сәнгате яңа темалар, жанр һәм жанр формалары, сурәт чаралары-алымнары белән байый. Милли тематика шул чор җәмгыятен борчыган барлык проблемаларны иңләп үтә. Озак вакытлар дәвамында Шәрык йогынтысында булган татар әдәбияты Гаребнең әдәби-эстетик карашларын үзләштерә башлый. Бу чорда Шәрык-Гареб синтезының матур үрнәге булган күпсанлы әсәрләр дөнья күрә. Татар сүз сәнгате реализм һәм романтизм белән бергә, рус-Европа әдәбиятларында киң урын алган модернизм юнәлешенең аерым агымнарын үзенә кабул итә. Гомумән, 1905–1917 еллар аралыгын үз эченә алган XX йөз башы әдәбияты Г. Тукай, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, М. Гафури, Дәрдемәнд, С. Рәмиев, Ш. Камал, Г. Камал, М. Фәйзи һ.б. иҗатында дөнья сүз сәнгате дәрәҗәсенә күтәрелә һәм бүген без «классика» дип атый торган бай мирас калдыра.

«Яңа заман әдәбияты»ның яңа этабы булган 1917 елдан алып 1950 еллар ахырына кадәрге дәвере «Совет чоры әдәбияты» дип билгеләнә. Әлеге чорны «Тоталитаризм чоры әдәбияты» дип атау да бар[1]. Каршылыклы мөнәсәбәткә билгеле бер нигез дә бар. «Тоталитаризм» төшенчәсе Сталин идарә иткән дәвер, әлеге шәхеснең эш стиле тудырган дәүләт системасы белән бәйле. 1917 елның октябрендә властька килгән большевиклар пролетариат диктатурасы игълан итә. Аңлашылганча, диктатура бер сыйныфның икенче сыйныф өстеннән гегемонлыгын, кеше ирекен чикләүне, нәрсәгәдер мәҗбүр итүне, үз идеологиясен көчләп тагуны аңлата. Шуның белән бергә, әлеге күренеш бөтен чорны да иңләп алмый. Әйтик, 1920 елларның күп өлеше язучыга иҗат иреге бирелү белән характерлана, сугыш елларында да иҗади мөмкинлекләр арта. Шуңа бу дәверне уртак исем белән «Совет чоры әдәбияты» дип атау үзен аклар кебек. Ил-халык тормышындагы җитди вакыйгаларга бәйле, татар әдәбияты бу елларда гаять каршылыклы үсеш кичерә.

---

[1] *Закирҗанов Ә.М.* Яңарыш юлыннан (Хәзерге татар әдәбият белеме мәсьәләләре). Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. Б. 51–52; *Закирзянов А.М.* Основные направления развития современного татарского литературоведения (кон. XX – нач. XXI в.). Казан: Ихлас, 2011. С. 144–145.

Шуңа да әлеге вакыт аралыгында түбәндәге чорлар аерып чыгарыла: «Гражданнар сугышы чоры (1917–1921 еллар)»; «20 нче еллар (1921–1932 еллар)»; «30 нчы еллар (1932–1941 еллар)»; «Бөек Ватан сугышы чоры (1941–1945 еллар)»; «Сугыштан соңгы еллар (1945–1950 еллар ахыры)».

1917 елның Октябрь инкыйлабы нәтиҗәсендә властька большевиклар килә. Җирне крестьяннарга бирүне һәм сугышны туктатуны яклап, алар халыкның күпчелеген үз артларыннан ияртүгә ирешә. Урыннарда советлар төзелеп, пролетариат диктатурасы урнаштырыла. Бәреп төшерелгән сыйныфның завод-фабрикалары, җирләре тартып алына. Шундый шартларда гражданнар сугышы башлана. Татар әдипләренең пролетариат диктатурасына, гражданнар сугышына мөнәсәбәте каршылыклы булып, берәүләр (Г. Ибраһимов, М. Гафури, Г. Камал, Ф. Бурнаш, Ш. Усманов һ.б.) тулысынча яклап чыга, икенчеләр (М. Фәйзи, Ш. Бабич, Ф. Әмирхан һ.б.) икеләнеп кала, өченчеләр (Г. Исхакый, Ф. Туктаров һ.б.) кабул итмичә, эмиграциягә китә. Бу еллар әдәбиятында түбәндәге үзенчәлекләр күзәтелә: инкыйлаб яңа әдәбият тудыра, ул исә көрәшне, дошманлыкны, максатка ирешү өчен кан түгүне матурлык итеп сурәтли; әсәрләргә «без» һәм «алар» каршылыгы килеп керә[1]; күпгасырлык әдәбият традицияләре буларак әдәп-әхлакны, милләт бердәмлеген саклау омтылышы; көрәшне чагылдырган яңа сурәт чараларына йөз тоту; шәхес мәнфәгатеннән бигрәк иҗтимагый мәнфәгатьне яклау һ.б. Инкыйлаб һәм гражданнар сугышы елларында татар әдәбияты ике төрле идеалны яклап чыга: берсе – милли азатлык идеалы, икенчесе – сәясәт белән бәйле булып, матур киләчәк һәм аның өчен көрәшү идеалы[2]. Әлеге сыйфатлар М. Гафуриның «Кызыл байрак», Ф. Борнашның «Чәчәктән һәйкәл», Г. Ибраһимовның «Яңа кешеләр» һ.б. әсәрләрендә тулы чагылыш таба.

1920–1930 еллар әдәбияты озак вакытлар бер чор эчендә өйрәнелде. Әмма аны икегә аеру сорала. Без «Егерменче еллар әдәбияты»ның чикләрен «1921–1932 еллар» дип күрсәтү ягында. Яшь совет дәүләте яшәешнең бөтен тармакларын яңа идеологиягә буйсындырырга омтыла. Шулай да язу иреге әлегә саклана. Әдәбиятта төрлелек, яңа стиль, форма эзләү күзәтелә. Төрле төркемнәр, оешмалар төзелә, әмма алар озын гомерле булмый. Татар әдәбияты яңага йөз тоту белән бергә, алдагы чор традицияләрен сакларга омтыла. Шул нигездә Г. Ибраһимов, К. Тинчурин, Һ. Такташ кебек әдипләрнең чор йөзен билгеләгән әсәрләре языла. Шул ук вакытта моңа кадәрге буржуаз җәмгыятьне тәнкыйтьләү, ул тудырган мирасны кире кагу, дингә, дин әһелләренә каршы

[1] *Яхин А.Г.* Әдәбият: унберьеллык мәктәпнең 10 нчы сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия. Казан: Мәгариф, 1995. Б. 5–8.

[2] *Яхин А.Г.* Әдәбият дәресләре: укытучылар, югары уку йортлары студентлары һәм укучылар өчен методик кулланма. Казан: Мәгариф, 2003. Б. 131–132.

чыгу, җитәкчеләрне мактау, яңа герой эзләү, сыйнфый көрәшне данлау омтылышлары да җәелә бара. Әдәбияттагы әлеге төрлелек, нигездә, ВКП(б) ҮК «Әдәбият-сәнгать оешмаларын үзгәртеп кору турында» карары (1932) чыкканчы саклана. Шуннан соң инде әдипләрне бер оешмага туплау, иҗат юнәлешен билгеле бер кысага кертү буенча киң эш җәелдерелә.

«Утызынчы еллар әдәбияты», 1932–1941 елларны үз эченә алып, тарихи-иҗтимагый планда социализмның нигездә төзелүе, яңа Конституция кабул итү һәм коточкыч репрессияләр белән характерлана. Әдәбият үсешенең иң катлаулы, каршылыклы чорына керә. 1934 елда СССР Язучылар берлеге төзелә һәм төп иҗат методы итеп социалистик реализм кабул ителә. Бу исә язучының иҗат иреген чикләүгә, хакимият карарларына, коммунистик идеологиягә йөз тотуга китерә. Шуның өстенә 1920 елларның икенче яртысында ук үзен сиздерә башлаган вульгар социологизм киң тамыр җәя. Әдәбиятта завод-фабрика тавышы, һәртөр лозунглар кеше шәхесен икенче планда калдыра. Татар әдәбияты таяныр җирлекне халык авыз иҗатында һәм үткән тарих сәхифәләрендә таба (Г. Бәшировның «Сиваш», М. Җәлилнең «Алтынчәч», Н. Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин», «Идегәй» һ.б. әсәрләр). Җәмгыятьнең алдынгы кешесен, яңа әхлагын эзләүдә, хезмәткә мөнәсәбәтен чагылдыруда уңышлы үрнәкләр пәйда була (Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ы, М. Җәлилнең «Хат ташучы» поэмасы һ.б.).

1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы әдәбиятның эчтәлеген тиз арада үзгәртүне таләп итә. Төп темалар буларак Ватанны сакларга ант итү, изге сугышка өндәү, чакыру, дошманга нәфрәт һ.б. урын ала. Аеруча публицистика һәм поэзия яңгыраш таба. Прозада хикәя, очерк жанрлары алгы планга чыга. Сугыш вакыйгаларына бәйле әдәбиятның идея эчтәлеге дә үзгәреш кичерә. Югарыда аталган темалар сугышның башлангыч чорында аеруча киң чагылыш тапса, алдагы елларда солдатның уй-хисләренә, теләк-омтылышларына, гомумән, рухи дөньясына игътибар арта, ә сугышның соңгы чорында җиңү шатлыгы, халыклар дуслыгы, гуманизм кебек мотивлар үзәк урынны били.

«Сугыштан соңгы еллар әдәбияты (1945–1950 еллар ахыры)» ил һәм халык тормышындагы вакыйгалар белән тыгыз бәйлелектә яши: репрессияләрнең яңа дулкыны булып уза; 1953 елда И. Сталин вафат була; партиянең XX съездыннан соң азмы-күпме демократик үзгәрешләр башлана һ.б. Сугыштан соңгы елларда киң урын алган «конфликтсызлык» теориясе әдәбият үсешен тоткарлый. Бертөрле, шаблон геройлар, сюжетлар, ясалма каршылыклар урын алган әсәрләр язылып, китап укучыларда теләктәшлек тапмый. Әдәбият, билгеле, үсеш-үзгәрешен туктатмый. К. Нәҗминең «Язгы җилләр», Г. Бәшировның «Намус» романнары Сталин (Дәүләт) премиясенә лаек була. М. Җәлил иҗаты

дөньякүләм яңгыраш ала. Репрессияләнгән әдипләрнең бай иҗаты 1950 еллар уртасында халыкка кайтарыла.

«Яңа заман әдәбияты»ның, 1960 еллардан башлап, 1980 еллар уртасына кадәр дәвам итә торган этабын «Торгынлык чоры әдәбияты», «Тоталитаризмнан соңгы чор әдәбияты» дип атау очрый. Шул ук вакытта әлеге атамаларның төгәл булмавы да ачык күренә. Бу елларда җәмгыятьтә торгынлык күзәтелсә дә, әдәбият җитди яңарыш кичерә, икенче яктан «тоталитаризм» дип аталган күренеш Сталин үлеме белән 1950 еллар уртасында тарих мәйданыннан китә, шуңа да аны 60–80 нче еллар белән бәйләү дә дөрес булмас. Әлеге чор әдәбиятын яңарыш һәм авангард эзләнүләр дәвере буларак өйрәнгән Д. Заһидуллина болай дип яза: «XX гасырның икенче яртысы татар әдәбиятында көчле әдәби-эстетик үзгәрешләр пәйда була. Алар татар әдәбиятының, советчыл идеология сызган чикләрдән үтеп чыгып, милли традицияләрне яңартуын тәэмин итәләр»[1]. Шул нигездә галимә «1960–1980 еллар әдәбияты»н «татар әдәбиятының милли нигезләргә кайту чоры»[2] дип бәяли.

1950 еллар ахырында иҗтимагый-сәяси тормыштагы үзгәрешләр әдәбият-сәнгать үсешенә гаять зур йогынты ясый. Икътисадта һәм сәясәттә торгынлык күзәтелсә дә, әдәбият җитди сыйфат үзгәрешләре юлына чыга. Татар сүз сәнгатендә официаль теләк-максатка һәм милли мәнфәгатьләргә йөз тоткан ике юнәлеш барлыкка килә. Соцреализм иҗат методы турында бәхәсләр барып, аның әдәби-эстетик чикләре, мөмкинлекләре бермә-бер киңәйтелә. Тема һәм жанр төрлелеге күзәтелә, тормышчан конфликт алгы планга чыга. Җәмгыятьтәге кимчелекләр, административ-бюрократик система я турыдан-туры, я эзоп теле ярдәмендә тәнкыйть ителә. Кеше шәхесенә, милләт язмышына, үткән тарихка игътибар арта.

1980 еллар уртасында башланып киткән үзгәртеп корулар нәтиҗәсендә ил тормышында яңа дәвер башлана. Без аны «Хәзерге татар әдәбияты» дип билгеләү ягында. Ул үз эчендә ике чорга бүленә: «Үзгәртеп корулар чоры әдәбияты» (1980 еллар уртасы – XX гасыр ахыры) һәм «XXI гасыр башы әдәбияты».

Икътисади, иҗтимагый, мәдәни тормыштагы үзгәрешләр тәэсирендә татар әдәбияты үз үсешендә «яңа дулкын»га (Д. Заһидуллина) керә. Милләт язмышы мәсьәләсе сүз сәнгатенең бөтен асылын биләп ала. Бу исә үткән тарихка, традицияләргә, тел сакланышына, милләтнең бүгенгесенә һәм киләчәгенә кагылышлы күпсанлы проблемаларның киң планда яктыртылуына китерә. Әдәбият тарихындагы «ак таплар» бете-

[1] *Заһидуллина Д.Ф.* 1960–19890 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. Б. 368.

[2] *Заһидуллина Д.Ф., Йосыпова Н.М.* XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек. Казан: Казан ун-ты, 2011. Т. 2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. Б. 5.

релеп, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Г. Рәхим һ.б. аерым әсәрләре, барыннан да бигрәк Г. Исхакый мирасы кайтарыла. Чит илләрдәге татар әдәбиятының матур үрнәкләре дөнья күрә. Нигездә реалистик һәм романтик юнәлешкә йөз тоткан татар сүз сәнгате модернизм һәм постмодернизм агымнарының алым-чараларына иркен мөрәҗәгать итә башлый.

XXI гасыр башы әдәбиятын аерым чор итеп аерып чыгару әдәбиятның үсеш-үзгәрешендәге яңалыклар белән билгеләнә. Дөрес, хәзерге сүз сәнгате азөйрәнелгән, әмма вакыт үткән саен аңа хас үзенчәлекләрне аерып чыгаруның артачагына шикләнмәскә мөмкин. Сыйфат үзгәрешләренең кайберләрен күрсәтеп үтик: шәһәр мәдәниятен үзләштергән яңа буын килү, шуңа нигезле авыл һәм шәһәр рухи мохитендә тәрбияләнгән яшь авторлар иҗатында үзенчәлекле синтез күзәтелү; яшәешне фәлсәфи аңлатуга омтылыш арта бару; туксанынчы еллардагы ашкынулы публицистик пафосның кимүе; милли тематикадагы бертөрлелекнең кеше шәхесенә игътибар, гомумкешелек кыйммәтләрен үзләштерү, аның белән кушылу рәвешендә үзгәрүе; милли үзенчәлекләргә ия булган һәм шул ук вакытта постмодернизм алымнарын үз иткән әдәбиятның үсүе; автобиографик материалларга игътибар арту нәтиҗәсендә мемуар һәм эссе жанрлары киңәю һ.б.

Шулай итеп, күпгасырлык татар әдәбияты тарихының дәверләргә, чор-этапларга объектив, төгәл бүленешен билгеләү, гаять бай сүз сәнгатебезнең системалы үсеш-үзгәрешен, табыш-югалтуларын, традицияләр дәвамчанлыгын һәм яңачалыкларын, халыкның иҗтимагый-фәлсәфи фикер үсешендәге, рухи тормышындагы урынын, тарихи-иҗтимагый, сәяси вакыйгаларны, танылган шәхесләрнең ролен һ.б.ны тулырак аңларга, шулар аша бүгенгебезне һәм киләчәгебезне яхшырту, камилләштерү юлларын ачыкларга җирлек бирә.

### 3.3. Татар әдәбияты тарихын өйрәнүнең төп аспектлары

Әдәбият белеме гасырлар дәвамында үсеп-үзгәреп, бай тәҗрибә туплый. Ул формалашу процессы кичергәндә үк әдәбиятны өйрәнүнең яңа юлларын, мөмкинлекләрен табуга нигезләнгән принципларын булдыру эшенә керешә. Алар исә, әдәбият тарихына, аерым авторлар иҗатына якын килү, бәяләү нигезе итеп алынган әдәби-эстетик, фәлсәфи карашлар, милли, тарихи, мәдәни шартлар йогынтысында метод, мәктәп, юнәлеш булып оеша. Чөнки белемнәрне гомумиләштерү һәм тикшеренүләрнең тагы да нәтиҗәле юлларын эзләү һәртөр фән үсешенең төп шартларыннан берсе булып тора.

Татар әдәбият белеме формалашу процессы кичергән XX йөз башында үк әдәбиятны өйрәнү юлларын, мөмкинлекләрен эзләүгә алына. Хезмәттә билгеләп үтелгәнчә, әдәбият фәне синкретик булуы белән характерлана, ягъни аерым китап булып яисә вакытлы матбугат

битләрендә дөнья күргән хезмәтләр һәм әдәбият теориясенә, һәм әдәбият тарихына, һәм әдәби тәнкыйтькә хезмәт итә. Шуның белән бергә, Г. Баттал, Җ. Вәлиди, Г. Сәгъди һ.б. эшчәнлегендә әдәбият тарихына, аерым авторлар иҗатына якын килү, бәяләү нигезе итеп алынган әдәби-эстетик, фәлсәфи карашлар нигезләнә, вакыт үтү белән фәнни принципларга үсеп әверелә. Татар әдәбият фәне, соңарып мәйданга килүе, каршылыклы үсеш кичерүе һәм әзерлекле кадрлар белән тәэмин ителмәве аркасында, дөнья әдәбият белемендә төрле чор-дәверләрдә, илхалыкларда формалашкан һәм шактый тулы калыплашкан сүз сәнгатен өйрәнү мәктәпләре, методлары, юнәлешләре казанышларына чагыштырмача аз мөрәҗәгать итә. Әмма бу тулысынча игътибарсыз калдыра дигән сүз түгел, чөнки фәнни метод, «закончалыкларны танып белү нигезендә барлыкка килгән кагыйдәләр буларак, алга таба да танып белүгә хезмәт итә»[1]. Шуңа да XX йөз башы әдәбият фәнендә культура-тарих мәктәбе принципларына таяну белән бергә, чагыштырма-тарихи яисә биографик һ.б. методларның нигез төшенчәләренә мөрәҗәгать итүләр күзәтелгән кебек, алдагы чорларда әлеге һәм башка мәктәп-метод-юнәлешкә таянып алып барылган тикшеренүләр урын ала. Гасырлар чигендәге әдәбият белеме дөньяви кабул ителгән казанышларны үзләштерү, үзебезнең бу өлкәдәге традицияләргә таяну һәм шулар нигезендә милли үзенчәлекләр калкытып куелган эзләнүләр юлыннан бара. Төрле дәвер, чор, этап әдәбияты тарихын яңача өйрәнү юлларын тикшергәндә әлеге мәсьәләләр дә игътибар үзәгендә тора.

Югарыда әйтелгәнчә, татар әдәбияты тарихы озак дәверләр дәвамында, нигездә, диахрон система буларак, ягъни әдәби хәрәкәтне хронологик эзлеклелектә өйрәнелә. Әдәбиятның эчке закончалыклары, иҗат тибы, юнәлеш һәм агым, жанр һәм стиль мәсьәләләре әлеге хронологик бүленеш эчендә, ягъни теге яки бу әдәби дәвергә, иҗтимагый ситуациягә бәйле тикшерелә. Шул сәбәптән, татар әдәбият белемендә реализм, романтизм, модернизм, иҗат типлары һәм методлары, юнәлешләр һәм агымнар һ.б. буенча махсус монография-тикшеренүләр күп түгел. Бу урында 1960–1980 еллар татар әдәбият белеме үсешенә зур өлеш керткән Х. Госман, Г. Халит, Н. Юзиев, И. Нуруллин, Р. Ганиева, Ф. Хатипов, Н. Хисамов, Й. Нигъмәтуллина һ.б.ның исемнәрен атап китү урынлы булыр. Аларның хезмәтләрендә төрле чор һәм дәвер татар әдәбияты, аерым шәхесләр иҗаты әдәби ысул, метод, юнәлеш, агым мәсьәләләре белән тыгыз бәйләнештә тикшерелә.

XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы әдәбият фәнендә татар әдәбияты тарихын яңача өйрәнү буенча җитди адым ясала. Яңа хезмәтләрдә әдәбиятның төрле чорлары үсеш-үзгәрешендәге хронологик күре-

[1] *Борев Ю.Б.* Введение в теорию литературы // Теория литературы. Т. 1. Литература. М.: ИМЛИ им. М. Горького РАН, 2005. С. 11.

нешләр белән бергә, эчке закончалыкларына, төп тенденцияләренә, башка әдәбиятлар белән багланышына, тормыш-чынбарлыкны чагылдыру үзенчәлекләренә, әдәби иҗатта шәхес концепциясе эволюциясенең чагылышына һ.б.га бәйле эзләнүләр, фикер-карашлар алгы планга чыга. Әдәби процессны синхрон система буларак, ягъни үз эчке закончалыклары нигезендә үсеп-үзгәреп торучы иҗат юнәлешләре, агымнары, стиль тенденцияләре эволюциясе буларак тикшергән күпсанлы хезмәтләр дөнья күрә[1].

### *3.3.1. Борынгы һәм урта гасырлар әдәбияты*

Күпгасырлык татар әдәбияты үзенең тамырлары белән мифологиягә һәм фольклорга барып тоташа. Кешеләрнең ышануларына, күзаллауларына бәйле барлыкка килгән мифлар «халык иҗатының иң борынгы катламы булып исәпләнә»[2]. Алар кешелек җәмгыятенең билгеле бер дәверендә дөньяның яралуын, кеше яшәешен, табигать күренешләрен һ.б.ны аңлату рәвешендә барлыкка килә. Мөһим сыйфат буларак синкретизм – төрле башлангычларның кушылуыннан гыйбарәт. Мифлар төрле формаларда безнең көннәргә дә килеп җитеп, поэтик образ тудыру алымы буларак әдәбиятка да киң үтеп керәләр. Киң планда караганда мифология гасырлар дәвамында сәнгать әсәрләре өчен җирлек һәм чыганак ролен үти. Иҗтимагый аң формасы буларак, дөньяны мифологик кабул итү үзенчәлекләре, халык тормышында (көнкүрешеннән алып дини ышануларына кадәр) киң чагылыш тапкан кебек, матур әдә-

[1] *Ганиева Р.К.* Восточный Ренессанс и поэт Кул Гали. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1988. 172 с.; *Ганиева Р.К.* Традиции Восточного Ренессанса в тюркских литературах Средневековья и Нового времени. Казань: Фэн, 2014. 272 с.; *Нигматуллина Ю.Г.* Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. Казань: Фэн, 1997. 190 с.; *Нигматуллина Ю.Г.* «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. Казань: Фэн, 2002. 167 с.; *Нигматуллина Ю.Г.* Системно-комплексное исследование художественного творчества: история научного направления в Казанском университете. Казань: Фэн, 2004. 251 с.; *Нигматуллина Ю.Г.* Татавангард и современный цивилизационный процесс. Казань: Фэн, 2011. 56 с.; *Саяпова А.М.* Поэзия Дардменда и символизм. Казань: Изд-во КГПИ, 1997. 210 с.; *Саяпова А.М.* Дардменд и проблема символизма в татарской литературе. Казань: Алма-Лит, 2006. 246 с.; *Заһидуллина Д.Ф.* Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. 255 б.; *Заһидуллина Д.Ф.* Дөнья сурәте үзгәрү: XX йөз башы татар әдәбиятында фәлсәфи әсәрләр. Казан: Мәгариф, 2006. 191 б.; *Заһидуллина Д.Ф.* 1960–1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 383 б.; *Загидуллина Д.Ф.* Татарская поэзия рубежа XX–XXI веков (1986–2015): эстетические ориентиры и художественные поиски. Казань: АН РТ, 2017. 268 с.; *Загидуллина Д.Ф.* Современная татарская проза (1986–2016): основные тенденции историко-литературного процесса. Казань: АН РТ, 2017. 246 с.; *Зарипова-Четин Ч.* Проблема демонизма в творчестве С. Рамиева в контексте восточно-европейской эстетики. Казань: Мастер Лайн, 2003. 175 с. һ.б.

[2] *Бакиров М.Х.* Татар фольклоры: югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 2008. Б. 19.

биятта авторның үзенә хас сәнгати фикерләвен укучыга җиткерү өчен дә файдаланыла. Ул, гадәттә, әдәби әсәрнең төп идеясен ачуга хезмәт итүче образ-символ, әдәби алым булып килә. «XX гасырда мифология белән әдәбият арасындагы хезмәттәшлек тагын да тыгызлана: традицион мифологик сюжетларны һәм образларны әдәби әсәр тукымасына кертеп җибәрү белән беррәттән, язучылар миф тудыруга, автор аңы аша уздырып, тормышның мифологик моделен төзүгә игътибар бирәләр»[1]. Хәзерге татар әдәбият фәнендә төрле чор сүз сәнгате әсәрләрен мифология белән тыгыз бәйләнештә өйрәнү активлашты. Аның уңышлы үрнәкләре буларак, М. Бакиров, Ф. Урманче, М. Ибраһимов, Л. Дәүләтшина һ.б.ның хезмәтләре дөнья күрә.

Уртак мирас булган гомумтөрки поэзиянең башлангычына караган сораулар гаять катлаулы булып, галимнәрнең игътибарын җәлеп итеп килә. Шуңа да М. Бакировның гомумтөрки поэзиянең генезисы-яралуы һәм иң борынгы формалары турында тикшеренүләре дөнья күрү[2] татар әдәбият белемендә үзенчәлекле вакыйга буларак бәяләнә. Галим поэзиянең мифология һәм йолалар белән керешкән башлангыч формаларына иркен мөрәҗәгать итеп, фольклористикада моңа кадәр яшәп килгән караш-фикерләр белән бәхәскә керә, үз позициясен күпсанлы мисаллар белән дәлилли.

Борынгы поэзиянең яралгысы хезмәт процессындагы эндәшләрдән, эмоциональ кабатлаулардан үсеп чыгуы, гомуми атамаларның акрынлап конкрет эчтәлекле сүзләр белән алышынуы һәм вакытлар үтү белән сүз-текстның тотрыклы хәлгә килү процессы эзлекле күзәтелеп, хезмәт һәм поэзия синкретизмы таркалу нигезендә поэтик мөстәкыйльлек башлангычына юл ачылу билгеләнә. М. Бакиров мифологияне, иң борынгы иҗтимагый аң формасы буларак, борынгы ыруглар чорында бердәнбер идеология һәм дөньяга караш формасы дип күрсәтә һәм аны, дөньяны поэтик үзләштерүнең беренче баскычы, дип нәтиҗә ясый. Мифология һәм поэзиянең үзара катлаулы мөнәсәбәтен ачыклаганда мимесис (ияру, охшату) һәм тел факторларына таяну кирәклеген искәртә.

Борынгы поэтик сүз сәнгатенең башлангычын тикшерү барышында күренекле галимнәр А.Н. Веселовский, А.Ф. Еремеев, М.С. Каган, Р.Я. Журов һ.б.ның карашларын җентекле өйрәнү аша моңа кадәр фәндә калыплашкан фикерләр белән бәхәскә керә һәм, борынгы поэзия бишеге булып йола-миф берлеге тора, дигән карашны яклый. Кеше хезмәтенең үзенчәлекле дәвамы булган йола-ритуаллар һәм мифологик идеология элек, үзара керешеп, аерылгысыз бербөтен, ягъни йола-мифология син-

[1] *Ибраһимов М.И.* Миф // Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. Казан: Мәгариф, 2007. Б. 114.

[2] *Бакиров М.Х.* Шигърият бишеге: Гомумтөрки поэзиянең яралуы һәм иң борынгы формалары. Казан: Мәгариф, 2001. 343 б.

кретизмы тәшкил итүләре дәлилле раслана. Әлеге фәнни концепциягә бәйле, автор шигъри-поэтик жанр яралгыларын һәм архаик жанрларны системалы рәвештә тикшерә.

М. Бакиров тикшеренүләренең тагын бер мөһим тармагы төрки бабаларыбызның (һун-гуннарның) поэтик сүз сәнгате нинди булуын ачыклау белән бәйле. Галим фикеренчә, ыру-кабилә коллективыннан әкренләп оештыручы – башлап йөрүче шәхес аерылып чыга һәм һун чорларыннан башлап шәхси иҗат һәм риторик сөйләм үрнәге буларак ораторлык сәнгате оеша. Гомумән, галимнең тикшеренү-табышлары, бердән, сүз сәнгатенең башлангычын, мифология һәм фольклор белән үзара тыгыз бәйләнешен ачарга, икенчедән, гомумтөрки поэзиянең гасырлар дәвамында үсеш-үзгәреш эволюциясен тулырак күзалларга, өченчедән, күпгасырлык әдәбиятта урын алган архетипларның, мифологиядән, фольклордан килүче образларның, мотивларның, бай сурәт чараларының ерак тамырларын, төрле чор сүз сәнгатендә башкарган функцияләрен тирәнтен аңларга ярдәм итә.

Татар шигъриятен мифопоэтик планда тикшерү Ф. Урманче хезмәтләрендә киң урын алып тора. Аның «Борынгы миф һәм бүгенге шигырь (Р. Фәйзуллин шигъриятенә бер караш)[1], «Олыгайгач, бер дога» («Борынгы миф һәм бүгенге шигырь» циклыннан: Рәдиф Гаташ иҗаты турында)», «Роберт Миңнуллин: шигъри осталык серләре»[2] хезмәтләре XX гасырның икенче яртысы татар шигъриятен яңа яссылыкта тикшерүгә юл салуы белән кыйммәт. Галим әлеге катлаулы мәсьәләгә чор, заман үзгәрешләренә нисбәтле якын килә һәм шигъри осталыкның, укучы күңеленә юл табуның мөһим шарты итеп халык авыз иҗаты белән бәйләнешне билгели. Ф. Урманче фикеренчә, соңгысы шагыйрь иҗатында тирән яшерелгән булырга, хәтта аны әдип үзе белмәскә дә мөмкин. Чөнки борынгыдан килүче образ-мотивлар белем, тәҗрибә рәвешендә безнең аңыбызда берегеп кала һәм иҗатта чагылыш таба. К. Юнг мондый күренешне «коллектив аңсызлык» дип атый. Автор танылган шагыйрь Р. Фәйзуллин шигъриятен чор әдәбияты контекстында тикшерә һәм үзенә генә хас сыйфат-билгеләрнең борынгы тамырларын ача. Х. Мәхмүтов язганча, хезмәттә шагыйрьнең мифология, әкият, дастан традицияләрен үстерүе, аларда урын алган сюжет, образ, мотивларның яңа серле-сихри мәгънәләрен ачуы, шулар аша чор, заман сорауларына җавап эзләве билгеләнә[3]. Ә менә Р. Гаташны романтик шагыйрь

---

[1] *Урманче Ф.И.* Борынгы миф һәм бүгенге шигырь (Татарстанның халык шагыйре Р. Фәйзуллин шигъриятенә бер караш). Казан: Школа, 2002. 260 б.

[2] *Урманче Ф.И.* Роберт Миңнуллин: шигъри осталык серләре. Казан: Мәгариф, 2005. 335 б.

[3] *Мәхмүтов Х.Ш.* Шигъриятнең тирән тамырлары // Казан утлары. 2003. № 10. Б. 139–142.

буларак бәяләп, иҗатының ислам мифологиясе белән тыгыз бәйләнешен дәлилли. Шагыйрьнең сәнгати фикерләвендә Шәрык мотивларының урынын, ролен билгеләү дә мөселман дөньясы белән булган тыгыз бәйләнешләрне торгызу, традицияләрне яңарту булып ачыла. Р. Миңнуллин иҗатын Ф. Урманче «моң» төшенчәсе аеруча киң урын алган әдип буларак өйрәнә. Сурәт чаралары остасы дип танылган шагыйрь мөрәҗәгать иткән тема-мотивлар (Идел, Агыйдел, Сөн, Алып батыр, Аккош, Үлем һәм үлемсезлек, Зират, Кошлар моңы һ.б.) бары тик халык авыз иҗаты белән тыгыз бәйләнештә генә тулы ачыла һәм поэтик яңгыраш ала, дигән нәтиҗәгә килә ул.

Мифопоэтика мәсьәләләре уңышлы чагылыш тапкан хезмәтләрнең берсе булып М. Ибраһимовның «Миф в татарской литературе XX века: проблемы поэтики»[1] хезмәте тора. Автор мифопоэтика мәсьәләсенең кыскача тарихын, «миф» төшенчәсенең асылын ачу аша конкрет әсәрләргә мифопоэтик анализ ясауны үзәккә ала. А. Гыйләҗевның «Җомга көн, кич белән...» повесте мифологик образларның туры кулланылышы һәм «яшерен мифологизм»ны ачу максатында өч яссылыкта тикшерелә: сюжет катламы; персонажлар системасы һәм хронотоп. Әлеге структура повестьның әдәби-эстетик үзенчәлекләрен тулы ачарга, моңа кадәр әдәбиятчылар игътибарыннан төшеп калган мәсьәләләрне калкытып куярга мөмкинлек бирә. Аерым алганда, сюжет катламындагы «яңадан туу», «кайту», «ялгызлык» мотивларының мифологиягә барып тоташкан йолалар белән бәйлелеге билгеләнә. Автор вакыйгаларга нисбәтле хәзерге, тарихи һәм психологик вакытларны аерып чыгара һәм соңгысының елга, буа образлары белән тыгыз бәйләнешенен ача. Әдәби урынга бәйле почта бинасының үзәккә алынуы, шулай ук юл хронотобына бәйле нәтиҗәләре әсәрне яңача бәяләүгә китерә. М. Ибраһимов әдәби әсәрләрдә архетипларның һәм образ-мифологемнарның тарихи-мәдәни шартлар йогынтысында трансформацияләнүен, әлеге үзгәрешләрнең мәдәни-тарихи ситуация, авторның индивидаль карашы, әсәрнең жанры кебек факторга нигезләнүен билгели. Ә. Еники һәм В. Распутин иҗатларына чагыштырма анализ аша бу мәсьәләнең милли мәдәният традицияләре белән тыгыз бәйле булуы турындагы нәтиҗәгә килә. Хезмәтнең тагын бер яңалыгы булып хәзерге әдәбиятта мифларның кулланылыш һәм алар үтәгән функцияләрне ачыклау тора. Әсәрләрне төп максатка бәйле анализлау аша типологик пландагы уртаклыкларны аерып чыгара: миф бер төр әсәрләрдә әдәби алым буларак кулланыла (Н. Гыйматдинова); икенчеләрендә яңа миф тудырыла (Ф. Бәйрәмова), өченчеләрендә мифның җимерелүе күзәтелә (З. Хәким).

[1] *Ибрагимов М.И.* Миф в татарской литературе XX века: проблемы поэтики. Казань: Гуманитария, 2003. 64 с.

Халык авыз иҗаты белән язма әдәбиятның тыгыз бәйләнеше күпгасырлар буе дәвам итә. Бу урында фольклорның мифология белән мөнәсәбәтен дә искәртеп китү урынлы булыр, чөнки мифологик мотивлар, образлар халык авыз иҗатына күпләп үтеп керә, аны баета, төрләндерә һәм аның аша сүз сәнгатендә чагылыш таба. Фольклор белән матур әдәбият бәйләнеше турында Л.И. Емельянов болай дип яза: «Фольклор үзенең тарихында күптөрле үзара мөнәсәбәтләргә кергән әдәбиятның табигый юлдашы, үсеш-үзгәреш кичергән мәдәни-тарихи контекстның җитди бер өлеше генә дә түгел, бәлки танып белүнең үзгә формасы буларак эчтәлеген билгеләүче генетик башлангычы булып тора»[1]. Шуңа да халык авыз иҗаты әсәрләре белән сүз сәнгате бәйләнеше, аерым авторлар иҗатында аның чагылышын өйрәнү әдәбият белеменең мөһим мәсьәләләреннән санала. К. Насыйри, Г. Тукайлардан килүче традицияләр XX–XXI гасырлар чигендә Ф. Урманче, Х. Мәхмүтов, Г. Гыйльманов, А. Садыйкова, Л. Мөхәммәтҗанова һ.б.ның хезмәтләрендә уңышлы дәвам иттерелә.

Ф.Урманчеевның «Дастаннарга лаек замана (Борынгы фольклор һәм хәзерге поэзия)» хезмәте[2] бу юнәлештәге тикшеренүләрне тарихи-генетик яссылыкта алып баруы белән әһәмиятле. Автор хәзерге татар шигъриятенә бәя биреп, интеллектуаль көченең ныгуын, арта баруын дәлилли. 1960 елларда ныклы нигез салынган әлеге юнәлеш поэзиядә фикер белән хиснең үрелеп баруына, фәлсәфи эчтәлекнең киң колач җәюенә юл ача. Ф. Урманчеев фикеренчә, хәзерге поэзияне бөтен тулылыгында аңлау һәм бәяләү өчен үткән тарихыбыз сәхифәләренә, халыкның этнографиясенә, яшәеш фәлсәфәсенә үтеп керү сорала. Әлеге үзенчәлек исә шигъриятнең халык авыз иҗаты белән бәйләнешен тикшерүгә китерә. Хезмәттә эзлекле рәвештә шигъри сюжетларда, образларда, сурәт чараларында фольклордан килүче билгеләр ачыкланып, чынбарлыкны тасвирлаудагы үзенчәлекләр, аерым шагыйрьләрдәге табышлар тагы да калкытып куела.

А.Х. Садыйкованың «Фольклор в эстетике Галимджана Ибрагимова» хезмәте[3] татар классик әдибенең бай иҗатын халык авыз иҗатына тыгыз бәйләп тикшерүе белән үзенчәлекле. Автор, язучының күпсанлы әсәрләренә тирән анализ аша, алардагы тема-мотивларның, образларга хас характер сыйфатларының халык күңелендә урын алган дастаннардан, әкиятләрдән, башка күптөрле жанрлардан килүен дәлилли.

[1] *Емельянов Л.И.* Литературоведение и фольклористика // Взаимодействие наук при изучении литературы. Л.: Наука, 1981. С. 108.

[2] *Урманчеев Ф.И.* Дастаннарга лаек замана (Борынгы фольклор һәм хәзерге поэзия). Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. 222 б.

[3] *Садекова А.Х.* Фольклор в эстетике Галимджана Ибрагимова. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 1995. 103 с.

А. Садыйкова фикеренчә, аның эстетикасы нигезендә матурлык сәнгать башлангычына – халык иҗатына – мөрәҗәгать итү белән барлыкка килә дигән аңлатма ята. Г. Ибраһимов иҗатының киң яңгыраш алуы, татар әдәбиятында җитди традицияләргә нигез салуы, халык тормышын бөтен күптөрлелегендә, бай төсмерләрдә, халыкчан характерлар аша чагылдыруының нигезендә фольклорга иркен мөрәҗәгать итүе тора. Халыкның фольклор әсәрләрендә тупланып килгән хыял-өметләре, идеаллары язучы әсәрләрендә әдәби-эстетик сурәтләрдә чагылыш таба. Нәтиҗәдә, «фольклор хикәяләү белән, Г. Ибраһимовның реалистик әсәрләре мәгънәсе һәм эстетикасы белән кушылып китә»[1], – дип яза галимә. Ә менә Л. Мөхәммәтҗанованың «Татарские книжные дастаны: история становления жанра и поэтика»[2] хезмәте фольклор һәм язма әдәбият бәйләнешен дастан жанрына нисбәтле тикшерү белән әһәмиятле. Автор китаби дастаннарның барлыкка килү, формалашу шартларын ачыклау аша, аларның поэтик үзенчәлекләрен билгеләүгә килә. Бу исә фольклордан матур әдәбиятка күчкән күпсанлы әдәби образларның, мотивларның, стиль үзенчәлекләренең халык авыз иҗаты белән бәйләнешен һәм әсәрдә башкарган әдәби вазифаларын тулы бәяләргә мөмкинлек бирә.

**Борынгы һәм урта гасырлар татар әдәбияты** – идеологик басымга азрак дучар булган дәвер. Ул чорларның тарихи-иҗтимагый һәм мәдәни күренешләрен, әдәби ядкәрләрнең алдагы буыннар өчен рухи азык булып хезмәт итүен, халыкның яшәү рәвешен, уй-хыялларын чагылдырган әсәрләрнең кыйммәтен, әдипләрнең сәнгати фикерләүдәге табышларын ачкан хезмәтләр[3] бүген дә әһәмиятен җуймаган тикшеренүләр нәтиҗәсе булып тора.

XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы әдәбият белемендә борынгы һәм урта гасырлар әдәбиятын өйрәнү мәсьәләләре даими игътибар үзәгендә тора. Югарыда аталган эзләнүләргә, гомумән, татар әдәбияты тарихын өйрәнү тәҗрибәсенә нигезләнеп, киң планда, төрле аспектта тикшеренүләр алып барыла. Нәтиҗә буларак Р. Ганиева, Н. Хисамов, Х. Миңнегулов, Р. Исламов, Ә. Шәрипов, Р. Әмирханов, Ф. Яхин, Г. Дәүләтшин һ.б.ның җитди монографияләре дөнья күрә. Фәнни хезмәт-

---

[1] *Садекова А.Х.* Фольклор в эстетике Галимджана Ибрагимова. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 1995. С. 63.

[2] *Мухаметзянова Л.Х.* Татарские книжные дастаны: история становления жанра и поэтика: автореф. дис. ... докт. филол. наук. Казань, 2015. 45 с.

[3] Борынгы татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. 576 б.; Татар әдәбияты тарихы: алты томда. 1 т. Борынгы һәм урта гасырлар дәвере. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 567 б.; *Хисамов Н.Ш.* Поэма «Кысса-и Йусуф» Кул Али: Анализ источников сюжета и авторского творчества. М.: Наука, 1979. 254 с.; *Хисамов Н.Ш.* Бөек язмышлы әсәр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 336 б.; *Миңнегулов Х.Й.* Сәйф Сараи. Тормышы һәм иҗаты. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1976. 190 б.; *Таһирҗанов Г.Т.* Тарихтан – әдәбиятка. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 168 б.

ләргә карата язылган рецензия-бәяләмәләрдә аларның кыйммәтен, яңалыгын ачыклау белән бергә, алда торган бурычларны күрсәтү омтылышлары да ясала. Бу дәвер әдәбиятын өйрәнүнең торышы турында Х. Миңнегулов язмасы игътибарга лаек. Автор җәмгыятьтәге үзгәрешләргә нисбәтле Урта гасырларның төрки телле сүз сәнгатен татар фәнендә тикшерүнең торышына туктала, күпсанлы китапларга бәя бирә. Әлеге өлкәдә тикшеренүләрнең тематикасы киңәю, яңа фактларның, исемнәрнең, әсәрләрнең әйләнешкә кертелүен, тарихи-чагыштырма һәм әдәби-эстетик планда өйрәнүләрнең тирәнәюен, тюркология һәм, гомумән, дөнья фәне казанышларына нигезләүне билгеләп үтә. Шуның белән бергә, бу чор әдәбиятын өйрәнү бурычларына да туктала: текстологик эшнең фәнни принципларын саклау, әдәби мирасны тулысынча китап укучыларга кайтару, дәверне этап-чорларга бүлүдәге каршылыкларны чишү, шигырь төзелеше, жанр төрлелеге, үзара йогынты күренешләре, традицияләр һәм яңачалык мәсьәләләре һ.б.[1]

Борынгы һәм урта гасырлар әдәбиятын фәлсәфи-эстетик планда һәм Көнчыгыш Ренессансы белән тыгыз бәйләнештә яңача өйрәнүне башлап җибәрүчеләрнең берсе – Р.К. Ганиева. Аның «Восточный Ренессанс и поэт Кул Гали» монографиясе фәнни-теоретик һәм фактик чыганакларның байлыгы, әдәби материалны, төрле чорларны киң планда һәм тирәнлектә иңләп алуы белән аерылып тора. Галимә тикшеренүләренең методологик нигезе булып герменевтика[2] тора һәм өстенлекле рәвештә чагыштырма-тарихи методка таяна. Р. Ганиева әлеге хезмәтендә Шәрык Ренессансы йогынтысында Урта гасыр татар әдәбияты беренче Яңарыш чорын кичерә дигән нәтиҗәсе белән татар әдәбият белеменә яңалык алып килә. «Югары эстетик дәрәҗәдәге гарәп һәм фарсы әдәбиятлары белән бәйләнештә булу XII–XIII гасыр болгар-татар әдәбиятының гуманистистик традицияләрне үзләштерүенә һәм ренессанс

[1] *Миннегулов Х.Ю.* О современном состоянии изучения тюркоязычной литературы Средневековья в Татарстане // Записи разных лет (Татарская литература: история, поэтика и взаимосвязи). Казань: Идел-Пресс, 2010. С. 34–48.

[2] Герменевтика – текстларны аңлату, аларны шәрехләү принциплары турындагы фән. Ул гуманитар фәннәрне өйрәнүнең методологик нигезен тәшкил итә һәм авторның укучы белән аралашу-бәйләнеш характерын билгели. Фән буларак, герменевтика XIX йөздә Ф. Шлейермахер, В. Дильтей хезмәтләренә нисбәтле барлыкка килә. XX йөздә Х. Гадамер, Г. Шпет, М. Бахтин тарафыннан үстерелә. Әлеге фән, әдәбият һәм сәнгатьтә аңлашылмаучылыктан бигрәк, аңлау процессына йөз тота. Әдәби әсәр текстында һәрвакыт ике башлангыч яши, берсе – билгеле бер кагыйдәләргә нигезләнү, икенчесе – авторның үзенчәлегенә бәйле, алардан читләшү. Шуңа күрә әсәрне аңлау өчен әлеге кагыйдәләрне белү генә җитми, бәлки авторның сүз, фикер сөрешен тоемлау максатында аның роленә керү сорала. Ул исә «дивинация» дип аталган күренешкә китерә, ягъни текстны яңача аңлатуга, авторны тулырак ачуга бәйле һәм, иң мөһиме, бер акт белән генә тәмамланмыйча, ә төрле дәрәҗәдә кабатланып торучы процесс тудыра. Аны Ф. Шлейермахер «герменевтик түгәрәк» термины белән атый.

мотивларының тизләтелгән үсешенә уңай йогынты ясый»[1], – дип яза автор. Кол Гали поэмасында гарәп-фарсы әдәбиятларындагы тәҗрибә гомумиләштерелә, синтезлаша. Галимә фикеренчә, «Кыйссаи Йосыф» әсәре традицион мотивларны үстерүе, яңартуы белән оригинальлеген саклый. Р. Ганиева Болгар чоры әдәби ядкәрендә чынбарлыкка романтик мөнәсәбәт, караш өстенлек итүен, шуңа нигезле авторның фәлсәфи-дидактик, дини-мистик һәм романтик мәхәббәткә бәйле идея-эстетик карашлары чагылуын дәлилли. Кол Галинең сәнгати фикерләвендә табыш-үзенчәлек итеп, табигатьнең бер өлеше рәвешендә кеше шәхесенең алгы планга куелуы (антропологизм) һәм, ренессанс романтизмы әдәбиятына хас булганча, кешенең эчке һәм тышкы матурлыгын, акыл көчен, хисләр муллыгын раславы билгеләнә.

Р. Ганиеваның Борынгы һәм Урта гасырлар әдәбиятына нисбәтле эзләнү-тикшеренүләре нәтиҗәсе буларак дөнья күргән «Татарская литература: традиции, взаимосвязи» китабы[2] әдәбият белемендәге соңгы казанышларга нигезләнеп, татар әдәбиятының аерым чорларын, әдипләр иҗатын, бер яктан, халыкның рухи тормышына, яшәү рәвешенә, икенче яктан, ислам идеологиясенә, өченче яктан, Шәрык һәм татар сүз сәнгатендәге Яңарыш чагылышына һәм аның традицияләренә, дүртенче яктан, әдипнең сәнгати фикерләү үзенчәлегенә нисбәтле тикшеренүнең уңышлы үрнәге булып тора. Галимә, Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» дастаны турындагы фикерләрен үстерә барып, аның Төрки һәм Шәрык Ренессансының аерылмас өлеше булуын билгели һәм әсәрдә, мөселман неоплатонизмына таянган хәлдә, Коръәни карашлар аша болгар-татар җирлегендә матурлык, акыл һәм мәхәббәт, тән һәм җан этик-эстетик төшенчәләре, сәнгать һәм бер аллалык (әт-Тәүхид) фәлсәфәсе кебек Урта гасырның мөһим проблемалары чагылышы үзенчәлеген ача. Р. Ганиева Кол Галинең гарәп-мөселман фәлсәфәсе йогынтысында язылган поэмасында мөселман неоплатонизмының түбәндәге сыйфат-билгеләрен аерып чыгара: а) кеше шәхесенең матурлыгын идеаллаштыру; автор фикеренчә, галәмнең бөтен матди байлыгы да кеше матурлыгына тиң түгел; ә) поэманың әдәби структурасында төс һәм нур образларының мөһим роль уйнавы, аларның исә, матурлык төшенчәсе белән кушылып, неоплатонизм фәлсәфәсенә нигезләнүе; б) әсәрдәге образлар системасының математик саннар һәм терминнар белән баетылуы да грек һәм шәрык неоплатонизмы фәлсәфәсе йогынтысын күрсәтә (чагыштырулар, саннарда чагылган гиперболалар һ.б.); в) хисләр дөньясын идея, акыл дөньясына каршы кую; акыл символы булып Йосыф тәкъдим

[1] *Ганиева Р.К.* Восточный Ренессанс и поэт Кул Гали. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1988. С. 72.

[2] *Ганиева Р.К.* Татарская литература: традиции, взаимосвязи. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. 272 с.

ителсә, хис-мәхәббәт символы булып Зөләйха күтәрелә; г) «Кол Гали» дигән тәхәллүснең дә неоплатоник традицияләрдә бирелүе: авторның һәм аның әсәренең Аллага мөнәсәбәте барлыгын аңлата; шигъриятне шагыйрь Алла биргән илһам чыганагы дип саный, шуңа да ул укучы-тыңлаучыны илһамландыра, рухына уңай йогынты ясый һәм әхлакый бозыклыклардан арындыра; д) Алланың геройлар тормышына һәм вакыйгаларга бик еш катнашуы һ.б.

XVI йөзнең беренче яртысында яшәгән Мөхәммәдъяр иҗатын төрки Ренессансы кысаларында тикшерү, аның поэмалары белән Нәвои һәм Фөзулинең гуманистик поэзиясе арасындагы типологик охшашлыкны ачыклау да татар шагыйре турындагы караш-фикерләребезне бермә-бер киңәйтә, баета. Белгәнебезчә, XVI гасыр урталарыннан алып XVIII гасыр ахырларына кадәр татар җәмгыяте торгынлык кичерә. Рухи тормыштагы төшенкелек әдәбиятта да чагылыш таба. Бу чор сүз сәнгатен бертөрле һәм берьяклы гына аңлату дөрес нәтиҗәләргә китерми. Р. Ганиева фикеренчә, ренессанс гуманизмы тибындагы неоплатоник эстетика үз урынын ислам идеологиясе һәмсуфичылык белән бәйле неоплатоник карашларга бирә. Мисал өчен, Мәүла Колый иҗатында ул, бер яктан, иҗтимагый һәм рухи тормышның каршылыклары, яшәешнең мәгънәсезлеге, гомернең кыскалыгы, үлемнең якынлыгы турындагы фикерләрдә, икенче яктан, гомумкешелек идеаллары булган гуманизмга, дуслыкка, гаилә бәхетенә, мәхәббәткә, юмартлыкка, игенче хезмәтенә дан җырлауда чагыла[1]. Ә инде иҗатында Урта гасыр романтизмыннан реализмга күчеш чоры үзенчәлекләре гәүдәләнгән Г. Утыз Имәни әсәрләрендә романтик-неоплатоник традицияләр буларак матурлык һәм сабырлык, тән һәм җан, фән һәм сәнгать мәсьәләләре эстетик планда ачыла. Галимә билгеләвенчә, шагыйрь белемне мөселман дөньясында кабул ителгәнчә аңлый: дини-фәлсәфи һәм мәгърифәтчелек. Яшәеш өчен кирәк дип дини белемне саный. Тән һәм җан, аскетлык кебек мәсьәләләрдә дини-суфичыл карашларны яклап, укучысын түземлек-сабырлыкка өндәгән әдипнең әхлакый идеалын каршылыкларны җиңеп максатына ирешкән көчле рухлы кеше билгели[2]. Ә инде XIX йөз ахырларыннан башлап татар һәм башка төрки әдәбиятларда мөселман цивилизациясе, ренессанс романтизмы һәм неоплатоник эстетика белән булган күпгасырлык бәйләнешләрдән читләшү күзәтелеп, европачыл әдәби фикерләүнең катлаулы процессына тартылу башлана дигән нәтиҗә ясала[3].

---

[1] *Ганиева Р.К.* Ренессансные и религиозно-мистические мотивы в поэзии Мэвла Колый // Татарская литература: традиции, взаимосвязи. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. С. 24–29.

[2] *Ганиева Р.К.* Антиклерикализм и этико-эстетические идеалы Утыз Имяни // Татарская литература: традиции, взаимосвязи. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. С. 30–53.

[3] *Ганиева Р.К.* Восточный Ренессанс и тюркские литературы Средневековья // Татарская литература: традиции и взаимосвязи. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. С. 3–13.

Р. Ганиева «Традиции Восточного Ренессанса в тюркских литературах Средневековья и Нового времени»[1] монографиясендә Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ына бәйле эзләнүләрен дәвам итеп, аның Шәрык Яңарышы белән бәйләнеше һәм үзеннән соңгы төрки-татар әдәбиятына тәэсире турындагы фикерләрен яңа мисаллар белән тагы да баета. Шәрык Ренессансы традицияләренең яңа заман әдәбиятларында чагылышын галимә татар Мәүлә Колый, төрекмәнле Мәхтүмколый, казакъ Абай, татар Утыз Имәни, азәрбайҗанлы Вазыйх, татар Г. Исхакый, чуваш Сеспель иҗатларына бәйле тикшерә һәм, төрки әдәбиятлардагы Яңарыш Шәрык Ренессансының бер өлеше булып тора, дигән нәтиҗәгә килә.

Урта гасырлар татар әдәбиятының гүзәл үрнәге булган «Кыйссаи Йосыф» һәм аның авторы Кол Гали сигез гасырдан артык халкыбызның рухи таянычы булып тора, шуңа да тикшеренүчеләрнең игътибарын даими җәлеп итә. Әлеге әсәрне озак еллар дәвамында системалы өйрәнеп, җитди фәнни казанышларга ирешкән галимнәрнең берсе – Н. Хисамов. Каләмдәше Т. Галиуллин язганча, «икенче мәхәббәтенә, юлдашына, күңел юанычына, щатлыгы-кайгысына әверелгән Кол Гали әсәренең әхлакый-фәлсәфи тирәнлегенә, рухани дөньясына үтеп керү юлларын эзли, ишарә-кинаяләрдә татар халкына хас милли сыйфатларны күреп, шигъри энҗеләрне күтәреп ала»[2]. Н. Хисамовның 1970–1980 еллардагы эзләнүләре нәтиҗәсе буларак рус һәм татар телләрендә ике монографиясе дөнья күрә[3]. Автор моңа кадәр гомуми планда гына күрсәтелеп килгән мәсьәләне – поэманың сюжет чыганакларын җентекләп барлый, шуларга нисбәтле Кол Галинең иҗади яңалыгын, табыш-үзенчәлекләрен ача. Ә инде әсәрнең төрки әдәбияттагы төрдәшләре белән чагыштырылуы, аны аңлауны, поэма авторының сәнгати фикерләвен, мәңгелек кыйммәтләргә караш-мөнәсәбәтен тагы да тирәнрәк аңларга җирлек тудыра.

Н. Хисамовның соңгы еллардагы тикшеренүләре «Кол Гали һәм төрки «Йосыфнамә» китабында[4] чагылыш таба. Урта гасыр төрки шигърияте тарихчыларда, фәлсәфәчеләрдә, телчеләрдә зур кызыксыну уята. Шундый шартларда «бөтен урта гасыр шигъриятенең яки аның тарихындагы озын бер дәвернең тулы панорамасын һәм логик контекстын берерлек гомумиләштерүче хезмәтләргә ихтыяҗ»[5] булу аңлашыла.

---

[1] *Ганиева Р.К.* Традиции Восточного Ренессанса в тюркских литературах Средневековья и Нового времени. Казань: Фән, 2014. 272 с.

[2] *Галиуллин Т.Н.* Дәвамчанлык // Казан утлары. 2007. № 3. Б. 110.

[3] *Хисамов Н.Ш.* Поэма «Кысса-и Йусуф» Кул Али: Анализ источников сюжета и авторского творчества. М.: Наука, 1979. 254 с.; *Хисамов Н.Ш.* Бөек язмышлы әсәр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 336 б.

[4] *Хисамов Н.Ш.* Кол Гали һәм төрки «Йосыфнамә». Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 208 б.

[5] Шунда ук. Б. 4.

Галимнең чагыштырма-тарихи методка[1] нигезләнгән тикшеренүләре әлеге максатка да хезмәт итә.

Йосыф һәм Зөләйха турындагы сюжет күпсанлы әдипләрне һәрвакыт үзенә җәлеп иткән һәм нәтиҗәдә төрки телләрдә генә дә берничә әсәр язылган. Н. Хисамов сюжетны төрләндерүнең бер тибын гәүдәләндерүче, тулы мәгънәсендә тердәш, ягъни версия тәшкил итүче әлеге дастаннарны чагыштырып өйрәнеп, төрки шигърият үсешендәге үзенчәлекләрне ачыклауга килә. Аерым алганда, урта гасыр төрки әдәбиятларда традицияләр дәвамчанлыгы һәм яңачалыклар бигрәк тә Йосыф сюжетын эшкәртүдә калку чагыла, дип билгели автор.

Монографиядә төрдәшләр ясалуның өч ысулы аерып чыгарыла: 1) шигъри ысул, 2) шигъри-структур ысул, 3) шигъри ярыш ысулы. Аларның эчтәлек асылы ачыклану, әдипләрнең нинди максатта әлеге ысулларның берсенә мөрәҗәгать итүен билгеләү дә хезмәт авторының бай фәнни-теоретик чыганаклар белән эш итүен, уңышлы гомумиләштерүләр ясавын, анализ һәм синтез алымнарына иркен мөрәҗәгать итүен күрсәтә. Ә инде төрки шигърияттә йосыфнамә үсешенә бәйле төрдәш ясаучы алты компонентның аерып чыгарылуы җитди яңалык булып кабул ителә. Алар түбәндәгеләр: 1) укмаштыру; 2) детальләштерү; 3) мотивлаштыру; 4) катлауландыру; 5) психологик баету; 6) метафоралаштыру. Хезмәтнең аерым бүлекләрендә чыганакларга һәм текст фактурасына, төп геройларга һәм идея-фәлсәфи проблематикага, шигъри тасвирлауга нисбәтле әлеге төрдәш ясаучы компонентларның чагылыш үзенчәлеге, функциясе, гомумән, әһәмияте җентекле һәм күпсанлы мисаллар ярдәмендә ачыклана.

Гомумән, Кол Гали, Шәййад Хәмзә, Сули Фәкыйһ, Әхмәди, Дүрбәк, Хәмдуллаһ Хәмди һ.б. төрки шагыйрьләрнең әсәрләре җентекле тикшерелеп, төрдәшләрнең өч төре билгеләнә һәм Урта гасыр төрки шигъриятенең үзәк проблемасын хәл итүдә кулланылган төрдәш ясаучы иң мөһим элементлар аерып чыгарыла. Әлеге тикшеренүләренә нигезләнеп, Н. Хисамов «Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасының бөтен эзлекле төрки йосыфнамәдә фундаменталь әһәмияткә ия» булуы турында нәтиҗә ясый. Шулай итеп, Н. Хисамовның әлеге монографиясе, Р. Харис билгеләп үткәнчә, «чагыштырма анализның күпкырлы һәм тирән булуы, фәнни яктан ныклы нигезләнүе, фәнни аппаратның киң булуы, үзеннән элгәрерәк галимнәрнең тикшерү нәтиҗәләренә таянуы,

[1] XIX йөзнең соңгы чирегендә рус галиме А.Н. Веселовский нигез салган әлеге метод бөтендөнья әдәбиятын чагыштырма-тарихи планда өйрәнүгә йөз тота. А.Н. Веселовский «Тарихи поэтика» хезмәтендә төрле чорлар һәм халыкларның роман-повестьларын, эпик мотивларын чагыштырып тикшерә һәм шуның белән сүз сәнгатен генетик һәм типологик планда өйрәнүне башлап җибәрә. Ул һәр халыкның әдәби-мәдәни үсешендә үзенә генә хас үзенчәлекләр урын алуын, шуңа күрә теге яки бу халыкның үсешендә «артта калу» яисә «торгынлык» турында сөйләшүнең урынсыз булуын билгели.

аларның фикерләре белән чын гыйльми диалог алып бару культурасы»[1] белән җитди казаныш булып тора.

Борынгы һәм урта гасырлар әдәбиятының гаять җитди һәм перспективалы юнәлеше Х.Й. Миңнегулов хезмәтләрендә тикшерелә. Галимнең 1960–1980 еллардагы эзләнүләрендә С. Сараи, Котб, Й. Баласагунлы һ.б. әдипләрнең иҗат үзенчәлеге, әсәрләренең текстологиясе мәсьәләләре киң чагылыш тапса, соңрак татар әдәбият белемендә бик аз өйрәнелгән мәсьәләгә – кысалы кыйсса жанрындагы әсәрләрне тикшерүгә килә. «Шәрык һәм татар әдәбиятында кысалы кыйссалар» исеме белән дөнья күргән монографиясендә[2] «Кәлилә вә Димнә», «Тутыйнамә», «1001 төн» кебек әсәрләрнең язылу үзенчәлеге, Шәрык дөньясында таралышы, татар укучысына килү юллары һәм, иң мөһиме, Г. Фәезханов, Ф. Халиди, Ш. Рәхмәтуллин тәрҗемәләрендә дөнья күреп, халыкның рухи тормышындагы урыны, шулай ук идея-эстетик һәм поэтик сыйфатлары киң планда тикшерелә.

Гаять үзенчәлекле жанр булган кысалы кыйссаларны автор фольклор һәм язма әдәбият мөнәсәбәте, урта гасырларда тәрҗемәләрнең кулланылышы, башка язучы әсәреннән файдалану күренешенә нисбәтле анализлый. Бу исә фәнни-теоретик һәм әдәби чыганаклар базасын киңәйтергә, төрле әдәбият үрнәкләрен чагыштырып бәяләргә мөмкинлек бирә. Х. Миңнегулов фикеренчә, Шәрыктан үтеп кергән кысалы кыйссалар татар укучылары арасында бик популяр була. Моның сәбәпләре күптөрле: бердән, жанр ягыннан үзенчәлекле булу, ягъни новелла, әкият, мәсәл, повесть, роман-хикәят, хикмәт кебек берәмлекләрдән тору; икенчедән, әлеге кыйссаларда күпсанлы халыкларның рухи казанышы, дөньяга карашы, яшәү рәвеше, хыял-омтылышлары чагылыш табу һәм алар, гадәттә, татарлар өчен дә уртак булу; өченчедән, вакыйгакүренешләрдә, үзара мөнәсәбәтләрдә кешегә хас изгелек, матурлык, сафлык, гаделлек, акыл кебек сыйфатлар якланып, киресенчә, хәйләкәрлек, мәкер, икейөзлелек, наданлык, аңгыралык һәрдаим кире кагылу, тәнкыйтьләнү. Гомумән, кысалы кыйссалар үз заманы укучысының эстетик зәвыгына җавап биреп, әхлакый һәм фәлсәфи сорауларга җавап эзләргә булышкан, педагогик карашлар формалаштырган һәм шуның белән күпсанлы фольклор һәм язма әдәбият әсәрләре язылуга нигез булган.

Х. Миңнегуловны Урта гасыр татар әдәбияты һәм гарәп, фарсы, төрки классикасы белгече итеп таныткан хезмәт – «Татарская литература и Восточная классика (Вопросы взаимосвязей и поэтики)»[3]. Галим,

[1] *Харис Р.* Төрки Йосыфнамәнең чишмә башы // Мәдәни җомга. 2006. 3 ноябрь.

[2] *Миңнегулов Х.Й.* Шәрык һәм татар әдәбиятында кысалы кыйссалар. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1988. 198 б.

[3] *Миннегулов Х.Ю.* Татарская литература и Восточная классика (Вопросы взаимосвязей и поэтики). Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1993. 384 с.

моңа кадәр алып барган тикшеренүләрен дәвам итеп, татар әдәбиятының Шәрык классикасы белән булган күпгасырлык тыгыз бәйләнешен өйрәнә һәм күпсанлы мисал-дәлилләр аша татар сүз сәнгатенең мөселман мәдәниятенең бер тармагы булуын билгели. «Әлеге бай, мәңге бетмәс чыганактан башка Кол Гали, Котб, С. Сараи, Мөхәммәдъяр, Утыз Имәни, К. Насыйри иҗатларын, безнең Тукайга кадәрге чор әдәбиятын күз алдына да китереп булмый. Әгәр татар әдәбияты XX гасыр башына җитди уңышларга ирешкән икән, монда Көнчыгыш классикасы белән күпгасырлык багланышлар зур роль уйный», – дип яза ул. Әлеге үзенчәлек хезмәтнең компаративистика методына (термин Франциядә барлыкка килә һәм «чагыштырма әдәбият белеме» дип тәрҗемә ителә) нигезләнеп язылуын күрсәтә.

Х. Миңнегулов тикшеренүләре фәнни-теоретик нигезе, бай фактик материалы белән аерылып тора. Автор татар дөньясының Шәрык илләре белән төрле өлкәдәге бәйләнешен ачу өчен күпсанлы тарихи, географик, дини, әдәби чыганакларга мөрәҗәгать итә. Алар арасында төрле архивларда саклана торган, киң җәмәгатьчелеккә генә түгел, белгечләргә дә аз таныш булганнары күп. Татар әдәбиятының Шәрык классикасы белән тыгыз бәйләнешен ачу аша «татар халкы һәм аның ата-бабаларының кешелек тарихында искиткеч зур, җитди роль уйнаган цивилизацияләрдә тоткан урыны, әһәмияте мәсьәләсе»[1] эзлекле билгеләнә. Галимне, беренче чиратта, рухи-мәдәни мәсьәләләр кызыксындыра. Шуңа да Котбның «Хөсрәү вә Ширин», С. Сараиның «Гөлестан бит-төрки» әсәрләре Шәрык әдәбияты белән тыгыз бәйләнештә һәм төрки-татар сүз сәнгате үсешенең гомуми фонында тикшерелә. Бу исә әдәби бәйләнештә тәрҗемә мәсьәләләре урынын ачыклау белән бергә, Урта гасыр төрки-татар әдәбиятына хас төп тенденцияләрне барлау, бәяләү мөмкинлеге бирә.

Монографиядә поэтика мәсьәләләре һәрдаим игътибар үзәгендә тора. Шәрык классикасы тәэсирендә Яңарыш этабына баскан татар әдәбияты аерым сюжет-мотивлар, идеяләр, сәнгати сурәтләү чаралары белән бергә жанрлар системасын да үзләштерә. Аерым алганда, газәл, касыйдә, мәдхия, мәрсия, кыйтга, дастан, кыйсса, хикәят кебек жанрлар бу чорда киң таралыш алып, Октябрьгә кадәрге татар әдәбиятында даими үсеп-үзгәреп, бай традицияләргә нигез сала. Гомумән, Х. Миңнегулов хезмәте, әдәби ядкәрләрне чагыштырма-тарихи планда тикшерүнең уңышлы үрнәге буларак, Шәрык әдәбияты белән күпгасырлык бәйләнешнең тирән, күптөрле булуын билгели, татар сүз сәнгатенең зур тарихын бөтенлекле, эзлекле ачуга җитди өлеш кертә һәм яңа тикшеренүләргә юл ача.

---

[1] *Урманче Ф.И.* Ераклардан килгән чишмәләр // Мирас. 1995. № 1–2. Б. 280.

Галимнең борынгы һәм урта гасырлар татар әдәбиятын текстологик һәм әдәби-эстетик планда тикшеренүләре күпсанлы мәкаләләрдә һәм китапларда чагылыш таба. Аеруча «Дөньяда сүземез бар…», «Гасырлар өнен тыңлап» җыентыкларында[1] урын алган «Алтын Урда чоры язма мәдәнияте», «Мәхәббәт җырчысы (Котбның тууына 700 ел тулу уңае белән)», «Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» дастаны», шулай ук «Гаделлек һәм хаклык җырчысы», «Затлы инсан Колшәриф» кебек мәкаләләре фәнни тирәнлеге, чор әдәбиятын яисә аерым әдип иҗатын әдәби барыш, дөнья цивилизациясе үсешенә бәйле тикшерүе белән аерылып тора. Ә инде «Урта гасыр әдәбиятын өйрәнү: нәтиҗәләр һәм бурычлар» дигән язмасында әлеге чор әдәби мирасын өйрәнүгә бәйле ул түбәндәге мәсьәләләрне аерып чыгара: 1) әдәби ядкәрләрне текстологик өйрәнү; 2) яңа материалларны эзләү, табу, фәнни әйләнешкә кертү; 3) чор әдәбиятын фәнни өйрәнү; 4) халык тарихы һәм әдәбиятның табигый бәйләнешен диалектик күренеш буларак өйрәнү; 5) Урта гасыр әдәбиятын мәктәптә һәм югары уку йортларында укыту. Х. Миңнегулов әлеге мәсьәләләр буенча эзләнү-тикшеренүләр юнәлешен шактый җентекле ача. Шулар арасында билгеле бер фикер каршылыклары тудырган сорауларга туктала. Аерым алганда, Шәрык әдәбиятлары белән багланышка бәйле болай дип яза: «Биредә бер хакыйкатьне истә тоту шарт: татар сүз сәнгате, фәлсәфәсе, иң беренче чиратта, үз җирлегендә, үзенең эчке табигый кануннары нигезендә яшәгән, үскән. Читтән алу, үзгәләрнең казанышын үзләштерү, кагыйдә буларак, эчке таләп, эчке ихтыяҗлар нигезендә башкарылган. Башка халыклар белән татар рухи мирасындагы охшашлыкларның, уртаклыкларның шактые типологик яисә генетик-типологик характерда. Шуңа күрә андагы бу төр күренешләрне дөнья фәнендә модага әверелгән төрле ... измнар тәэсирендә туган дип карау – берьяклы караш»[2].

Галимнең алдагы елларда дөнья күргән «Гасырлар чигендә уйланулар»[3], «Записи разных лет»[4] китапларында да Урта гасырлар татар әдәбияты мәсьәләләренә киң урын бирелә. Аерым мәкаләләрдә, бу чор әдәбиятын өйрәнүнең торышы белән бергә, басылып чыккан хезмәтләргә этрафлы бәя бирелә. Ә инде «Этапы развития тюрко-татарской, античной и русской литератур» монографиясендә Борынгы һәм Урта гасырлар әдәбиятына махсус бүлекләр багышлана. Автор татар әдәбиятының бу дәверләрен эзлекле рәвештә, зур әдәбиятның мөһим өлеше

---

[1] *Миңнегулов Х.Й.* Дөньяда сүземез бар... Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 336 б.; *Миңнегулов Х.Й.* Гасырлар өнен тыңлап... Казан: Мәгариф, 2003. 335 б.

[2] *Миңнегулов Х.Й.* Дөньяда сүземез бар... Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. Б. 14.

[3] *Миңнегулов Х.Й.* Гасырлар арасында уйланулар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. 319 б.

[4] *Миннегулов Х.Ю.* Записи разных лет (Татарская литература: история, поэтика и взаимосвязи). Казань: Идел-Пресс, 2010. 407 с.

буларак өйрәнә. Аерым авторлар иҗатына махсус тукталып, аларның әдәби-эстетик табышларын дөнья сүз сәнгате фонында тикшереп бәяли. Башка төрки халыклар әдәбият фәнендә булган тикшеренүләргә таянып, чор әдәбияты турындагы караш-фикерләрне тагы да тирәнәйтә. Китапның тагын бер үзенчәлеге шунда, галим фәнни планда беренчеләрдән булып Кырым ханлыгы әдәбиятына бәя бирә, төп әдипләр иҗатына хас сыйфат-билгеләрне аерып чыгара.

Х.Ю. Миңнегуловның «Тюрко-татарская словесность в контексте межлитературных связей»[1] монографиясе төрки-татар әдәбиятын башка халыклар әдәбияты белән тыгыз бәйләнештә өйрәнү ягыннан әһәмияткә ия. Хезмәттә татар әдәбиятының Борынгы һәм Урта гасырларга караган дәверләре хәзерге фәнни казанышлар биеклегеннән торып тикшерелә. Автор моңа кадәр булган фәнни фикерләрне тагы да үстерә, башка төрки халыклар әдәбиятындагы тикшеренүләр белән баета, алар арасындагы тыгыз бәйләнешнең генетик тамырларын барлый. Хезмәт бай фактик материал һәм яңача күзәтү белән аерылып тора. Ул татар әдәбиятын чагыштырма-тарихи планда тикшерүгә уңышлы җирлек әзерли.

Төрки-татарларның мөселман Көнчыгышы белән бәйләнеше гаять киң һәм төрле булып, яңадан-яңа тикшеренүләргә этәргеч бирә. Алтын Урда дәүләте белән кыпчак-мәмлүкләр Мисыры арасындагы мәдәни бәйләнеш – шуларның берсе. Р. Исламовның «Алтын Урда һәм мәмлүкләр Мисыры: язма мирас, мәдәни багланышлар» монографиясе[2] әлеге катлаулы һәм гаять мөһим мәсьәләне өйрәнүгә багышланган. Галим, Алтын Урда һәм кыпчак-мәмлүкләр Мисыры дәүләтләренең бай язма мәдәнияткә ия булуын билгеләп, алар арасындагы багланышларны, аерым алганда XVI гасыр башында Мисырда Ә. Фирдәүсинең «Шаһнамә» поэмасы төрки телгә тәрҗемә ителү һәм аның төрки поэзиясе үсешендә тоткан урынын билгеләүне максат итеп куя. Автор ике бөек дәүләтнең тарихына, мәдәниятенә кагылышлы бай фәнни чыганаклар белән эш итә. «Шаһнамә»нең табылу, тәрҗемә ителү, авторлык, төп текстлар турындагы материал да гаять мөһим булып, тикшеренү объектының катлаулылыгы турында сөйли. Р. Исламов төрки «Шаһнамә»не Фирдәүси, Низами һ.б. әдипләрнең текстлары белән чагыштыру аша Коръән мотивларына, Искәндәр Зөлкарнәйн, Хөсрәү-Ширин сюжетларына текстологик анализ ясый һәм төрле халыкларның рухи тормышындагы уртаклыклар турында кызыклы нәтиҗәләргә килә. Төрки «Шаһнамә»нең жанр һәм композиция, метрика һәм рифма бирелеше күпсанлы мисалларда ачыкланып, әсәрнең Урта гасыр шигъриятендәге

[1] *Миннегулов Х.Ю.* Тюрко-татарская словесность в контексте межлитературных связей. Казань: Ихлас, 2017. 360 с.

[2] *Исламов Р.М.* Алтын Урда һәм мәмлүкләр Мисыры: язма мирас, мәдәни багланышлар. Казан: Матбугат йорты, 1998. 250 б.

урыны тагы да тулылана. Ә инде сәнгатьчә тасвирлауда халыкчан афоризмнарның кулланылышын тикшерү төрки поэзия аша безнең көннәргә үзгәрешсез килеп җиткән «җан кошы», «тутый җан», «кот очу», «саба җиле» һ.б. образлы сурәтләмәләрнең асыл мәгънәсен тирәнрәк аңларга ярдәм итә. Гомумән, Р. Исламов монографиясе, төрки-татар сүз сәнгатенең бәйләнеш даирәсен бермә-бер киңәйтеп, Урта гасыр язма мәдәниятебезне, аның рухи кыйммәтен объектив күзалларга һәм бәяләргә мөмкинлек бирә.

Ф. Яхинның «Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология» дип аталган хезмәте [1] татар әдәбият белеменең үзенчәлекле бер ягын – татар поэзиясендә дини карашларның чагылыш үзенчәлеген дини мифология һәм фольклор мифологиясенә нисбәтле өйрәнә. Авторның игътибар үзәгендә, беренче чиратта, гомумтөрки әдәбият үрнәкләре тора. Әлеге ядкәрләрдә төшләр символикасы чагылышын ачу-аңлату аша шигъриятнең ислам дине белән тыгыз бәйләнешен, димәк, әсәрләрдә урын алган күпсанлы мотив, символ, метафора һ.б. булып килгән элемент-детальләрнең әдәби функциясен билгеләү мөмкинлеге туа. XII–XIII йөзләрдә суфичылыкның, поэзиядә дини-мистик карашларның урынын җентекле барлау аша Ә. Ясәви, С. Бакыргани, «Кисекбаш» китабы, Мәҗлеси, Сайади, Мөхәммәдъяр бине Мәхмүд һ.б. иҗатларына эзлекле бәя бирелә. «XII гасырның мистик шагыйрьләре Ә. Ясәви һәм С. Бакыйгани иҗатлары дини мифологик һәм мистик күзаллауларга корылган. Аларның әсәрләре дини публицистик планда һәм үгетнәсихәтчелек юнәлешендә язылганнар. Мифологик материал ярдәмендә шигырьләренең эчтәлеген һәм мәгънәсен тирәнәйтүгә ирешкәннәр», – дип яза Ф. Яхин. Авторның әлеге үрнәкләрнең традицияләрен җентекле барлавы да кызыклы нәтиҗәләргә китерә.

Фәнни хезмәтләр арасында аерым бер чор белән генә чикләнмичә, төрле дәверләр өчен уртак яисә якын булган әдәби күренешләрне иңләп алганнары да бар. Борынгы һәм урта гасырлар сүз сәнгате бай булган кебек, аны өйрәнүнең юл-юнәлешләре һәм төрләре бер-берсеннән аерылып тора. Ә. Шәриповның бу дәвер әдәбиятына бәйле тикшеренүләре борынгы төрки һәм төрки-татар әдәбиятында шигъри жанрлар үсеше белән бәйле. Галимнең «Зарождение и становление системы стихотворных жанров в древнетюркской и тюрко-татарской литературе (VIII–XIV вв.)» китабы[2] татар әдәбиятының иң бай тармагы булган шигърияттә жанрлар системасы барлыкка килү һәм аның үсеш этапларын тулы эзлеклелектә, бай фактик материалга нигезләнеп ачыклавы

[1] *Яхин Ф.З.* Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология. Казан: ТДГИ нәшр., 2000. 268 б.

[2] *Шарипов А.М.* Зарождение и становление системы стихотворных жанров в древнетюркской и тюрко-татарской литературе (VIII–XIV вв.). Казань, 2001. 364 с.

белән әһәмиятле. Шигъри жанрлар мәсьәләсен хезмәт авторы гамәли һәм теоретик якларның тыгыз бәйләнешендә ача.

Төрки-татар шигъри жанрлар формалашуга гарәп һәм фарсы-таҗик классик поэзиясе, аның теоретик поэтикасы гаять зур йогынты ясый. Соңгысы исә, Ә. Шәрипов фикеренчә, урта гасырларда ук үрнәк поэтик канун төсен ала һәм ачык, төгәл теориягә нигезләнә. Идел Болгарстаны һәм Алтын Урда дәверендә, бер яктан, эчке ихтыяҗ, икенче яктан, Шәрык классикасы тәэсирендә төрки-татар шигъриятенең поэтикасы системалы төс ала. Поэтик жанрлар, билгеле булганча, беренче булып халык авыз иҗатында барлыкка килә. Шул нисбәттән автор эзлекле рәвештә татар халкының йола-календарь поэзиясен, эпос-дастаннарны, әкиятләрдәге шигъри өзекләрне, балладаларны, җырларны, бәетләрне, мөнәҗәтләрне, мәкаль һәм табышмакларны жанр үзенчәлеге ягыннан этрафлы тикшереп бәяли. Әнә шул нигездә борынгы төрки поэзия, аның күренекле вәкилләре Й. Баласагунлы, Ә. Ясәви, С. Бакыргани, Ә. Йүгнәки әсәрләренә жанр ягыннан тирән анализ ясала. Аеруча еш очрый торган газәл, кыйтга, хикмәт, мөнәҗәт, мөрәббәгъ һ.б. жанрларның сыйфат-билгеләре ачыклану белән бергә, әдипләрнең иҗат үзенчәлекләре дә билгеләнә.

Болгар чорының күренекле әсәре Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф», Алтын Урда чорына караган «Кисекбаш китабы», Котб, С. Сараи, Х. Кятиб, Хәразми, М. Болгари, Рабгузи әсәрләренең жанрларына хас охшашлык һәм аерымлыклар, язма әдәбият традицияләре чагылышы, фольклор йогынтысы ачыклану, поэтика мәсьәләләре белән бергә әлеге дәверләр сүз сәнгатенең тулы бер панорамасын тудыра. Тикшеренүләренә нигезләнеп, Ә. Шәрипов XIII–XIV гасырларда шигъри жанрлар системасының тулы структурасы барлыкка килү турында нәтиҗә ясый. Алдагы чорларда исә автор индивидуальлегенә бәйле үзгәрешләр белән жанрларның үсү традициясе дәвам иттерелә.

Борынгы һәм урта гасырлар тарихына, иҗтимагый фикер үсешенә караган хезмәтләр дә рухи ядкәрләребезне ачу-аңлатуга, киң катлау укучыларга кайтаруга хезмәт итә. Бу яктан Р. Әмирхановның «Татарская социально-философская мысль средневековья», А. Юзиевнең «Татарская философская мысль конца XVIII–XIX вв.», шулай ук авторлар коллективының «Очерки истории татарской общественной мысли» кебек китаплар[1] аеруча игътибарга лаек. Р. Әмирханов тикшеренү объекты итеп XIII–XVI гасыр урталарын ала һәм социаль-фәлсәфи фикер үсешен, бер яктан, бу дәвернең тарихи үзенчәлекләренә нисбәтле,

[1] Очерки истории татарской общественной мысли. Казань: Татар. кн. изд-во, 2000. 191 с.; *Амирханов Р.М.* Татарская социально-философская мысль средневековья (XIII – середина XVI вв). Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 1993. 124 с.; *Юзеев А.Н.* Татарская философская мысль конца XVIII – XIX в. Казань: Татар. кн. изд-во, 2001. 192 с.

икенче яктан, ислам дине таралышы, диннең халык тормышында тоткан урынын билгеләү, шулай ук Идел буенда суфичылык күренешен ачыклау белән бәйле, өченче яктан, халыкның рухи-мәдәни тормышы елъязмасы булган әдәби әсәрләрдә чагылыш тапкан әхлакый, фәлсәфи, социаль мәсьәләләрнең асылын ачу-аңлату аша өйрәнә. Хезмәттә Й. Баласагунлы һәм Ә. Ясәвинең этик-эстетик, Кол Гали кыйссасының фәлсәфи проблематикасы, Котб һәм С. Сараиның мәхәббәткә, ил белән идарә итүгә, байлык-фәкыйрьлеккә һ.б. карашларындагы гуманистик фикерләр – болар барысы да автор шәхесе, халык тормышы, шул чорда өстенлек иткән этик, дини карашлар белән тыгыз бәйләнештә һәм әсәрләргә идея-эстетик анализ аша бирелә.

Борынгы һәм урта гасырлар сүз сәнгате турында сүз алып барганда Г. Дәүләтшинның «Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы» дип аталган гаять җитди хезмәтен[1] читләтеп үтеп булмый. Монографиядә борынгы чорларда рухи культура формалашу, аның аерым өлкәләре (мифологик һәм космогоник карашлар, халык авыз иҗаты, календарь, дин, язмачылык һәм мәгърифәт, фәнни карашлар һ.б.) үсешен, үзенчәлекләрен тарихи планда тикшерү максат итеп куела. Авторның күпләгән чыганакларга таянып борынгы чорлар, шулай ук Болгар, Җүчи Олысы, Казан ханлыгы дәүләтләрендәге рухи мәдәниятның торышы турындагы эзләнүләре татар сүз сәнгатенең үсеш-үзгәрешен аңларга, нигез тамырларын билгеләргә ярдәм итә. Халык авыз иҗатының төрле жанрларын, аеруча легендаларны, риваятьләрне тикшерү барышында аларның килеп чыгышы, таралышы, халык тормышы, рухи яшәеше белән бәйләнеше һәм алдагы чорлар сүз сәнгатенә йогынтысы билгеләнә. Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителү, Җүчи Олысында дини вазгыять мәсьәләләре халыкның рухи мәдәгнияте, иҗтимагый фикере белән тыгыз бәйләнештә карала. Болар исә татар әдәбиятының торышын, тирән тамырларын, аерым тема-мотивлар, карашлар үсешен киң планда ачарга, бәяләргә мөмкинлек бирә. Авторның ислам гыйлеме, язмачылык, мәгариф, шул исәптән төрле фәннәр үсешенә бәйле фикерләре татар сүз сәнгате үсеше турындагы карашларыбызны бермә-бер киңәйтә.

Борынгы чорлардан алып XX йөз башына кадәрге дәвердә татар иҗтимагый фикере үсеше тарихын өйрәнүгә багышланган икенче хезмәттә татар милли мәдәниятенең нигез кыйммәтләре төрки-мөселман цивилизациясе белән бәйләнештә карала һәм шул нигездә иҗтимагый фикер үсешенең төрле тарихи этаплардагы үзенчәлекләре билгеләнә.

[1] *Дәүләтшин Г.М.* Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 512 б.

Борынгы һәм урта гасырлар әдәбияты мәсьәләләре төрле дәрәҗәдә урын алган башка хезмәтләр дә[1] бу дәвер сүз сәнгате турындагы белем-мәгълүматны баетуга зур өлеш кертә. Аларда татар әдәбиятының үсеш-үзгәреше ислам дине идеологиясе белән тыгыз бәйләнештә карала һәм аңа Шәрык мөселман дөньясы, аерым алганда, гарәп, фарсы һәм төрек телендәге әдәбият йогынтысы ачыклана. Авторларның игътибар үзәгендә халык яшәешенең чагылышы булган сүз сәнгатенең үз җирлегендәге яшәү шартлары һәм рухи байлыгы, тарихи вакыйгалар йогынтысында эчке закончалыкларына бәйле әдәби процесс буларак яшәве тора. Шуңа нисбәтән аерым монография-мәкаләләрдә гомуми тенденцияләр, аерым автор иҗатына хас закончалыклар, әдәбияттагы төп тема-мотивлар, сурәт чаралары байлыгы, жанрлар төрлелеге һ.б. тикшерүгә киң урын бирелә.

Күптөрле тикшеренүләрнең нәтиҗәсе буларак «Татар әдәбияты тарихы»ның I томы[2] һәм соңрак «Средневековая татарская литература (VIII–XVIII вв.) китабы[3] дөнья күрә. Күпсанлы тикшеренүчеләрнең тырышлыгы белән дөнья күргән монографияләр Борынгы һәм урта гасырлар татар әдәбиятының үсеш тенденцияләрен, аерым авторлар иҗатындагы табыш-яңачалыкларны чагылдырган, төрле чорлар сүз сәнгатен үзара тыгыз бәйләнештә, традицияләр дәвамчанлыгында бәяләгән җитди фәнни хезмәт булып тора. М. Бакиров билгеләп үткәнчә, беренче томның тарихилык принцибына нигезләнүе, комплекслы планда эшләнүе, ягъни халыкның тарихи, иҗтимагый-социаль тормышы һәм мәдәни үсеше белән тыгыз бәйләнүе андагы табыш-яңалыкларга җирлек булып тора[4].

XXI гасыр башында исә сигезтомлык «Татар әдәбияты тарихы»ның I томы[5] җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителә. Күпсанлы белгечләр тырышлыгы белән әзерләнгән бу хезмәт үз эченә гомумтөрки чорга караган ядкәрләрдән алып XV гасырга кадәрге төрки-татар әдәби мирасын ала. «Борынгы һәм Урта гасырлар әдәбияты тарихын яктыртуга багышланган бу беренче томның яңа гыйльми материаллар исәбенә баюы, барыннан да элек, өйрәнү объектының тарихи-хронологик чикләре киңәю белән бәйле»[6].

---

[1] *Нигматуллина Ю.Г.* Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. Казань: Фэн, 1997. 190 с.; *Сибгатуллина Ә.Т.* Суфичылык серләре. Казан: Матбугат йорты, 1998. 368 б.; *Сибгатуллина Ә.Т.* Илаһи гашыйклар юлыннан. Казан: Кыйбла, 1999. 144 б. һ.б.

[2] Татар әдәбияты тарихы: алты томда. 1 т. Борынгы һәм урта гасырлар дәвере. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 567 б.

[3] Средневековая татарская литература (VIII–XVIII вв). Казань: Фэн, 1999. 240 с.

[4] *Бакиров М.Х.* Әдәбиятыбыз тарихына яңа адым // Казан утлары. 1986. № 7. Б. 158–161.

[5] Татар әдәбияты тарихы: сигез томда / төз. Р.Ф. Рахмани. 1 т.: Борынгы чор һәм Урта гасырлар / фәнни мөх. М.Х. Бакиров. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. 415 б.

[6] Рахмани Р. Беренче том турында // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 1 т.: Борынгы чор һәм Урта гасырлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. Б. 14.

Сигезмотлык «Татар әдәбияты тарихы»ның 2 нче томы[1] урта гасырлардагы татар әдәбиятының XV–XVIII йөзләрен үз эченә ала. Татар халкы гаятҗ зур фаҗигаләргә юлыккан дәвердә әдәби мирасны саклау үзе батырлыкка тиң булган. Шуңа да ядкәрләр чагыштырмача аз булып, хезмәттә алар «Казан ханлыгы чоры», «XVII гасыр әдәбияты», «XVIII гасыр әдәбияты» дигән өч кисәккә бүлеп тикәерелә. Авторлар тарафыннан моңа кадәр читтә калып килгән яисә соңгы елларда табылган тарихи-документаль язмалар, яңа авторлар һәм әсәрләр әйләнешкә кертелә. Әдәбият тарихын халык тормышы, чорның иҗтимагый вакыйгалары белән тыгыз бәйләнештә ачуга да җитди игътибар бирелә.

Борынгы һәм Урта гасырлар әдәбиятын өйрәнүдә тагын бер юнәлеш булып әдәби мирасны бөтен тулылыгында укучыга кайтару тора, чөнки «Тарих буенча дәреслекләр дә, фәнни публикацияләр дә, никадәр кыйммәт булмасын, үз чоры әдәби һәйкәлләренең тере эчтәлеген алыштыра алмый»[2]. Шул максаттан чыгып, ике гасыр чигендә галимнәр тарафыннан гаять мөһим текстологик эш башкарыла һәм моңа кадәр киң катлау укучыга я өзекләре, я журнал варианты аша гына билгеле булган әсәрләрнең тулы тексты дөнья күрә. Алар түбәндәгеләр: «Идегәй» (1988) дастаны, «Мәҗмугыл-хикаят» (1994) китабы, Колшәрифнең «И күңел, бу дөньядыр» (1997) җыентыгы, Мөхәммәдъярның «Нуры содур» (1997) җыентыгы, Сайадиның «Бабахан дастаны» (1998), С. Сараиның «Гөлестан. Лирика. Дастан» (1999) җыентыгы, «Бакырган китабы» (2000), Суфи Аллаһиярның «Сөбател-гаҗизин»е (2000), М. Колый «Хикмәтләр»е (2001), Т. Ялчыголның «Рисаләи Газизә»се (2001), М. Әл-Болгариның «Нәһҗел-фәрадис»е (2002), Котбның «Хөсрәү вә Ширин»е (2003), Рабгузи Насретдин Борһанетдин улының «Кыйссасел-әнбия»се (2003), «XVIII гасыр әдәбияты: поэзия» (2006), Мәүла Колый поэмалары (2008)[3] һ.б.

---

[1] Татар әдәбияты тарихы: сигез томда / төз. Р.Ф. Рахмани. 2 т.: XV–XVIII гасырлар / фәнни мөх. Х.Й. Миңнегулов. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. 471 б.

[2] *Амирханов Р.М.* Татарская социально-философская мысль средневековья (XIII – середина XVI в). Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 1993. С. 7.

[3] Борынгы һәм урта гасырлар татар әдәбиятын өйрәнүдә таяныч булып торган әсәрләрнең текстологиясен эшләүдә һәм төзеп бастырып чыгаруда Ш. Абилов, Х. Миңнегулов, Ф. Яхин, Н. Исмәгыйлев, Ә. Шәрипов, Ф. Нуриева, Ә.Алиева, Р. Марданов һ.б. зур хезмәт куя: Идегәй: Татар халык дастаны / кереш сүз авторы – И. Надиров. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. 254 б.; *Колшәриф.* И күңел, бу дөньядыр: Газәлләр, кыйсса / төзүче, текст һәм искәрмәләрне әзерләүче, кереш сүз авторы – Ә. Шәрипов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. 94 б.; *Мөхәммәдъяр.* Нуры содур. Поэмалар, шигырь / текстны хәзерге телгә тәрҗемә итүче, кереш сүз авторы, искәрмәләрне һәм аңлатмаларны әзерләүче – Ш. Абилов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. 336 б.; *Сайади*. Бабахан дастаны / текстны әзерләүче һәм кереш сүз авторы – Ф. Яхин. Казан: Раннур, 1998. 192 б.; *Сараи Сәйф.* Гөлестан. Лирика. Дастан / басмага әзерләүче, кереш һәм ахыргы мәкалә авторы – Х. Миңнегулов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 296 б.; Бакырган китабы: XII–XVII йөз төрки татар шагыйрьләре әсәрләре /текстны әзерләүче,

Шулай итеп, Борынгы һәм урта гасырлар әдәбияты мифологиягә, фольклорга нигезләнеп, халык тормышы, аның яшәү рәвеше, уй-фикерләре, хыял-омтылышлары белән тыгыз бәйләнештә үсеп, Шәрык Яңарышының уңай йогынтысын тойган хәлдә, XIII–XVI гасыр уртасы аралыгында үзенчәлекле тарихи, социаль-мәдәни, фәлсәфи-эстетик карашларны үз эченә алган Яңарыш чоры кичерә. Сүз сәнгате, ислам дине идеологиясенә һәм мөселман неоплатонизмына нигезләнеп, үсеш-үзгәреш кичерә. XVII–XVIII йөзләр әдәбиятында декадентлык күренеше урын ала. Ислам дине белән тыгыз бәйләнештә булып, ул суфичылык әдәбиятының үсешенә этәргеч бирә. Шуның белән бергә, XVIII гасыр ахыры – XIX гасыр башында иҗат юнәлеше буларак реализмга хас билгеләр барлыкка килә, һәм шул рәвешле җитди сыйфат үзгәрешләренә нигез салына. Урта гасырлар татар әдәбиятының Шәрык халыклары әдәбияты белән тыгыз бәйләнеше күчмә сюжетларның, төрдәшләрнең, шулай ук типологик охшашлыкларның урын алуына юл ача. Сүз сәнгатендә гаять әһәмиятле урын алып торган бу күренеш яңа традицияләргә дә нигез сала. Хәзерге әдәбият белемендә шигъри жанрлар поэтикасы, аларның барлыкка килүе, үсеш эволюциясе, бай сурәт чаралары, поэтик образлар дөньясы зур кызыксыну уята, һәм алар җитди тикшеренү объектлары булып тора. Әлеге дәвер әдәби мирасының текстологиясен эшләү, аны китап укучыларга кайтару да күз уңында торган мәсьәлә булып кала. Соңгы елларда урта гасырларда яшәп иҗат иткән әдипләрнең күпсанлы әсәрләре дөнья күрүе дә зур казаныш булып кабул ителә. Шуның белән бергә, а) бу чор язма әсәрләренең жанр табигатен һәм аларның традицияләрен, ә) урта гасыр Ренессансына хас сыйфат-билгеләрнең шул чор һәм соңрак дәвер әдипләр иҗатында чагылыш үзенчәлеген, б) әдәби мирасның үз чоры өчен һәм дөнья мәдәнияте үсешендәге иҗтимагый, әхлакый-эстетик әһәмиятен һ.б. ачыклау киләчәктә дә дәвам ителергә тиешле бурыч булып кала.

---

искәрмәләр язучы – Ф. Яхин. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. 240 б.; *Мәхмүд әл-Болгари.* Нәһҗел-фәрадис / әсәрне басмага әзерләүче, кереш мәкалә авторы – Ф. Нуриева. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. 384 б.; *Суфи Аллаһияр.* Сөбател-гаҗизин (Гаҗизләргә терәк) / хәзерге татар теленә шигъри тәрҗемәне эшләүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы – Ф. Яхин. Казан: Иман, 2000. 156 б.; *Колый Мәүла.* Хикмәтләр / төзүче, иске татар теленнән күчерүче һәм сүз башы язучы М. Гайнетдин. Казан: Иман, 2001. 136 б.; Мәҗмугыл-хикаят / басмага әзерләүче Н. Исмәгыйлев. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. 447 б.; *Ялчыгол Таҗеддин.* Рисаләи Газизә / әсәрне басмага әзерләүче һәм кереш мәкалә авторы Х. Миңнегулов. Казан: Иман, 2001. 480 б.; *Котб.* Хөсрәү вә Ширин (шигъри роман) / фәнни редакторы, кереш мәкалә авторы һәм басманы матбугатка әзерләүче Х. Миңнегулов. Казан: Мәгариф, 2003. 367 б.; Мәүла Колый поэмалары / төз. Р.Ф. Мәрданов. Казан: Милли китап, 2008. 88 б.; *Һөвәйдә* (Мулла Хуҗа-Нәзәр бине Гаиб-Нәзәр Җәмйани). Рәхәте-дил – Җан рәхәте / текстологик әзерләү, сүз башы авторы – профессор Ф.З. Яхин. Казан: ТӘһСИ, 2018. 268 б. һ.б.

### *3.3.2. XIX йөз әдәбияты*

XIX йөз татар сүз сәнгатен өйрәнүгә М. Госманов, М. Гайнетдинов, Х. Миңнегулов, М. Әхмәтҗанов, Ә. Сибгатуллина, Ф. Бәширов, И. Гомәров хезмәтләрендә киң урын бирелә. М. Госманов, М. Акмулла һәм Г. Кандалыйның иң тулы җыентыкларын[1] төзеп, бай аңлатма-искәрмәләр белән һәм иҗат үзенчәлекләрен тирән эчтәлекле кереш мәкаләләрдә аңлатып, китап укучыларга җиткерә.

Галимнең борынгы язма мирасыбызны тикшерүгә багышланган хезмәтләре җитди казаныш булып тора. Ул, күпсанлы экспедицияләр оештырып, төрле төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребездә сакланып калган фольклор үрнәкләрен, әдәби ядкәрләрне җыеп, фәнни эшкәртеп укучыга тәкъдим итү буенча озак еллар дәвамында системалы эш алып бара. М. Госманов һәм аның шәкертләре тарафыннан җыелган, тупланган төрки-татар һәм Шәрык телләрендәге ядкәрләр бүгенге кульъязма мирасыбызның кыйммәтле өлешен тәшкил итә. Җәмәгатьчелектә галим-филолог, тәнкыйтьче, текстолог, публицист буларак танылу алган М. Госмановның археограф язмалары буларак тәкъдим ителгән «Каурый каләм эзеннән» (1984, 1994), «Ябылмаган китап яки чәчелгән орлыклар» (1996) китаплары каршылыклы, еш кына, фаҗигале татар тарихы, аерым шәхесләр язмышы елъязмасы буларак кабул ителә. Галимнең атаклы әдипләр, фикер ияләре Ш. Мәрҗани, Х. Фәезханов, Г. Кандалый, М. Акмулла, Р. Фәхретдин, Һ. Атласи һ.б. турындагы язмалары аеруча XIX йөз һәм XX йөз башы татар иҗтимагый фикере үсешен, әдәби барышын тулырак аңларга бай материал булып тора. Г. Кандалый һәм М.Акмулланың әсәрләре текстологиясен бай аңлатма-искәрмәләр белән эшләп, М. Госманов әлеге әдипләрнең шәхесен үз чоры каршылыклары белән ачып, иҗатларына тирән анализ аша Яңа заман әдәбиятының башлангычында торуларын һәм бу сыйфат үзгәрешенең төп үзенчәлекләрен билгеләве белән XIX йөз татар әдәбиятын өйрәнүдә яңа этапны башлап җибәрә.

«Фәнгә бөтен барлыгы-вөҗүде белән чумып, мәгълүмат-фактларны бөртекләп җыючы»[2] зыялы шәхесләрнең берсе булган М. Гайнетдинов та XIX йөз әдәбиятының үсеш тенденцияләрен, казаныш-табышларын ачуга зур хезмәт куя. Алтытомлык «Татар әдәбияты тарихы»ның икенче томында урын алган мәкаләләрнең яртысына якыны аның тарафыннан язылу гына да әлеге галимнең бу чор әдәбиятын өйрәнүгә керткән өлешен ачык чагылдыра. Сигезтомлык әдәбият тарихының 1 нче һәм 2 нче томнарында дистәдән артык фәнни мәкалә аның тарафыннан язылган. Алар фактик материалга байлыгы, теге яисә бу әдип иҗатын үз чоры

[1] *Акмулла.* Шигырьләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. 137 б.; *Кандалый Г.* Шигырьләр һәм поэмалар / төз., кереш сүз авторы М.Г. Госманов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. 558 б.

[2] *Кадыйров Р.* Гомер итмәк – тырышмактыр // Гайнетдин М.В. Гасырлар мирасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. Б. 3.

иҗтимагый вакыйгалары белән тыгыз бәйләнештә ачуы ягыннан әһәмиятле. М. Гайнетдиновның эзләнүләре «Татарская литература XIX века (Идейно-художественный генезис и исторические судьбы)» дип аталган фәнни доклад буларак басылып чыга[1]. Галимнең тикшеренүләре социологик метод принципларына таяну белән үзенчәлекле[2].

М. Гайнетдинов хезмәтендә XIX йөзне татар халкының иҗтимагый тормышында җитди үзгәрешләр башланган, милләтнең әдәби-эстетик башлангычын билгеләгән тарихи әһәмиятле әсәрләр дөнья күргән чор буларак бәяли. Әдәби хәрәкәтне халык тормышындагы социаль-иҗтимагый күренешләр белән тыгыз бәйләнештә өйрәнеп, аның төп этапларын, алар арасындагы традиция-яңачалык мөнәсәбәтен, үсеш тенденцияләрен мәгърифәтчелек реализмына күчешнең мөһим факторы буларак аңлата. М. Гайнетдинов фикеренчә, XIX йөзнең беренче яртысындагы әдәби хәрәкәт моңа кадәр бик аз өйрәнелгән иҗтимагый-мәдәни күренеш белән бәйле. Ул аны «абызагайлар хәрәкәте» дип атый. Галим Т. Ялчыгол, Г. Курсави, Утыз Имәни, Ә. Каргалый кебек шәхесләрнең эшчәнлеге әлеге күренеш белән тыгыз бәйлелектә тикшерелергә тиеш дип саный. М. Гайнетдинов XIX йөз әдәбияты үсешенең этапларын билгеләүдә яңа караш тәкъдим итә: 1) XIX йөзнең 20–30 нчы еллары; 2) 1845–1875 еллар; 3) XIX йөзнең соңгы чирегe. 1 нче этапның асылын билгеләүче, хәрәкәтләндерүче көч итеп әлеге «абызагайлар хәрәкәте»н атый, ә инде 2 нче этап абызагайларлар хәрәкәте белән мәгърифәтчелек реализмы арасында күпер ролен үти, шуңа күрә аны «вакытсызлык» («безвременье») исеме белән билгеләп... белдерә. Галим фикеренчә, 3 нче этап мәгърифәтчелек идеологиясен үзенә нигез итеп алган мәгърифәтчелек реализмының мәйданга чыгуы белән үзенчәлекле.

М. Гайнетдиновның соңгы елларда дөнья күргән «Хакыйкать юлыннан», «Гасырлар мирасы» исемле җыентыкларындагы[3] абызагайлар хәрәкәтенә, дастан жанрына, Г. Утыз Имәни, Ш. Зәки, Б. Вәисов, М. Акмулла, Р. Фәхретдин, Ф. Кәрими һ.б.ның тормышына һәм иҗатына багышланган мәкаләләре фактик материалга байлыгы, әдәби процессны яңару хәрәкәте белән бәйләп тикшерүе, тәнкыйди стиле, пафосы белән

[1] *Гайнетдинов М.В.* Татарская литература XIX века (Идейно-художественный генезис и исторические судьбы): дис. в виде научного докл. ... докт. филол. наук. Казань, 2000. 101 с.

[2] Социологик метод әдәбиятның социаль тормыш күренешләре белән бәйләнешенә, ягъни сүз сәнгатен иҗтимагый аңның бер формасы буларак кабул итүгә нигезләнә. Аның асылын тарихилык принцибы, шулай ук әдәбиятны халыкның иҗтимагый, мәдәни тормышы закончалыклары чагылышы рәвешендә һәм, киресенчә, иҗтимагый тормышка йогынты ясаучы күренеш итеп аңлау билгели. Бу яктан ул культура-тарих һәм чагыштырма-тарих методлары белән якыная. Әдәби әсәрне социологик метод нигезендә анализлау социаль-тарихи чор үзенчәлекләрен, аерым тенденцияләрен, икътисади һәм сәяси законнар йогынтысын, аларның персонаж характерында чагылышын алгы планга куя.

[3] *Гайнетдинов М.В.* Хакыйкать юлыннан. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 319 б.; *Гайнетдинов М.В.* Гасырлар мирасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 319 б.

игътибарга лаек һәм бу чор сүз сәнгатен өйрәнүгә җитди өлеш булып тора. М. Гайнетдинов тырышлыгы белән Ф. Кәрими хикәя-повестьлары, сәяхәтнамәләре (1996) һәм К. Насыйри әсәрләренең 1, 2, 4 нче томнары дөнья күрә (2003, 2004, 2005). (Мәгърифәтче әсәрләренең 3 нче томын төзүче, гарәп графикасындагы аерым текстларны гамәлдәге язуга күчерүче һәм кереш мәкалә авторы – Х. Мәхмүтов.)

XIX йөз әдәбиятының аерым мәсьәләләре Х. Миңнегуловның «Дөньяда сүземез бар...», «Гасырлар өнен тыңлап...» җыентыкларында[1], «Этапы развития тюрко-татарской, античной и русской литератур», «Тюрко-татарская словесность в контексте межлитературных связей» монографияләрендә[2] һәм күпсанлы мәкаләләрендә чагылыш таба. Галимнең әлеге хезмәтләрендә урын алган Т. Ялчыгол, Ш. Зәки, Акмулла, Р. Фәхретдин турындагы мәкаләләре бу чорлар әдәбияты тарихын, андагы сурәт-табышлар байлыгын, сәнгати фикерләүдәге үзенчәлекләрне тирәнрәк ачарга ярдәм итә.

М. Әхмәтҗановның «Татар кульязма китабы» исемле монографиясе әдәбиятыбыз тарихы өчен гаять кыйммәтле булган кульязма китапларны һәм документларны өйрәнүе белән әһәмиятле. Галимнең тарихи-генетик методка нигезләнгән тикшеренүләре XIX йөз әдәбиятын өйрәнүгә дә зур өлеш кертә. Хезмәттә «татар әдәбияты тарихында тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгән, иске кульязмалар битләрендә сакланган төрки ырым-догалар, фаллар системасы, китап хатимәләре, эпиграфик поэзия үрнәкләре, васыятьнамәләр, әдәби табышмаклар мисаллары, календарьлар, елъязмалар, хат язу калыплары, әдәбиятта кече жанрлар дигән бер система итеп»[3] карала. Аларның бер өлеше борынгы һәм урта гасырларга нисбәтле. Ә менә мал ияләренең үзләреннән соңгы дәгъвачыларына тигез итеп бүлеп биргән мөлкәт язуы-васыятьнамә XIX йөз татар җәмгыяте эчендәге үзара мөнәсәбәтләрне тулырак аңларга ярдәм итә. Шулай ук бу чорга караган китап хатимәләре (бетемнәре) дә, ә алар «күчерүчеләр тарафыннан иҗат ителеп күчерелә, яки төгәлләнгән әсәргә өстәлгән кечкенә шигырьләрдән торган» аерым хезмәтләрнең авторы, язылу урыны, вакыты, сәбәбе турында кызыклы мәгълүмат бирә.

Әдәбиятның тагын бер кече жанры булган елъязмалар халыкның тарихи хәтере һәм мавыктыргыч сүз сәнгате энҗеләре булып тора. Алар янәшәсендә халык тарихын, мәдәниятен өйрәнү өчен мөһим фәнни чыганак булып кульязма календарьлар тора. М. Әхмәтҗанов

[1] *Миңнегулов Х.Й.* Дөньяда сүземез бар... Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 336 б.; Миңнегулов Х.Й. Гасырлар өнен тыңлап... Казан: Мәгариф, 2003. 335 б.

[2] *Миннегулов Х.Ю.* Этапы развития тюрко-татарской, античной и русской литератур. Казань: Ихлас, 2014. 288 б.; *Миннегулов Х.Ю.* Тюрко-татарская словесность в контексте межлитературных связей. Казань: Ихлас, 2017. 360 с.

[3] *Әхмәтҗанов М.И.* Татар кульязма китабы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. Б. 255.

билгеләгәнчә, соңгыларында рус һәм татар халыклары әдәби-мәдәни багланышларының әдәбиятның башка жанрларында күренмәгән очраклары күзгә ташлана. Хезмәттә шулай ук «Таһир белән Зөһрә», «Түләк белән Сусылу», «Хурлуга белән Һәмра» һ.б. дастаннарның яңа версияләре кулъязмалары тикшерелә. Алар исә татар әдәбиятында мәгълүм булган сюжетларның тарихын өйрәнүгә яңа сәхифәләр өсти. М. Әхмәтҗанов тикшеренүләренең тагын бер яңалыгы шунда, алар XIX йөз әдәбиятын яңа исемнәр белән баета. Ул моңа кадәр иҗатлары мәгълүм булмаган, яисә тар катлау белгечләргә генә билгеле булган Кол Мөхәммәд (XIX йөз башы) һәм Әхмәтҗан Тубыли (гасырның икенче яртысы) турында башлап сүз әйтә. Әлеге шәхесләргә бәйле бирелгән мәгълүматлар, әсәрләреннән үрнәкләр бу чор әдәбияты турындагы әдәби-эстетик күзаллавыбызны киңәйтә һәм баета.

XIX йөз әдәбиятын фәнни планда өйрәнүче галимнәрнең берсе – Ә. Сибгатуллина. Аның «Суфичылык серләре» һәм «Илаһи гашыйклар юлыннан» хезмәтләре[1] ислам дине белән тыгыз бәйле «суфичылык» дип аталган фәлсәфи-эстетик күренешнең асылын, аның татар әдәбиятында (шактый өлешен XIX йөз әдипләре алып тора) чагылыш үзенчәлекләрен өйрәнүе белән әһәмиятле. Автор әлеге мәсьәләне теоретик планда һәм суфичылык белән бәйле символ, образ, атамаларны ачу, аңлату юнәлешендә тикшерә. Ә. Сибгатуллина хезмәтләре урта гасырлардан алып Октябрьгә кадәрге (билгеле бер планда аннан соңгы да) татар әдәбиятының әдәби-эстетик үзенчәлекләрен, поэтик байлыгын, тел-стилен тулырак күзалларга һәм аңларга ярдәм итә. Ул чорлар әдәбиятын ислам дине, Коръәни карашлар белән тыгыз бәйлелектә өйрәнү генә дөрес нәтиҗәләргә китерә дигән фикерне раслый.

Ә. Сибгатуллинаның «В поисках человека» монографиясе[2] XIX йөз татар поэзиясендә шәхес концепциясе чагылышын тикшерүгә багышланган. Шәрык әдәбияты йогынтысында булган татар шигърияте үзенең бай традицияләренә нигезләнеп үсә һәм мәгърифәтчелекнең шифалы әдәби-эстетик карашларын үзенә сеңдерә. XIX йөз поэзиясе яңа сыйфат үзгәрешләренә күчеп, милли эчтәлекле шигърият булып формалаша. Әлеге күчеш чорына бәйле шәхес концепциясен автор әдәби һәм тарихи-мәдәни, фәлсәфи күренеш буларак тикшерә. Хезмәттә чор каршылыкларының, татар җәмгыятендә патриархаль-феодаль мөнәсәбәтләр җимерелеп, яңа социаль мөнәсәбәтләр урнашу күренешенең әдипләр иҗатында, аерым алганда, шәхес концепциясендә эз калдыруы ачыклана. Урта гасырлардан килүче «камил инсан» концепциясенең яңа

---

[1] *Сибгатуллина Ә.Т.* Суфичылык серләре. Казан: Матбугат йорты, 1998. 368 б.; *Сибгатуллина Ә.Т.* Илаһи гашыйклар юлыннан. Казан: Кыйбла, 1999. 144 б.

[2] *Сибгатуллина А.Т.* В поисках человека (концепция личности в поэзии XIX века). Елабуга: Изд-во ЕГПИ, 2001. 142 с.

заманда халык язмышы, милләтне камилләштерү идеясенә таба үсүе күпсанлы мисалларда дәлилләнә.

«XX йөз башы татар прозасы» хезмәтендә Ф. Бәширов татар әдәбиятындагы яңарыш дәверен XIX йөзнең соңгы чирегеннән башлап билгели[1]. Ул чорда мәйдан күргән проза әсәрләрен тикшерү аша «XIX гасырның соңгы чирегендә яңа әдәбият булып формалашкан татар иҗат дөньясында сүз сәнгате принциплары тагын да камилләшә, жанрлар колачы киңәя һәм яңа эчтәлек белән байый, әдәби хәрәкәттә мөһим сыйфат үзгәрешләре барлыкка килә. Шуңа мөнәсәбәттә тормышка йөз белән борыла баручы, реаль образларны, реаль вакыйгаларны сурәтләү объекты итеп алып, ситуацияләр һәм детальләр дөреслегенә омтылучы яңа төр татар прозасына да нигез салына»[2] дигән нәтиҗәгә килә. Дөрес, әлеге фикер моңа кадәр Г. Халит, И. Нуруллин, Р. Ганиева, Ф. Мусин хезмәтләрендә якланган иде. Ф. Бәширов исә аны XX йөз башы прозасы үсеш-үзгәрешенә нигез итеп ала.

Күпгасырлык татар әдәбияты ислам дине, Коръәни карашлар белән аерылгысыз бәйләнгән. Изге китапның аятьләрендәге фикер-карашлар сүз сәнгатен даими сугарып килә. Шуңа да рухани әдәбият, киң үсеш алып, төрле чорлар әдәби барышында мөһим урын алып тора. Җ. Зәйнуллинның бу юнәлештәге эзләнүләре «XVIII йөз – XX йөз башында татар рухани әдәбияты (Коръән тәфсирләре, хәдисләр һ.б. чыганаклар. Тәрҗемә принциплары һәм тел үзенчәлекләре)» китабында[3] чагылыш таба. Рухани әдәбият – гаять зур әзерлек таләп иткән өлкә. Бу темага Коръәнне, аның тәфсирләрен, хәдисләрен җентекләп өйрәнеп һәм гарәп телен, аның татарчага тәрҗемә ителү үзенчәлекләрен белеп кенә мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Җ. Зәйнуллин монографиясе фәнни-теоретик чыганаклары, фактик материал базасы белән дә аерылып тора. Гомумән, ислам диненең яңа күтәрелеше күзәтелгән, әдәби барышта рухани әдәбият киңрәк урын ала барган шартларда XVIII йөз – XX йөз башына караган мирасны барлау, тикшерү киләчәктә дә дәвам ителергә тиешле җитди эш булып тора.

З. Мөхәммәтшин, И. Гомәров, А. Хасавнех, Г. Зәйниева, Л. Сәмигуллина, Р. Сафиуллина, Р. Маханова, М. Сибгатуллина, Р. Ханнанов һ.б.ның соңгы еллардагы махсус тикшеренүләре[4] бу чор әдәбияты-

---

[1] *Бәширов Ф.К.* XX йөз башы татар прозасы. Казан: Фикер, 2002. 287 б.

[2] Шунда ук. Б. 266.

[3] *Зайнуллин Г.Г.* Во имя Аллаха...: Татарская богословская литература XVIII – начала XX веков и ее языковые особенности. Казань: Мәгариф, 1999. 238 с.

[4] *Мөхәммәтшин З.Г.* Фатих Халидинең иҗат мирасы. Казан: Таң-Заря, 2001. 159 б.; *Гомәров И.Г.* Мәгърифәт җырчысы: Гали Чокрый иҗатының тормыш һәм иҗат сәхифәләре. Казан: Школа, 2006. 144 б.; *Хасавнех А.А.* Этико-эстетические воззрения поэта-суфия XIX века Ахметзяна Тубыли: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2002. 28 с.; *Самигуллина Л.М.* Концепция героя в период зарождения и становления татарской драматургии (1887–1910): автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2004. 22 с.;

ның аерым катламнарын ачуга өлеш кертә. З. Мөхәммәтшин «Фатих Халидинең иҗат мирасы» хезмәтендә XIX йөзнең танылган әдибе тормышына һәм иҗат мирасына җентекле күзәтү ясый. Аның Шәрык әдәбияты белән багланышларына киң урын биреп, тәрҗемәчелек эшчәнлеген югары бәяли. Басма һәм кульязма әсәрләрен шул чорның иҗтимагый фикере, әдәби барышы белән тыгыз бәйләнештә анализлый һәм аларның халык тормышын, уй-хыялларын чагылдыруга бәйле әһәмиятен, рухи тормыштагы урыннарын билгели.

И. Гомәров монографиясендә[1] Гали Чокрыйның тормыш юлы, иҗаты тикшерелә. Үз чорында киң танылу алган әдипнең киң катлау укучыга аз билгеле булган әсәрләре өйрәнелеп, текстологиясе эшләнә. Шагыйрьнең байтак әсәрләре тулы рәвештә тикшереп бәяләнә. Тикшеренүче әдипнең үзенә кадәрге әдәбияттагы аерым традицияләрне дәвам итүен һәм яңалыклар алып килүен ача һәм хәзерге заман биеклегеннән бәя бирә.

XIX йөз һәм XX йөз башы әдәбияты буенча алып барылган тикшеренүләр киң планда алтытомлык «Татар әдәбияты тарихы»ның II томында[2], «История татарской литературы нового времени (XIX – начало XX вв.)» дигән монографиядә[3] чагылыш таба. II томның әһәмиятен Х. Миңнегулов түбәндәгеләрдә күрә: 1) бай фактик материал туплану һәм аларның байтагы төрле архивлардан алынып, киң җәмәгатьчелеккә беренче тапкыр тәкъдим ителү; 2) бу чор әдәбиятының халыкның рухи тормышындагы урыны яңача һәм киң планда ачылу, фәнни казанышларга нигезләнеп бәяләнү; 3) әдәби процесс һәм аерым авторлар иҗаты тулы, эзлекле тикшерелү, үзара бәйләнешләргә, типологик охшашлыкларга җитди игътибар бирелү һ.б.[4] Авторлар коллективы тарафыннан башкарылган икенче хезмәт хезмәт М. Гайнетдинов (XIX йөз) һәм Г. Халитнең (XX йөз башы) концептуаль карашларына нигезләнә. Икенче китап соңарып дөнья күрә, шуңа да 1990 еллар дәвамында алып барылган тикшеренүләрнең бер өлеше анда чагылыш тапмый. Шулай да хезмәт фәнни нигезе, фактик чыганакларга байлыгы белән аерылып тора. Яңа заман

---

*Сафиуллина Р.Ф.* Традиции фольклора в творчестве Габдельджаббара Кандалый: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2007. 21 с.; *Маханова А.А.* Творчество Суфи Аллаяра и его традиции в татарской литературе: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2008. 27 с.; *Сибгатуллина М.Р.* Идейно-эстетическая направленность творчества Ф. Карими: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2008. 23 с.; *Ханнанов Р.Г.* Татарская сценическая литература в контексте тюркской драматургии (конца XIX – начала XX века): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2009. 22 с. һ.б.

[1] *Гомәров И.Г.* Мәгърифәт җырчысы: Гали Чокрый иҗатының тормыш һәм иҗат сәхифәләре. Казан: Школа, 2006. 144 б.

[2] Татар әдәбияты тарихы: алты томда. 2 т. XIX йөз әдәбияты. Казан, 1985. 563 б.

[3] История татарской литературы нового времени (XIX – начало XX в.). Казань: Фикер, 2003. 472 с.

[4] *Миңнегулов Х.Й.* Әдәбият тарихын өйрәнү юлында // Казан утлары. 1987. № 6. Б. 130–134.

татар әдәбиятының сыйфат үзгәрешләрен, Шәрык һәм Гареб дөньясының фәлсәфи-эстетик фикеренә мөнәсәбәтен, аерым авторлар иҗатында күзәтелгән яңачалыкларны, шулай ук тема, жанр, стиль өлкәсендәге эзләнүләрне эзлекле ачуы белән татар әдәбият белемендә алга таба бер адым булып тора. Хезмәтнең төп яңалыгы әлеге чор сүз сәнгатен, бер яктан, тарихка, иҗтимагый фикер үсешенә тыгыз таянган хәлдә, эчке закончалыкларга бәйле үсеш кичерүче, икенче яктан, ислам дине тәгълиматы белән сугарылган милли әдәбият буларак өйрәнү белән аңлатыла.

Сигезтомлык «Татар әдәбияты тарихы»ның 3 нче томы[1] тулысы белән XIX гасыр татар әдәбиятының үсеш-үзгәреш үзенчәлекләренә багышлана. Әлеге хезмәт соңгы елларда табылган яңа фактик материаллар белән баетылган. Анда яңа авторлар (И. Гаспралы, Г. Ибраһимов, Ә. Тубыли) иҗатына этрафлы бәя бирелә. Моңа кадәр билгеле булган шәхесләр мирасы яңа заман биеклегеннән торып тикшерелә, яңа сыйфат-билгеләре күрсәтелә, әдәбият тарихындагы урыннары ачык һәм төгәл билгеләнә. Бу исә татар әдәбияты тарихын билгеле бер системада күз алдына бастыру мөмкинлеге бирә.

Шулай итеп, гаять кызыклы һәм каршылыклы XIX йөз әдәбиятын өйрәнүдә яңа уңышларга ирешелә: 1) җитди үзгәрешләр юлына чыккан Яңа заман татар әдәбиятының тарихи, иҗтимагый, мәдәни тамырлары ачыклана; 2) бу чор иҗтимагый фикер үсешенең нигезе булган мәгърифәтчелек идеологиясенең бөтен сүз сәнгатен сугаруы, яңа темаларга, форма-алымнарга, иң мөһиме, яңа тип геройларның мәйданга чыгуына җирлек әзерләве фикере мөһим тенденция буларак баетыла, тирәнәйтелә; 3) әдәбиятның Шәрык һәм Гареб әдәби-эстетик, фәлсәфи фикерләрен үзләштерү юлына чыгуы, шуңа бәйле үзенчәлекле синтез күзәтелү һәм XX гасыр башында аның тагы да үстерелүе, тирәнәйтелүе турында җитди нәтиҗәләр ясала; 4) бу дәвернең бай мирасы кайтарылып, әдәбият тарихының яңа исемнәргә баюы күзәтелә һ.б.

XIX йөз сүз сәнгатен өйрәнүгә бәйле җитди мәсьәләләр (кульязма текстларны укучыга кайтару; бу чор әсәрләренең тулы антологиясен төзеп, бастырып чыгару; әдәбиятта дини һәм дөньяви башлангыч, шуларга бәйле гуманистик идеяләрнең чыгылыш үзенчәлеге; мәгърифәтчелек реализмы һәм романтизмының урта гасыр романтизмы һәм XX йөз башындагы Европа тибындагы романтизм белән диалектик бәйләнеше һ.б.) яңа тикшеренүләрне көтә.

### *3.3.3. XX йөз башы сүз сәнгате*

Татар әдәбиятының «алтын чор»ы – XX йөз башы әдәбият белеменең даими игътибар үзәгендә тора. Алдарак чорда алып барылган

[1] Татар әдәбияты тарихы: сигез томда / төз. Р.Ф. Рахмани. 3 т.: XIX йөз / фәнни мөх. Ф.Г. Галимуллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. 551 б.

тикшеренүләрнең нәтиҗәсе буларак, алтытомлык «Татар әдәбияты тарихы»ның III томы 1986 елда дөнья күрә [1]. Татар сүз сәнгатенең классик дәверен үз эченә алган китапны эшләүгә күренекле галимнәр тартыла һәм ул Г. Халит яклаган концепциягә нигезләнә. Хезмәттә 1905–1917 еллар аралыгының тулы, эзлекле әдәби-мәдәни картинасы тудырыла. Моңа кадәр читтә калып килгән күпсанлы әдәби күренешләр әйләнешкә кертелә. Классик әдипләребез иҗатын объектив һәм бөтен тулылыгында, каршылыгында тикшерү буенча җитди нәтиҗәләргә ирешелә. Хезмәттә әлеге дәвернең үткән чорлар белән тыгыз бәйләнешен ачуга, традицияләр дәвамчанлыгы һәм яңачалыклар чагылышын билгеләүгә киң урын бирелә. Әдәбият фәненең соңгы казанышларына таяну, моңа кадәр читләтеп үтелгән модернизм агымнарына караш-мөнәсәбәтне белдерүгә мөмкинлек бирә һәм шуның белән яңа эзләнүләргә юл ачыла.

Ике гасыр чигендә бу дәвер әдәбиятын өйрәнүдә күпсанлы монографияләр[2] һәм җыентыклар басылып чыгып, җитди казанышларга

[1] Татар әдәбияты тарихы: алты томда. 3 т. XX гасыр башы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 598 б.

[2] *Мәхмүтов Һ., Илялова И., Гыйззәт Б.* Октябрьгә кадәрге татар театры. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. 397 б.; *Бәширов Ф.К.* XX йөз башы татар прозасы. Казан: Фикер, 2002. 287 б.; *Ганиева Р.К.* Татарская литература: традиции, взаимосвязи. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. 272 с.; *Ганиева Р.К.* Нәҗип Думавиның иҗат сәхифәләре. Казан: Отечество, 2003. 108 б.; *Зарипов-Четин Ч.* Проблема демонизма в творчестве С. Рамиева в контексте восточно-европейской эстетики. Казань: Мастер Лайн, 2003. 175 с.; *Заһидуллина Д.Ф.* Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 255 б.; *Заһидуллина Д.Ф.* Дөнья сурәте үзгәрү: XX йөз башы татар әдәбиятында фәлсәфи әсәрләр. Казан: Мәгариф, 2006. 191 б.; *Мәһдиев М.С.* Әдәбият һәм чынбарлык: XX йөз башы татар әдәбияты тарихына яңа материаллар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 304 б.; *Мәһдиев М.С.* Реализмга таба. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1989. 156 б.; *Магдеев М.С.* Социальные корни таланта. Казан: Изд-во Казан. ун-та, 1990. 158 с.; *Махмутов А.Г.* Торжество прекрасного: Формирование и развитие литературно-эстетической мысли татарского народа в конце XIX – начале XX века. Казан: Школа, 2000. 178 с.; *Миңнегулов Х.Й.* Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 367 б.; *Мусин Ф.М.* Гаяз Исхакый. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 191 б.; *Нигматуллина Ю.Г.* Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. Казань: Фэн, 1997. 189 с.; *Рәмиев З.З.* XX йөз башы татар әдәбияты: авторлык, төп текст һәм хронология мәсьәләләре. Казан: Школа, 2000. 180 б.; *Саяпова А.М.* Поэзия Дардменда и символизм. Казань: Изд-во КГПУ, 1997. 210 с.; *Сәхапов Ә.Җ.* Исхакый иҗаты. Казан: Мирас, 1997. 368 б.; *Сәхапов Ә.Җ.* Исхакый һәм XX гасыр татар әдәбияты. Казан: Мирас, 1997. 528 б.; *Сәхапов Ә.Җ.* Яңарыш хәбәрчесе. Казан: Мәгариф, 2003. 367 б.; *Сахапов А.Ж.* Вестник Возрождения. Казань: Центр инновационных технологий, 2001. 528 с.; *Сахапов А.Ж.* Исхаки и татарская литература XX века. Казань: Дом печати, 2003. 608 с.; *Сахапов А.Ж.* Золотая эпоха татарского ренессанса. Казань: Татар. кн. изд-во, 2004. 319 с.; *Харрасова Р.Ф.* Әдәби бәйләнешләр яктылыгында. Казан: Гарт, 2002. 261 б.; *Шәмсутова А.А.* Г. Исхакый иҗатында феминизм проблемаларының идея-эстетик эволюциясе (1897–1954). Казан: Гуманитария, 2003. 192 б.; *Яруллина Р.* Гаяз Исхакый иҗаты (1897–1906). Казан: ТГГИ нәшр., 2000. 164 б.

ирешелә[1]. XX йөз башы татар әдәбиятын өйрәнүнең аеруча мөһим аспектларының берсе озак вакыттан соң туган халкына кайтарылган милләтпәрвәр Г. Исхакый иҗаты белән бәйле. Атаклы әдипнең иҗатын киң катлам укучыларга җиткерү һәм өйрәнү эшенә 1980 еллар ахырында И. Нуруллин алына. Алдагы елларда әсәрләренең текстологиясен эшләү, иҗатын чорларга бүлү, аерым әсәрләренең әдәби-эстетик сыйфатларын, татар әдәбиятына тәэсирен ачу, сәнгати фикерләү үзенчәлекләрен, киң планда иҗат концепциясен билгеләү буенча җитди эшчәнлек алып барыла. Бу өлкәдә Л. Гайнанова, Һ. Мәхмүтов, Ә. Кәримуллин, Р. Ганиева, Ә. Сәхапов, Ф. Мусин, Х. Миңнегулов, Ф. Ибраһимова һ.б. зур хезмәт куя.

Ә. Сәхапов монографияләре Г. Исхакыйның бай әдәби мирасын барлау, үз чоры әдәби процессындагы урынын билгеләү һәм XX гасыр татар әдәбиятына йогынтысын ачу ягыннан әһәмиятле[2]. Аның күпсанлы хезмәтләренең бер үзенчәлеге булып Г. Исхакый иҗатын иҗтимагый фикер, тарих, фәлсәфә, милли сәясәт һ.б. үсеш-үзгәреше белән тыгыз бәйләнештә тикшерү тора. Әдипнең XX гасыр башы татар сүз сәнгатенең иң югары казанышларыннан берсе булган әсәрләре шул гасыр татар әдәбияты белән үзара тыгыз бәйләнештә бәяләнеп, аларның бөтен әдәби барышка тәэсире билгеләнә. Ул үзенең тикшеренүләрен комплекслы методка нигезләнеп алып бара. Шуның белән бергә язучының биографиясенә бәйле фактларга һәм шәхесенә хас сыйфатларга зур

---

[1] Тукай һәм XX гасыр мәдәнияте: шагыйрьнең 110 еллыгына багышланган халыкара конф. материаллары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. 322 б.; Творчество Тукая в контексте евразийской культуры: материалы конф. Казань: Фикер, 2002. 176 с.; Гаяз Исхакый һәм татар дөньясы: әдипнең 120 еллыгына багышланган халыкара фәнни-гамәли конф. материаллары. Казан: Фикер, 2000. 296 б.; Гаяз Исхакый иҗаты: хәзерге караш: Г. Исхакыйның тууына 130 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конф. материаллары. Казан, 2008. 376 б.; *Ганиева Р.К.* Шагыйрьнең рухи дөньясы. Казан: ТаРИХ, 2002. 112 б.; *Галиуллин Т.Н.* Шигърият баскычлары. Казан: Мәгариф, 2002. 231 б.; *Хисамов Н.Ш.* Тукайны төшенү юлында. Казан: ТаРИХ, 2003. 80 б.; *Миңнегулов Х.Й.* Гасырлар өнен тыңлап... Казан: Мәгариф, 2003. 335 б.; Галиәсгар Камал: әдип һәм заман. Казан, 2005. 156 б.; *Гыйләҗев Т.Ш.* Әдәби мирас: тарих һәм заман. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 206 б.; Галимҗан Ибраһимов һәм XXI гасыр: тууына 120 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конф. материаллары. Казан: 2007. 332 б.; *Шәйхелисламов З.Р.* Аңлыем дип шагыйрь җанын... (Әхмәт Фәйзи иҗатында Тукай). Казан: Фикер, 2001. 144 б. һ.б.

[2] *Сәхапов Ә.Җ.* Исхакый иҗаты. Монография. Казан: Мирас, 1997. 368 б.; *Сәхапов Ә.Җ.* Исхакый һәм XX гасыр татар әдәбияты. Казан: Мирас, 1997. 528 б.; *Сахапов М.Ж.* Вестник Возрождения. Казань: Центр инновационных технологий, 2001. 528 с.; *Сахапов М.Ж.* Исхаки и татарская литература XX века. Казань: Дом печати, 2003. 608 с.; *Сәхапов М.Җ.* Яңарыш хәбәрчесе: Г. Исхакый иҗаты турында. Казан: Мәгариф, 2003. 367 б.; *Сахапов М.Ж.* Золотая эпоха татрского ренессанса. Казань: Татар. кн. изд-во, 2004. 320 с.; *Сәхапов М.Җ.* Бердәм агым. Казан: Рухият, 2005. 320 б.

урын бирә[1]. Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт премиясенә лаек булган «Яңарыш хәбәрчесе» монографиясендә[2] Г. Исхакый иҗаты, миллилек һәм тарихилык принципларына нигезләнеп, XX гасыр татар әдәбияты контекстында тикшерелә. Хезмәттә әдипнең шәхес буларак формалашуы, ул яшәгән дәвернең иҗтимагый-сәяси, милли үзенчәлекләре дә игътибар үзәгендә тора. М. Хәсәнов язганча, «Г. Исхакыйның сәяси эшчәнлеге, иҗатының идея-эстетик эволюциясе татар җәмгыятенең сәяси үсеше белән тыгыз бәйләнештә карала»[3]. Г. Исхакыйның, шул чор зыялылары кебек үк, социаль-икътисади, мәдәни-идеологик мөнәсәбәтләр өлкәсендә тирән үзгәрешләрнең зарурилыгын, яңа идеологиянең мөһимлеген аңлауга һәм социаль тәртипләргә протест рәвешендә яңа кыйбла, яңа милли тәгълимат эзләү юлына чыгуы эзлекле күрсәтелә. Автор фикеренчә, әдип башлангыч чор иҗатына караган әсәрләрендә («Өч хатын белән тормыш», «Очрашу яки Гөлгыйзар», «Ике гашыйк», «Ике йөз елдан соң инкыйраз» һ.б.) мәгърифәтчелек идеалларын яклап чыга, татар әхлагына үтеп керә башлаган инкыйраз күренешләре – азгынлыкны, гамьсезлекне, битарафлыкны, фахишәлекне фаш итә һәм үсеп килүче буынны яманлыклардан сакланырга чакыра. Ә инде «Ике йөз елдан соң инкыйраз»ы ул чордагы татар әдәбиятының магистраль юлын билгеләгән бер маяк буларак бәяләнә. Әсәр татар әдәбияты өчен идея-теоретик база хезмәтен үтәп кенә калмыйча, бөтен бер иҗат юнәлешенә (аның асылында милли әдәбиятның төп вазифасы үз халкына хезмәт итүдә дигән фикер ята) нигез сала. Г. Исхакыйның беренче рус инкыйлабыннан соң язылган күпсанлы проза һәм драма әсәрләренә милли яңарыш проблемалары чагылышыннан чыгып җентекле анализ ясала. Татар яшәешенә бәйле «Тормышмы бу?» дигән сорауга җавап эзләү аша язучы халыкның киләчәген тәэмин итәрлек милли идеология өчен көрәш юлына чыга. Әсәрләрдә күтәрелгән җитди проблемаларны галим этик, этник, мәдәни, дини, рухи,

[1] Биографик метод язучының биографиясен һәм шәхесен иҗатчының иң мөһим, хәлиткеч шарты буларак тикшерә. Аңа XIX йөзнең беренче чирегендә француз тәнкыйтьчесе, шагыйре һәм язучысы Ш.О. Сент-Бев тарафыннан нигез салына. Әлеге метод тарафдарлары әдәби әсәрне язучының үз-үзен чагылдыру, уй-фикерләрен, дөньяга карашын, яшәү рәвешен, теләк-омтылышын белдерү чарасы итеп карыйлар. Икенче төрле әйткәндә, язучы «мин»е белән иҗатчы «мин»е арасында аерма юк дип саныйлар. Ш.О. Сент-Бев болай дип яза: «Литература, литературное творение неотделимы для меня от всего остального в человеке, от его натуры, я могу наслаждаться тем или иным произведением, но мне затруднительно судить о нем помимо моего знания о самом человеке; я бы сказал так: «каково дерево, таковы и плоды».

[2] *Сәхапов М.Җ.* Яңарыш хәбәрчесе: Г. Исхакый иҗаты турында. Казан: Мәгариф, 2003. 367 б.

[3] *Хәсәнов М.* Милли яңарыш хәбәрчесе // Сәхапов М.Җ. Яңарыш хәбәрчесе: Г. Исхакый иҗаты турында / М.Х. Хәсәнов кереш сүзе белән. Казан: Мәгариф, 2003. Б. 8.

милли, фәлсәфи аспектларда тикшерә һәм Г. Исхакый иҗатының милли һәм гомумкешелек кыйммәтләренә йөз тотуын билгеләп үтә.

Әдипнең мөһаҗирлек чоры иҗатын инкыйразга каршы көрәш мотивларының сәнгати формада гәүдәләнеше буларак тикшерү XX гасыр, аеруча совет чоры татар әдәбиятының үсеш-үзгәрешен, эчтәлек-тенденцияләрен, төп юнәлеш-эзләнүләрен тирәнтен аңларга ярдәм итә. Г. Исхакый иҗаты югалган мөмкинлекләрне ачыклау белән бергә, бу дәвер сүз сәнгате турында бөтенлекле күзаллау тудыра, дип билгели автор.

Г. Исхакый иҗатында яңа бер катламны ачып, җитди тикшеренүләргә юл ачкан хезмәтләр арасында А. Шәмсутова монографиясе [1] игътибарга лаек. Автор Г. Исхакый мирасындагы хатын-кыз язмышы мәсьәләсен феминистик проблемалар күзлегеннән анализлый. Әдипнең күпсанлы әсәрләрендә урын алган идеяләрне рус һәм Көнбатыш әдәбиятларындагы карашлар белән тарихи-чагыштырма, типологик планда бәяли. Комплекслы тикшерү барышында психологик метод[2] алымнарына җитди игътибар бирелә, бу исә күпсанлы әсәрләрнең уртак моментларын һәм фәлсәфи, социаль, психологик, дини аспектларга нигезләнгән үзенчәлекләрен ачыклауга мөмкинлек бирә. Феминизм, бер яктан, хатын-кызның иҗтимагый тигезлеген яклаган идеологияне, икенче яктан, иҗтимагый-сәяси хәрәкәтне аңлата. А. Шәмсутова әлеге катлаулы мәсьәләне татар иҗтимагый фикере үсеше, әдәби хәрәкәт һәм ислам дине реформаторлыгы белән тыгыз бәйләнештә тикшерә. Аның фикеренчә, «XIX гасырның икенче яртысында алдынгы фикерле

---

[1] *Шәмсутова А.А.* Гаяз Исхакый иҗатында феминистик проблемаларның идея-эстетик эволюциясе (1897–1954). Казан: Гуманитария, 2003. 192 б.

[2] Психологик методка әдәбият белемендә XIX йөзнең соңгы чирегендә нигез салына һәм ул, психология фәненең гаять зур үсеше белән бәйле, тулы бер әдәби юнәлеш булып үсә. Әлеге юнәлеш нигезендә, бер яктан, әсәрнең аны иҗат итүче белән бәйләнешен, икенче яктан, укучы тарафыннан кабул ителү үзенчәлекләрен ачыклау ята. Ул үз эченә төрле илләрдә, әдәбиятларда барлыкка килгән түбәндәге мәктәп һәм агымнарны ала: сәнгать психологиясе (психология искусства), фрейдизм, неофрейдизм, К. Юнгның аналитик психологиясе һ.б. Психологик юнәлеш тарафдарлары әсәрдәге әдәби образның эчтәлеккә караганда баерак булуын, төрлечә бәяләнә алуын, күпмәгънәлелеген күрсәтәләр. Ә инде субъективлыктан котылу өчен алар автор биографиясенә һәм психологиясенә, әсәрнең тарихи һәм милли эчтәлегенә мөрәҗәгать итүне яклыйлар. Әдәби әсәргә анализда язучының шәхси психологик үзенчәлекләренә зур игътибар бирелә. Гомуми психология белән шөгыльләнүче Л.С. Выготский сәнгать әсәренең укучыга психологик тәэсир итүе мәсьәләләрен алга куеп, җитди тикшеренүләр алып бара. Австрияле З.Фрейдның аңсыз психологик процессларны тикшерүне күздә тоткан методы әдәбият-сәнгать өлкәсен дә иңләп ала. Табиб-психолог фикеренчә, әдәби әсәрнең нигез чыганагы һәм төп мотивлары булып авторның бала вакыттагы борчылулары һәм психосексуаль үсеш элементлары тора. Кешенең эш-гамәлен тәртипкә салучы аң артында ул, еш кына, үтеп чыга алмаслык тирән һәм көчле теләкләрнең булуын ача. Әнә шуларны ачыклау психоанализ, ә Фрейд методы – психоаналитик метод дип атала.

дин әһелләре дә мәгърифәтчеләр мәйданга алып чыккан хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсен ислам фәлсәфәсе яссылыгында хәл итү кирәклегенә төшенәләр». Шул уңай белән автор бер үзенчәлекне дә билгеләп: әгәр хатын-кызның гаиләдәге, җәмгыятьтәге урыны мәсьәләсен Көнбатышта алдынгы карашлы хатын-кызлар күтәреп чыкса, татар дөньясында бу эштә ир-атлар башлап йөри. Әлеге гомуми мәсьәләләргә нисбәтле Г. Исхакыйның «мәгърифәтчелек», «таңчылык», «милләтчелек», «мөһаҗирлек» чорлары иҗатында феминистик проблемаларның гәүдәләнеш үзенчәлеге ачыклана.

А. Шәмсутова карашынча, Г. Исхакыйның «мәгърифәтчелек» чоры әсәрләре («Кәләпүшче кыз», «Бай углы», «Ике гашыйк», «200 елдан соң инкыйраз», «Очрашу яки Гөлгыйзар») Көнбатыш феминистик фикерләре белән аваздаш идеяләрне күтәрүе һәм татар җирлеге өчен генә хас үзенчәлекле чишелешне тәкъдим итүе белән әһәмиятле. Г. Исхакый үгет-нәсихәт бирү юлыннан бара, шуңа да аң-белем, тәрбия ярдәмендә хатын-кыз язмышы мәсьәләсен хәл итеп була дип ышана. Әдипнең ир-атларда таяныч таба алмаган геройлары, гадәттә, Коръәнгә сыена.

Г. Исхакыйның «таңчылык» дәвере иҗатының асылын «Тартышуда гына табарсың үз хакыңны…» шигаре билгели һәм бу үзенчәлек феминистик карашларда да чагылыш таба. «Алдым-бирдем», «Тартышу», «Теләнче кызы», «Тормышмы бу?» әсәрләренә ясалган җентекле анализ аша, хезмәт авторы Исхакыйның «хатын-кыз эмансипациясенә социаль үзгәрешләр нәтиҗәсендә генә ирешеп булуы» турындагы фикергә килүен белдерә. Г. Исхакыйның «Остазбикә», «Мөгаллимә», «Ул әле өйләнмәгән иде» кебек әсәрләрендәге феминистик идеяләр милли эчтәлек белән сугарылуы, милли яңгыраш алуы белән үзенчәлекле. Язучы карашларындагы сыйфат үзгәрешен эзлекле тикшереп, А. Шәмсутова «Остазбикә»дәге Сәгыйдәгә мөнәсәбәттә болай дип яза: «Ана кешенең бөеклеген, аның Эволюция өчен башкарган гамәленең тиңсезлеген күтәргән идеясе әдипнең дә, ул иҗат иткән чор әдәбиятының да фикер үзгәреше, үсешенең гуманистик югарылыкка атлавын исбатлый».

Г. Исхакыйның мөһаҗирлек чоры әсәрләрендә миллият һәм дәүләтчелек фикерләре тагы да үстерелә. Автор әдипнең «Дулкын эчендә», «Көз» кебек әсәрләрен Көнбатышта урын алган феминистик карашлар белән чагыштырып бәяли. Хатын-кыз өчен барлык әхлакый-психологик проблемаларны чишү идеологиясе итеп Г. Исхакыйның ислам динен тануы билгеләнә. Әдипнең гаилә корганда ир-аттан ир дә, дус та булу таләп итеlә дигән карашы да Көнбатыштагы идеяләрдән аерылып тора. Гомумән, А. Шәмсутова хезмәте Г. Исхакый иҗатын фәнни казанышлар биеклегеннән торып бәяләве һәм житди ачышларга килүе, шулай ук әлеге мирасны өйрәнүнең яңа юлларын ачуга этәргеч бирүе белән татар әдәбият белемендә яңалык булды.

XX йөз башы әдәбиятының күптөрлелеген, төрле иҗат типларына, юнәлеш-агымнарына шактый иркен мөрәҗәгать итүен ачу ягыннан А. Саяпова, Д. Заһидуллина, Р. Ганиева хезмәтләре игътибарга лаек. XX йөз башы әдәбиятына, аның аерым вәкилләре иҗатына яңача якын килүнең уңышлы үрнәге булып А. Саяпованың «Поэзия Дардменда и символизм», «Дардменд и проблема символизма в татарской литературе» дигән монографияләре тора[1]. Гаять бай фәнни-теоретик әдәбиятка нигезләнеп язылган хезмәтләрнең яңалыгы, бер яктан, XX йөз башы әдәбиятының иң күренекле шагыйрьләреннән булган Дәрдемәнд иҗатын монографик планда беренче тикшерүдә булса, икенче яктан, фәлсәфә, иҗтимагый фикер, социология, психология өлкәсендәге казанышларга һәм әдәбият белемендәге герменевтикага, рецептив эстетикага таянып, әдип иҗатын яңача бәяләүдә чагыла[2].

Галимә, шагыйрьнең дөньяга карашы, яшәешне әдәби образларда кабул итүе, сәнгати фикерләү үзенчәлеге, символистларга хас булганча, экзистенциаль тоемлауга нигезләнүе турында нәтиҗә ясый. Дәрдемәнд иҗатындагы фәлсәфи эчтәлекне А. Саяпова Көнчыгыш һәм Көнбатыш фәлсәфи-эстетик фикере синтезы буларак аңлата, шуңа бәйле татар сүз сәнгатен бөтендөнья әдәбияты фәлсәфи-эстетик фикере кысаларында өйрәнү өчен тикшеренүләргә юл ача. Галимә, XX йөз башы татар әдәбиятында реалистик, романтик һәм модернистик юнәлешләрнең тулы бер катлам тәшкил итүен билгеләп, Дәрдемәнд шигъриятенә С. Рәмиев. Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов һ.б.ның иҗатлары белән бәйле чагыштырма-типологик анализ ясый. Бу исә шагыйрь иҗатының үткән традицияләргә, шул исәптән суфичыл карашларга нигезләнүен һәм үз заманының социаль, иҗтимагый, тарихи, мәдәни вакыйгаларына мөнәсәбәтле алып килгән табышларын ачарга мөмкинлек бирә.

---

[1] *Саяпова А.М.* Поэзия Дардменда и символизм. Казань: Изд-во КГПИ, 1997. 210 с.; *Саяпова А.М.* Дардменд и проблема символизма в татарской литературе. Казань: Алма-Лит, 2006. 246 с.

[2] Рецептив эстетика әсәрне кабул итү үзенчәлеге белән бәйле булып, китап укучының ролен калкытып куя. Әдәбият белеменең әлеге юнәлеше тарафдарлары фикеренчә, әдәби әсәрнең яшәеше, әдәби процесстагы урыны китап укучы белән «очрашуы», соңгысының караш-мөнәсәбәте белән бәйле. Шуңа да «рецептив эстетиканың төп өйрәнү предметы булып рецепция, ягъни укучы яки тыңлаучының әдәби әсәрне кабул итүе тора. Дөрес, әсәр белән укучы мөнәсәбәте төрлечә булып, бер төр әсәр текстында укучы үзе дә катнашырга, урын алырга мөмкин. Авторлар кайвакыт китап укучы турында уйланалар, аның белән әңгәмә алып баралар. Икенче төр әсәрләрдә, кабул итүче субъектның үзенчәлекле чагылышы булып, күз алдында тотылган укучының әсәрнең эчке катламында урын алуы тора. Аны икенче төрле «адресат концепциясе» дип атыйлар. Укучы-адресат булып конкрет шәхес, авторның замандаш публикасы һәм ерактагы, читтәге зат була ала. Әлеге үзенчәлеккә нигезләнеп, рецептив эстетикага нигез салучы немец галимнәре Х.Р. Яусс, В. Изер, М. Науман һ.б.ның хезмәтләрендә үзәккә автор түгел, ә аның адресаты куела.

Д. Заһидуллинаның «Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы» хезмәтендә[1] гасыр башы татар прозасындагы яңалыкларны, «сәнгать әсәре ярдәмендә тормыш моделе тудыруның өр-яңа ысулларын сынап караган» яңа тип авторларның күпсанлы әсәрләрен тикшереп бәяләү һәм шул чор әдәбиятындагы урынын билгеләү максат итеп куела. XX гасыр башында татар җәмгыяте тизләтелгән үсеш чорын – Яңарыш дәверен кичерә. Рус капиталы белән көрәштә татар буржуазиясе үсеп, ныгып җитә. Яшәешнең төрле якларына бәйле иҗтимагый-фәлсәфи һәм сәяси фикердәге күтәрелеш милли үзаң үсешенә һәм ахыр чиктә татар милләте формалашуга китерә. Боларның нигезендә яткан җәдитчелек хәрәкәте дини реформаторлыкка, мәгариф системасына, вакытлы матбугат һәм китап чыгаруга уңай йогынты ясый.

Модернизм әдәбиятының идея-эстетик принципларына бәйле күпсанлы әсәрләрне анализлаганда автор текстларны аңлатуны, аларны шәрехләү принципларын үз эченә алган герменевтикага таяна. Хезмәттә бу чор прозасында символларга мөрәҗәгать итүнең закончалыклары аерып чыгарыла. Тикшеренүче символизм эстетикасының тамырларын да, XX гасыр башындагы табыш-үзгәрешләрне дә күз уңында тота. Ф. Әмирхан, М. Хәнәфи, Б. Мансур, Г. Рәхим, М. Гафури, Ә. Таңгатаров, Ширин, Г. Газиз һ.б.ның проза әсәрләрендә символларның төп идеяне ачудагы урыны дәлилле билгеләнә. Галимә аларны берничә катламга бүлеп карый. Берсе – тарихилык принцибын үзенчә аңлаткан мәдәни синтез юлы; икенчесе – милли, ягъни тарихи яки мифологик булуы белән «бүгенгене милләтнең үткәне һәм бүгенгесе кебек аңларга ярдәм итү; өченчесе – аллегорик образлар ярдәмендә милли, әхлакый, фәлсәфи фикерләрне укучыга җиткерү.

Әдәбияттагы сызлану яисә экзистенциализм фәлсәфәсенең XX йөз башы прозасында чагылыш үзенчәлекләре татар әдәбият белемендә иң аз өйрәнелгән өлкә булып кала бирә. Галимә өч дистәләп хикәя һәм нәсерне тикшерү аша XX йөз башы әдәбиятында экзистенциализм фәлсәфәсенә нигезләнгән тулы бер агым-катлам булуын дәлилли. Н.Думави, Г. Газиз, Ф. Әмирхан һ.б. авторларның киң катлау укучыларга таныш әсәрләрен дә «яңача» укый, моңа кадәр игътибардан читтә калган деталь-күренешләрне таба, аларның әсәрдәге ролен билгели.

Хезмәттә мәхәббәт темасының чор, яшәеш үзенчәлекләре, халыкны борчыган мәсьәләләр белән тыгыз бәйлелектә тикшерелүе дә игътибарны җәлеп итә. Күпсанлы мисалларда XX гасыр башы прозасында әлеге табигый хис-тойгыны тасвирлауның гаҗәеп матур төсмерләре булуы ачыклана. Галимә фикеренчә, татар әдәбиятындагы мәхәббәт фәлсәфәсе, бер яктан, Шәрык ренессансы чорыннан килә торган неоплатонизм

[1] *Заһидуллина Д.Ф.* Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. 255 б.

эстетикасын кулланган романтик сурәтләүгә нигезләнсә, икенче яктан, рус һәм Европа фәлсәфәсендәге караш-фикерләрне дә читкә какмый. Билгеле ки, тормышның үзе кебек, мәхәббәт турындагы әсәрләр дә бертөрле генә түгел. Сөю хисен кешене азатлыкка, тормыш ваклыкларыннан өстен булырга өндәүче, яшәеш матурлыгын күрергә ярдәм итүче могҗиза рәвешендә тасвирлау белән бергә, аерым хикәя-нәсерләрдә тән мәхәббәтен җан мәхәббәтенә каршы кую, яраткан кешеңне югалтуның олы фаҗига булуын ачып, яшәү мәгънәсен югалту буларак чагылуы, кайвакыт мәхәббәт нәфрәткә күчеп, дөньяга ләгънәт укуга китерүе кебек каршылыклы күзаллаулар да булуын билгели автор.

XX гасыр башында татар дөньясында сәнгатьнең башка төрләре, аерым алганда рәсем сәнгате белән кызыксыну импрессионизм төшенчәсе үтеп керүгә китерә. Нигезендә рух, кичереш Матурлыгын ачу принцибы яткан бу агым татар әдәбиятына да билгеле бер йогынты ясап, бер төркем әсәрләрнең әдәби-эстетик асылын билгели. Д. Заһидуллина фикеренчә, XX йөз башы прозасында импрессионистик алымнарның түбәндәге сыйфат-хасиятләре киң чагылыш таба: кеше гомеренең бер аралыгын һәм, гадәттә, уй-кичереш үзгәрешен ачу; мизгел матурлыгын тудыру; табигатьне җанландыру һәм аның хәрәкәте аша көймоңга, музыкага хас эмоциональлеккә ирешү; шәхеснең эчке дөньясын, уй-кичерешләрен тасвирлауга нигезле психологиясенә үтеп керү, хис һәм акыл көрәшен күзәтү; төрле жанр сыйфатлары синтезына килү һ.б. Автор әлеге чор прозасында сәнгатьлелекне үстерү юлындагы эзләнүләрнең сурәтләнгән тормыш моделен тәэсирлерәк, лирик яңгырашлырак итү юнәлешендә баруын, әдипләрнең еш кына кушылмалылыкка омтылуын күрсәтә.

«Дөнья сурәте үзгәрү»[1] китабында Д. Заһидуллина татар әдәбиятының күпгасырлык тарихына күз ташлап, анда яшәеш сурәтләренең ни сәбәпле һәм ни рәвешле үзгәрүен тикшерә. Әдәбиятыбызда дөнья сурәте үзгәрүендә аеруча әһәмиятле дәвер буларак XX йөз башы игътибар үзәгендә тора. Автор фикеренчә, бу чорда дөньяның яңа моделе формалаша, яңа тип геройлар мәйданга килә. Әлеге контекстта Дәрдемәнд, Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, Н.Думави һ.б. иҗатындагы милли дөнья сурәте чыгылышын тикшереп, әдәбиятыбызның классик чорына фәлсәфи ноктадан торып бәя бирелә.

Галимәнең, алдагы эзләнүләре нәтиҗәсе буларак, «Модернизм в татарской литературе первой трети XX века»[2] монографиясе дөнья күрә. Үсеш-үзгәрешендә икенче Яңарыш чорын кичерүче татар әдәбия-

[1] *Заһидуллина Д.Ф.* Дөнья сурәте үзгәрү: XX йөз башы татар әдәбиятында фәлсәфи әсәрләр. Казан: Мәгариф, 2006. 191 б.

[2] *Загидуллина Д.Ф.* Модернизм в татарской литературе первой трети XX века. Казань: Татар. кн. изд-во, 2013. 207 с.

ты Көнчыгыш һәм Көнбатышның әдәби-фәлсәфи йогынтысында булып, житди сан һәм сыйфат үзгәрешләренә ирешә. Аның бер чагылышы булган модернистик эчтәлекле әдәбиятта символизм, экзистенциализм, экспрессионизм, импрессионизм, гыйсъянчылык кебек агымнар пәйда була. Күпсанлы әсәрләрне тикшерү аша XX йөз башы әдәбиятында аларның тулы бер агым-катлам булуын дәлилли. Галимә Дәрдемәнд, Н.Думави, Г. Газиз, Ф. Әмирхан һ.б. авторларның киң катлау укучыларга таныш әсәрләрен дә «яңача» укый, моңа кадәр игътибардан читтә калган деталь-күренешләрне таба, аларның әсәрдәге ролен билгели. Авторның 1917 елдан соңгы әдәбият буенча тикшеренүләре бу чор сүз сәнгатенә бәйле фикер-карашларны бермә-бер киңәйтеп җибәрә. XX йөз башындагы модернистик эзләнүләрнең яңа шартларда да үзгә юллар, алымчаралар белән дәвам ителүе, аларның социалистик реализм иҗат методы белән катлаулы мөнәсәбәте билгеләнә. Рус әдәбиятының көчле йогынтысында булган авангард әдәбият форма һәм эчтәлекне яңарту юлларын эзли. Шул рәвешле имажинизм һәм футурузм дип аталган агымнар мәйданга килә. Автор фикеренчә, аларда билгеле бер дәрәҗәдә XX йөз башы модернизм әдәбияты билгеләре саклана. Әмма бу күренеш озакка бармый. 1920 елларның икенче яртысында сүз сәнгатендә бертөрлелек көчәя һәм ул әдипләрнең сәнгати эзләнүләрен бермә-бер тарайта.

XX йөз башы әдәби мирасыбызны текстологик яктан тикшерү, әсәрләрнең туу тарихы, авторлыгы, текстларда авторның иҗади ирегe чагылу үзенчәлекләре З. Рәмиевнең «XX йөз башы татар әдәбияты: авторлык, төп текст һәм хронология мәсьәләләре» исемле монографиясендә[1] тикшерелә. Эзләнү-тикшеренүләрне ул берничә юнәлештә алып бара. Аның берсе – әдәби текстларның авторлыгын ачыклау. Гасыр башында татарлар яшәгән төбәкләрдә чыккан күпсанлы газета-журналларда ачык, яшерен һәм имзасыз әсәрләр еш очрый. Яшерен имзалы текстларның авторларын ачыклау буенча З. Рәмиев зур эш башкара. Бай чыганакларга нигезләнеп, Г. Тукай, Ф. Әмирхан һ.б. әдипләрнең псевдонимнарын билгеләү, әсәрләрен җыю, туплау һәм халыкка җиткерүнең тулы елъязмасын бирә. Бу өлкәдә күп хезмәт куйган Р. Гайнанов, Р. Нәфыйгов кебек галимнәр хезмәтләренә дә таянып, Тукайның – 64, Ф. Әмирханның 17 ачык һәм яшерен имзалар белән эш итүен ачыклый. Авторлыкны ачыклау кебек мөһим, әмма бик тә четерекле мәсьәләдә З. Рәмиев гаять игътибарлы булуны, бары тик һәркем кабул итәрлек дәлилле булганда гына хәл ителгән дип санауны таләп итә. Һәрберебезгә яхшы таныш «Сөй гомерне...» шигыре, истәлеккә таянып, озак еллар дәвамында Тукайга нисбәтле өйрәнелде. Чор вакытлы матбугатын тикшереп, галим әлеге шигырьнең 1912 елда «Йолдыз» да С. Сүнчәләй

[1] *Рәмиев З.З.* XX йөз башы татар әдәбияты: авторлык, төп текст һәм хронология мәсьәләләре. Казан: Школа, 2000. 180 б.

исеме белән басылуын ачыклый. Әдәбият белемендә теге яки бу әсәрне берәр авторга мөнәсәбәтле тикшергәндә тел-стиль чаралары да нигез, дәлил буларак күрсәтелә. Хезмәттә, күпсанлы мисалларга нигезләнеп, моңа сак килү искәртелә.

Текстология алдында торган мөһим бурычларның берсе итеп галим әсәрләрнең төп текстын билгеләүне саный. Моның өчен текстлар тарихын өйрәнү, ягъни текст үзгәрешләрен үзендә гәүдәләндергән бөтен төр кулъязма һәм басма материалларны бер-берсенә тыгыз мөнәсәбәттә өйрәнеп чыгу кирәк. XX йөз башы әдипләренең байтак автограф кулъязмалары сакланса да, бик күбесе югалу турында ачынып яза З. Рәмиев. Әдипләрнең аерым әсәрләре үзләре исән вакытта басылып чыкмый, ягъни алар текстларның дөрес булу-булмавына мөнәсәбәтләрен белдерә алмыйлар. Кайбер басмаларда исә чор, идеология йогынтысында аерым әсәрләр кыскартылып та бирелә. Мондый очракларда кулъязмалар һәм үз вакытында аннан эшләнгән факсимилесы ярдәмгә килә. Аларны чыганак буларак максатчан тикшереп, галим байтак шигырьләрдәге хаталарны таба. Төп текстны сайлап алуда басма чыганаклар белән дә сак һәм игътибарлы эш итү сорала. Авторларга язмаларын үзгәртүләрсез укучыга җиткерү шактый кыен булган. Бу, беренче чиратта, цензура тоткарлавы белән аңлатыла. Г. Коләхмәтовның «Яшь гомер» драмасы кыскартуларга дучар булуы билгеле. М. Гафуриның 1904 елда басылган «Фәкыйрьлек берлә үткән тереклек»нең исеме цензура таләбе белән 1908 елда «Аракы эчүнең бәласе» дип бирелә. Текстлар газета-журналлар редакциясе тарафыннан да үзгәртелү очраклары булган. Әйтик, Тукайның «Хөрмәтле Хөсәен ядкәре» шигырендәге «әүлияләр» сүзен редакция «дустлар» мәгънәсендә, ди. Тукай килешмичә, бу очракта «изгеләр» мәгънәсендә кулланыла, дип язып чыга.

Текстологиядә билгеле бер дәрәҗәдә өйрәнелсә дә, әлегәчә фәнни системага салынмаган даталаштыру һәм хронология мәсьәләләре дә галим игътибарыннан читтә калмый. Әсәрнең иҗат ителү, басылу вакыты әһәмиятле роль уйный, чөнки анда чорга бәйләнгәнлек һәрвакыт чагылыш таба һәм «эчтәлеккә салынган хисси-фәлсәфи байлыкны тирәнтен аңлауны гына түгел, бәлки язучының иҗат юлын күзалларга да ярдәм итә». З. Рәмиев аеруча әсәрнең тәмамлану һәм басылып чыгу даталарын ачыклауның мөһимлеген билгели. Автор татар текстологиясенең нигез принципларын эшли һәм XX йөз башында яшәп иҗат иткән әдипләребезнең иҗатын тулырак аңлау, өйрәнү мөмкинлеге бирә. Әлеге хезмәт үзенең гамәли ягы белән дә игътибарга лаек. Текстта ук әдәбият белеменә караган бик күп яңалыклар урын алу өстенә, бүгенге текстологларның, тәнкыйтьчеләрнең, теоретикларның яңа эзләнүләренә нигез дә булып тора.

XX йөз башы татар әдәбиятын өйрәнүгә багышланган хезмәтләр арасында Р. Харрасованың «Әдәби бәйләнешләр яктылыгында» моно-

графиясе[1] игътибарга лаек. Автор татар әдәбият белемендә арткарак калып килгән мәсьәләне – татар әдәбиятының башка халыклар әдәбияты белән үзара тыгыз бәйләнеш-мөнәсәбәтен ачыклауны, компаративистика методына[2] нигезләнеп, тикшерү объекты итеп ала. Бай фәнни-теоретик һәм әдәби хезмәтләргә таянып, Яңа заман татар әдәбиятының Шәрык сүз сәнгатенә, аерым алганда, төрек әдәбиятына йөз белән борылуы, тәрҗемәчелек эшенең җанлануы билгеләнә. Р. Харрасова фикеренчә, бер яктан, төрек әдәбиятының иң яхшы үрнәкләре – аеруча Ш. Сами, Ә. Мидхәт, Т. Әбуззия әсәрләре – татарчага күпләп тәрҗемә ителә, аларның фикер-карашлары татар прозасының сан һәм сыйфат үзгәрешләренә, еш кына, җирлек булып та тора. Икенче яктан, XIX йөз ахыры – XX йөз башы татар укучысы Көнчыгыш аша Көнбатышның күренекле фикер ияләре һәм әдипләре булган Ж. Руссо, Дж. Локк, Ф. Лист һ.б. хезмәтләре белән танышу мөмкинлеге ала. Алар яклаган идеяләр тиз арада татар әдәбиятының аерым вәкилләре иҗатында чагылыш та таба. Автор язганча, «...Мөселман дөньясының яшәү рәвешендәге, милли психологиясендәге, әдәби мирасындагы уртаклыклар, үзе дә шул мирас җирлегендә үскән төрек әдәбияты – татар язучыларына алар күтәргән проблемаларны тотып алырга, идея-эчтәлектәге яңалыкны күрергә булыша».

Әлеге киң пландагы күзәтүләргә нигеләнеп, XX йөз башы татар әдәбиятының иң күренкле вәкилләреннән берсе булган Г. Исхакыйның башлангыч чор иҗатына этрафлы бәя бирелә, шәрык (төрек) әдәбияты белән уртаклыклары ачыклану белән бергә, татар әдибенең әдәби-эстетик фикерләвендәге үзенчәлекләр калкытып куела. Дөрес,

[1] *Харрасова Р.Ф.* Әдәби бәйләнешләр яктылыгында. Казан: Гарт, 2002. 261 б.

[2] Компаративистика методы әдәби күренешләрне чагыштырып бәяләүне үзәккә ала. Бу яктан ул чагыштырма-тарихи методка бик якын. Шулай да аның өйрәнү өлкәсе бермәбер киң. Компаративистиканың мөһим билгесе булып бер милли әдәбиятның аерым чорларын, авторларын, әсәрләрен, шулай ук төрле әдәбиятларны чагыштырып өйрәнү тора. Соңгысына бәйле бөтендөнья сүз сәнгате үсеше компаративистиканың өйрәнү предметы булуын билгеләп үтү кирәк. Әлеге методның асылын билгеләүче принципларның берсе – әдәби күренешләрнең үзара йогынтысы һәм аның тигез дәрәҗәдә әһәмиятле булуы. Икенче төрле әйткәндә, үзара «диалог»та әдәби мәгълүматны җибәрүче һәм кабул итүченең статус-дәрәҗәләре бертигез. Бу урында рецепция күренеше кызыклы үзгәреш кичерә, ягъни тәэсир итүче аны кабул итүченең әдәби карашларын үзгәртә. Үз чиратында, «җибәрүче»дә элекке хәлендә калмый. Компаративистиканың икенче бер мөһим принцибын А.Н. Веселовский «каршы агым» («встречное течение») дип атый. Теге яки бу әдәби күренеш йогынтысын кабул иткәндә, әлеге материал, кабул итүченең әзерлегенә бәйле, билгеле бер үзгәреш кичерә, еш кына ул яңадан «тудырыла». Әдәбият үсешендәге закончалыкларга бәйле, компаративистикада күренешләрдәге охшашлык-аерымлыкны чагыштырып бәяләүнең ике төре аерып чыгарыла – генетик һәм типологик. Беренчесе текстара бәйләнешләрдәге, жанр төзелешендәге, конфликт төрләрендәге, тема-мотивлардагы уртаклыкны ачыклауга йөз тота. Ә инде типологик тикшеренүнең нигезендә төрле милли әдәбиятларда мөстәкыйль барлыкка килгән күренеш-билгене чагыштыру ята.

тикшеренүче Г. Исхакый белән генә чикләнми. Шул чорның күпсанлы әдипләре иҗатын өйрәнеп, мондый нәтиҗәгә килә: «1895–1905 елларда иҗат итүчеләр барысы да җитди эзләнүләр белән яши. Һәм алар, беренче чиратта, тел, сәнгатьчә фикерләү, дин ягыннан үзләренә якын торган, ә мәдәни үсештә бераз алдарак барган төрек әдәбиятына мөрәҗәгать итәләр».

Ике гасыр чигендә татар әдәбияты рус-Европа әдәби-фәлсәфи фикерен дә үзләштерә башлый. «Рус сәяси хәрәкәтләреннән хәбәрдарлык, аларда турыдан-туры катнашу, руслар белән бергә яшәү, рухи һәм милли изелүнең көчлелеге, социаль тормыштагы кискен каршылыклар татар иҗтимагый фикерен алга җибәрүче шартлар булып торды», – дип яза Р. Харрасова. Шундый шартларда рус телен, әдәбиятын өйрәнү, тәрҗемә итү көчәя бара. Актив иҗтимагый эшчәнлек белән яшәгән Г. Исхакый да моннан читтә калмый, билгеле. Рус әдәбиятының иң яхшы үрнәкләре белән танышу татар әдибенең дөньяга карашына, сәнгати фикерләвенә зур йогынты ясый. Автор фикеренчә, Г. Исхакыйның «Очрашу яки Гөлгыйзар», «Ике йөз елдан соң инкыйраз», «Теләнче кызы» әсәрләрендә рус һәм Европа фәлсәфәчеләренең, әдипләренең караш-фикерләре киң чагылыш таба. Мәгърифәтчелек идеологиясен яклап әдәби иҗатка килгән язучы, әкренләп, тәнкыйди реализм, Европа тибындагы романтизм эстетикасын үзләштерүгә килә. Башка әдәби агым-юнәлешләргә хас алымчараларны үз итүендә шулай ук рус әдәбиятының уңай тәэсире ачык чагыла. Төрек, рус-Европа әдәби-фәлсәфи фикерләренең йогынтысын тойган хәлдә, Г. Исхакый үз җирлегебездә үскән, татар әдәбиятының күпгасырлык традицияләрен тирәнтен үзләштергән, милли үзенчәлекләргә ия әдип булып җитешә, дигән нәтиҗәгә килә автор. Р. Харрасова хезмәте әдәби бәйләнешләр кебек кызыклы, әһәмиятле юнәлеш буенча алдагы тикшеренүләргә җирлек әзерләве белән дә игътибарга лаек.

Г. Исхакый иҗаты буенча башка тикшеренүләрдә дә әдипнең бай мирасы заман биеклегеннән торып бәяләнә, аның публицистика һәм әдәби тәнкыйть өлкәсенә керткән өлеше билгеләнә. Шул ук вакытта Г. Исхакый иҗатын текстологик өйрәнү дәвам ителеп, әдипнең унбиш томлык академик басмасы дөнья күрә. Әлеге уникаль басма җәмәгатьчелек тарафыннан шатланып каршы алына, бик югары бәяләнә һәм аны эшләүче бер төркем белгечләр 2016 елны Татарстан Республикасының Фән һәм техника өлкәсендәге премиясенә лаек була.

XX йөз башы татар әдәбиятының төп фигураларыннан берсе булган Г. Тукай мирасы һәрдаим тикшеренүчеләрнең игътибар үзәгендә тора. Аның гаҗәеп бай һәм халыкчан иҗатын өйрәнү төрле юнәлешләр буенча алып барыла: әсәрләренең тулы текстологиясен эшләү, Тукай энциклопедиясен эшләү; үз чоры әдәби процессындагы урынын, яңалыгын билгеләү; әдип иҗатының XX йөз татар сүз сәнгатенә йогынтысын ачу; иҗат

методларына, юнәлеш-агымнарга нисбәтле бәяләү; әсәрләрен әдәбиятның традицияләре дәвамчанлыгында күзәтү; Шәрык һәм Гареб әдәбиятлары йогынтысы; тема-мотивлар һәм идея-проблематика чагылышы; сәнгати сурәтләү чаралары байлыгы; мифология һәм фольклор белән мөнәсәбәте; публицистик һәм тәнкыйди эшчәнлеге; заманчалыгы, әсәрләрен һәр буынның үзенчә кабул итүе, мөнәсәбәт белдерүе; ислам дине һәм иҗтимагый фикер белән бәйләнеше; иҗатының мәдәни, социаль-тарихи, иҗтимагый кыйммәте; Евразия идеясе чагылышы; иҗатының милли һәм гомумкешелек әһәмияте һ.б. Халык шагыйренең 100, 110, 115, 120, 125, 130 еллыгы уңае белән үткәрелгән халыкара конференцияләрдә, алар буенча басылып чыккан җыентыкларда[1] җитди яңалык-табышлар урын алып, иҗатының яңадан-яңа төсмерләре ачыклана. Даими үткәрелеп килә торган «Тукай укулары» да классик әдип иҗатын аңлауда, киң катлам укучыларга җиткерүдә мөһим чара булу белән бергә, мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында иҗатын өйрәнүне камилләштерүгә, яңа юлларны, алым-чараларын эзләүгә җитди өлеш кертә[2].

Тукай әсәрләренең тулы текстологиясен эшләү һәм академик басмасын әзерләү мәсьәләсе XX гасыр дәвамында әдәбият галимнәренең игътибар үзәгендә була. Совет чорында шагыйрьнең берничә басмасы дөнья күрә. Аның иң тулысы буларак 1986 елда биштомлык җыентыгы басылып чыга. Әмма ул идеология йогынтысыннан котыла алмый. Әдипнең аерып шигырьләре кыскартылып басыла, кайберләре җыентыкка керми кала. Ике гасыр чигендә бу мәсьәлә буенча Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре тарафыннан җитди эш башкарыла. Шул нигездә шагыйрьнең 125 еллыгына икетомлык җыентыгы басылып чыга, ә инде 130 еллыгы уңаеннан алты томлык академик басмасы укучыларга килеп ирешә.

XX йөз башы әдәбиятын өйрәнүдә җитди казаныш чагылышы буларак «Тукай энциклопедиясе»[3] дөнья күрә. Ул татар әдәбиятындагы беренче энциклопедия булуы белән үк кыйммәт. Хезмәттә Г. Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты төрле планда яктыртыла, аның белән бәйле

[1] Творчество Тукая в контексте евразийской культуры: материалы конференции. Казань: Фикер, 2002. 176 с.; Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар. Казан: 2011, 315 б.; Габдулла Тукай и тюркский мир: материалы международной конференции. Казань: ИЯЛИ, 2016. 484 с.; Духовное наследие: поиски и открытия. Казань: ИЯЛИ, 2016. 276 с.; Габдулла Тукайның тормыш һәм иҗат хроникасы өчен материаллар (1886–1907). Казан, 2018. 448 б. һ.б.

[2] Тукай укулары, апрель 1999 = Тукаевские чтения. Чыг. 2: Чыгышлар җ-гы / төз.: Э.С. Вильданова, Н.М. Гафиятуллина. Казан: Отечество, 2000. 166 б.; Тукай укулары, 22 апрель 1998: чыгышлар җыентыгы / төз.: Э.С. Вильданова; мөх.: Л.Г. Алексеева, Р.Н. Андеева. Казан, 1999. 175 б.һ.б.

[3] Габдулла Тукай. Энциклопедия / баш мөх. З.З. Рәмиев. Казан: Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2016. 864 б.

әдәби-мәдәни мәгълүматлар, хезмәтләр, истәлекләр бөтен байлыгында һәм тулылыгында китап укучыларга җиткерелә. Энциклопедиядә сигез тематик юнәлешкә караган материаллар бирелеп, алар бөек Тукайның тормышын, иҗатын, ул яшәгән чорны иңләп ала. Хезмәтнең баш мөхәррире З. Рәмиев язганча, «Тукай дөньясының зурлыгы һәм тирәнлеге төрле яктан, сыйнфый һәм идеологик бәяләргә буйсындырылмыйча ачыла»[1]

Тукай иҗатын максатчан өйрәнүчеләр арасында Т. Галиуллин, Х. Миңнегулов, Р. Ганиева, Ф. Галимуллин, В. Әминева, З. Рәмиев, Ф. Яхин, Р. Исламов, Н. Йосыпова һ.б. бар. Ф. Галимуллин «Мәктәп китапханәсе» сериясендә «Г. Тукай. Сайланма әсәрләр. Шагыйрь турында истәлекләр» китабын төзеп бастыра. Галим китапка язылган кереш мәкаләсендә шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлына этрафлы күзәтү ясый[2]. Игътибар үзгенә Тукайның әдәби иҗатка килү юлы һәм шактый тиз вакыт аралыгында халык шагыйре булып танылу сәбәпләрен ачу куела. Әлеге язма тулылыгы, фактик дәлилләргә бай булуы, шагыйрь иҗатына заман биеклегеннән торып бәя бирүе белән аерылып тора. Г. Тукайның, бер яктан, үзеннән соңгы әдәбиятка йогынтысы, икенче яктан, XX гасыр татар сүз сәнгатендә әдәби образы чагылышы мәсьәләләре Н. Гафиятуллина хезмәтендә тикшерелә[3]. Ф. Яхин «Әдәбият укыганда: фәнни тикшеренүләр»[4] хезмәтендә бөек шагыйрь иҗатының киң җәмәгатьчелек игътибарыннан читтә калган якларын өйрәнүгә алына. «Тотса мәскәүләр якаң…» язмасында әлеге фельетонның язылу тарихы һәм аңа этәргеч биргән «Бакырган китабы» чагыштырма планда этрафлы бәяләнә. Ә инде «Г. Тукай иҗатының асыл хикмәтләре», «Г. Тукай «Бердәмлек һәм тәрәккыять комитеты»нда», «Г. Тукай журнализмы» язмаларында әдипнең күпкырлы эшчәнлегенең аерым сәхифәләре фактларга бәйле ачыклана. Тукайга булган игътибар бөек шәхеснең туганнары, якыннары, дуслары, хезмәттәшләре белән булган мөнәсәбәтенә ачыклык кертүне сорый. Р. Исламов һәм Җ. Миңнуллин тарафыннан төзелгән «Тукай – ядкәрләрдә» китабы[5] әлеге сорауларга җавап рәвешендә язылган. Ике томлы басмада моңа кадәр билгеле булган истәлекләр белән бкергә, өр-яңа хатирәләр, докумиентлар да урын алган.

Бу дәвернең күренекле әдипләреннән Г. Исхакый, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Дәрдемәнд, Г. Камал, С. Рәмиев, К. Тинчурин, Җ. Вәлиди,

[1] *Рәмиев З.З.* Тукай энциклопедиясе хакында // Фәнни Татарстан. 2016. № 2. Б. 38–42.

[2] *Галимуллин Ф.Г.* Халыкның үз шагыйре // Г. Тукай. Сайланма әсәрләр. Шагыйрь турында истәлекләр. Казан: ТаРИХ, 2002. Б. 5–42.

[3] *Гафиятуллина Н.М.* XX гасыр шигъриятендә Тукай. Казан: Матбугат йорты, 2002. 152 б.

[4] *Яхин Ф.З.* Әдәбият укыганда: фәнни тикшеренүләр. Казан: Сүз, 2014. 236 б.

[5] Тукай – ядкәрләрдә: ике томда / төз.: Р. Исламов, Җ. Миңнуллин. 1 т. Казан: Рухият, 2015. 322 б.

Г. Сәгъди һ.б.ның юбилейлары үткәрелү, җыентыклары басылып чыгу да Яңарыш чоры турында күзаллауларыбызны киңәйтә, яңа сәхифәләр өсти[1].

XX йөз башы татар әдәбиятын иҗат агымына, жанр үзенчәлегенә, стиль эзләнүләренә, тема-мотивларга нисбәтле күпсанлы фәнни тикшеренүләр алып барыла. З. Салахова Г. Ибраһимов иҗатын натурализм күренешенең эволюциясенә бәйле өйрәнеп, язучы әсәрләрендә фотографизм һәм биологизм кебек типлары урын алуын дәлилли[2]. А. Кадыйрова Г. Исхакыйның зыялылар темасына багышланган пьесаларын XX йөз татар драматургиясендә барган эзләнүләр фонында тикшерә. Автор әлеге чорны гаять әһәмиятле күчеш дәвере буларак бәяли. Г. Исхакыйның «Мөгаллим» һәм «Мөгаллимә» пьесаларын «Яңа драма» дип аталган әдәби күренеш белән тыгыз бәйләнештә өйрәнә һәм аларның татар сәхнә әдәбияты үсешендәге урыннарын билгели[3]. Р. Мингазова исә классик язучы иҗатын руссоизм традицияләренә нисбәтле тикшерә һәм француз фәлсәфәчесе карашларының XX йөз башында үтеп керү шартларын, Яңарыш әдәбиятына уңай йогынтысын, Г. Ибраһимов әсәрендә идея-эстетик планда трансформацияләнүен күрсәтә[4]. Д. Абдуллина Г. Тукай иҗатында Коръән мотивларын әдәбият белеменең соңгы казанышларына нигезле тикшерсә[5], Т. Мирсияпова XX йөз татар сүз сәнгатенә экзистенциализм мотивларының шактый тирән үтеп керүен М. Хәнәфи әсәрләрен бәяләү аша билгели[6]. Бу урында тагын бер җитди хезмәтне атап үтү сорала – И. Рәмиеваның «Рус, татар, төрек әдәбиятларында ханбикә Сөембикә образы»

---

[1] Гаяз Исхакый һәм татар дөньясы. Казан, 2000. 296 б.; Галимҗан Ибраһимов һәм XXI гасыр. Казан, 2007. 332; Кәрим Тинчурин һәм татар сәнгате. Казан, 2007. 336 б.; Дәрдемәнд мирасы һәм хәзерге заман: Дәрдемәнднең тууына 150 ел тулуга багышланган Бөтенроссия фәнни-гамәли конференция материаллары (11 декабрь, 2009). Казан, 2009. 272 б.; Мәҗит Гафури: әдип һәм халык язмышы: Мәҗит Гафуриның тууына 130 ел тулуга багышланган Бөтенроссия фәнни-гамәли конференция материаллары (28 октябрь, 2010 ел). Казан, 2010. 347 б.; Г. Ибраһимов мирасы һәм төрки дөнья: Г. Ибраһимовның тууына 125 ел тулуга багышланган Халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары (17 апрель, 2012 ел). Казан, 2012. 265 б.; Галимҗан Ибраһимовның иҗат дөньясында = В мире творчества Галимджана Ибрагимова. Казан, 2012. 375 б. һ.б.

[2] *Саляхова З.Г.* Натурализм в творчестве Галимджана Ибрагимова: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2004. 23 с

[3] *Кадырова А.О.* Пьесы Исхаки на тему трудовой интеллигенции. Казань: Меддок, 2006. 190 с.

[4] *Мингазова Р.А.* Руссоистские традиции в творчестве Галимджана Ибрагимова: автореф. дис. ... канд.филол. наук. Казань, 2009. 26 с.

[5] *Абдуллина Д.М.* Коранические мотивы в творчестве Габдуллы Тукая: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2005. 29 с.; *Абдуллина Д.М.* Габдулла Тукай иҗатында Коръән мотивлары. Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. 191 б.

[6] *Мирсияпова Т.И.* Экзистенциальные мотивы в творчестве М. Ханафи: автореф. дис. ... канд.филол. наук. Казань, 2009. 26 с.

китабы[1]. Компаративистика методына нигезләнеп язылган монография тарихи шәхесләр образын өйрәнүдә яңа башлангычка нигез салуы белән аерылып тора. Автор ханбикә Сөембикә образының XVI–XIX гасырлар рус әдәбиятында, XX гасыр башы татар әдәбиятында һәм төрек әдәбиятында сурәтләнешен тикшерә. Шул рәвешле, татар халкы тарихында мөһим урын алып торган шәхескә төрле халыкларның караш-мөнәсәбәте билгеләнеп, өч халык әдәбиятын чагыштырып өйрәнелә, сәнгати фикерләү үзенчәлекләре ачыклана. Болардан тыш, әлеге дәвернең күренекле әдипләре – аерым алганда, Г. Исхакый буенча Х. Шаһбанова (1998), Р. Яруллина (1998), С. Сәмитова (1998), Р. Фәхретдин буенча Г. Даутов (2001), Г. Зәйнуллина (2002), Ф. Габидуллина (2004), Г. Исхакый, Ф. Кәрими һәм Ф. Әмирхан буенча Л. Гарәпшина (2002), Г. Якупова (2006), Г. Исхакый һәм М. Горький буенча Д. Хәйруллина (2005), Ф. Туйкин буенча Э. Галимҗанова (2004), А. Таһиров буенча Р. Бәдретдинов (2008), Г. Ибраһимов буенча З. Салахова (2004), Р. Минһаҗева (2009), М. Гафури буенча М. Мөбарәкшин (2013), XX йөз башында татар китабы, аларның эчтәлеге, төрләре, нәшер ителүе һәм таралуы, тәрҗемә ителүе буенча З. Гыйләҗев (2003) һ.б.ның фәнни тикшеренүләре дөнья күрә.

Шулай итеп, XX йөз башы әдәбияты даими игътибар үзәгендә булып, фәнни тикшеренүләр яңа табышларга китерә. Арада «Яңа заман татар Ренессанс әдәбиятының үзәк фигурасы» (Р. Ганиева) булган Г. Исхакый иҗатын кайтару һәм әлеге бай мирасны тикшерә башлау гаять зур әһәмияткә ия. Бу чор әдәбиятын өйрәнү, нигездә, өч юнәлештә бара. Берсе – традицион юл булып, күренекле классиклар иҗатының идея-эстетик һәм фәлсәфи-этик катламнарын ачу, заман биеклегеннән торып бәяләү, шәрехләү, башка халыклар әдәбияты белән чагыштыру, традицияләр дәвамчанлыгы һәм яңачалыкларга мөнәсәбәтле тикшерү һ.б. Бу уңайдан Г. Тукай энциклопедиясен төзү буенча җитди эш башкарылуны һәм шуңа бәйле халык шагыйре иҗатының яңа яклары ачылуны әйтеп үтәргә кирәк. Икенчесе – бу чор әдәбиятының аерым вәкилләре иҗатын әдәби юнәлешләр һәм агымнарга нисбәтле өйрәнү. Бу исә, үз чиратында, XX йөз башы татар әдәбиятының реализм һәм романтизм белән шактый киң планда модернизм агымнарын үзләштерүен нигезли. Татар әдәбияты Шәрыкка һәм Гаребкә мөнәсәбәт мәсьәләсендә торган саен киңрәк Гаребкә йөз тотып, рус-Европа әдәби-фәлсәфи карашларын кабул итү юлына чыга. Өченчесе – XX йөз башы әдәбиятында билгеле бер урын алып та, төрле сәбәпләр аркасында әдәби процесстан читләштерелгән язучыларның мирасын өйрәнү, аларны әдәби әйләнешкә кертү һәм шуның белән бу чор сүз сәнгатен эзлекле, бердәм күренеш буларак аңлауга килү.

[1] *Рәмиева И.Р.* Рус, татар, төрек әдәбиятларында ханбикә Сөембикә образы. Казан, 2009. 244 б.

### *3.3.4. Совет чоры әдәбияты*

Хәзерге әдәбият белемендә аеруча күп бәхәсләр, фикер каршылыклары уяткан чор булып сүз сәнгатенең Октябрь инкыйлабыннан соңгы үсеш-үзгәреше тора. «Совет әдәбияты» исеме белән аталып йөртелгән бу дәвер һич тә бертөрле генә түгел. Аның «20 нче еллар», «30 нчы еллар», «Сугыш чоры», «Сугыштан соңгы еллар» һ.б. дип ваграк чорларга бүленеше әдәбият үсешендәге аерым биеклекләрне һәм югалтуларны билгеләргә омтылуның бер чагылышы. Белгәнебезчә, моңа кадәр әлеге чор әдәбияты, нигездә, берьяклырак, партиялелек, сыйнфыйлык кысаларында һәм социалистик реализм иҗат методы яктылыгында өйрәнелеп килenә. Андый хезмәтләргә тәнкыйди якын килү һич тә аларның әдәбият тарихын өйрәнүдәге билгеле бер урынын сызып атуга китерергә тиеш түгел. Мисал өчен, Т. Галиуллин һәм А. Әхмәдуллин хезмәтләре[1] социалистик реализм эстетикасына нигезләнеп язылган. Шул ук вакытта алар бүген дә тикшерелгән чор әдәбиятын аңлауда бай чыганак булып тора. Бу авторларның, бер яктан, 20–30 нчы еллар әдәбиятын халык авыз иҗатыннан, аеруча XX йөз башы сүз сәнгатеннән килә торган традицияләр җирлегендә өйрәнүенә бәйле булса, икенче яктан, әдәбият үсешенең төп тенденцияләре, шул исәптән аерым әдипләр иҗаты гуманизм идеалларыннан, гомумкешелек кыйммәтләреннән чыгып бәяләнә.

1990 еллардан башлап совет чоры әдәбият тарихына кагылышлы байтак хезмәтләр дөнья күрде. Әйтергә кирәк, алар бертөрле генә түгел. Аерым авторлар бу чор әдәбиятына берьяклы гына бәя бирү, хәтта кара мөһер сугу юлыннан киттеләр. Мондый берьяклылык «хакыйкый үткәнне бөтен тулылыгында»[2] күз алдына китерергә мөмкинлек бирми. Хәзерге әдәбият белеме алдында торган мөһим бурыч – совет чоры әдәбиятын, кискен кире кагудан яисә үткәндәге дини-рухи әдәбият белән чагыштырып, бертөрле генә бәяләүдән качып, бөтен тулылыгында, объектив ачыклау һәм үсеш тәҗрибәсен бәяләү[3]. Әлеге фикер «Татар әдәбияты тарихы»ның 6 нчы томы басылып чыгу уңаеннан Р. Батулла әйткән сүзләрдә тулылана: «Сиксән ел буена турысын әйтергә ярамаганда, татар шагыйрьләре, бигрәк тә алтмышынчы еллардан башлап, әйтергә теләгәннәрен тел төбенә, астарлы сүзгә яшереп, читләтеп, кактырып-суктырып иҗат итәргә дучар иде. Өстеңдә кылыч асылынып

---

[1] *Галиуллин Т.Н.* Дыхание времени (Вопросы становления и развития социалистического реализма в татарской поэзии). Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1979. 303 с.; *Ахмадуллин А.Г.* Татарская драматургия: Истоки и формирование социалистического реализма. М.: Наука, 1983. 264 с.

[2] *Хәсәнов М.* Татар әдәбияты тарихын өйрәнүнең кайбер методологик мәсьәләләре // Казан утлары. 1992. №1. Б. 142.

[3] *Нигматуллина Ю.Г.* Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. Казань: Фэн, 1997. С. 146.

торганда шулай кылмый, кая барасың? Кырык ел шул юнәлештә иҗат ителгән әсәрләрнең тел төбен ачып салу – галимнәрнең, тәнкыйтьчеләрнең бурычы»[1]. Яңа методологик принципларга таянып, Октябрьдән соңгы әдәбиятны яисә аерым чорларын бәяләү омтылышы Ф. Мусин, Ә. Әхмәдуллин, Т. Галиуллин, Й. Нигъмәтуллина, Н. Ханзафаров, Н. Хисамов, А. Яхин, Х. Миңнегулов, Ф. Хатипов, Р. Сверигин, Р. Салихов, Ф. Галимуллин, Э. Галиева, В. Әминева, Ә. Закирҗанов, В. Макарова, Р. Сарчин һ.б. хезмәтләрендә ясала.

Бу чор әдәбиятын бөтен тулылыгында, байлыгында күз алдына китерү, ягъни «ак таплар»сыз өйрәнү буенча җитди эш башкарыла. Идеологик күрсәтмәләрдән, сыйнфый мәнфәгатьләрдән чыгып бәя бирелгән һәм шунлыктан әдәби әйләнештән алынган яисә дөньяга бөтенләй чыкмаган әсәрләр кире кайтарыла. Г. Ибраһимовның «Адәмнәр», Ф. Әмирханның «Шәфигулла агай», Г. Рәхимнең «Идел» кебек хикәя-повестьлары, Ф. Кәримнең төрмәдә язган шигырьләре, Х. Туфанның үз вакытында басылмый калган шигырьләре тупланган «Гүзәл гамь» җыентыгы, С. Батталның «Батый ханга ачык хат» поэмасы, И. Салаховның унтугыз елдан соң гына басылып чыккан романы – әнә шундыйлардан[2]. Ф. Мусин билгеләп үткәнчә, «алар, бер яктан, 1917 елдан соңгы әдәбиятыбызны идея-эстетик берьяклылыктан коткаруга булышса, икенче яктан, татар әдәбиятының революциягә кадәрге милли вазифасын тоталитаризм дәверендә дә күпмедер башкара алуын күрсәтә»[3].

Әдәби мирасны бөтен рәвештә өйрәнү омтылышында чит илләрдәге татар әдәбиятына да игътибар арта. Г. Исхакыйның бай иҗаты белән янәшә М. Исмәгыйли, Х. Габдүш, Х. Хәмидулла, М. Арсланбәк, Ш. Келәүле һ.б. иҗаты да халкыбызга кайтарыла, әдәби әйләнешкә кертелә. Бу өлкәдә аеруча И. Надиров, Ә. Кәримуллин, Х. Миңнегулов, Т. Әйди, М. Госманов, Л. Гайнанова, Р. Гайнетдинов, Ә. Сәхапов, Римзил Вәлиев кебек шәхесләребез эшчәнлеген билгеләп үтү кирәк[4]. Чит илләрдәге татар әдәбиятын өйрәнүнең төп аспектлары һәм әлеге мирасның идея-эстетик кыйммәте, әдәби-иҗтимагый әһәмияте Х. Миңнегулов хезмәтләрендә аеруча тулы чагылыш таба. Галимнең вакытлы матбугат битләрендә дөнья күргән күпсанлы мәкаләләре, шулай ук «Дөньяда

---

[1] Тарихыбыз тулымы? («Татар әдәбияты тарихы» ның 6 нчы томы басылып чыгу уңаеннан фикер алышу) // Казан утлары. 2003. № 5. Б. 132.

[2] Бу турыда тулырак мәгълүмат: *Галиуллин Т.* Татар әдәбиятында «диссидентлар» булганмы? // Шигърият баскычлары. Казан: Мәгариф, 2002. Б. 172–181; *Мухаметдинов Р.* Татарские диссиденты // Звезда Поволжья. 2004. 14–20 октября. С. 3.

[3] *Мусин Ф.М.* Вакыт үзе куя бәһане // Мәдәни җомга. 2004. 7 май.

[4] *Кәримуллин Ә.Г.* Суоми иленең татар китаплары // Казан утлары. 1990. № 9. Б. 177–183; *Надиров И.* Финляндия татарлары // Мирас. 1992. № 2. Б. 73–81; *Госманов М.Г.* Чәчелгән орлыклар: Гөлҗа татарлары // Казан утлары. 1992. № 3–4. Б. 76–98; *Госманов М.Г.* Ябылмаган китап яки чәчелгән орлыклар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. 206 б. һ.б.

сүземез бар...» (1999), «Гасырлар өнен тыңлап...» (2003) җыентыкларында урын алган язмалары киң катлау татар укучысы өчен яңа бер дөнья – читтә яшәгән милләттәшләребезнең иҗат дөньясын ачуга хезмәт итә. Ә инде Х. Миңнегуловның «Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты» һәм «Чит илләрдәге татар әдәбияты» монографияләре[1] яңа фактик материалга байлыгы, әлеге мирасны укучыга кайтаруы, аны заман биеклегеннән торып фәнни нигездә тикшерүгә алынуы, яңа эзләнүләргә юнәлеш бирүе белән җитди яңалык буларак кабул ителә. Г. Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗатына багышланган хезмәт олы әдипнең чит илләрдәге тормышын, әдәби һәм фәнни-публицистик иҗатын, гомумән, киңкырлы эшчәнлеген бербөтен итеп һәм системага салып тикшерүе белән әһәмиятле. Милләтпәрвәр язучының туган иленнән киткәч иҗат иткән әсәрләре шактый өйрәнелгән, әмма Х. Миңнегулов аларны кабатламый, киресенчә, билгеле табышларга нигезләнеп, повесть-драмаларын үз аңлавында яңача бәяли. Г. Исхакыйның әлеге чор әдәби иҗаты культура-тарих методы[2] принципларында тикшерелә. Автор кат-кат искәрткәнчә, язучы әсәрләре, беренче чиратта, милли рух белән сугарылган. Бу исә аның алган тәрбиясе белән тыгыз бәйле булып, туган җирендә үк үзен халык бәхете, азатлыгы өчен көрәшкә багышлавы белән аңлатыла. Әдипнең чит илләрдә яшәргә мәҗбүр булуы иҗатының проблематикасында да, яклаган караш-фикерләрендә дә киң чагылыш таба. Х. Миңнегулов, совет илендәге татар әдәбиятыннан аермалы буларак, Г. Исхакыйның XX йөз башындагы сүз сәнгатебездә урын алган милли-гуманистик традицияләрне иң тулы, иң эзлекле һәм яңа төсмерләр белән баетып дәвам итүен билгели. Шуңа да язучының бай, сәнгати яктан югары мирасы бөтен татар әдәбияты белән күчемле бәйләнештә каралып, аның үсеш-үзгәреш үзенчәлекләрен тулы аңларга мөмкинлек

[1] *Миңнегулов Х.Й.* Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 367 б.; *Миңнегулов Х.Й.* Чит илләрдәге татар әдәбияты. Казан: Мәгариф, 2007. 399 б.; *Миңнегулов Х.Й.* «Их, шатланам татар булуыма» (Минһаҗ Исмәгыйлинең тормышы һәм иҗаты) // Мирас. 1996. №. 5–6. Б. 252–270; *Миңнегулов Х.Й.* Минһаҗ Исмәгыйли шигырьләре // Мирас. 1996. № 11. Б. 41–49; *Миңнегулов Х.Й.* Хөсәен Габдүш хикәяләре // Мирас. 1998. № 7. Б. 65–81; *Миңнегулов Х.Й.* Чит илләрдәге татар әдәбияты һәм матбугаты // Дөньяда сүземез бар... Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. Б. 194–210.

[2] Культура-тарих методына француз фәлсәфәчесе, тарихчысы, әдәбиятчысы И.А. Тэн тарафыннан нигез салына. Әлеге методның асылын әдәбият-сәнгатьне чынбарлык аша аңлату билгели, ягъни әсәрдә сурәтләнгән әдәби дөнья да, язучы психологиясе дә реальлек аша бәяләнә ала. Ул дөньядагы бөтен нәрсәне дә танып белеп һәм аңлатып була дип раслаучы позитивизм фәлсәфәсе белән тыгыз бәйле. И. Тэн билгеләп үткәнчә, әдәбиятның характеры өч башлангыч көч, өч төрле чыганак белән билгеләнә, берсе – «раса», ягъни теге яки бу халыкка хас үзенчәлек, менталь сыйфатлар, хәтта темперамент; икенчесе – «тирәлек», ягъни халыкның характерен формалаштыручы географик, тарихи, социаль-иҗтимагый факторлар; аерым кешегә бәйле – яшәү урыны, тәрбиясе, гаиләсе, профессиясе, җәмгыятьтәге урыны һ.б.; өченчесе – «момент», ягъни әсәр язылган вакытның, чорның үзенчәлекләре.

бирә, дигән нәтиҗәгә килә. Ә инде Гаяз Исхакыйның публицистик язмалары, аларга хезмәт авторы аңлатмалары татарның милли-азатлык көрәше сәхифәләрен шактый тулы күзалларга, аңларга мөмкинлек бирә. «Яңа милли юл» – бүгенге укучыда да соклану һәм горурлык хисе уята торган милли һәм көрәшче журнал. Х. Миңнегулов хезмәтендә урын алган дистәләрчә мәкалә (барысы да диярлек Г. Исхакый кулы белән язылган) татарның үткән тарихына, милләтпәрвәр шәхесләренә яңача карарга, эш-гамәлләрен яңача бәяләргә җирлек бирә, милли хисне үстерә. Г. Исхакыйның әлеге язмалары нигездә публицистик характерда булсалар да, алар сәяси-иҗтимагый мәсьәләләрне, фәнни бәяләмәләрне дә үз эченә ала. Татар әдәбияты, аның үсү-үзгәрү тарихы да бермә-бер байый, төрләнә, җәмгыятьтәге урыны ачыклана.

Х. Миңнегуловның «Чит илләрдәге татар әдәбияты» хезмәте бу өлкәдә озак еллар дәвамында алып барган өйрәнүләренең билгеле бер этабына йомгак, нәтиҗә булып тора. Төрле сәбәпләр аркасында туган җиреннән китәргә мәҗбүр булган татарлар, дөньяның төрле читләренә таралып яшәсәләр дә, һәркайда белем-мәгърифәткә, эшмәкәрлеккә омтылганнар, иҗат белән шөгыльләнгәннәр һәм күпсанлы газета-журналлар нәшир иткәннәр. Әдәби әсәрләр нигездә әлеге вакытлы матбугат битләрендә урын алган һәм төрле төбәкләргә (СССРдан тыш) таралган. Шуңа да әсәрләр урын алган журналлар алгы планга чыгарып тикшерелә. Хезмәттә эзлекле рәвештә «Яңа милли юл», «Казан», «Азат Ватан», «Яңа япун мөхбире» кебек журналлар турында бай мәгълүмат бирелеп, аларда урын алган күпсанлы шигырь, хикәя, драмалар татар укучысына тәкъдим ителә һәм тикшереп бәяләнә. Хезмәттә «әсәрләрнең камиллеге, фикри тирәнлеге ягыннан әһәмиятле саналган авторлар»дан[1] С. Гыйффәт, Ш. Келәүле, Х. Габдүш, М. Исмәгыйли, Х. Хәмидулла һ.б. иҗатына шактый киң урын бирелә. Автор әлеге мирасны тема-мотивлар, алым-чаралар, тел-стиль ягыннан анализлый. «Ватанны, туган җирне сагыну, халыкның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге хакында уйлану, аның бәйсезлеге, бәхете өчен көрәш, ислам динен зурлау һәм хөрмәт итү – чит илләрдәге татар әдәбиятының төп мотивлары. Миллилек һәм XX йөз башы, һәм совет чоры мөһаҗирлек әдәбиятында да, публицистикасында да үзәк урынны били»[2], – дип яза ул. Күпсанлы әсәрләрне өйрәнү аша, Х. Миңнегулов аларның Идел-йорттагы сүз сәнгате, күпгасырлык мирасыбыз белән аерылгысыз һәм табигый бәйләнешле булуы турында нәтиҗә ясый. Гомумән, күпсанлы авторларның, шул исәптән Х. Миңнегуловның чит илләрдәге татар әдәбиятын тикшерү өлкәсендәге эшчәнлегенең әһәмияте түбәндәгеләр белән билгеләнә: 1) озак вакытлар дәвамында читтә калып килгән әдәби мирасның татар укучысына

[1] *Мөхәммәтшин З.Г.* Чит илләрдә татар әдәбияты // Казан утлары. 2008. № 6. Б. 126.

[2] *Миңнегулов Х.Й.* Чит илләрдәге татар әдәбияты. Казан: Мәгариф, 2007. Б. 5.

кайтарылуы; 2) әдәби ядкәрләрдә сурәтләнгән тормыш материалының, тема-проблемаларның күптөрлелеге, аларның синкретизмы, асылда милли рух, эчтәлек белән сугарылган булуы күрсәтелү; 3) читтә дөнья күргән әсәрләрне совет чоры татар әдәбияты белән чагыштырып бәяләү һәм яңа нәтиҗәләргә килү; 4) читтәге әдәбиятның күпгасырлык милли традицияләргә тугры калуы, аны яңа шартларда дәвам итүе билгеләнү; 5) XX гасыр татар әдәбиятының чикләре бермә-бер киңәйтелү, аны тулы һәм бербөтен итеп өйрәнү мөмкинлеге ачылу; 6) татар сүз сәнгате, аның халыкның рухи тормышындагы урыны турындагы карашларыбызны киңәйтүе һ.б.

Совет чоры әдәбиятының аерым чорларындагы әдәби процесс үзенчәлекләре, традицияләр дәвамчанлыгы һәм заманга бәйле яңачалыклар, вульгар-социологик эстетика һәм аның әдәбиятта чагылышы һ.б. мәсьәләләр Ф. Галимуллин, Й. Нигъмәтуллина, Э. Бариева монографияләрендә тикшерелә.

Ф. Галимуллин «Эстетика һәм социологизм: 20–30 нчы еллар татар әдәбиятында эстетика кануннарының һәм социологизм таләпләренең үзара мөнәсәбәте» хезмәтендә[1] XX гасырның 20–30 нчы еллар әдәби хәрәкәте үзенчәлекләрен күпсанлы әдәби фактларга, моңа кадәр читтә калдырылган әсәрләргә нигезләнеп өйрәнә. Ике кисәктән торган хезмәтнең беренче бүлеге «Эстетик фикер һәм социологизм мөнәсәбәте» дип атала һәм әдәбиятны эстетик ләззәт бирү чарасыннан бигрәк, идеология коралы итеп кенә карауның сүз сәнгатен берьяклы үсеш юлына китерүе эзлекле рәвештә ачыклана. Октябрьдән соңгы чорда әле үткәннең бай традицияләре билгеле бер дәрәҗәдә дәвам иттерелә, әдәбиятның күптөрлелегенә, агым-юнәлешләргә юл куела. Бу исә тема, жанр төрлелегенә, тел-стиль киңлегенә, сәнгать чаралары муллыгына һәм, иң мөһиме, чынбарлыкны бөтен каршылыгында, катлаулылыгында сурәтләргә мөмкинлек бирә. Әмма егерменче елларның икенче яртысыннан башлап, әдәбият-сәнгать инде максатчан рәвештә идеологиягә буйсындырыла, социаль заказ белән язу гадәти күренешкә әйләнә, ягъни вульгар социологизм дип аталган мәнсез күренеш өстенлек ала. Тикшерүче-галим әдәбияттагы эстетик кануннарның, аның эчке закончалыкларының, матурлыкка, гомумкешелек кыйммәтләренә хезмәт итүче асыл вазифасының әсәр эчтәлеген сыйнфый мәнфәгатьләргә буйсындырган, миллилекне, бай тарихыбызны, атаклы шәхесләрне инкарь иткән, әдәби мирасны, гаҗәеп бай традицияләрне кире каккан социологизм тырнакларында эләгеп калуын, әдәби-эстетик эзләнүләргә никадәр зыян салуын, кайвакыт фаҗигаларга китерүен конкрет мисалларда ачып сала. Безнең күз алдына

[1] *Галимуллин Ф.Г.* Эстетика һәм социологизм: 20–30 нчы еллар татар әдәбиятында эстетика кануннарының һәм социологизм таләпләренең үзара мөнәсәбәте. Казан: Мәгариф, 1998. 223 б.

чорның тулы әдәби мохите бастырыла. Моңа кадәр киң катлауга түгел, белгечләргә дә аз таныш булган әдипләр, аларның әсәрләре әдәби әйләнешкә кертелә.

Ф. Галимуллин шагыйрь-язучыларыбызның шәхесенә, әдәби иҗатына яңача карарга, аларның дөньяга карашларындагы үзгәрешләрне күзәтергә мөмкинлек бирә. Егерменче еллар башында «Адәмнәр» хикәясе белән чорның реаль картиналарын натуралистик формаларда чагылдырган, яңа хакимиятнең булдыксызлыгын, әхлаксыз йөзен ачкан Г. Ибраһимовның карашлары үзгәрү эзлекле күзәтелә. Диктатураның асыл максатларын тирәнтен аңлый алмаган әдип әсәрләрен яңадан эшкәртеп язарга мәҗбүр була. Бөтен җаны-тәне белән яңа җәмгыятькә хезмәт иткән һәм үзе шуның корбаны булган олы шәхеснең фаҗигасен тирәнрәк аңлый башлыйсың. Ә менә Ф. Әмирханны идеологиягә буйсындыру теләге барып чыкмый. Социаль инкыйлабны, тулаем, уңай күренеш буларак каршы алса да, әдип яңа хакимиятнең асылын шактый тиз аңлап ала. Аның яңа төр яшәешкә, яңа «кыйммәтләр»гә карикатура рәвешендә язылган «Шәфигулла агай» хикәясе егерменче еллар әдәбиятын бермә-бер баета, төрләндерә. Әсәрләре 20–30 нчы елларда дөнья күргән М. Фәйзи, Һ. Такташ С. Баттал, И. Гази, Х. Госман, Н. Баян, Ф. Кәрим, К. Нәҗми, Г. Гали, Ф. Борнаш, М. Җәлил һ.б. иҗатын хуплаудан яисә тәнкыйтьләүдән бигрәк, аңларга кирәклегенә күбрәк төшенәсең. 20 нче елларның атаклы шагыйре Һ. Такташ һәм бу елларда үзенчәлекле әдип буларак киңрәк танылa барган Х. Туфан иҗатларында эстетик кануннарга таяну омтылышын һәм мәҗбүри социологизм юлыннан китү күренешенең каршылыклы хәрәкәтен тирәнтен ачыклау, бигрәк тә соңгысының «Аккордлар», «Ант» кебек әсәрләренә бирелгән бәя шагыйрьләр иҗатын өйрәнүнең өлгесе буларак кабул ителә.

Белгәнебезчә, әдәби процесс үз эченә, әсәрләр иҗат итү белән бергә, әдәби тәнкыйтьне дә ала. Соңгысы 20–30 нчы елларда үзенең кискенлеге, аяусызлыгы белән аерылып тора. Әдәби әсәрләргә бәя биргәндә вульгар социологизм таләпләрен нигез итеп алган тәнкыйтьчеләр сәяси якка гына игътибар итеп, еш кына аерым вакыйга, герой яисә детальгә таянып, ашыгыч, ләкин хәлиткеч нәтиҗәләр ясыйлар. Ш. Зәкиев, Ф. Мөсәгыйть, Ф. Мөбәр, Х. Наум, Г. Толымбай кебек тәнкыйтьчеләр, еш кына, үз фикерләрен җәмәгатьчелек карашы итеп биреп, әдипләр язмышына турыдан-туры куркыныч тудыралар. Сыйнфыйлык идеясен үзәккә кую берьяклы гына фикер йөртергә урын калдыра, тәнкыйтьчеләрне әдәбиятның эчке кануннарын ачудан читкә алып китә. Аерым хезмәтләрдә кешенең эчке дөньясын сурәтләү дә кимчелек булып санала башлый. Бу елларда күп бәхәсләр уяткан мәсьәләләрнең берсе – әдәби мираска мөнәсәбәт. Вульгар социологизм тарафдарларының Г. Исхакый, Дәрдемәнд, С. Җәләл, Г. Рәхим иҗатларына мөнәсәбәте «рәхимсез

көрәш» рәвешендә була. Г. Тукай, Ф. Әмирхан әсәрләренә дә капма-каршы, еш кына бер-берсен кире кагучы бәяләр бирелә.

Ф. Галимуллин хезмәтенең «Өслүб үзгәрешенең асылы һәм алшартлары» дип аталган икенче кисәгендә 20–30 нчы еллар әдәби хәрәкәтендә нинди сәбәпләр тәэсирендә стиль үзгәрешләре күзәтелү һәм аларның асылы нидән гыйбарәт булу тикшерелә. Әдәбиятның үсеш-үзгәрешен сүз сәнгатенең үз хасиятләреннән чыгып бәяләүгә омтылган Г. Сәгъди, Г. Нигъмәти, Җ. Вәлидиләрнең эшчәнлеге, фикер-карашлары шул ук социологизм киртәләренә бәрелеп зәгыйфьләнә, яңа рух өстәрлек, үзләре артыннан ияртерлек көчле яңгырамый. Табигый талантлары, үткән традицияләр йогынтысы һәм әдәби сиземләүләре белән әдәбиятның төп бурычы халык тормышының рухи хәрәкәтен яктыртуда булуын яхшы аңлаган Һ. Такташ, Г. Ибраһимов, Ф. Борнаш кебек әдипләрнең дә иҗади сәнгатьлелекне күтәрүгә омтылышлары купшы сүзләр белән төрелгән каршылыкка очрый. Дөрес, әлеге шәхесләр үзләре дә бу мәсьәләдә эзлекле булмыйлар. Кызганыч ки, ул елларда әдәбият-сәнгатьнең хакимият кулындагы бер винтикка әйләнүе, әдипләрнең билгеле бер темаларга язарга һәм сәясилеккә өстенлек биреп, тормышны «революцион үсештә», икенче төрле әйткәндә, ал буяуларга буяп сурәтләргә мәҗбүр булулары, һәркемнең үзенә хас өслүбен, иҗат индивидуальлеген ачарга тулы мөмкинлек бирми. Чорга хас өслүбне эзләүгә бәйле бер чиктән икенчесенә ташланулар күзәтелә. Әдәбиятта антитеза – иске белән яңаны каршы куеп тасвирлау алымы активлаша, ә инде шәхси-интим һәм иҗтимагый мөнәсәбәтләрдә соңгысына өстенлек бирелә. Әсәрләрдә еш кына сәяси хәлләргә иллюстрация ясалу, сәнгатьле иҗат белән публицистика арасындагы аерманы чамалап бетермәү сәнгатьлелек дәрәҗәсен киметүгә, коры дидактизмга, акыл өйрәтүгә, ясалма үрнәк образлар тудыруга китерә. Әнә шулай социаль, сыйнфый мәүзугълар алгы планга чыгып, сәнгатьлелек икенче планда калган һәм моны яхшы, шулай тиеш дип шаулаган чорда Г. Толымбайның әдәбиятка яңа килгән яшьләр Тукайга караганда чистарак, шәбрәк язалар, дию яисә рәсми тәнкыйтьнең Һ. Такташ иҗатын М. Крыймов, Г. Ильясовлардан түбәнрәк бәяләве сәбәпләре ачыклана төшә.

Әдәби хәрәкәттә, аерым алганда иҗат өслүбе мәсьәләләрендәге җитди кимчелекләрне, еш кына артка чигенүләрне җентекле күзәтү белән бергә, әдәбият үсешен тәэмин итәрлек, үткәннәр белән алдагы чорларны тоташтырырлык эзләнүләр, табышлар да игътибардан читтә калмый. Образлы фикерләүнең яңа мөмкинлекләрен ачарга омтылуның тормыш чынбарлыгына тугры калган (Г. Толымбай «Егет», Г. Ибраһимов «Кызыл чәчәкләр», «Тирән тамырлар» һ.б.), чорны эстетик үзләштерүдә сатира алымнарыннан уңышлы файдаланган (Г. Гобәйдуллин, Ф. Әмирхан һ.б.) әсәрләр иҗат итүгә китерүе монографиядә дәлилле ачыла. Укучы

зәвыгына йөз тотып эзләнүләр 20–30 нчы еллар сүз сәнгатендә Һ. Такташ, Г. Ибраһимов, К. Тинчурин һәм алар белән янәшә торган Ф. Борнаш, Г. Рәхим, М. Галәү, Т. Гыйззәт, Н. Исәнбәт, Б. Сирин һ.б.ны аерым бер иҗат биеклекләренә китерә. Шуның белән бергә, өслүб өлкәсендәге эзләнүләр, язучының тулаем иҗат осталыгы хәрәкәттә карала. Хезмәттә фәннилеккә якын өслүб элементларына мөрәҗәгать итүче Х. Туфан, шәкел белән мавыгучы Г. Кутуй, лирик Ш. Маннур, сәяси лирикада үзен иркен хис итүче Г. Мөхәммәтшин, лирик-интим шигырьләр белән укучыларын сөендерүче Н. Дәүли, прозада хис-кичерешләр тирәнлегенә омтылган Г. Гобәйдуллин, шәхес иреге темасын яңа биеклеккә күтәргән Г. Рәхим, юлъязма, очерк стилендә иҗат итүче Ш. Госманов һ.б. чорга хас иҗат портретлары тудырыла. Әлеге әдипләр дә билгеле бер кысаларда язарга мәҗбүр булалар. Әдәбиятның үсеш-үзгәрешен билгеләгән индивидуальлек, һәр авторның үз иҗат йөзе кыенлык белән генә юл яра. Бу күренеш исә еш кына язучыга сәяси мөһер сугу өчен нигез була. 20 нче еллар ахырында иҗат үзенчәлеге белән аерылып тора башлаган Ш. Маннурны бик тиз «акылга утырталар»: махсус рәвештә «маннурчылык» дигән термин уйлап табыла, ә шагыйрьнең үзен әдәби хәрәкәттән читләштерәләр.

Иҗади фикерләү бертөрлелекне кабул итми. Кызганыч ки, ул елларда әлеге гади, ләкин бик мөһим таләптән читкә китәләр. Әдәби әсәрнең автор тарафыннан шәхсән иҗат ителүен һәм аны укып кабул итү дә шәхсән булырга тиешлеген инкарь итеп, хакимият әдәбиятны да шактый бертөрле итүгә ирешә. Ә инде социалистик реализм иҗат методы бу күренешне билгеле бер дәрәҗәдә канунлаштыра. Шуңа да озак еллар дәвамында идеологиягә туры килгән әсәрләр пропагандалана, аларга берьяклы гына бәя бирелә. Сәясилек һәм социальлеккә өстенлек бирелү сурәтләү өслүбенең ярлылануына, тараюына китерә. Әсәрләрдә геройларның схематик рәвештә бик җиңел генә уңайга һәм тискәрегә бүленүе, еш кына, эчке ихтыяҗдан бигрәк, автор тарафыннан этеп-төртеп йөртелү, каршылыклы кеше образы булудан бигрәк, ниндидер социаль катлау вәкиле буларак сурәтләнүләре – шуның нәтиҗәсе иде.

Әдәби процесста гаять мөһим һәм шул ук вакытта катлаулы күренеш булган әдәби мирас, иҗат методлары, әсәр стиле һ.б. эстетик категорияләр күпсанлы мисалларда ачыклана, фәнни-теоретик яктан калыплана, гомуми, уртак үзенчәлекләре билеләнә. Татар әдәбиятында 20 нче елларның икенче яртысында – 30 нчы елларда өстенлек алган вульгар социологизмның табигатен ачу, аның сүз сәнгатенә хас эчке кануннарны инкарь итүен һәм шуның белән әдәбиятның үсеш-үзгәрешенә зур зыян китерүен билгеләргә мөмкинлек бирә. Галим 20–30 нчы еллардагы әдәби хәрәкәтне тикшерсә дә, аерым тенденцияләрнең, карашларның сиксәненче елларга кадәр дәвам итүен эзлекле күзәтә, сәбәпләрен билгели. Авторның әдәби-теоретик табышлары, нәтиҗәләре бүгенге әдәби

хәрәкәтне дә тулырак аңларга, аерым әдәби төрләр үсешен, тәнкыйтьнең торышын бәяләргә ярдәм итә.

Бу өлкәдәге тикшеренүләрен дәвам итеп, галим алдагы елларда «Әле без туганчы»[1], «Табигыйлеккә хилафлык»[2] дигән хезмәтләрен бастырып чыгара. Аларда әлеге чорларның катлаулы әдәби мохите тулы һәм системада күз алдына бастырыла. Әдәбияттагы эстетик кануннарның, гомумкешелек кыйммәтләренә хезмәт итүче асыл сыйфатларның вульгар социологизм таләпләренә бәйле юк ителүен ача һәм моның әдәби-эстетик эзләнүләргә никадәр зыян салуын конкрет мисалларда дәлилли. Ф. Галимуллин әдипләр иҗатын объектив бәяли һәм шуның белән Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, М. Фәйзи, Һ. Такташ, Х. Туфан кебек язучылар шәхесенә, мирасына яңача карарга, аларның иҗат концепциясендәге үзгәрешләрне күзәтергә мөмкинлек бирә. Бөтен җаны-тәне белән яңа җәмгыятькә хезмәт иткән һәм үзләре үк шуның корбаны булган шәхесләрнең фаҗигасен тирәнрәк аңлый башлыйсың. Күпсанлы мисалларда әйдәп баручы әдипләрнең тормыш материалын сайлап алуда, алым-чаралар, образлы тел куллануда үзләренә генә хас иҗат индивидуальлеген ача, шуның белән аларның әдәби процесстагы урынын, әһәмиятен билгели.

1920 еллар әдәбиятын өйрәнүгә бәйле нигез принципларның берсе булып, бу чорны гасыр башы белән күчемле бәйләнештә карау тора[3]. «Ике дәвер шигъриятен чагыштырып караганда, тирәннән, астан агып яткан чишмәләрне, ерганакларны барлаганда, – дип яза Т. Галиуллин, – сурәтле фикерләүнең бернинди сәясәткә, өстән иңдерелгән хакимияткә бирешми торган үз эчке кануннары, уртаклыклары барын сиземләве кыен түгел»[4]. Үткәндәге казанышларга нигезләнгән сүз сәнгате үзенең төрлелеге, эзләнүләре белән көчле: реализм һәм романтизм белән янәшә модернизм агымнары да калкып чыга, аеруча символизм һәм гыйсъянчылык агымнары көчәя. Әдәби-эстетик планда 20–30 нчы еллар әдәбиятында да Шәрык Ренессансында иркен кулланылган яктылык, нур образлары урын ала. Әдәбияттагы ленинизм һәм сталиниада юлбашчыларны кояш нурларына тиңләп сурәтли. Әмма аларның эстетик табигате зур үзгәреш кичерә: аллачыл-неоплатоник фикерләү халыкчан-фольклор сурәтләр белән алыштырыла һәм үзенең метафорик-символик байлыгын, киңлеген югалта[5]. Егерменче елларның икенче яртысында хакимиятнең әдәбиятка басымы көчәя. Ил күләмендә алып барылган

[1] *Галимуллин Ф.Г.* Әле без туганчы... Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 320 б.

[2] *Галимуллин Ф.Г.* Табигыйлеккә хилафлык. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 303 б.

[3] *Мусин Ф.М.* Вакыт үзе куя бәһане // Мәдәни җомга. 2004. 7 май.

[4] *Галиуллин Т.Н.* Шигърият баскычлары. Казан: Мәгариф, 2002. Б. 63.

[5] *Ганиева Р.К.* Философско-эстетические основы тюркских литератур средневековья // Татарская литература: традиции и взаимосвязи. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. С. 16.

сыйнфый дошман эзләү, дингә каршы көрәш, индустрияләштерү, соңрак колхозлаштыру хәрәкәтләренә ияреп, әдәбият система идеологиясе таләп иткәнне язуга күчә. Дөрес, әлеге гомумтенденция барлык әдипләр иҗатына да хас дию хакыйкатькә хилафлык китерү булыр. Аерым әдипләр иҗатында я субъектив эчтәлек буларак, я эзоп теле белән яңа җәмгыятьтәге кимчелекләрне тәнкыйтьләү, хөкүмәтнең аңлатуы кыен булган эш-гамәлләрен кире кагу күзәтелә.

1930 елларда татар әдәбияты каршылыклы үсеш кичерә. Бер яктан, соцреализм кануннарының мәҗбүриләп тагылуы, коточкыч эзәрлекләү-репрессияләр нәтиҗәсендә әдәбият хәлсезләнеп кала, почмакка куып кертелә. «Октябрь көннәреннән соң әхлак принциплары кискен үзгәрде, – дип яза Ф. Хатипов. – Хакимиятнең дин әһелләренә, руханиларга карата үтә кырыс, каты сәясәте матур әдәбиятка да килеп керде. Партия хакимияте әдәбиятның гуманистик кыйбласын киметте, бүтән якка борып җибәрде. Язучылар яңа җәмгыятьнең барлык күренешләрен сүзсез кабул итәргә һәм мактап сөйләргә бурычлы иде»[1]. Икенче яктан, халык авыз иҗатына, бай әдәби мираска нигезләнеп, милли традицияләр дәвамчанлыгы буларак язылган әсәрләр (Х. Туфанның «Ант»ы, Ә. Фәйзинең «Флейталар», М. Җәлилнең «Хат ташучы» һәм «Алтынчәч»е һ.б.) бүген дә әдәби-эстетик кыйммәтен югалтмаган хәлдә, шул чорның сәнгати табышлары булып торалар. Ул еллар әдәбиятының иң актив төре булган шигърияткә мөнәсәбәтле Т. Галиуллин болай дип яза: «Татар поэзиясе 30 нчы елларда катлаулы үсеш юлы үтте. Төрле сәбәпләр белән аңлатылган үсеш авырлыкларына карамастан, бу чор шигърияте чынбарлыкны, кешенең рухи дөньясын тасвирлау юлында зур уңышларга ирешә»[2]. Тагын шунысы да бар: әдәбият тарихын язучының гадел булуы, дөреслеккә хилафлык китермәве әсәрләрнең моңа кадәр читтә калган үзенчәлекләрен күрергә, аңларга мөмкинлек бирә. «Моңарчы без, әсәрләрне анализлаганда, күбесенчә уңай геройларның фикер сөрешенә генә игътибар итә килдек, тискәре яки каршылыклы персонажларның карашы ул кадәр әһәмиятле түгел, аларның сөйләменә нинди дә булса җитди мәгънә салынмый, аны тик кире кагу, бәхәсләшү өчен генә файдаланырга мөмкин дип саный идек. Ләкин хәзер әлеге әсәрләрне объектив яктан бәяләгәч, фикер беркадәр үзгәрә төште: чынында исә аларның сүзләрендә хәят дөреслеге кайчан тирәнрәк, төгәлрәк тә чагыла икән»[3]. Әнә шул яссылыкта Ф. Хатипов Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» (1928), Ф. Хөснинең «Җир тыңлый» (1931), Ш. Камалның «Матур туганда» (1936) кебек романнарын яңача бәяләүнең уңышлы үрнәген бирә һәм

[1] *Хатипов Ф.М.* Мөлкәтебезне барлаганда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. Б. 12.
[2] *Галиуллин Т.Н.* Утызынчы еллар татар шигърияте // Шигърият баскычлары. Казан: Мәгариф, 2002. Б. 125.
[3] *Хатипов Ф.М.* Мөлкәтебезне барлаганда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. Б. 20.

аларда колхозлашу хәрәкәтенең драматик каршылыклары яктыртылуын, әлеге күренешнең асылда мәҗбүрилеккә нигезләнүен, шуңа нисбәтле законсызлыкның көчәюен, әхлак дәрәҗәсенең түбәнәюен, кешенең кадере кимүен шактый тулы ачуларын билгеле. «Күмәкләштерү турындагы роман-повестьларда нәрсә уңай, нәрсә тискәре икәнен бүгенге аң яктылыгында бәяли белергә, тискәренең чыганагын анык төшендерергә бурычлыбыз. Сәяси репрессияне гаепләп тә мәдәни репрессиягә өндәү үзен акламас дип уйлыйм»[1], – дип яза ул.

1920–1930 еллар әдәбиятына шактый үзенчәлекле мөнәсәбәт-караш белән А. Яхинның программа һәм дәреслекләрендә очрашабыз. Галим-методист үзенең тикшеренүләрен структураль методка нигезләнеп алып бара[2]. Аның эзләнүләре, әсәрне бәяләү юллары төзелеш-структура аша эчтәлекне ачуга юнәлтелә. Әдәби текстның күптөрле өлеш-элементларының үзенчәлекле бәйләнешендә автор яклаган караш-фикерләр ачыла, дип саный ул. Совет чоры сүз сәнгатенең башлангычы булган гражданнар сугышы еллары әдәбиятында ике юнәлешне билгели: 1) әдәби мирасны дәвам итү, ягъни XX йөз башында үзәктә торган шәфкатьлелек, мәхәббәт, шәхес иреге мәсьәләләрен яклап чыгу (Г. Ибраһимовны «Яңа кешеләр»е, М. Гафуриның «Мин»е, «Сулган чәчәк»е, М. Фәйзинең «Асылъяр»ы һ.б. әсәрләр); 2) яңа идеологияне пропагандалау, ягъни көрәш темасына бәйле «Без» һәм «Алар» каршылыгын берьяклы ачу, үч хисенә өстенлек бирү һ.б. (Ф. Борнашның «Чәчәктән һәйкәл»е, М. Максудның «Изге көрәшкә»се һ.б. әсәрләр). А. Яхин 20 нче еллар әдәбиятында (1921–1930) әхлак һәм идеология эчтәлеге нигезендә ике юнәлеш дәвам итә дип саный: 1) әдәби мирасны дәвам итү; 2) социалистик үзгәртеп коруны алга сөрү. Соңгысына бәйле әдәбиятта мирасны кире кагу, яңа пролетариат мәдәнияте төзү хыялы, иске тормышны сүгеп, бүгенгене тулаем мактау һәм гражданнар сугышы әдәбиятындагы сыйнфый дошманнарга каршы көрәш идеясенең җәмгыятьнең тоткасы булган гаиләгә, әхлакка, дингә каршы көрәш булып дәвам итүе күзәтелә. 30 нчы елларда (1930–1941) совет

---

[1] *Хатипов Ф.М.* Мөлкәтебезне барлаганда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. Б. 22.

[2] Структураль метод әдәби әсәрнең структура–төзелешен өйрәнүне күздә тота. Ул формаль методтан үсеп чыга, ягъни аның сәнгать әсәрен алым буларак анализлавын эчтәлек һәм форманың бердәмлегенә нигезләнгән структур принципларны ачыклау белән алыштыра. XX гасырның утызынчы елларында нигез салынган әлеге метод башлангычында чех филологлары В. Матезиус һәм Я. Мукаржовский тора. Алдагы елларда структурализм Париж семиотика мәктәбе вәкилләре Р. Барт, К. Бреман, Ж. Женнет, Ю. Кристева һ.б. тарафыннан үстерелә. Россиядә бу юнәлештә эзләнүләр 1960 елларда башлана һәм аның башында Ю.М. Лотман тора. Тартус университетының ул җитәкләгән филологларына Мәскәү галимнәре (В.В. Иванов, В.Н. Топоров һ.б.) килеп кушыла. Структураль метод ике төп принципка таяна: берсе – системада элементлар түгел, ә аларның үзара мөнәсәбәте алда тору; икенчесе – методологик планда синхронлыкның диахронлыктан өстенлеген тану.

чоры әдәбиятындагы ике юнәлеш дәвам итә. Галим фикеренчә, берсендә хакыйкать, туган якка мәхәббәт, дуслык, шәфкатьлелек темаларын үзкыйммәткә ия матурлык итеп тасвирлау алга чыкса, икенчесендә партиягә тугрылык идеалының башка барлык идеаллардан өстенлеген таләп итү, шымчылык-әләкне гадәти күренеш итеп күрсәтү, кешеләрдә куркаклык, шикләнү сыйфатлары тәрбияләү төп максатлардан санала[1].

Күпгасырлык татар әдәбиятының үсеш-үзгәреш этапларын, аларга хас гомум тенденцияләрне, үзенчәлекләрне ачыклау белән бергә, аерым авторлар иҗатын яңартып өйрәнү мәсьәләсе дә көн тәртибенә килеп баса. Әлеге сорау шактый үзенчәлекле рәвештә әдәбият галиме А. Яхин төзегән дәреслек-хрестоматияләрдә чагылыш таба. Әдәби әсәрләрне өйрәнүнең структур һәм системалы анализ дип аталган ысулына нигезләнеп, ул күпсанлы әсәрләргә яңача бәя бирә. Галимнең анализ-нәтиҗәләре байтак әсәрләрнең моңарчы читтә калган катлам-хасиятләрен билгеләргә, фикер-карашларны тирәнәйтергә ярдәм итә. Й. Нигъмәтуллина мондый үзгәреш-яңалыкларны Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» һәм Ш. Камалның «Матур туганда» романнарына анализда күрә. Озак вакытлар дәвамында «Тирән тамырлар» исеменә бәйле совет власте дошманнары гына күздә тотылса, А. Яхин исә яңа совет власте бюрократизмының «тирән тамырларын» үзгә сюжет сызыгы буларак тикшерә. Ш. Камал романында сыйнфый көрәш темасына бәйле совет органнарының булдыксызлыгы, гади халык проблемаларына игътибарсызлыгы метафора булып килгән күренешләрдә, аеруча өлкә партия оешмасы җитәкчеләренең балык тоту вакыйгасында тулы ачыла[2]. Шуның белән бергә, А. Яхин бәяләмәләрендә Г. Ибраһимов, Һ. Такташ кебек әдипләр иҗатына бәхәсле, каршылыклы фикерләр дә урын алган. Мисал өчен, Р. Ганиева бер мәкаләсендә Г. Ибраһимовның «Көтүчеләр» хикәясе турында А. Яхин карашларын тәнкыйтьли һәм әсәрне бары тик романтик эстетикага нигезләнеп анализлау гына дөрес аңларга мөмкинлек бирә дигән нәтиҗәгә килә[3]. А. Яхинның Һ. Такташ иҗаты турындагы фикер-карашларында да субъективлык үзен нык сиздерә. Шагыйрь иҗатының икенче чорында «көрәшче кешенең идеал була алуына шикләнә башлый, халыкның бүгенге газабы белән вәгъдә ителгән матур киләчәк арасында бернинди дә бәйләнеш юклыгын сиземли»[4], дип күрсәтә һәм «Ай кебек без озак яшәмәбез...», «Болай... гади җыр гына», «Ак чәчәкләр» кебек шигырьләре аша Такташ илдәге хакимият тәртипләренә, хәерчелек, гадел-

[1] Татар әдәбияты тарихы (20–30 нчы еллар) / төз. А.Г. Яхин. Казан: КДУ, 2001. Б. 20.

[2] *Нигматуллина Ю.Г.* Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. Казань: Фэн, 1997. С. 166–167.

[3] *Ганиева Р.К.* Галимҗан Ибраһимовның «Көтүчеләр» хикәясе // Татарская литература: традиции, взаимосвязи. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. Б. 224–231.

[4] *Яхин А.Г.* Әдәбият: унберьеллык мәктәпнең 10 нчы сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия. Казан: Мәгариф, 1995. Б. 70.

сезлекләргә каршы чыга дигән нәтиҗәгә китерә[1]. Шул ук вакытта әдипнең яңа хакимиятне, аның эш-гамәлләрен яклаган, Ленин һәм партияне мактаган, кан түгүгә дә мәдхия укыган шигырьләре («Гасырлар һәм минутлар», «А, партия», «Провокатор», «Син дошманым минем», «Беспартийный», «Йомшак башлар» һ.б.) читтә калу, иҗатына берьяклы гына бәя бирүгә китерә. Ә бит чынында, Т. Галиуллин язганча, «олы шагыйрьнең фаҗигасе егерменче елларның икенче яртысыннан..., «иске, черек тормышны җимереп», «барабаннар белән» үз халкын юкка чыгару эшенә керешкән хакимиятне мактау юлына чыккач башлана»[2]. Талантлы шагыйрь үз заманы баласы, аның иҗатын чор каршылыкларына бәйләп өйрәнү сорала, шуңа да «Такташның олы, үзенчәлекле, горур таланты аклауга да, яклауга да мохтаҗ түгел. Аны үзеннән генә тормаган каршылыклары белән, бизәмичә, почмакларны әйләнеп үтмичә, шомартмыйча кабул итү лазем»[3].

Һ. Такташ иҗатын өйрәнүгә бәйле М. Хабетдинова фикер-карашлары да игътибарга лаек. «Һади Такташ иҗатында шәхес проблемасы» дигән фәнни тикшеренүе егерменче елларның иң күренекле шагыйре иҗатында шәхес концепциясенең эволюциясен ачуны максат итә. Хезмәттә әлеге проблема романтизм һәм реализмның фәлсәфи-эстетик сыйфатларына бәйле өйрәнелеп, Такташның милли менталитетка, чорның иҗтимагый күренешләренә нигезләнгән сәнгати фикерләү үзенчәлеген ачу буларак формалаша. Шагыйрь иҗатының аерым этапларына бәйле, аның мөселман һәм татар милли поэтик традицияләрендә тәрбияләнүе, героеның әкренләп ирекне чикләүче һәм күк, һәм җир законнарын кире кагып, дөньяны көч ярдәмендә үзгәртеп коруга килүе билгеләнә. Милли шагыйрь буларак формалашкан Такташ бераздан революцион чынбарлыкны да кабул итми. Аның герое гомумкешелек улы буларак бирелә. Гыйсъянчылык чорында Такташ үзен иҗатчы, үзгәртеп коручы шагыйрь буларак аңлауга килә. М. Хәбетдинова фикеренчә, иҗатының соңгы чорында Такташ киңкырлы, үз эшләре өчен җавап бирергә әзер тулы канлы шәхесләр булып ачылган геройлар галереясын бирә[4]. Шулай да авторның «Камил» пьесасындагы Камил образын да милли яшәү рәвешен үзенчә яклаучы дип аңлатуы бик тә бәхәсле.

Бөек Ватан сугышы шартларында әдәбиятның роле нык арта һәм аңа мәгълүм күләмдә иҗат иреге дә бирелә[5]. Й. Нигъмәтуллина язганча,

---

[1] *Яхин А.Г.* Әдәбият дәресләре: укытучылар, югары уку йортлары студентлары һәм укучылар өчен методик кулланма. Казан: Мәгариф, 2003. 159 б.

[2] *Галиуллин Т.Н.* Егерменче еллар татар шигърияте // Шигърият баскычлары. Казан: Мәгариф, 2002. Б. 83.

[3] Шунда ук. Б. 85.

[4] *Хабутдинова М.М.* Проблема личности в творчестве Хади Такташ: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1998. 19 с.

[5] *Галиуллин Т.Н.* Татар поэзиясе тарихын яңача өйрәнү мәсьәләләре // Шигърият баскычлары. Казан: Мәгариф, 2002. Б. 14.

сугыш елларында совет әдәбиятында гомумкешелек, гуманистик кыйммәтләрнең дәрәҗәсе күтәрелә[1]. Әдәбият алдында торган бурыч та уртак – Ватанның азатлыгын яклау һәм саклау. Татар әдипләре әлеге изге максатка тугры калып, дошманга каршы көрәштә «пуля һәм җыр»-дан файдалануның сокландыргыч үрнәкләрен бирәләр. Сугыш чоры сүз сәнгатенең югары казанышы буларак, М. Җәлил һәм Ф. Кәрим иҗатлары бөтен ил күләмендә танула. XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы әдәбият белемендә сугыш чоры әдәбиятына игътибар кимеми. Әдипләрнең китаплары даими чыгып тора, иҗатлары мәктәп һәм югары уку йортлары курсларында өйрәнелә. Тормышы үлемсезлек үрнәге булып танылган, иҗаты милли эчтәлек белән сугарылып, гомумкешелек идеалларына хезмәт итүче патриот-шагыйрь Муса Җәлил исеме аерым урын алып тора. Әдипнең 90,100, 110 еллык юбилейлары уңае белән үткәрелгән фәнни конференцияләр җыентыкларында, шагыйрь тормышын, көрәшен һәм иҗатын озак еллар дәвамында өйрәнеп килгән Р. Мостафин китапларында[2] мирасын яңача бәяләүнең уңышлы юллары тәкъдим ителә. Яңа җәмгыять идеалларына ышанып һәм омтылып иҗат иткән шагыйрь мирасы әдәбият һәм идеология мөнәсәбәтенә бәйле тикшерелә һәм аның чор рухына бәйле төрле этаплар аша үтеп тә бербөтен булып калуы раслана. Җәлилнең тормышын, көрәшен, иҗатын тарихи һәм эстетик планда өйрәнеп, аның бай традицияләрне үстерүе, сүз сәнгатенең форма һәм эчтәлегенә җитди яңалыклар алып килүе, гомумән, Шәхес һәм Шагыйрь буларак формалашуы һәм иҗатының дөньякүләм әһәмияте билгеләнә.

XX гасыр ахырында җәмгыятьтә барган үзгәрешләр йогынтысында үткән мирасыбыз, бигрәк тә совет чорында иҗат ителгән әсәрләр турында бәхәсләр бара, каршылыклы фикерләр яңгырый. М. Җәлил иҗаты да моннан читтә калмый. Аерым язмаларда, әдипнең коммунистик идеалны яклавын нигез итеп, әдәби мирасының әһәмиятен түбәнәйтү омтылышлары була. Әмма андый фикерләр киң җәмәгатьчелектә яклау тапмый. Шуның белән бергә, һәр яңа буын Җәлил иҗатын үзенчә кабул итүен, бәяләвен һәрдаим истә тотарга кирәк. Билгеле булганча, әдип иҗатына юл аның Шәхесен аңлау аша салына. «Палач балтасына башын тоткан» хәлдә шундый әсәрләр иҗат итә алган кешегә рухи көч, батырлык, чыдамлык каян килгән? Тормышы һәм иҗаты үлемсезлек символына әверелгән әдипнең таянычы нәрсә соң? Бу сорауга җавапны, беренче чиратта, тормышы, көрәше һәм иҗаты бирә. Барысының да нигезен исә

---

[1] *Нигматуллина Ю.Г.* Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. Казань: Фэн, 1997. С. 149.

[2] *Мустафин Р.А.* По следам оборванной песни. Изд. перераб. и доп. Казань: Татар. кн. изд-во, 2004. 399 с.; *Мустафин Р.А.* Силуэты: литературные портреты писателей Татарстана. Казань: Татар. кн. изд-во, 2006. 351 с.

үзенең халкы, туган җире белән тыгыз бәйләнеш тәшкил итә. Шагыйрь иҗатында күтәрелү-табышлар да, төшү-югалтулар да бар. Әмма ул бервакытта да халкының яшәү рәвешеннән, шатлык-куанычыннан, кайгыхәсрәтеннән аерылмый. Халык иҗатыннан илһамланып, данлы һәм фаҗигале тарихыннан көч-куәт, гыйбрәт алып яши. Лирик геройның уй-хисләре артында без Шагыйрьнең олы йөрәген күрәбез. Аның иленә тугрылыгы, җиңүгә ышанычы, ярату хисе, фашизмга нәфрәте шигъри юлларында калкып чыга.

М. Җәлил иҗатын бөтен тулылыгында аңлауга, кабул итүгә нисбәтле туган сорауларның тагын берсе булып, бер яктан, миллихалыкчан эчтәлекле булуын, икенче яктан, чорга бәйле социалистик реализм иҗат методына йөз тотып язылуын ачыклау тора. Миллилек төшенчәсе милли тел, эчтәлек белән тыгыз бәйләнгән. Автор әсәрендә халыкка хас милли сыйфатларны, яшәү рәвешен, теләк-омтылышларны сурәтләү аша милләтнең тарихи язмышына, бүгенгесе һәм киләчәгенә бәйле җитди проблемалар куя һәм тасвирланган вакыйга-күренешләр аша милли рух, милли психология тудыра. Әдәбиятның милли үзенчәлекләре гомумкешелек кыйммәтләре белән бәйләнеп, үзара керешеп, бер-берсен тулыландырып та килә. М. Җәлилнең эстетик идеалы матурлык һәм батырлык төшенчәләре белән тыгыз бәйле. Алар социалистик идеологиягә бәйле үстерелеп һәм баетылып килсә дә, Җәлил иҗатында төсмерләр байлыгы, төрле яңгырашлы булуы белән аерылып тора. Аның әсәрләрендәге эстетик матурлык, батырлык, романтик күтәренкелек, иленә-халкына тугрылык, үлем һәм яшәү фәлсәфәсенең төрле яссылыкларда бирелүе, олы мәхәббәткә омтылып, аннан көч алып яшәве һ.б. фикер-төшенчәләр гомумкешелек идеаллары булып яңгырый һәм шуның белән дөнья халыкларының күңелен яулый. Әмма Җәлил иҗаты бервакытта да милли җирлектән аерылмый. Әдипнең гаҗәеп бай сурәтле, аһәңле теле, фольклордан, мифологиядән килүче образлар, символлар, традицион шигырь калыплары, үзенчәлекле шигъри хатлар, аларда якыннарына мөрәҗәгать итү алымнары, иҗатында халыкның киләчәге өчен борчылуы, тирәнтен уйлануы һ.б. – болар барысы да әлеге бай мирасның милли асылын, халыкчан рухын билгели.

Сугыштан соңгы елларда татар әдәбиятында тема һәм жанр ягыннан җанлану күрәбез. Бөтен совет әдәбиятына хас уртак күренеш буларак, сугыш темасы алгы планга чыга. Г. Әпсәләмовның «Ак төннәр», «Алтын йолдыз», «Газинур», «Мәңгелек кеше», М. Әмирнең «Саф күңел», Ш. Маннурның «Муса», Н. Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында» повесть-романнары аеруча киң яңгыраш ала. Үз вакытында югары бәяләнгән әлеге һәм башка әсәрләргә хәзерге әдәби тәнкыйть башкачарак якын килә. Әлеге мәсьәләгә беренчеләрдән булып мөрәҗәгать иткән Ф. Миңнуллин сугыш темасын яктыртуда прозабызның төрле этаплар

аша үтүен билгели. Шуларның сыйфат-үзенчәлекләрен ачыклау аша аерым авторлар иҗатына килә. Тәнкыйтьче фикеренчә, хәрби-патриотик тема буенча гаять актив эшләгән Г. Әпсәләмов әсәрләрендә «күпмедер дәрәҗәдә татар совет прозасының егерменче еллардан, Г. Ибраһимов һәм Ш. Усмановлар иҗатыннан ук килә торган аерым сыйфатларын, әйтик, ашкынулы романтика, көрәш пафосы һәм революцион аскетизм кебек хасиятләрен тагы да үстерә, көчәйтә төшә. Совет кешеләренең батырлыгын сурәтләгәндә, ул еш кына әкият һәм легенда алымнарына мөрәҗәгать итә»[1]. Ф. Миңнуллин сугыш вакыйгалары сурәтләнешенә бәйле Г. Әпсәләмов әсәрләрен шактый соңрак язылган Х. Камалов романнары белән чагыштыра. Беренчесендә сугыш хәлләрен, солдат-офицерларны сурәтләгәндә шомарту, арттыру урын алса, икенче авторда «сугыш турында дөресен язу, сугышның кырыслыгын һәм рәхимсезлеген күрсәтү (...), кырыс буяулар белән язылган хакыйкать»[2] өстенлек итә. Тәнкыйтьче нәтиҗәсендә сугыш темасы чагылышына гына түгел, бәлки, гомумән, совет чоры әдәбиятын бәяләгәндә нигез булырга тиешле карашлар чагыла: «Сугышка ике төрле мөнәсәбәт, тормышка мөнәсәбәттә ике төрле концепция. Берсе – «социалистик реализм» принципларына нигезләнеп язылган норматив әдәбият үрнәге. Икенчесе – бернинди тыю һәм киртәләр белән санашмыйча язылган кырыс чынбарлык, хакыйкать, тормыш чынлыгы. Киләчәк, билгеле, икенче алым – тормыш чынлыгы ягында»[3]. Бу уңайдан төрле халыклар әдәбиятларында хәрби-патриотик тема белән артыграк мавыгуны да әйтеп үтәргә кирәк. А. Гыйләҗевнең «Күңелем серләре» дип аталган публицистик уйлануларында мондый юллар бар: «Без сугыш хәлләренә кайта-кайта ил халыкларының күзен чынлыктан, чынбарлыктан каплап тоттык. Бүтән бер юнәлештә дә алга китә алмаган, икътисади һәлакәткә килеп терәлгән ил бары тик сугыш мактанчыклыгы, шапырынулы буш коткы белән генә яши ала иде»[4].

Сугыш чоры әдәбиятының гаҗәеп матур үрнәген калдырган Ф. Кәрим иҗаты да махсус тикшерену объекты булды. Р. Сарчинның «Поэзия Фатиха Карима в историко-литературном контексте 1930-х – 1945 годов»[5] хезмәтендә әдипнең тормышын һәм иҗатын ул яшәп иҗат иткән чор контекстында өйрәнеп бәяләү омтылыш ясала. Шагыйрь иҗатының эволюциясе рус һәм татар әдипләре белән диалогик бәйләнештә өйрәнелү, Ф. Кәрим иҗатын үзенчәлекле әдәби дөнья итеп

[1] *Миңнуллин Ф.М.* Безнең прозада сугыш темасы // Балта явызлар кулында. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. Б. 98–99.

[2] Шунда ук. Б. 101.

[3] Шунда ук. Б. 103.

[4] *Гыйләҗев А.* Күңелем серләре (Куен дәфтәрләреннән) // Казан утлары. 2000. № 11. Б. 15.

[5] *Сарчин Р.Ш.* Поэзия Фатиха Карима в историко-литературном контексте 1930-х – 1945 годов. Казань: Бриг, 2015. 270 с.

күзаллау мөмкинлеге бирә. Хезмәт авторы шагыйрь тормышындагы «ак таплар»ны ачыклауга да килә. Аның төрмә-лагерьлар белән бәйле тормышын ачыклау да шигърияттендәге тема-мотивларны, аларның урынын билгеләүгә китерә.

1960 еллардан соңгы әдәбият «Хрущев җепшеклеге»нә бәйле җәмгыятьтәге үзгәрешләр дулкынында үсеш-үзгәреш кичерә. Әдәби процесс катлаулы, каршылыклы булуы белән характерлана. Бу еллар сүз сәнгатендәге төп тенденцияләр, табыш-югалтулар «Татар әдәбияты тарихы»ның 6 нчы томындагы Ф. Мусин мәкаләсендә шактый тулы урын алган[1]. Ә инде әлеге авторның «Вакыт үзе куя бәһане» язмасында әлеге чорга хас сыйфат-үзенчәлекләр тагы да конкретлаштырыла. «Үзгәрүчән заман йогынтысында әдәбиятыбызда бу чорда ике мөһим идея-эстетик юнәлеш барлыкка килә»[2], – дип яза ул. Беренче юнәлеш, рәсми характерда булып, хакимият идеологиясенә нигезләнә. Бу төр әсәрләрдә төрле төзелешләрне мактау, җитәкчеләргә, партиягә мәдхия уку, интернационализм идеяләрен хуплыйбыз дип милләтләрнең ассимиляцияләнүен яклау һ.б. үзәктә тора. «Торгынлык чорында безнең әдәбият халыкның рухи байлыгы темасын, милли мәсьәләләрне читләтебрәк үтәргә тырышты, проблеманы иң дөрес, заманча хәл итү – аны кузгатмау дип санады»[3]. Икенче юнәлеш исә милләт язмышы белән тыгыз бәйләнештә булып, күпгасырлык традицияләргә нигезләнә, гомумкешелек кыйммәтләрен яклый, кеше яшәешен туган җиренә, халкына, гореф-гадәтләренә, рухи-мәдәни мираска мөнәсәбәтле тасвирлый. Н. Исәнбәт, Г. Бәширов, Ә. Еники. С. Баттал, Ф. Хөсни, Н. Фәттах, И. Юзеев, Х. Туфан, С. Хәким, Х. Вахит, М. Мәһдиев, А. Гыйләҗев, Ш. Хөсәенов, Т. Миңнуллин һ.б.ның әсәрләрен без бүген дә кыйммәтле ядкәр буларак кабул итәбез. Гомумән, 60–80 нче еллар әдәбиятындагы төп казанышларыбыз әлеге икенче юнәлеш белән бәйле икәнен танырга тиешбез. Шуңа күрә әлеге чор әдәбиятын тулаем характерлаганда, аның күптөрлелеген, күпкырлылыгын истә тоткан хәлдә, «үз сыйфат югарылыгында»[4] калуын, шул нигездә яңарыш юлына басуын билгеләп үтәргә кирәк.

Совет чоры татар әдәбиятын, шул исәптән 60–80 нче елларны өйрәнү төрле юнәлешләрдә барып, берсе гомуми характерда булуы белән үзенчәлекле. 1960–1990 еллар татар әдәбияты тарихы буенча алып барылган эзләнүләрнең нәтиҗәсе буларак «Татар әдәбияты тарихы»ның 6 нчы

[1] *Мусин Ф.М.* Әдәбият фәне һәм тәнкыйть // Татар әдәбияты тарихы: алты томда: VI т.: 60–90 еллар әдәбияты. Казан: Раннур, 2001. Б. 458–479.

[2] *Мусин Ф.М.* Вакыт үзе куя бәһане // Мәдәни җомга. 2004. 7 май.

[3] *Хатипов Ф.М.* Рәшәле дөнья (Р. Сверигин белән берлектә) // Мөлкәтебезне барлаганда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. Б. 50.

[4] *Галиуллин Т.Н.* Татар поэзиясе тарихын яңача өйрәнү мәсьәләләре // Шигърият баскычлары. Казан: Мәгариф, 2002. Б. 14.

томы[1] басылып чыга. Күпсанлы авторлар тырышлыгы белән сүз сәнгатенең гаять каршылыклы һәм мөһим чоры билгеле бер концептуаль нигезгә корылып һәм максатчан эзлеклелектә тикшереп бәяләнә. Илнең әлеге чоры иҗтимагый-социаль үсештә торгынлык белән бәяләнә. Чит илләр белән ике арада «тимер челтәр» корылу халык тормышының барлык тармакларына, шул исәптән мәдәният үсешенә дә тискәре йогынты ясый. Шулай да мәдәни тормыш үзенең җанлылыгын киметми. 1960 еллар башында күзәтелгән җитди сыйфат үзгәрешләре алдагы елларда да әдәби хәрәкәтне сугарып тора. Авторлар коллективы алдында, иҗтимагый тормыш белән тыгыз бәйлелектә, сүз сәнгате үсешенең төп юнәлеш-тенденцияләрен ачу, әйдәп баручы әдипләр иҗатына объектив бәя бирү бурычы тора. Әйтергә кирәк, максатка, нигездә, ирешелә. Безнең карашыбызча, хезмәттәге төп табыш-яңалыклар түбәндәгеләр белән билгеләнә: 1) идеологик кысалардан арындырып, чор сүз сәнгатенең эзлекле, системалы, дәвамлыклы тарихын укучы күз алдына бастыру; 2) әлеге дәвер әдәбияты үсешенең ике юнәлешен аерып чыгару һәм рәсми юнәлешне яклаган әсәрләрдә һәртөр карарларның үтәлеше, төзелешләр тавышы, җыңү рапортлары шаукымы өстенлек итүе билгеләнсә, халыкчан-милли юнәлешкә караган әсәрләрдә халык язмышы, тел сакланышы, татар авылларының киләчәге, буыннар арасындагы рухи бәйләнеш, табигатьне саклау һ.б. мәсьәләләр калку итеп куелуын күрсәтү; 3) әдәби барышны әйдәп баручы, иҗатлары белән татар әдәбиятының торышын билгеләүче, еш кына яңа сүз әйтүче әдипләр мирасына тулы, эзлекле бәя бирү, аларның әдәбият тарихындагы урынын билгеләү омтылышы ясалу; 4) социалистик системага, аның идеологиясенә караш-мөнәсәбәт үзгәргән вакытта, иҗатларында шул чор чынбарлыгын, халыкның ышанычын, хыял-омтылышын чагылдырган әдипләрне «агарту» яисә «каралту» юлыннан китмичә, бер яктан, заман рухы чагылышы, икенче яктан, гомумкешелек кыйммәтләре якланышына нисбәтле рәвештә бәяләү; 5) дәвер әдәбиятын үткән чорлар, бигрәк тә XX гасыр башы сүз сәнгатендәге табышлар белән күчемле бәйләнештә, ягъни традицияләр дәвамчанлыгында тикшерү һәм шулар аша яңачалыкларны билгеләү.

Шуның белән бергә, әлеге гаять кирәкле һәм җитди хезмәтне тагы да камилләштерү мөмкинлекләре булуын күрсәтеп үтү кирәк. Аларның кайберләре алтынчы том басылып чыгу уңае белән оештырылган фикер алышуда әйтелеп, «Казан утлары» журналында басылып чыга. Тәкъдим-фикерләрне гомумиләштереп атау белән чикләнәбез: а) хезмәтнең концепциясе чор әдәбиятын һәм әдипләр иҗатын хронологик эзлеклелектә өйрәнүне күздә тота, шуңа бәйле әдәби барышта өстенлек иткән юнәлеш-агымнар, ысул-стильләр мәсьәләсе читтәрәк кала; шуны

[1] Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. 6 том. Казан: Раннур, 2001. 544 б.

ук аерым әдипләр иҗаты чагылыш тапкан язма-бәяләмәләрдә дә күрәбез; ә) фәнни мәкаләләрдә тематик һәм жанр төрлелеген, шуның төрле образ-сурәтләрдә чагылышын билгеләү белән мавыгу сизелә. Шул ук вакытта, әдип иҗатында өстенлек иткән әдәби юнәлешнең нигез принциплары, асылы, яшәешнең күптөрлелеген аңларга омтылуда үзенчәлекле агымнар рәвешендәге эзләнүләр читтәрәк кала. Ул чор татар әдәбиятында өстенлек иткән реализмның сыйфатлары күпчелек әдипләрдә охшаш булып чыккан, ягъни, эчке катламнары ачылмау аркасында, сәнгати фикерләүдәге табышлары гомуми планда гына билгеләнә; романтик сурәтлелеккә йөз тоткан әдипләрнең төрлелеген күрәбез. Аларның уртак һәм аермалы якларын билгеләү белән бергә, романтизмның чорга, яшәү рәвешенә бәйле яңа сыйфатларын аерып чыгару да мөһим мәсьәлә булып кала. Ә инде дөнья әдәбиятында кабул ителгән модернизм һәм постмодернизм юнәлешләренә хас билгеләр урын алган әсәрләрне бәяләү үрнәген Й. Нигъмәтуллина «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве» китабында И. Юзеев, Р. Фәйзуллин, Р. Гаташ иҗатларына нисбәтле тәкъдим итә; б) чорга һәм әдип иҗатына бәя бирүдә аналитик фикерләүнең җитенкерәмәве сизелә. Аерым әсәрләрдәге вакыйга-күренешләр артык гади аңлатыла.

Гомумән, билгеле бер җитешсезлекләрдән азат булмаса да, әдәбият тарихының яңа томы басылып чыгу – үзе үк зур казаныш. Нинди генә караштa булсак та, хезмәттә зур бер чорның әдәби хәрәкәт үзенчәлекләре билгеләнеп, дистәгә якын әдип иҗатына монографик планда бәя бирелә, илледән артыгының аерым әсәрләренә теге яки бу дәрәҗәдә күзәтү ясала. Монографиядә урын алган фикерләрне баету, тулыландыру әдәбият белеме алдындагы бурычларның берсе булып тора.

Й. Нигъмәтуллина «Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур» хезмәтендә татар сүз сәнгатенең күпгасырлык тарихын Шәрык һәм Гареб мәдәниятләре синтезында, аннан да бигрәк рус әдәбияты белән чагыштырма планда өйрәнә[1]. Аның тикшеренү өлкәсе гаять катлаулы: татар һәм рус әдәбиятларындагы типологик охшашлыкны «цивилизация тибы», «мәдәният тибы», «сәнгати фикерләү тибы» төшенчәләре аша ачу. Автор әдәбиятлар үсешендәге төрле этап-чорларны эзлекле һәм тыгыз бәйләнештә тикшерә һәм һәрберсендә, бик уңышлы сайланган әсәрләргә нигезләнеп, шул чор өчен хас булган мәдәни билге-сыйфатларны аерып чыгара. Хезмәтнең тагын бер яңалыгы шунда, мәдәният тибының алышынып торуын, аның цивилизация үсеш-үзгәрешенә бәйле булуын һәм аларның әдәби процесс үзенчәлекләрендә чагылуын дәлилли.

[1] *Нигматуллина Ю.Г.* Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. Казань: Фэн, 1997. 190 с.

Бай теоретик база, әдәбиятка үзенчәлекле шәхси караш бер-берсеннән нык аерылып торган әдәбиятлардагы охшаш, уртак законча-лыкларны табуга китерә һәм әдәбият үсешенең бердәм картинасын күз алдына бастыра. Хезмәт куелган проблема кысаларында тулы, тәмамлан-ган тикшеренү булып тора, шуның белән бергә, ул киләчәк эзләнүләргә юл салып калдыруы белән дә әһәмиятле. Кембридж университеты про-фессоры Эндрю Рейнольдс язганча, авторның зур табышы булып мәдә-нияттә, цивилизациядә һәм әдәби фикерләүдә гомумкешелек, милли һәм шәхсән сыйфат-билгеләрне ачыклауның нигез шартларын эшләү тора[1].

Й. Нигъмәтуллина татар әдәбияты тарихын фәнни-теоретик планда һәм синхрон яссылыкта тикшерүчеләрнең берсе булып таныла. Аның җитди бәхәсләргә юл ачкан «Запоздалый модернизм» в татарской литера-туре и изобразительном искусстве» китабы[2] җитди фәнни тикшеренүләре нәтиҗәсе булып тора. Галимә фәлсәфилеккә йөз тоткан шигърияттә Тынлык темасының төрле сурәт-формаларда, вариантларда урын алуын билгели һәм поэзиядәге үзгәрешләр аеруча тулы чагылыш тапкан бер-ничә шагыйрь иҗатына тукталa. И. Юзеев иҗатында, аның фикеренчә, универсаль бәйләнешкә кергән тормыш күренешләренә бәйле үткән, бүгенге һәм киләчәк Вакытның биргәлеген аңлау калкып чыга. Шагыйрь аеруча фәлсәфи мәгънәле символларга теләп мөрәҗәгать итә, әмма алар социаль-психологик аспектта ачыла. Шигырь-поэмаларында фәлсәфи һәм психологик эчтәлекнең үзара кушылуы һәм тәэсир итешүе билге-сезлек, каушау, куркып көтү атмосферасы тудыра һәм шул ук вакытта «уяныгыз» дигән катгый чакыру авазы булып та ишетелә. И. Юзеев иҗа-тында өстенлек иткән әдәби юнәлешне һәм стильне Й. Нигъмәтуллина болай билгели: «Образларның шартлылыгы һәм масштабларының киң-леге, көнкүреш тәгәллегеннән баш тарту, интонацион төзелешнең өстен-лекле бер доминантага буйсындырылуы – болар барысы да романтик стиль билгеләре»[3]. Ә менә тормыш-чынбарлыкны ачык күренеп тор-ган романтик тойгылар аша чагылдыручы Р. Гаташны иҗатында рухи башлангычтан килүче һәм кешенең эчке дөньясын бөтен тулылыгында ача алучы дип саный. Аның шигъриятендәге төп мотивны «дөньяның, Кешенең һәм табигатьнең матурлыгы, байлыгы алдында шатланып, илһамланып соклану интонациясе» рәвешендә ача. И. Юзеевның капма-каршы образларның төгәллеге һәм стиль ачыклыгына, сурәтләү чарала-рын куллануцагы җыйнаклык белән характерлы шигырьләреннән аер-малы буларак, Р. Гаташта хисләр өермәсе өстенлек итә.

[1] *Рейнольдс Э.* Научный труд татарского ученого в восприятии английского слависта // Научный Татарстан. 1998. № 2. С. 94.

[2] *Нигматуллина Ю.Г.* «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобрази-тельном искусстве. Казань: Фэн, 2002. 167 с.

[3] Шунда ук. Б. 117.

Галимә татар шигъриятендәге эзләнүләр аеруча тулы чагылыш тапкан әдип дип Р. Фәйзуллин иҗатын саный. Күпсанлы шигырь-поэмаларына нигезләнеп, үзенчәлекләрен билгеләүгә килә. Башлангыч чор иҗатында туган якны ярату хисләре өстенлек иткән шагыйрьнең тәҗрибәсе арту белән әдәби күзаллавы киңәя – Җир шарын иңли башлый. Ул кеше яшәешенең мәгънәсен, аны Галәмнең гармониясенә һәм матурлыгына якынайту юлларын эзләүгә чыга. Әдип дөнья бердәмлеген капма-каршылыклар бердәмлеге буларак кабул итә, шул ук вакытта алар бары күчерелмә символик мәгънәдә генә каршылыкта торучы төрле күренешләр бәйләнеше булып та ачыла. Шунысы игътибарга лаек, әлеге бердәмлек идеясе һәм космос, һәм җир образларында чагыла. Тормыш фәлсәфәсенә нигезле, аерым шигырьләрендә фаҗигалелек мотивы экзистенциональ мәгънә ала (кеше табигать тарафыннан ялгызлыкка дучар ителгән). Р. Фәйзуллин шигырьләре еш кына табигать дөньясыннан алынган ассоциатив образларның параллель рәте буларак төзелә һәм ул лирик герой халәтен бирү белән тәмамлана. Бу исә хис һәм фикер шагыйрендә фикер өстенлек итүдә, төрле метафоралар аша чагылып, укучыда көчле эмоцияләр тудыруда чагыла. Шуңа да «интеллектуаль шагыйрь» буларак бәяләнә. Шагыйрь иҗатында Галәм объективлыкның иң бөек символы буларак урын ала һәм ул шагыйрьнең төп темасы булган хакыйкатьне, яшәү мәгънәсен эзләү белән тыгыз бәйләнгән.

Яшәешне фәлсәфи аңларга омтылыш әлеге өч шагыйрьне берләштерсә дә, дип нәтиҗә ясый галимә, – Кеше һәм Тынлык мөнәсәбәтендә һәрберсенең өстенлек биргән мотивы бар: И. Юзеевта – Кеше Акылы; Р. Гаташта – Ярату хисе; Р. Фәйзуллинда – Кеше һәм Галәм[1].

Й. Нигъмәтуллина прозада барган эзләнүләрнең бер төрен үзенчәлекле алым-формалар ярдәмендә кешенең ике төрле асылын, ике ягын ачуда күрә. Шактый бәхәсләр уяткан «Албастылар»ны (Г. Гыйльманов) ул кеше күңелендәге яхшы һәм начар башлангычлар көрәше турындагы әсәр дип бәяли. Хикәяләү барышында «сихерле» урман тормышы белән авыл тормышы арасында ассоциацияләр туа, реаль һәм фантастик дөнья арасында чик юыла. Гомумән, хәзерге татар прозасында традицион темаларга яңача якын килү, яңа стиль һәм жанр формасы өлкәсендәге эзләнүләр хикмәтле вакыйгадагы фәлсәфилекне һәм автор позициясенең укучы белән фикер алышуга нигезләнүен үзара бәйләргә мөмкинлек бирә.

Драматургиядә барган модернистик эзләнүләрне Й. Нигъмәтуллина Аманулланың «Җәйге кырау», Т. Миңнуллинның «Хушыгыз», З. Хәкимнең «Җүләрләр йорты» пьесаларына бәйле рәвештә тикшерә. Хәзерге заман кешесенең рухи дөньясына метафора булып торган «Җәйге кырау» пьесасында драматик һәм прозаик әсәрләргә хас жанр

[1] Шунда ук. Б. 127–134.

билгеләре үзара кушылып китүе ачыклана. Тормыш концепциясенең модернистик төсмер алуы, автор фикеренчә, тормышта билгеле вакыйгаларның кабатланып килүенә нигезләнә. Соңгысы аеруча яшәү һәм үлем, яхшылык һәм явызлык, батырлык һәм куркаклык, бөеклек һәм түбәнлек кебек күренешләрнең үзара бәйләнеше буларак, модернистик тенденциянең стиле белән реалистик әсәр кысаларында «өлгерүе» билгеләнә. Ә инде Т. Миңнуллинның «Хушыгыз», З. Хәкимнең «Җүләрләр йорты», Аманулланың «Әлепле артистлары» пьесаларында «уен»ның, бер яктан, әсәрләрнең темасы булып торуын, икенче яктан, тормышны күпертеп сурәтләүгә нигез әдәби алым рәвешендә урын алуы дәлилләнә[1].

Д. Заһидуллинаның «1960–80 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр»[2] монографиясендә әлеге чор сүз сәнгате яңа концепциягә нигезләнеп тикшерелә. Автор әдәбиятка йогынты ясаган иҗтимагый, социаль һәм мәдәни факторларны өйрәнеп, татар әдәбиятының үз эчендә барган закончалыкларга бәйле, аның әкренләп сыйфат үзгәрешләренә килүен билгели. Аның үзенчәлеге шунда ки, «милли әдәбиятта авнгард традицион әсәрләр белән янәшә яши». Шуңа да әдәбият фәнендә алар бергә каралып килделәр. Д. Заһидуллина карашынча, «татар шигъриятендә авангард бербөтен юнәлеш яки агым хасил итми, бәлки пафос үзенчәлеге, лирик герой бирелеше, форма өлкәләрендә төрлелеге белән аерылып торган күренешләр рәвешендә яши». Бу елларда авангард эзләнүләр башлап шигърияттә урын ала, аннары башка төрләргә үтеп керә. Үзгәреш әсәрләрнең формасында да, эстетик табигатендә дә күзәтелә. Нәтиҗәдә «1960–80 еллар татар шигъриятен әдәби кыйбла үзгәрү, милли нигезләргә әйләнеп кайту вакыты дип бәяләргә мөмкин»,[3] дип яза Д. Заһидуллина. Авангард эзләнүләр һәм аның милли шигърияткә йогынтысы, шагыйрьләр иҗатында төрле планда һәм яссылыкта чагылыш үзенчәлекләре Р. Фәйзуллин, Г. Афзал, И. Юзеев, Р. Әхмәтҗанов, Р. Гаташ, Ш. Анак, Р. Харис, М. Әгъләмов, Зөлфәт иҗатына нисбәтле тикшереп бәяләнә. Хезмәтнең икенче бүлегендә 1960–1980 елларда татар прозасы үсеше өйрәнелеп, автор бу чор «татар әдәбиятының милли нигезләргә кайтуы, XX гасыр башы әдәбияты белән ике арада күпер булдыруы, өр-яңа алымнарны беренче планга этәрүе эпик әсәрләрдә аеруча ачык»[4] күренде дип саный. Шул планда татар позасының әдәби юнәлешләргә мөнәсәбәте, чынбарлыкны сурәтләүдә яңа юллар эзләве Ә. Еники, Г. Әпсәләмов, Г. Бәширов, Г. Ахунов,

[1] *Нигматуллина Ю.Г.* «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. Казань: Фэн, 2002. С. 144–156.

[2] *Заһидуллина Д.Ф.* 1960–80 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 383 б.

[3] Шунда ук. Б. 29.

[4] Шунда ук, Б. 157.

Н. Фәттах, Х. Сарьян, Ш. Хөсәенов, Ә. Баян, М. Юныс, А. Гыйләҗев, М. Галиев иҗатлары аша бәяләнә.

Әдәбият тарихының мөһим проблемалары буларак сатирик поэзия һәм автобиографик проза үсеше[1], әдипләрнең иҗат лабораториясе[2], әдәбиятта кеше һәм табигать бәйләнеше[3], XX гасырның 80–90 нчы елларында повесть жанры[4], сугыштан соңгы елларда татар романы[5], детектив жанр[6], XX гасырның икенче яртысында «лагерь прозасы» эволюциясе[7] һ.б. махсус өйрәнү объекты булып тора.

Әдәбият фәнендәге икенче бер юнәлеш әдәби төрләрне һәм жанрларны тарихи-мәдәни аспектта тикшерү белән бәйле булып, Г. Гыйльманның «Заман сүз сорый» (1991), Ф.Зөлкарнәевнең «Чакма чакмый ут чыкмый» (1991), Н. Юзиевнең «Сәнгатьчә матурлык һәм осталык» (1995), Н. Хисамовның «Хәтер сагында» (2004), Т. Галиуллинның «Шигъръият баскычлары» (2002), «Шәхесне гасырлар тудыра» (2003), «Әдәбият – хәтер хәзинәсе» (2008), «Яктылык» (2011), Х. Әшрәфҗановның «Язучы һәм тарих (Татар тарихи романы үсешенә бер караш)» (1998), Ф. Мусинның «Татар әдәбиятының хәзерге этаптагы үсеше мәсьәләләре» (1998), Н. Ханзафаровның «Татарская комедия» (1996), А. Әхмәдуллинның «Офыклар киңәйгәндә» (2002), «Күңелләрне уятыр» (2007), А. Саттарованың «Современная татарская драматургия 1985–2000 гг.» (2003), Ә. Исмәгыйлевның «Комедиянең жанр үзенчәлеге» (2005), А. Әхмәдуллинның «Татарская драматургия» (2012) һ.б. хезмәтләрдә чагылыш таба.

Х.Әшрафҗановның «Язучы һәм тарих (Татар тарихи романы үсешенә бер караш» хезмәте[8] тарихи роман жанрын тарихи һәм чагыштырма-типологик планда өйрәнүе белән әһәмиятле. Автор татар әдәбият белемендә беренчеләрдән булып әлеге жанрның ерак тамыр-

[1] *Гайнуллина Г.Р.* XX гасырның 60–70 нче елларында татар автобиографик прозасы үсеше: филол. фән. канд....дис.. Казан, 2001. 163 б.

[2] *Фатхрахманов Р.Г.* Творческая лаборатория прозаика (на материале произведений А. Еники, М. Магдеева, А. Гилязова, Н. Фаттаха и др.): автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2000. 32 с.

[3] *Гиниятуллина А.Ф.* Проблема «человек и природа» в татарской прозе 60–90-х годов XX века: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2006. 26 с.

[4] *Фаттахов И.Ф.* Татарская повесть 80–90-х гг. XX века (эпоха и образ автора): автореф. дис. ... канд.филол. наук. Казань, 2002. 29 с.

[5] *Кашапова А.М.* Романтические культы в послевоенных татарских романах (1945–1960 гг.): препринт. Уфа: РИО БашГУ, 2005. 40 с.; *Кашапова А.М.* Послевоенные татарские романы: проблемы творческого метода (1945–1960 гг.): автореф. дис. …канд. филол. наук. Уфа, 2005. 23 с.

[6] *Галиуллин Р.Р.* Эволюция детектива в татарской литературе: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2007. 23 с.

[7] *Габидуллин Р.Р.* Татарская «лагерьная проза» во второй половине XX века: жанровая типология и поэтика: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2009. 24 с.

[8] *Әшрәфҗанов Х.Ә.* Тарихка әдәби сәяхәт. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. 288 б.

ларын тикшерә, халык тормышы белән бәйле вакыйгаларның әдәби-эстетик чагылыш үзенчәлекләрен ача. «Тарихилык» төшенчәсен әдәбият тарихы белән тыгыз бәйләнештә өйрәнеп, үсеш-үзгәреш эволюциясен, ягъни тарихи роман жанрының XX йөз дәвамында күзәтелгән төп этапларын, аларга хас сыйфат-билгеләрне аерып чыгара.

Н. Ханзафаровның «Татарская комедия» монографиясе[1] драматургиянең бер жанрын формалашу һәм үсү үзенчәлекләренә нисбәтле тикшерү белән югары бәя ала. Хезмәтнең кыйммәте һәм яңалыгы түбәндәгеләр белән билгеләнә: 1) татар комедиясенең башлангычында мифологиягә, фольклорга барып тоташкан йола-уеннар торып, аның халыкның уенкөлү культурасына барып тоташуын ачу; 2) әлеге жанр формалашуына, бер яктан, татар әдәбиятының эчке закончалыкларына нисбәтле үсеше, икенче яктан, иҗтимагый һәм мәдәни шартлар, халыкның рухи тормышындагы үзгәрешләр, өченче яктан, Шәрык һәм рус әдәби-эстетик фикере көчле йогынты ясавын дәлилләү; 3) күпгасырлык көлү культурасы, төрле халыкларның көлү культурасы тәҗрибәсен үзенә туплау аша, милли эчтәлекле комедиянең үсешенә, бай жанр формаларына юл ачуын билгеләү; 4) XX гасыр дәвамында татар комедиясенең төрле чор-этаплар аша үтеп, халыкның рухи ихтыяҗларына җавап бирүен, жанр төрлелеген, конфликт характерын, милли образлар бирелешен, сурәт чаралары байлыгын күрсәтү; 5) әлеге жанрның үсеш-үзгәрешен тәэмин итүче авторларның иҗат үзенчәлекләрен ачуы; 6) комедия жанрына кагылышлы тикшеренүләрнең перспективаларын билгеләве һ.б.

Әдәбият тарихын, аның аеруча катлаулы булган шигърият төрен дәвамлы өйрәнеп, дистәләрчә монография һәм җыентыкларда чагылдырып килгән галимнәрнең берсе Т. Галиуллинның «Шигърият баскычлары», «Шәхесне гасырлар тудыра», «Әдәбият – хәтер хәзинәсе», «Яктылык» китаплары[2] – XX гасыр татар шигъриятен «бөтенкешелеккә хас шәфкатьле, игелекле кыйммәтләргә» йөз тотып һәм миллилек, тарихилык, бөтенлек принципларына нигезләнгән концепция аша өйрәнүнең гаҗәеп уңышлы үрнәге. Алар әдәби-эстетик планда бер-берсен тулыландыра, баета барган мәкаләләрдән торган монографияләр буларак кабул ителә. «Шигърият баскычлары»ның фәнни-теоретик нигезен аңларга ярдәм иткән «Милли үзаң һәм шигърият», «Татар поэзиясе тарихын яңача өйрәнү мәсьәләләре» кебек язмаларда шигъриятнең милли һәм гомумкешелек кыйммәтләре белән бәйлелеге, сүз сәнгате буларак кешедә милли үзаң тәрбияләү функциясе һәм рухи-мәдәни мирасны

---

[1] *Ханзафаров Н.Г.* Татарская комедия. Казань: Фэн, 1996. 189 с.

[2] *Галиуллин Т.Н.* Шигърият баскычлары: Әдәби-тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Мәгариф, 2002. 231 б.; *Галиуллин Т.Н.* Шәхесне гасырлар тудыра. Казан: Татар. кит. нәшр. 2003. 192 б.; *Галиуллин Т.Н.* Әдәбият – хәтер хәзинәсе. Казан: Мәгариф, 2008. 231 б.; *Галиуллин Т.Н.* Яктылык: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 319 б.

традицияләр яктылыгында өйрәнү принциплары билгеләнә. Озак еллар калыплашкан фикерләрдән арыну, карашлар төрлелегенә омтылу аша һәм әсәрләргә сәяси күзлектән чыгып түгел, бәлки әдәби-эстетик якын килү, төрле чорлар мирасын рухи уртаклык, эчке кануннар берлегендә өйрәнү, шулай ук дини карашлар белән тыгыз бәйлелектә тикшерү генә әдәбиятны бөтен тулылыгында ачу мөмкинлеге бирә, дип саный автор.

Галим-тәнкыйтьче кайсы чор шигъриятен генә өйрәнмәсен, таянычнигез, билгеле бер дәрәҗәдә камиллек үрнәге итеп XX гасыр башы поэзиясенең таҗы булган бөек Тукай иҗатын ала. Хезмәтләрдә урын алган «Тукай һәм XX гасыр татар шигърияте», «Тукай шигырьләрен яңадан укыганда» кебек язмаларның уртак нигезе шуннан гыйбарәт – халык гаме белән яшәгән Тукайның әдәби мирасы киң һәм тирән, аны объектив, бөтен тулылыгында, шулай ук әдәби-эстетик һәм әхлакый-фәлсәфи планда өйрәнү заман таләбе булып тора. Шуңа да Тукай шигырьләренә яңа чор биеклегеннән бирелгән бәя рецептив эстетикага нигезләнгән шәрехләү үрнәге буларак кызыксыну уята.

Татар шигъриятенең 1917 елдан соңгы үсеш мәсьәләләре – Т. Галиуллинның төп өйрәнү-тикшерү объекты булып тора. Каршылыклы чорның аерым сәхифәләренә ул даими әйләнеп кайта, яңа табылган фактмәгълүматларга нигезләнеп, яңадан-яңа үзенчәлекләрен ача, XX гасыр сүз сәнгатен бербөтен күренеш буларак бәяләүнең принципларын эшли. Галим әлеге дәвер шигъриятенең аерым этапларын милли мәнфәгатьләр чагылышында һәм, гомумкешелек кыйммәтләренә нигезләнеп, әдәбиэстетик планда тикшерүе белән татар шигъриятен өйрәнүнең яңа этабына юл сала.

Совет чоры татар поэзиясенең үсеш юнәлешен билгеләүдә 1920–1930 еллар җитди урын алып тора. Т. Галиуллин «гасырлар дәвамында халыкның киңәшчесе, юлдашы, рухи таянычы булган» шигърияттә заман үзгәрешләренең аеруча киң чагылыш табуын билгели. Шагыйрьләрнең инкыйлабларны, пролетариат диктатурасын кабул итүитмәве, үткән мирасны яклавын яисә кире кагуын ачыклау аша чорның әдәби барышын объектив күз алдына бастыра. Шуның аша әдипләрнең теге яки бу иҗат методына, агым-юнәлешләргә мөнәсәбәтенә ачыклык кертелә, сәбәпләре билгеләнә. Әйдәп баручы шагыйрьләр иҗатына дәлилле анализ аша «чор идеологиясе кеше характерын әхлакый-хисси яссылыкта тулырак ачуны чикләсә дә, стильләр бертөслелегенә алып килми» дигән нәтиҗә ясала.

Иҗтимагый аңның үзенчәлекле чагылышы булган сүз сәнгатен тикшергәндә Т. Галиуллин аерым билге-үзенчәлекләрне, тенденцияләрне ачыклау аша, яңа эзләнүләрне, проблемаларны билгеләргә омтыла. Шуның бер үрнәге 60 нчы елларда татар поэзиясенә килүче буын (Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Р. Мингалим, Г. Рәхим, Р. Гаташ һ.б.) иҗатын

өйрәнүдә күренә. Әлеге әдипләр иҗатына бәйле фикер-карашларны ул системага сала: күнегелгән калыплардан арыну, форма өлкәсендә яңа тәҗрибәләргә йөз тоту; традицион сурәтләрдән, еш кына вәгазьчелеккә кайтып калган уй-фикерләрдән метафорага, шартлылыкка, иркен сурәтле фикерләүгә омтылу; читтәрәк калып килгән аерым казанышларны калкытып (Дәрдемәнд, С. Рәмиев һ.б.), ул традицияләрне яңа шартларда үстерү, ил-халык язмышы турында уйлануларны галәми мәсьәләләр белән бәйләү, үрү һ.б. Шуның белән бергә, Т. Галиуллин ирешелгән казанышлар белән генә канәгатьләнмичә, поэзия үсешенә яңа рух өргән әлеге буын шагыйрьләрнең серле шигъри дөньясын заман биеклегеннән, дөнья сәнгате казанышларыннан торып ачу юлларын эзли. Төп яңалыкның, сыйфат үзгәрешенең формада булмыйча, эчтәлектә, иҗтимагый, фәлсәфи мәсьәләләрне хис-фикер синтезы рәвешендә чагылдырып, укучыны сискәндереп җибәрүдә, битарафлыктан чыгаруда, кеше һәм табигать, тарих һәм милләт турындагы уйлануларны халыкчан сурәтләр, мәгънәле деталь-символлар, сынландырулар һ.б. аша гәүдәләндерүдә булуын аңлауга килә. Әлеге эзләнүләр яссылыгында югарыда исемнәре аталган шагыйрьләр генә түгел, алардан бераз соңрак килгән М.Әгъләмов һәм Зөлфәт, Рәшит Әхмәтҗанов һәм Р. Миңнуллин, К. Сибгатуллин һәм Ф. Яруллин, З. Мансуров һәм М. Галиев, Л. Шагыйрьҗан һәм Э. Шәрифуллина һ.б. иҗаты да яңа яклары белән ачылып китә.

Т. Галиуллин хезмәтләренең мөһим бер үзенчәлеге шигъри әсәрләргә хисси-тойгылы бәяләмәнең аң-акыл җегәренә нигезләнгән аналитик фикерләү белән үрелеп баруында («Фикер һәм хис бердәмлеге», «Акыл һәм җан берлеге», «Матурлык дөньясында» һ.б.). XX гасырның 60 нчы елларыннан соң шигърият реалистик һәм романтик сурәтлелеккә нигезләнгән хәлдә модернистик агымнарны да үз итә. Шулай да яңалык-табышларны ул, беренче чиратта, стиль эзләнүләре белән бәйләп карый. Бу аңлашыла да, чөнки һәр шагыйрьнең иҗади йөзе нәкъ менә стиль эзләнүләрендә, үзенә хас сурәтләрдә, алым-бизәкләрдә, телендә, алым-чараларның эчке мөмкинлекләрен ачуда чагыла. Реалистик эзләнүләр заман агышын йөрәк хисе белән иңләргә омтылу, тормыш һәм кешегә фәлсәфи планда якын килү, көндәлек тормышка, җиргә бермә-бер якынаю белән билгеләнсә, поэзиядәге романтик тенденция кешенең рухи дөньясына игътибар көчәю, яшәешнең мәңгелек проблемаларына, шуңа бәйле еш кына күтәренке һәм фаҗигале пафоска мөрәҗәгать итү, шартлы алымнардан, метафорик сөйләмнән иркен файдалану һ.б. белән аңлатыла.

А. Әхмәдуллинның «Дөреслеккә ирешү юлында» (1993), Офыклар киңәйгәндә» (2002), «Күңелләрне уятыр» (2007), «Татарская драматургия» (2012) кебек монография һәм җыентыкларында драма төренең мәйданга килгәннән алып бүгенге көнгә кадәрге үсеш-үзгәреш тен-

денцияләре, традиция-яңачалыклар, классик һәм бүгенге көн авторларының сәнгатьчә фикерләүдәге табышлары һ.б. җентекле һәм фәнни нигезгә салынып тикшерелә. Ул сүз сәнгатендә милләтнең язмышы, хыял-омтылышлары гына түгел, бәлки бөтен асылы, яшәү рәвеше, рухи кыйммәтләре, гомумән, иң матур сыйфатлары якланып һәм сакланып килүен ачык аңлап эш итә.

Сәхнә әдәбиятындагы яңалыклар төрле яссылыкта һәм юнәлештә чагылыш таба дип саный А. Әхмәдуллин. Аларның берсе тормышны объектив һәм дөрес чагылдыру белән бәйле. Совет чорында моңа ирешүдә җитди уңышлар булса да, социалистик реализм иҗат методы таләпләре, билгеле бер дәрәҗәдә цензура драматургларны кысачикләрдә тота. Моның белән бәйле икенче җитди мәсьәлә калкып чыга, ул – шәхес концепциясе. XX гасырның 2 нче яртысында татар драматургиясе кеше шәхесен иң зур кыйммәт буларак тасвирлауга, аның мәнфәгатьләрен яклауга килә. Яңалыкларның тагын берсе тематик киңлек, төрлелек һәм яңа тип геройларның сәхнәгә чыгуында чагылыш таба. Бу очракта гомумән форма һәм эчтәлектәге эзләнүләр турында сүз алып бару дөрес булыр. А. Әхмәдуллин татар драматургиясенең төп үсеш юлы реализм белән бәйле дип саный. Шулай да ул аерым авторларның романтик сурәтлелеккә йөз тотуын яисә модернизм элементларын теләп куллануларын һич тә инкарь итми. Киресенчә, реалистик иҗат методы кысаларына сыймаган форма-алымнарга мөрәҗәгать итеп, «икенчел художество моделе» тудыру омтылышларын яңалык буларак тәкъдим итә. Әлеге чор сәхнә әдәбиятында жанрлар байлыгы һәм формалар төрлелеге мәсьәләсенең теоретик нигезләнүе, кайберләренә ачыклык кертелүе дә әһәмиятле. Галимнең комедия жанры үсеше, трагедиянең исә артка калу сәбәпләре яисә трагикомедия, моңсу драма, мелодрама һ.б. жанрларны аңлау һәм кабул итүдәге каршылыклар турындагы фикерләре әдәбият белемен баетуга хезмәт итә.

XX гасыр әдәбият тарихының проза төрен системалы тикшерүчеләрнең берсе булган Ф. Галимуллинның «Инешләр Иделгә кушыла»(1995), «Эзләнү вакыты»(2005), «Писательское слово на рубеже эпох» (2014) һ.б. җыентыклары әдәби вакыйга буларак кабул ителде. Әдәби процессның эчке үзенчәлекләрен ачу аша, тикшеренүче теге яисә бу әдип иҗатына килә һәм аның сәнгати табышларын чор әдәбияты фонында бәяли. Шуңа да күпсанлы язмалары дәлилле булуы, фәлсәфи киңлеге, эмоциональ тәэсире белән аерылып тора. Ә. Баянов, М. Насыйбуллин, М. Хәбибуллин, М. Маликова кебек әдипләрнең иҗат үзенчәлеген күреп алып, аларны әдәби җәмәгатьчелеккә беренчеләрдән булып җиткерүче Ф.Г. Галимуллин булды. Аның каләменнән Г.Ахунов, М. Мәһдиев, А. Гыйләҗев, Ә. Еники, И. Салахов, Р. Мөхәммәдиев, Р. Сибат, Ф. Садриев һ.б.ның иҗат портретлары төште.

Өченче юнәлеш булып аерым авторлар иҗатын, сәнгати эзләнүләрен тикшерү тора. XX–XXI гасыр чигендә басылып чыккан хезмәтләр арасында Ә. Сәхаповның «Кырыс реализм» (А. Гыйләҗев иҗаты, 1995), Л. Минһаҗеваның «Ибраһим Салахов» (1999), А. Даутовның «И. Юзеев шигъриятендә романтизм» (2002), А. Шәмсутованың «Фәүзия Бәйрәмова прозасы» (2004), Ф. Хәсәнованың «Ренат Харис шигърияте» (2005), Р. Сабировның «Шигырьләрдә – минем йөрәгем...» (Х. Туфан иҗаты, 2006), Ф. Миңнуллинаның «Юныс Сафиуллин драматургиясе» (2007), Ф. Хатипов һәм Р. Сверигинның «Әмирхан Еники: әдипнең тормыш һәм иҗат юлы» (2009), шулай ук «XX гасырның 70–90 нчы еллар татар поэзиясе контекстында К. Сибгатуллин иҗаты» (2008) һ.б. китаплар фактик материалга байлыгы, әдипләр иҗатын яңача бәяләү омтылышы белән игътибарга лаек. Шуның белән бергә, замандаш әдипләрдән Н. Фәттах, И. Салахов, Ф. Шәфигуллин, Ә. Еники, Х. Сарьян, Т. Миңнуллин, Х. Туфан, Г. Ахунов, Ф. Яруллин, Г.Афзал, Ю. Сафиуллин, Р. Фәйзуллин, Ш. Рәкыйпов, К. Сибгатуллин, А. Гыйләҗев, Ю. Әминев, М. Әгъләм һ.б иҗаты махсус тикшеренүләр[1] объекты булды.

Дүртенче юнәлеш булып күпгасырлык әдәбият тарихының мәктәп һәм югары уку йортлары дәреслекләрендә чагылышы тора. 1990 еллар башында татар һәм рус мәктәпләре өчен яңа программа һәм дәреслекләр эшләү башлана. Бу эшкә тәҗрибәле галимнәр, укытучы-методистлар А. Әхмәдуллин, Ф. Хатипов, А. Яхин, Ф. Мусин, З. Хәбибуллина,

[1] *Кашфиева Л.А.* Татарская сатирическая поэзия 50–80-х годов: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1991. 20 с.; *Ибатуллина Д.Э.* Поэтика прозы Амирхана Еники: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1993. 21 с.; *Минһаҗева Л.И.* Ибраһим Салахов (тормышы һәм эшчәнлеге). Казан: Матбугат йорты, 1999. 176 б.; *Шакирова Г.А.* Драматургия Туфана Миннуллина 80–90-х годов: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2000. 19 с.; *Макарова В.Ф.* Поэтика прозы Хасана Сарьяна: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2002. 25с.; *Гайфуллина Ф.А.* Проза Гарифа Ахунова (эволюция творчества): автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2003. 26 с. *Мифтахова М.А.* Поэзия Хасана Туфана 60–80 гг. XX века: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2004. 27 с.; *Хакимова С.Г.* Проза Фаниса Яруллина: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2004. 23 с.; *Гилаева И.И.* Гамил Афзал: лирика һәм сатира (автор позициясе һәм сәнгатьчәлек) = Гамиль Афзал: лирика и сатира (авторская позиция и художественность): филол. фән. канд. ... дис. Казан, 2004. 228 б.; *Карамова А.З.* Психологизм в творчестве Амирхана Еники: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2005. 20 с.; *Хузина М.К.* Поэтический мир Равиля Файзуллина: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2005. 26 с.; *Гиниятуллина А.Ф.* Проблема «человек и природа» в татарской прозе 60–90-х годов XX века: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2006. 26 с.; *Шарипова А.С.* Морально-этическая концепция в драматургии Юнуса Аминева: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2007. 29 с.; *Шаехов Л.М.* Трагедия в стихах в татарской драматургии: зарождение и развитие: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2012. 22 с.; *Насибуллина Н.Ш.* Типология жанров и систематизация художественных образов в поэзии Роберта Миннуллина: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2013. 22 с.; *Бәдретдинова Л.Ш.* Гази Кашшафның әдәби-тәнкыйди һәм гыйльми эшчәнлеге. Казан, 2014. 216 б.; *Макарова В.Ф.* Комическое в татарской прозе XX века: автореф. дис. ... докт. филол. наук. Казань, 2014. 51 с.

Х. Миңнегулов, Т. Галиуллин, Ш. Садретдинов, Ф. Галимуллин, Н. Юзиев, Ә. Хуҗиәхмәтов, Ф. Ганиева, М. Җәләлиева, Д. Сибгатуллина һ.б. тартыла. V–XI сыйныфлар өчен язылган дәреслекләр күпгасырлык әдәби мирасны мәктәп укучыларына җиткерүдә гаять мөһим вазифа үти: беренчедән, әдәбиятның тулы, эзлекле һәм яңа кайтарылган ядкәрләр белән тулыландырылган тарихы урын ала; икенчедән, марксистик-ленинчыл методологиядән арынган яңа концепция тәкъдим ителеп, аның нигезендә гомумкешелек кыйммәтләренә йөз тоту, әсәрләргә тарихилык һәм миллилек принципларыннан якын килү алга чыга; өченчедән, әдәбият үсешенең төп тенденцияләрен, әдипләрнең әдәби-эстетик казанышларын ачуда яңа эзләнүләрнең нигезе билгеләнә, ачыклана һәм фәнни тикшеренүләргә юл салына. XXI гасыр башында мәктәп программалары һәм дәреслекләренең яңа варианты дөнья күрде. Әлеге җаваплы эшкә Ф. Галимуллин, Д. Заһидуллина, Ә. Закирҗанов, Ф. Ганиева, Ф. Хәсәнова, Р. Ханнанов, Ә. Мотыйгуллина кебек әдәбият белгечләре һәм мәктәп укытучылары тартылды. Нәтиҗәдә яңа стандартлар нигезендә эшләнгән заманча дәреслек-хрестоматияләр укучыларга килеп ирешә.

XX гасыр татар әдәбияты буенча югары уку йортлар студентлары өчен чыгарылган Д. Заһидуллина һәм Н. Йосыпова дәреслеге[1] өр-яңа концепциягә нигезләнүе белән аерылып тора. Хезмәтнең яңалыгы XX гасыр татар әдәбиятын бербөтен күренеш итеп өйрәнүдә, әдәби процесс үзенчәлекләрен «ак таплар»сыз ачуда, сүз сәнгатенең үсешүзгәрешен синхрон яссылыкта тикшерүдә, әдипләр иҗатына объектив һәм тулы бәя бирүдә чагыла.

Д. Заһидуллинаның «Современная татарская проза (1986–2016 гг.): основные тенденции историко-литературного процесса» һәм «Татарская поэзия рубежа XX–XXI веков (1986–2015): эстетические ориентиры и художественные поиски»[2] монографияләре ике гасыр чиге әдәбиятын өйрәнүдә яңа башлангыч булып тора. Автор безнең күз алдында барган әдәби процессны фәнни казанышларга нигезләнеп бәяли, җитди гипотезалар белән чыгыш ясый. XX гасыр ахырында татар әдәбияты үсешенең яңа этабына керде, дип саный галимә. Бу, беренче чиратта, сүз сәнгатенең төрлелегендә чагыла. Классик традицияләрне аеруча үз иткән әдәбиятыбыз, модернизм һәм постмодернизм алымнарына да бик теләп мөрәҗәгать итә, чынбарлыкны чагылдыруның яңадан-яңа юлларын эзли. Бу исә XX йөз башы тардицияләрен, шулай ук гасырның

[1] *Заһидуллина Д.Ф., Йосыпова Н.М.* XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек. Казан: Казан университеты, 2011. 1 нче китап: XX йөзнең беренче яртысында татар әдәбияты. 230 б.

[2] *Загидуллина Д.Ф.* Современная татарская проза (1986–2016 гг.): основные тенденции историко-литературного процесса. Казань: Изд-во Академии наук РТ, 2017. 246 с.; *Загидуллина Д.Ф.* Татарская поэзия рубежа XX–XXI веков (1986–2015): эстетические ориентиры и художественные поиски. Казань: Изд-во Академии наук РТ, 2017. 268 с.

60 нчы елларында урын алган милли хасиятләрне калкытып куюга, аларда урын алган тема һәм проблема, жанр һәм мотив эзләнүләрен, сәнгать чаралары байлыгын яңа заманга бәйле ачуда, бәяләүдә, киң планда укучыга җиткерүдә чагыла.

Үткән әдәбиятыбызга, аеруча XX гасыр сүз сәнгатенең аерым вәкилләре иҗатына каршылыклы, кискен, хәтта урыны белән кире каккан карашлар да очрый. Бу уңайдан А. Гыйләҗев фикерләренә тукталып үтик. Танылган прозаик чын әдәбият үз халкына хезмәт итәргә тиеш дип саный. «Әдәбият, асыл әдәбият, тарихка багана булып басарлык әдәбият – бары тик милли генә була ала, – дип яза ул «Күңелем серләре» язмасында. – Ходай коллары – адәм балаларын бары тик милли мәйданда гына тулысынча аңлап вә аңлатып була»[1]. Шуңа да ул кешегә рух, көч өсти торган, аның күңелендә ышаныч-өмет тойгылары тәрбияли торган, милләтнең матур сыйфатларын югары күтәреп, аның тәрәккыятенә ярдәм итәрлек фикер-карашлар, тормыш күренешләре, истә кала торган тулы канлы образлары булган әдәбиятны югары күтәреп куя. Әлеге максатка хезмәт итми дип бәяләп, Ф. Әмирхан, М. Гафури, Г. Ибраһимов, Ш. Камал һ.б. аерым әсәрләрен кискен тәнкыйтьли. Автор болай дип дәвам итә: «Безнең татарда татарны яраткан әдипләр бармы? Татарда нинди милли сыйфатларны әсәрләрендә тапканнар алар? Татар язмышын нинди мисаллар белән ачарга тырышканнар? (...) Ә. Еники дә, М. Мәһдиев тә татарның милли әдипләре, алар татарны яра алалар, аның җанын аңлыйлар. Менә нәрсә кыйммәт минем өчен! Шул сыйфатлары белән алар үз чордашларыннан нык аерылып торалар.(...) Әгәр Еники белән Мәһдиевтә чорның социаль каршылыкларын аңлау, шул каршылыклар чарпалышында үз төп урыннарын билгеләү көче дә булса, алар татар тормышын дөнья мәйданына чыгарырлык әсәрләр яза алыр иде[2]. Танылган әдипнең фикерләре билгеле бер бәхәскә урын калдырса да, аларда дөреслек, хакыйкать барлыгын танымый мөмкин түгел. Әмма татар сүз сәнгатенә йогынты ясаган җитди сәбәпләрне дә онытмыйк. А. Гыйләҗев үзе үк билгеләп үткәнчә, берничә гасырга сузылган кимсетелү, рәнҗетелү эзсез үтмәгән. Мескенлек, куркаклык психологиясе геннарга үтеп кереп, буыннан буынга күчеп килә. Халкыбыз аннан әле гомумән котыла алырмы? Әлеге халәт-сыйфат билгеле инде әдәбиятка, татар канлы геройларга да үтеп керә. Ә бит элеккеге СССРда татар әдәбиятының урыны һич тә түбән булмаган. Хәзер дә Россиядә һәм Бердәмлек илләрендә үз урынын саклап кала дип уйларга нигез бар. Татар әдәбияты нинди генә шартларда да халык белән арасын өзмичә, аның рухи-мәдәни ихтыяҗларына җавап биреп килә һәм бүген дә әлеге мөһим вазифасын, нигездә, уңышлы башкара.

[1] *Гыйләҗев А.* Күңелем серләре (Куен дәфтәрләреннән) // Казан утлары. 2000. № 11. Б. 18.
[2] Шунда ук. Б. 19.

Шулай итеп, хәзерге әдәбият белемендә аеруча күп бәхәсләр, фикер каршылыклары уяткан чор булып сүз сәнгатенең Октябрь инкыйлабыннан соңгы үсеш-үзгәреше тора. «Совет әдәбияты» исеме белән аталып йөртелгән бу дәвер һич тә бертөрле генә түгел. Ул тарихка зур казанышлары һәм шул ук вакытта җитди югалтулары белән кереп кала. Шуңа да хәзерге әдәбият белеме әлеге чор әдәбиятын бөтен тулылыгында, объектив ачыклау һәм үсеш тәҗрибәсен бәяләү кызыклы эзләнүләр, төрле мәктәп-метод-юнәлеш приципларына нигезләнүгә бәйле үзенчәлекле фәнни бәхәсләр белән бара. Әдәби мирасны бөтенлекле рәвештә күзаллау омтылышында чит илләрдәге татар әдәбиятын өйрәнә башлау да зур казаныш булып тора. Г. Исхакыйның бай иҗаты белән янәшә М. Исмәгыйли, Х. Габдүш, Х. Хәмидулла, М. Арсланбәк, Ш. Келәүле һ.б. иҗаты да халкыбызга кайтарыла, әдәби әйләнешкә кертелә. Ул исә әлеге мирасның идея-эстетик кыйммәтен, әдәби-иҗтимагый әһәмиятен ачу белән, XX гасыр татар әдәбиятының чикләрен бермә-бер киңәйтеп, аны тулы һәм бербөтен итеп өйрәнү мөмкинлеге бирә. Гомумән, әдәбият фәне гаять кызыклы һәм каршылыклы булган, үзеннән бай әдәби мирас калдырган әлеге чорга хас төп тенденцияләрне, сәнгати фикерләүдәге үзгәрешләрне, сурәтләүнең бай төсмерләрен, аерым әдипләр иҗатындагы казанышларны, әдәби төрләрне һәм жанрларны тарихи-мәдәни аспектта тикшерү юлына чыга.

**III бүлек нәтиҗәләре**

1. XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы татар әдәбият белемендә барган фикер алышуларда татар әдәбияты тарихын өйрәнүнең методологик һәм фәнни-теоретик нигезләре ачыкланып, тикшеренүләрнең максаты һәм төп юнәлешләре билгеләнә: 1) марксизм-ленинизм тәгълиматының берьяклы карашларыннан баш тарту; 2) үткән чорларда тулы калыплашкан эзлеклелек, бердәмлек, объективлык, системалылык кебек принципларга таяну; 3) әдәбият тарихын өйрәнүнең үзәген тәшкил иткән тарихилык һәм миллилек принципларының, күчеш чоры үзенчәлекләренә нисбәтле, җитди сыйфат үзгәрешләре кичерүе; 4) Шәрык һәм Гареб әдәбиятларының тирән йогынтысын тойган хәлдә, татар әдәбияты тарихын эчке сыйфат үзгәрешләре нигезендә хәрәкәт итүче, үзенә генә хас сыйфат-билгеләре булган күренеш итеп аңлау һәм бәяләү; 5) әдәбиятның җәмгыятьтәге урыны үзгәрүгә, шулай ук фәндә яңа терминнар һәм төшенчәләрнең кулланышка керүенә бәйле, аны сәнгать төре буларак аңлау, кабул итү һәм бәяләүнең төрлелегенә, аерым алганда, диалогик характерына йөз тоту.

2. Күпгасырлык татар әдәбияты тарихының дәверләргә, чор-этапларга объектив, төгәл бүленешен, чикләрен билгеләү гаять бай сүз сәнгатебезнең системалы үсеш-үзгәрешен, табыш-югалтуларын, традицияләр дәвамчанлыгын һәм яңачалыкларын, халыкның иҗтимагый-

фәлсәфи фикер үсешендәге, рухи тормышындагы урынын, тарихи-иҗтимагый, сәяси вакыйгаларның, танылган шәхесләрнең ролен һ.б.ны тулырак аңларга, шулар аша әдәбиятның үсеш-үзгәреш перспективаларын, әдәбият фәнендәге эзләнүләр юнәлешен, камилләштерү юлларын ачыкларга җирлек бирә.

3. Җәмгыятьнең төрле өлкәләрендәге җитди үзгәрешләргә бәйле XX гасырның 90 нчы еллары чигендә татар әдәбият тарихын өйрәнүдә яңа этап башлана. Әдәбият фәне, үзенең традицияләренә, тупланып килгән, билгеле бер системага салынган казанышларына таянган хәлдә, дөньякүләм сүз сәнгате тарихын тикшерүдәге яңалыкларга йөз белән борылып, татар әдәбият тарихын яңа методологик һәм фәнни-теоретик нигездә өйрәнү юлына чыга. Аерым дәверләргә, чор-этапларга бәйле яңалыклар түбәндәгеләрдә чагыла:

– Борынгы һәм урта гасырлар әдәбияты халык мифологиясенә, фольклорына нигезләнеп, халык тормышы, аның яшәү рәвеше, уй-фикерләре, хыял-омтылышлары белән тыгыз бәйләнештә үсеп, Шәрык Яңарышының уңай йогынтысын тойган хәлдә, XIII–XVI гасыр уртасы аралыгында үзенчәлекле тарихи, социаль-мәдәни, фәлсәфи-эстетик карашларны үз эченә алган Яңарыш чоры кичерә. XVII–XVIII йөзләр әдәбиятында декадентлык күренеше урын ала. Ислам дине белән тыгыз бәйләнештә, ул суфичылык әдәбиятының үсешенә этәргеч бирә. XVIII гасыр ахыры – XIX гасыр башында иҗат юнәлеше буларак реализмга хас билгеләр барлыкка килә. Урта гасырлар татар әдәбиятының Шәрык халыклары әдәбияты белән тыгыз бәйләнеше күчмә сюжетларның, төрдәшләрнең, шулай ук типологик охшашлыкларның урын алуына юл ача. Сүз сәнгатендә гаять әһәмиятле урын алып торган бу күренеш яңа традицияләргә дә нигез сала. Хәзерге әдәбият белемендә шигъри жанрлар поэтикасы, аларның барлыкка килүе, үсеш эволюциясе, бай сурәт чаралары, поэтик образлар дөньясы зур кызыксыну уята һәм алар җитди тикшеренү объектлары булып тора. Әлеге дәвер әдәби мирасының текстологиясен эшләү, аны китап укучыларга кайтару да күз уңында торган мәсьәлә булып кала. Урта гасырларда яшәп иҗат иткән әдипләрнең күпсанлы әсәрләре дөнья күрүе дә зур казаныш булып тора. Шуның белән бергә, а) бу чор язма әсәрләренең жанр табигатен һәм аларның традицияләрен, ә) Урта гасыр Ренессансына хас сыйфат-билгеләрнең шул чор һәм соңрак дәвер әдипләр иҗатында чагылыш үзенчәлеген, б) әдәби мирасның үз чоры өчен һәм дөнья мәдәнияте үсешендәге иҗтимагый, әхлакый-эстетик әһәмиятен һ.б.ны ачыклау киләчәктә дә дәвам ителергә тиешле бурыч булып кала.

– XIX йөз әдәбиятын өйрәнүдә яңа уңышларга ирешелә: 1) җитди үзгәрешләр юлына чыккан Яңа заман татар әдәбиятының тарихи, иҗтимагый, мәдәни тамырлары ачыклана; 2) бу чор иҗтимагый фикер үсешенең нигезе булган мәгърифәтчелек идеологиясенең бөтен сүз сәнгатен

сугаруы, яңа темаларга, форма-алымнарга, иң мөһиме, яңа тип геройларның мәйданга чыгуына җирлек әзерләве фикере мөһим тенденция буларак баетыла, тирәнәйтелә; 3) әдәбиятның Шәрык һәм Гареб әдәби-эстетик, фәлсәфи фикерләрен үзләштерү юлына чыгуы, шуңа бәйле үзенчәлекле синтез күзәтелү һәм XX гасыр башында аның тагы да үстерелүе турында җитди нәтиҗәләр ясала; 4) бу дәвернең бай мирасы кайтарылып, әдәбият тарихының яңа исемнәргә баюы күзәтелә һ.б. Ә инде XIX йөз сүз сәнгатен өйрәнүгә бәйле җитди мәсьәләләр (кульязма текстларны укучыга кайтару; бу чор әсәрләренең тулы антологиясен төзеп, бастырып чыгару; әдәбиятта дини һәм дөньяви башлангыч, шуларга бәйле гуманистик идеяләрнең чыгылыш үзенчәлеге; мәгърифәтчелек реализмы һәм романтизмының урта гасыр романтизмы һәм XX йөз башындагы Европа тибындагы романтизм белән диалектик бәйләнеше һ.б.) яңа тикшеренүләрне көтә.

– XX йөз башы әдәбиятына нисбәтле Г. Исхакый иҗатын кайтару һәм әлеге бай мирасны тикшерә башлау гаять зур әһәмияткә ия. Бу чор әдәбиятын өйрәнү, нигездә, өч юнәлештә бара: берсе – традицион юл булып, күренекле классиклар иҗатының идея-эстетик һәм фәлсәфи-этик катламнарын ачу, заман биеклегеннән торып бәяләү, шәрехләү, башка халыклар әдәбияты белән чагыштыру, традицияләр дәвамчанлыгы һәм яңачалыкларга мөнәсәбәтле тикшерү һ.б.; икенчесе – бу чор әдәбиятының аерым вәкилләре иҗатын әдәби юнәлешләр һәм агымнарга нисбәтле өйрәнү. Бу исә үз чиратында XX йөз башы татар әдәбиятының реализм һәм романтизм белән шактый киң планда модернизм агымнарын үзләштерүен нигезли һәм татар әдәбиятының рус-Европа әдәби-фәлсәфи карашларын кабул итү юлына чыгуын дәлилли; өченчесе – XX йөз башы әдәбиятында билгеле бер урын алып та, төрле сәбәпләр аркасында әдәби процесстан читләштерелгән язучыларның мирасын өйрәнү, аларны әдәби әйләнешкә кертү һәм шуның белән бу чор сүз сәнгатен эзлекле, бердәм күренеш буларак аңлауга килү.

– Сүз сәнгатенең Октябрь инкыйлабыннан соңгы үсеш-үзгәреше хәзерге әдәбият белемендә аеруча күп бәхәсләр, фикер каршылыклары уяткан чор булып тора һәм аны бөтен тулылыгында, объектив ачыклау һәм үсеш тәҗрибәсен бәяләү кызыклы эзләнүләр, төрле мәктәп-метод-юнәлеш приципларына нигезләнүгә бәйле үзенчәлекле фәнни бәхәсләр белән бара. Чит илләрдәге әдәби мирас өйрәнелә башлап, татар әдәбиятының чикләрен бермә-бер киңәйтеп, аны тулы һәм бербөтен итеп өйрәну мөмкинлеге туа. Әдәбият фәне гаять кызыклы һәм каршылыклы булган, үзеннән бай әдәби мирас калдырган әлеге чорга хас төп тенденцияләрне, сәнгати фикерләүдәге үзгәрешләрне, сурәтләүнең бай төсмерләрен, аерым әдипләр иҗатындагы казанышларны, әдәби төрләрне һәм жанрларны тарихи-мәдәни аспектта тикшерү юлына чыга.

## IV бүлек
# ХӘЗЕРГЕ ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬНЕҢ ТОРЫШЫ ҺӘМ ҮСЕШ ПЕРСПЕКТИВАЛАРЫ

### 4.1. Хәзерге әдәби барышта тәнкыйтьнең урыны

Әдәбият белеменең үзенчәлекле бер тармагы булган әдәби тәнкыйть әдәби әсәрләргә заманның фәнни-теоретик, әдәби-эстетик, әхлакый-фәлсәфи казанышларыннан чыгып бәя бирә, үз чорының әдәби процесс үзенчәлекләрен ача. Теге яки бу әдәби әсәрнең идея-эстетик кыйммәтен ачыклау, аны китап укучыга тәкъдим итү дә булып тора. Шуңа да әлеге бәядә әсәрнең эчтәлек һәм формага бәйле сәнгати эшләнешен, яңалыгын объектив рәвештә билгеләү мөһим шартлардан санала. Шул рәвешле китап турында киң катлам укучыларда фикер-караш, мөнәсәбәт тудырыла һәм ул еш кына аның шул чор әдәбиятындагы урынын билгеләүгә дә йогынты ясый. Гомумән, тәнкыйть, бер яктан, аерым әсәрләрне яисә шул чор әдәби процессын өйрәнеп бәяләве белән әдәби-иҗади процессны оештыруга, үсеш-үзгәрешенә ярдәм итә; икенче яктан, китап укучы белән әдип арасында арадашлык вазифасын башкара, соңгысының сәнгати фикерләү үзенчәлекләрен төшенергә, аңларга булыша; өченче яктан, эстетик төшенчәләрнең нигезен ачу-аңлату аша әдәби зәвыкны үстерергә ярдәм итә[1].

Тәнкыйтьнең нәрсә булуы турында, аның асылында иҗадилыкмы, фәннилекме өстенлек итүгә бәйле бәхәсләр даими бара. Әлеге сыйфатларны каршылыкта түгел, бәлки диалогик бәйләнештә карау уңышлы. А.А. Жук язганча, тәнкыйть «әдәби процесс мәгълүматлары белән генә эш итүче фән түгел. Чын асылында ул үзе әлеге әдәби иҗатның аерылгысыз өлеше, әдәби эшчәнлек төре. Тәнкыйтьче – һәрвакыт әдип, әдәби тормышта тере катнашучы, бәлки аны өйрәнүче генә түгел (соңгысы әдәбият белеменә карый)»[2].

«Матур әдәбиятның таянычы, рухи юлдашы, изге намусы, хөкемдары»[3] буларак, тәнкыйть *әдәби процесста* гаять җитди урын алып тора.

---

[1] Литературный энциклопедический словарь. М.: Советская энциклопедия, 1987. С. 170–171; Литературная энциклопедия терминов и понятий. М.: Интелвак, 2003. С. 414–416; Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. Казан: Мәгариф, 2007. Б. 32–34. һ.б.

[2] *Жук А.А.* Конспект вступительной лекции по курсу истории русской литературной критики // Русская литературная критика. Саратов: Изд-во Сарат.ун-та, 1994. С. 8.

[3] *Галиуллин Т.Н.* Тәнкыйть һәм әдәби процесс // Казан утлары. 1984. № 11. Б. 162.

XX гасыр башында тәнкыйть мәкаләләре белән актив чыгыш ясаган М. Укмасый болай дип яза: «Әдәбият эчендә тәнкыйть булмаса, Аурупа галәмендә бу кадәр әдәбиятлар вөҗүдкә (барлыкка) килмәгән булыр иде. Бу мәхсулатны (казанышны) күрмәс идек. Аурупада нинди генә голүм вә фөнун (гыйлем һәм фән) яки сәнгатькә даир бер тәэлиф (китап) мәйданга килде исә, әрбабы (каләм ияләре) тарафыннан мизанга салынып, бакчасына карап акчасы, кыйммәтенә карап хөрмәте биреләдер»[1]. Бу, беренче чиратта, тәнкыйть башкарган бурыч-вазифаларның җитдилеге белән бәйле. Чөнки ул әдәби әсәр яисә әдәби процесс турында гына түгел, бәлки гомумән мәдәнияткә, аның аша чагылыш тапкан дөньяны күзаллауга йогынты ясый. Танылган драматург Т. Миңнуллин әдәби тәнкыйтьнең асылын болай аңлата: «Әдәби тәнкыйтьнең чын асылы – анализдыр. Әйтик, язучыны теге яки бу әсәрне язарга нинди сәбәпләр этәргән, максатына ирешә алганмы язучы, ирешә алмаса, ни комачаулаган, бүгенге җәмгыять күзлегеннән караганда әһәмиятлеме язылган әсәр, язучы фикерен ни дәрәҗәдә осталык белән әйтә алган. Гомумәдәби процесста үз урыны бармы әсәрнең һ.б., һ.б. Мондый тәнкыйть-анализ теләсә кемне уйландыра. Син язучылык хезмәтенең ничаклы җаваплы икәнен янә бер тоясың, ягъни үз эшеңә читтәнрәк карап бәя бирәсең»[2]. Шуңа да әдәби тәнкыйть, бер яктан, хәзерге сүз сәнгатен тулыландыра, баета, икенче яктан, аны аңларга, яңадан-яңа якларын ачарга ярдәм итә. Болар өстенә тәнкыйть күптөрле функцияләр башкара[3].

Әдәби тәнкыйть функцияләренең берсе *оештыру* белән бәйле, ягъни ул әдәби күренешләрне бәяләү белән генә чикләнмичә, әдипләрне билгеле бер проблематика, актуаль мәсьәлә тирәсенә туплауга ярдәм итә. Бу төр эшчәнлекнең тагын бер формасы булып төрле конкурслар, дискуссияләр аша теге яки бу чор әдәби процессын, аерым әдипләр иҗатын бәяләүне оештыра. Соңгысына нисбәтле төрле әдәби һәм дәүләт премияләренә лаек язучыларны барлау, алар иҗатын тикшерү, киң катлау укучыларга җиткерү дә тәнкыйтьнең җитди бурычларыннан берсе булып тора.

Аның тагын бер функциясе – *киләчәкне күзаллау*, прогноз бирү. Киң планда караганда тәнкыйть әдәби хәрәкәт артыннан бара: басылып чыккан әсәрләрне бәяли, нәтиҗәләр ясый, гомумиләштерү белән шөгыльләнә. Шул ук вакытта ул сүз сәнгатендә әлегә шытым гына булып сиземләнгән табышларны тотып ала, аларның киләчәктә билгеле бер тен-

---

[1] *Укмаси М.* Интикад // Гыйлаҗев Т.Ш. Рецензияләрдән – тәгъзияләргә. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. Б. 232.

[2] «Таяныч ул – халык...» // Казан утлары. 2005. № 9. Б. 87.

[3] *Егоров Б.Ф.* О мастерстве литературной критики. Жанры. Композиция. Стиль. Л., Советский писатель, 1980. 317 с.; *Крылов В.Н.* Русская символистская критика (1890–1910-е гг.): генезис, типология, жанровая поэтика: дис. ... докт. филол. наук. Казань, 2007. 508 с. һ.б.

денцияләргә, закончалыкларга, сәнгати фикерләү үзенчәлекләренә үсеп әвереләчәген билгели. Мисал өчен, хәзерге әдәбиятның архетип булып килгән мифологик образларга еш мөрәҗәгать итүен, әмма әлеге саф күңелле, рухи бөтен, камил геройларның тормышта әлегә булмавын билгеләгән Л. Дәүләтшина әдәбиятның тормыш-яшәеш үзгәрешләрен алдан сизүчәнлеген искәртә: «Оча торган кешеләр»нең бүгенге әдәбият мәйданында киң таралуы да әдәбиятның күрәзәчелегенә бәйле булса кирәк»[1]. Әдәби тәнкыйтьнең табышы буларак бәяләнә торган мондый күренеш җитди гомумиләштерүләр нәтиҗәсендә генә була ала. Шул рәвешле тәнкыйть «әдәби юнәлешнең эчке резервларын эзлекле аңлау-аңлату чарасы һәм аның әле ачылмаган иҗади мөмкинлекләрен билгеләү юлы һәм формасы» вазифасын үти[2].

Тәнкыйтьнең мөһим бер функциясе – *әдипкә*, аның дөньяны кабул итүенә йогынты ясау. Тәнкыйть мәкаләсе өйрәнелә торган әсәрнең авторын да күздә тотып языла. Тәнкыйтьче әсәрне анализлау барышында автор белән бәхәс-әңгәмә дә алып бара, аерым очракларда аның эзләнүләрен дәвам итә, тулыландыра, яңа якларын ача. Еш кына аерым штрихларда, кинаяле сүз артында яткан караш-фикерләрен үстереп, логик табышларга, иҗатчының үзе өчен дә серле булган иҗади фикерләү дөньясына килә. Шуның белән ул язучы әсәренең тирән катламнарын ачуга үзеннән өлеш кертә һәм әдипнең үзен дә бай мәгълүмат, үзенчәлекле караш-концепцияләр белән баета. Шулай ук язучы күз уңыннан төшеп калган яисә китап укучыларда каршылык уяткан, сәнгати планда тиешенчә дәлилләнеп, ачылып бетмәгән фикер, караш, төшенчә һ.б. бәяләп, әдипнең зәвыгын формалаштыруда, тел-стилен калыплаштыруда катнаша. «Һәрбер олы язучы, иҗатка керешкәнче, башкалар язган әсәрләр белән яхшылап танышып чыга, бөтен милли әдәби казанышларны, башка халыкларның сәнгать байлыкларын кызыксынып, күңел биреп, кирәксенеп өйрәнә, шуларның иң мөһим хасиятләрен, кабатлана торган билгеләрен аңына, күңеленә сеңдерә, – дип яза Ф. Хатипов. – Шулай итеп, анда матур әдәбиятның табигате, асыл хосусияте турында караш туа. Кәгазьгә төшмәгән теория аның аңында хасил була. Әгәр шулай булмаса, шагыйрь үзенең шигырьләрен рифма, ритм, строфа белән язмас, әдип әсәренең жанрын билгели алмас, каһарманнар язмышын мәгълүм бер сюжетка салып, бәйләнеш-мөнәсәбәтләр аркылы күрсәтмәс иде»[3]. XX йөз башында Г. Баттал тәнкыйтьнең әлеге үзенчәлеген болай билгели: «Мәдәни халыкларның әдәбиятында тәнкыйть шундый

---

[1] *Дәүләтшина Л.* Киләчәккә күз төбәп // Казан утлары. 2005. № 9. Б. 157.

[2] *Жук А.А.* Конспект вступительной лекции по курсу истории русской литературной критики // Русская литературная критика. Саратов: Изд-во Сарат.ун-та, 1994. С. 7.

[3] *Хатипов Ф.М.* Иҗат серләре // Мөлкәтебезне барлаганда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. Б. 236–237.

зур урын тота ки, бер мөхәррир әдәбият тарихында тик мөнәкъкыйдлек белән генә үзенә мәңгелек исем калдыра; тәнкыйть әдәби вә гыйльми әсәрләрнең кимчелек вә кәмаләтле *(камиллекле)* якларын ачып биру илә генә калмыйча, мөхәррир вә мужидләргә *(иҗат итүчеләргә)* юлбашчы да була»[1].

Икенче яктан, әдәби тәнкыйть китап *укучыга*, аның әдәби зәвыгына зур йогынты ясый. Бу турыда сүз алып барганда, тәнкыйтьнең матур әдәбият белән якынлыгы, ягъни соңгысы үтәгән бурыч-вазифалар белән кушылып, үрелеп баруын да билгеләп үтү кирәк. Тәнкыйтьче үзе тикшерә торган әсәрне (әдип иҗатын) укучыга тәкъдим итеп кенә калмый, бәлки анда әдәби сурәтләнеш тапкан вакыйга-күренешләргә, тема-проблемага, алым-чараларга үз карашын, мөнәсәбәтен белдерә. Шуның белән ул китап укучының зәвыгын үстерә, «нәрсә яхшы, нәрсә начар», «сәнгати матурлык», «иҗат дөньясы», «сурәтле дөнья» һ.б. күпсанлы төшенчәләрне аңларга булыша. Зәвыклы укучы тәрбияләүнең әһәмияте бүген аеруча үсте. Тамашалы сәнгать төрләренең әдәбиятны кысрыклавы күз алдында. Ә бит алар, беренче чиратта, тышкы эффектлылыкка, күзгә күренеп торган әйберләргә (төсләр, музыка, кием һ.б.) йөз тота. Бүгенге укучыларда шактый кызыксыну уяткан, киң планда массачыл әдәбият үрнәкләре буларак бәяләнгән детектив, хатын-кыз һәм солдат романнары кебек жанрлар вакыйгалылыкка, тәэсирлелеккә, төрле инстинктларга кагылучы күренешләргә, интригага, көтелмәгән сюжет борылышларына байлыгы белән характерлана. Болар – бу тип әсәрләрнең уңай ягы. Шуның белән бергә, аларда җитди сәнгать әсәренә хас булган үзенчәлекләр – кеше күңеленең тирән төпкелләренә төшү, яшәешне милли, әхлакый, фәлсәфи мәсьәләләр яктылыгында гәүдәләндерү, чор рухын чагылдырган образ-характерлар тудыру һ.б.шундый сыйфатлар урын алмый диярлек. Ә бит гомумкешелек кыйммәтләренә нигезләнгән чын гуманистны тәрбияләү башкача мөмкин түгел. Әдәби зәвык тәрбияләү (башка функцияләр белән бергә) әлеге олы максатка да хезмәт итә.

Әдәби зәвык төшенчәсе милли һәм әхлакый тәрбиядән шулай ук аерылгысыз. Миллилек күпгасырлык татар әдәбиятын иңләп үтә. Тәнкыйтьченең бурычы әлеге сыйфатның тарлык, чикләнү күренеше булмавын, киресенчә, үз укучысы һәм башкалар өчен дә мөһим, кызыклы төшенчә буларак ачудан-аңлатудан гыйбарәт. Бары тик милли һәм гомумкешелек кыйммәтләрен яклаган һәм саклаган матур әдәбият әсәрләре генә вакыт сынавын уза.

Тәнкыйть функцияләре арасында аның *чынбарлыкка* тәэсир итүе дә бар. Бу аның дөньяга карашы, актив тормыш позициясе белән тыгыз

[1] *Баттал Г.Т.* Яңа әсәрләр // Гыйлаҗев Т.Ш. Рецензияләрдән тәгъзияләргә: XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. Б. 149.

бәйле. Тикшеренү объекты булган сүз сәнгате әсәрендә урын алган мәсьәләләргә нисбәтле тәнкыйтьче караш-фикерләре белән уртаклаша, бәя бирә, иң мөһиме, әдип иҗатында я объектив, я субъектив рәвештә чагылыш тапкан, еш кына әсәрнең төрле катламнарында ачылган яшәеш-чынбарлыкның нигез мәсьәләләрен үзәккә алып, бәхәс кора, анализ ясый, үзгәрешләр мөмкинлеген, юлларын билгели. Әсәрдә сурәтләнгән чынбарлык тәнкыйди язма авторының уй-фикерләре белән тулылана. Язучы фикеренең яңа якларын ачып, үзе дә иҗат процессында катнаша һәм шуның белән тормыш-чынбарлыкка йогынты ясый, икенче яктан, укучы күңелендә яклау табып, аның аша тормыш-чынбарлыкны үзгәртеп коруда катнаша.

Әдәби тәнкыйтьнең гаять катлаулы бурычларын тормышка ашыру җитди каршылыклар, тукталыш-торгынлыклар, хәтта аерым чигенешләр белән бара. Аның торышын, социаль функцияләр үтәвен өйрәнү билгеле бер теоретик закончалыклар формалашуга җирлек бирә. Аларны тикшерү белән тәнкыйть теориясе шөгыльләнә. Әдәбият тарихы һәм әдәбият теориясе белән тыгыз бәйләнештә торучы тәнкыйть әдәбият белеменең бер тармагы буларак карала. Бу сыйфатында алгы планга, үзенчәлекле әдәби иҗат төре булган тәнкыйть түгел, бәлки тәнкыйть теориясе һәм тәнкыйть тарихы чыга. Киң планда әлеге төшенчә тәнкыйтьнең асылын аңлатуны (онтологиясен), аның тарихи эволюциясен, әдәби процесста сүз сәнгате белән үзара тәэсир итешүен, шулай ук жанрларын һәм жанр формаларын ачыклауны үз эченә ала. Әдәби тәнкыйть теориясендә аларны «поэтика» термины белән белдерәләр[1]. Рус символик тәнкыйтен барлыкка килү, типология һәм жанрлар поэтикасы ягыннан тикшергән В.Н. Крылов тәнкыйть поэтикасы төшенчәсен болай аңлата: «тәнкыйть теориясенең әдәби әсәрне һәм ул нигезләнгән чынбарлыкны шәрехләү, бәяләү принциплары һәм алымнары турындагы, тәнкыйть хезмәтендә логик-аналитик һәм әдәби элементларның үзара мөнәсәбәте һәм тәэсир итешүе турындагы, укучыга йогынты ясау алымнары бергәлеге турындагы, әдәби-тәнкыйди текстларның жанр-төзелеш структурасы турындагы бүлеге»[2].

Әдәби әсәр авторы белән китап укучы арасында арадашчы ролен үтәүче тәнкыйтьнең теориясе, бер яктан, әдәбиятка, аны аңлау, бәяләү юлларына, принципларына, икенче яктан, адресатлар буларак язучыга

---

[1] *Егоров Б.Ф.* О мастерстве литературной критики. Жанры. Композиция. Стиль. Л., Советский писатель, 1980. 317 с.; *Поляков М.Я.* В мире идей и образов: Историческая поэтика и теория жанров. М.: Сов.писатель, 1983. 367 с.; *Зельдович М.Г.* В поисках закономерностей: о литературной критике и путях ее изучения. Харьков, 1989. 160 с.; *Крылов В.Н.* Русская символистская критика (1890–1910-е гг.): генезис, типология, жанровая поэтика: дис. ... докт. филол. наук. Казань, 2007. 508 с. һ.б.

[2] *Крылов В.Н.* Русская символистская критика (1890–1910-е гг.): генезис, типология, жанровая поэтика: дис. ... докт. филол. наук. Казань, 2007. С. 48.

һәм укучыга юнәлтелгән, ягъни аларның үзара бәйләнешен, бер-берсенә йогынтысын ачыклый. Икенче төрле, әдәби тәнкыйть үсеш-үзгәрешендә үзе белән бәйләнешкә керүче төрле якларны иңләп алган система тәшкил итә.

Тәнкыйть теориясендә фәнни-теоретик тикшеренүләрнең объекты булып торган тәнкыйди язма тексты мөһим урын алып тора. Аның үзгә табигате матур әдәбият тексты белән фәнни текст арасында торуына бәйле. Ул әдәби текст кебек күпмәгънәлелеккә йөз тотмаса да, фәнни язмадагы кебек төгәллек-конкретлык белән дә аерылып тормый. Дөрес, әдәбият белемендә тәнкыйть текстының әдәбилеккә авышуы яисә якынаю турында фикерләр өстенлек итә[1]. Бердән, күптөрле фикер-карашлар уятучы әдәби әсәр турындагы язма үзе дә бертөрле генә бәяләнә алмый, икенчедән, тәнкыйть язмасында һәрвакыт диярлек әсәрдән цитаталар урын ала. Шуның белән тексттагы әдәбилек төсмере бермә-бер арта һәм текстара бәйләнеш, автор сөйләме, персонаж сөйләме кебек төшенчәләр белән байый. Югарыда әйтелгәнчә, тәнкыйть язмалары һич тә бертөрле түгел (бу жанрлар төрлелегендә дә чагыла). Шуңа күрә аерым текстлар әдәби әсәр кебек укылса (бигрәк тә «эссе», «очерк» жанрындагылары), икенчеләренең абстракт фикерләүгә нигезләнеп язылуын күрәбез (әйтик, проблемалы мәкаләләрнең байтагы). Тәнкыйть текстының үзенчәлекләрен билгеләгәндә аның әдәбият белән бәйлелегеннән тыш, кайсы аудиториягә төбәлгән булуы, нинди максат белән язылуы да зур роль уйный. Соңгысы жанрлар классификациясендә аеруча тулы чагылыш таба (бу мәсьәлә алдагы бүлекчәдә тикшерелә). Ә инде язманың нинди аудиториягә атап язылуына килгәндә, гадәттә өч төркемне аерып чыгару күзәтелә: яшьләр өчен, махсус әзерлекле (элитар) укучыга (бу төркемгә язучылар да керә) һәм киң катлам укучыны күздә тотып. Билгеле әлеге бүленеш бик тә шартлы, чөнки алар барысы да киң планда китап укучы булып торалар. Шулай да аерым язмаларда мондый бүленеш үзен шактый ачык сиздерә. Мисал өчен, Ф. Хатиповның «Иҗат серләре» мәкаләсе киң катлам укучыларга атап язылган. Автор укучысын сүз сәнгате дип аталган серле дөнья белән таныштыруны максат итә. Язмада күпсанлы мисаллар ярдәмендә әдәби әсәрнең язучы күңелендә барлыкка килүе, тормыш-чынбарлык күренешләре белән бәйлелеге, уй-фикерләрне кәгазьгә төшерү процессы, аның катлаулылыгы, әдипнең традицияләргә нигезләнүе, яңачалык-табышларга ирешү юллары

[1] *Хализев В.Е.* Интерпретация и литературная критика // Проблемы теории литературной критики. М.: Изд-во Моск. ун-та, 1980. С. 49–92; *Крылов В.Н.* Русская символистская критика (1890–1910-е гг.): генезис, типология, жанровая поэтика: дис. ... докт. филол. наук. Казань, 2007. 508 с.

һ.б. эзлекле рәвештә ачыла[1]. Ә инде М. Бакировның «Йөрәгемне былбыл чакты...» язмасы элитар укучыны күздә тотып язылган. Хезмәттә шагыйрь Зөлфәт иҗаты, теоретик төшенчәләргә нигезләнеп, сурәтле ассоциатив фикерләү үзенчәлекләрен билгеләү яссылыгында тикшерелә. Мәкалә авторы талантлы әдипне «контрастлар шагыйре» дип атый һәм аңарда төрле халәткә күчү тойгысының бик нык үскән булуын дәлилли. Әлеге фәлсәфи-диалектик һәм поэтик алымнарның Зөлфәткә табигать дөньясы, кеше рухы турындагы хакыйкатьне әйтергә мөмкинлек бирүен ача[2].

Әдәби әсәргә нисбәтле язылган текстта иҗат мәсьәләсе, аңа эстетик яктан бәя бирү теге яки бу дәрәҗәдә урын алса да, язма авторы яшәешнең күптөрле сорауларын читләтеп үтә алмый, ягъни чор-заман проблемалары фәлсәфи, әхлакый, сәяси, тарихи мәсьәләләр белән үрелеп, ялганып китә. Тәнкыйть яшәешнең рухи-иҗтимагый өлкәләре булган сүз сәнгате, фәлсәфә, эстетика, социология, психология, тарих һ.б. белән тыгыз бәйләнештә тора. Шул рәвешле «әдәби тәнкыйть, гуманитар культураның үзенчәлекле өлкәсе буларак, әдәбият белемендә генә түгел, бәлки фәлсәфәдә, тарихта, сәясәттә, социаль психологиядә ачышлар ясарга мөмкинлек бирә»[3].

Әлеге бәйләнеш гаять үзенчәлекле төс алган өлкә булып журналистика тора, чөнки ул тәнкыйтьнең гадәти яшәү, үсү-үзгәрү урыны да булып санала. XX йөз башында күпләп татарча газета-журналлар чыга башлау һәм аларда тәнкыйтькә киң урын бирелү нәтиҗәсендә тәнкыйть иҗатның бер төре буларак статус ала. Бу исә һәр текстка дип әйтерлек публицистика элементларының үтеп керүенә юл ача. Аерым очракларда исә тәнкыйтьнең публицистик тибы турында сүз алып бару мөмкинлеге туа. Мондый язмалар әдәби тормышның теге яки бу чорына юнәлтелеп, әдәби иҗатка йогынты ясаган шартлар, иҗтимагый күренешләр, чынбарлык вакыйга-хәлләре белән әсәр арасындагы бәйләнешләр һ.б. үзәккә алына. Публицистик як өстенлек иткән язмалар, гадәттә, киң катлам укучыга атала һәм аларда аны әңгәмәгә тарту, бәхәскә китерү алымнары да урын ала. Мондый текстларны бәяләгәндә социаль-иҗтимагый һәм мәдәни мохитне ачыклау белән бергә, язма структурасының үзенчәлекләрен, публицистиклыкның башка элементларга йогынтысын, чагыштырма урынын да билгеләү сорала.

Тәнкыйть әдәбият тарихы һәм сәнгатьнең башка төрләре белән тыгыз бәйләнештә яши. Әдәбият тарихын өйрәнүче, билгеле инде, үткән мирас

---

[1] *Хатипов Ф.М.* Иҗат серләре // Мөлкәтебезне барлаганда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. Б. 220–243.

[2] *Бакиров М.Х.* Йөрәгемне былбыл чакты... // Мәдәни җомга. 2000. 12 апрель.

[3] Русская литературная критика: учеб. пособие для вузов по направлению «Филология», спец. «Рус. язю и лит.». Саратов: Изд-во Сарат. ун-та, 1994. С. 5.

белән кызыксына, аны бәяли, закончалыкларын ача, системага салып тикшерә. Ул бүгенге әдәби процесска да тукталырга мөмкин һәм аны сүз сәнгатенең эзлекле үсеш-үзгәрешендәге бер этап буларак бәяли ала. Шуның кебек үк тәнкыйтьченең төп максаты хәзерге әдәби процесс күренешләрен бәяләү-аңлату булса да, ул үткәндәге әдәби фактларга, әсәрләргә, чорларга, юнәлеш-агымнарга бүгенге көн биеклегеннән, яңа концепцияләргә таянып анализ ясый, тикшерә ала. Аңлашылганча, әдәби тәнкыйть һич тә тар рамкаларда калмыйча, әдәбият тарихы, әдәбият теориясе, публицистика белән үзара йогынтылы мөнәсәбәттә була. Бу урында шуны да искәртеп китәргә кирәк, әдәбият турындагы фәннең башлангычында тәнкыйть тора. «Әдәби тәнкыйть әдәбият тарихы һәм татар нәзари фикере формалашуга җирлек әзерли; әдәбият белеменең бу тармаклары, әдәби тәнкыйть эчендә барлыкка килеп, сан һәм сыйфат үсеше кичерәләр»[1]. Мисал өчен, татар әдәби тәнкыйтенең формалашу чоры булган XX йөз башы тәнкыйтенә караган хезмәтләр бер төрле генә түгел, дөресрәге, алар синкретик характерда булып, эчтәлекләрендә һәм тәнкыйтькә, һәм әдәбият тарихына, һәм теориягә караган мәсьәләләр тыгыз үрелеп бара. Шуңа да бу чор әдәбият белеменең нигезен тәшкил иткән Җ. Вәлиди, Г. Баттал, Г. Сәгъди, Г. Ибраһимов, Г. Исхакый, Г. Тукай, Ф. Әмирхан һ.б.ның хезмәтләре әлеге өч тармакның һәркайсы үсешендә мөһим бер этап буларак бәяләнә. Алга таба аларның һәрберсе үзенең предметын, өйрәнү объектын таба һәм үзенә хас тикшеренү методларын, принципларын билгели.

Шулай итеп, тәнкыйть әдәбият белеменең мөһим бер тармагы булып тора. Аның асылын билгеләүче иҗадилык һәм фәннилек диалогик бәйләнеш тәшкил итә. Әдәби процесста җитди урын алып торучы тәнкыйть оештыру, киләчәкне күзаллау, әдипнең тел-стилен, карашфикерләрен баету, зәвыклы укучыны тәрбияләү, әйләнә-тирә чынбарлыкка йогынты ясау кебек функцияләр аша эстетик, социаль, иҗтимагый характердагы бурыч-функцияләрне тормышка ашыра. Аның табигатен, тарихи эволюциясен, сүз сәнгате әсәрләрен тикшерү юлларын, жанрларын һ.б. тәнкыйть теориясе өйрәнә. Аның төп объекты булып тәнкыйди язма тексты тора. Соңгысының үзенчәлекле табигате матур әдәбият тексты белән фәнни текст арасында торуына бәйле. Тәнкыйть текстының адресатына нигезле яшьләр өчен, махсус әзерлекле (элитар) һәм киң катлау укучыга рәвешендәге өч катлам аерып чыгарыла. Әдәби тәнкыйть яшәешнең рухи-иҗтимагый өлкәләре булган сүз сәнгате, публицистика, фәлсәфә, эстетика, социология, психология, тарих һ.б. белән тыгыз бәйләнештә тора. Тәнкыйть хәзерге әдәби процесс белән бергә үткән

---

[1] *Гыйлаҗев Т.Ш.* Рецензияләрдән тәгъзияләргә: XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. Б. 23.

мирас сәхифәләрен дә заман биеклегеннән торып бәяли, шул рәвешле әдәбият тарихы һәм әдәбият теориясе белән үзара үрелеп яши.

### 4.2. Тәнкыйтьтә торгынлык һәм аннан чыгу юлларын эзләү

Хәзерге әдәби тәнкыйтьне без, тәнкыйть тарихының эзлекле дәвамы буларак, үсеш-үзгәрешенең мөһим бер чоры дип карыйбыз. Ул үз эченә 1980 елларның икенче яртысыннан алып XXI гасыр башы аралыгындагы дәверне ала. Җәмгыятьтәге үзгәрешләр, әдәби процесс белән тыгыз бәйләнештә тәнкыйть җитди сыйфат үзгәрешләре кичерә, шуңа да әлеге чорны үз эчендә ике этапка бүләргә мөмкин: 1) 1980 еллар уртасы – 1990 еллар һәм 2) XXI гасыр башы. Мондый бүленеш бик шартлы, тәнкыйтьтәге яңачалыклар, җитди эзләнүләр 1990 еллар дәвамында бара һәм яңа гасыр башында инде үзен шактый ачык сиздерә.

Әдәби тәнкыйтьнең торышы җәмгыятьтәге иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни шартлар, гомум әдәби процесс, үткән чорлардагы тәнкыйди фикернең йогынтысы, бу өлкәдә эшләүчеләрнең теоретик әзерлеге, традицияләр дәвамчанлыгы, буыннар бәйләнеше һ.б. белән тыгыз бәйле. XX гасырның 80 нче еллары икенче яртысында җәмгыятьнең барлык өлкәләрендә башланып киткән үзгәрешләр рухи-мәдәни күренеш буларак әдәби тәнкыйть өлкәсендә эшләүчеләргә дә зур йогынты ясый. Бер яктан, демократик күренешләр иҗат ирегенә, фикер төрлелегенә юл ачса, икенче яктан, икътисади һәм иҗтимагый тормыштагы авырлыклар, идеологик ориентирларны югалту җитди каршылыклар тудыра. Әлеге билгеләр татар әдәби тәнкыйтенең үз үсешендә яңа чорга керүе турында сүз алып барырга җирлек бирә. В.Н. Коновалов билгеләп үткәнчә, «чорның әдәби тәнкыйтен социокультура факторлары һәм үзенең эволюциясе нәтиҗәсендә үсеп-үзгәреп торучы бөтенлекле система рәвешендә карарга була. Әлеге системаның үткәндәге һәм алдагы чорлардан аермасы структурасы, юнәлешләре һәм агымнары үзгәрешендә, функцияләрен үтәвенең яңа формаларында чагыла»[1].

Әдәби процесс гаять каршылыклы үсеш-үзгәреш дәверенә керә һәм тиз генә җанланып китә алмый. Моны Татарстан язучыларының 1989 елда үткән XI съезды материаллары да раслый. Җитди сөйләшүне башлап җибәрүче Ә. Еники үзенең чыгышында халык аңында зур үзгәрешләр баруын билгеләп, «без язучылар да нәкъ шушы процессны кичерәбез. Иске карашлардан әкренләп арынабыз, яңача уйларга, заманны яңача аңларга тырышабыз. Мәгәр язучы исемен йөрткән кешедә бу процесс тизрәк тә һәм тирәнрәк тә булырга тиеш, минемчә. Чөнки без үзебезнең иҗатыбыз белән турыдан-туры халыкның аңына һәм рухына тәэсир итүчеләр.(...) Ләкин татар әдәбиятының бу өлкәдә мактанырлык

[1] *Коновалов В.Н.* Литературная критика 70 – начала 80-х годов XIX века (системный анализ): дис. в виде научного докл. ... докт.филол. наук. Саратов, 1996. С. 22.

эше һич тә җитәрлек түгел әле»[1] дип күрсәтә. Әлеге фикерләрне дәвам итеп, Р. Харис та әдәбиятыбызның электән килә торган кайбер җитешсезлекләреннән арына алмавын искәртә һәм үзгәртеп корулар башлангач, «татар әдәбиятының тирән өстәл тартмасыннан элек язылган һәм үз заманын беразга узып киткәнлеге аркасында гына басылмый калган бер генә әсәр дә чыкмады дисәк тә ярый.(...) Өр-яңа әсәрләребез һәм аларда сурәтләнгән вакыт арасында дистәләрчә елларга сузылган дистанция сакланып килә»[2] дип борчыла. Тәнкыйтьче Ф. Миңнуллин исә тагын да кискенрәк: «Үзгәртеп кору дәвере, минемчә, бездәге әдәби атмосфераны бары начарайтты гына. Карьеристлар яңа шартларга һәммәбезгә караганда да тизрәк һәм яхшырак яраклаштылар.(...) Съездыбызны без критерийлар һәм чикләрнең шактый буталган бер чагында, үзебездәге иҗади атмосфераны елдан-ел ныграк югалта барган уңайсыз шартларда каршылыйбыз»[3]. Әлеге фикерләрдә чор әдәбиятына, әдәби процесска гомуми бәя чагылуын күрми мөмкин түгел.

Җанлы әдәби процесс белән турыдан-туры бәйләнгән тәнкыйтьнең дә бу чордагы үсеш-үзгәреше бертөрле генә түгел. Җәмгыятьтәге чикләүләрдән, мәдәни өлкәдәге цензурадан, соцреализм кысаларыннан арынгач та әдәбият һәм тәнкыйть өлкәсендә күтәелгән үсеш тиз генә күренми. Төп мәсьәлә, билгеле, җәмгыятьнең күчеш-үзгәреш этабында калган иҗатчы шәхесе белән бәйле. Коммунистик идеология шартларында тәрбияләнгән кешегә җәмгыятьтәге кискен үзгәрешләрне җаны һәм акылы белән кабул итеп, аларга караш-мөнәсәбәтен булдыру өчен, күрәсең, билгеле бер вакыт аралыгы кирәк була. Бу уңайдан 1984 һәм 1989 елларда үткәрелгән Татарстан язучыларының Х һәм XI съездларында әдәби тәнкыйть буенча чыгыш материалларын чагыштырып карау кызыклы. Х съездда ясаган чыгышында Т. Галиуллин тәнкыйтьнең үсеш юлында булып, күпсанлы хезмәт-мәкаләләрдә әдәби процесстагы төп тенденцияләрне ачыклау, әдәби күренешләрне чынбарлыкка бәйләп аңлату, жанрлар хәрәкәтен, сурәтлелек чараларының байый, яңара баруын бәяләү хас, дип күрсәтә. Шуның белән бергә тәнкыйть алдында торган бурычларга киң тукталып, аерым тәнкыйтьчеләр эшчәнлегенә бәя бирә һәм мондый нәтиҗәгә килә: «Ике съезд арасында активлашып, хәзер әдәби процесста торган саен мөһимрәк роль уйный барган тәнкыйтьнең (...) яңа үсеш югарылыгына күтәрелерлек потенциаль мөмкинлеге зур»[4]. Үзгәртеп корулар башланып дүрт ел узганнан соң булган XI съездагы

---

[1] *Еники Ә.* Хәерле сәгатьтә! (Татарстан язучыларының XI съездын ачканда сөйләгән сүзе) // Казан утлары. 1989. № 11. Б. 127.

[2] *Харис Р.* Әйтәсе сүзебез соңармасын // Казан утлары. 1989. №11. Б. 133–135.

[3] *Миңнуллин Ф.М.* Кичермәсләр безне, кичермәсләр… // Балта явызлар кулында. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. Б. 136.

[4] *Галиуллин Т.Н.* Тәнкыйть һәм әдәби процесс // Казан утлары. 1989. № 11. Б. 167.

чыгышында Н. Фәттах тәнкыйтьнең акрын җанлануын («без уянып, күзне ачып, уйлана-борчыла башлаганчы шактый вакыт үтеп китте») билгеле[1]. Ә бит алдагы елларда тәнкыйтьнең үсешен тәэмин итүчеләр буларак Т. Галиуллин атаган шәхесләр (М. Хәсәнов, А. Әхмәдуллин, Ф. Миңнуллин, Ф. Мусин, Х. Госман, Р. Мөхәммәдиев, Р. Мостафин, Ф. Хатипов, Ә. Мәхмүдов, М. Вәлиев, С. Маннапов һәм тагын тәнкыйть мәкаләләре белән чыгыш ясаган дистәләрчә әдип) 1980 еллар ахырында да иҗат итә.

Үзгәртеп корулар башланган чордагы тәнкыйтьнең торышы, андагы уңай һәм кимчелекле яклар Ф. Миңнуллинның 1987 елгы әдәби тәнкыйть торышына күзәтү төсендә язылган мәкаләсендә аеруча тулы чагылыш таба. Басылып чыккан монография һәм җыентыкларга тукталып, тәнкыйтьче түбәндәге кимчелекләрне аерып күрсәтә: а) фәнни хезмәтләрдә «безнең теоретиклар да тере, җанлы әдәби әсәрне сүтеп, гарипләндереп тикшерергә һәм аңлатырга яраталар»; ә) «үзләре тикшерә торган әдипнең тормыш һәм иҗат юлын шомартып, матурлап бирү»; б) «тәнкыйтьнең адресаты үтә тар, радиусы бик бәләкәй» булу, ягъни тәнкыйтьнең нигездә әдәби җәмәгатьчелек өчен, еш кына исә иҗаты тикшерелә торган язучының үзе, аның якыннары, танышлары өчен язылу; в) «әдәбият галимнәре һәм тәнкыйтьчеләр арасында әдәбиятның тар бер өлкәсендә «специальләшү», шул тар өлкәдә белгеч булып калу» тенденциясе көчәю; г) әдәбияттагы кимчелекләрне исемнәре китап сөючеләргә аз таныш булган, яңарак кына каләм тибрәтүгә алынучыларга кайтарып калдыру. Шул елда басылып чыккан китапларны эзлекле тикшергәннән соң, Ф. Миңнуллин аларның гомуми күзәтү, обзор характерында булуы, шуңа бәйле «тыныч, салмак тонлы, төссез-хиссез обзорларның елдан-ел арта, ә үткен телле проблематик хезмәтләрнең, киресенчә, торган саен кими» баруы турында нәтиҗә ясый. Китап күзәтү, рецензия, иҗат портреты кебек күпсанлы мәкаләләрне тикшереп-бәяләү аша тәнкыйтьче татар әдәби тәнкыйтенең сүрәнләнүен, шактый мөшкел хәлгә төшүен билгели. Моның сәбәпләрен ул яшәеш, иҗтимагый тормыш, милли рух белән бәйләп тикшерә. Бердән, әлеге күренеш әдәбиятыбызның хәлен аңлата дип саный ул – «әдәбиятына күрә тәнкыйте». Икенчедән, безнең халыкка хас күндәмлек, юашлык, ягъни «гражданлык хисләребез, иманыбыз нык булмау» тәэсире. «Акрынлап, торгынлык елларында урнашкан шартларга бирәүләребез – күнегә, икенчеләребез яраклаша бардык. Бу – тәнкыйтьчеләргә дә кагыла...»[2] – дип яза Ф. Миңнуллин. Шуңа якын фикерләр белән 1990 еллар дәвамында күпләр чыгыш ясый: А. Хәлим «барлы-юклы традицион тәнкыйтебез сүнеп калгандай булды» дип, М. Вәлиев «нишләп соң

[1] *Фәттах Н.С.* Гаделлек – нигез булсын // Казан утлары. 1989. № 11. Б. 160–161.

[2] *Миңнуллин Ф.М.* Бугазыңа төер тыгылмаса... // Балта явызлар кулында. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. Б. 107–123.

без үзебездә булган рухи-эстетик байлыкны күрә, аны тиешенчә бәяли алмыйбыз? дип ачынып язсалар, М. Юныс исә татар әдәби тәнкыйте «җан тәслим кылган» дип кырт кисә. З. Мансуров тәнкыйть «әдәби күренешләрне артык гади аңлатып», бу өлкәдә «нисбәт үзешчәннәр ягына авыша башлады» дигән фикер ягында. Р. Фәйзуллин «ориентир – маяклар күрсәтергә тиеш әдәби тәнкыйтебез бик зәгыйфь» дисә, Р. Сверигин тәнкыйтьнең үз функцияләреннән читләшүен күрсәтеп, аңа оеганлык хас, ди. Г. Ахунов, Ф. Бәйрәмова, А. Гыйләҗев, С. Хафизов һ.б.ның язмаларында да тәнкыйтьнең артта калуы, чор, заман таләпләренә җавап бирмәве билгеләнә. Болар барысы да гасыр ахыры әдәби процессында бу тармакның бер урында таптана башлавын, аерым мәсьәләләрдә хәтта артка чигенүен күрсәтә. Икенче төрле, татар әдәби тәнкыйте «кризис» чорына керә. Эзләнүләрнең саегу сәбәбе нәрсәдә? Бу сорауларга җавап табу өчен XX гасыр ахырындагы, төгәлрәк алганда, 1980 еллар ахыры – 1990 еллар башындагы социаль-мәдәни ситуацияне бәяләү һәм аның йогынтысын ачык күзаллау кирәк.

Иҗтимагый-тарихи, социаль тормыштан алынган «кризис» термины әдәбият-сәнгатьнең, шул исәптән тәнкыйтьнең табигатенә туры килми, шуңа да аның кулланылыш үзенчәлегенә ачыклык кертик. Югарыда әйтелгәнчә, әдәби процессның бер өлеше буларак, тәнкыйть сүз сәнгатенең, әдәбият белеменең, публицистиканың көчле тәэсирен тоеп яши. Аның үсеш-үзгәреше, бер яктан, тышкы факторларга бәйле булса, икенче яктан, эчке, ягъни традицияләр, яңачалыклар кебек факторларга барып тоташа. Беренчесе турында югарыда инде сүз булды, икенчесенә килгәндә, XX гасырның 80 нче еллар ахыры – 90 нчы еллар башы татар әдәби процессы гаять катлаулы, каршылыклы күренеш хасил итә. Чөнки татар сүз сәнгатендәге эзләнүләр, шактый ачык күренеп торган каршылыклар, сәнгати фикерләүдәге, алым-чаралардагы төрлелекләр тәнкыйтьне дә активлыкка, адекват рәвештә мөнәсәбәтен белдерергә этәрә. Әмма тәнкыйть моңа әлегә әзер булмый.

Бу урында шуны да искәртик: татар әдәби тәнкыйтенең үсеш юлындагы аерым чор-этапларда урын алган торгынлык, кризис билгеләре арасында типологик охшашлык белән очрашабыз. Әдәбияттагы кебек тәнкыйтьтә дә сыйфат үзгәреше «иске» белән «яңа» көрәшенә нигезләнеп, сүз сәнгатендәге яңа билгеләрне аңлау һәм бәяләү омтылышы рәвешендә барлыкка килә. Әдәби процесстагы чорлар үзгәреше эчке сыйфат яңарышы белән аңлатыла, ә аны чагылдыруда тәнкыйть билгеле бер каршылыкка керә. Әлеге каршылык аерым *күчеш* чорларында ачык күренеп торса, икенчеләрендә алай ук кискен булмый. Аның *беренчесе* 1920 еллар уртасында күзәтелә. Яңа идеологиягә нигезләнгән яңа тәнкыйть булдыру нияте белән бу чорда, үткән мирастан баш тарту күзәтелү белән бергә, еш кына әсәрләргә сәнгати яктан түгел, бәлки сыйнфый күзлектән

бәя бирелү башлана, яңа форма һәм эчтәлек эзләү белән мавыгу да стихияле төс ала. Шундый шартларда аерым язучылар иҗатына «әдәби судлар» оештырыла, аларда инде иҗат осталыгы, стиль үзенчәлекләре һ.б. түгел, ә әдип иҗатының заман күренешләренә, үзгәрешләргә никадәр аваздаш булуы (әйтерсең, ул сәнгатилекнең төп билгесе) алгы планга куела. Тәнкыйть язмалары кискен, хәтта усал булулары белән аерылып тора. Авторлар еш кына теге яки язучының иҗатын тикшереп бәяләүдән бигрәк, аның шәхесе, социаль чыгышы, идеологик карашлары, совет системасына лояльлеге һ.б. белән мавыга. Шундый шартларда тәнкыйть асыл сыйфатын, төп таләп-шартларын үзгәртә, әдәбиятка сәнгать әсәре булудан бигрәк идеология чарасы итеп кенә карый башлый. Нәтиҗә буларак, 20 нче еллар ахырына вульгар-социологик тәнкыйть өстенлек ала һәм озак вакытларга әлеге тармакның үсешен тоткарлый. Татар әдәби тәнкыйтендә *икенче* «кризис» 1940 еллар ахыры – 1950 еллар башында күзәтелә. Сәбәпләре турында уйланганда, эчке һәм тышкы шарт-факторларның булуы күренә. Бөек Ватан сугышы елларында әдәбият үзенчәлекле үсеш кичерә. Бер яктан, идеологик басым кими, йомшара, соцреализм эстетикасы яңа төсмерләр белән байый, икенче яктан, сугыш шартлары, шуңа бәйле патриотик, әхлакый һәм гуманистик идеалларның алга чыгуы, аларның үзенә хас сәнгати алым-чаралар таләп итүе һ.б. сүз сәнгатендәге сыйфат үзгәрешләрен тәэмин итә. Сугыштан соңгы елларда әдәбият әкренләп үз агымына кайта. Сугышта җиңеп чыгуны, илдәге үзгәрешләрне Сталин исеме белән генә бәйләү, социалистик системаны төрлечә мактау һ.б. әдәбиятка да үтеп керә. Бу исә, гадәттә, тормыш каршылыкларын шомартып, киләчәк матурлыгын күпертеп сурәтләүгә китерә. «Язучыларга әсәрләренә кемнәрне герой итеп алу һәм нинди темаларны яктырту кирәклеге турында күрсәтмәләр бирү, аларның эше белән администраторлык рухында җитәкчелек итәргә тырышу кебек кимчелекләр һәм ялгышлар булды»[1]. Шундый шартларда әдәбиятта «конфликтсызлык теориясе» өстенлек ала һәм ул әдәби тәнкыйтьтә дә күзәтелә. Бу чор әдәбиятының һәм тәнкыйтенең «көпшәкләнүенә» китергән сәбәпләр арасында, билгеле инде, ВКП(б) ҮК ның әдәбият-сәнгать мәсьәләләре буенча кабул ителгән, аерым алганда, 1944 елгы «Татарстан партия оешмасында масса-политик һәм идеологик эшләрнең торышы һәм аларны яхшырту чаралары турында», 1946 елгы «Звезда» һәм «Ленинград» журналлары турында карарлар бар. Беренчесенә бәйле татар халкы тарихын объектив сурәтләү тыелу белән бергә, әсәрләрне бәяләүдә цензураның тагы да көчәюе күзәтелсә, икенче карар гомумән әдәбият эшендә партия җитәкчелегенең, идеологик басымның артуына китерә. Әдәби тәнкыйть үсешендә *өченче* «кри-

[1] *Гыйззәтуллин Н.* Әдәби хәрәкәт // Татар әдәбияты тарихы: алты томда. V т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 177.

зис» 1960 еллар башына туры килә (алдагылар белән чагыштырганда күпкә «йомшак»). Билгеле булганча, «Хрущев җепшеклеге» йогынтысындагы демократик күренешләр дулкынында сүз сәнгатенә «яңа дулкын» килә һәм барлык төрләрдә дә сыйфат үзгәрешләренә нигез салына. Әдәби тәнкыйть исә яңалыкларны тиз генә күреп, аңлап бетерә алмый. Мисал буларак, Р. Фәйзуллинның фәлсәфи-лирик эчтәлек белән һәм яңа формаларга йөз тотып язылган шигырьләре тәнкыйтьтә каршылыклы бәяләнүен (хәтта Х. Туфанның да аларны тиз генә кабул итмәвен) искә төшерик, А. Гыйләҗевның «Өч аршын җир» кебек әсәрен эчке тәнкыйтьнең гомумән кире кагуын, бары «Дружба народов» журналында рус телендә бастырырга мәҗбүр булуын билгеләп үтү дә җитә. Бу уңайдан Р. Кутуйның «Литературная газета»да чыккан «Поэзия дип нәрсәне атарга?» мәкаләсе игътибарга лаек[1]. Зур кызыксыну уяткан язма җитди бәхәсләр китереп чыгара. Аның асылы шул чор шигъриятендәге яңа тенденцияләргә мөнәсәбәт белән бәйле. Автор традиция һәм яңачалык мәсьәләләрен берьяклы гына аңлавын күрсәтеп, яңалыкны, димәк, әйдәп баручы тенденцияне иректә шигырь формасы белән эш итүчеләргә генә кайтарып калдыра. Н. Юзиев язганча, «Р. Кутуйның байтак фикерләре белән шагыйрьләр һәм тәнкыйтьчеләр хаклы рәвештә килешмәделәр. (...) Хәзерге поэзиядәге новаторлыкны тик иректә шигырь белән язучыларда гына күрүе дә мәсьәләне үтә тарайтып аңлатуга кайтып кала»[2]. Дөрес, бу чор тәнкыйте бертөрле генә булмый, «иске» тәнкыйть янында «яңа» тәнкыйть тә шактый тиз аякка басып, ныгып китә.

1980 еллар ахыры – 90 нчы еллар башында татар әдәби тәнкыйте үзенең үсеш-үзгәрешендә тагын «торгынлык» чорына керә. Моңа китергән шартлар турында сүз алып барганда, беренче чиратта, күчеш чоры үзенчәлекләрен искә алу кирәк. Югарыда күрсәтелгән тышкы факторлардан тыш эчке шартлар – шәхеснең аңындагы үзгәрешләр, шулай ук әдәбият-сәнгатьнең торышы, заман таләпләренә, рухи ихтыяҗларга ни дәрәҗәдә җавап бирүе, традицияләр дәвамчанлыгы һәм яңачалыкларга омтылышы һ.б. зур әһәмияткә ия. «Әлбәттә, “үзгәртеп кору”ның майлаган кебек кенә баруына өмет итү беркатлылык булыр иде, шулай да ул бик озакка сузылды, көтелмәгән авырлыклар белән бара, – дип яза А. Әхмәдуллин. – Бу шартларда шәхеснең үз урынын билгеләүдә, рухын сынауда, психологик кичерешләр казанында кайнауда булган үзенчәлекле сыйфатларын әдәбиятта чагылдыру “перестройка”ның серләрен, максатын, бурычларын, үзенчәлекләрен тирән күзаллауны һәм, әлбәттә инде, зур талант көчен сорый»[3]. Нәкъ менә күчеш чоры иҗтимагый аңда

[1] *Кутуй Р.* Что назвать поэзией? // Литературная газета. 1964. 3 декабря.

[2] *Юзиев Н.Г.* Традицияләр яңарганда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1966. Б. 4.

[3] *Әхмәдуллин А.Г.* Бүгенге татар драматургиясенең кайбер үзенчәлекләре // Мирас. 2004. № 2. Б. 88.

каршылыклы халәт китереп чыгара. Бер яктан, иске карашлардан арынып җитмәү, икенче яктан, яңачалыкка омтылыш күзәтелеп, ике катлам барлыкка килә. Ул исә иҗат эшендә аеруча кискен чагылыш таба. Татар әдәбияты һәм сәнгате җитди каршылыклар этабына керә.

XX гасырның 80 нче елларыннан соңгы татар әдәбиятының үсеш-үзгәреше нәрсә белән характерлана соң? Р. Мостафин «Чорлар чатындагы үзгәрешләр» дигән язмасында җәмгыятьтә үзгәртеп корулар башланганнан соңгы чорда әдәбияттагы яңалык-үзенчәлекләрне түбәндәгеләрдә күрә: 1) идеология үзгәрү нәтиҗәсендә күп әдипләрнең аптырап калуы; 2) цензураның юкка чыгуы, тулаем алганда, сүз, матбугат иреге бирелү; 3) җәмгыятьтә дингә карашның уңай якка үзгәрүе; 4) публицистиканың киң үсеш алуы; 5) классик мирасыбызның әйләнеп кайтуы һәм 6) үткән тарихыбызга игътибар арту һ.б. Тәнкыйтьче совет чорындагы «уңай герой» урынына җыен вак җаннарны күрсәтергә омтылуны бер чиктән икенчесенә ташлану дип билгеләп, болай яза: «Әдәби персонажларыбыз вакланды, үрнәк булырлык геройларыбыз бөтенләй юкка чыкты». Әдәбиятның китап укучыны тәрбияләүче, тормышына юнәлеш биреп торучы рухи көч буларак читләшүенә нигезләнеп нәтиҗә ясый: XX гасыр азагында – XXI гасыр башында татар әдәбияты бик авыр чор – кризис чоры кичерә»[1].

Тәнкыйтьнең үз позицияләрен югалтуына китергән объектив сәбәпләрнең берсе булып XX гасырның 70–80 нче елларында әдәбиятка, шул исәптән тәнкыйтькә килүчеләрнең саны аз булу, ике буын арасында билгеле бер күләмдә бушлык барлыкка килү тора. Икенче яктан, Г. Халит, И. Нуруллин, Ф. Миңнуллин, Ф. Зөлкарнәй кебек үзенчәлекле әдәби зәвыкка ия булган, гражданлык позицияләрен яклый белүче, тирән эзерлекле шәхесләребезне, профессиональ тәнкыйтьчеләребезне югалту да эзсез калмый билгеле. Сәбәпләрнең тагын берсе реалистик тәнкыйть кризисы белән бәйле. Әдәбиятны бәяләүдә калыплашкан принциплар чор үзгәрешләре тәэсирендә дөнья күргән әсәрләрне анализлауга нигез була алмый. Мондый омтылышларның байтагы уңышка ирешми, әсәрләрдә чагылыш тапкан сәнгати фикерләү үзенчәлекләре читтә кала. Бу исә язучыларда да ризасызлык уята. Татар әдәбиятының реалистик һәм романтик юнәлештәге тирән сыйфат үзгәрешләрен, шулай ук модернистик алымнарга нигезләнгән эзләнүләрне әдәби тәнкыйть аңлап кабул итүгә, бәяләүгә күтәрелә алмый. Шуңа да бу еллар сүз сәнгатенең йөзен билгеләргә тиешле Роб. Әхмәтҗанов, К. Сибгатуллин, Ф. Бәйрәмова, А. Хәлим кебек әдипләрнең иҗаты үз бәясен алмый, нәтиҗәдә әдәби процесстагы урыннары да объектив билгеләнми.

---

[1] *Мостафин Р.Ә.* Чорлар чатындагы үзгәрешләр // Казан утлары. 2004. № 5. Б. 146–150.

Күчеш чоры әдәби тәнкыйтьтә җитди каршылыклар китереп чыгарса да, аның хәл-торышы һич тә бертөрле булмый. Киң планда 1980 еллар ахыры – 1990 еллар эзләнүләренең саегуы, аналитик тәнкыйтьнең кимүе, әдәби процессны эзлекле бәяләп бара алмавы белән характерланса, бер үк вакытта «яңа тәнкыйть» үсеп китүгә җирлек тә әзерләнә. Чор-җәмгыять үзгәрешләрен, әдәби процесс үзенчәлекләрен үз вакытында тоемлаган, аңлаган, бәя биргән, мөһим нәтиҗәләргә килгән тәнкыйди язмалар да дөнья күрә. Аерым алганда, 1988–1989 елда «Казан утлары» журналы тарафыннан үткәрелгән «Заман һәм шагыйрь» дигән фикер алышуда шул чор татар шигърияте, анда заман алып килгән үзгәрешләрнең чагылышы, гомумән, татар әдәбиятының торышы мәсьәләләре үзәктә тора. Сөйләшүдә катнашкан М. Вәлиев, М. Шабаев, Г. Рәхим, Ф.Зөлкарнәй, Г. Гыйльманов, Ә. Баянов, З. Низаметдинов, М. Гайнетдинов һ.б.ның мәкаләләрендә шигъри көчләребезне барлау, поэзия үсешенең төп юнәлешләрен, поэтик үзенчәлекләрне ачыклау омтылышы ачык сиземләнә. Хезмәтләрдә кыю фикерләр, принципиаль мәсьәләләр, әдәбиятта хөкем сөргән икейөзлелек, әшнәлек, кода-кодагыйлык күренешләре өчен тирәнтен борчылу чагылыш тапса да, алар гомуми планда гына аталып, конкрет исемнәр, әсәрләр белән дәлилләнмәгәнгә, үзенчәлек-тенденцияләр аерып чыгарылмаганга, яңгыраш алмый. Шуңа да Н. Фәттах «Казан утлары»нда бара торган бәхәс-дискуссияләрне дә «әйткәләшү» генә дип атый[1]. Аның фикеренчә, тәнкыйтьтә чын язучы белән графоман һәм һәвәскәрләрне аеру, иҗатларына объектив һәм тулы бәя бирү юк. Ә бу исә татар әдәбиятында таләпләрнең кимүенә һәм аның гомумән уртакул дәрәҗәсенә төшеп калуына китерергә мөмкин. Шул ук вакытта арада Ф. Зөлкарнәев һәм Г. Гыйльманов мәкаләләренең фәннилеге, фикри җегәре, фактик материалның байлыгы белән аерылып торуын да билгеләп үтү кирәк. Ф. Зөлкарнәев поэзиянең торгынлыкта булуын билгеләп, «һаман кузгалып китәргә кыймый торган үшән йөк атын хәтерләтә», ди. Озак вакытлар дәвамында сакланып килгән чикләү-тыюлар, түбәнсетү-рәнҗетүләр (бигрәк тә адым саен милләтчелектә гаепләүләр), провинциаль фикерләү рәвеше буларак, кыюсызлык, чикләнгәнлек, мәнфәгатьләр тарлыгы сыйфатында калкып чыга. 1980 еллар ахыры шигъриятендәге җитешсезлекләрнең берсе итеп ул «тормыштагы яңарыш, үзгәрешләр чагылуы» җитәрлек булмауны күрсәтә. Ф. Зөлкарнәев шигърияттә уртакул шагыйрьләрнең, кәсепчеләрнең артуы өчен борчыла. Моның сәбәбе, билгеле, озак еллар дәвамында рухи-эстетик ихтыяҗларның канәгатьләндерелмәве. «Уртакул чамага гына исәпләнгән кысан әдәби пространство, һичшиксез, барыннан да элек уртакул, әрсез-усал каләм әһелләрен

[1] *Фәттах Н.* Гаделлек – нигез булсын! // Казан утлары. 1989. № 11. Б. 160.

формалаштыруга хезмәт итә», – дип яза ул. Тәнкыйтьче шигъриятнең яңалыкларга тиз генә ияреп китмәү сәбәбен халыкның, әдәбиятның үзенчәлегендә күрә. Күптөрле фаҗигале чорларны кичергән милләтнең үзенә хас менталь сыйфаты буларак һәрнәрсәгә сак якын килүен, ашыкмауны яклавын да билгеләп үтә[1].

Г. Гыйльмановның «Заман тойгысы бармы?» язмасы шигъри тәнкыйть алдында торган бурычларны ачыклау омтылышы белән кызыклы. Ул болай дип яза: «Бүгенге тәнкыйтьтә татар поэзиясенең асыл йөзе күпчелек очракта һәвәскәр шагыйрьләр иҗаты белән билгеләнә икән. Икенчесе: бүгенге поэзия тәнкыйте «ялкынсыз», «тешсез», «предметсыз» икән...» Монда еш кына газета-журнал редакцияләренең, аерым шагыйрьләрнең тәнкыйтькә карата үтә «сугышчан» позициясе зур йогынты ясавын да искәртеп үтә тәнкыйтьче[2].

Мондый үрнәкләрне дәвам итәргә мөмкин булса да, тагын бер мисал белән чикләнәбез. Т. Галиуллин татар шигъриятенең язмышы турында борчылып язган «Шигырь кемгә кирәк?» дигән язмасында әлеге иҗат төренең асылы, аның халык язмышы, мәнфәгате белән аерылгысыз булырга тиешлеге турындагы теоретик фикерләре белән уртаклашканнан соң, конкрет мисалларга нигезле аерым уңышларны, аннан да бигрәк борчыган мәсьәләләрне күтәрә. «Халык елмаеп сөйләү, аның язучысы исә кычкырып көлү сәләтен югалтып бара икән», – дип яза ул һәм аеруча тирән борчылу белән сәяси сатираның «сәхнәдән үк төшеп китүен» күрсәтә. Шигърият тәнкыйтенең артта калу сәбәпләреннән әдипләр арасындагы мохитне дә атый: «Үз иҗатына ераккарак китеп карау сәләтен югалткан исемле шагыйрьгә сүз әйтү дә куркыныч». Автор шигъриятнең хәл-торышына нисбәтле «яңачалык, кыюлык җитешмәү, фикерләүдәге торгынлык, элек ачылган юлдан атлау укучыны югалтуга алып килә» дип нәтиҗә ясый[3]. Әнә шундый эчке көрәш, тартыш фонында әдәби тәнкыйтьнең эзләнүләр юнәлешендә үсеп-үзгәрүе күзәтелә. Ул исә, беренче чиратта, әдәби процесс, аерым алганда, сүз сәнгатенең торышы, эзләнүләре белән тыгыз бәйле.

1980 еллар уртасында башланып киткән үзгәртеп корулар тәэсирендә татар әдәбияты үз үсешендә сыйфат үзгәрешләре кичерә. Милләт язмышы мәсьәләсенә бәйле үткән тарихка, традицияләргә, тел саклanышына, милләтнең бүгенгесенә һәм киләчәгенә кагылышлы күпсанлы проблемалар киң планда яктыртыла. Әдәбият тарихындагы «ак таплар» бетерелеп, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Г. Рәхим һ.б.ның аерым әсәрләре, барыннан да бигрәк Г. Исхакый мирасы кайтарыла. Чит илләрдәге

---

[1] *Зөлкарнәев Ф.* Сабыр төбе алтынмы? // Казан утлары. 1989. № 2. Б. 165–173.
[2] *Гыйльманов Г.Х.* Заман тойгысы бармы? // Казан утлары. 1989. № 3. Б. 168–174.
[3] *Галиулин Т.* Шигырь кемгә кирәк? // Казан утлары. 1995. № 7. Б. 139–142.

татар әдәбиятының матур үрнәкләре дөнья күрә. Нигездә реалистик һәм романтик юнәлешкә йөз тоткан татар сүз сәнгате модернистик агымнарга, алым-чараларга иркен мөрәҗәгать итә башлый.

1990 еллар дәвамында «яңа дулкын» әдәбиятын аңлата, бәяли алырлык, табышларны билгеләрлек, эзләнүләр юнәлешен ачарлык яңа тәнкыйть кирәклеге көн тәртибендә торып, вакытлы матбугатта чагылыш таба. Киң планда караганда әдәбият казанышлары белән тәнкыйди-эстетик фикер арасында җитди аерма килеп чыга. Шундый шартларда әдәби тәнкыйть үсешенә таяныч булган публицистиканың җанлануы күзәтелә. Дөрес, 1980 еллар ахырына кадәр әле ул пыскып кына янган утны хәтерләтә. Т. Миңнуллин билгеләп үткәнчә, «бу жанрда безнең темалар төрлелеге җитми, проблемаларның киңлеге һәм тирәнлеге канәгатьләндерми»[1]. Публицистиканың чын-чынлап күтәрелеше Татарстан суверенитет турында Декларация (1990) кабул иткәннән соң башлана. «Сиксәненче елларның икенче яртысында – туксанынчы елларның башында әдәбиятыбызның публицистика тармагы бик нык үсте, аякка басты дип әйтергә кирәк, – дип яза Р. Мостафин. – Бер Айдар Хәлимнең ялкынлы публицистикасы гына да ни тора! Шулай ук Фәүзия Бәйрәмова, Әмир Мәхмүдов, Әхмәт Рәшитов, Рафаэль Хәкимовларның чыгышлары суверенитет өчен көрәш барганда үз ролен уйнады, халыкның аңын агартуда зур әһәмияткә ия булды»[2].

Билгеле, агымдагы әдәби тәнкыйтьнең җанлануы иң беренче чиратта республикадагы басмаларга, аларның тулаем әдәбиятка һәм әдәби процесска, шул исәптән әдәби тәнкыйть язмаларына теге яки бу дәрәҗәдә «җылы» караштa булуларына бәйле. Хәбәрдарлык, сүз һәм матбугат иреге күпсанлы газета-журналларның дөнья күрүенә китерде. Моңа кадәр чыгып килгән «Казан утлары», «Ватаным Татарстан» («Социалистик Татарстан»), «Сөембикә»(«Азат хатын»), «Татарстан яшьләре» кебек газета-журналлардан тыш, 80 нче еллар ахыры – 90 нчы еллар башында ике телдә яшьләр өчен «Идел», шулай ук «Мирас», Аргамак», «Казан» журналлары һәм «Мәдәни җомга», «Татарстан хәбәрләре», «Заман-Татарстан» газеталары чыга башлау һәм аларның барысында да диярлек әдәби тәнкыйтькә багышланган махсус бүлек-рубрикалар ачылу әдәбият белеменең бу тармагына киң мәйдан бирде. Яңа гасыр башында Чаллыда «Мәйдан», Казанда «Сәхнә» журналлары оешу әлеге мөмкинлекне тагы да арттырды. Икенче яктан, ил тормышындагы вакыйгалар кешенең дөньяны күзаллавына, кабул итүенә, эстетик аңга һәм әдәби иҗатка көчле йогынты ясады. Бу яктан алып караганда, ягъни әдәби тәнкыйть язмаларына теге яки бу басмада урын

[1] *Миңнуллин Т.* Каләмебез, сүзебезне эшкә җигик! // Казан утлары. 1989. № 11. Б. 129.
[2] *Мостафин Р.Ә.* Чорлар чатындагы үзгәрешләр // Казан утлары. 2004. № 5. Б. 147.

бирү ягыннан алганда «Казан утлары» журналы белән «Мәдәни җомга» һәм «Шәһри Казан» газеталары бигрәк тә аерылып тора. Соңгы вакытта бу рәткә «Мәйдан» журналы да килеп кушылды. Әлеге басмалар, әдәби тәнкыйтьне җанландыру максатыннан чыгып, «Түгәрәк өстәл» сөйләшүләре уздыралар, әдәби темаларга анкеталар булдырып, анда куелган сорауларга күренекле әдипләрнең кызыклы, мәгънәле, еш кына каршылыклы җавапларын урнаштыралар. Бәхәсләр һәм дискуссияләр дә матбугат битләрендә даими үткәрелә. Мондый чаралар, әлбәттә, әдәбиятыбызга кагылган рухи-эстетик фикерне җанландыра, сафта күренгән азмы-күпме кадрларны шушы юнәлештә уйланырга һәм үзләренең фикри-эстетик куәтләрен сынап карарга этәрә.

Әдәби тәнкыйтьнең торышын, үсеш-үзгәрешен традицияләр яктылыгында карау табигый һәм зарури, чөнки XX йөз башы, шулай ук тоталитаризм чоры (1917–1950 еллар ахыры) һәм тоталитаризмнан соңгы чор (1950 еллар ахыры – 1980 еллар уртасы) әдәбиятының иң үзенчәлекле сыйфатларын шактый тулы чагылдырып, тәнкыйть теориясендә дә билгеле бер табышларга ирешелде. Аларны, ягъни каршылыклы үткәнебезне белми торып, бүгенгене тулы, ачык бәяләү һәм киләчәккә үсеш юлларын билгеләү мөмкин түгел. «Җәмгыятьтәге үзгәрешләргә һәм халык характерының тарихи үсешенә бәйле рәвештә традицияләр һәрвакыт үзгәреп, яңарып торалар. Традиция ул үткәннең казанышларын гади кабатлау гына яки үзгәрешсез генә терелтү түгел. Традиция белән бәйләнешнең бердәнбер чарасы – аны дәвам итү, үстерү. Ә традицияне баету, дәвам итү үзеннән-үзе новаторлыкка илтә. Шушы мәгънәдә традиция новаторлыкны тудыра, ә новаторлык традицияне баета дип әйтә алабыз»[1], – дип яза Н. Юзиев. Сүз сәнгатенә нисбәтле әйтелгән әлеге фикерләр әдәби тәнкыйтькә дә карый.

Бу чор тәнкыйтенең каршылыклы үсешенә китергән, яңа эзләнүләргә этәргән сәбәпләр арасында аның үткән традицияләрнең билгеле бер өлешеннән баш тартуы тора. Белгәнебезчә, 1960–1980 елларда тәнкыйтьтә язучыларны тематикага нисбәтле теге яки бу төркем вәкиле итеп аеру, бүлү күзәтелде: «авыл прозасы», «производство темасы», «яшьләр темасы», «интеллигенция темасы», «сугыш темасы», «әхлак һәм мәхәббәт темасы» һ.б. Яңа чор әдәбияты исә мондый бүленешкә материалны аз бирә башлады. Киресенчә, модернистик эзләнүләр, үзенчәлекле алым-чараларга омтылу, мифология, фольклор белән тыгыз бәйләнеш һ.б. тәнкыйтьчеләрне дә яңа юллар-алымнар эзләргә этәрә. Бу исә термин-төшенчәләрнең дә үзгәрүенә китерә.

XXI гасыр башы татар әдәби тәнкыйтендә бигрәк тә «яңа дулкын» авторларга игътибар арту күзәтелә. Киң катлау укучылар теленә

---

[1] *Юзиев Н.Г.* Традицияләр яңарганда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1966. Б. 8.

Н. Гыйматдинова, Г. Гыйльманов, Ф. Сафин, В.Имамов, М. Кәбиров һ.б. исемнәре килеп керә. Аларның иҗатын еш кына традицион реалистик әдәбиятка каршы куеп карау да урын ала. Тәнкыйтьтә публицистик башлангычның артуы бик күп тормыш материалы, төрле факт-хәлләрнең урын алуына, бай мәгълүматка мөрәҗәгать итүгә, шуларга бәйле бәхәс элементларын киң куллануга китерә. Аерым алганда партиялелек, соцреализм, совет әдәбияты төшенчәле буенча бәхәсләр булып уза. XX гасырның беренче чирегендә дөнья күргән, төрле графикада язылу аркасында моңа кадәр читтә калып килгән бай тәнкыйди мирасның киң катлам укучыларга килеп ирешүе, чит илләрдәге татар әдәбиятының, анда урын алган тәнкыйть материалларының кайтуы да тәнкыйтьнең торышына билгеле бер йогынты ясый, җанлылык тудыра[1].

Шулай итеп, җәмгыятьтәге үзгәртеп корулар әдәби тәнкыйтькә дә көчле йогынты ясый. Иҗат ирегенә, фикер төрлелегенә юл ачылу белән бергә, социаль-мәдәни тормыштагы авырлыклар, шулай ук идеологик ориентирлар югалу җитди каршылыклар тудыра. Татар әдәбиятында торган саен киңрәк урын алучы сәнгати эзләнүләрне, яңа караш-концепцияләрне, алым-чаралар байлыгын әдәби тәнкыйть ачып-аңлатып бетерә алмый, ягъни ул кризис этабына керә. Аның тышкы һәм эчке сәбәпләре арасында күчеш чоры үзенчәлекләре, реалистик тәнкыйтькә генә йөз тоту, шулай ук калыплашкан принципларның яңа төр әсәрләрне анализлауга нигез була алмавы, аналитик тәнкыйтьнең үз позицияләрен югалтуы, тәнкыйтьчеләр буыны алмашыну һ.б.ны күрсәтеп була. Шул ук вакытта эчке көрәш, тартыш фонында «яңа тәнкыйть» үсеп китүгә җирлек тә әзерләнә. Аерым алганда, әсәрләргә бәя бирү принципларының яңа алымнар белән баетылуы, әдипләрнең актив рәвештә тәнкыйть белән шөгыльләнүе, үткән еллар әдәби тәнкыйтен яңача бәяләү омтылышлары арту, шуңа нисбәтле әдәбиятның һәм тәнкыйтьнең бурычлары, функцияләре, гомум мәдәни тормыштагы урыны турында бәхәсләр көчәю, тәнкыйтькә яңа авторлар килү һ.б. ике гасыр чиге татар әдәби тәнкыйтендәге яңачалыкларның нигезе булып тора. Гомумән, күчеш чоры әдәби тәнкыйте җитди каршылыклар белән барса да, аның хәл-торышы һич тә бертөрле генә булмый. Болар барысы да татар әдәбият белемендә тәныйтьнең яңа эчтәлек белән баюы турында сүз алып бару мөмкинлеге бирә.

---

[1] *Миңнегулов Х.Й.* Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 367 б.; *Миңнегулов Х.Й.* Дөньяда сүземез бар... Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 336 б.; *Закирҗанов Ә.М.* Яңа җилләр исәме? (Соңгы еллар әдәби тәнкыйтенә бер караш) // Казан утлары. 2001. N6. Б. 95–101; *Әхмәдуллин А.Г.* Күңелләрне уятыр: Хәзерге татар драматургиясе. Казан: Мәгариф, 2007. 223 б. һ.б.

## 4.3. Хәзерге әдәби тәнкыйтьтә фәнни-теоретик һәм фәлсәфи-эстетик карашлар

Сүз сәнгатенең үсеш-үзгәрешен өйрәнү аны танып белүнең методологиясен, принципларын, бу өлкәдәге фәнни ачышларны нигезләүче концепцияләрне ачуны таләп итә. Шуңа нисбәтле әдәбият белемендә, шул исәптән әдәби тәнкыйтьтә юнәлеш, агым, мәктәп, метод кебек терминнар формалаша.

XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте гаять зур әдәби-эстетик, фәнни-методологик үсеш ясый. Кыска гына вакыт аралыгында ул үз предметын булдырып, аның бурыч-вазифаларын, функцияләрен, үзенә хас алым-чараларын булдыра. Бу юлда ул Шәрык һәм Гареб әдәбият белеме казанышларыннан иркен файдалана, алардагы табышларны татар әдәбиятына бәйле эшкәртә[1]. Аның өлгергәнлек билгесе буларак тәнкыйтьнең юнәлеш-төрләре формалашу да күзәтелә. XX йөз башында татар әдәби тәнкыйте реалистик һәм романтик тәнкыйтькә хас принципларга нигезләнә. Т. Гыйләҗев язганча, Ф. Әмирхан, Г. Исхакый, Г. Гобәйдуллин, Х. Искәндәров һ.б. хезмәтләрендә реаль чынбарлыкны тулы һәм дөрес чагылдыру, җанлы һәм тормышчан образлар, табигый типлар тудыру кебек мәсьәләләрнең үзәккә алынуы реалистик әдәби тәнкыйть барлыкка килүне күрсәтә. Ә инде Г. Исхакый, Җ. Вәлиди, Н. Думави кебек тәнкыйтьчеләрнең сәнгатьчә фикерләве эстетик (романтик) тәнкыйть формалашу турында нигезле сүз алып бару мөмкинлеге бирә[2].

XX йөз башы татар әдәбияты модернизм агымнарына да шактый иркен мөрәҗәгать итә. М. Хәнәфи, Ф. Әмирхан һ.б. үз әсәрләрендә кеше яшәешенең аерым мизгелләрен, яисә чиктәш халәтен чагылдырган вакыйга-күренешләрне чагылдыралар. Экзистенциализм, импрессионизм, символизм кебек агымнарга нисбәтле язылган әсәрләр шуңа туры килә торган, әлеге яңа иҗат принципларын аңлаткан тәнкыйть юнәлеше һәм агымының мәйданга килүенә дә сәбәпче була. Д. Заһидуллина билгеләп үткәнчә, «әдәби тәнкыйть тә аерым авторлар иҗатына мөнәсәбәтле модернизмның кайбер сыйфатларын аерып күрсәтүгә ирешә». Әмма яңа агым тарафдарлары тәкъдим иткән гомумкешелек фәлсәфәсен «милли ихтыяҗлар, милли форма белән кушу

---

[1] XX йөз башында барган һәм 1920 елларда да Г. Нигъмәти, Г. Сәгъди һ.б.ның хезмәтләрендә киң чагылыш тапкан «Шәрыкме – Гаребме?» турындагы бәхәсләрдән соң, татар әдәбият белемендә, шул исәптән тәнкыйтьтә рус-Европага йөз белән борылу күзәтелә. Моңа илдәге сәяси һәм идеологик мохит тә зур йогынты ясый. Гасыр дәвамында татар әдәби тәнкыйте рус сүз сәнгатенең һәм тәнкыйтенең иң яхшы үрнәкләрен өйрәнеп, тәҗрибәләрен файдаланып килә.

[2] *Ганиева Р.К.* Татарская литература: традиции, взаимосвязи. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. 272 с.

юлында ярдәмче булырга тиешле әдәби-нәзари фикер әлеге бурычны үтәп чыга алмый»[1].

1920–1930 елларда гаять каршылыклы үсеш юлына чыккан әдәби тәнкыйтьтә көчле бәхәсләр бара. Әдәбият-сәнгать максатчан рәвештә идеологиягә буйсындырыла, социаль заказ белән язу гадәти хәлгә әйләнә, ягъни вульгар-социологизм дип аталган күренеш өстенлек ала. Әлеге чорны фәнни нигездә өйрәнгән Ф. Галимуллин «Эстетика һәм социологизм» дигән хезмәтендә әдәбияттагы эстетик кануннарның, аның эчке закончалыкларының, матурлыкка, гомумкешелек кыйммәтләренә хезмәт итүче асыл вазифасының әсәр эчтәлеген сыйнфый мәнфәгатьләргә буйсындырган, миллилекне, бай тарихыбызны, атаклы шәхесләрне инкарь иткән, әдәби мирасны, гаҗәеп бай традицияләрне кире каккан социологизм тырнакларында эләгеп калуын, әдәби-эстетик эзләнүләргә никадәр зыян салуын, кайвакыт фаҗигаләргә китерүен конкрет мисалларда ача[2].

Киң планда караганда совет чорында тәнкыйтьнең иң югары формасы, иң объективы булып марксистик тәнкыйть санала. Бу исә дөнья әдәби тәнкыйтендә киң таралыш алган, XX йөз башы татар тәнкыйте дә чит итмәгән тәнкыйть юнәлеш-агымнарын, нигездә, кире кагуга, читләтеп үтүгә яисә реалистик һәм романтик тәнкыйть кысаларында карауга китерә. Шуңа да 1990 еллардан башлап төрле тәнкыйть типларын, формаларын барлау, кире кайтару, аклау башлана. Мисал өчен, Д. Заһидуллина, Э. Галиева, Г. Азизова, Т. Гыйлаҗев, Ч. Гыйлаҗева хезмәтләрендә XX йөз башында һәм 1920–1930 елларда татар әдәби тәнкыйтенең аерым юнәлеш-агымнарга нигезләнүе, фәнни нәтиҗәләргә ныклы җирлек әзерләве ачыклана[3]. Т. Гыйләҗев билгеләп үткәнчә, «1920–1930 еллар татар әдәби тәнкыйте татар эстетик һәм иҗтимагый фикере үсеше тарихында табигый һәм закончалыклы баскыч буларак бәяләнергә хаклы[4].

А. Саяпованың «Дәрдемәнд поэзиясе һәм символизм» китабында XX йөз башы татар әдәбиятында символизм күренешенең җирләшүе

---

[1] *Заһидуллина Д.Ф.* Әдәбият кануннары һәм заман. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. Б. 255–257.

[2] *Галимуллин Ф.Г.* Эстетика һәм социологизм: 20–30 нчы еллар татар әдәбиятында эстетика кануннарының һәм социологизм таләпләренең үзара мөнәсәбәте. Казан: Мәгариф, 1998. 223 б.

[3] *Заһидуллина Д.Ф.* Әдәбият кануннары һәм заман. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. 271 б.; *Галиева Э.Р.* Татар әдәбият белемендә культура-тарих мәктәбе. Казан: Фән, 2002. 360 б.; *Саяпова А.М.* Дардменд и проблема символизма в татарской литературе. Казань: Алма-Лит, 2006. 246 с.; *Хайдаров Л.И.* Вопросы арабской литературы в татарском литературоведении начала XX века: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2004. 27 с.; *Гыйләҗева Ч.М.* Әдәбият фәне һәм Габдрахман Сәгъди. Казан: Школа, 2012. 208 б. һ.б.

[4] *Гыйләҗев Т.Ш.* Татар әдәби тәнкыйте (1920–1930 еллар). Казан, 2016. Б. 187.

классик шагыйрь Дәрдемәнд иҗаты белән тыгыз бәйләнештә тикшереләп, әдәби тәнкыйтьнең дә әлеге катлаулы күренешне читләтеп үтмәве дәлилләнә. Шуның белән бергә, башка күп кенә әдипләр кебек үк, Дәрдемәнд иҗатында да башка юнәлешләргә караган, аерым алганда, импрессионизм һәм экспрессионизм алым-чараларының урын алуы билгеләнә. Бу чорда символик тәнкыйть үрнәкләре дә дөнья күрә һәм әдәби процессны тулырак аңлауга, бәяләүгә яңа мөмкинлекләр ача[1].

Әдәби тәнкыйть, катлаулы күренеш буларак, чорның иҗтимагый, эстетик һәм әдәби-иҗади аңы белән тыгыз бәйләнештә яши, закончалыклы төстә хәрәкәт итә. Чор тәнкыйте үткән белән тыгыз бәйләнештә үзендә типологик һәм тарихи-конкрет сыйфат-билгеләрне чыгылдыра, аларны яңа шартларда дәвам итә. Әлеге үзенчәлекләр, беренче чиратта, теге яки бу чорда объектив рәвештә оешкан, формалашкан тәнкыйть юнәлешләре, агымнары аша күчә. Билгеле инде аларның җирләшүе, теге яки бусының өстенлек алуы бик күп төрле факторларга бәйле. Әдәбият белән тыгыз бәйләнештә булып, әсәрнең кайсы юнәлеш-агымда һәм нинди иҗат методына нигезләнеп язылуы тәнкыйть язмасына зур йогынты ясаса да, теге яки бу әсәрне шәрехләү барышында үзенә хас алым-чаралар, жанрлар белән эш итә, ниндидер максатчан бурычларын үти. Әлеге процесста, билгеле инде аерым билге-сыйфат алга чыга, өстенлекле роль уйный. Шуңа бәйле юнәлеш-агымнар һәр чорда бертөрле генә булмый, билгеле бер үзгәреш кичерә, трансформацияләнә. Әлеге процесста традицияләр гаять мөһим урын алып тора. Шуңа нигезле тарихилык принцибы алга чыга, ул исә системалы һәм типологик якын килүне таләп итә. Типологик якын килү тәнкыйть тарихында кабатланып торучы күренешләргә нигезләнә. Тәнкыйть теориясенә караган төшенчәләрне билгеләгәндә рус әдәбият белеме аша килеп кергән, киң планда дөньякүләм казанышлар булып саналган күренешләргә таянабыз. Шуларның берсе – тәнкыйть юнәлешләре. Аларны ачыклау гаять мөһим, чөнки яңа әдәби әсәрләрнең әһәмиятен, аларның әлеге чор сүз сәнгатенә керткән өлешен һәм киң планда әдәбият-сәнгатьнең җәмгыятьтәге урынын дөрес аңлау, бәяләү, киң планда авторның нинди алымнар, детальләр ярдәмендә укучыга нәрсә җиткерергә теләгәнен билгеләү мөмкин түгел. Әдәбият турындагы төшенчәләр, танып белү методологиясе, аның критерийлары әдәби процесс белән тыгыз бәйләнештә барлыкка килә, үсә-үзгәрә. Икенче яктан, алар билгеле бер традицияләр булуны да таләп итә. Соңгылары исә, сүз сәнгате барлыкка килгәннән алып, гасырлар дәвамында эзлекле рәвештә формалаша.

«Әдәби тормыш күренешләрен агымдагы процесстан аермыйча, гомум әдәби хәрәкәттән һәм яшәп килүче яки “тиешле” әдәби юнәлеш-

[1] *Саяпова А.М.* Дардменд и проблема символизма в татарской литературе. Казань: Алма-Лит, 2006. 246 с.

тән чикләнгән нindидер әйбер кебек алмыйча танып белергә кирәк»[1], – дип яза А.С. Курилов. Сүз сәнгатендә әдәби юнәлеш билгеле бер максатны күздә тотып, шуңа яраклы идеяне чагылдыра. Ә ул теге яки бу чор үзенчәлекләренә бәйле гомум характерда һәм аерым очракта таррак идеяне ачуга юнәлтелергә дә мөмкин. Гомумән, әдәби юнәлеш төшенчәсе тарихи конкрет булуы белән характерлана, ягъни ул аерым чорларда урын алган караш-концепциягә нигезле барлыкка килергә һәм шул рәвешле яшәүдән дә туктарга мөмкин. Матур әдәбиятка бәйле күзәтелгән әлеге үзенчәлекләр әдәби тәнкыйтьтә дә чагылыш таба. Тәнкыйтьче теге яки бу әсәргә, әдәби процесска бәя бирү барышында анда өстенлек иткән сәнгати фикерләүне, аңа хас сыйфат-билгеләрне ачыклый, үзе яклаган концепциядән чыгып, аларны бәяли, аңлата һәм шул рәвешле теге яки бу юнәлеш-агым тарафдары буларак эш итә.

Хәзерге татар әдәби тәнкыйте, күптөрле тышкы һәм эчке факторларга нисбәтле, яңа чор әдәби процессын, шул исәптән аерым әсәрләрне аңлау-бәяләүнең критерийларын, фәнни нигезләрен ачучы теоретик һәм эстетик караш-фикерләр эзләү юлына чыкты. Шундый шартларда әдәби тәнкыйтьнең юнәлеш-агымнарын (реаль, романтик, эстетик, импрессионистик, символик һ.б.), төрләрен (профессиональ, язучы, укучы) һәм типларын (филологик, философик, публицистик) ачыклау, шуларга нигезләнүнең уңышлы үрнәкләре пәйда булды.

XX гасыр татар әдәбиятының үзәк үсеш юлы булып реализм һәм романтизм тора. Шуңа да совет чоры татар тәнкыйтендә, нигездә, реаль һәм романтик тәнкыйть яшәде. Алар, үз традицияләрен саклаган хәлдә, билгеле бер сыйфат үзгәрешләре кичереп, хәзерге тәнкыйтьтә дә киң урын алып тора.

Сүз сәнгатендә реализм әйдәп баручы ролендә кала һәм шәхеснең кыйммәтен ассызыклаган хәлдә, традицияләргә тугрылык саклап, иҗтимагый тормышка аерым игътибар бирелә. Әнә шундый иҗатны бәяләргә алынган *реаль тәнкыйть* нигезендә чор картинасын тудыру, ягъни заман, хакимият, гомумән системаның бөтенлекле образын күз алдына бастыру тора. Аның концептуаль җирлеген әсәрләрдә тудырылган тормыш моделе үзенчәлекләрен ачу билгели. Шуңа да тәнкыйтьче вакыйга-күренешләрнең генә түгел, детальләрнең төгәллегенә, тормышчанлыгына җитди игътибар бирә. Язучы иҗатында урын алган тел-сөйләм катламы да, стиль үзенчәлекләре дә аның бәяләү объектына әйләнә. Үзәк сорауларның берсе буларак шәхес концепциясе, аны ачарга ярдәм итүче алым-чаралар байлыгы да тәнкыйтьченең игътибарын җәлеп итә. Реализмның үзәген тәшкил иткән «социаль-психологик детерминизм, ягъни кеше холкы һәм

[1] *Курилов А.С.* Проблема «литературного направления» в русской критике первой трети XIX века: автореф. дис. ... канд. филол. наук. М., 1972. С. 11.

фигыленең социаль шартларга бәйле булуын раслау»[1] реаль тәнкыйтьнең өйрәнү өлкәсе булып тора.

Реаль тәнкыйтьнең бер үрнәге буларак язылган «Күңел кемне көтә?» мәкаләсендә М. Вәли-Барҗылы әдәби әсәрдә чагылыш тапкан күренешләрне, геройларны чынбарлык белән тыгыз бәйләнештә карауны максат итә. Заман герое турында уйланып, болай дип яза: «Соңгы елларның реаль чынбарлыгында нинди соң ул – безнең еллар герое? Бүгенге тормышта без кемнәргә – нинди типларга – чыннан да «герой» дип әйтә алабыз?» Автор әсәр геройларын әлеге яссылыкта бәяли, чөнки «теге яки бу герой язучы күңеле аша тормыштан китапка үтеп керә». Шул рәвешле әдипкә дә мондый таләпләр куя: 1) язучының бүгенге көндә үз янәшәсендә иҗат итүче, көрәшүче, тормыш төзүче геройларга мөрәҗәгать итүе; 2) «замана яшәеше китереп чыгарган зур-зур проблемаларны үзе язган әсәрләрнең үзәгенә» куюы; 3) «социаль эчтәлекнең үткенлеге, актуальлеге»; 4) бөтен кешелек өчен мөһим булган идеяләрне яклавы. Дөрес, мәкалә авторы язучылар игътибарының нигездә тышкы дөнья вакыйгаларына, күренешләренә генә юнәлгән булуын кабул итми, алардан күренеш һәм вакыйганың рухи һәм фәлсәфи асылын ачуны да таләп итә[2].

Татар әдәбият белемендә *романтик тәнкыйть* XX йөз башында Д. Заһидуллина тарафыннан «рухиятчеләр» мәктәбе вәкилләре буларак билгеләнгән әдәбиятчылар иҗатына нисбәтле барлыкка килә. Аның нигезен язучы әсәрендә кеше рухы, күңел дөньясы ни рәвешле чагылыш табу, яшәешнең психологик җирлеген ачу кебек мәсьәләләр билгели. Г. Ибраһимов үзенең «Татар шагыйрьләре» (1913) дигән хезмәтендә беренчеләрдән булып әдәбиятны Матурлык һәм Образлылык төшенчәләренә нисбәтле бәяли. Романтик тәнкыйть өйрәнү объектына бик нык якыная, шуңа да анда авторның хыял дөньясы, хис-кичерешләре чагылышы шактый киң урын ала. Эстетика канунары белән эш итү иҗатчының рухына, күңеленә, хис-хыялына тизрәк һәм тирәнрәк үтеп керү мөмкинлеге бирә. Бу төр тәнкыйть тарафдарлары «бары тик эчке, әхлакый-рухи дөнья мөмкинлекләрен барлау, шуларны эшкә җигү генә кешене камиллеккә, яхшыга, югарылыкка әйди»[3] дигән принципка таяналар. Романтик эчтәлекле әсәр «рухи дөнья белән гаять тыгыз бәйле булып, матди башлангычтан аерылган диярлек, шуңа да аңа күтәренке образлар хас»[4]. Бу үзенчәлек исә тәнкыйтьтә субъективлык өстенлек алуга, әдәби образда романтик рухлы әдип үзе киң планда чагылыш табуга китерә.

Хәзерге әдәби процесста романтик сурәтлелекнең артуы күзәтелә. Әлеге үзенчәлек, үз чиратында, романтик тәнкыйть традицияләренең

---

[1] *Хафизов С.* Туксанынчы еллар әдәбияты // Казан утлары. 1999. № 12. Б. 145.

[2] *Вәли-Барҗылы М.* Күңел кемне көтә? // Казан утлары. 2004. № 6. Б. 132–140.

[3] *Хафизов С.* Туксанынчы еллар әдәбияты // Казан утлары. 1999. № 12. Б. 146.

[4] *Борев Ю.Б.* Эстетика. М.: Изд-во полит-й лит-ры, 1969. С. 63.

яңаруына, яңа сыйфатлар белән баюына юл ача. И. Юзеев, Ф. Садриев, З. Мансуров, Р. Гаташ, М. Кәбиров һ.б. иҗатын ачкан язмалар кеше һәм дөнья гаме белән сугарылган, аларда хис-кичереш нечкәлекләре, табигать матурлыклары, язмыш сынаулары үзенчәлекле синтез хасил итә.

Әдәбиятның сурәтләү объекты итеп кешенең эчке дөньясы, психологиясе билгеләнү чагылыш тапкан мәкаләләрнең берсе – Н. Гафиятуллинаның «Романтик әдәбиятта заман фаҗигасе: Әсгать Сәлах»[1]. Автор хәзерге прозадагы эзләнүләр, аның XX гасырның 60 нчы елларына караган башлангычы турындагы уй-фикерләре белән уртаклашкач, Ә. Сәлахның «Соңгы вальс»ына реалистик һәм романтик сюжет сызыклары үзара керешеп киткән әсәр буларак тирән анализ ясый. Тәнкыйтьче повестьта иҗтимагый проблеманың гомумкешелек мәсьәләләренә кушылып китүен, шулар аша җәмгыятькә тулы, төрле яклы бәя бирелүен ача. Матурлык һәм ямьсезлек антитезасы хронотопта да, үзара мөнәсәбәтләрдә дә, образлар бирелешендә дә чагылыш тапкан, лирик башлангычка киң урын бирелгән әсәр соңгы еллар прозасының табышы буларак күрсәтелә. Тәнкыйтьченең «Хәтер сызлануы»[2] язмасында З. Мансуров иҗатына романтик тәнкыйть принципларыннан чыгып бәя бирелә. Замандаш шагыйрь китабының исеме үк («Җәрәхәтле йөрәк җылырак») «мәгънәви һәм эстетик эчтәлекнең юнәлешен, агышын чагылдыра» дип саный автор. Шуңа да анализ нәкъ менә лирик геройга бәйле булып, аның сызланулы, җәрәхәтле күңеленең символик мәгънә алуы эзлекле ачыла. Үзгә бер сыйфат итеп З. Мансуровның романтик контрастлар белән иркен эш итүе, ачкыч-сүзләр ярдәмендә әсәрләрдәге катламнар ачылу, гаҗәеп яңгырашка ирешелү күрсәтелә. Автор эзлекле рәвештә шагыйрьнең серле иҗат дөньясын, аның күптөсмерлелеген ача. Әдипнең фәлсәфи, символик, әхлакый мотивлар урын алган әсәрләрен бәяләү аша аның фәлсәфи-романтик лирикага йөз тотуын дәлилли.

*Эстетик тәнкыйть* – дөнья әдәбият белемендә аеруча киң чагылыш тапкан төрләрнең берсе. Аның концепциясен сәнгатьнең актив, тәэсирле көченә ышану тәшкил итә, ягъни «сәнгатьнең «мәңгелек» һәм «үзгәрешсез» законнары позициясеннән әдәбият турында фикер йөртелә»[3]. Шуңа мондый язмаларда матурлыкның, яхшылыкның, дөреслекнең мәңгелек булуы идеясе үзәктә тора. Әлеге тәнкыйть тарафдарлары әдәбият-сәнгать әсәрен танып, бәяләп бетерү мөмкин түгел дип саныйлар. Бу яктан, ягъни киңлек, тирәнлек ягыннан ул тормышның үзе кебек үк колачлы. Әдәби әсәр үзе эстетик кыйммматкә ия һәм аны аңлау да

[1] *Гафиятуллина Н.М.* Романтик әдәбиятта заман фаҗигасе: Әсгать Сәлах // Мәйдан. 2004. № 4. Б. 27–30.

[2] *Гафиятуллина Н.М.* Хәтер сызлануы // Казан утлары. 2004. № 1. Б. 177–181.

[3] *Недзвецкий В.А.* Русская литературная критика XVIII–XIX веков. Курс лекций. М.: Изд-во МГУ, 1994. С. 97.

укучыдан эстетик хисслелек, интуиция таләп итә. Хәзерге татар әдәби тәнкыйтендә әлеге сыйфат-билгеләргә нигезләнүчеләр булып әзерлекле, тирән эстетик зәвыкка ия авторлар, нигездә, профессиональ тәнкыйтьчеләр һәм вуз укытучылары тора.

Ф. Хатипов «Якты җирлектәге һәлакәт» язмасында[1] тәнкыйтьнең төп вазифасы буларак, әсәрнең «серенә төшенергә тырышу, күркәмлеге, хикмәте нәрсәдә икәнен ачыклау»ны эстетик анализның нигезе дип саный. Аның эчтәлеге жанр белән дә бәйле булуын билгели. Шуңа да ул бәяләүне хикәя жанры үзенчәлекләре булган «инсан хәятының бик гыйбрәтле, тирән мәгънәле төбәкләрен, адәм баласы холкының төрле якларын, кәеф-халәтенең күп төсмерләрен» сурәтләвен калкытып куюдан башлый. Сәнгать әсәре, беренче чиратта, җанга, рухка йогынты ясый. Тәнкыйтьче әнә шул сыйфат-билгегә игътибарны юнәлтә. Үзе тикшерә торган М. Хуҗин хикәяләрендә «җанны назлый торган, нурланып балкыган күренешләр, мөнәсәбәтләр җылылыгы белән дә, кискен драматизм, сагыш, күңел китеклеге, бәндә рухының ярлылана, тупаслана, коргаксый төшүе белән дә» очрашуыбызны ассызыклый. «Аның хикәяләрендә тоташ моң агыла. Еллар үткән саен бу моң яктыра, тирәнәя, нәфисләнә бара», – дип яза ул. Тәнкыйтьче өчен вакыйгалар катламы түгел (гәрчә анысы да бик әһәмиятле), бәлки геройларның күңел тибрәнешләре, аны ачу-аңлату өчен автор кулланган детальләр, психологик сурәтләр алгы планда тора. «Каңгый илендә» герое яшәешендә бер халәттән икенче халәткә күчүнең нигез мизгелләрен ачып, М. Хуҗин хикәясенең рухи-интеллектуаль яссылыкта язылуына килә. Автор әлеге хикәядә матурлыкны, мәңгелек кыйммәтләргә таянуны күрә. Аның өчен әсәрнең укучыда «уй хәрәкәте кузгатуы» сәнгатьчә көчен күрсәтә торган мөһим билге. «Хикәянең бөтен төзелеше, логикасы эчке драмага юнәлгән», дип яза ул. Бу исә, үз чиратында, геройның туган якны сагыну тойгысын фаҗигале коллизия аркылы зур художество көче белән сурәтләгән автор стиленә хас җитди үзенчәлекне билгеләргә мөмкинлек бирә. Шул рәвешле, мәкалә авторы эзлекле рәвештә «хикәянең сәнгатьчел куәтен, эстетик энергиясен формалаштыруга» хезмәт итүче компонентларны (сюжет үстерелешен, перипетияне, контраст төсләрне, юл асты мәгънәләрен һ.б.) ачуга килә. Бу урында тагын шуны да билгеләп үтү кирәк, эстетик тәнкыйтьнең бер сыйфаты булып, анализ-шәрехләүдә логик нәтиҗәләрдән бигрәк, әсәр тудырган эмоцияләрне ачу санала. Ф. Хатипов мәкаләсендә әлеге билгенең үзгәрүен күрәбез. Автор хикәянең сәнгати тәэсирен тирәнтен тоеп бәяләүдә логик эзлеклелекне саклый.

Хәзерге татар әдәби тәнкыйтендә иң актив эшләүчеләрнең, әдәби процессның проза төрен сәнгатьнең эстетик закончалыкларыннан

[1] *Хатипов Ф.М.* Әдәбият теориясе. Казан: Мәгариф, 2000. 351 б.

чыгып һәм системалы өйрәнеп килүчеләрнең берсе – Р. Сверигин. Аның «Туксанынчы еллар әдәбияты», «Үткән ел прозасына бер караш», «Гасырлар чатында» кебек мәкаләләре[1] тирән эчтәлеге, сүз сәнгатенең эчке хасиятләрен белеп, аңлап язылулары, фикер ачыклыгы, объективлык, нәтиҗәләренең дәлилле булуы белән игътибарга лаек. Галимнең «Нурзилә новеллалары...», Ф. Яруллинга 65 яшь тулу уңае белән язылган «Аны беләбезме?» мәкаләләре, үзе таләп иткәнчә, «әсәрләргә эстетик җәһәттән якынлашып, алардагы сәнгатьчә гүзәллекне бәяләү, образлы фикерләрне авторның әдәби осталыгы, кулланган стиль-сурәтләү чаралары белән, тормыш күренешләрен үзенчә художестволы итеп яктырту осталыгы белән бәйләнештә аңлату»[2] рухында язылган. Аерым әдипкә, әдәби чорга, еллык күзәтүләргә бәйле хезмәтләрендә без зәвыклы укучыны, таләпчән тәнкыйтьчене күрәбез. «Үткән ел прозасына бер караш» язмасында тәнкыйтьче әсәрләргә бер-ике җөмлә белән, әмма күп сыйдырышлы бәя бирә, кирәк урында итәгатьле генә саллы сүзен дә әйтә. Аның өчен абруй-дәрәҗәләрдән бигрәк сәнгать әсәренең эчке хасиятен ачу кыйммәтрәк. Әлеге мәкаләсендә Р. Сверигин безнең игътибарны әсәрләрнең жанр ачыклыгы мәсьәләсенә юнәлтә. Бәя бирү критерийлары итеп мавыктыргыч булуны, образлылыкны, фикер тирәнлеген ала һәм тәнкыйтьнең бурычларын дә эстетик кыйммәтләрне ачыклауда күрә.

Хәзерге татар әдәби тәнкыйтендә киң үсеш алган төрләрнең берсе булып *мифологик тәнкыйть* тора. Башлангычы швейцария психологы К.Г. Юнг концепциясенә нигезләнүе сәбәпле аны «архетип тәнкыйть» дип тә йөртәләр. Татар әдипләре үткән мирасыбызны барлый барып, Болгар һәм Алтын Урда чорларына гына түгел, тагын да элгәрерәк дәверләргә үтеп керәләр. Сүз сәнгатебез «эре һәм кыю адымнар белән мифологиягә, миф тудыруга, күпмедер дәрәҗәдә дини фәлсәфәгә»[3] йөз белән борылды. Ф. Бәйрәмова, Н. Гыйматдинова, Г. Гыйльманов һ.б. авторлар иҗаты әлеге күренешләрнең бер чагылышы булып тора. Мондый әсәрләр киң катлау укучыларда зур кызыксыну тудырып, әдәби тәнкыйть тә аларны бәяләргә алына. Аерым алганда, Д. Заһидуллина, А. Шәмсутова, Л. Дәүләтшина хезмәтләре мифологик тәнкыйтьнең җирләшүе турында нигезле сүз алып бару мөмкинлеге бирә. Шуның өстенә әлеге күренешне фәнни нигездә өйрәнү үрнәге булган Й. Нигъмәтуллинанаң «“Запоздалый модернизм” в татарской литературе и изобразительном искусстве» һәм Ф. Урманчеевның «Борынгы миф һәм бүгенге шигырь

---

[1] *Сверигин Р.Х.* Туксанынчы еллар әдәбияты // Казан утлары. 1999. № 6. Б. 126–128; *Сверигин Р.Х.* Үткән ел прозасына бер караш // Казан утлары. 2000. № 7. Б. 132–137; *Сверигин Р.Х.* Гасырлар чатында // Казан утлары. 2002. № 4. Б. 145–154.

[2] *Сверигин Р.Х.* Нурзилә новеллалары... // Казан утлары. 2003. № 6. Б. 174–176.

[3] *Шәмсутова А.А.* «Җан сурәте» // Мәйдан. 2007. № 4. Б. 140.

(Татарстанның халык шагыйре Р. Фәйзуллин шигъриятенә бер караш)» дигән тикшеренүләре дә мифологик тәнкыйтьнең үзенчәлекләрен ачуга хезмәт итә[1].

Мифологик тәнкыйть кешелек җәмгыятенең беренче иҗат җимеше булган миф турындагы өйрәтүләргә нигезләнә. Анализ барышында анда урын алган ниндидер мифның асылы, төзелеше, эчтәлеге ачыла һәм әсәр авторы концепциясен аңлаудагы урыны билгеләнә. Фәндә әдәбиятның мифка мөнәсәбәтле үзенчәлекле түгәрәк тәшкил итүе билгеләнә: сүз сәнгате мифтан аерылып чыгып, үзенең сыйфат-билгеләре булган иҗат күренеше булып үсә, аннары исә еш кына теге яки бу сурәтләү объектына нисбәтле, аны аңлауда җитди компонент буларак әсәр үзәгенә алына, ягъни миф яисә архетип тикшеренү объектына әйләнә[2]. Мифологиягә бәйле күренешләрне ачу әдәби иҗатның тирән милли катламнарын, башлангычын аңлауга, димәк, кешелек җәмгыятен өйрәнүгә хезмәт итә. Ул еш кына борынгы ышанулар, беренче дини карашларның, йолаларның барлыкка килүенә дә барып тоташа. Мифологиягә, мифологик аңга бәйле теоретик фикерләр тәнкыйтьтә өйрәнү, тикшеренү инструменты булып тора, шул сыйфатта файдаланыла. Әдәби әсәрдә сурәтләнгән архетиплар, гадәттә, гаять зур роль уйный, автор позициясе белән тыгыз бәйле була, чөнки алар К. Юнг өйрәтүләре буенча, аңсызлык чарасы булса да, кешелекнең иң кирәкле, мөһим тәҗрибәсен буыннардан буыннарга тапшыручы алым буларак урын ала. Бу мәгънәдә ул «коллектив аңсызлык»ның бер өлеше булып тора һәм анда кешелек акылы чагыла. Икенче төрле, мифлар «коллектив аңсызлык» чагылышы, ә инде аларның образы – архетиплар. Әдәби әсәрдә урын алган архетиплар – кешенең аңсызлыгында тупланып килгән «беренчел образларның» сурәтләнеше. Мифологик тәнкыйтьнең бер үрнәге буларак, Л. Дәүләтшина «Киләчәккә күз төбәп» язмасында[3] XX–XXI гасыр чикләрендә дөнья күргән бер төркем әсәрләрне тикшерә. Автор хәзерге татар әдәбиятында хыялый, мистик әдәбият тарафдарларының артуын билгеләп, язучыларның мифологик образларны калкытып куюлары сәбәбен эзләүгә килә. Заман үзгәрешләре, күчеш чоры йогынтысында сүз сәнгатендә архетип һәм мифлар белән кызыксыну арта дип саный. Аның артында исә моңа кадәр кабул ителгән кыйммәтләрнең хәзерге таләпләргә җавап бирмәве ята. «Хәзерге җан-рух кризисы язучыларны бүгенге көн сүз сәнгате бирә алмаган тотрыклылыкны милли аңның ерак төпкелләреннән, тәңречелек

---

[1] *Нигматуллина Ю.Г.* «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. Казань: Фэн, 2002. 167 с.; *Урманчеев Ф.И.* Лиро-эпос татар Среднего Поволжья: основные проблемы изучения баитов. Казань: Татар. кн. изд-во, 2002. 256 с.

[2] *Козлов А.С.* Литературоведение Англии и США XX века. М.: Московский Лицей, 2004. С. 124–136.

[3] *Дәүләтшина Л.* Киләчәккә күз төбәп // Казан утлары. 2005. № 9. Б. 154–158.

идеяләреннән эзләргә этәрә», – дип яза ул. Автор фикеренчә, мифологик сурәтлелек «универсаль дөнья сурәтен, яшәеш моделен тудыруга» хезмәт итә, бу исә милли проблемаларны дөньякүләм яссылыкта карауга китерә. Шул рәвешле әдәбиятта мифологик карашларның, образтөшенчәләрнең, архетипларның алгы планга чыгуының төп сәбәбе буларак кешенең чынбарлыктан таба алмаган таянычны коллектив һәм тарихи аң казанышларыннан, архетиплар арасыннан эзләве күрсәтелә. Әнә шул яссылыкта Л. Дәүләтшина Г. Гыйльмановның «Оча торган кешеләр», «Албастылар», Ф. Бәйрәмованың «Канатсыз акчарлаклар», Н. Гыйматдинованың «Ак торна каргышы» кебек әсәрләрен бәяли. Автор әлеге әсәрләрдә тудырылган мифологик Яшәеш моделенең Күк белән Җир арасындагы каршылыкка нигезләнүен һәм аның кеше күңелендә барган тартышуга бәйле булуын ача. «Барлык Галәмне колачлаган, яшәү мәгънәсенә әверелгән тартышу нигездә кеше җанындагы Явызлык Игелек көрәшенә кайтып кала, шунда гомумиләшә», – дип яза ул. Шул ук вакытта әлеге идеаль геройлар гадәти түгел, алар архетип дәрәҗәсенә күтәрелсәләр дә безнең заман геройлары буларак кабул ителми. Чөнки әдәбиятта урын алсалар да, «тормышта алар әле юк, алар килер өчен җирлек тә әзер түгел әле». Бу күренеш әдәбиятның күрәзәчелек сыйфаты белән бәйләп аңлатыла. Мәкалә авторы мондый нәтиҗә ясый: «Мифологик күзаллаулар белән бергә әсәр кысасына мифологик образлар кертелә. Мифологик образ төп геройга яшәү хакыйкатен таныту, автор позициясен ачыклау өчен хезмәт итә».

1990 еллар башы сүз сәнгатендә әдәби-эстетик карашлар, сәнгати ориентирлар үзгәреш кичерү белән бергә, тәнкыйть тә җитди каршылыклар чорына кергән вакытта язучылар үзләре тәнкыйтькә килә. Әлеге үзенчәлекле тәнкыйть төре *импрессионистик тәнкыйтьнең* җанлануына юл ача. Аның нигезендә әдәби әсәр турындагы беренчел, ихлас туган хис-кичерешләргә таяну ята. Язма авторы ниндидер юнәлеш-агымга яисә концепциягә таянмыйча, укылган әсәр нигезендә туган эмоциональ тойгыларны алга чыгара. Шуңа да тәнкыйть язмасы тикшерү объектына мөнәсәбәттә фәнни, дәлилле нәтиҗә-бәя чыгарырга омтылмый. Гомумән, эмоциональ тәнкыйть субъектив карашлар өстенлек итү белән характерлана, чөнки «бары бер генә укучыны – үзен, шәхси эмоцияләрен генә исәпкә ала»[1]. Импрессионистик тәнкыйтьнең үсеше, беренче чиратта, язучы тәнкыйте белән бәйле. Бу төргә мөрәҗәгать итүчеләр булып, нигездә, әдипләр үзләре тора. Шуның белән бергә, аның символик һәм сентименталь тәнкыйтькә якынлыгын да билгеләп үтәргә мөмкин. Импрессионистик тәнкыйть үзенә хас жанрлар системасын тудыра, аерым алганда, ул эссе (Р. Сибатның «Өчтомлыкны

[1] Литературный энциклопедический словарь / под ред. В.М. Кожевникова и П.А. Николаева. М.: Советская энциклопедия, 1987. С. 170.

укыгач өч сүз» һ.б.), күзәтү (Р. Зәйдулланың «Куркытмагыз кошлар авазын» һ.б.), әдәби-биографик очерк (Ә. Сәлахның «Күкрәүләре һаман яңгырый (шагыйрә С. Сөләймәнованы искә алганда)» һ.б.), рецензия (Р. Шәрәфиевнең «Ак казлар чакыруы», Т. Галиуллинның «Шигъри аһәңле публицистика» һ.б.) кебек жанрларның активлашуы да шуның белән аңлатыла.

Әлеге рухта янып-кайнарланып язылган мәкаләләрнең берсе – Р. Гаташның «Йолдызларны танып, сөенә белик...» хезмәте[1]. Җаны-тәне белән шигърият дөньясында яшәүче Р. Гаташ мәкаләсенең башламы үк үзенчәлекле. Ул татар поэзиясенә күзәтү язмасына алынуның авырлыгын сиздерә: «Шигырь, «Әнкәбез-Шигърият», үз каләмдәшләрең – шагыйрьләр турында язу – ул шигырьнең үзен язу-тудыруга караганда катлаулырак, четереклерәк эш бугай». Бүгенге тәнкыйтьнең «тешсезлеге» турында «Ә тәнкыйтьне, нинди генә объектив булмасын, шундый дип кабул итәбезме соң без? Кайсыбыз «ярата» аны? Үзебезне «мактаган әйбәт язмаларны» искә алмаганда... Шуңа да тәнкыйть үсми, шигырь тәнкыйте юк, дип сөйләүләр һаман дәвам итәчәк», дип уйлана, шактый кискен сораулар да куя. Әнә шулай саллы башланып киткән мәкаләдә хәзерге шигъриятнең йомшак яклары да күрсәтелә: стильалымнардагы бертөрлелек, гомуми сәясилек, ялангач публицистика, прозаизм, хәтта примитивизм көчәю; артык дөрес милли чынлык чагылу; маңгайга бәреп әйтелгән хакыйкать; шигырьнең үз үсешеннән чыкмаган нәтиҗәләр; жанрларда һәм үлчәү-формаларда игезәктәй охшашлык һ.б. Әмма әлеге фикер-карашлардан соң, аерым авторлардагы, әсәр-җыентыклардагы кимчелекләр тәфсилләп күрсәтелербәяләнер дисәк, язманың тоны бик нык үзгәрә. Тәнкыйтьче аерым штрихлар белән унга якын шагыйрьнең иҗат юнәлешләрен яисә кайбер табышларын күрсәткәннән соң, мондый нәтиҗәгә килә: «зур мирас һәм шигъри мәктәпләр белән сыналган, төрле стильләрдә үскән һәм якты йолдызларын күктә балкыткан татар шигыренең бүгенгесе дә зарланырлык түгел. Булганны яратырга өйрәнсәк иде. Әйе, йолдызлар бар, алар яна – күрә, сөенә белик дип әйтәсем килә минем». Шул рәвешле, тәнкыйтьче сәнгать әсәренең үзкыйммәтен күтәреп куя, тышкы тирәлек белән тыгыз бәйләнешне дә алга чыгармый, асылда үзенең интуициясенә таяна.

*Символик тәнкыйтьнең* уңышлы үрнәге булып Г. Гыйльмановның «Образ. Символ. Рухи кодлар» дигән проблемалы мәкаләсе[2] тора. Бу төр тәнкыйтьнең җирләшүе хәзерге татар әдәбиятында символизм

[1] *Гаташ Р.* Йолдызларны танып, сөенә белик... (Шагыйрьләребез турында бер уй) // Казан утлары. 2002. № 3. Б. 118–121.

[2] *Гыйльманов Г.Х.* Образ. Символ. Рухи кодлар (Г. Моратның «Түбә» китабын укыганда туган уйлар) // Казан утлары. 1999. № 4. Б. 143–155.

агымында иҗат ителгән шактый сандагы әсәрләрнең дөнья күрүе белән бәйле. Мәкаләдә өйрәнү объекты – Г. Моратның «Түбә» җыентыгы. Автор мәсьәләне теоретик планда ачуга да игътибар итеп, 1980 еллар татар шигъриятендәге бер үзенчәлекне ача. Аның фикеренчә, бу чорда әдәбиятка килгән шагыйрьләрдә «сюжетлылыкны – метафорик, символик иҗат актив рәвештә алыштыра барды, вакыйгалылыкны, тасвирлама әдәбиятны ассоциатив (образлар багланышы) логикага корылган образлылык кысрыклый башлады. Соңгысы исә үзе ике юнәлешкә бүленеп китте: бер шагыйрьләр метафорик, символик иҗат алымнарына өстенлек бирсә, икенчеләр лирик-фәлсәфи канатны алга үстерде». Автор хәтта «символизмның яңадан тууы дип тә әйтергә мөмкиндер бу үзгәрешләрне» дип билгели. Укучының игътибарын төп объекты символлар булган баллада жанрына да юнәлтә, аның төрле чорлардагы иң яхшы үрнәкләрен атап үтә.

Символларның ерак тамырларын барлап, борынгы әдәбиятка мөрәҗәгать итә һәм «безнең милли әдәбиятыбызның нигезендә төсмерлелеккә нигезләнгән образлылык» ятуын күрсәтә. Г. Гыйльманов XX гасырның икенче яртысы әдәбиятында символларның активлашуын җәмгыятьтәге шартлар белән бәйләп карый, ягъни «сәяси баскынчылык», идеология басымы әдипләрне яшерен тел, «эзоп теле» белән эш итәргә этәрә. Ә инде хәзерге әдәбиятта символларга игътибар арту милли үзаң үсүгә, үткән тарих белән кызыксынуга бәйле. «Рухиятебезнең йөзек кашы булырдай образларның кире кайтарылуы, яңа мәгънәләр өстәп, гамәлгә куелуы, милли үзаң, дин-иман символларының белем-мәктәп, йола-әхлак системасына кертелүе, башка кайбер сәбәпләр символик әдәбиятның үсешенә көчле һәм көтелмәгән импульс бирделәр».

Символның сәнгатьлелек белән бәйләнешенә тукталып, аның «әдәбилекнең дә югары дәрәҗәсе, асыл дәрәҗәсе» булуын билгели. Шуның белән бергә, тәнкыйтьче бер үзенчәлекне искәртә: «монда символларның эчтәлегенә салынган мәгънәви спектрның ничек, ни дәрәҗәдә ачылуы да мөһим», ягъни «символик образларның көче, егәрлеге аны урынлы куллану белән бәйләнгән». Әнә шул планда автор Г. Морат иҗатын бәяли, символларның яшәеш күренешләрен гомумиләштереп, шартлы код рәвешендә күзалларга ярдәм итүен конкрет мисалларда күрсәтә. Хезмәттә Г. Морат әсәрендә Тәңре, Ат, Канатлы барс, Фәрештә, Вакыт, Көймә (Кораб), Ай, Аккош, Һомай, Баш, Түбә һ.б. символларның гаҗәеп үзенчәлекле фикер-карашлар, мәгънәви ассоциацияләр тудыруы раслана. Г. Моратның романтизм, символизм, рационализм башлангычларын берләштергән иҗаты турында мондый нәтиҗә ясый: «Үз сүзен һәрвакыт борынгылыктан килүче рухи символ-кодларыбыз булырдай егәрле образларга төреп бирә, эретерлек сурәтләр тудыра, һәр

татар кешесенең җан-бәгырен кузгата, аның иманын ныгыта, кыйбласын барлый...»

Хәзерге татар әдәби тәнкыйтендә тикшеренүчеләрнең игътибарын торган саен күбрәк *психоаналитик тәнкыйть* җәлеп итә. Аның башлангычы Зигмунд Фрейд эшчәнлеге белән бәйле. Атаклы психолог «өйрәтүләренең нигезендә ике теория ята: теләк-омтылыш теориясе һәм «аңсызлык» теориясе[1]. Аның беренчесе кешене «канәгатьлек эзләүче» буларак караса, икенчесе исә кешене аңы булган зат итеп кенә түгел, бәлки үзенә күптөрле психологик импульслар туплаган «аңсызлык» халәтенә дә ия дип саный. З.Фрейд фикеренчә, «аңсызлык» материалы булып җәмгыятьтә кабул ителгән кануннарга бәйле безнең аңыбыздан мәҗбүри «чыгарылган» эротик теләк тора. Кешене берьяклы гына бәяләүгә йөз тоткан беренче теория җитди тәнкыйтькә очрый. Икенчесе исә дөньякүләм яңгыраш ала. З.Фрейдның «аңсызлык» теориясе К. Юнгның «коллектив аңсызлык»ы белән тулылана, ягъни кеше аңында тискәре, эгоистик импульслар гына түгел, бәлки уңай, күтәренке импульслар да яшәве дәлилләнә. Халыкның яшәү тәҗрибәсен туплаган «коллектив аңсызлык» бер буыннан икенчесенә күчә бара. Әдәбиятта ул «архетиплар» буларак чагылыш таба. Бу яктан психолоаналитик тәнкыйть мифологик тәнкыйтькә якыная.

Геройны «аңсызлык» һәм «коллектив аңсызлык» халәтендә сурәтләү XX йөз башы татар әдәбиятында (Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Н. Думави, М. Хәнәфи) урын алса да, аны бәяләүнең аерым үрнәкләре генә пәйда була. Киң планда караганда, гасырлар дәвамында исламга нигезләнгән татар әдәбияты «аңсызлык»ка бәйле эротик характердагы карашларны сурәтләүгә бик сак килә. Совет чорында да бу мәсьәләгә мөнәсәбәт каршылыклы була. XX гасырның 60 нчы елларында әдәбиятта психологизм тирәнәя. Бу исә психоаналитик тәнкыйтьнең үзәген тәшкил иткән психоанализ белән кызыксынуга китерә. Шуңа да кешенең эчке дөньясын, җан хәрәкәтен, хис-кичерешләрен сурәтләү үзенчәлекләрен, алым-чараларны ачу киң яңгыраш ала. Хәзерге тәнкыйтьтә әсәргә анализны психологик планда алып бару, ягъни психологик детальләр, психологик диалоглар, психологик портрет һәм пейзаж күренешләрен бәяләү, алар үтәгән әдәби-эстетик функцияне билгеләү игътибар үзәгендә тора. Моңа мисал булып М. Җәләлиеваның «Тойгы катламнары», Д. Заһидуллинаның «Сары йортлар сере» (М. Кәбиров)» һ.б. язмалар[2] тора. М. Җәләлиева мәкаләсендә Ә. Еники иҗатын кешенең эчке дөньясын сурәтләү үзен-

---

[1] Литературная энциклопедия терминов и понятий / под ред. А.Н. Николюкина. М.: Интелвак, 2003. С. 830.

[2] *Җәләлиева М.Ш.* Тойгы катламнары // Казан утлары. 2002. № 11. Б. 160–169; *Заһидуллина Д.Ф.* «Сары йортлар сере» // Яңа дулкында (1980–2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык). Казан: Мәгариф, 2006. Б. 169–179 һ.б.

чәлеге белән бәйләп карый. Шуңа нисбәтле ул әдипнең түбәндәге стиль билгеләрен аерып чыгара: 1) психологик геройның үз эчендә күптөрле тавышлар тудыра алуы; 2) герой хисләренең тышкы дөнья белән каршылыкка керүе; 3) әдәби характерның үз эчендәге каршылыгы; 4) «язучының эстетик фикерләвендә психологик процессның дүртенче үзенчәлеге – табигать образын сурәтләве аша яңарак сыйфатлар табуында»; 5) җыр-моң мотивының күпчелек әсәрләрен иңләп үтеп, геройның рухи дөньясын ачуга хезмәт итүе һ.б.

Татар әдәбиятында эротик теләк-кызыксынуның психологик нигезләрен ачу киң урын алмаса да, аның капма-каршысы буларак *үлем белән кызыксыну* һәрвакыт булган һәм хәзерге әдәби процесста чагылыш табып, тәнкыйтьтә дә күзәтелә. Аның уңышлы үрнәкләре булып экзистенциаль күренешләр үзәккә куелган В.Имамовның «Могикан», З. Хәкимнең «Шайтан куентыгы» әсәрләренә бәяләмә рәвешендә язылган Ә. Закирҗановның «Могиканнар кисәтә», А. Саттарованың «Двуединая сущность личности в трагедии З. Хакима “Шайтан куентыгы”» хезмәтләре[1] тора.

Хәзерге әдәби тәнкыйтьтә күзәтелгән җитди яңалыкларның берсе модернистик агымнарны өйрәнү белән бәйле. ХХ гасыр ахырында татар сүз сәнгате реализм һәм романтизм кысаларына кереп бетмәгән яңа төр концепцияләргә, алым-чараларга, сәнгати эзләнүләргә дә йөз тота. Әдәби барышта «яңадан стиль тенденцияләре белән баю, бер-берсенә бөтенләй охшамаган сукмаклар табу күзәтелә»[2], «модернистик билгеләрне үзенә сеңдергән шигъри әсәрләр иҗат ителә, постмодерн алымнары да кулланыла»[3]. Әлеге сыйфат үзгәрешләре үзенә хас тәнкыйтьнең мәйданга килүенә китерә. Ул Й. Нигъмәтуллина, Д. Заһидуллина, И. Вәлиулла, А. Шәмсутова һ.б. исемнәре белән бәйле. Аларның хезмәтләре аналитик фикерләүгә йөз тотуы, берничә юнәлеш-агымга хас билгеләрне үзенә алып синтезлашкан булуы белән характерлана.

Иҗатчының әдәби тәнкыйтькә мөнәсәбәтенә, аның белән бәйләнешенә нисбәтле профессиональ тәнкыйть, язучы тәнкыйте, укучы тәнкыйте кебек төрләрен аерып чыгаралар. Мондый бүленеш, бер яктан, тәнкыйть язмасы белән чыгыш ясаучының җаваплылыгында, икенче яктан, аңа куелган таләпләрдә дә ачык чагыла.

*Профессиональ тәнкыйть* иҗатның әлеге өлкәсе белән максатчан, төп хезмәте буларак шөгыльләнүче эшчәнлеген белдерә.

[1] *Закирҗанов Ә.М.* «Могикан»нар кисәтә // Заман белән бергә. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. Б. 68–73; *Саттарова А.М.* Современная татарская драматургия (1985–2000 гг.): Концепция эпохи и героя. Казань: Гуманитария, 2003. С. 117–122.

[2] *Заһидуллина Д.Ф.* Соңгы еллар татар прозасы // Хәзерге татар әдәбияты. Казан: Мәгариф, 2008. Б. 413.

[3] *Йосыпова Н.* Соңгы еллар татар поэзиясе // Хәзерге татар әдәбияты. Казан: Мәгариф, 2008. Б. 428.

Профессиональлек дәрәҗәсен билгеләү шактый каршылыклы мәсьәлә. Ул тәнкыйтькә куелган төп максат-бурычлар белән бәйле. Шуңа да укучы профессиональ тәнкыйтьчедән әдәби әсәрнең төзелеш-структурасына, киң планда эчке закончалыкларына нигезләнгән бәя-анализны, шул нигездә тормышның сүз сәнгатенә бәйле рухи иҗтыяҗларын, мәдәни сыйфат-билгеләрен ачуны көтә. Әлеге төр тәнкыйтьнең җирлеге булып иҗатчының белем-күнекмәләре, үткән традицияләрне, тәнкыйть тарихына караган казанышларны үзләштерүе һәм шуларга бәйле шәхси зәвыгын, тәҗрибәсен булдыруы тора. Әнә шулар профессиональ тәнкыйтьчегә өр-яңа әдәби күренешләрне ачарга, бәяләргә мөмкинлек бирә. «Профессиональ тәнкыйтьнең һәрвакыт очрый торган кыенлыгы – үзенең эстетик тәҗрибә белән тикшерелә торган әдәби әсәрдә урын алган билгесезлек каршылыгы»[1].

Югарыда әйтелгәнчә, XX йөз башында формалашу процессы кичергән татар әдәби тәнкыйте тиз арада Җ. Вәлиди, Г. Карәм кебек профессиональ тәнкыйтьчеләрне дә мәйданга чыгара. Әлеге яңа иҗат төренең әһәмиятен тирәнтен аңлаган газета-журнал мөхәррирләре тәнкыйтькә шактый киң урын бирәләр. Ә инде «Шура», «Аң» кебек журналларда махсус рубрикалар ачыла. Хәзер дә әдәби-иҗтимагый журналлар буларак чыгып килүче «Казан утлары», «Мәйдан», «Мирас» битләрендә «Рецензия», «Әдәби тәнкыйть», «Китап күзәтү», «Иҗатына бер караш» кебек рубрикаларның урын алуы, ТР Язучылар берлеге каршында тәнкыйть секциясе эшләп килүе профессиональ тәнкыйтьнең булуы турында сөйли. Шул ук вакытта хәзерге әдәби процесста саф профессиональ тәнкыйтьчеләр юк диярлек. Иҗтимагый-социаль һәм мәдәни шартлар әлеге иҗат төре белән генә шөгыльләнү мөмкинлеге бирми. Шуңа да киң җәмәгатьчелектә сүз сәнгате тарихын, әдәби иҗат үзенчәлекләрен максатчан өйрәнүче фәнни-тикшеренү институтлары хезмәткәрләрен, югары уку йортлары укытучыларын, шулай ук газета-журналларда эшләп, тәнкыйть белән шөгыльләнүчеләрне профессиональ тәнкыйтьче дип атау күзәтелә.

Бу төр тәнкыйть үзенең фәннилеге, фактларга таянуы, конкретлыгы һәм җитди, аналитик нәтиҗәләре белән характерлана. Бу яктан ул әдәбият белеменә якыная. Шуңа да профессиональ тәнкыйтьне әдәбият белеменең фактик базасы, җирлеге дип атау бар. В. Хализев болай дип яза: «Әдәби-тәнкыйди эшчәнлек тарихи-әдәби һәм үзенең теоретик гомумиләштерүләрен хронологик аңлатып кына калмый, бәлки аларга җирлек тә әзерли. (...) Тәнкыйть фәнни әдәбият белеменең нигезен тәш-

[1] История русской литературной критики: учеб. для вузов / В.В. Прозоров, О.О. Милованова, Е.Г.Елина и др.; под ред. В.В. Прозорова, М.: Высш.шк., 2002. С. 12.

кил итә»[1]. Мисал өчен, галим һәм тәнкыйтьче Т. Галиуллинның соңгы еллардагы тикшеренүләре нәтиҗәсе булган «Шигърият баскычлары» (2002), «Шәхесне гасырлар тудыра» (2004) хезмәтләре фәнни-теоретик һәм методологик нигезе, фактик материалга байлыгы, язма-мәкаләләрдә авторның концептуаль карашлары киң чагылыш табу белән игътибарны җәлеп итә.

Галим-тәнкыйтьче хезмәтләренең мөһим бер үзенчәлеге шигъри әсәрләргә хисси-тойгылы бәяләмәнең (импрессионистик тәнкыйть чагылышы) аң-акыл җегәренә нигезләнгән аналитик фикерләү белән үрелеп баруында («Фикер һәм хис бердәмлеге», «Акыл һәм җан берлеге», «Матурлык дөньясында» һ.б.). Ул исә, бер яктан, татар поэзиясенең тирән катламнарына нигезләнгән иң уңышлы традицияләрнең аерым әдипләр иҗатындагы шигъри яңачалыклар белән үрелеп баруын ачуда, икенче яктан, татар һәм башка халыкларның әдәбият белеме ирешкән казанышларын иркен файдалануда, өченче яктан, теге яки бу шагыйрьнең сәнгати фикерләү үзенчәлеген әдәби барыш, аерым юнәлеш-агымнар, шулай ук милли һәм гомумкешелек кыйммәтләренә нисбәтле бәяләүдә чагыла. Т. Галиуллин фикеренчә, күпгасырлык тарихында романтик һәм реалистик юнәлешләргә йөз тоткан татар поэзиясе XX гасыр башында чынбарлыкны гәүдәләндерүнең яңа баскычына күтәрелә һәм Шәрык, рус-Европа халыклары казанышлары белән аваздаш эзләнүләр юлына чыга. XX гасырның 60 нчы елларыннан соң шигърият реалистик һәм романтик сурәтлелеккә нигезләнгән хәлдә модернистик агымнарны да үз итә. Шулай да яңалык-табышларны ул, беренче чиратта, стиль эзләнүләре белән бәйләп карый. Бу аңлашыла да, чөнки һәр шагыйрьнең иҗади йөзе нәкъ менә стиль эзләнүләрендә, үзенә хас сурәтләрдә, алым-бизәкләрдә, теледә, алым-чараларның эчке мөмкинлекләрен ачуда чагыла. Реалистик эзләнүләр заман агышын йөрәк хисе белән иңләргә омтылу, тормыш һәм кешегә фәлсәфи планда якын килү, көндәлек тормышка, җиргә бермә-бер якынаю белән билгеләнсә, поэзиядәге романтик тенденция кешенең рухи дөньясына игътибар көчәю, яшәешнең мәңгелек проблемаларына, шуңа бәйле еш кына күтәренке һәм фаҗигале пафоска мөрәҗәгать итү, шартлы алымнардан, метафорик сөйләмнән иркен файдалану һ.б. белән аңлатыла.

Шагыйрьләр белән бергә, әдәбият-сәнгатьнең башка төрләрендә эшләүче мәртәбәле шәхесләр турындагы язмалар эчке егәре, мәгънәви тирәнлеге белән аерылып тора. Авторның М. Мәһдиев, Г. Ахунов, А. Гыйләҗев, Р. Кәримов, В. Хаков турындагы әдәби портрет, тәнкыйдибиографик очерк жанрларына караган мәкаләләре шәхси-рухи башлангычның көчле булуы, тормыш мизгелләрен, биографик фактларны,

[1] *Хализев В.Е.* Интерпретация и литературная критика // Проблемы теории литературной критики. Сб. статей. М.: Изд-во Моск.ун-та, 1980. С. 91.

иҗат үзенчәлекләрен яшәешнең мөһим мәсьәләләре белән үрүе, кешелек сыйфатларын калкытып куюы белән игътибарны җәлеп итә, әдәби әсәр кебек яратып, кызыксынып укыла. Әлеге язмалар тәнкыйтьне җанландыруга гына түгел, жанрларга бәйле теоретик сорауларны ачыклауга, тулыландыруга, кайберләренең эчке хасиятләрен билгеләүгә дә хезмәт итә.

Үткәндәге һәм хәзерге әдәби тәнкыйтьнең зур өлешен *язучы тәнкыйте* алып тора. Төп иҗади эшчәнлекләре әдәби әсәрләр язу белән бәйле әдипләрнең XX гасыр ахыры – XXI гасыр башында актив рәвештә тәнкыйть белән кызыксынулары күзәтелә. Монда берничә сәбәпне күрсәтергә мөмкин: берсе, үзе дә бер вәкиле булган әдәби процесска караш-мөнәсәбәтен белдерү, аерым тенденцияләрен билгеләү теләге; икенчесе, төрле сәбәпләр аркасында тәнкыйтьнең үз функцияләрен үтәп бетермәве, хәзерге сүз сәнгатендә яңалык-эзләнүләрне тулысынча ачып бирмәве, шул ук вакытта моның мөһимлеген аңлау язучыларны тәнкыйть белән кызыксынуга этәрә; өченчесе, үзенең иҗат йөзен, стиль үзенчәлекләрен ачу, башкаларга җиткерү омтылышы (үзтәнкыйтьнең үсеше). Профессиональ тәнкыйть үзенең академик характерда булуы белән аерылып торса, язучы тәнкыйтенә үтә субъективлык, шәхси башлангычның киң урын алуы, үзгә зәвыкка нигезләнү хас. Әдип теге яки бу әсәрне үзенең әдәби-эстетик эзләнүләренә, шәхси иҗат тәҗрибәсенә нигезләнеп бәяли, мөнәсәбәтен белдерә, шуңа бу төр язмаларда көтелмәгән ассоциацияләр, бәйләнешләр, нәтиҗәләр урын алырга мөмкин. Язучы тәнкыйте төр һәм жанр ягыннан да бик чуар. Хәзерге тәнкыйтьтә импрессионистик юнәлешнең активлашуы, шулай ук эссе жанрының яңарышы да шуның белән бәйле, икенче яктан, әдипләрнең публицистик тәнкыйть төрен, шулай ук фәлсәфилекне үз итүен, гомумән, төрле юнәлеш-агымнарга, алым-чараларга хас элементларны үз эченә алган тәнкыйть синтезын күрәбез. Бу яктан анда образлылык һәм логик эзлеклелек, сәнгатилек һәм фәннилек үзара кушылып китә. «Язучы тәнкыйте үзенең иң яхшы үрнәкләрендә авторитарлык һәм ваклану күренешләре булмавы белән кыйммәт. Ул тәнкыйть жанрлары өлкәсендә үзен иркенрәк тоя: язучы-тәнкыйтьчеләрдән сирәге генә жанрлар чиге турында уйлана, әмма киң катлам укучылар белән аралашуның яңа актив формаларын эзләү бара»[1]. Язучы тәнкыйтенең яшәү рәвеше булып көндәлекләрдәге язулар, хатлар, хәзерге әдәбият турында публицистик мәкаләдә яисә әдәби әсәрдә урын алган уйланулар-фикерләр дә тора.

---

[1] *Лежнев С.П.* Проблемы писательской критики // Русская литературная критика. Саратов: Изд-во Саратовского ун-та, 1994. С. 84.

Мисал өчен, «өлкәннәр өчен дә шигырьләр язучы балалар шагыйре»[1]. Р. Миңнуллин иҗатында публицистика, очерклар, истәлекләр, әңгәмәләр, рецензия-бәяләмәләр, китап күзәтүләр тулы бер катлам тәшкил итә. Әлеге күпсанлы язмаларында ул дөнья әдәбиятын, бигрәк тә балалар әдәбиятын яхшы белүче, татар әдәбиятының алтын баганалары булып торучы әдипләр иҗатын тирән аңлаучы, яңадан-яңа якларын барлаучы шәхес булып ачыла. Татар шигъриятенең, шул исәптән балалар әдәбиятының бүгенгесе өчен борчылып яшәүче, замандаш шагыйрьләргә һәм яшь авторларга гаять игътибарлы булуы белән дә әдәби тәнкыйть үсешенә җитди өлеш кертә. Р. Миңнуллинның әдәби тәнкыйтькә караган язмаларының бер үзенчәлеге шунда, аның фикер сөреше, уйланулары һич тә аерым бер автор яисә китап белән генә чикләнми. Аңа киңлек, масштаблылык хас. Балалар шигъриятенең шәхес тәрбияләү белән бәйле булуын тирәнтен аңлап, шигъри сүзнең көченә ышанып, ул болай дип яза: «Бала күңеленә үз вакытында шигъри орлык салынган булса, ул инде гомер буе аны онытмый». Бу исә шигърият алдына зур таләпләр куя. Әдип соңгы елларда шигырь чыгаручылар, үзләрен шагыйрь дип санаучылар күбәюен билгели. Шигърият белән кызыксыну начар түгел, билгеле. Әмма, үзе язганча, «шунысы гына үкенечле: укучыларның шигъри зәвыгы бозыла. Шигырьнең асылы югала бара, күзгә күренеп бәясе төшә»[2]. Ә бит ул балалар әдәбияты өчен аеруча куркыныч. «Югары сәнгать әсәренә куела торган таләп белән генә балалар шигырен үстерергә мөмкин. Әгәр дә сабыйларга атап язылган әсәр сәнгать әсәре булмый икән, ул чагында аның файдасыннан зыяны күбрәк»[3].

Р. Миңнуллин үзенең язмаларында даими рәвештә шигърият, шигырь, лирик герой, моң, халыкчанлык, шигъри тел һ.б. турында уйлана, шуларга нисбәтле аерым авторларга кискен таләпләр дә куя. Шигърият дигән серле дөньяга саф күңел, ихласлык белән килүне яклый ул һәм җитди таләп-шартларны аерып күрсәтә. Беренчедән, туган җирне, илне, телне, халыкны ярату кирәк. «Шигърият яратудан туа, – дип яза әдип, – хәтта сатирик, юмористик шигырьләр дә шушы тойгының капма-каршысы булган нәфрәт хисенә нигезләнеп языла». Икенче бер шарт итеп ул үз-үзеңә ышаныч тойгысы булуны саный: «Халыкка кирәклегеңне тойганнан соң гына зур шагыйрь була аласың». Өченчесе – тормышны өйрәнү, битараф булмау. «Шигырь ул – кичерү, сагыну, уйлану

[1] *Миңнуллин Р.* «Әдип сәясәтче дә булырга тиеш» // Сайланма әсәрләр: 7 томда. 7 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. Б. 446.

[2] *Миңнуллин Р.* Өзәңгеләр өзелмәс (М. Кәбировның «Өзәңгегә баскан чак» җыентыгы) // Сайланма әсәрләр: 7 томда. 5 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. Б. 119–125.

[3] Миңнуллин Р. Балачакка шигырь кирәк! («Ки-кри-күк» җыентыгына кереш сүз) // Сайланма әсәрләр: 7 томда. 5 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. Б. 102.

дигән сүз. Тормыш, яшәү, бүгенге, киләге, халык, ил язмышы турында уйлану. Алар өчен борчылу». Шагыйрьнең бу фикере халыкчанлык төшенчәсе белән дә кушылып китә. «Халыкчан булу өчен халык кайгысы белән кайгырып, халык шатлыгы белән шатланып яшәргә дә кирәк шул. Халыкның үзе булырга кирәк». Дүртенчесе – ихласлык. «Ихластан яза белсәң, шигырь барыбер халыкка барып җитә, чөнки һәркемнең күңелендә моң белән бергә шигырь дә яши». Бишенчесе – күңелдә моң булу. Моң табигый булырга, еллар дәвамында җанның, күңелнең аерылгысыз кисәгенә әверелергә тиеш. Шул чагында гына ул укучылар күңеленә барып җитәчәк»[1]. Әдипнең әлеге теләк-уйлануларында шигъриятнең халкыбыз рухи тормышындагы урыны, әхлакый һәм эстетик вазифалары тагы да ачыла төшә.

Тәнкыйти язмаларның тагын бер төре буларак *укучы тәнкыйтен* аерып чыгаралар. Ул китап укучыларның үз заманы әдәби процессына, аерым әсәрләргә бәйле караш-фикерләре белән уртаклашуга нигезләнә. Әдәби әсәр киң катлам укучыга атап языла, шуңа да аларның мөнәсәбәте зур кызыксыну тудыра һәм газета-журналлар үз битләрендә әледән-әле укучылардан килгән хат-язмаларны урнаштыралар. Алар, гадәттә, «Укучы фикере» исеме астында тәкъдим ителә. Бу төр профессиональ һәм язучы тәнкыйтеннән ихласлыгы, укылган әсәр нигезендә туган хисси уйланулары, шәхси кичерешләрне чагылдыруы белән аерылып тора. Шул ук вакытта укучы тәнкыйте бертөрле генә түгел. Күбесе әдәби әсәргә бәйле туган беренче тойгыларга нигезләнсә, арада матур әдәбият белән даими кызыксынып баручы, теоретик әзерлекле, анализ принципларын яхшы ук үзләштергән укучыларның язмалары да бар. Мисал өчен, С. Хәйретдинова-Карюкованың «Әсәрләрендә якты нур бар» мәкаләсе, М. Маликова иҗаты белән танышканнан соң, «бер тында» язылган. Автор вакыйга һәм күтәрелгән мәсьәләләрнең чор-заман рухы белән сугарылуын, гаять тә актуаль булуын билгели. Шуларга бәйле илдәге сәяси-иҗтимагый мохиткә үзенең бәясен бирә. Укучы тәнкыйтенә хас булганча, М. Маликова иҗатының идея-эстетик ягына тукталмыйча, әхлакый-тәрбияви әһәмиятен ача: «һәр әсәрендә ниндидер якты көч, якты нур бар. Иң авыр мизгелләрне тасвирлаганда да укучы шул якты нурга тотынып өметкә бара» [2].

Тәнкыйть язмасының максат-бурычларына, кемне күздә тотып язылуына, анализ объекты булып торган әсәрнең үзенчәлегенә, яңа эстетик концепцияләр эзләүгә һ.б.га нисбәтле тәнкыйтьнең филологик, фәлсәфи, публицистик, аналитик дип аталган төрләре дә аерып чыгарыла.

[1] *Миңнуллин Р.* «Әдип сәясәтче дә булырга тиеш» // Сайланма әсәрләр: 7 томда. 7 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. Б. 445–446.

[2] *Хәйретдинова-Карюкова С.* Әсәрләрендә якты нур бар // Мәйдан. 2005. № 3. Б. 143.

*Филологик тәнкыйть* әдәби әсәрне тел-стиль үзенчәлекләре ягыннан тикшереп бәяләүне күздә тота. Ул өйрәнү объектының идея-проблематика ягын, киң планда бөтенлекле анализны читтә калдырып, алгы планга грамматика һәм сурәт чаралары, тел билгеләре кебек мәсьәләләрне чыгара. Бер яктан караганда тәнкыйтьнең бу төре таррак яисә берьяклырак булып тоелса да, асылда һич тә алай түгел. Аның әһәмияте халыкчан тел билгеләренә укучының гына түгел, бәлки язучыларның да игътибарын җәлеп итүдә. Әдәбият – сүз сәнгате. Әлеге төп үзенчәлеге матур әдәбият әсәрләренең теленә гаять зур таләпләр куя. «Әдип биниһая зур байлык белән эш итә. Ул хәзинә язучының үз карамагында, үз күңелендә. Димәк, төзү материалыннан иркен, тоткарлыксыз файдалану өчен язучыдан тел байлыгын бөтен тулылыгында үзләштерү сорала»[1]. Шуңа да тәнкыйть язмасында тел-стиль мәсьәләләренә игътибар итү мөһим бурычлардан санала.

Ф. Сафиуллинаның «Хәзерге әдәби телебез үсеше» язмасы хәзерге әдәби процесска тел-стиль үзенчәлекләре ягыннан бәя бирүнең матур үрнәге булып тора. Автор әлеге катлаулы мәсьәләнең бөтен әсәр тексты белән бәйләнештә, әдипнең сурәт чаралары байлыгына нисбәтле билгеләнүен ассызыклый. Аның фикеренчә, «татар әдәби теленең хәрәкәте, яңалыгы, яшәүчән көче матур әдәбиятның төрле жанрларында»[2] бердәй тигез чагыла. Язучы сайлаган, иҗат иткән жанр тел-өслүб чараларының әлеге стильгә тәңгәл килүен таләп итә. Әдәбият галимнәре билгеләп үткәнчә, хәзерге хикәяләүдә автор вазифасы зур үзгәреш кичерә. Бу исә, бер яктан, драма төренә хас үзенчәлекнең проза әсәренә дә үтеп керүенә китерсә, икенче яктан, әсәрдәге эмоциональлекне, киеренкелекне арттыра.

Ә. Шәрипов «К. Сибгатуллин шигырьләренең сәнгатьчә эшләнеше» дигән мәкаләсендә[3] әдип шигырьләренең строфа төзелешен, тел-сурәтләү чараларын, ритмын һ.б. компонентларын тикшерә. Автор шагыйрьнең оригинальлеген, поэтик ачышларга килүен билгеләп, иҗатына халкыбыз зирәклеген, акылын-фәлсәфәсен туплаганлыгын ачуга килә. Алар нигезендә халыкчан әйтелмәләрнең, зирәк фикерләрнең тирән, мәгънәле әдәби функция үтәве ята. Мәкалә авторы шагыйрьнең бик күп фикерләренең халык теленә мәкаль-әйтем булып кереп китүен конкрет мисаллар белән раслый һәм, бер үзенчәлек буларак, К. Сибгатуллинның поэтик фикерләве антитезага нигезләнгән булуы турында нәтиҗә ясый.

---

[1] *Хатипов Ф.М.* Әдәбият теориясе. Казан: Мәгариф, 2000. Б. 74.

[2] *Сафиуллина Ф.С.* Хәзерге әдәби телебез үсеше // Казан утлары. 2002. № 11. Б. 151–159.

[3] *Шәрипов Ә.М.* Кадыйр Сибгатуллин шигъриятенең сәнгатьчә эшләнеше // XX гасырның 70–90 нчы еллар татар поэзиясе контекстында Кадыйр Сибгатуллин иҗаты. Чаллы: Набережночелнинская типография, 2008. Б. 17–19.

Филологик анализның тагын бер уңышлы үрнәге буларак Ф. Хәсәнованың «Ренат Харис шигърияте» мәкаләсен[1] күрсәтергә мөмкин. Замандаш шагыйрьнең иҗаты поэтик алымнар кулланылышы ягыннан тикшерелә һәм бу бүлекчә исемнәрендә дә чагылыш таба: «Шигырьдә металогик алым», «Шигырьдә автологик алым», «Шигырьнең поэтик синтаксисы». Автор, Р. Харисның лирик һәм эпик әсәрләре текстын структур яктан тикшереп, әдипнең идея-эстетик карашларын, сәнгати эзләнүләр юнәлешен, киң планлы поэтик дөньясын шактый тулы ачуга килә.

Югарыда әйтелгәнчә, тәнкыйтьнең бер үзенчәлеге булып аның төрле фәннәр һәм иҗтимагый процесс белән тыгыз бәйләнеше тора. Әдәби әсәрне яисә әдәби процессны бары эстетик яктан гына бәяли торган тәнкыйть юк, булса да үтә максатчан язылганы гына. Тәнкыйть язмасында төрле аспектка өстенлек бирелергә мөмкин. Бу яктан караганда тәнкыйть публицистика белән аеруча тыгыз бәйләнештә булып, соңгысының элементлары теге яки бу дәрәҗәдә һәр төр тәнкыйтьтә урын ала. Аерым хезмәтләрдә исә публицистик як өстенлек алып, аларны *публицистик тәнкыйть* дип атау кабул ителгән. Аның урыны төрле чорларда төрлечә булу күзәтелә. XX гасырның 80 нче еллар ахыры – 90 нчы еллар башында бу төр тәнкыйть аеруча киң яңгыраш ала. Ул күптөрле сәбәпләр белән аңлатыла: газета-журналлар артып, аларда махсус тәнкыйть рубрикалары ачылу; халыкның үткәне белән кызыксынуга бәйле әдәби ядкәрләрне заман биеклегеннән яңача бәяләү омтылышы көчәю; социаль-иҗтимагый тормыштагы үзгәрешләр гаять үзенчәлекле булып, тәнкыйть язмасында аларны читләтеп үтү мөмкин булмау; чынбарлык вакыйгалары чагылган әсәрләрдә публицистик эчтәлекнең киң урын алуы һ.б. Гомумән, публицистик тәнкыйть әдәби әсәрне җәмгыятькә, андагы процессларга бәяле тикшерүгә йөз тота. Шул сәбәптән яшәешкә социологик характеристика мөһим урын алып тора һәм ул язма структурасының башка элементлары белән тыгыз үрелеп бара. Әлеге төр тәнкыйтьнең тагын бер сыйфаты булып, аның укучыга юнәлтелгән булуы санала. Бу исә, үз чиратында, китап укучыларның зәвыгы төрле булуны, кызыксыну дәрәҗәсен исәпкә алуны таләп итә. Мондый хезмәтләрдә әдипнең үзе, дөньяга карашы, әсәренең язылу тарихы турында мәгълүматлар бирү белән бергә, иҗтимагый тормыштагы мәсьәләләр дә үрелеп бара. Әлеге сыйфатлар чагылыш тапкан автор буларак, Ә. Еники хезмәтләренә мөрәҗәгать итик.

Ә. Еникинең публицистик язмаларында, аерым алганда, «Соңгы китап»ындагы әдип, әдәбият, әсәрләренең язылу тарихы, аңа йогынты ясаган шартлар турындагы уйлануларында сүз сәнгате алдында торган

[1] *Хәсәнова Ф.Ф.* Ренат Харис шигърияте. Казан: Школа, 2005. 260 б.

бурычлар, үткән әдәбият традицияләре һәм заманга хас яңачалыклар, әдәби процессның төп тенденцияләрен ачу, билгеле бер дәрәҗәдә үсеш перспективаларын билгеләү үзара үрелеп бара. Иҗат кебек изге гамәлгә килүчеләргә олы әдип, Р. Фәйзуллин сүзләре белән әйткәндә, «тирән әхлакый сабаклар бирә»[1]. Аларның берсе – үзеңә хас язу стилен табу, чөнки ул каләм тибрәтүчедән чын иҗатчыга үсүнең төп шартларыннан санала. Икенчесе – гади, табигый итеп язу, ачык һәм ихлас булу. Өченчесе – акыл һәм йөрәк эшенең зур җаваплылык икәнен тою. «Ихлас теләк минем иҗатымда төп максатка да әйләнде: кешеләр гадел, намуслы булсын! – менә нәрсә хакында мин язарга тиеш», – ди ул. Дүртенчесе – «җәмгыятьнең тазалыгы өчен борчылу, аңардагы кимчелекләр өчен көенү, шуларны фаш итүдән курыкмау» – язучының гражданлык йөзе шулар белән билгеләнә. Бишенчесе – «чын язучы гомере буена өч вакыт эчендә яши: үткәнне онытмый, бүгенгене күрә, киләчәкне уйлый»[2]. Алтынчысы – язучы һәрвакыт матурлыкка омтылып, матурлыкка сокланып яшәргә тиеш. Җиденчесе – әдәбиятның беренче сүзеннән башлап соңгы ноктасына кадәр тел сәнгате икәнен һәрдаим истә тоту. «Хикмәт шунда ки, дип яза әдип, – әйтәсе һәм күрсәтәсе килгән бөтен нәрсә – фикер һәм хистән алып, төскә һәм искә (мәсәлән, чәчәк исе) хәтле – үзенең иң дөрес, иң төгәл сүзен табарга тиеш»[3]. Аның әлеге теләк-фикерләрендә әдәбиятның сүз сәнгате буларак үзенчәлекләре дә, бурыч-вазифалары да, халыкның рухи тормышындагы роле дә ачыла.

Хәзерге әдәби тәнкыйтьнең публицистика белән үрелеп баруы, тормыш-яшәеш мәсьәләләре аша җитди фәлсәфи сорауларга килү мөмкинлеге бирә. Икенче яктан, миллилек сыйфаты белән сугарылган хәзерге сүз сәнгате тәнкыйтьтә дә милләт язмышына кагылышлы мәсьәләләрнең киң планда урын алуына, еш кына Үткән һәм Киләчәк, Язмыш һәм Хакыйкать, Фаҗига һәм Өмет һ.б. төшенчәләргә нисбәтле тикшереп бәяләнүгә китерә. Шул яссылыкта хәзерге тәнкыйтьтә фәлсәфилек киң урын ала. *Фәлсәфи тәнкыйть* дип аталган күренеш һич тә бертөрле генә түгел, дөресрәге ул башка төрләр белән тыгыз бәйләнештә килә. Еш кына символик һәм импрессионистик тәнкыйтьтләрдә фәлсәфилек мөһим компонент булган кебек, фәлсәфи тәнкыйть тә бик теләп символик билгеләрне, импрессионистик сыйфатлар һ.б.ны үзенә ала. Бу төрдә аеруча уңышлы эшләүче И. Вәлиулла «Мәңгелек бәхет эзләреннән....», «Һәр шагыйрь – бер дәрья...»[4] кебек тәнкыйть җыентыкларында, күпсанлы

[1] Олуг әдибебез бар! (Татарстанның халык язучысы Ә. Еникигә 90 яшь) // Казан утлары. 1999. № 3. Б. 49.

[2] *Еники Ә.* Әсәрләр. 5 томда. 4 т.: Соңгы китап. Истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. Б. 461–463.

[3] Шунда ук. Б. 220.

[4] *Вәлиулла И.Ә.* Мәңгелек бәхет эзләреннән… Эсселәр. Казан: РИЦ «Школа», 2004. 128 б.; *Вәлиулла И.Ә.* Һәр шагыйрь – бер дәрья... Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 156 б.

мәкаләләрендә үткән һәм хәзерге татар әдәбияты үрнәкләрен Иман, Рух, Милләт, Моң, Сабантуй, Мәхәббәт, Көрәш, Ирек, Намус, Вакыт, Галәм һ.б. мәңгелек төшенчәләргә нисбәтле тикшерә. Әлеге аспектта танылган әдипләр иҗаты яңа яктан ачыла. Р. Низами язганча, соңгы җыентыгының «кайсы гына битен ачып укысаң да, авторның һәр җөмләсе моңга, нурга, фәлсәфәгә манчылган!»[1]. И. Вәлиулланың «Яңа маяклар эзләгәндә...» мәкаләсе[2] аналитик күзәтүләре, фикри җегәре, оста чагыштырулары, җентекле уйланулары, дәлилле нәтиҗәләре белән аерылып тора. Совет чоры татар шигъриятенә күз ташлап, ул ерак гасырлардан килүче Яхшылык, Сафлык, Иптәшлек, Дуслык һ.б. рухи кыйммәтләрнең коммунистик идеология эчендә «эретелүен» билгели. Соңгы еллар татар шигъриятендә яшәешнең, чынбарлыкның олы мәгънәсен эзләп табуга тиң үзгәрешләр баруын мисаллар аша күрсәтә. Аның беренче нәтиҗәсе буларак, күңелләрдә Өмет уянды, дип ачыклый автор. Икенче бер үзенчәлек булып үткән чор җәмгыятенең асылын тәнкыйтьләү тора. Болар исә ерактагы һәм якындагы тарихны хәтергә төшерү белән бергә бара. Тәнкыйтьче фикеренчә, сүз иреге, хәбәрдарлык, демократия, сайлау хокукы, шәхси милеккә хокук һ.б. төшенчәләр демократик романтизм тудырды. Аның белән тыгыз бәйләнештә милли романтизм төп Маягыбызга әверелде. Соңгысы исә әдәбиятта тематик төрлелеккә китерде: 1) Казан ханлыгының яулап алынуы; 2) милли-дини изелү; 3) милли коллыкта татар яшәешенең деградацияләнүе; 4) яшьләрнең маңкортлашуы; 5) яңа милли Яңарыш – Ислам дterritory кайтуы; 6) татар теленең күтәрелүе; 7) югалган дәүләтчелекне торгызу. И. Вәлиулла үзенең фикер-карашларында хәзерге поэзиянең әйдәп баручы вәкилләре булган Зөлфәт, Р. Харис, Р. Миңнуллин, Р. Гаташ, Р. Мингалим, И. Юзеев, Р. Фәйзуллин, Р. Зәйдулла, Г. Морат, М.Әгъләм, Р. Низами һ.б.ның иҗатларына таяна. Әмма соңгы вакытта милли азатлык хәрәкәтенең, гомумән, демократик үзгәрешләрнең җитди каршылыкка очравын билгеләп, автор болай яза: «Әгәр демократик романтизм кыргый капитализмның тынчу атмосферасында җан бирсә, милли романтизм да шул ук кыргый капитализм, Ичкерияне канга батыру атмосферасында югалды дигән сүз. Җәмгыятьнең криминальләшүе, бай-ярлыга бүленүе, полярлашуы, рухи яктан саегуы да милләт эчендәге бердәмсезлекне арттырды түгелме?» Һәм дәвам итә: «Бүген романтизм чоры узды кебек. Социаль системаларны алыштыру җәмгыятьне кешелеклерәк ясамады. Дин тоту иреге кайтты, әмма, кызганычка, дин әле җәмгыятьтә үзенең лаеклы урынын ала алмады. Ә асылда бит Ислам бүгенге татар халкы өчен табылган төп Маяк булып тора! Ләкин ни өчен Ислам кебек дини маяклар булганда да җәмгы-

[1] *Низами Р.* Тәнкыйть тә – тирән дәрьядыр // Казан утлары. 2007. № 6. Б. 172.
[2] *Вәлиулла И.Ә.* Мәңгелек бәхет эзләреннән… Эсселәр. Казан: Школа, 2004. 128 б.

ять гуманлашу кичерми, кешеләр күңеленә Миһербанлык, Мәхәббәт, Яхшылык, Сафлык, Дуслык кебек хис-тойгылар кайтмый? Әллә без шул Маякларның яктысын күрә алмыйбызмы, әллә инде шул Маякларга таба юнәлергә дә теләмибезме?» Әнә шундый шактый күңелсез уйланулардан соң, И. Вәлиулла татар шигъриятенең киләчәген фәлсәфилеккә йөз тотуда күрә.

* * *

Әдәбият-сәнгатьнең торышы, киң планда мәдәниятнең язмышы, үсеш-үзгәреш мөмкинлекләре, әдәби тормыштагы аерым вакыйгалар, җитди мәсьәләләр, шуларга бәйле бәхәс-каршылыклар, шул исәптән теоретик һәм методологик билгеләмәләр һәм аларның диалогик характеры аеруча тулы дискуссияләрдә урын ала.

XX йөз ахыры – XXI йөз башы тәнкыйтенә хас сыйфат-билгеләрне, аның яңарышын билгеләү максатында әлеге иҗат төренең хәлен, үсеш-үзгәрешен билгеләүче төп урын булган әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси «Казан утлары» журналы битләрендә барган ике дискуссия материалларына мөрәҗәгать итик. Журнал редакциясе 1999 елда «Туксанынчы еллар әдәбияты», 2004–2005 елларда «Безнең заман герое» дип аталган дискуссияләр үткәреп, галим, тәнкыйтьче, язучы һәм, гомумән, китап укучыларның игътибарын әлеге мәсьәләләргә юнәлтә.

Редакция тәкъдим иткән сорауларга җавап рәвешендә «Туксанынчы еллар әдәбияты» дип аталган сөйләшү шактый кызыклы, җанлы үтә. Асылында әлеге фикер алышуда үзгәртеп кору башланганнан соңгы татар әдәбиятының гомуми торышына бәя бирү үзәктә тора. Журнал битләрендә урын алган төрле характердагы мәкаләләр сүз сәнгатендәге уңышлы һәм кимчелекле яклар турында гомуми күзаллау булдырырга мөмкинлек бирә. А. Хәлим публицистик рух белән сугарылган язмасында[1] әдәби әсәрнең укучы тарафыннан кабул ителүе, вакытлар узганнан соң да аңа янәдән әйләнеп кайту теләге тусын өчен кирәкле шартларны күрсәтә: а) чын сәнгать әсәре тәэсирле булырга, тетрәтергә тиеш (мисал буларак М. Юнысның «Шәмдәлләрдә генә утлар яна» повестен атый); ә) үз вакытында укучыга ирешү, яңа сүз булу (тәнкыйтьче А. Гыйләҗевның «Йәгез, бер дога...» романы соңгарак калып чыкты дигән фикердә тора); б) матур телгә, бай сурәтләү чараларына нигезләнгән сюжетның мавыктыргыч итеп корылуы; в) чын әсәр «татарның, заманның үсеш, я булмаса, чигенеш тенденциясен ачып кына калмаска, көтмәгән сюжет нигезендә нечкә сурәтләү чаралары, ихлас идея, соклангыч тел белән без күргән дөньяны чалканы белән әйләндереп салырга тиеш».

---

[1] *Хәлим А.* Туксанынчы еллар әдәбияты // Казан утлары. 1999. № 4. Б. 137–140.

Әдәбияттагы үзгәрешләргә килгәндә, җитди яңалык дип чиста тәнкыйть тә, чиста публицистика да булмаган яңа жанрны – рухани публицистиканы атый. Аныңча, мондый әсәрләрдә заман тенденциясе төп ачышны тәшкил итә. Гомумән, 1990 еллар башыннан безнең нәфис әдәбиятның заман сулышы, публицистик тын алыш белән сугарылуын билгели. Ә инде «татар әдәбиятын гасырлар буе артка сөйрәп торган килгән сыйфат – ул шәхесне кол дәрәҗәсенә төшергән тыйнаклык, – дип яза тәнкыйтьче. – Бу куркаклык, төшенкелек, бар нәрсә белән килешә торган мич башы тыйнаклыгы. Безнең әдәбият татар кешесендә шундый тыйнаклык тәрбияләп, егерменче гасыр азагында төп башына утырды. Безнең бурыч – яңа, көрәшчел, кара көчләргә каршы торучы әдәбият тудыру».

Шагыйрь Рәдиф Гаташ мәкаләсендә[1] сүз бара торган чорның әдәби йөзен билгеләүчеләр буларак Ә. Еники, Г.Ахунов, А. Гыйләҗев, Н. Фәттах, Ә. Баянов, М. Юныс исемнәрен атый, чөнки «шигырь сулышы – шигырь аша дога, язмыш тавышы; шигырь җененнән ярал- ган бер рух яши бу әдипләрдә һәм шул нәрсә алар иҗатын кызыклырак, җанлырак итә». Соңгы еллар әдәби казанышы дип саналырдай әсәрләр арасыннан «шәкел, стиле ягыннан булсын, йә киңлеге, фикри тирәнлеге, киң колачлыгы җәһәтеннән булсын, татарның рухи тамырларын бар- лау ягыннан булсын – һәр ноктадан камил һәм яңача бер үрнәк» булган «Догалы еллар»ны (М. Галиев) аерып куя. Ә инде бүгенге шигъртияттәге кимчелекләргә килгәндә, аеруча поэма жанрында үсеш, яңалык булмау- га борчыла ул. «Шигырьдә дә күбрәк ачык капкаларны кагу. Күбрәк тапталган темаларга язу, шәрә публицистика, йәки милләт турында “ачыш”лар. Яки тоташ чордан, җәмгыятьтән зарлану... Әмма борынгы традицияләргә, жанрларга кайту да бераз сизелә».

Җыйнак, әмма фикер-мәгънәгә бай язмасында Т. Миңнуллин идео- логик чикләүләр юкка чыкса да, 1990 еллар татар әдәбиятында ил күләмендә танылырдай казанышлар булмавын билгели һәм аның төп сәбәпләренең берсен ашыгу, кабалану аркасында тирәнгә чумып уйла- нулар, мохитне, заман кешесен төрле яклап өйрәнергә вакыт җитмәүдә күрә. Танылган драматург фикеренчә, хәзерге сүз сәнгате алдында шәхес белән шәхес, кеше белән җәмгыять, кеше белән табигать мөнәсәбәт- ләрен югары сәнгать ысуллары белән сурәтләү бурычы тора. Һәр татар язучысы кешене шәхес итеп, татарны милләт итеп, дөньяны камил итеп саклап калуга бөтен көчен куярга тиеш дип саный ул[2].

Фикер алышу уңае белән урнаштырылган язмалар арасыннан тагын икесен атап үтик. Танылган тәнкыйтьче Р. Сверигин чор әдәбияты- ның йөзен билгеләүче берничә әдипнең иҗатларына хас сыйфатларны

[1] *Гаташ Р.* Туксанынчы еллар әдәбияты // Казан утлары. 1999. № 4. Б. 140–142.

[2] *Миңнуллин Т.* Туксанынчы еллар әдәбияты // Казан утлары. 1999. № 5. Б. 136–137.

билгели. Берсе – Ф. Яруллин – «һәрвакыт үзе булып – халык, милләт, җәмгыятебезне борчыган, заман, тормыш проблемаларын йөрәге аша үткәрүче, кичерүче һәм сынмас, буйсынмас рухлы олы шәхес»; икенчесе – М. Юныс – «хөр фикерле, югары хәзерлекле, кыю, гадел һәм дөреслекне яклаучы гали зат»; өченчесе – Ә. Баянов – «проза, лирика, драма күренешләренең үзенчәлекле үзара үрелеше, прозасындагы мәгънәле шигърият, әдәби детальләр һәм символларның функцияләре, юмор бизәкләре» белән аерылып торучы әдип[1].

Башкортстанда яшәп иҗат итүче тәнкыйтьче С. Хафизов 90 нчы еллар сүз сәнгатенең торышын күпгасырлык әдәбиятыбыз фонында тикшерә. Аерым бер табышлар булса да, ул югалту-җитешсезлекләр өчен аеруча борчыла. «Фаталь мохит идеясен кабатлау артты, – дип яза ул. – Мондый әдәбиятта Җан бөеклеге, геройлыгы яисә трагедиясе юк. Җан хәрәкәте юк. Ахыр чиктә бәни адәмне алга, яхшы тормышка, матурлыкка дәртләндергән рух, иреккә чакырган мотив юк». Тәнкыйтьче «кеше концепциясе, геройны тасвирлау алымнарының һаман искечә калуын да искәртеп үтә. Бүгенге һәм алдагы көннәр әдәбиятында «әхлакый үзәге көчле, кешеләр каршында җаваплылыгы зур, тирәлеген уңай якка үзгәртергә сәләтле олпатлы, чын һәм натураль кешеләрне» күрергә тели[2].

Шул рәвешле, «Туксанынчы еллар әдәбияты» исеме белән барган фикер алышу, тәнкыйтьчеләрне барлау, активлаштыру белән бергә, XX гасыр ахыры татар әдәбиятында барган эзләнүләрне, үсеш-үзгәреш үзенчәлекләрен ачыклауга, киләчәк перспективаларын билгеләүгә билгеле бер өлеш кертә. Язучы тәнкыйтенең үсүе, шуңа да импрессионистик эчтәлекле, публицистик рух, уй-фикер белән үрелеп барган язмаларның артуы күзәтелә. Әмма тәнкыйтьтә профессиональлекнең җитмәве, аналитик тәнкыйтьтән бигрәк, шәхси уйлануларга нигезләнүнең өстенлек итүе дә ачыла. Шулар белән бергә, әдәби процесста тәнкыйтьнең урынын билгеләү, киләчәктә үсеш юлларын барлау ягыннан файдалы булуын атап үтәргә кирәк.

«Казан утлары» журналы редакциясе тәкъдим иткән «Безнең заман герое» исемле бәхәс (2004–2005 еллар) җәмәгатьчелектә зур кызыксыну уята. Монда берничә факторны искә алырга кирәк: беренчедән, кешенең шәхесен формалаштыруда гаять зур роль уйнаган сүз сәнгатенең асылы, ул яклаган һәм саклаган идеяләр, гомумкешелек кыйммәтләре нәкъ менә әдәби геройлар белән бәйле. Бу аеруча проза һәм драматургия төрләренә хас. Г. Исхакый һәм Г. Камал, Ф. Әмирхан һәм Г. Ибраһимов, Ә. Еники һәм А. Гыйләҗев, М. Мәһдиев һәм Т. Миңнуллин кебек бик күп танылган каләм ияләренең исемнәрен атадыкмы, хәтергә алар иҗат иткән үзенчәлекле һәм гыйбрәтле, кабатланмас характерга ия геройлар килә:

[1] *Сверигин Р.Х.* Туксанынчы еллар әдәбияты // Казан утлары. 1999. № 6. Б. 126–128.

[2] *Хафизов С.* Туксанынчы еллар әдәбияты // Казан утлары. 1999. № 12. Б. 144–147.

Зөләйха һәм Хәмзә бай, Хәят һәм Карлыгач-Сылу, Акъәби һәм Бибинур карчык, Шәяхмәт һәм Әлмәндәр һ.б. Әдәбиятның төп сурәтләү объекты булган кеше һәм аның катлаулы тормышын әдәби сурәтләрдә чагылдыруда авторның сәнгати фикерләү үзенчәлекләре, дөньяга карашы киң урын ала. Икенчедән, фикер алышу темасының шулай аталуы бүгенге әдәбиятның һәр төре турында киң планда сөйләшү алып бару мөмкинлеге бирә. Ә бу исә хәзерге татар сүз сәнгатенең төп тенденцияләрен, сәнгати эзләнүләр юнәлешен, табыш һәм югалтуларын билгеләргә мөмкинлек тудыра. Өченчедән, әдәби процесста арттарак калып килгән тәнкыйтьне җанландыруга, яңа яшь көчләрне тартырга ярдәм итә.

Редакцион мәкаләдә фикер алышуның юнәлешен билгеләү рәвешендә, гомумән, уйлану-борчылу ачык чагыла: хәзерге җәмгыятьтә «матур әдәбиятның роле кимеде түгелме? «Әдәбият – тормыш көзгесе» дигән шигарьне өлге итеп алган күбебез өчен табигый борчылудыр бу. Моңа кадәр без әдәбиятны кеше аңын формалаштыруда иң төп факторларның берсе дип инанып килдек. Хәзерге вәзгыятьтә бу чыннан да шулаймы?» Әлеге уйлануларга бәйле конкрет сораулар куела: «Бүгенге татар әдәбиятының (соңгы 20 елда) каһарманнары кемнәр? Аларда яшьләр күңелен яуларлык нинди сыйфатлар бар? Язучыларның бу каһарманнар образын ачып салуда уңышлы һәм кимчелекле яклары нидән гыйбарәт? Гомумән, ихтирамга лаек олы язмышлы шәхесләр тиешле дәрәҗәдә чагылыш табамы?»[1].

Дискуссия уңае белән журнал битләрендә Р. Шәрәфиев, Р. Фәизов, Р. Фәтхрахманов, М. Вәлиев, Ә. Рәшит, Р. Мостафин, Ә. Әхмәдуллин, Н. Гариф, Д. Заһидуллина, К. Тимбикова, Ә. Закирҗанов, А. Хәлим, С. Хафизов һ.б.ның мәкаләләре басылып чыкты. Аерым авторлар хәзерге әдәби процессны тулаем иңләсә, икенчеләре аерым әдәби төрләргә туктала, өченчеләре исә заман героен чынбарлыгыбыздан эзли яисә үткән тарихның билгеле шәхесләрен замандаш итеп күрәсе килә. Фикер алышуда әдәби үсешнең төп тенденцияләрен, тема-проблемалар төрлелеген, аерым төр-жанрлар торышын билгеләү, заман героена хас сыйфат-билгеләрне ачыклау, сәнгати уңышларны һәм җитешсезлекләрне аерып күрсәтүгә бәйле шактый җитди, кызыклы һәм фикер төрлелегенә, каршылыкларга, яңа уйлануларга этәрә торган сөйләшү булды.

Әлеге дискуссияне башлап җибәргән Р. Шәрәфиев тормышка якынаюны максат итеп, әйләнә-тирәбездәге әхлаксызлык күренешләренең бүгенге әдәбиятыбызны басып алуы өчен борчыла. Аның фикеренчә, үзебез кебек вак интригалар белән яшәүчеләрне, уй-хыяллары көнкүреш ыгы-зыгысыннан, парлашу-аерылышу кичерешләреннән үза алмаган, аның каравы уйлап чыгарылмаган әдәби геройларның чит ил телесе-

[1] Дискуссия: «Безнең заман герое» // Казан утлары. 2004. № 1. Б. 161.

риалларыннан безнең сүз сәнгатенә үтеп керүе һәм тиз арада түргә үк менеп утыруы матур әдәбиятыбыздагы эзләнүләрнең сыегаюын күрсәтә. Андый әсәрләрнең тулы бер катлам тәшкил итүенә нигезләнеп, аларны «бозыклык реализмы» дип атый[1]. Ә менә Р. Фәизовның «Алар безнең арада» мәкаләсе[2] шактый үзгә концепциягә корылган. Автор ачык итеп соцреализм чоры әдәбиятындагы уңай геройларны сагына. Үз фикерен әлеге иҗат методы мәсләгенә нигезләнеп, әдәбиятыбызда чын сүз осталары үсеп чыгуы белән дәлилләргә омтыла. Ә бит Ә. Еники, А. Гыйләҗев, Н. Фәттах кебек әдипләребезнең идея-эстетик карашлары соцреализм кысаларын читләтеп үтеп, гомумкешелек кыйммәтләренә, милләт проблемаларына нигезләнүе белән киң яңгыраш алды. Тәнкыйтьченең шактый киң планда әдәби герой, прототип, индивидуальлек һәм гомумилек мәсьәләләре турында фикер йөртүе дә берьяклы. Үзен «әдәбият солдаты» дип атаган тәнкыйтьченең Ф. Латыйфи әсәрләрендәге персонажларны социалистик реализм геройлары дип атавында да әлеге иҗат методын бөтен асылында аңламавы күренә. Шуларга нигезләнеп, хәзерге әдәбияттагы аерым сыйфат-билгеләрне аерып чыгара: 1) әдәбиятның үткән заманны тасвирлый башлавы; 2) үткән чорлар сурәтләнгән әсәрләрнең геройлары, аларның гамәлләре һәм рухлары бүгенге көнгә килеп тоташу; 3) әдәбият тулы канлы тормыш белән яши дип әйтергә нигез булу; 4) уртага бүгенге көн геройларын куеп язылган әсәрләрдә шактый берьяклылык шәйләнү.

Журналда басылып чыккан язмалар арасында үзенең эчтәлеге һәм максаты белән Р. Фәтхрахманов мәкаләсе[3] игътибарга лаек. Үзгәртеп корулар башланып, яңа юнәлешләр, әдәбиятның фәлсәфи һәм рухи концепциясен эзләү чорында татар әдәбиятында ике юнәлеш барлыкка килде дип саный тәнкыйтьче. Беренче юнәлеш тарафдарлары эзләнүләренең нигезендә үткәндәге казанышларны кире кагу, яңага омтылып, вәзгыятькә аналитик бәя бирергә тырышу ята. Әлеге «яңа традицион булмаган агым тарафдарлары исә популярлык мәсьәләсенең чишелешен азгынлык һәм оятсызлык пропагандалау аша хәл итәргә омтылалар» дип яза ул. Р. Фәтхрахманов фикеренчә, икенче юнәлешне ислам дине кануннарына нигезләнгән фикер-карашларга таянып, чынбарлыкның мөһим сорауларына мөрәҗәгать итүчеләр тәшкил итә. Әдәбиятны нечкә тоемлаучы буларак, тәнкыйтьче Р. Сибат, М. Кәбиров әсәрләренә тирән фәлсәфи-эстетик анализ ясый. Әлеге икегә бүленешнең нигезендә «әдипнең сурәтләү объектына карата тоткан позициясе» тора. Әгәр беренче төркем «тормыш тасвирын тудырганда нәфеснең иң түбән, иң актык теләкләрен кузгатуны һәм үстерүне максат» итеп

---

[1] Дискуссия: «Безнең заман герое» // Казан утлары. 2004. № 1. Б. 161.

[2] *Фәизов Р.* Алар безнең арада // Казан утлары. 2004. № 2. Б. 149–154.

[3] *Фәтхрахманов Р.Г.* Татарга сатма матбугат... // Казан утлары. 2004. № 3. Б. 158–162.

куйса, икенчеләр «үзенең мең елга сузылган тарихында тәкъвалык киемен үзенә өлге итеп алган» әдәбиятыбыз традицияләрен яңа шартларда үстерә. Тәнкыйтьче укучының китаптан, матур әдәбияттан читләшү сәбәпләрен түбәндәгеләрдә күрә: 1) матди бөлгенлек, акчасызлык; 2) рухи тамырларның коруы; 3) көнбатыш пропагандасы йогынтысында бер катлам укучының милли рухын югалтуы.

Р. Фәтхрахманов татар әдәбиятының бүгенгесен һәм киләчәген әдипләрнең ялган кыйбладан чын кыйблага борылуында, ягъни рухани карашларга нигезләнгән әхлакый кыйммәтләрне байрак итеп күтәрүдә күрә һәм фикерен болай дәвам итә: «Чын татар романының герое булырдай типларны, мөгаен, милләтнең (...) татарлыгын югалтмаган һәм сакларга омтылган катламы арасыннан эзләргә кирәктер». Әнә шундый геройлар иҗат итүчеләргә ул Ф. Бәйрәмова, А. Хәлим, Ф. Яруллин, Н. Гыйматдинова һ.б.ны кертеп карый. Тәнкыйтьченең әлеге бүленешендә берьяклылык, ягъни дини-рухани юнәлештә язмаучыларның барысын да азгынлык һәм оятсызлыкны таратучылар итеп күрү сизелә. Шуңа да әдәбиятның киләчәген рухани карашларга нигезләнгән әхлакый кыйммәтләрне байрак итеп күтәрүдә күргән мәкалә авторы белән бәхәсләшү теләге кала: бер төрле генә уйлау һәм бәяләү чорын үттек бит инде, тормыш күпкырлы булган кебек, әдәбият та төрле булганда гына киңәеп, тармакланып үсәчәк.

Ә. Рәшит «Зурдан кубып сөйләшкәндә» мәкаләсендә[1] хәзерге татар шигърияте турында фикер йөртә һәм күпгасырлык рухи мираска бәйле мондый нәтиҗә ясый: «Борынгыдан калган бөек мирас безгә ышанычлы таяныч ноктасы булды. Иң сөенечлесе, без халкыбыз яулаган шул рухи биеклектә кала алдык». Ул бүгенге поэзиягә хас яңалыкүзенчәлекләр һәм кимчелекләр дип түбәндәгеләрне атый: 1) әдәбиятта юнәлеш-ориентирларның тарих ягына авышуы; 2) поэма яки дастан кебек жанрда вакыйганың һәм шәхеснең гамәл-кыланышында нинди фәлсәфи мәгънә ятуын ачыклауга игътибар арту, шул ук вакытта ачык кына сюжет сызыгы булмау; 3) публицистик башлангычның өстенлек итүе белән зур гомумиләштерүләргә килү; 4) шигъриятнең төп каһарманы булып тарихи шәхесләр һәм лирик «мин» тору; 5) бер-берсен баетып, тулыландырып гомум бер симфония хасил иткән жанр төрлелеге кимеп, нindидер абстракт «шигырь» төшенчәсе барлыкка килү; 6) темапроблематиканың тараюы, әсәр каһарманнарының конкретлыкларыннан баш тартып, ниндидер аморф хәлгә керүе күзәтелү һ.б.

Дискуссиягә килгән язмалар арасында фикер-карашларының ачыклыгы, конкретлыгы белән М. Вәли-Барҗылының «Күңел кемне көтә?» мәкаләсе дә[2] кызыклы. Танылган тәнкыйтьче безнең заман героена хас

[1] *Рәшит Ә.* Зурдан кубып сөйләшкәндә // Казан утлары. 2004. № 4. Б. 132–139.
[2] *Вәли-Барҗылы М.* Күңел кемне көтә? // Казан утлары. 2004. № 6. Б. 132–140.

сыйфатлар дип рухи сафлык, рухи ныклыкны, бүгенге тормышта нык күбәеп, көчәеп киткән эреле-ваклы әшәкелек ташкынына каршы тора алуны, шундый мохиттә яшәп тә буялмый, пычранмый кала алуны саный. А. Гыйләҗев, Ә. Еникиләрнең әнә шундый геройлары «олы юлның якты маяклары сыман еллар аша да балкып, нур чәчеп торалар. Алар әдәбиятыбызның көчен һәм шул ук вакытта халкыбызның рухи-әхлакый йөзен, характерын да күрсәтәләр. Милләтебезнең тулы вәкаләтле вәкиләре булып яшиләр», – дип яза ул. Автор әсәр герое белән тормыштагы герой мөнәсәбәтенә бәйле мәсьәләгә туктала һәм алар арасына тигезлек куярга омтылып бәхәскә юл калдыра. Милләт, халык хакына олуг Иҗат дигән Иманны гына таныган, шуңа гына хезмәт иткән Ә. Еники, Н. Фәттахларны безнең чор геройлары дип саный. Тәнкыйтьче фикеренчә, әдәбиятта да иң матур әхлакый сыйфатларга ия булган, укучыга рухи көч өстәп, хәтта үз артыннан ияртә торган геройлар алгы планга чыгарга тиеш. Заман героена үзе куйган таләпләрдән чыгып, автор Ә. Еники, Н. Фәттах, А. Гыйләҗевләр юлын дәвам итүчеләр дип Ф. Садриев, М. Маликова, Р. Фәизов, В.Имамовларны саный. Киләчәктә дә әдәбиятның бурычын рухи яктан бай булган, чын кешелек сыйфатларына ия Кеше образын раслауда, шуның өчен көрәшүдә күрә. Әлеге язма уңаеннан шуны әйтергә кирәк: тәнкыйтьче «заман герое» төшенчәсен башка мәгънәдә, ягъни реаль тормыш, андагы прототиплар рәвешендә аңлый. Бу исә аны төп сорауны ачыклаудан читкә алып китә.

Р. Зариповның «Пегас кашына микән?» язмасында[1], нигездә, тәнкыйди фикер өстенлек итә. Хәзерге әдәбиятка хас бер үзенчәлек итеп ул үрнәк алырлык сыйфатларга ия булмаган кешеләрнең (Достоевскийның Свидригайлов сыман агайларын) уңай герой буларак тәкъдим ителүен атый. Икенче бер кимчелек буларак тәнкыйтьче әсәрләрнең жанр хасияте юылуын, асылда күбесенең очерк жанрына якынлыгын билгели. Моның аеруча авыл-колхоз темасына язылган әсәрләрдә урын алуын күрсәтә. Р. Зарипов XX гасырның 60–80 нче елларында әдәбиятыбызда киң урын алган «гүзәл әби һәм бабай образлары» белән мавыгуны, аларны бәяләүдәге фикерләрне дә бик үк кабул итми. Тәнкыйтьче изге максат белән язылган әсәрләрнең дә байтагында милли гореф-гадәтләр, традицияләр кире кагылу өчен борчыла һәм укучыны көнбатышның зарарлы йогынтысыннан, шуларга таянып язылган үзебезнең «популяр» китаплардан саклау юлларын эзли. «Ният изге, кыйбла дөрес, ихласлыкка хилафлык китерми торган иҗат зарур, – дип яза ул. (...) Һәм ул кешелегебез сагында торсын өчен, язучы халкына иң киме акның – ак, ә караның кара булуына иман китерү һәм шул позициясеннән бернәрсә бәрабәренә дә, бер карыш та чигенмәү таләп ителә...» Шуның белән бергә,

[1] *Зарипов Р.* Пегас кашына микән? // Казан утлары. 2004. № 9. Б. 154–158.

Т. Миңнуллинның «Кырларым-тугайларым», «Әлдермештән Әлмәндәр» кебек пьесалары заман сынавын узмаган әсәрләр дип бәяләнү белән килешеп булмый. Беренче пьесада үткән гасырның 70–80 нче еллар авылы кешеләренең, икмәк дип җан атучының, шәхси мәнфәгатьләренә караганда, иҗтимагый кирәклекне алга куйган колхоз рәисенең образы тудырыла. Нәкъ шундый булулары белән алар чор рухын чагылдыра да инде. Әгәр «Әлдермештән Әлмәндәр»дә Әлмәндәр карт дингә килүче итеп сурәтләнсә, вакыйга-күренешләр, геройлар башка фәлсәфәдән, үзгә концепциядән чыгып бәяләнер иде. Гомумән, үткәннең колхоз-производство турындагы яисә әхлакый-фәлсәфи мәсьәләләрне үз эченә алган әсәрләрен бүген инде әдәби-эстетик кыйммәте юк дип, җиңел генә тарихтан сызып ату дөрес булмас. Бу очракта, заман белән бәйлелектә, аларның үз чоры һәм киләчәк өчен әһәмиятен күрсәтү, шул ук вакытта, идеологик карашлар яисә соцреализм таләпләренең йогынтысын билгеләү, сәбәпләрен ачу сорала.

«Безнең заман герое»на бәйле фикер алышуның кульминациясе булып А. Хәлимнең «Сез беләмсез кая барганны?» исемле кайнар публицистика белән сугарылган күләмле хезмәте[1] санала ала. Анда әдәбият мәсьәләләре татар милләтенә, татар яшәешенә кагылышлы гаять җитди сораулар белән тыгыз бәйләнештә карала. Башка мәкаләләрдән аермалы буларак, әдипнең тирән борчылулары, җитди уйланулары һәм бүгенге яшәешебезне һәм әдәбиятыбызны педагогик, фәлсәфи, тәнкыйди, социаль анализлау нәтиҗәсендә туган хезмәтнең нигезендә милләт язмышы мәсьәләсе тора. Текстта ул сүз сәнгатенең милләт каршындагы җаваплылыгы булып төгәлләшә. Автор милләт һәм әдәбият кебек аерылгысыз бәйләнгән төшенчәләрне бербөтен итеп карый. Язманы буеннан-буена өмет хисе сугара: без булган, бар һәм булачак. Моның өчен һәркемнең күңелендә милли үзаң уятырга, барлык милләтпәрвәрләрнең эчке потенциалын бергә туплап, бердәм хәрәкәт итәргә кирәк. Шуларны милли идея итеп күтәргән тәнкыйтьче әдәбиятның төп бурычын милләт каһарманы тәрбияләүдә күрә һәм моның асылын, нигез-шартларын, юнәлешен җентекле аңлата. Хезмәттә хәзерге әдәбиятка хас булган, ассызыклап чыгарылган кимчелекләр белән килешми мөмкин түгел. Менә аларның кайберләре: 1) масштабсызлык, 2) таушалган «массовый» тел белән язу – «тел – иң җитешмәгән байлыгыбыз», 3) тетрәткән сюжет булмау, 4) фәлсәфәсезлек һ.б.

Әлеге әдәби-эстетик, әхлакый-фәлсәфи уйланулар синтезы булган хезмәттә автор белән бәхәскә керерлек каршылыклы фикерләрнең күп булуын да әйтеп үтәргә кирәк. Бердән, киң масштаблы булуы, яшәешнең күп якларын иңләп алуы төп сораудан читләшүгә китергән; икен-

[1] *Хәлим А.* Сез беләмсез кая барганны? // Казан утлары. 2005. № 1. Б. 109–136; *Хәлим А.* Сез беләмсез кая барганны? // Казан утлары. 2005. № 2. Б. 96–120.

чедән, А. Хәлимнең акны ак, караны кара дип әйтергә теләвен хуплаган хәлдә, урыны белән берьяклылык, субъективлык өстенлек ала. Әйтик, ул хаклы рәвештә: «Кайчан без мактамыйча җылы сүз әйтергә, хурламыйча тәнкыйть итәргә өйрәнербез икән?» – ди. Шунда ук үзенә каршы килеп, Ф. Сафинның «Саташып аткан таң»ында, нигездә, җитешсезлекләрне генә күрә. Һәрхәлдә романга ясалган анализ шундый фикер калдыра. Икенче урында Т. Миңнуллинның «Илгизәр плюс Вера», «Шәҗәрә»ләре артында «нинди матур кыланышлы мәкер ятканын» ачарга кирәклекне искәртә. Тәнкыйтьченең әлеге карашлары белән килешү кыен, чөнки аларда үтә шәхси карашлары урын алган. Ә бит «Илгизәр плюс Вера»ның төп идеясе түбәндәгечә: акылны җуеп, хисләргә генә өстенлек биреп, мәхәббәт уеннарына кызыгып, ашыгыч адым ясамагыз. Милли тамырлардан аерылуга китерүче катнаш никахлар еш кына бәхетсезлек, ятимлек, ялгызлык, хәтта фаҗига белән тәмамлана. Г. Исхакыйның «Көз», «Ул әле өйләнмәгән иде», Ф. Әмирханның «Хәят», Ш. Камалның «Акчарлаклар», Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять» кебек әсәрләренә бирелгән бәя дә берьяклы. Мисал өчен, «Көз» повесте А. Хәлим әйткән эчкечелекне, күңел ачуны якламый, әсәрнең төп идеясе үз тамырларыннан, гасырлар дәвамында тупланып килгән йола-гадәтләрдән, традицияләрдән аерылган кешенең рухи йомшаклыгын һәм, киресенчә, милли яшәү рәвеше кешедә горурлык, өмет, көрәш сыйфатлары тәрбияли дигәнне раслауда. Мәктәп укучыларында милли үзаң тәрбияләүдә «Көз» повесте – иң уңышлы әсәрләрнең берсе.

Әлеге дискуссия әдәби тәнкыйтькә билгеле бер җанлану алып килә, утыздан артык авторның катнашуы үзе генә дә игътибарга лаеклы күренеш. Ул буыннар алмашуның ныклы җирлеген ачу белән бергә, тәнкыйтьнең бурыч-вазифаларын аңлауда, әсәр анализының нигез принципларын билгеләүдә, юнәлеш-агымнарга, методларга мөнәсәбәттә төрлелек саклануны, каршылыклар булуны билгеләргә мөмкинлек бирә. Шул ук вакытта аналитик тәнкыйтькә йөз тотып, билгеле бер юнәлеш-агым концепциясеннән бәя бирү үрнәкләренең пәйда булуын, әдәби тәнкыйть яңарышындагы аерым сыйфатларның калкытып куелуын дәлилли.

Шулай итеп, хәзерге татар әдәби тәнкыйте, күптөрле тышкы һәм эчке факторларга нисбәтле, яңа чор әдәби процессын, шул исәптән аерым әсәрләрне аңлау-бәяләүнең критерийларын, фәнни нигезләрен ачучы эстетик концепцияләр эзләү юлына чыга. Шундый шартларда әдәби тәнкыйтьнең төрле юнәлеш-агымнарына (реаль, романтик, эстетик, импрессионистик, символик һ.б.), төрләренә (профессиональ, язучы, укучы) һәм типларына (филологик, философик, публицистик) йөз тоткан, шуларга нигезләнгән уңышлы үрнәкләр дөнья күрә. Язучы, тәнкыйтьче һәм укучы арасында үзара аңлашуга, ярдәмләшүгә нигезләнгән мөнәсәбәтләр урнаша башлый. Тәнкыйтьнең

байтак элекке нигезләмәләре, шартлары кабаттан бәяләнә, методологик һәм теоретик принципларына ачыклык кертелә. Әдәби барышны язучының чынбарлыкны кабул итү һәм чагылдыру хасияттеннән чыгып, ягъни әдәби юнәлеш-агым нигезендә тикшереп бәяләү иҗат психологиясен һәм эволюциясен ачуда уңышлы табышларга китерә. Тәнкыйтьтә татар милли әдәбиятына хас булган сыйфат-билгеләрне аерып чыгару, гомумкешелек кыйммәтләре аша яктырту омтылышлары арта.

## 4.4. Әдәби тәнкыйть жанрлары системасы

Татар әдәби тәнкыйтендә жанрлар мәсьәләсе аз өйрәнелгән өлкә булып кала, ягъни аны табигате, бүленеш принциплары, классификациясе, эчтәлеге һәм төзелеше ягыннан теоретик планда өйрәнү әле башлангыч этабында гына. Шулай да тәнкыйтькә бәйле тикшеренүләр күрсәткәнчә (М. Мәһдиев, Р. Мөхәммәдиев, Э. Галиева, Т. Гыйлаҗев, Г. Азизова, Ч. Гыйлаҗева һ.б.), төрле чорларда, аеруча XX гасырның беренче чирегендә аерым жанрларның эчке хасиятләрен, төзелеш үзенчәлекләрен билгеләү омтылышлары урын ала. Аерым алганда, әдәби тәнкыйтьтә жанрлар формалашу, баю һәм аларның төрләнү чоры кичерүе XX гасыр башына туры килә. Бу чорда «гыйльми-тәнкыйди фикердә жанрлар мәсьәләсе, теоретик проблема буларак, көн тәртибенә дә куела»[1].

Тәнкыйтькә бәйле «жанр» төшенчәсе әлегәчә күп бәхәсләр уята. Чөнки, эстетик аң чагылышының бер формасы буларак, әдәби тәнкыйть иҗтимагый һәм әдәби мохиткә бәйле үсеш-үзгәреш кичерә. Тәнкыйтьченең әдәби-эстетик карашлары, теләк-максатлары тәнкыйть язмасының жанр формасында һәм эчтәлегендә чагылыш таба. Бу исә тәнкыйть жанры теориясендә, аның, бер яктан, тотрыклылыгын, икенче яктан, даими үзгәреп торуын, шулай ук эчтәлекле форманың тәнкыйть эшчәнлегенә бәйлелеген, жанрларның үзара йогынтысын, классификацияләрнең нигез шартларын үз эченә алган принципларга таянуны таләп итә. Жанрны тәнкыйтьнең табигате, функцияләре, әдәби процесстагы урыны белән тыгыз бәйләнештә генә аңлап була. Язучы белән укучыны үзара бәйләүче тәнкыйтьче, билгеле бер максат-бурычлардан чыгып эш итә, үзенә хас әдәби-эстетик карашларга нигезләнеп, әсәрне анализлый. «Шул ук вакытта тәнкыйтьче анализ һәм бәя предметы булган әдәбиятның объектив һәм сурәтле эчтәлегенә таяна, ул исә, үз чиратында, тәнкыйди фикерләүнең эстәлегенә һәм структурасына, аргу-

[1] *Гыйлаҗев Т.Ш.* Рецензияләрдән тәгъзияләргә: XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. Б. 22.

ментлар системасына, төзелешенә һәм тәнкыйтьче язмасының стиленә йогынты ясый»[1].

Әлеге процесста, тәнкыйть юнәлеше, агымы, төрләре һәм типлары белән бергә, жанр мөнәсәбәте дә әһәмияткә ия. Жанр төре, аның эчтәлегенә һәм төзелешенә караган элементларның үзгәреше төрле чорлар белән чагыштыргандагы уртаклык һәм аерымлыкларны билгеләргә ярдәм итә. Соңгысы исә һәр чорның үзенә хас жанрлар системасы булдыруын аңларга булыша. «Үзенчәлекле тәнкыйть поэтикасының фундаментын, беренче чиратта, аның үзенчәлекле жанрлар системасы төзи. Алар исә бары тик әлеге әдәби төрдәге эшчәнлек тудырган (рецензия, проблемалы мәкаләр, күзәтү, кереш сүз, соңгы сүз һ.б.) үзенчәлекле формаларны, шулай ук тәнкыйть тарафыннан үзләштерелгән һәм аның үз бурычларына буйсынган «мөстәкыйль» әдәби жанрларны (хат, памфлет, пародия, эпиграмма һ.б.) үз эченә ала»[2]. Тәнкыйть әдәби чынбарлыктан тыш күренешләр белән дә эш итә: тәнкыйтьченең шәхси тәҗрибәсе, автобиографик фрагментлар, истәлекләр, чор характеристикасы, иҗтимагый әхлак турында уйланулар һ.б. Болар исә жанрларның аерым үзенчәлекләре җуелуга, төрле жанрларга хас сыйфатларны үзенә алган синтетик жанр барлыкка килүгә китереп, аерым жанрларны тикшергәндә әлеге синтезлашу күренешен исәпкә алуны таләп итә.

Һәр чорның әдәби тәнкыйте үткәндәге традицияләргә нигезләнә. Ә инде яңа чорның юнәлеш-агымнары, үзенең әдәби-эстетик таләпләреннән чыгып, жанрлар системасына билгеле бер үзгәрешләр кертә, жанрларның үзенчәлекле баскычын, ягъни тәнкыйтьнең һәр этабы үзенә хас жанрлар системасын булдыра. Жанр системасындагы үзгәрешләр төрле юллар белән барырга, аларга төрле шартлар йогынты ясарга мөмкин: «тәнкыйтьнең бурычлары турындагы күзаллаулар үзгәрү; үткәннең жанрлар «запасына» сайлап мөрәҗәгать итү; элекке жанрларны жанрара бәйләнешләргә таянып, яңа функцияләрдә файдалану; әдәбият, публицистика, фәлсәфә белән үзара тыгыз мөнәсәбәт нигезендә тагы да баю. Теге яки бу жанрның әһәмиятен ассызыклаучы тәнкыйди дискуссияләр дә билгеле бер роль уйнарга мөмкин»[3].

Әдәби-тәнкыйть жанрларын бүлеп чыгаруның нигез шартлары (критерийлары), аларның классификацияләү принциплары әдәбият

[1] Жанры русской литературной критики 70–80-х годов XIX века. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1991. С. 9.

[2] *Жук А.А.* Конспект вступительной лекции по курсу истории русской литературной критики // Русская литературная критика. Саратов: Изд-во Сарат. ун-та, 1994. С. 8.

[3] *Крылов В.Н.* Русская символистская критика (1890–1910-е гг.): генезис, типология, жанровая поэтика: дис. ... докт. филол. наук. Казань, 2007. С. 246.

белемендә әлегәчә эшләнеп бетмәгән[1]. Хәер, ул мөмкин дә түгелдер, чөнки җанлы әдәби процессны, шул исәптән тотрыклылык һәм тарихи үзгәрүчәнлек белән характерланучы тәнкыйть жанрларын ниндидер билгеләмә кысаларына тулысынча кертеп бетереп булмый. Шуңа да жанрларның төрен билгеләүдә, үзара тәэсир итешүен ачыклауда билгеле бер каршылыклар, керешеп китүләр, кабатлаулар очрап тора. Тәнкыйть теориясендә төрле яссылыкта жанр классификациясен аерып чыгару күзәтелә. Мисал өчен, М.Я. Поляков жанрлар системасын, тәнкыйтьнең публицистик табигатеннән һәм конструктив принцип буларак диалогик характерыннан чыгып, өч төргә бүлә[2]. Мондый классификациядән татар әдәби тәнкыйте дә теләп файдалана. Студентлар өчен чыгарган программаларында Р. Харрасова аларны түбәндәгечә төркемли: 1. Информатив төр (хәбәр-мәкаләчек, аннотация, күзәтүләр, хисаплар, әңгәмәләр, репортажлар). 2. Аналитик төр (рецензия, әдәби күзәтү, проблемалы әңгәмә, эпистоляр язмалар, статьялар, анализга нигезләнгән комментарийлар, фәнни бәхәсләр). 3. Әдәби-публицистик төр (әдәби портрет, очерк (сәяхәтнамә-юлъязма, очерк-портрет, проблемалы очерк, биографик очерк, тәнкыйди-биографик очерк, иҗат манерасын ачкан очерк), фельетон, пародия, шарж, памфлет, эссе)[3].

Казан рус әдәбият белеменең күренекле вәкиле В.Н. Коновалов, тәнкыйть һәм әдәбиятның диалогик характерына, тәнкыйди анализ объектларының үзара тәэсир итешүенә, аргументлаштыру системасы билгеләренә нигезләнеп, түбәндәге классификацияне тәкъдим итә: 1. Хәзерге әдәбиятның әһәмиятле булган аерым күренешләре тәнкыйди анализның предметы булып тору. Ул үз эченә библиографик язма, рецензия-бәяләмә, монографик мәкаләне ала. Аңа оперативлык, яңалыклар турында мәгълүмат бирү хас. 2. Тәнкыйди анализ предметы булып теоретик мәсьәләләр, әдәбиятның торышы турында уйланулар тору. Ул, гадәттә, проблемалы мәкаләдә чагыла. 3. Әдәби процессның аерым чорын, аның үсеш закончалыкларын һәм тенденцияләрен бәяләү (әдәби

---

[1] Рус әдәбият белемендә XVIII–XX йөз башы тәнкыйтенә нисбәтле әлеге проблема буенча җитди хезмәтләр дөнья күрә: *Егоров Б.Ф.* О мастерстве литературной критики. Жанры. Композиция. Стиль. Л., Советский писатель, 1980. 317 с.; *Поляков М.Я.* В мире идей и образов: Историческая поэтика и теория жанров. М.: Сов. писатель, 1983. 367 с.; Жанры русской литературной критики 70–80-х годов XIX века / науч. ред. В.Н. Коновалов. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1991. 162 с.; *Коновалов В.Н.* Литературная критика 70 – начала 80-х годов XIX века (системный анализ): дис. в виде научного доклада ... докт. филол. наук. Саратов. 1996. 56 с.; История русской литературной критики: учеб. для вузов / под ред. В.В. Прозорова. М.: Высш. школа, 2002. 463 с. һ.б.

[2] *Поляков М.Я.* В мире идей и образов: Историческая поэтика и теория жанров. М.: Сов.писатель, 1983. С. 176.

[3] Әдәби тәнкыйть буенча практикум: махсус курс программасы / төз. Р.Ф. Харрасова. Казан: Казан дәүләт ун-ты, 2004. 19 б.; Әдәби тәнкыйть теориясе: махсус фән программасы / төз. Р.Ф. Харрасова. Казан: Казан дәүләт ун-ты, 2007. 32 б.

күзәтү – концептуаль, мәгълүмати, күзәтү-цикл). 4. Тәнкыйть буенча язылган хезмәтләргә мөнәсәбәтле тәнкыйди язмалар. 5. Язучының шәхесен, иҗатын анализлауга багышланган язмалар – әдәби күренешне һәм әдип иҗатын бәяләүне язучының шәхесе, тормышы, биографик фактлары белән тыгыз бәйләнештә алып бару (тәнкыйди-биографик очерк, әдәби портрет). Мондый классификацияне ул «вертикаль буенча» дип атый һәм төрле жанрларны чагыштырып карау, үзенчәлекләрен билгеләү мөмкинлеген күрсәтә. Әмма ул күп жанрлар өчен уртак булган жанр формалары белән тулыланырга тиеш, ягъни «горизонталь буенча». Алар: хат, уйлану-фикерләү, язма-эссе, диалог, параллель, очерк һ.б.[1]

Әдәби тәнкыйтьтә язманың күләменә һәм төренә нисбәтле дә жанрлар системасын аерып чыгаралар: кече жанрлар (рецензия, газета мәкаләсе, реплика, аннотация); урта жанрлар (күзәтү, төрле мәкаләләр, эссе, фельетон, памфлет, иҗат портреты, некролог (соңгысы хәзерге вакытта элекке мәгънәсен югалтып, характеристика төсен алды); катлаулы жанрлар (дискуссия (оештырылган һәм стихияле), мәкаләләр җыентыгы, цикл, монографик мәкалә, әдәби портрет, кереш мәкалә, йомгаклау мәкаләсе).

Татар әдәбият белемендә тәнкыйть жанрлары башлангычы ерак дәверләргә барып тоташа. Урта гасырларда ук инде «шигъри әсәрләрдә каләмдәшләре әсәрләрен бәяләү, тамгалау традициясе яшәгән. Шулай ук шәрех, хашияләр, «бәяләү»ләр (китап бите кырыендагы искәрмәләр) язу гадәте дә киң тарала. XIX гасырның соңгы чирегендә мәкалә, рецензия әдәби тәнкыйть жанрлары буларак калыплашуның беренче адымнарын ясый»[2]. Ә инде XX йөз башы әдәбият белемендә, тәнкыйть формалашу процессы белән бергә, аның төр-жанрларын булдыру эше башлана. Шул нигездә 1910 еллар әдәби тәнкыйтьтендә тулы бер система тәшкил иткән жанрлар классификациясе барлыкка килә. Бу чорда тәнкыйть жанрларын тулы система буларак өйрәнгән хезмәтләр булмаса да, күпсанлы текстларны тикшерү аша Т. Гыйлаҗев түбәндәге жанрларны аерып чыгара: 1. Рецензия (кыска рецензия, монорецензия, монорецензия-кыска рецензия, рецензия-мәкалә, авторецензия). 2. Мәкалә (программ мәкалә, проблемалы мәкалә, бәхәсле мәкалә, күзәтү мәкаләсе, юбилей мәкаләсе, әдәби параллель, диалог). 3. Әдәби портрет (әдәби-тәнкыйди портрет, иҗат очеркы, мемуар очерк, силуэт). 4. Некролог – тәгъзия (некролог-мәкалә, некролог-хәбәр, некролог-эссе, шигъри прозадагы некролог, некролог-сыктаулар). 5. Хат (аерым хатларның бәхәсле

---

[1] Жанры русской литературной критики 70–80-х годов XIX века / науч.ред. В.Н. Коновалов. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1991. С. 9–16.

[2] *Гыйлаҗев Т.Ш.* Рецензияләрдән тәгъзияләргә: XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. Б. 22.

мәкаләгә, авторецензиягә, үзтәнкыйтькә, хәбәргә, күзәтү мәкаләсенә якынлыгы искәртелә)[1].

Жанрлар классификациясе, беренче чиратта, жанр табигатендә тотрыклылык һәм үзгәрүчәнлекнең үзара бәйләнешенә нигезләнә; икенче яктан, иҗади эшчәнлек төре буларак, тәнкыйтьнең үзенчәлекләре, эчтәлек-төзелеше мөһим роль уйный; өченче яктан, жанрларның үзара тәэсир итешүе, бер-берсенә якынаюы, керешеп китүе дә җитди мәсьәлә булып калка[2]. Һәрбер жанр үзенә хас эчтәлек һәм форма таләп итә. Ул исә тәнкыйть белән әдәбият арасындагы бәйләнеш-мөнәсәбәткә нигезләнә. Чөнки тәнкыйтьче билгеле бер бурыч-максат белән әдәби күренешләрне бәяли, аңлата, үз карашын белдерә. Бу очракта ул теге яки бу юнәлеш-агымга нигезләнгән концепциядән чыгып эш итә, үзе яклаган әдәби-эстетик идеалга таяна, шуларны яклый. Бу мәсьәләне максатчан тикшергән Р. Харрасова болай дип яза: «Әдәби тәнкыйть жанрларының төрлелегенә, язмаларның күләменнән тыш, тәнкыйтьченең үз алдына куйган иҗади бурычы, хезмәтнең нәрсә өчен башкарылганлыгы, вакыйгаларның иңләнү киңлеге, исәпкә алынган фактларның күләме һәм аларның шәрехләнү характеры, хезмәтнең теоретик дәрәҗәсе, автор тарафыннан әдәби-стилистик чаралар сайланышы да тәэсир итә»[3]. Жанр табигате, югарыда әйтелгәнчә, тотрыклылык һәм шул ук вакытта үзгәрүчәнлек сыйфаты белән билгеләнә. Аның эчке сыйфат-билгеләре күптөрле факторларга, аерым алганда, тикшерү объекты булган әсәрнең төренә, калкытып куелган бурычларга, әдәби-тәнкыйди мохиткә, хәтта социаль шартларга һ.б. бәйле үзгәреш кичерә. Шуңа да билгеле бер жанр кысаларында калса да, тәнкыйть язмалары бер-берсеннән шактый аерылып тора. Теге яки бу чорда аерым жанрларның активлашуы күзәтелү дә югарыдагылар белән аңлатыла.

Жанрлар, аларның классификациясе, үзгәреше һәм үзенчәлекләре система буларак каралганда нәтиҗәле. Әлеге мәсьәләне максатчан тикшергән В.Н. Коновалов тәнкыйть жанрлары системасын социаль һәм эстетик проблематика, функцияләр, әдәби процессны анализлау принциплары, шәхси башлангычны чагылдыру чаралары һәм хәтта мәкаләнең күләме һәм исеме кебек детальләр гомумилеге буларак билгели[4]. Әлеге караш-фикерләрне без нигез итеп алабыз.

Хәзерге татар әдәби тәнкыйтендә жанрлар тулы бер система тәшкил итә. Ул, беренче чиратта, тәнкыйтьнең заман таләпләренә никадәр

---

[1] *Гыйлаҗев Т.Ш.* Рецензияләрдән тәгъзияләргә: ХХ йөз башы татар әдәби тәнкыйте. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. Б. 9–23.

[2] Жанры русской литературной критики 70–80-х годов XIX века. С. 6–8.

[3] *Харрасова Р.Ф.* Әдәби тәнкыйть нигезләре. Казан: ТӘһСИ, 2017. Б. 226.

[4] *Коновалов В.Н.* Литературная критика 70 – начала 80-х годов XIX века (системный анализ): дис. в виде научного докл. ... докт.филол. наук. Саратов. 1996. С. 16–17.

җавап бирүенә, әдәби процессның мөһим тенденцияләрен чагылдыруына нигезләнсә, икенчедән, чор тәнкыйтенең сыйфат-билгеләрен тулы һәм эзлекле ачуы белән бәйле. Өченчедән, тәнкыйди фикер иҗтимагый-социаль тормышның йогынтысында булып, үзендә көчле публицистик башлангычны чагылдыра. Бу исә публицистик тәнкыйть тибының үсүе белән бергә, төрле юнәлеш-агымнарга да публицистиканың үтеп керүенә юл ача. Мәкаләләрдә авторның шәхси карашлары, үткән һәм киләчәк турында уйланулары, шулай ук милли, әхлакый, фәлсәфи мәсьәләләр киң урын ала. 1990 еллар дәвамында әдәби әсәрләрне бәяләгәндә социологик һәм иҗтимагый карашларның, башлангычларның өстенлек алуын күрәбез. Шуңа да анализ-бәяләмәдә милләт язмышына бәйле мәсьәләләрнең куелышын һәм чишелешен тикшерү алгы планга чыга. Татар әдәби тәнкыйте үткән традицияләрне үстерә барып, яңа әдәби-эстетик концепцияләргә йөз тота һәм шуларга яраклы жанрлар системасын булдыра. Әлеге системада хәзерге тәнкыйтьнең төп үзенчәлекләрен, әйдәп баручы тенденцияләрен, шул исәптән каршылыкларын да чагылдыручы жанрлар киңрәк, активрак кулланыла. Аларны түбәндәге эзлеклелектә күрсәтергә мөмкин: рецензия-бәяләмә, монографик мәкалә, проблемалы мәкалә, күзәтү мәкаләсе, тәнкыйди-биографик очерк, әдәби портрет, эссе һ.б.

*Рецензия-бәяләмә* – яңа басылып чыккан әсәрнең төп проблемаларын яктырту аша гомуми бәя биреп язылган мәкалә. Тәнкыйтьче әсәрнең уңай һәм кимчелекле якларын күрсәтеп, китап укучыларның игътибарын җәлеп итә. Тәнкыйтьне җанландыру, чор әдәби процессы белән бәйләнешен арттыру һәм китапны пропагандалау вазифасы ягыннан китапка күзәтү ясау мөһим роль уйный. Әлеге бәядә әсәрнең эчтәлек һәм формасына бәйле сәнгати эшләнешен, яңалыгын объектив рәвештә билгеләү нигез шартлардан санала. Шул рәвешле китап турында киң катлам укучыда фикер-караш, мөнәсәбәт тудырыла һәм ул, еш кына, әлеге иҗат җимешенең чор әдәбиятындагы урынын билгеләүгә дә йогынты ясый. Әдәби рецензия тәнкыйтьченең зәвыгы, сүз сәнгатенә мөнәсәбәте белән бергә, күзәтү ясала торган китапның төр һәм жанрына, авторның үз алдына куйган максатына тыгыз бәйле. Рецензия жанрының уңышлы үрнәкләре Р. Мостафин, М. Вәли-Барҗылы, Р. Сверигин, Р. Шәрәфиев, Ф. Бәширов, Ә. Мәхмүдов һ.б. иҗатында урын ала. Мисал өчен, соңгы елларда бу жанрда иң актив эшләүчеләрнең берсе булган Р. Шәрәфиевнең «Безнең дә әниләр бар иде» рецензиясендә тикшерү объекты булып Ш. Маннаповның «Мәңгелектән елмаю» китабы тора. Аның каләменә ихласлык белән кушылып киткән публицистик пафос хас. Мәкалә структурасында теоретик фикерләр дә «эретелгән». Авторның күзәтүләре, аерым хикәяләргә бәясе әдәбиятның асылы, функцияләре турындагы карашлары белән үрелеп бара.

Бу яктан караганда язмада төрле компонентларның нисбәте мәсьәләсе дә калкып чыга. Р. Шәрәфиевнең, әсәрләргә бәя бирүдән бигрәк, гомуми мәсьәләләр, заман үзгәрешләренең әдәбиятта чагылышы белән мавыгуы сизелә. Бу исә игътибарны тикшерелә торган китаптан читкә алып китә. Рецензиянең бер үзенчәлеге буларак, язмада аерым хикәяләрнең кыскача эчтәлеге дә урын ала. Мәкалә авторы, зәвыклы укучы буларак, сюжет вакыйгаларын кыска, әмма ачык-аңлаешлы, укучыда кызыксыну уятырлык дәрәҗәдә тәкъдим итә. Тулаем алганда, әлеге зур булмаган рецензия үз максатына ирешә. Автор укучы күңеленә аклык сирпүче табышларны күрсәтә һәм, үз сүзләре белән әйткәндә, «китап тараткан җылы дулкыннарга» алып керә, шуларда «коендыра». Р. Фәизовның «Ак каз» җыентыгы, Ф. Сафинның «Саташып аткан таң»ы турындагы фикерләре дә хәтердә уелып калырлык. Авторны, нигездә, сурәтләнгән вакыйгалар, аларның тарихи нигезе, масштаблылыгы, бүгенгебез белән никадәр тыгыз бәйләнештә булуы кызыксындыра[1].

Әлеге жанрны үстерү максатында «Казан утлары» журналы 2000 елда рецензияләр конкурсы үткәрә. Басылып чыккан мәкаләләр бер дәрәҗәдә түгел, билгеле. Бу, бер яктан, һәркемнең әдәбиятны аңлавы, белеме, эстетик зәвыгы белән аңлатылса, икенче яктан, тикшерү өчен алынган материалның да төрлелегеннән килә: кемдер аерым бер хикәяне анализласа, икенче берәү җыентыкка күзәтү ясый. Конкурста катнашучылар арасында Ф. Хатипов, К. Тимбикова һ.б.ның мәкаләләре аеруча игътибарга лаек[2].

*Монографик мәкаләдә* язучының иҗатына яисә аерым әсәренә анализ шактый киң әдәби һәм иҗтимагый күренешләр белән бәйләнештә бирелә. Шуның белән бергә, тәнкыйтьченең фикер-карашлары теоретик һәм методологик нигезләмәләр белән үрелеп бара. Рецензиядән ул күләме, төзелеше һәм авторның социаль, фәлсәфи, эстетик гомумиләштерүләргә йөз тотуы белән дә аерыла. Мондый язмада әсәр анализына җитди теоретик фикер-карашларны, аерым очракларда бәхәсле сорауларны ачыклау, мөнәсәбәтне белдерү аша киленә. Тәнкыйть мәкаләсенең үзәген тәшкил иткән анализ әсәрнең төзелешен, автор позициясен, ул яклаган идеяне ачыклау юнәлешендә алып барыла. Аерым мәсьәләләр публицистик, әдәби, әхлакый уйланулар белән үрелеп китәргә дә мөмкин. Тагын бер сыйфаты буларак, гадәттә, язма исемендә автор яклаган яисә бәхәскә чакырган фикер чагылыш таба.

---

[1] *Шәрәфиев Р.* Безнең дә әниләр бар иде... // Казан утлары. 2002. № 3. Б. 171–175; *Шәрәфиев Р.* Ак казлар чакыруы // Казан утлары. 2002. № 12. Б. 151–155; *Шәрәфиев Р.* Хакны әйтүчеләр илдә бар // Казан утлары. 2003. №8. Б. 153–159.

[2] *Хатипов Ф.М.* Якты җирлектәге һәлакәт // Казан утлары. 2000. № 3. Б. 137–141; *Тимбикова К.* Шагыйрьнең хыялында йөрткән китабы // Казан утлары. 2000. № 6. Б. 166–169 һ.б.

Мисал өчен, әлеге жанрның уңышлы үрнәге булып Г. Гыйльмановның «Образ. Символ. Рухи кодлар (Г. Моратның «Түбә» китабын укыганда туган уйлар)», Ф. Бәширнең «Кеше күңеле – карурман», Р. Рахманиның «Шагыйрәнең язмыш келәме», Р. Фәтхрахмановның «Йөрәкнең җеназасы (татар тормышына Айдар Хәлим прозасы аша бер караш)» һ.б. мәкаләләр[1] тора.

Әдәбиятка үзенчәлекле караш-мөнәсәбәте белән аерылып торган авторларыбызның берсе булган Р. Фәтхрахмановның «Йөрәкнең җеназасы (татар тормышына Айдар Хәлим прозасы аша бер караш)» мәкаләсе аналитик бәясе белән игътибарны җәлеп итә. Әдәби процессны, аның төп тенденцияләрен аерып чыгарырга омтылып, тәнкыйтьче «милли әдәби рух мутантлашып, үзенең асыл сыйфатларын җуеп ук бетереп диярлек» бара һәм «куштан тәнкыйтьнең купшы ялтыравыгы» бу күренешне тизләтә генә дип билгели. Р. Фәтхрахманов А. Хәлимнең «Татар вакыты», «Өч аяклы ат» әсәрләренә реализм кануннарыннан чыгып тирән анализ ясый һәм әлеге иҗатның төп үзенчәлекләреннән берсе итеп тормыш-чынбарлыкны мөселман идеологиясе призмасы аша яктыртуда күрә. Мәкалә авторы А. Хәлим иҗатын «яшәешебез көзгесе» буларак бәяләп, аның яңачалыгын «публицистика белән әдәби сурәтне үзара кушу, синтезына ирешү»дә күрә. Әсәрләргә анализ аша татар милләте, аның язмышы турында гаять борчулы уйлары кушылып китә. Язучы иҗаты, аның татар язмышына биргән бәясе тудырган уйлар, «Йөрәкнең җеназасы» дип, мәкаләнең исеменә үк чыгарылган – .

Уртак максат һәм концепция берләштергән монографик мәкаләләр *тәнкыйди монография* жанрын тәшкил итәргә мөмкин**.** Фәнни монографиядән аермалы буларак, ул аерым бүлекләрдән түгел, бәлки әдәби-эстетик планда бер-берсен тулыландыра, баета торган аерым мәкаләләрдән тора. Тәнкыйди монография үрнәге буларак, Т. Галиуллинның «Шигърият баскычлары», Ф. Хатиповның «Мөлкәтебезне барлаганда», Д. Заһидуллинаның «Яңа дулкында» һ.б. хезмәтләр[2] дөнья күрә.

Т. Галиуллинның «Шәхесне гасырлар тудыра» китабы – XX гасыр татар шигъриятен «бөтенкешелеккә хас шәфкатьле, игелекле кыйммәтләргә» йөз тотып һәм миллилек, тарихилык, бөтенлек принципларына нигезләнгән концепция аша өйрәнүнең уңышлы үрнәге. Хезмәт әдәби-

[1] *Гыйльманов Г.Х.* Образ. Символ. Рухи кодлар (Г. Моратның «Түбә» китабын укыганда туган уйлар) // Казан утлары. 1999. № 4. Б. 143–155; *Бәшир Ф.* Кеше күңеле – карурман // Казан утлары. 2003. № 3. Б. 154–157; *Рахмани Р.* Шагыйрьнең язмыш келәме // Казан утлары. 2003. № 4. Б. 121–134; *Фәтхрахманов Р.Г.* Йөрәкнең җеназасы (Татар тормышына Айдар Хәлим прозасы аша бер караш) // Казан утлары. 2003. № 11. Б. 132–138 һ.б.

[2] *Галиуллин Т.Н.* Шигърият баскычлары. Казан: Мәгариф, 2002. 231 б.; *Хатипов Ф.М.* Мөлкәтебезне барлаганда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 272 б.; *Заһидуллина Д.Ф.* Яңа дулкында (1980–2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык). Казан: Мәгариф, 2006. 255 б. һ.б.

эстетик планда бер-берсен тулыландыра, баета барган мәкаләләрдән торган монография буларак кабул ителә. Т. Галиуллин фикеренчә, озак еллар калыплашкан фикерләрдән арыну, карашлар төрлелегенә омтылу аша һәм әсәрләргә сәяси күзлектән чыгып түгел, бәлки әдәби-эстетик якын килү, төрле чорлар мирасын рухи уртаклык, эчке кануннар берлегендә өйрәнү, шулай ук дини карашлар белән тыгыз бәйлелектә тикшерү генә әдәбиятны бөтен тулылыгында ачу мөмкинлеге бирә.

Иҗтимагый аңның үзенчәлекле чагылышы булган сүз сәнгатен тикшергәндә Т. Галиуллин аерым билге-үзенчәлекләрне, тенденцияләрне ачыклау аша яңа эзләнүләрне, проблемаларны билгеләргә омтыла. Шуның бер үрнәге 1960 елларда татар поэзиясенә килүче буын (Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Р. Мингалим, Г. Рәхим, Р. Гаташ һ.б.) иҗатын өйрәнүдә күренә. Әлеге әдипләр иҗатына бәйле фикер-карашларны ул системага сала: күнегелгән калыплардан арыну, форма өлкәсендә яңа тәҗрибәләргә йөз тоту; традицион сурәтләрдән, еш кына вөгазьчелеккә кайтып калган уй-фикерләрдән метафорага, шартлылыкка, иркен сурәтле фикерләүгә омтылу; читтәрәк калып килгән аерым казанышларны калкытып (Дәрдемәнд, С. Рәмиев һ.б.), ул традицияләрне яңа шартларда үстерү, ил-халык язмышы турында уйлануларны галәми мәсьәләләр белән бәйләү, үрү һ.б. Т. Галиуллин, ирешелгән казанышлар белән генә канәгатьләнмичә, поэзия үсешенә яңа рух өргән әлеге буын шагыйрьләрнең серле шигъри дөньясын заман биеклегеннән, дөнья сәнгате казанышларыннан торып ачу юлларын эзли. Төп яңалыкның, сыйфат үзгәрешенең формада булмыйча, эчтәлектә, иҗтимагый, фәлсәфи мәсьәләләрне хис-фикер синтезы рәвешендә чагылдырып, укучыны сискәндереп җибәрүдә, битарафлыктан чыгаруда; кеше һәм табигать, тарих һәм милләт турындагы уйлануларны халыкчан сурәтләр, мәгънәле деталь-символлар, сынландырулар һ.б. аша гәүдәләндерүдә булуын аңлауга килә. Әлеге эзләнүләр яссылыгында югарыда исемнәре аталган шагыйрьләр генә түгел, алардан бераз соңрак килгән М.Әгъләмов һәм Зөлфәт, Рәшит Әхмәтҗанов һәм Р. Миңнуллин, К. Сибгатуллин һәм Ф. Яруллин, З. Мансуров һәм М. Галиев, Л. Шагыйрьҗан һәм Э. Шәрифуллина һ.б. иҗаты да яңа яклары белән ачылып китә.

Хәзерге тәнкыйтьтә, еш кына, теоретик мәсьәләләр, әдәбиятның торышы турында уйланулар анализ предметы булып тора. Билгеле инде, әдәби барышка яисә теоретик мәсьәләләргә кагылышлы сораулар һәрбер тәнкыйть мәкаләсендә очрый. Монографик мәкаләдә һәм рецензиядә теоретик сорау тәнкыйтьченең карашларын, анализ нәтиҗәләрен методологик нигезләү өчен урын алса, аерым очракларда алар тикшерү объекты буларак үзәк урынны били. Андый язмалар *проблемалы мәкалә* жанрын тәшкил итә. Әдәбият белемендә аларның ике төрен аерып чыга-

ралар[1]. Берсе – агымдагы әдәби хәрәкәтнең торышын, үсеш-үзгәрешен билгеләүне максат иткән язмалар. Аларда әдәби процесска караган теге яки бу проблема калкытып куела, шуның тирәсендә барган бәхәсләрнең асылы аңлатыла һәм авторның дәлилле фикерләре урын ала. Мәкаләдә әдәби материал шактый иркен кертелгән публицистик, идеологик, аерым очракларда эстетик мәгълүматлар белән үрелеп бара. Шуның белән бергә, фикер ачыклыгы, дәлил-фактларның ышандыру көче, логик эзлеклелек мондый хезмәтләрнең мөһим бер үзенчәлеге булып тора[2].

С. Хафизовның «Ислах, яки яманаттан ярлыкау» мәкаләсе[3] 1990 еллар башы татар әдәбиятында һәм тәнкыйтендә барган бәхәсләр уңае белән язылган. Автор, язманың исеменнән күренгәнчә, үзләрен реформаторлар, демократлар дип атаучыларның үткәндәге һәм үз чоры әдәбиятын нигездә кара төсләр ярдәмендә бәяләүне кабул итми. Аларны, үзе язганча, «кайда чүп, кайда орлык?» икәнен аңлап эш итәргә чакыра. С. Хафизов газета-журнал битләрендәге язмаларда Һ. Такташ, М. Җәлил, Х. Туфан кебек шәхесләребез иҗатына ревизия ясарга теләүчеләргә дәлилле отпор биреп, болай дип яза: «Әдәбият кадәр әдәбиятны – олы, мөкатдәс милли байлыкны – үлеләй-терeләй җирләп куярга маташуның чын ирләр шөгыле булмавы маңгай бәреп исбатлауларсыз да ачык бит». Мәкалә авторының совет чоры, бигрәк тә «торгынлык чоры» дәверенә биргән бәясе фикри куәте, фактик нигезе белән кызыклы. Шул рәвешле, ул чор тәнкыйтенең кимчелекләрен, урынсыз дәгъваларын ачып сала һәм аның үсеш-яңарышын традицияләргә таянуда, бер чиктән икенчесенә ташланмыйча, аек акыл йөртүдә, шул ук вакытта дөнья казанышларын үзләштерүдә күрә.

Проблемалы мәкаләнең икенче төрен *теоретик яисә тикшерену мәкаләсе* дип атыйлар. Аның беренче төрдән һәм монографик мәкаләдән аермасы теоретик һәм методологик мәсьәләләрне тикшерү белән бәйле. Мондый язмалар һәм әдәби процесска, һәм тәнкыйть теориясенә караган сорауларга җавап эзләве белән әһәмиятле. Аларда, еш кына әдәбият теориясе, эстетика буенча дөнья күргән хезмәтләргә караш белдерелеп, бәхәсләр дә алып барыла. Шуның белән бергә, әдәби процессны теоретик планда бәяләү, үз чиратында, алдагы үсеш перспекти-

[1] Жанры русской литературной критики 70–80-х годов XIX века. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1991. С. 21–22.

[2] *Әхмәдуллин А.Г.* Үз карашы: әдәбиятка да... мафиягә дә // Офыклар киңәйгәндә. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. Б. 184–188; *Хатипов Ф.М.* Романнарда – Сөембикә образы // Мөлкәтебезне барлаганда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. Б. 172–183; *Хисамов Н.Ш.* Тамырларны барлап // Хәтер сагында. Казан: Мәгариф, 2003. 424–427 б.; *Галимуллин Ф.Г.* Кадыйр Сибгатуллин шигъриятендә заман сулышы // XX гасырның 70–90 нчы еллар татар поэзиясе контекстында Кадыйр Сибгатуллин иҗаты. Чаллы: Набережночелнинская типография, 2008. Б. 7–11 h.б.

[3] *Хафизов С.* Ислах, яки яманаттан ярлыкау // Казан утлары. 1994. №4. Б. 129–138.

валарын билгеләргә дә ярдәм итә. Бу яктан әлеге тәнкыйть жанрының программ характерда булуы, киләчәкне күзаллау мөмкинлеге ачыла. Теоретик мәкаләдә аерым әсәрләргә җентекле анализ ясалырга мөмкин, әмма әдәби материал теоретик мәсьәләләрне ачыклау, авторга үз карашларын яклау өчен хезмәт итә. Бу төр мәкаләнең бер үрнәге булып Ф. Хатиповның «Классик реализм (Тәнкыйть реализмы булганмы?)», Д. Заһидуллинаның «Милли реализм юлыннан», «Символизмны яңартып», Н. Йосыпованың «Хәзерге татар драматургиясендә интеллектуаль тенденция: М. Гыйлаҗев» язмалары[1] тора.

Н. Йосыпова мәкаләсе сәхнә әдәбиятында барган әдәби-эстетик эзләнүләрне ачыклау рәвешендә язылган. Автор эзлекле рәвештә хәзерге татар драматургиясенең үсеш юнәлешләрен, төп тенденцияләрен барлый һәм, шуларга нигезләнеп, аерым үзенчәлекләрне билгели. Эзләнүләрнең тематик, жанрлар, концепцияләр өлкәсендә баруын ассызыклап, төп игътибарын интеллектуаль тенденциянең кемнәр иҗатында һәм ни рәвешле чагылышын ачыклауга юнәлтә. Хезмәттә теоретик фикерләр М. Гыйләҗев иҗатына, аерым алганда, «Бичура» пьесасына анализ ярдәмендә конкретлаштырыла.

Әдәби процессның аерым чорын, аның үсеш закончалыкларын һәм тенденцияләрен бәяләүне үз эченә алган мәкаләләрне *әдәби күзәтү* жанры дип атау кабул ителгән. Тәнкыйтьченең өйрәнү предметына бәйле алар еллык күзәтү, аерым бер төр, жанр торышына күзәтү, теге яки бу әдәби юнәлеш, агымга күзәтү, тематик күзәтү, катнаш күзәтү һ.б. дип билгеләнә. Әдәби күзәтү, нигездә, чорның тарихи-иҗтимагый, социаль-мәдәни вакыйгалары белән тыгыз бәйләнештә алып барыла һәм анда нинди дә булса әдәби тенденциянең үзенчәлекләре тикшерелә. Мондый хезмәтләрдә күпсанлы әсәрләр бәяләнә, чагыштырып нәтиҗәләр ясала. Күзәтүләрнең мөһим үзенчәлеге булып публицистик эчтәлек белән сугарылуы, шулай ук әхлакый һәм фәлсәфи карашларның урын алуы тора. Әлеге сыйфат язманың тел-стилендә дә чагылыш табып, үзенчәлекле синтез барлыкка китерә. Сүз сәнгатенең төп тенденцияләрен билгеләү максаты эчтәлектә ачык күренеп торган бәяләү характерын алга чыгара. Ул исә анализ-бәя өчен әсәрләрнең сайланышына да җитди игътибар бирүне сорый.

Ф. Сафин «Гыйбрәт алыйм дисәң...» мәкаләсендә[2] соңгы еллар прозасына күзәтү ясый. Язучы һәм заман турындагы уйлануларына

[1] *Хатипов Ф.М.* Классик реализм (Тәнкыйть реализмы булганмы?) // Мөлкәтебезне барлаганда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. Б. 184–197; *Заһидуллина Д.Ф.* Милли реализм юлыннан // Казан утлары. 2003. № 6. Б. 134–147; *Заһидуллина Д.Ф.* Символизмны яңартып // Мәйдан. 2005. № 2. Б. 35–39; *Йосыпова Н.* Хәзерге татар драматургиясендә интеллектуаль тенденция: М. Гыйлаҗев // Фәнни язмалар – 2007: җыентык / фәнни ред. И.А. Гыйләҗев. Казан: Казан ун-ты нәшр., 2008. Б. 135–141.

[2] *Сафин Ф.* Гыйбрәт алыйм дисәң... // Казан утлары. 2002. № 9. Б. 131–140.

бәйле, «үткән, мәрхүм «бәхетле чор» иллюзияләреннән арынырга ярдәм итү» бурычын үтәүче әдәбиятта ул чор яшәешен бүгенгенең социаль-иҗтимагый яшәеш призмасы аша күрсәтү кирәклеген билгели. Бер үзенчәлек буларак проза жанрлары таләпләренә җавап бирмәгән әсәрләр язылуын атый. Бүгенге прозаны әйдәп баручы авторлар иҗатына хас сыйфатлар дип ул яңа тип геройлар килүне, стиль төрлелеген (мәсәлән, А. Хәлим «вакыйганы умырып-умырып алып мөшкә авызына ыргыта, сюжет буенча кисәк-дуамал ыргымнар белән алып бара укучыны»), телгә, сурәтлелеккә игътибар артуны («Ф. Латыйфиның теле җырлап тора, шактый катлаулы нәрсәләр хакында язып та, теле аһәңлелекне, сыгылмалылыкны югалтмый, төсмер-табышларга бай»), традицион җирлектә яңа катламнар ачу омтылышын, XX йөз башында нигез салынган модернизм юнәлешен яңартуны (Г. Гыйльманов, Н. Гыйматдинова), әдәби әсәр аша дини белем бирүне, рухани әдәбиятның торгызылуын (Ф. Яхин, Ф. Бәйрәмова), тарихи тематикага игътибарның зур булуын (М. Хәбибуллин, Н. Фәттах, Р. Батулла, Р. Зәйдулла, Н. Гариф, С. Шәмси) билгели.

Аерым жанрлар торышына тукталып, «егерменче гасыр хикәясе авторларга бай, төсмерләргә мул, киң сулышлы һәм татар прозасының төп үсеш тенденциясен фактта раслый», дип күрсәтә. 1990 елларда детектив прозаның уңышлы үрнәкләрен алга таба дәвам итүдә сүлпәнлек күзәтелүгә игътибар итә. Шуңа охшаш хәл фантастика жанрында да саклана икән. Ф. Сафин, потенциаль мөмкинлекләре зур булса да, юмор-сатираның бер урында тапталуына борчыла. Ф. Баттал, Т. Миңнуллин, Ф. Садриев, К. Кәримов, И. Шиһапов, Ә. Сафиуллиннар уңышлы гына эшләп килсәләр дә, «бездә бу тармак халыкчанлык дәрәҗәсендә үсеш алып китә алмый әле». Ә инде хәзерге прозадагы аерым кимчелек-җитешсезлекләр буларак, тәнкыйтьче түбәндәгеләрне атый: 1) аналитик куәгә ия булган әсәрләрнең аз булуы; 2) еш кына вакыйганы сөйләп бирүгә йөз тоту, милли идеянең тулы чагылышын тапмавы; 3) геройларның эш-гамәлләрендә күңел халәтенең үсеш-эволюциясе сизелмәү, еш кына схематик ситуацияләргә куелулары; 4) әсәрләрдә мотивлаштыру, мантыйк искә алынмау, сюжет борылышларының зәгыйфьлеге күзәтелү һ.б. Гомумән, Ф. Сафин, кимчелек-җитешсезлекләр булса да, татар прозасын үсеш-хәрәкәттә дип саный һәм аңа хаксыз тел-теш тидерүдән сакланырга чакыра.

Хәзерге шигърият турындагы уйлануларга бәйле Р. Зәйдулланың «Куркытмагыз кошлар авазын» исемле бик тә мәгънәле язмасы[1] тормыш-яшәештә әдәбият-сәнгатьнең урыны турындагы уйланулар белән башланып китә. Тәнкыйтьче аерым авторларның иҗат биеклекләрен

---

[1] *Зәйдулла Р.* Куркытмагыз кошлар авазын // Казан утлары. 2003. № 7. Б. 146–152.

билгеләгән әсәрләренә этрафлы бәя бирү аша хәзерге шигърият мәсьәләләренә килә. Л. Шагыйрьҗан, Э. Шәрифуллина, З. Мансуров поэмаларына бәяләр төрлечә булса да, алар шигъри анализның матур үрнәге булып тора. Р. Зәйдулла нәрсә турында гына уйланып язса да – поэма жанры сыйфатларымы, шигырь техникасымы, публицистик яисә гражданлык лирикасымы – аңлап-белеп яза, шуңа да фикерләре ачык, мәгънәле. Татар поэзиясе, аның традицияләреннән, тамырларыннан читләшүе артуга әрнүле сүзләре, хәзерге шигъриятне «тавыш-тынын бик сиздерми генә агып яткан нәни инеш» итеп күзаллавы – бар да акылтойгы катламында үз урынын ала.

Сәхнә әдәбиятын өйрәнү, аның бүгенге торышын барлау, киләчәгенә ориентирлар билгеләү һаман да артка калып килә. Төрле спектакль премьералары, театрларның гастрольләре уңае белән язылган күзәтү төсендәге мәкаләләрдән тыш ( ә аларда драма әсәре турында гомуми сүз әйтеп, спектакль үзе, артистлар уены үзәктә тора), драматургиягә кагылышлы хезмәтләр аз булуы күренә. Драматургия белгече А. Әхмәдуллинның «Бүгенге драматургиянең кайбер үзенчәлекләре»[1] язмасында хәзерге сәхнә әдәбиятындагы эзләнүләр юнәлеше билгеләнә. Тәнкыйтьче күпсанлы драматургларның соңгы еллар иҗатын тема-проблемалары, жанрлар байлыгы, стильләр төрлелеге ягыннан эзлекле барлый. Ә. Әхмәдуллин әдәбиятның, шул исәптән драматургиянең иҗтимагый һәм тәрбияви әһәмиятен аеруча калкытып куя, шуңа да пьесаларда гаҗизлек мотивының киңәюен, кешенең кыргый инстинктларына күп мөрәҗәгать итүне, еш кына явызлык-караңгылыкның изгелек-матурлыктан өстен чыгуын сурәтләүне кабул итми. Кешенең рухын күтәрә, җанына хөрлек, өмет бирә торган хәл-күренешләрнең, образ-геройларның күбрәк булуын тели.

Максат-вазифасыннан, композицион төзелешеннән чыгып, күзәтүләрнең концептуаль, мәгълүмати һәм күзәтү-цикллар дип йөртелгән төрләре дә хәзерге татар тәнкыйтендә урын ала.

*Концептуаль күзәтүләрнең* нигезен тәнкыйтьченең әдәбияттагы аерым бер үзенчәлек-тенденциягә карата позициясе, үз фикер-карашларын дәлилләве билгели. Д. Заһидуллина «Яңа дулкында» исемле мәкаләсендә[2] соңгы еллар татар прозасында барган үзгәрешләрне «модернизм элементларын үзенә туплаган яңа дулкында» язылган әсәрләр билгели дип яза. Алдагы чор әдәбиятында Р. Төхфәтуллин, М. Мәһдиев, А. Гыйләҗев һ.б. иҗатында «авыл реализмы» урын алган булса, соңгы еллар сүз сәнгатендә «психологик реализм» (Ф. Бәйрәмова), «милли реализм» (Ф. Латыйфи), «интеллектуаль реализм»

---

[1] *Әхмәдуллин А.Г.* Бүгенге татар драматургиясенең кайбер үзенчәлекләре // Мирас. 2004. № 2. Б. 87–91.

[2] *Заһидуллина Д.Ф.* Яңа дулкында // Казан утлары. 2003. № 1. Б. 152–159.

(Р. Сибат), «магик реализм» (Н. Гыйматдинова) кебек агымнарның җирләшүен күрсәтә һәм соңгысының әсәрләренә этрафлы күзәтү ясый. М. Җәләлиеваның «Тойгы катламнары» язмасы[1] Ә. Еники иҗатында кеше эчке дөньясын чагылдыру алымнарын – психологизмын ачу ягыннан әһәмиятле.

*Мәгълүмати күзәтүләр* зур булмаган вакыт аралыгындагы әдәби-иҗтимагый тормышны үз эченә ала. Аларда әдәби барышны тулысынча иңләү максат итеп куелмый. Авторның бәя-мөнәсәбәте фрагментар рәвештә булырга мөмкин, ә инде күзәтүгә алынган әсәрләр еш кына җәмәгатьчелектә кызыксыну уятуга бәйле була. Ю. Сафиуллинның «Сәхнә әсәрләребез нинди?» мәкаләсендә[2] драма әсәрләренең театр белән бәйләнеше, спектакль буларак тамашачыга җиткерелүе турындагы фикерләр өстенлек итә. Автор театрның (нигездә, Камал театрының) XX гасыр ахырындагы хәлен, эчке халәтен шактый тулы ача. Пьесага куелган таләпләрне исә сәхнә әдәбияты кануннары белән бәйләнештә карый. Язма билгеле бер вакыт аралыгында басылып чыккан яисә төрле театрларда куелган пьесалар, аларның авторлары исемнәренә, төрле саннарга, фактларга бик бай. Автор сәхнә әдәбиятындагы кимчелекләрне дә тоемлый. Аның «шундый чор килде, халык театрга кәмит карарга гына йөри, дип үз-үзебезне алдап ятсак, тамашачыны беркайчан да үз артыбыздан ияртә алмабыз», – дигән фикере хәзерге татар театрына бәя булып яңгырый. Драматургиянең җәмгыятьтәге урыны, аны үстерү өчен кирәк булган шартлар, тамашачы зәвыгы турындагы фикер-карашларын Көнбатыш Европа, рус сәхнә әдәбияты мисалларына таянып аңлата. Әмма биш ел эчендәге (XX гасыр ахыры) драматургия турында сүз алып барылган язмада, аның хәл-торышына ачык, аңлаешлы бәя бирү, билгеле бер дәрәҗәдә төп юнәлешләрен, үсеш перспективаларын билгеләү дә сорала. Автор исә борчу тудырган мәсьәләләрнең байтагын читләтеп үтә.

*Күзәтү-цикллар* исә, исеменнән аңлашылганча, мөстәкыйльлекләрен саклаган хәлдә, төзелеше, тәнкыйди юнәлеше, бәяләү объектының эзлеклелектә алынуы белән үзара бәйләнгән язмаларны тәшкил итә. Аларны, еш кына, авторның шартлы образы, берсеннән икенчесенә күчеп баручы сорау-мәсьәләләр берләштерә. Андый мәкаләләр, гадәттә, алдан планлаштырылмый, бәлки әдәби-иҗтимагый вакыйга-хәлләргә нисбәтле языла. Тәнкыйтьче Р. Сверигинның «Үткән ел прозасына бер караш», «Гасырлар чатында» мәкаләләре[3] хәзерге татар прозасының төп үсеш тенденцияләрен ачыклау омтылышында бер-берсен дәвам итәләр, тулыландыралар.

---

[1] *Җәләлиева М.Ш.* Тойгы катламнары // Казан утлары. 2002. № 11. Б. 160–169.

[2] *Сафиуллин Ю.* Сәхнә әсәрләребез нинди? // Казан утлары. 2000. №2. Б. 138–144.

[3] *Сверигин Р.Х.* Үткән ел прозасына бер караш // Казан утлары. 2000. № 7. Б. 132–137; *Сверигин Р.Х.* Гасырлар чатында // Казан утлары. 2002. № 4. Б. 145–154.

Хәзерге тәнкыйтьтә әдәби күренешләрне һәм әдип иҗатын бәяләүне язучының шәхесе, тормыш-яшәеш хәлләре, биографик фактлары белән тыгыз бәйләнештә алып бару бик активлашты. Мондый хезмәтләрнең бер төре булган *тәнкыйди-биографик очеркта* әдип иҗатына анализ тормыш юлын күз алдына бастыру белән үрелеп бара. Биографик фактларны барлау үзмаксат булмыйча, игътибар үзәгендә иҗат үзенчәлекләрен, аерым тема-мотивларны, мәсьәләләрне, дөньяга карашны һ.б.ны язучы биографиясе призмасы аша чагылдыру тора. Мондый язмалар, гадәттә, әдипнең күптомлыгы чыгу яисә юбилее уңаеннан дөнья күрә. Әлеге жанрның уңышлы үрнәкләре буларак С. Поварисовның халык шагыйре И. Юзеевның 70 еллыгы уңаеннан язылган «Моң эчендә асылташ», Т. Галиуллинның А. Гыйләҗевның тууына 75 ел тулуга бәйле дөнья күргән «Киләчәк кешесе», Р. Сверигинның Ф. Яруллинга 65 яшь тулу уңаеннан язылган «Аны беләбезме?» һ.б. мәкаләләрен[1] күрсәтеп була.

*Әдәби портретта* язучының иҗат үзенчәлеге бәяләнә. Тәнкыйтьче әсәрләрне анализлау аша әдипнең тормыш-чынбарлыкны чагылдыру, гомумән, сәнгати фикерләү үзенчәлеген ача. Әлеге жанрда биографик материаллар, истәлекләр, башка язучылар белән чагыштырулар файдаланылса да, соңгылары ярдәмчел вазифа башкара. Киң планда әдәби портретта язучының шәхесе һәм иҗаты бербөтен буларак, органик бәйләнештә тикшерелә. «Әдәби-тәнкыйди портрет башка тәнкыйть жанрларына караганда әдәбиятка якынрак: анда детальләр, вак әйберләр, автор «мин»е, ассоциативлык, билгеле бер күләмдә уйланмалык зур роль уйный»[2]. Әдипнең иҗат үзенчәлекләре, әдәби-эстетик карашлары гомум әдәби процесстагы урынын ачыклау белән үрелеп бара. Әлеге жанр җитди эзләнүләр нәтиҗәсендә генә дөньяга килә. Әдәби портрет хәзерге тәнкыйтьтә шактый актив кулланыла. Аның уңышлы үрнәкләрен Р. Мостафин, Т. Галиуллин, А. Әхмәдуллин, Ф. Мусин, М. Вәлиев, Р. Сверигин, Р. Рахмани, Д. Заһидуллина һ.б. иҗатында күрәбез.

Р. Рахманиның тәнкыйди язмалары хис һәм фикер бергәлегенә ирешкән әдәби әсәр кебек укыла. Аның каләме шактый сайлап, иҗатлары вакыт сынавын узган, җәмәгатьчелектә танылып та, тәнкыйть тарафыннан әлегәчә ачылып-аңлатылып бетмәгән әдипләргә төбәлә. Тәнкыйтьченең «Кыйблабызга тугрылык» язмасы[3] М. Юнысның бай иҗатын ачуда яңа бер баскыч булып тора. Олы язучының иҗат үзен-

[1] *Поварисов С.* Моң эчендә асылташ (татар халык шагыйре И. Юзеевка 70 яшь) // Казан утлары. 2003. № 1. Б. 145–149; *Галиуллин Т.* Киләчәк кешесе // Татарстан. 2003. № 2. Б. 52–57; *Сверигин Р.Х.* Аны беләбезме? (Ф. Яруллинга 65 яшь тулу уңаеннан) // Казан утлары. 2003. № 2. Б. 130–137.

[2] *Крылов В.Н.* Русская символистская критика (1890–1910-е гг.): генезис, типология, жанровая поэтика: дис. ... докт. филол. наук. Казань, 2007. С. 354.

[3] *Рахмани Р.* Кыйблабызга тугрылык // Казан утлары. 2002. № 4. Б. 170–184.

чәлекләренә, феномены асылына төшенү өчен, «көнкүреш логикасыннан берникадәр фәлсәфи аң югарылыгына күчеп фикер йөртергә тиешбездер», дип яза ул. Мәкалә дә шуның матур үрнәге. Р. Рахманиның әдәби әсәр теле турында уйланулары һәр язучыга аталган теләк булып тора: «Матур әдәбият теле ул – сәнгатьле фикерләүне барлыкка китергән материал һәм шартлы чара; тел ул – язмыш, психология; тел ул – фикер, идея, көрәш!» «Дөнья меридианнары белән үрелгән өр-яңа тема, өр-яңа тормыш катламы» алып килгән М. Юнысны ул герой психологиясенә тирән үтеп керү, фикри мәгънәгә йөз тоту, тәэсирле тасвирлаулар остасы дип бәяләп, әсәрләренең публицистик карашлар белән үрелеп баруын күрсәтә. Гомумән, әлеге язма М. Юнысны шәхес, художник, язучы буларак ачу ягыннан әһәмиятле.

Р. Рахманиның Л. Шагыйрьҗан иҗаты турындагы «Шагыйрәнең язмыш келәме» язмасы[1] тематик-проблематик нигездә әдибәнең иҗат эволюциясен эзлекле ачуга корылган. Үзе дә шигъри җанлы тәнкыйтьче Л. Шагыйрьҗанның иҗат дөньясын тирәнтен аңлап, белеп яза, әлеге поэзияне татар әдәбиятындагы үзенчәлекле һәм уникаль күренешләрнең берсе дип бәяли. Р. Рахмани шагыйрә лирик героеның хис-кичерешләр байлыгын, күңел тибрәнешләрен ачык тоемлый һәм әдибәнең интим кичерешләр белән чикләнмичә, аларның эстетик чагылыш-тәэсирен ачуга килүен иҗатында үсеш буларак тәкъдим итә. Шигърияткә фанатикларча бирелгән Л. Шагыйрьҗанны, үз сүзләре белән әйткәндә, «ил кызын» лирик героеның рухи халәте үзгәрү мизгелләрен бирү остасы буларак китап укучыларга тәкъдим итә.

Әдәби процесска, заман таләпләренә бәйле тәнкыйди жанрларның билгеле бер үзгәреше чагылышы буларак, соңгы елларда татар әдәби тәнкыйтендә *эссе* жанры активлашты. Хәзерге татар әдәби тәнкыйтенең мөһим үзенчәлеге буларак импрессионистик тәнкыйтьнең киң урын алуын һәм аның эссе жанрында шактый тулы чагылуын исәпкә алып, әлеге жанрга киңрәк тукталу сорала. Гомумән, эссе жанры нәрсә ул? Рус телендәге күпсанлы сүзлекләрдә, фәнни хезмәтләрдә эсседа шәхси фикер һәм хис-кичерешләр чагылу, күләм ягыннан зур булмау, композициясенең иркле булуы кебек сыйфатлар күрсәтелә[2]. Татар телендәге сүзлекләрдә эссе проза төре жанры буларак кына карала[3].

Т. Гыйләҗев XX йөз башы тәнкыйтендә «некролог-эссе» дип аталырга мөмкин булган жанрны аерып чыгара һәм мөһим билгесе итеп әдип-

---

[1] *Рахмани Р*. Шагыйрьнең язмыш келәме // Казан утлары. 2003. № 4. Б. 121–134.

[2] Словарь литературоведческих терминов / ред.-сост. Л.И. Тимофеев и С.В. Тураев. М.: Просвещение, 1974. С. 477.; Литературная энциклопедия терминов и понятий / под ред. А.Н. Николюкина. М.: Интелвак, 2003. С. 1246–1247; һ.б.

[3] Әдәбият белеме сүзлеге / төз.-мөх. А.Г. Әхмәдуллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. Б. 238; Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге / фәнни редакторлар: Т.Н. Галиуллин, Д.Ф. Заһидуллина. Казан: Мәгариф, 2007. Б. 228.

нең «иҗаты, язучылык сәләте, әдәби репутациясе турында тәнкыйтьче күңелендә туган уй-фикерләрнең, гыйльми-нәзари раслауга дәгъва итмичә, лирик чигенешләр белән үреп язылган публицистик яңгырашлы язма»[1] булуын билгели. Р. Харрасова эссены «автордан шагыйрәнә осталык һәм прозаиклык таләп иткән» жанр дип күрсәтә һәм «әдәби тәнкыйтькә караган эсселарда кайсы да булса башлангычның алгы планга чыгуы» күзәтелүне дә искәртә. Автор шәхесен алга чыгарып, «самими-ихлас уй-фикер һәм хис-мөнәсәбәт бер төенгә төйнәлгән әдәби тармак» дип атый[2]. Аның үзенчәлеген язучы иҗатына анализда тәнкыйтьче «мин»енең керешеп китүе, лирик һәм публицистик чигенешләр, истәлек-мемуарлар белән үрелеп бирелү билгели. Әдәби-публицистик жанр буларак эсседагы ике башлангычны аерып кую, дөресрәге, кайсының өстенлек итүен ачыклау автор язмасының максат-функциясе белән тыгыз бәйле. Моны ачыклау аның я әдәби иҗатка, я әдәби тәнкыйтькә я публицистикага каравын билгели. Әлеге үзенчәлеккә игътибар итмәгәнлектән, журналист-галим И. Низамов студентлар өчен чыгарылган дәреслек-кулланмасында дистәләгән язмага эссе жанры кысаларында бертөрле генә бәя-аңлатма бирә. Мисал өчен, ул «эссе» жанры үрнәкләре итеп тәкъдим иткән Р. Сибатның «Өчтомлыкны укыгач өч сүз» һәм Ш. Рәкыйповның «Мәңге сакларга» язмалары[3] һич тә бертөрле бәяләнә алмый. Берсе – Р. Фәйзуллин иҗатына бик тә самими, шәхси уй-фикер, хис-кичереш аша якын килү, мөнәсәбәт белдерү булганлыктан, әдәби тәнкыйтьнең эссе жанрына карый, икенчесе – Рейстагка байрак элүче Гази Заһитовка багышланган, әдәби тәнкыйтькә бернинди катнашы юк, киресенчә, конкрет бер темага бәйле авторның ирекле уйланулары әхлакый, сәяси, милли, фәлсәфи караш-фикерләр белән үрелеп баруы, үзенең шәхси фикерен калкытып куюы белән публицистиканың эссе жанры үрнәге.

XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы татар әдәби тәнкыйтендә эссе жанрының активлашуы түбәндәгеләр белән аңлатыла: 1) татар сүз сәнгатендә лирик-эмоциональ башлангычның артуы тәнкыйтьтә дә лириклыкның үсешенә китерә; 2) тәнкыйтьнең публицистика белән үрелеп баруы, билгеле бер дәрәҗәдә синтезы; 3) тәнкыйтьченең роле арту, субъективлыкка игътибар; 4) язучы шәхесе белән кызыксыну; 5) жанр чикләрен үтеп чыгу, таләпләрен сакламау; 6) тәнкыйть функцияләренең билгеле бер үзгәреш кичерүе.

[1] *Гыйлаҗев Т.Ш.* Рецензияләрдән тәгъзияләргә: XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. Б. 174.

[2] *Харрасова Р.Ф.* Иҗат лабораториясе (Икенче кисәк: Поэтик иҗат). Казан: КДУ, 2004. Б. 24.

[3] *Низамов И.М.* Эссе жанры: «Әдәби-публицистик жанрлар» курсыннан журналистика факультеты студентлары, аспирантларына уку кулланмасы. Яр Чаллы: Оператив полиграфия лабораториясе, 2007. Б. 12.

Ике гасыр чигендә эссе жанрына актив мөрәҗәгать итүчеләр арасында Р. Сибат, М. Галиев, Р. Гаташ, Н. Гамбәр, И. Вәлиулла, Т. Галиуллин, А. Хәлим һ.б. бар. Үзләре дә сүз сәнгатенең төрле төрләрендә иҗат итүче язучылар булуын беләбез. Бу да аның бер үзенчәлеген тәшкил итә. «Казан утлары», «Мәйдан», «Мәдәни җомга», «Мирас» кебек журналларда һәм тәнкыйть җыентыкларында урын алган язмалар әлеге авторларга хас типологик уртаклыкларны, ягъни эссе жанры үзенчәлекләре, аерым алганда, текстларның композицион төзелеше, әдәби әсәрне шәрехләү һәм бәяләүнең принциплары, алымнары, укучыга йогынты ясау чаралары һ.б. турында сүз алып барырга мөмкинлек бирә. Эссе жанрының активлашуы татар әдәбият белемендә импрессионистик тәнкыйть юнәлешенә йөз тоту белән дә аңлатыла. Сүз сәнгатендә генә түгел, тәнкыйди фикердә дә милли проблемаларга игътибар арту, үткән тарихны, шул исәптән әдәби-мәдәни мирасны тулысынча торгызу, кире кайтару, аларны бүгенгедән торып бәяләү күзәтелә.

Хәзерге татар әдәби тәнкыйтендә эссе жанрына хас сыйфат-билгеләр үзе дә танылган язучы булган Р. Сибат мәкаләләрендә ачык чагылыш таба. Бу төр язмалар эмоциональ башлангычның көчәюе белән үзенчәлекле. Р. Сибат «Прозабыз Ахуны» мәкаләсендә[1] остазы һәм замандашы Г.Ахуновның шәхесен һәм иҗатын органик бергәлектә тикшерү омтылышы ясый. Авторның самими уй-фикерләре олы әдипнең иҗади фикерләү үзенчәлеген шәхесе, биографиясе, яшәешнең мәңгелек сорауларына караш-мөнәсәбәте аша ачуга юнәлгән. Остазлары турындагы уйлануларына язучыны шәхес буларак ачу, сүз сәнгатенең асылын аңлау омтылышы кушылып китә: «Кулыңны һәм йөз-битеңне генә түгел, ә Җаныңны юып, Рух утыңны кабызып керергә кирәк Әдәбият дигән Гүзәл Сарайга! Ул (...) Рухият, Гүзәл Хисләр, Әдәби Иман, Яхшылык-Матурлык бакчасы». Р. Сибат прозаик язмышы белән бәйле истәлек-хатирәләрне барлый. Г.Ахунов әти-әнисенең якты образларын торгыза, шулар аша иҗатчы шәхесенең нигезен, тамырларын ача. Нәкъ менә әтисе сүзләре аша аның «сәерҗан», «серлеҗан» булып үсүе, бу сыйфатларның иҗатында чагылуы укучыны да җәлеп итә, кызыксыну уята.

Әлеге жанрдагы язмалар төзелеш-структура ягыннан да игътибарга лаек. Бу – язучы яшәгән чор, әдәби мохит турында мәгълүмат бирү, әсәрне шәрехләү, әдип иҗатын бәяләү, әдәби-мәдәни фактларга мөрәҗәгать итү, теоретик мәсьәләләргә тукталу кебек компонентларның берелеш максатына бәйле. Эссе теоретик сорауларны да (алар киң урын алып тормый) читләтеп үтми. Эмоциональ-шәхси башлангыч белән бергә теоретик сорауларның да урын алуы, бер яктан, тәнкыйтьче карашларына

[1] *Сибат Р.* Прозабыз Ахуны // Казан утлары. 2000. № 9. Б. 131–147.

аргумент, аларны дәлилләү өчен хезмәт итсә, икенче яктан, тикшерүгә алынган авторга хас иҗат принципларының ни дәрәҗәдә традицияләргә нигезләнүен һәм яңачалыкка омтылуын ачарга булыша. Р. Сибат «Өчтомлыкны укыгач өч сүз (Р. Фәйзуллинның өчтомлыгын укыгач туган уйлар)» язмасын[1] шагыйрь һәм шигърият турындагы уйланулары белән башлый да, «тылсымлы Хиссият Иле» булган Поэзия алдында, аның «могҗизалы сер-сихере» алдында сокланып, илһамланып баш июен белдерә. «Шагыйрьләргә чыннан да дога кылырлык ич, – дип яза ул, – алар Җирдә яшәгән чакта ук үзләренең Җан-Рухлары белән Күк Инсаннары рәвешендә, Югары Рух ияләре буларак та иҗат итәләр. Шунсыз илаһи чын Поэзия дә юк! Шагыйрьләр һәрвакыт югарыдан торып сүз йөртәләр. Хәтта иң түбән хәлләрдә калганда да. Яп-яшь кенә килеш чахоткадан үлеп барганда да... Палач балтасы астына башын салганда да...» Автор Р. Фәйзуллинның кыска шигырьләренә бәя бирер алдыннан, типологик охшашлыкка нигезләнеп, японнарда киң таралган танка һәм хайку шигырь формалары, үзенчәлекләре турында яза һәм татар шагыйренең халык иҗаты үзәген тәшкил иткән кыска формаларга «кайту»ын билгели. Әлеге язмада теоретик фикерләр шәрехләү барышына эзлекле кушылып китә. Р. Сибат аны тәнкыйть мәкаләсенең жанрын, үзенчәлекләрен ачыклау буларак та файдалана. «Гаташ – мәхәббәт җырчысы» мәкаләсендә[2] тәнкыйть теориясенә туктала: «Тәнкыйть ул калыпларга төренгән була, ә эсселар – ирекле язмалар алар. Безнең татар әдәбиятында чын мәгънәсендә эссеистик әсәрләр юк диярлек. Бу безнең өчен эссе түгел, сүрән жанр. Чын эсселарны шәхсән үзем Марсель Галидә, тагы Равил Фәйзуллин белән Зөлфәттә һәм Наис Гамбәрдә таптым». Хәзерге татар тәнкыйтенең йомшак якларыннан берсе – төрле юнәлеш-агымнарда язылган әсәрләргә бертөрле һәм гомум принциплардан чыгып бәя бирү. «Прозабыз Ахуны»нда Р. Сибат әлеге мәсьәләгә тукталып кына калмый, бәлки эссе жанрының мондый катлаулы проблеманы чит итмәвен күрсәтә. Ул татар прозасының реализмга («булган хәлләрне сөйләп чыгу, ягъни сюжет җебен нык тотып, вакыйгаларны бәян итү») һәм романтизмга йөз тотуын билгеләп, Г. Ахунов әсәрләренә шуларга нигезле бәя бирә. Автор әдәби әсәрнең бурыч-вазифалары, бигрәк тә прозага хас хикәяләү, сурәтләү, бәяләү үзенчәлеге турында үз фикерләре белән уртаклаша: «Әдәби әсәргә бәя биргәндә хикмәт «нәрсәне әйтмәгән яисә әйтеп бетерә алмаган»ны эзләүдә түгел, ә иң мөһиме: «Нәрсә турында әйткән?.. Ә төп критерий – ничек әйткән?»

[1] *Сибат Р.* Өчтомлыкны укыгач өч сүз (Р. Фәйзуллин өчтомлыгын укыгач туган уйлар) // Казан утлары. 1996. № 10. Б. 133–148.

[2] *Сибат Р.* Гаташ – мәхәббәт җырчысы // Казан утлары. 1998. № 3. Б. 134–150.

Эссе жанрындагы язмалар төзелешендә мәкалә исеме, өлешләргә бүленеш һәм аларның атамасы, бетем төп максатка буйсындырыла. «Өчтомлыкны укыгач өч сүз» язмасында исем төзелеш-композициягә турыдан-туры ишарә итә. «Тәүсүз» дип аталган беренче өлештә мәкалә язуга алыну сәбәпләре, максат-бурычлары ачылса, «Уртасүз» дип аталган икенче өлеш үз эчендә ун кисәккә бүленгән («Шигъри бомба», «Тәнме, җанмы», «Җан җылысы», «Исләрдән торган хисләр», «Поэтик сер» һ.б.) һәм алар Р. Фәйзуллин шигъриятенең үзенчәлекләрен, үсеш-үзгәреш тенденцияләрен, шагыйрь эволюциясен ачуга хезмәт итә. Ә инде «Ахырсүз»дә гомумиләштереп нәтиҗәләр ясала. «Гаташ – мәхәббәт җырчысы»ның төзелеше дә моңа бик охшаш булып, түбәндәге бүлекчәләрдән тора: «Кереш», «Гөлләр су сорый», «Кояшлы утраулар», «Диңгез эзлим», «Юл җырлары», «Кар астында гөлләр», «Соңгы сүз».

А. Гыйләҗевның шул исемдәге романы турындагы «Йәгез, бер дога!» язмасы[1], бер яктан, монографик мәкаләгә якын булуы белән игътибарны җәлеп итсә, икенче яктан, эссега хас тагын бер үзенчәлекнең чагылышын күрәбез. Ул – әдәби, публицистик, социологик материалларга, фактларга иркен мөрәҗәгать итү. Автор үз карашларын укучыга тулырак, ачыграк җиткерү өчен фәлсәфи уйланулары, әдәби-эстетик фикерләре белән уртаклаша. Аларның нигезе – әдәби әсәрдә. Р. Сибат болай дип яза: «Бу романында тормышны, аның күпкырлы якларын тасвирлаучы прозаик кына түгел, ә дөньяны күзаллауда төгәл фикерләре булган, тирән уйлары туган философ язучы да». Әлеге сыйфат бүлекчә исемнәрендә дә чагылыш таба: «Өч аршын уй», «Акулаларның яман эче...», «Кешене хайванлаштыру...», «Төрмә мәхәббәте», «Татарлар һәм татарлык», «Оран». Фәлсәфи уйланулар мәкалә авторына язучы образын тудырырга һәм аңа үз, шәхси мөнәсәбәтен тулырак ачарга мөмкинлек бирә. Моңа исә аерым детальләр, авторның күзаллаулары, ассоциатив фикерләре, хәтта уйлап чыгарулары да ярдәм итә. Ә инде мәкаләнең интонациясе, үзенчәлекле чагыштырулар, тәэсирле сөйләм тәнкыйтьче стилен тагы да үтемле итә. Моңа тагын авторның укучысына эндәш-мөрәҗәгатен дә өстәргә кирәк: «Укыйк “Дога”ны, гыйбрәтләр алыйк, сәҗдәгә калыйк»; «Укы вә аңла үз әдип-шагыйрьләреңне». Тәнкыйтьче фикердәше буларак укучысына эндәшеп, аны әңгәмәгә, еш кына бәхәскә чакыра, әйтергә кирәк «язучы-тәнкыйтьче-укучы» диалогына өнди.

Мәкаләләрдә сәнгать һәм мәдәният тарихына караган мәсьәләләр, заманның актуаль сораулары белән үрелеп бара. Шуңа да классик үрнәкләрдән цитаталарны файдалану, аерым әсәрләр белән чагыштырулар әдәбият турындагы әңгәмәне яңа биеклеккә күтәрү белән бергә,

[1] *Сибат Р.* «Йәгез бер дога!» // Казан утлары. 2001. № 10. Б. 121–131.

бәяләү объекты булган әсәрнең әдәби барыштагы урынын аңларга, билгеләргә ярдәм итә. Р. Сибат «Йәгез, бер дога!» язмасында әлеге романның гына түгел, гомумән, А. Гыйләҗев иҗатының нигез концепциясен 1960 еллар башында язылган «Өч аршын җир» повестеннан эзләргә кирәк, ди. Төрмә-лагерьлар афәтенең әдәбиятта чагылышы уңае белән В. Шаламов, Е. Гинзбург, В. Аксенов, А. Солженицын, И. Салахов, Г. Тавлин иҗатларына мөрәҗәгать итә, охшаш һәм аермалы якларын билгели.

Шулай итеп, тәнкыйтьченең әдәби-эстетик карашлары, теләк-максатлары тәнкыйть язмасының жанр формасында һәм эчтәлегендә чагылыш таба. Әдәби-тәнкыйть жанрларын бүлеп чыгаруда төрле шартларга нигезләнү, аларны төрле яссылыкта бәяләү күзәтелә. Татар әдәби тәнкыйте үзенең традицияләрен дәвам итеп һәм төрле халыклар, беренче чиратта, рус тәнкыйть теориясе казанышларыннан файдаланып, чорның әдәби процесс үзенчәлекләренә туры килүче жанрлар классификациясен булдыра.

## IV бүлек нәтиҗәләре

1. Аерым әсәрләрне яисә шул чор әдәби процессын өйрәнеп бәяләве белән әдәби-иҗади процессны оештыруга, үсеш-үзгәрешенә ярдәм итеп, китап укучы белән әдип арасында арадашлык вазифасын башкаручы, соңгысының сәнгати фикерләү үзенчәлекләрен төшенергә, аңларга булышучы тәнкыйть әдәби процесста гаять җитди урын алып тора. Әдәбият тарихы һәм әдәбият теориясе белән тыгыз бәйләнештә торучы тәнкыйть әдәбият белеменең бер тармагы буларак карала. Бу сыйфатында алгы планга, үзенчәлекле әдәби иҗат төре булган тәнкыйть түгел, бәлки тәнкыйть теориясе чыга. Киң планда әлеге төшенчә тәнкыйтьнең асылын аңлатуны, аның тарихи эволюциясен, әдәби процесста сүз сәнгате белән үзара тәэсир итешүен, әсәрне бәяләү юлларын, принципларын, шулай ук жанрларын һәм жанр формаларын ачыклауны үз эченә ала.

2. Тәнкыйть теориясендә фәнни-теоретик тикшеренүләрнең объекты булып торган тәнкыйди язма тексты мөһим урын алып тора. Аның үзгә табигате матур әдәбият тексты белән фәнни текст арасында торуына бәйле. Тәнкыйть текстының үзенчәлекләрен билгеләгәндә, әдәбият белән бәйлелегеннән тыш, кайсы аудиториягә төбәлгән булуы, нинди максат белән язылуы да зур роль уйный. Соңгысы жанрлар классификациясендә аеруча тулы чагылыш таба. Ә инде язманың нинди аудиториягә атап язылуына килгәндә, гадәттә, яшьләр өчен, махсус әзерлекле (элитар) һәм киң катлам укучыны күздә тоткан өч төркемне аерып чыгару күзәтелә. Билгеле әлеге бүленеш бик тә шартлы, чөнки алар барысы да киң планда китап укучы булып торалар.

3. Хәзерге әдәби тәнкыйть үзенең тарихына, анда тупланып килгән традицияләренә нигезләнә. Шуңа да җитди мәсьәлә булып әлеге фәннең табигатен ачыклау, аның чорларга бүленеше һәм шуңа нисбәтле аерым фактларны, үзенчәлекләрне билгеләү һәм аларны системалаштыру тора. Татар әдәби тәнкыйтен чор-этапларга бүлү озак вакытлар дәвамында сүз сәнгатенең чорларга бүленеше белән тәңгәлләштереп карала һәм бәяләнә. Әмма тәнкыйть тарихын һәм чорларга бүленешен бу рәвешле билгеләү каршылыклар, аерым бәхәсләр тудыра. Моңа кадәр тупланган тәҗрибәгә таянып, татар әдәби тәнкыйте үсешендә без биш чор-этапны аерып чыгарабыз: 1 нче чор – әдәби тәнкыйтьнең тууына әзерлек чоры ( борынгы чорлардан алып XX йөз башына кадәр); 2 нче чор – татар әдәби тәнкыйтенең формалашу дәвере (XX йөз башы); 3 нче чор – тоталитаризм дәвере әдәби тәнкыйте (1917–1950 еллар башы); 4 нче чор – тоталитаризмнан соңгы дәвер әдәби тәнкыйте (1950 еллар уртасы – 1980 еллар уртасы); 5 нче чор – XX йөз ахыры – XXI йөз башы әдәби тәнкыйте (1980 еллар уртасы – XXI йөз башы).

4. Әдәбияттагы кебек тәнкыйтьтә дә сыйфат үзгәреше «иске» белән «яңа» көрәшенә нигезләнеп, сүз сәнгатендәге яңа билгеләрне аңлау һәм бәяләү омтылышы рәвешендә барлыкка килә. 1980 еллар ахыры – 90 нчы еллар дәвамында татар әдәбиятында торган саен киңрәк урын алучы сәнгати эзләнүләрне, яңа караш-концепцияләрне, алым-чаралар байлыгын әдәби тәнкыйть ачып-аңлатып бетерә алмый, ягъни ул кризис дәверенә керә. Аның тышкы һәм эчке сәбәпләре арасында күчеш чоры үзенчәлекләре, реалистик тәнкыйтькә генә йөз тоту, шулай ук калыплашкан принципларның яңа төр әсәрләрне анализлауга нигез була алмавы, аналитик тәнкыйтьнең үз позицияләрен югалтуы, тәнкыйтьчеләр буыны алмашыну һ.б.ны күрсәтеп була. Шул ук вакытта эчке көрәш, тартыш фонында «яңа тәнкыйть» үсеп китүгә җирлек тә әзерләнә. Аерым алганда, әсәрләргә бәя бирү принципларының яңа алымнар белән баетылуы, әдипләрнең актив рәвештә тәнкыйть белән шөгыльләнүе, үткән еллар әдәби тәнкыйтен яңача бәяләү омтылышлары арту, шуңа нисбәтле әдәбиятның һәм тәнкыйтьнең бурычлары, вазифалары, гомум мәдәни тормыштагы урыны турында бәхәсләр көчәю, тәнкыйтькә яңа авторлар килү һ.б. ике гасыр чиге татар әдәби тәнкыйтендәге яңалыкның нигезе булып тора.

5. XXI гасыр башы татар әдәби тәнкыйте, күптөрле тышкы һәм эчке факторларга нисбәтле, яңа чор әдәби процессын, шул исәптән аерым әсәрләрне аңлау-бәяләүнең критерийларын, фәнни нигезләрен билгеләүче эстетик концепцияләр эзләү юлына чыга. Тәнкыйтьнең байтак элекке нигезләмәләре, шартлары кабаттан бәяләнә, методологик һәм теоретик принципларына ачыклык кертелә. Шундый шартларда әдәби тәнкыйтьнең төрле юнәлеш-агымнарына (реаль, романтик, эстетик,

импрессионистик, символик һ.б.), төрләренә (профессиональ, язучы, укучы) һәм типларына (филологик, философик, публицистик) йөз тоткан, шуларга нигезләнгән уңышлы үрнәкләр дөнья күрә. Тәнкыйтьтә татар милли әдәбиятына хас булган сыйфат-билгеләрне аерып чыгару омылышлары арта.

6. Хәзерге әдәби тәнкыйтьтә үз стильләре, әдәбиятны аңлау һәм эчке хасиятләрен билгеләүдә үзенчәлекле алым-билгеләре белән аерылып торучы тәнкыйтьчеләр килү күзәтелә. Алар иҗатына, милли традицияләргә нигезләнү белән бергә, башка халыклар әдәбият белемендәге табышларны иҗади үзләштерү, татар сүз сәнгатенә дөнья әдәбияты фонында бәя бирү омтылышы хас. Җәмгыятьтә тарихилык һәм документаль публицистика белән кызыксыну арту, тәнкыйтькә дә йогынты ясап, аның синтезлашуына китерә. Тәнкыйть язмасында, әдәбият-сәнгатькә генә түгел, төрле фән тармакларына караган мәгълүматларның киң урын алуы аның культурология белән гаять тыгыз бәйләнешенә китерә.

7. Тәнкыйтьченең әдәби-эстетик карашлары, теләк-максатлары тәнкыйть язмасының жанр формасында һәм эчтәлегендә чагылыш таба. Әдәби-тәнкыйть жанрларын бүлеп чыгаруда социаль-мәдәни шартларга нигезләнү, аларны төрле яссылыкта бәяләү күзәтелә. Татар әдәби тәнкыйте, үзенең традицияләрен дәвам итеп, чорның әдәби процесс үзенчәлекләренә туры килүче жанрлар классификациясен булдыра. Әдәби тәнкыйтьтә лирик-эмоциональ башлангыч арту күзәтелә. Ул авторның «мин»ен калкытып кую, хис һәм фикернең үрелеп баруы, эмоциональ тойгыларны алга чыгару кебек үзенчәлекләрдә чагыла. Күбрәк язучы тәнкыйтенә нигезләнгән импрессионистик тәнкыйтьнең активлашуы да шуның белән аңлатыла. Хәзерге тәнкыйтьтә рецензия-бәяләмә, проблемалы мәкалә, теоретик мәкалә, монографик мәкалә, иҗат портреты, әдәби-биографик очерк, эссе кебек жанрлар аеруча киң кулланыла.

# ЙОМГАК

1. Татар әдәбият белеменең торышы җәмгыятьтәге социаль-мәдәни шартлар һәм әдәби процессның гомуми үзенчәлекләре белән билгеләнә. Аның үсеш-үзгәрешенә үткәндәге һәм хәзерге сүз сәнгатен яңача бәяләү ихтыяҗы белән моңа кадәр калыплашкан фәнни-теоретик фикернең әлеге максатны үти алмавы аркасында туган каршылык этәргеч бирә. Аларга нигез булып түбәндәгеләр тора: 1) хәзерге татар әдәбият белеме методологиясенең нигез принципларын, тикшеренү юлларын, чараларын билгеләүдә күчеш чоры үзенчәлекләренә таяну; 2) 1920 еллар ахырыннан башлап совет әдәбиятында өстенлек иткән, марксизм-ленинизм идеологиясенә нигезләнгән берьяклы карашлардан арыну; 3) әдәбият белеменең үткән мираска, традицияләргә мөнәсәбәтен билгеләүдә тарихилык, дәвамчанлык, эзлеклелек һәм кабатланып тору принципларына нигезләнү; 4) әдәбиятның җәмгыятьтәге урыны үзгәрү һәм китап укучы яңа буын формалашу; 5) чит илләрдәге әдәбият белеме казанышлары белән танышу мөмкинлеге туу, татар әдәбият фәненең акрынлык белән аларны үзләштерә башлавы һ.б.

2. Методологик һәм теоретик эзләнүләрнең нигезен әдәбият фәненең эчке закончалыкларына нигезле үсеш-үзгәрешен, әдәби-тарихи процессны өйрәнүнең яңа эчтәлек белән баетылган принципларын берләштергән система тәшкил итә. Ул, татар әдәбият белеменең үзенә хас методологиясен эшләү омтылышы белән бәйле булып, башка халыклар казанышларын милли әдәбият үзенчәлекләре, сыйфат-билгеләре белән тыгыз бәйләнештә файдалануны күздә тоткан хәлдә, түбәндәге теоретик һәм методологик мәсьәләләрне үз эченә ала: 1) әдәбият турындагы фәннең термин-төшенчәләрен эшләү һәм, аерым категорияләрнең чорга хас яңа эчтәлек белән баюы нисбәтле, бу өлкәдәге эзләнүләрне дәвам итү; 2) үткән чорларның актуаль һәм кыйммәтле дип кабул ителгән, үзләштерелгән яисә иҗат ориентиры итеп алынган тәҗрибәсен файдалану, ягъни традиция һәм яңачалыкның, үзара диалектик бәйләнештәге төшенчәләр буларак, әдәбият турындагы фәннең эчке үсеше логикасына нигезләнүе, шуның белән аның тарихи үсеш закончалыкларын билгеләве; 3) бөтен филология фәненең теоретик фикерен, күптөрле концепцияләрне иҗади үзләштерү татар әдәбият фәненең яңа баскычына нигез булып тора һәм чагыштырма-тарихи әдәбият

белеменең активлашуына китерә; 4) күчеш чоры үзенчәлекләре тарихилык принцибын яңа эчтәлек белән баета, ягъни ике гасыр чигендә яшәүче китап укучы, төрле чор әсәрләрен кабул иткәндә үз заманына хас социаль-мәдәни һәм фәлсәфи-эстетик сыйфатларга нигезләнеп, яңа диалогик бәйләнешкә, мөнәсәбәткә килеп керә; 5) миллилек принципы, берничә аспектны үз эченә алып (милли әдәбият тарихының төзек, эзлекле системасын булдыру; милли үзенчәлекләрне калкытып куюга, аерып чыгаруга, вакыйга-күренешләрдә, образ-характерларда эретеп бирүгә хезмәт итә торган алым-чараларны билгеләү һәм бәяләү; үткән чордагы һәм хәзерге әдәби процесска бәя биргәндә сүз сәнгате әсәренең милли үзенчәлекләрен аерып чыгаруга хезмәт итүче методларга, мәктәп-юнәлешләргә нигезләнү; миллилекнең диалогик характерына таяну, ягъни тикшеренү объектындагы милли һәм гомумкешелек кыйммәтләрен ачу, аңлату), яңа эчтәлек белән байый; 6) алгы планга әдәбиятны эчке закончалыклары нигезендә үсеп-үзгәреп торучы сүз сәнгате буларак бәяләү, аның эстетик, иҗтимагый, фәлсәфи вазифаларын ачу, татар әдәбиятын дөнья әдәбиятының бер өлеше итеп күзаллау, шуңа бәйле уртаклыклар һәм милли әдәбиятның үзенә хас сыйфатларын билгеләү һ.б. чыга.

3. Хәзерге татар әдәбият теориясендә бәхәсләр уяткан, тикшеренүләргә этәргән проблема булып әдәби юнәлешләр, агымнар, аларның төрле чорларда чагылыш үзенчәлекләрен, традицияләрен һәм бүгенге әдәби барыштагы урыннарын билгеләү тора. Әдәбият, төрле дәверләр, этаплар, чорлар аша үтеп, җитди үзгәрешләр кичерә һәм иҗат тибы, иҗат юнәлеше, иҗат методы, иҗат агымы кебек әдәби бергәлекләрне мәйданга чыгара. Кешенең тормышны танып-белү үзенчәлеге белән бәйле булган иҗат типлары, иҗтимагый, мәдәни һәм эстетик шартларга бәйле, иҗат юнәлешләре булып формалаша. Әдәбият фәнендә озак вакытлар дәвамында классицизм юнәлеше әдәби күренеш буларак урын алмаган, аның үрнәкләре татар укучысына XX йөз башында тәрҗемә әсәрләр аша гына ирешеп, әдәби барышка аз йогынты ясаган дип санала. Соңгы еллардагы тикшеренүләр күрсәткәнчә, татар әдәбиятының төрле чорларында классицизм эстетикасының әдәби процесска бәйле сыйфат үзгәрешләре кичергән үзенчәлекләрен үзләрендә чагылдырган әсәрләр дөнья күрә.

4. Хәзерге татар әдәбият теориясендә әдәби процессны яисә аерым язучы иҗатын әдәби юнәлеш-агым тарафдары буларак бәяләү омтылышы арту күзәтелә. Татар сүз сәнгатендәге эзләнүләрнең киңәюен, әдипләрнең реализм һәм романтизмга хас булмаган алым-чараларга мөрәҗәгать итеп, үзенчәлекле әдәби дөнья тудыру омтылышларын таныган хәлдә, мондый әсәрләрне модернизм һәм постмодернизм үрнәге буларак кабул итүгә һәм хәзерге әдәби барыштагы урыннарын

билгеләүгә әдәбият фәне сак килә. Бу татар әдәбиятының дөнья сүз сәнгатендәге яңа сыйфат-күренешләрне турыдан-туры күчереп кую белән шөгыльләнмичә, үзенең эчке закончалыкларына һәм милли традицияләргә таянып үзләштерүе белән аңлатыла. Мондый әсәрләрдә реалистик әдәбиятка хас булмаган алым-чаралар, иҗади фикерләү аша яшәешне үзенчәлекле танып-белү, яңа чынбарлык тудыру омтылышы күзәтелә. Теоретик фикердә модернизм һәм постмодернизмның хәзерге татар әдәбиятында чагылыш тапкан мөһим сыйфат-билгеләре аерып чыгарыла һәм аларның шактый ныклы җирләшүе турында нәтиҗә ясала.

5. XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы татар әдәбият теориясе игътибар үзәгендә торган мәсьәләләрнең берсе булып «иҗат методы» төшенчәсе тора. Иҗтимагый-мәдәни шартлар һәм сүз сәнгатенең эчке закончалыклары нигезендә иҗат методлары билгеле бер үзгәреш кичерә, яңа сыйфат-билгеләр белән байый. Җәмгыятьтәге үзгәрешләр тәэсирендә соцреализмның тарихта калуы традицион реализмның тармакланып үсеп китүенә, эзләнүләрнең тирәнәюенә, баюына китерә. Әдәбият фәне, әлеге үзгәрешләрне тиз генә ачып-аңлатып бирә алмыйча, җитди каршылыкларга керә. Моннан чыгу юлларын эзләүдә әдәби барышны яисә аерым әдип иҗатын юнәлеш-агымнарга мөнәсәбәтле бәяләү омтылышлары ясала. Соцреализмнан соңгы әдәбиятны без «яңа реализм», «яңа романтизм» дип атау ягында. Әлеге төшенчәләр, вакытлы күренеш буларак, күчеш чоры әдәбиятының үзенчәлекләрен аңлау-аңлатуга хезмәт итә, шуңа да хәзерге әдәби процессның әйдәп баручы иҗат методын билгеләү һәм бәяләү филология фәне алдында торган бурычларның берсе булып кала.

6. Теоретик фикердә зур кызыксыну уяткан «жанр» төшенчәсе әдәбиятның закончалыклы күренеше буларак барлыкка килә һәм даими үсеп-үзгәреп тора. Әлеге үзенчәлек хәзерге әдәби процесска хас тема һәм проблематикадагы, жанр һәм жанр формасындагы, сәнгати сурәтләүдәге эзләнүләрне шактый тулы чагылдыручы трагедия жанрында ачык күренә. Ерактагы һәм якындагы тарихка мөрәҗәгать итеп яисә төрле легенда-риваятьларга нигезләнеп язылган пьесаларда жанр таләпләре, төп сыйфатлары нигездә саклана. Посттоталитар чынбарлыкның төрле якларын ачуга багышланган трагедия жанрындагы әсәрләрдә тудырылган әдәби дөнья, төп герой буларак тәкъдим ителгән образлар социаль каршылыкларда һәм экзистенциаль характерда сурәтләнә, аларны аңлауда һәм бәяләүдә төрлелек, хәтта каршылык күзәтелә. Шул рәвешле, чор үзгәрешләре тәэсирендә, башка жанрлар кебек үк, трагедия дә билгеле бер трансформация кичерә.

7. Иҗтимагый һәм мәдәни шартлар йогынтысында әдәби әсәр поэтикасында җитди үзгәрешләр күзәтелә. Аеруча мөһим теоретик категорияләрнең берсе булган әдәби образ, сүз сәнгате тарихына яисә

җанлы әдәби процесска мөнәсәбәтле төрле караш-фикерләргә этәреп, үзенчәлекле яклары белән ачыла. Шуның бер чагылышы булып образ-символларның актив кулланышы һәм яңа сыйфатлар белән баюы тора.

8. XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы татар әдәбият белемендә барган фикер алышуларда татар әдәбияты тарихын өйрәнүнең түбәндәге методологик һәм фәнни-теоретик нигезләре ачыклана: 1) марксизм-ленинизм тәгълиматына нигезләнгән берьяклы карашлардан баш тарту, 2) үткән чорларда тулы калыплашкан эзлеклелек, бердәмлек, объективлык, системалылык кебек принципларга таяну, 3) әдәбият тарихын өйрәнүнең үзәген тәшкил иткән тарихилык һәм миллилек принципларының, күчеш чоры үзенчәлекләренә нисбәтле, җитди сыйфат үзгәрешләре кичерүе, 4) Шәрык һәм Гареб әдәбиятларының тирән йогынтысын тойган хәлдә, татар әдәбияты тарихын эчке сыйфат үзгәрешләре нигезендә хәрәкәт итүче, үзенә генә хас сыйфат-билгеләре булган күренеш итеп аңлау һәм бәяләү; 5) әдәбиятның җәмгыятьтәге урыны үзгәрүгә, шулай ук фәндә яңа терминнар һәм төшенчәләрнең кулланылышка керүенә бәйле, аны сәнгать төре буларак аңлау, кабул итү һәм бәяләүнең төрлелегенә, аерым алганда, диалогик характерына йөз тоту.

9. Күпгасырлык татар әдәбияты тарихының дәверләргә, чор-этапларга объектив, төгәл бүленешен, чикләрен билгеләү гаять бай сүз сәнгатебезнең системалы үсеш-үзгәрешен, табыш-югалтуларын, традицияләр дәвамчанлыгын һәм яңачалыкларын, халыкның иҗтимагый-фәлсәфи фикер үсешендәге, рухи тормышындагы урынын, тарихи-иҗтимагый, сәяси вакыйгаларны, танылган шәхесләрнең ролен һ.б.ны тулырак аңларга, шулар аша әдәбиятның үсеш-үзгәреш перспективаларын, әдәбият фәнендәге эзләнүләр юнәлешен, камилләштерү юлларын ачыкларга җирлек бирә.

10. Әдәбият фәне, үзенең традицияләренә, казанышларына таянган хәлдә, дөньякүләм сүз сәнгате тарихын тикшерүдәге яңалыкларга йөз белән борылып, татар әдәбият тарихын яңа методологик һәм теоретик нигездә өйрәнү юлына чыга. Ул түбәндәгеләрдә чагыла: 1) татар әдәбият белемендә өстенлек иткән диахрон система белән бергә синхрон системага йөз тоту, шуңа бәйле әдәбият тарихын, аерым әдипләр иҗатын әдәби юнәлешләргә, агымнарга, стиль үзенчәлекләренә нисбәтле тикшеренүләрнең артуы; 2) сүз сәнгатен бәяләүдә төрле мәктәп-метод-юнәлеш прицпипларына нигезләнү, татар әдәбиятын дөнья әдәбиятының бер өлеше рәвешендә, шулай ук чагыштырма һәм типологик планда өйрәнү; 3) төрле сәбәпләр аркасында әдәби процесстан читләштерелгән язучыларның мирасын барлау, аларны әдәби әйләнешкә кертү һәм шуның белән төрле чорлар сүз сәнгатен эзлекле, бердәм күренеш буларак аңлауга килү; 4) күпгасырлык татар әдәбиятының ислам тәгълиматына нигезләнгән үзенчәлекләрен, Шәрык һәм рус-Европа әдәбиятлары

белән тыгыз бәйләнешен ачу; 5) күренекле классиклар иҗатының идея-эстетик һәм фәлсәфи-этик катламнарын заман биеклегеннән торып бәяләү, шәрехләү, башка халыклар әдәбияты белән чагыштыру, традицияләр дәвамчанлыгы һәм яңачалыкларга мөнәсәбәтле тикшерү; 6) чит илләрдәге әдәби мирасны киң катлам укучыларга кайтару һәм фәнни нигездә өйрәнү һ.б.

11. Әдәби процесста җитди урын алып торучы тәнкыйть оештыру, киләчәкне күзаллау, әдипнең тел-стилен, караш-фикерләрен баету, зәвыклы укучыны тәрбияләү, әйләнә-тирә чынбарлыкка йогынты ясау кебек функцияләр аша эстетик, социаль, иҗтимагый характердагы бурыч-функцияләр тормышка ашырыла. Аның табигатен, тарихи эволюциясен, сүз сәнгате әсәрләрен тикшерү юлларын, жанрларын һ.б.ны өйрәнүче тәнкыйть теориясенең төп объекты булып тәнкыйди язма текст тора. Әдәби тәнкыйть яшәешнең рухи-иҗтимагый өлкәләре булган сүз сәнгате, публицистика, фәлсәфә, эстетика, социология, психология, тарих һ.б. белән тыгыз бәйләнештә тора. Ул, хәзерге әдәби процесс белән бергә, үткән мирас сәхифәләрен дә заман биеклегеннән торып бәяли, шул рәвешле әдәбият тарихы һәм әдәбият теориясе белән үзара үрелеп яши.

12. Хәзерге әдәби тәнкыйть үзенең тарихына, анда тупланып килгән традицияләренә нигезләнә. Шуңа да җитди мәсьәлә булып әлеге фәннең табигатен ачыклау, аны чорларга бүлү һәм шуңа нисбәтле аерым фактларны, үзенчәлекләрне билгеләү һәм аларны системалаштыру тора. Моңа кадәр тупланган тәҗрибәгә таянып, татар әдәби тәнкыйте үсешендә биш чор аерып чыгарыла: 1 – әдәби тәнкыйтьнең тууына әзерлек чоры ( борынгы чорлардан алып XX йөз башына кадәр); 2 – татар әдәби тәнкыйтенең формалашу дәвере (XX йөз башы); 3 – тоталитаризм дәвере әдәби тәнкыйте (1917–1950 еллар башы); 4 – тоталитаризмнан соңгы дәвер әдәби тәнкыйте (1950 еллар уртасы – 1980 еллар уртасы); 5 – XX йөз ахыры – XXI йөз башы әдәби тәнкыйте (1980 еллар уртасы – XXI йөз башы).

13. XX гасыр ахыры татар әдәбиятында торган саен киңрәк урын алучы сәнгати эзләнүләрне, яңа караш-концепцияләрне, алым-чаралар байлыгын әдәби тәнкыйть ачып-аңлатып бетерә алмый, ягъни ул торгынлык дәверенә керә. Аның тышкы һәм эчке сәбәпләре арасында көчеш чоры үзенчәлекләре, реалистик тәнкыйтькә генә йөз тоту, шулай ук калыплашкан принципларның яңа төр әсәрләрне анализлауга нигез була алмавы, аналитик тәнкыйтьнең үз позицияләрен югалтуы, тәнкыйтьчеләр буыны алмашыну һ.б.ны күрсәтеп була. Шул ук вакытта эчке көрәш, тартыш фонында тәнкыйть яңарышына җирлек тә әзерләнә. Аерым алганда, әсәрләргә бәя бирү принципларының яңа алымнар белән баетылуы, әдипләрнең актив рәвештә тәнкыйть белән шөгыльләнүе – «язучы тәнкыйте» үсү, үткән еллар әдәби тәнкыйтен яңача бәяләү омтылышлары арту,

шуңа нисбәтле әдәбиятның һәм тәнкыйтьнең бурычлары, функцияләре, гомум мәдәни тормыштагы урыны турында бәхәсләр көчәю, тәнкыйтькә яңа авторлар килү һ.б. ике гасыр чиге татар әдәби тәнкыйтендәге яңачалыкларның нигезе булып тора.

14. XX–XXI гасырлар чигендә татар әдәби тәнкыйте күптөрле тышкы һәм эчке факторларга бәйле, ул чор әдәби барышын, шул исәптән аерым әсәрләрне аңлау-бәяләүнең критерийларын, фәнни нигезләрен билгеләүче теоретик һәм фәлсәфи-эстетик концепцияләр эзләү юлына чыга. Тәнкыйтьнең байтак элекке нигезләмәләре, шартлары кабаттан бәяләнә, методологик һәм теоретик принципларына ачыклык кертелә. Шундый шартларда әдәби тәнкыйтьнең төрле юнәлеш-агымнарына (реаль, романтик, эстетик, импрессионистик, символик һ.б.), төрләренә (профессиональ, язучы, укучы) һәм типларына (филологик, философик, публицистик) йөз тоткан, шуларга нигезләнгән уңышлы үрнәкләр дөнья күрә.

15. Тәнкыйтьченең әдәби-эстетик карашлары, теләк-максатлары тәнкыйть язмасының жанр формасында һәм эчтәлегендә чагылыш таба. Әдәби-тәнкыйть жанрларын бүлеп чыгаруда социаль-мәдәни шартларга нигезләнү, аларны төрле яссылыкта бәяләү күзәтелә. Татар әдәби тәнкыйте, үзенең традицияләрен дәвам итеп һәм бу өлкәдәге казанышлардан файдаланып, чорның әдәби процесс үзенчәлекләренә туры килүче жанрлар классификациясен булдыра. Әдәби тәнкыйтьтә лирик-эмоциональ башлангыч арту күзәтелә. Ул авторның «мин»ен калкытып кую, хис һәм фикернең үрелеп баруы, эмоциональ тойгыларны алга чыгару кебек үзенчәлекләрдә чагыла. Бу исә күбрәк язучы тәнкыйтенә нигезләнгән импрессионистик тәнкыйтьнең активлашуына китерә. Хәзерге тәнкыйтьтә рецензия-бәяләмә, проблемалы мәкалә, теоретик мәкалә, монографик мәкалә, иҗат портреты, әдәби-биографик очерк, эссе кебек жанрлар аеруча киң кулланыла.

## ФАЙДАЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ


Абдулбариева Т.А. Традиции классицизма в драматургии Гаяза Исхаки (к проблеме мотивов государственности): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2010. 27 с.

Абдуллина Д.М. Габдулла Тукай иҗатында Коръән мотивлары. Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. 191 б.

Абдуллина Д.М. Коранические мотивы в творчестве Габдуллы Тукая: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2005. 29 с.

Аверинцев С.С., Андреев М.Л., Гаспаров М.Л., Гринцер П.А., Михайлов В.В. Категории поэтики в смене литературных эпох. М., 1994.

Азбукина А.В. Образ-символ «соловей» в русской поэзии XIX века: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2002. 21 с.

Азизова Г.А. Вопросы истории татарской литературы в трудах Гали Рахима: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2001. 21 с.

Азизова-Хөснетдинова Г. Гали Рәхим – әдәбият тарихчысы. Казан, 2005. 160 б.

Акмал Н. Шигырьне сагыну // Казан утлары. 2003. № 11. Б. 139–145.

Акмал Н. Яшел чирәм // Мирас. 2003. № 12. Б. 69–71.

Аминова В.Р. Типы диалогических отношений между национальными литературами (на материале произведений русских писателей второй половины XIX в. и татарских прозаиков первой трети XX в.). Казань: Казан. гос.ун-т, 2010. 476 с.

Амирханов Р.М. Татарская социально-философская мысль средневековья (XIII – середина XVI в.). Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 1993. 124 с.

Аристотель. Сочинения: В 4-х т. Т. 4. М.: Мысль (ред. и авт. вступ. ст.: А.И. Доватур, Ф.Х. Кесседи; примеч. В.В. Бибихина и др.). 1983. 830 с.

Ахмадуллин А.Г. Татарская драматургия: истоки и формирование социалистического реализма. М.: Наука, 1983. 264 с.

Ахметзянов М.И. Новые археологические материалы и их значение в исследованиях по истории татарской литературы: автореф. дис. ... докт. филол. наук. Казань, 1998. 66 с.

Ахметов Р.Р. Татарский театр // Звезда Поволжья. 2008. 27 марта – 2 апреля.

Әдәби тәнкыйть буенча практикум: махсус курс программасы / төзүчесе доцент Р.Ф. Харрасова. Казан: Казан дәүләт ун-ты, 2004. 19 б.

Әдәби тәнкыйть теориясе: махсус фән программасы / төз. Р.Ф. Харрасова. Казан: Казан дәүләт ун-ты, 2007. 32 б.

Әдәбият белеме сүзлеге / төз.-мөх. А.Г. Әхмәдуллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. 239 б.

Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге / фәнни редакторлар: Т.Н. Галиуллин, Д.Ф. Заһидуллина. Казан: Мәгариф, 2007. 231 б.

Әдәбият теориясенә кереш: Урта мәктәпнең тел-әдәбият укытучылары өчен кулланма / Н.Х. Лаисев, М.С. Мәһдиев, Ф.Ә. Ганиева һ.б.; З. Мәҗитов редакциясендә. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 303 б.

Әминева В.Р. Классицизм // Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге / фәнни ред. Т.Н. Галиуллин, Д.Ф. Заһидуллина. Казан: Мәгариф, 2007. Б. 72–75.

Әхмәдуллин А. Уңай геройлар сагындыра // Казан утлары. 2004. № 7. Б. 162–165.

Әхмәдуллин А.Г. Әле нокта куймыйбыз // Казан утлары. 2001. № 7. Б. 141–147.

Әхмәдуллин А.Г. Боз кузгалырга итә // Казан утлары. 2007. № 6. Б. 121–124.

Әхмәдуллин А.Г. Бүгенге татар драматургиясен өйрәнү һәм укытуның кайбер мәсьәләләре // Югары һәм урта һөнәри уку йортларында татар әдәбиятын укытуның мөһим мәсьәләләре (Г. Тукайның тууына 120 ел тулуга багышланган фәнни-гамәли конференция материаллары, 6–7 апрель, 2006 ел, Яр Чаллы / фәнни редакторлары: Х. Миңнегулов, Г. Сөнгатов. Казан: В.И. Ульянов-Ленин ис. Казан дәүләт университеты, 2006. Б. 22–25.

Әхмәдуллин А.Г. Бүгенге татар драматургиясенең кайбер үзенчәлекләре // Мирас. 2004. № 2. Б. 87–91.

Әхмәдуллин А.Г. Дөреслеккә ирешү юлында. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. 255 б.

Әхмәдуллин А.Г. Күңелләрне уятыр: Хәзерге татар драматургиясе: монография. Казан: Мәгариф, 2007. 223 б.

Әхмәдуллин А.Г. Офыклар киңәйгәндә. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. 239 б.

Әхмәдуллин А.Г. Татар әдәбияты тарихын өйрәнүнең кайбер нәзарыйметодологик принциплары // Офыклар киңәйгәндә. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. Б. 112–118.

Әхмәдуллин А.Г. Татар драматургиясе тарихын өйрәнү мәсьәләләре // Офыклар киңәйгәндә. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. Б. 7–16.

Әхмәдуллин А.Г. Татар совет драматургиясен яңача өйрәнү мәсьәләләре // Дөреслеккә ирешү юлында. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. Б. 7–19.

Әхмәдуллин А.Г. Төзүче-редактордан // Әдәбият белеме сүзлеге / төз.-ред. А. Әхмәдуллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. Б. 3–4.

Әхмәдуллин А.Г. Үз карашы: әдәбиятка да ... мафиягә дә // Офыклар киңәйгәндә. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. Б. 184–188.

Әхмәдуллин А.Г. Эзләнүләр дәвам итәме, алар бәрәкәтлеме? // Офыклар киңәйгәндә. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. Б. 16–26.

Әхмәдуллин А.Г. Яңалыкка омтылып // Дөреслеккә ирешү юлында. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. Б. 75–83.

Әхмәтҗанов М.И. Дастаннар ватаны: Кама аръягының көнчыгыш төбәкләре һәм татар әдәбияты тарихы. Казан: Мәгариф, 1999. 158 б.

Әхмәтҗанов М.И. Мәгариф, археографик эзләнүләр. Казан: Тарих инст-ты, 2009. 187 б.

Әхмәтҗанов М.И. Мәгариф, археографик эләнүләр. Казан: ТФА Тарих институты, 2009. 187 б.

Әхмәтҗанов М.И. Татар кульъязма китабы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. 270 б.

Әхмәтҗанов М.И. Яңа археографик табышлар һәм аларны татар әдәбияты тарихын тикшерүдә куллану. филол. фән. докт. ... дис.; Г. Ибраһимов исем.тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты. Казан, 1998. 421 б.

Әшрәфҗанов Х.Ә. Тарихка әдәби сәяхәт. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. 288 б.

Бадретдинов Р.Ф. Творческое наследие А. Тагирова: идейное содержание и художественные особенности: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2008. 23 с.

Бакиева С. «Такташ кызы» // Такташ турында истәлекләр / төзүчеләре: Н. Юзиев, Н. Садыйкова. Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. Б. 201–202.

Бакиров М.Х. Әдәбиятыбыз тарихына яңа адым // Казан утлары. 1986. № 7. Б. 158–161.

Бакиров М.Х. Йөрәгемне былбыл чакты... // Мәдәни җомга. 2000. 12 апрель

Бакиров М.Х. Татар фольклоры: югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 2008. 359 б.

Бакиров М.Х. Шигърият бишеге: Гомумтөрки поэзиянең яралуы һәм иң борынгы формалары. Казан: Мәгариф, 2001. 343 б.

Бакиров М.Х. Шигърият дөньясына сәяхәт. Казан: ТГЖ нәшр., 1999. 237 б.

Бариева Э.Р. Методология советской литературной науки (1917–1923 гг.): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1982. 24 с.

Бариева Э.Р. Методология советской литературной науки (1917–1923 гг.): дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1982. 192 с.

Баттал Г.Т. Яңа әсәрләр // Гыйлаҗев Т.Ш. Рецензияләрдән тәгъзияләргә: XX өз башы татар әдәби тәнкыйте. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. Б. 149–154.

Батталова А.Д. Мотив «дома» в татарской драматургии: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2006. 24 с.

Батталова А.Д. Татар драматургиясендә йорт образының үсеш-үзгәреше (1960–2000 еллар). Казан: Алма-Лит, 2009. 131 б.

Батталова А.Д. Татар драматургиясендә йорт образының үсеш-үзгәреше (1960–2000 еллар) = Эволюция образа дома в татарской драматургии (1960–2000 гг.): филол. фән. канд. ... дис.: 10.01.02 / КДУ. Казан, 2006. 175 б.

Батулла Р. Тәнкыйтьче кем ул? // Мәдәни җомга. 2005. 27 май.

Бахтин М.М. Эстетика словесного творчества. М.: Искусство, 1979. 424 с.

Баян Ә. Иярле атлар исән булсын: Шагыйрьнең борчулы уйлары // Мәдәни җомга. 2002. 17 декабрь.

Бәдретдинова Л.Ш. Гази Кашшафның әдәби-тәнкыйди һәм гыйльми эшчәнлеге. Казан, 2014. 216 б.

Бәшир Ф. Кеше күңеле – карурман // Казан утлары. 2003. № 3. Б. 154–157.

Бәшир Ф. Сөйлә, каләм! Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 143 б.

Бәширов Ф.К. XX йөз башы татар прозасы. Казан: Фикер, 2002. 287 б.

V–XI класслар өчен татар әдәбияты программасы / төзүчесе – А.Г. Яхин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. 40 б.

Богаткина М.Г. Теория литературы: Формирование новой научной парадигмы: учебное пособие / Казан. гос. ун-т; филол. фак.; каф. рус. лит. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2007. 56 с.

Большаков В.П. Классицистическая теория жанров и ее преодоление // Теория литературы. Т. III. Роды и жанры (Основные проблемы в историческом освещении). М.: ИМЛИ им. М. Горького РАН, 2003. С. 11–32.

Большакова А.Ю. Современные теории жанра в англо-американском литературоведении // Теория литературы. Том III. Роды и жанры (Основные проблемы в историческом освещении). М.: ИМЛИ им. М. Горького РАН, 2003. С. 99–132.

Борев Ю.Б. Введение в теорию литературы // Теория литературы. Т. 1. Литература. М.: ИМЛИ им. М. Горького РАН, 2005. С. 3–27.

Борев Ю.Б. Жанр // Словарь литературоведческих терминов / сост. Ю.Б. Борев. М., 1998. С. 345–346.

Борев Ю.Б. О трагическом. М.: Советский писатель, 1961. 390 с.

Борев Ю.Б. Эстетика. М.: Изд-во полит-й лит-ры, 1969. 350 с.

Борынгы татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. 576 б.

Буало Н. Поэтическое искусство // Литературные манифесты западноевропейских классицистов / под ред. Н.П. Козловой. М.: Изд-во Моск. ун-та, 1980. С. 425–439.

Бушмин А.С. Наука о литературе: Проблемы. Суждения. Споры. М.: Современник, 1980. 334 с.

Валидов Дж. Очерк истории образованности и литературы татар. Казан: Иман, 1998. 159 с.

Вәли-Барҗылы М. Күңел кемне көтә? // Казан утлары. 2004. № 6. Б. 132–140.

Вәлиев М.Х. Күңелем кошы. Казан: Мәгариф, 2004. 223 б.

Вәлиев Мөд.Х. Гамәл дәфтәре: Әдәбият һәм тормыш турында уйланулар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 447 б.

Вәлиулла И.Ә. Мәңгелек бәхет эзләреннән… Эсселәр. Казан: Школа, 2004. 128 б.

Вәлиулла И.Ә. Һәр шагыйрь – бер дәрья... Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 156 б.

Вәлиулла И.Ә. Яңа маяклар эзләгәндә... // Казан утлары. 2004. № 8. Б. 154–157.

Веселовский А.Н. Историческая поэтика. М.: Высшая школа, 1989. 404 с.

Г. Ибраһимов мирасы һәм төрки дөнья: Г. Ибраһимовның тууына 125 ел тулуга багышланган Халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары (17 апрель, 2012 ел). Казан, 2012. 265 б

Габдулла Тукай и тюркский мир: материалы международной конференции, посвященной 130-летию со дня рождения Г. Тукая / сост. Ф.Х. Миннуллина, А.Ф. Ганиева. Казань: ИЯЛИ, 2016. 484 с.

Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар: Габдулла Тукайның тууына 125 ел тулуга багышланган Халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары (25 апрель, 2011 ел). Казан: 2011, 315 б.;

Габдулла Тукай. Энциклопедия / баш мөх. З.З. Рәмиев. Казан: Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2016. 864 б.

Габдулла Тукайның тормыш һәм иҗат хроникасы өчен материаллар (1886–1907) / З.З. Рәмиев, М.И. Ибраһимов редакциясендә. Казан, 2018. 448 б.

Габидуллин Р.Р. Татарская «лагерьная проза» во второй половине XX века: жанровая типология и поэтика: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2009. 24 с.

Гаджиев А.А. Романтизм и реализм: Теория литературно-художественных типов творчества. Баку: Элм, 1972. 348 с.

Гайнетдинов М.В. Гасырлар мирасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 319 б.

Гайнетдинов М.В. Давылларда, җилләрдә: Х. Туфанның тормыш һәм иҗат сәхифәләре . Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 280 б.

Гайнетдинов М.В. Татарская литература XIX века (Идейно-художественный генезис и исторические судьбы). дис. в виде научного доклада ... докт. филол. наук. Казань, 2000. 101 с.

Гайнетдинов М.В. Хакыйкать юлыннан. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 319 б.

Гайнуллин М.Х. Татар әдәбияты. XIX йөз. Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. 687 б.

Гайнуллин М.Х. Татарская литература XIX века. Казань: Тат. кн. изд-во., 1975. 307 с.

Гайнуллина Г.Р. Развитие татарской автобиографической прозы в 60–70-е годы XX века: автореферат дис. … канд. филол. наук. Казань, 2001. 22 с.

Гайнуллина Г.Р. XX гасырның 60–70 нче елларында татар автобиографик прозасы үсеше: филол. фән. канд. ...дис.: 10.01.02 / КДУ; фәнни җит. Т.Н. Галиуллин. Казан, 2001. 163 б.

Гайфуллина Ф.А. Проза Гарифа Ахунова (эволюция творчества): автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2003. 26 с.

Галиәсгар Камал: әдип һәм заман. Казан: Г. Ибраһимов исем. ТӘСИ, 2005. 156 б.

Галиева Э.Р. Татар әдәбият белемендә культура-тарих мәктәбе. Казан: Фән, 2002. 360 б.

Галиева Э.Р. Татар әдәбияты фәненең ике йолдызы // Милли мәдәният. 2002. № 2. Б. 4–23.

Галимҗан Ибраһимов һәм XXI гасыр: тууына 120 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. Казан: Г. Ибраһимов исем. ТӘСИ, 2007. 332 б.

Галимҗан Нигъмәти: тормышы, фәнни-методик эшчәнлеге / Т.Ш. Гыйләҗев редакциясендә. Казан: Бриг, 2018. 252 б.

Галимзянова Э.М. Творческое наследие Фазыла Туйкина: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2004. 24 с.

Галимуллин Ф.Г. Әле без туганчы... Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 320 б.

Галимуллин Ф.Г. Инешләр Иделгә кушыла. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 136 б.

Галимуллин Ф.Г. Кадыйр Сибгатуллин шигъриятендә заман сулышы // XX гасырның 70–90 нчы еллар татар поэзиясе контекстында Кадыйр Сибгатуллин иҗаты. Чаллы: Набережночелнинская типография, 2008. Б. 7–11.

Галимуллин Ф.Г. Офыкларны алдан күреп. Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. 200 б.

Галимуллин Ф.Г. Табигыйлеккә хилафлык. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 303 б.

Галимуллин Ф.Г. Эстетика һәм социологизм: 20–30 нчы еллар татар әдәбиятында эстетика кануннарының һәм социологизм таләпләренең үзара мөнәсәбәте. Казан: Мәгариф, 1998. 223 б.

Галимуллин Ф.Г. Халыкның үз шагыйре // Г. Тукай. Сайланма әсәрләр. Шагыйрь турында истәлекләр. Казан: Татарстан Республикасы «Хәтер» нәшрияты (ТаРИХ), 2002. Б.5–42.

Галиулин Т. Шигырь кемгә кирәк? // Казан утлары. 1995. № 7. Б. 139–142.

Галиуллин Р.Р. Эволюция детектива в татарской литературе: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казан, 2007. 23 с.

Галиуллин Т. Киләчәк кешесе // Татарстан. 2003. № 2. Б. 52–57.

Галиуллин Т. Хәзерге татар поэзиясенең төп үсеш тенденцияләре // Югары һәм урта һөнәри уку йортларында татар әдәбиятын укытуның мөһим мәсьәләләре (Г. Тукайның тууына 120 ел тулуга багышланган фәнни-гамәли конференция материаллары, 6–7 апрель, 2006 ел, Яр Чаллы / фәнни ред.: Х. Миңнегулов, Г. Сөнгатов. Казан: Казан дәүләт университеты, 2006. Б. 13–18.

Галиуллин Т. Шигъри аһәңле публицистика // Татарстан. 2003. № 11. Б. 56–59.

Галиуллин Т.Н. Әдәбият – хәтер хәзинәсе. Казан: Мәгариф, 2008. 231 б.

Галиуллин Т.Н. Гомер учагы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. 207 б.

Галиуллин Т.Н. Дәвамлылык. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 168 б.

Галиуллин Т.Н. Дәвамчанлык // Казан утлары. 2007. № 3. Б. 107–112.

Галиуллин Т.Н. Дәгъва. Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. 256 б.

Галиуллин Т.Н. Дыхание времени (Вопросы становления и развития социалистического реализма в татарской поэзии). Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1979. 303 с.

Галиуллин Т.Н. Егерменче еллар татар шигърияте // Шигърият баскычлары. Казан: Мәгариф, 2002. Б. 47–90.

Галиуллин Т.Н. Кереш / Т.Н. Галиуллин // Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге (Фәнни редакторлар Т.Н. Галиуллин, Д.Ф. Заһидуллина). Казан: Мәгариф, 2007. Б. 3–4.

Галиуллин Т.Н. Онытмадык сине, Фәрваз дус! // Мәдәни җомга. 2009. 7 авг.

Галиуллин Т.Н. Татар әдәбиятында «диссидентлар» булганмы? // Шигърият баскычлары. Казан: Мәгариф, 2002. Б. 172–181.

Галиуллин Т.Н. Татар поэзиясе тарихын яңача өйрәнү мәсьәләләре // Шигърият баскычлары. Казан: Мәгариф, 2002. Б. 9–19.

Галиуллин Т.Н. Тәнкыйть кемгә кирәк? // Татарстан яшьләре. 1989. 28 гыйнвар.

Галиуллин Т.Н. Тәнкыйть һәм әдәби процесс // Казан утлары. 1984. № 11. Б. 162–167

Галиуллин Т.Н. Утызынчы еллар әдәбияты // Әдәбият (XX йөзнең 30–90 нчы еларында татар әдәбияты): Унберьеллык урта мәктәпнең 11 нче сыйныфы өчен дәреслек. Беренче кисәге /Ф.Г. Галимуллин, Т.Н. Галиуллин, Ф.А. Ганиева, Н.Г. Юзиев, А.Г. Әхмәдуллин; А.Г. Әхмәдуллин редакциясендә. Казан: Мәгариф, 1995. Б. 3–19

Галиуллин Т.Н. Утызынчы еллар татар шигърияте // Шигърият баскычлары. Казан: Мәгариф, 2002. Б. 91–125.

Галиуллин Т.Н. Шагыйрьләр һәм шигырьләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 208 б.

Галиуллин Т.Н. Шәхесне гасырлар тудыра. Казан: Татар. кит. нәшр. 2003. 192 б.

Галиуллин Т.Н. Шигърият баскычлары. Казан: Мәгариф, 2002. 231 б.

Галиуллин Т.Н. Яктылык: әдәби тәнкыйть мәкаләләре / кереш сүз авторы Д. Заһидуллина. Казан: Татар. кит. нәшр., 319 б.

Ганиева Р.К. Антиклерикализм и этико-эстетические идеалы Утыз Имяни // Татарская литература: традиции, взаимосвязи. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. С. 30–53.

Ганиева Р.К. Восточный Ренессанс и поэт Кул Гали. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1988. 172 с.

Ганиева Р.К. Восточный Ренессанс и тюркские литературы средневековья // Татарская литература: традиции и взаимосвязи. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. С. 3–13.

Ганиева Р.К. Галимҗан Ибраһимовның «Көтүчеләр» хикәясе // Татарская литература: традиции, взаимосвязи. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. Б. 224–231.

Ганиева Р.К. Гаяз Исхакый иҗаты (Казан дәүләт университетының татар филологиясе һәм тарихы факультеты студентлары өчен махсус курс программасы). Казан: КДУ, 2005. 38 б.

Ганиева Р.К. Нәҗип Думави // Татар әдәбияты тарихы: алты томда. 3 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. Б. 214–234.

Ганиева Р.К. Нәҗип Думавиның иҗат сәхифәләре. Казан: Отечество, 2003. 106 б.

Ганиева Р.К. Проблемы творческих методов в тюркоязычных литературах начала XX века. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1973. Ч. 1. 28с.

Ганиева Р.К. Проблемы творческих методов в тюркоязычных литературах начала XX века. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1976. Ч. 2. 26 с.

Ганиева Р.К. Ренессансные и религиозно-мистические мотивы в поэзии Мэвла Колый // Татарская литература: традиции, взаимосвязи. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. С. 24–29.

Ганиева Р.К. Татарская литература: традиции, взаимосвязи. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. 272 с.

Ганиева Р.К. Төрки әдәбиятларда иҗат методы мәсьәләләре // Хәзерге татар әдәбият белеменең актуаль мәсьәләләре. Казан: Г. Ибраһимов исем. ТӘТИ, 1979. Б. 97–105.

Ганиева Р.К. Традиции Восточного Ренессанса в тюркских литературах Средневековья и Нового времени. Казань: Фэн, 2014. 272 с.

Ганиева Р.К. Тукайның иҗат методы (романтик тенденцияләр эволюциясенә карата) // Татар әдәбияты мәсьәләләре. Казан: Г. Ибраһимов исем. ТӘТИ, 1972. Б. 51–72.

Ганиева Р.К. Ф. Бәйрәмова иҗатына лаеклы хезмәт // Шәмсутова А.А. Фәүзия Бәйрәмова прозасы. Казан: Гуманитария, 2004. Б. 5–10.

Ганиева Р.К. Фатих Әмирхан иҗаты – мәктәптә // Татарская литература: традиции и взаимосвязи. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. Б. 213–223.

Ганиева Р.К. Философско-эстетические основы тюркских литератур средневековья // Татарская литература: традиции и взаимосвязи. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. С. 14–23.

Ганиева Р.К., Галимҗанова Э.М. Фазыл Туйкинның «Ватан каһарманнары» комедиясе – классицизм әдәбияты үрнәге // Проблемы развития татарской нации (языковой, литературно-фольклорный и искусствоведческий аспекты). Казань: Фэн, 2004. Б. 114–127.

Ганиева Р.К., Рәмиева И.Р. М.М. Херасковның «Россияда» поэмасында Сөембикә ханбикә образы // Татарская литература: традиции и взаимосвязи. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. Б. 232–257.

Гараева Г.Ф. Художественные своеобразие документальной прозы Ш. Ракипова: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2007. 28 с.

Гаташ Р. Йолдызларны танып, сөенә белик... (Шагыйрьләребез турында бер уй) // Казан утлары. 2002. № 3. Б. 118–121.

Гаташ Р. Туксанынчы еллар әдәбияты // Казан утлары. 1999. № 4. Б. 140–142.

Гаташ Р. Шагыйрь турында замандашлары // Казан утлары. 2003. № 10. Б. 133–139.

Гаташ Р. Шигърият, синең хакка. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. 224 б.

Гафиятуллина Н.М. Образ Тукая в татарской поэзии ХХ века: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2002. 24 с.

Гафиятуллина Н.М. Романтик әдәбиятта заман фаҗигасе: Әсгать Сәлах // Мәйдан. 2004. № 4. Б. 27–30.

Гафиятуллина Н.М. Хәтер сызлануы // Казан утлары. 2004. № 1. Б. 177–181.

Гафиятуллина Н.М. ХХ гасыр шигъриятендә Тукай. Казан: Матбугат йорты, 2002. 152 б.

Гачев Г.Д. Национальные образы мира: Курс лекций. М.: Академия, 1998. 432 с.

Гаяз Исхакый иҗаты: хәзерге караш: Гаяз Исхакыйның тууына 130 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. Казан: Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ, 2008. 376 б.

Гаяз Исхакый һәм татар дөньясы: әдипнең 120 еллыгына багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. Казан: Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ, 2000. 296 б.

Гегель Г.В. Ф. Эстетика: перевод с немецкого. Москва: Искусство, 1971. Т. 3: Лекции по эстетике . 1971. 621 с.

Гилаева И.И. Гамил Афзал: лирика һәм сатира ( автор позициясе һәм сәнгатьчәлек) = Гамиль Афзал: лирика и сатира (авторская позиция и художественность): филол. фән. канд. ... дис.: 10. 01. 02 / КДУ; ф. җит. Т.Н. Галиуллин. Казан, 2004. 228 б.

Гилаева И.И. Гамиль Афзал: лирика и сатира (авторская позиция и художественность): автореф. дис. .... канд. филол. наук: 10.01.02 / Казан. гос. ун-т. Казань, 2004. 22 с.

Гилазов Т.Ш. Основные тенденции развития татарской литературной критики в 20–30-е годы (проблемы метода и героя): автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 1992. 25 с.

Гилазова Ч.М. Проблемы литературоведения в историко-литературном наследии Г. Сагди: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2006. 31 с.

Гильманов Д.Ш. Тюремные мотивы в татарской литературе (Средневековье – начало ХХ века): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2006. 24 с.

Гиниятуллина А.Ф. Проблема «человек и природа» в татарской прозе 60–90-х годов XX века: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2006. 26 с.

Гомәров И.Г. Мәгърифәт җырчысы: Гали Чокрый иҗатының тормыш һәм иҗат сәхифәләре. Казан: Школа, 2006. 144 б.

Гомәров И.Г. Мәгърифәт җырчысы: Гали Чокрыйның тормыш һәм иҗат сәхифәләре. Казан: Школа, 2006. 144 б.

Гончарова-Грабовская С.Г. Комедия в русской драматургии конца XX – начала XXI века: учеб. Пособие. М.: Флинта: Наука, 2006. 280 с.

Госман Х.Г. Бөек Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы чорында татар поэзиясе. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1960. 18 б.

Госман Х.Г., Мәҗитов З.М. Әдәбият теориясе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. 126 б.

Госманов М.Г. Гасырдан – гасырга. Мәкаләләр җ-гы / төз. Җ. Миңнуллин.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 488 б.

Госманов М.Г. Каурый каләм эзеннән: археограф язмалары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. 463 б.

Госманов М.Г. Чәчелгән орлыклар: Гөлҗа татарлары // Казан утлары. 1992. № 3–4. Б. 76–98.

Госманов М.Г. Ябылмаган китап яки чәчелгән орлыклар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. 206 б.

Громова М.И. Русская драматургия конца XX – начала XXI века: учеб. Пособие. 2-е изд., испр. М.: Флинта: Наука, 2006. 368 с.

Гуляев Н.А. Литературные направления и методы в русской и зарубежной литературе XVII–XIX веков: кн. для учителей. М.: Просвещение, 1983. 144 с.

Гуляев Н.А. Теория литературы: учеб. пособие для филол. специальностей ун-тов и пед. ин-тов. М.: Высшая школа, 1977. 278 с.

Гумеров И.Г. Идейно-эстетические особенности творчества Гали Чокрыя: автореф. дис. канд. филол. наук: 10.01.02 / Казан. гос. ун-т; науч. рук. Х.Ю. Миннегулов. Казань, 2003. 23 с.

Гыйззәтуллин Н. Әдәби хәрәкәт // Татар әдәбияты тарихы: алты томда. 5 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 175–194.

Гыйлаҗев Т.Ш. Әдәби мирас: тарих һәм заман / Кереш сүз авт. Д.Ф. Заһидуллина. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 206 б.

Гыйлаҗев Т.Ш. Рецензияләрдән тәгъзияләргә: XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. 254 б.

Гыйлаҗева Ч.М. Г. Ибраһимов иҗатында татар әдәбиятын чорларга бүлү мәсьәләсе // Фәнни язмалар – 2001. Казан: Школа, 2002. Б. 214–218.

Гыйләҗев А. Гадел һәм ачык булырга кирәк // Мәдәни җомга. 2003. 24 октябрь.

Гыйләҗев А. Көндәлекләр (1992–1993) // Сайланма әсәрләр: 6 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. Б. 83–255.

Гыйләҗев А. Күңелем серләре (Куен дәфтәрләреннән) // Казан утлары. 2000. № 11. Б. 12–41.

Гыйләҗев Т.Ш XX йөз башы әдәбияты // Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанов Ә.М., Гыйләҗев Т.Ш., Йосыпова Н.М. Татар әдәбияты: теория, тарих. Казан: Мәгариф, 2006. Б. 138–205.

Гыйләҗев Т.Ш. Татар әдәби тәнкыйте (1920–1930 еллар) / фән. мөх. А.Г. Әхмәдуллин. Казан: Отечество, 2016. 240 б.

Гыйләҗев Т.Ш. XX йөз башы татар әдәбиятын укыту мәсьәләләре: методик кулланма. Казан: Печатный двор, 2002. 96 б.

Гыйләҗева Ч.М. Әдәбият фәне һәм Габдрахман Сәгъди. Казан: Школа, 2012. 208 б.

Гыйльманов Г.Х. Заман сүз сорый. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. 208 б.

Гыйльманов Г.Х. Заман тойгысы бармы? // Казан утлары. 1989. № 3. Б. 168–174.

Гыйльманов Г.Х. Образ. Символ. Рухи кодлар (Г. Моратның «Түбә» китабын укыганда туган уйлар) // Казан утлары. 1999. № 4. Б. 143–155.

Гыйльманов Г.Х. Тамырлар кайдан килә? // Мәдәни җомга. 2004. 10 декабрь.

Гыймранова Д. Театрга гашыйк булыгыз! (Драматургларның соңгы еллар иҗаты) // Казан утлары. 2003. № 2. Б. 124–129.

Давлетшина Л.Х. Мифологизм в татарской прозе конца XX – начала XXI веков: автореф дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2005. 24 с.

Давыдова Т.Т., Пронин В.А. Теория литературы: учеб. пособие. М.: Логос, 2003. 232 с.

Данилова И.Л. Модерн – Постмодерн? О процессах развития драматургии 90-х годов. Казань: Фэн, 1999. 96 с.

Даутов А.И. Илдар Юзеев шигъриятендә романтизм. Казан: ИНТЕЛПРЕСС, 2002. 152 б.

Даутов Г.Ф. Р.Фахрутдинов – писатель и литературовед: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2001. 19 с.

Даутов Р.Н. Балачак әдипләре: биобиблиографик белешмәлек. Беренче китап = Писатели нашего детства: биобиблиографическая книга. Первая книга. Казан: Мәгариф, 2002. 223 б.

Даутов Р.Н. Балачак әдипләре: биобиблиографик белешмәлек. Икенче китап = Писатели нашего детства: биобиблиографический справочник. Вторая книга. Казан: Мәгариф, 2004. 286 б.

Даутов Р.Н., Гамбәров Н.Г. Балачак әдипләре: биобиблиографик белешмәлек. Өченче китап = Писатели нашего детства: биобиблиографический справочник. Книга третья. Казан: Мәгариф, 2005. 335 б.

Дәүләтшин Г.М. Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 512 б.

Дәүләтшина Л. Киләчәккә күз төбәп // Казан утлары. 2005. № 9. Б. 154–158.

Дискуссия: «Безнең заман герое» // Казан утлары. 2004. № 1. Б. 161.

Духовное наследие: поиски и открытия / под ред. И.Г. Гумерова. Казань: ИЯЛИ, 2016. 276 с.

Егоров Б.Ф. О мастерстве литературной критики. Жанры. Композиция. Стиль. Л., Советский писатель, 1980. 317 с.

Емельянов Л.И. Литературоведение и фольклористика // Взаимодействие наук при изучении литературы / под ред. А.С. Бушмина. Л.: Наука, 1981. С. 102–130.

Еники Ә. Әдәбият – тормыш фәне // Татарстан яшьләре. 1980. 11 декабрь.

Еники Ә. Әсәрләр. 5 томда. 4 том: Соңгы китап. Истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 479 б.

Еники Ә. Халык тормышы һәм әдәбият // Хәтердәге төеннәр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. Б. 24–33.

Еники Ә. Хәерле сәгатьтә! (Татарстан язучыларының XI съездын ачканда сөйләгән сүзе) // Казан утлары. 1989. № 11. Б. 127–128.

Еники Ә. Язу ул – вөждан эше // Соц. Татарстан. 1990. 8 апрель.

Еники Ә. Язу – намус эше // Хәтердәге төеннәр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. Б. 220–222.

Ермилова Е.В. Теория и образный мир русского символизма. Москва: Наука, 1989. 176 с.

Жанры русской литературной критики 70–80-х годов XIX века. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1991. 162 с.

Жук А.А. Конспект вступительной лекции по курсу истории русской литературной критики // Русская литературная критика. Саратов: Изд-во Сарат.ун-та, 1994. С. 7–15.

Җәләлиева М.Ш. Әдәбиятта тойгы катламнары: укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма. Казан: Мәгариф, 2005. 111 б.

Җәләлиева М.Ш. Тойгы катламнары // Казан утлары. 2002. № 11. Б. 160–169.

Загидуллина Д.Ф. Изучение истории татарской литературы в XXI веке // Татарская культура в контексте европейской цивилизации: материалы международной научной конференции. Казань: Ихлас, 2010. С. 9–13.

Загидуллина Д.Ф. Современная татарская проза (1986–2016 гг.): основные тенденции историко-литературного процесса. Казань: Изд-во Академии наук РТ, 2017. 246 с.

Загидуллина Д.Ф. Татарская поэзия рубежа XX–XXI веков (1986–2015): эстетические ориентиры и художественные поиски. Казань: Изд-во Академии наук РТ, 2017. 268 с.

Загидуллина Д.Ф. Формирование и этапы становления теории татарской литературы (первая треть XX века): автореф. дис. ... докт.филол. наук. Казань, 2001. 70 с.

Зайнуллин Г.Г. Во имя Аллаха...: Татарская богословская литература XVIII – начала XX веков и ее языковые особенности. Казань: Магариф, 1999. 238 с.

Закирҗанов Ә.М. «Могикан»нар кисәтә // Заман белән бергә. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. Б. 68–73

Закирҗанов Ә.М. Әдәбият тарихын өйрәнүнең төп принциплары һәм чорларга бүлү мәсьәләсе // Югары һәм урта һөнәри уку йортларында татар әдәбиятын укытуның мөһим мәсьәләләре (Г. Тукайның тууына 120 ел тулуга багышланган фәнни-гамәли конференция материаллары, 6–7 апрель, 2006 ел, Яр Чаллы / фәнни редакторлары: Х. Миңнегулов, Г.Сөнгатов. Казан: В.И. Ульянов-Ленин исем. Казан дәүләт университеты, 2006. Б. 160–166.

Закирҗанов Ә.М. Заман белән бергә. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 175 б.

Закирҗанов Ә.М. Иҗат офыклары // Казан утлары. 2004. №. 4. Б. 160–163.

Закирҗанов Ә.М. Рухи яңарыш. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 287 б.

Закирҗанов Ә.М. Хәзерге татар драматургиясенең актуаль мәсьәләләре. Уку-укыту әсбабы. Казан: Казан ун-ты нәшр., 2010. 80 б.

Закирҗанов Ә.М. Яңа җилләр исәме? (Соңгы еллар әдәби тәнкыйтенә бер караш) // Казан утлары. 2001. N6. Б. 95–101.

Зарипов Р. Кашка тәкәме, кәҗә тәкәсеме? // Казан утлары. 2003. № 9. Б. 145–147.

Зарипов Р. Пегас кашына микән? // Казан утлары. 2004. № 9. Б. 154–158.

Зарипова-Четин Ч. Проблема демонизма в творчестве С. Рамиева в контексте восточно-европейской эстетики. Казань: Мастер Лайн, 2003. 175 с.

Зариф Ф. Әдәбият һәм яшәеш көзгесе // Мирас. 2004. № 1. Б. 91–97.

Зарубежная эстетика и теория литературы XIX–XX вв.: Трактаты, ст., эссе / сост., общ. ред. Г.К. Косикова. М.: Изд-во МГУ, 1987. 510 с.

Заһидуллина Д. Уңай герой югалу: сәбәпләр, нәтиҗәләр // Казан утлары. 2004. № 10. Б. 134–144.

Заһидуллина Д.Ф. «Албастылар» яки татар прозасында яңа сыйфатлар // Казан утлары. 2001. № 11. Б. 111–117.

Заһидуллина Д.Ф. «Гамәл дәфтәре»ндә ниләр бар?.. // Мәйдан. 2004. № 6. Б. 103–106.

Заһидуллина Д.Ф. «Сары йортлар сере» // Яңа дулкында (1980–2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык). Казан: Мәгариф, 2006. Б. 169–179.

Заһидуллина Д.Ф. 1960–80 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр: монография. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 383 б.

Заһидуллина Д.Ф. Әдәбият кануннары һәм заман. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. 271 б.

Заһидуллина Д.Ф. Дәресләрдә әдәби-тарихи күзаллау // Мәгариф. 2004. № 11. Б. 35–37.

Заһидуллина Д.Ф. Дөнья сурәте үзгәрү: XX йөз башы татар әдәбиятында фәлсәфи әсәрләр: монография. Казан: Мәгариф, 2006. 191 б.

Заһидуллина Д.Ф. Кереш сүз // Әмирхан Ф. Әсәрләр. Казан: Мәгариф, 2002. Б. 5–12

Заһидуллина Д.Ф. Марат Кәбиров: «шагыйрь прозасы» // Мәйдан. 2004. № 1. Б. 96–101.

Заһидуллина Д.Ф. Милли реализм юлыннан // Казан утлары. 2003. № 6. Б. 134–147

Заһидуллина Д.Ф. Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. 255 б.

Заһидуллина Д.Ф. Образ // Әдәбият белеме: трминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. Казан: Мәгариф, 2007. 231 б.

Заһидуллина Д.Ф. Символизмны яңартып // Мәйдан. 2005. № 2. Б. 35–39.

Заһидуллина Д.Ф. Соңгы еллар татар прозасы // Хәзерге татар әдәбияты. Казан: Мәгариф, 2008. Б. 412–428.

Заһидуллина Д.Ф. Татар әдәбияты шигърияттән башлана // Казан утлары. 2003. № 4. Б. 166–169.

Заһидуллина Д.Ф. Тәнкыйтьсез үсеп булмас // Казан утлары. 2003. № 8. Б. 146–152.

Заһидуллина Д.Ф. XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф. Заһидуллина, Н.М. Йосыпова. Казан: Казан университеты, 2011. 1 нче китап: XX йөзнең беренче яртысында татар әдәбияты. 230 б.

Заһидуллина Д.Ф. XX йөз башы татар әдәбиятында гыйсъянчылык фәлсәфәсе // Югары һәм урта һөнәри уку йортларында татар әдәбиятын укытуның мөһим мәсьәләләре (Г. Тукайның тууына 120 ел тулуга багышланган фәнни-гамәли конференция материаллары, 6–7 апрель, 2006 ел, Яр Чаллы / фәнни редакторлары: Х. Миңнегулов, Г. Сөнгатов. Казан: В.И. Ульянов-Ленин исем. Казан дәүләт университеты, 2006. Б. 153–162

Заһидуллина Д.Ф. һ.б. Әдәби әсәр: Өйрәнәбез һәм анализлыйбыз: урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма. Казан: Мәгариф, 2007. 112 б.

Заһидуллина Д.Ф. Яңа дулкында (1980–2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык). Казан: Мәгариф, 2006. 255 б.

Заһидуллина Д.Ф. Яңа дулкында // Казан утлары. 2003. № 1. Б. 152–159.

Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанов Ә.М., Гыйләҗев Т.Ш. Татар әдәбияты: Теория, тарих. Казан: Мәгариф, 2004. 247 б.

Зәйдулла Р. Куркытмагыз кошлар авазын // Казан утлары. 2003. № 7. Б. 146–152.

Зәйнуллин Җ.Г. XVIII йөз – XX йөз башында татар рухани әдәбияты. Казан: Мәгариф, 1998. 205 б.

Зельдович М.Г. В поисках закономерностей: о литературной критике и путях ее изучения. Харьков: Изд-во при Харьк.ун-те, 1989. 160 с.

Зинченко В.Г., Зусман В.Г., Кирнозе З.И. Методы изучения литературы. Системный подход: Учебное пособие. М.: Флинта: Наука, 2002. 200 с.

Зөлкарнәев Ф. Сабыр төбе алтынмы? // Казан утлары. 1989. № 2. Б. 165–173.

Зөлкарнәй Ф. Чакма чакмый ут чыкмый. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. 184 б.

Ибатуллина Д.Э. Поэтика прозы Амирхана Еники: автореф. дис.... канд. фил. наук.: 10.01.02 / АН РТ. ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова; науч. рук. Ф.М. Мусин. Казань, 1993. 21с.

Ибрагимов М.И. Миф в татарской литературе XX века: проблемы поэтики. Казань: Гуманитария, 2003. 64 с.

Ибрагимова Л.Г. Модернизм в татарской и русской прозе 1900–1920 гг.: проблемы поэтики: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2014. 27 с.

Ибраһимов Г. Татар әдәбиятында өченче дәвер // Милләт. Тел. Әдәбият: Сайланма хезмәтләр. Казан: Мәгариф, 2007. Б. 132–136.

Ибраһимов Г. Татарның соңгы тарихында өч дәвер (эпоха) // Милләт. Тел. Әдәбият: Сайланма хезмәтләр. Казан: Мәгариф, 2007. Б. 127–131.

Ибраһимов М.И. Миф // Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге / фәнни ред.: Т.Н. Галиуллин, Д.Ф. Заһидуллина. Казан: Мәгариф, 2007. Б. 113–114.

Ибраһимов М.И. Мифологик мәктәп // Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге / фәнни ред.: Т.Н. Галиуллин, Д.Ф. Заһидуллина. Казан: Мәгариф, 2007. Б. 114–115.

Игламов Н. Две реальности // Звезда Поволжья. 2007. 6–12 декабря.

Игламов Р. В пространстве трагедии // Идель. 1998. № 2. С. 77–78.

Игламов Р. Выдающийся драматург. Казань: Татар. кн. изд-во, 1987. 112 с.

Ил йолдызы: татар мөһаҗирләре матбугатында Габдулла Тукай / төз., иск. һәм аңлатмалары язучы З. Мөхәммәтшин. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 189 б.

Ильин И.П. Постмодернизм от истоков до конца столетия: эволюция научного мифа. М.: Интрада, 1998. 255 с.

Ислам на европейском Востоке: Энциклопедический словарь. Казань: Магариф, 2004. 383 с.

Исламов Р.М. Алтын Урда һәм мәмлүкләр Мисыры: язма мирас, мәдәни бәйләнешләр. Казан: Матбугат йорты, 1998. 250 б.

Исламов Р.М. Әдәбият гыйлемендә эзлебез // Мәдәни җомга. 2009. 23 октябрь, 30 октябрь

История русской литературной критики: Учеб.для вузов / В.В. Прозоров, О.О. Милованова, Е.Г. Елина и др.; под ред. В.В. Прозорова. М.: Высш. шк., 2002. 463 с.

История татар с древнейших времен: в семи томах. Т. II. Волжская Булгария и Великая Степь. Казань: РухИЛ, 2006. 956 с.

История татарской литературы нового времени (XIX – начало XX в.). Казань: Фикер, 2003. 472 с.

Йосыпова Н. Соңгы еллар татар поэзиясе // Хәзерге татар әдәбияты. Казан: Мәгариф, 2008. Б. 428–436.

Йосыпова Н. Хәзерге татар драматургиясендә интеллектуаль тенденция: М. Гыйлаҗев // Фәнни язмалар – 2007: җыентык / фәнни ред. И.А. Гыйләҗев. Казан: Казан ун-ты нәшр., 2008. Б. 135–141.

Йосыпова Н.М. ХХ гасыр татар шигъриятендә символлар. Казан: Казан ун-ты, 2011. 120 б.

Кабанова И.В. Введение // Современная литературная теория. Антология / сост. И.В. Кабанова. М.: Флинта: Наука, 2004. С. 7–21.

Кадыйров Р. Гомер итмәк – тырышмактыр // Гайнетдин М.В. Гасырлар мирасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. Б. 3–6.

Кадыров О.Х. Роль Л.Н. Толстого в становлении и развитии татарской реалистической литературы: дис. ... д-ра филол. наук / Казан. гос. акад. культуры и искусства. Казань, 1996. 330 с. + Прил.

Кадыров О.Х. Романтизм Галимджана Ибрагимова (Творчество и эстетика): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1967. 31 с.

Кадырова А.О. Пьесы Исхаки на тему трудовой интеллигенции. Казань: Меддок, 2006. 190 с.

Казначеев С.М. Проблема нового реализма: регенерация метода // Вопросы филологии. 2009. №1. С. 24–33.

Кандалый Г. Шигырьләр һәм поэмалар / төзүчесе, кереш сүз авторы М.Г. Госманов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. 558 б.

Карамова А.З. Психологизм в творчестве Амирхана Еники: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2005. 20 с.

Каримова А.А. Идейно-эстетическая эволюция проблемы феминизма в творчестве Гаяза Исхаки: автореф. дис. …канд. филол. наук. Казань, 2000. 27 с.

Каримуллин А.Г. У истоков татарской книги. Казан: Татар. кн. изд-во, 1971. 223 с.

Кашапова А.М. Послевоенные татарские романы: проблемы творческого метода (1945–1960 гг.): автореф. дис. …канд. филол. наук. Уфа, 2005. 23 с.

Кашапова А.М. Романтические культы в послевоенных татарских романах (1945–1960 гг.): препринт. Уфа: РИО БашГУ, 2005. 40 с.

Кашфиева Л.А. Татарская сатирическая поэзия 50–80-х годов: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1991. 20 с.

Каюм Насыйри (1825–1945) / Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары. Казан: Татгосиздат, 1948. 145 б.

Кәрим Тинчурин һәм татар сәнгате: Бөтенроссия фәнни-гамәли конференция материаллары. Казан: Г. Ибраһимов ис. ТӘСИ, 2007. 336 б.

Кәрими Ф. Морза кызы Фатыйма / төзүче, кереш сүз авторы М. Гайнетдинов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. 414 б.

Кәримуллин Ә.Г. Китап дөньясына сәяхәт. Казан: Татар. кит. нәшр, 1979. 208 б.

Кәримуллин Ә.Г. Суоми иленең татар китаплары // Казан утлары. 1990. № 9. Б. 177–183.

Козлов А.С. Литературоведение Англии и США XX века. М.: Московский Лицей, 2004. 256 с.

Козлова Н.П. Ранний европейский классицизм (XVI–XVII вв.) // Литературные манифесты западноевропейских классицистов / под ред. Н.П. Козловой. М.: Изд-во Моск. ун-та, 1980. С. 5–28.

Коновалов В.Н. Литературная критика 70 – начала 80-х годов XIX века (системный анализ): дис. в виде научного докл. ... докт. филол. наук. Саратов, 1996. 56 с.

Коновалов В.Н. Теоретические проблемы классификации литературно-критических жанров // Жанры русской литературной критики 70–80-х годов XIX века. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1991. С. 5–16.

Краткий словарь литературоведческих терминов: кн. для учащихся / ред.-сост.:Л.И. Тимофеев, С.В. Тураев. 2-е изд., дораб. М.: Просвещение, 1985. 208 с.

Крылов В.Н. Русская символистская критика (1890–1910-е гг.): генезис, типология, жанровая поэтика: дис. ... докт. филол. наук. Казань, 2007. 508 с.

Культурология: учебное пособие / сост. и отв. ред. А.А. Радугин. М.: Библионика, 2005. 304 с.

Курилов А.С. Проблема «литературного направления» в русской критике первой трети XIX века: автореф. дис. ... канд. филол. наук. М., 1972. 17 с.

Кутуй Р. Что назвать поэзией? // Литературная газета. 1964. 3 декабря

Лаисов Н.Х., Мәһдиев М.С., Ганиева Ф.Ә. Әдәбият теориясе: Сәнгать төре һәм идеология формасы буларак матур әдәбият. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 189 б.

Ласкова Р.А. Творчество М. Аглямова (тематика, жанры и поэтика): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2008. 23 с.

Латыйфи Ф. 2002 ел прозасына бер караш (Язучыларның «Әдәби ел йомгаклары» җыелышыннан) // Казан утлары. 2003. № 5. Б. 135–140.

Лебедева О.Б. История русской литературы XVIII века: учебник. М.: Высш. шк., 2003. 415 с.

Лежнев С.П. Проблемы писательской критики // Русская литературная критика. Саратов: Изд-во Саратовского ун-та, 1994. С. 84–89.
Литературная энциклопедия терминов и понятий / под ред. А.Н. Николюкина. Институт научной информации по общественным наукам РАН. М.: Интелвак, 2003. 1600 стб.
Литературные архетипы и универсалии / под ред. Е.М. Мелетинского. М.: Рос. гос. гуманит. ун-т, 2001. 433 с.
Литературный энциклопедический словарь / под ред. В.М. Кожевникова и П.А. Николаева. М.: Советская энциклопедия, 1987. 750 с.
Лихачев Д.С. Принцип историзма в изучении единства содержания и формы литературного произведения // Вопросы методологии литературоведения. М.–Л.: Наука, 1966. С. 142–169.
Лихачев Д.С. Сады Классицизма // Поэзия садов. К семантике садово-парковых стилей. Сад как текст. М.: Согласие; Тип. «Новости», 1998. С. 102–114.
Лосев А. Проблема символизма и реалистическое искусство. М.: Искусство, 1976. 367 с.
Лотман Ю.М. Символ в системе культуры // Избранные статьи: в трех томах. Т. 1. Статьи по семиотике и типологии культуры. Таллинн: Александра, 1992. С. 191–199.
Магдеев М.С. Социальные корни таланта. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1990. 159 с.
Магдеев М.С. Татарская советская литературная критика (1917–1932): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1964. 25 с.
Макарова В.Ф. Комическое в татарской прозе XX века: автореф. дис. ... докт. филол. наук. Казань, 2014. 51 с.
Макарова В.Ф. Поэтика прозы Хасана Сарьяна: автореф. дис. канд. филол. наук.:10.01.02. Казань, 2002. 25с.
Мансуров З. Каләмебез илаһи антка тугрымы? (Бүгенге шигъри әсәрләрне укыганда туган уйлар) // Мәдәни җомга. 2004. 16 апрель.
Мансуров З. Савапка торырлык җаваплар // Мәдәни җомга. 2003. 18 апрель.
Мансуров З.М. Күңелдә фидаи яшәсә: әдәбият, сәнгать һәм яшәеш турында уйланулар. Казан: Мәгариф, 2006. 496 б.
Маханова А.А. Творчество Суфи Аллаяра и его традиции в татарской литературе: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2008. 27 с.
Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар: (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 415 б.
Мәхмүтов Х.Ш. Гыйбарәләр тарихыннан сәхифәләр. Казан: Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты, 2008. 462 б.
Мәхмүтов Х.Ш. Каюм Насыйри һәм татар фольклористикасы // Насыйри К. Сайланма әсәрләр. 4 томда. 3 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. Б. 3–14.
Мәхмүтов Х.Ш. Шигъриятнең тирән тамырлары // Казан утлары. 2003. № 10. Б. 139–142.
Мәһдиев М.С. Әдәбият һәм чынбарлык: XX йөз башы татар әдәбияты турында яңа материаллар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 304 б.
Мәһдиев М.С. Кыршауланган әдәбият // Соц. Татарстан. 1990. 1 апрель.

Мәһдиев М.С. Мәҗит Гафури (1880–1934). Тормыш һәм иҗат юлы турында кыскача очерк. Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. 32 б.

Мәһдиев М.С. Реализмга таба: XX йөз башы татар әдәбиятында чынбарлыкның чагылышы мәсьәләләре / фәнни ред. Р.К. Ганиева. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1989. 156 б.

Мәһдиев М.С. Татар совет әдәбияты тәнкыйте (1917–1932 еллар): фил. фән. канд. ... дис. Казан, 1963. 324 б.

Мәһдиев М.С. Фатих Әмирхан: Тормышы һәм иҗат юлы турында кыскача очерк. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 86 б.

Мелетинский Е.М. Трансформации архетипов в русской классической литературе (Космос и Хаос, герой и антигерой) // Литературные архетипы и универсалии / под ред. Е.М. Мелетинского. М.: Рос. гос. гуманит.ун-т, 2001. С. 150–224.

Мингазова Р.А. Руссоистские традиции в творчестве Галимджана Ибрагимова: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2009. 26 с.

Миннегулов Х.Ю. О современном состоянии изучения тюркоязычной литературы Средневековья в Татарстане // Записи разных лет (Татарская литература: история, поэтика и взаимосвязи). Казань: Идел-Пресс, 2010. С. 34–48.

Миннегулов Х.Ю. Основные проблемы в современном татарском литературоведении // Записи разных лет (Татарская литература: история, поэтика и взаимосвязи). Казань: Идел-Пресс, 2010. С. 337–350.

Миннегулов Х.Ю. Основные тенденции развития современной татарской литературы // Ученые записки – 2004. Казань: Школа, 2005. С. 165–173.

Миннегулов Х.Ю. Татарская литература и Восточная классика (Вопросы взаимосвязей и поэтики). Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1993. 384 с.

Миннегулов Х.Ю. Тюрко-татарская словесность в контексте межлитературных связей (Монография). Казань: Изд-во «Ихлас», 2017. 360 с.

Миннегулов Х.Ю. Этапы развития тюрко-татарской, античной и русской литератур. Казань: Ихлас, 2014. 288 с.

Минһаҗева Л.И. Ибраһим Салахов (тормышы һәм эшчәнлеге). Казан: Матбугат йорты, 1999. 176 б.

Миңнегулов Х. «Бигрәк татар җанлы кеше иде» (Хөсәен Хәмидулла турында) // Ватаным Татарстан. 1992. 21 июнь.

Миңнегулов Х.Й. «Их, шатланам татар булуыма» (Минһаҗ Исмәгыйлинең тормышы һәм иҗаты) // Мирас. 1996. №. 5–6. Б. 252–270.

Миңнегулов Х.Й. Әдәбият тарихын өйрәнү юлында // Казан утлары. 1987. № 6. Б. 130–134.

Миңнегулов Х.Й. Гасырлар өнен тыңлап... Казан: Мәгариф, 2003. 335 б.

Миңнегулов Х.Й. Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 367 б.

Миңнегулов Х.Й. Дөньяда сүземез бар... Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 336 б.

Миңнегулов Х.Й. Минһаҗ Исмәгыйли шигырьләре // Мирас. 1996. № 11. Б. 41–49.

Миңнегулов Х.Й. Мөнәсәбәтебезне ачык белдерик // Мәдәни җомга. 2006. 1 сентябрь.

Миңнегулов Х.Й. Сәйф Сараи. Тормышы һәм иҗаты. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1976. 190 б.

Миңнегулов Х.Й. Татар әдәбияты тарихын өйрәнүнең кайбер мәсьәләләре // Югары һәм урта һөнәри уку йортларында татар әдәбиятын укытуның мөһим мәсьәләләре: Г. Тукайның тууына 120 ел тулуга багышланган фәнни-гамәли конференция материаллары, 6–7 апрель, 2006 ел, Яр Чаллы / фәнни редакторлары: Х. Миңнегулов, Г.Сөнгатов. Казан: В.И. Ульянов-Ленин исем. Казан дәүләт университеты, 2006. Б. 10–13.

Миңнегулов Х.Й. Урта гасырлар татар әдәбияты: нәтиҗәләр, бурычлар // Дөньяда сүземез бар... Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. Б. 8–25.

Миңнегулов Х.Й. Хөсәен Габдүш хикәяләре // Мирас. 1998. № 7. Б. 65–81.

Миңнегулов Х.Й. Чит илләрдәге татар әдәбияты һәм матбугаты // Дөньяда сүземез бар... Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. Б. 194–210.

Миңнегулов Х.Й. Чит илләрдәге татар әдәбияты. Казан: Мәгариф, 2007. 399 б.

Миңнегулов Х.Й. Шәрык һәм татар әдәбиятында кысалы кыйссалар. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1988. 198 б.

Миңнегулов Х.Й., Садретдинов Ш.А. Әдәбият: урта мәктәп һәм гимназияләрнең 9 нчы сыйныфы, урта махсус уку йортлары, педагогия училищелары, колледж һәм лицей укучылары өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 1994. 336 б.

Миңнуллин Р. «Әдип сәясәтче дә булырга тиеш» // Сайланма әсәрләр: 7 томда. 7 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. Б. 443–454.

Миңнуллин Р. Балачакка шигырь кирәк! («Ки-кри-күк» җыентыгына кереш сүз) // Сайланма әсәрләр. 7 томда. 5 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. Б. 102–104.

Миңнуллин Р. Өзәңгеләр өзелмәс (М. Кәбировның «Өзәңгегә баскан чак» җыентыгы) // Сайланма әсәрләр: 7 томда. 5 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. Б. 119–125.

Миңнуллин Т. «Таяныч ул – халык...» (шагыйрь Р. Фәйзуллинның драматург Т. Миңнуллин белән әңгәмәсе) // Казан утлары. 2005. № 9. Б. 76–88.

Миңнуллин Т. Каләмебез, сүзебезне эшкә җигик! // Казан утлары. 1989. № 11. Б. 128–132.

Миңнуллин Т. Татарның әхлакый кодексы // Утырып уйлар уйладым: Көндәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. Б. 324–363.

Миңнуллин Т. Туксанынчы еллар әдәбияты // Казан утлары. 1999. № 5. Б. 136–137.

Миңнуллин Т. Хәлил әйбәт егетме? // Мәгариф. 2000. № 3. Б. 32–33.

Миңнуллин Ф.М. Безнең прозада сугыш темасы // Балта явызлар кулында. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. Б. 98–99.

Миңнуллин Ф.М. Бугазыңа төер тыгылмаса... // Балта явызлар кулында. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. Б. 107–123.

Миңнуллин Ф.М. Кичермәсләр безне, кичермәсләр… // Балта явызлар кулында. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. Б. 124–146.

Миңнуллина Ф.Х. Юныс Сафиуллин драматургиясе (Заман һәм герой). Казан, 2007. 132 б.

Мирсияпова Т.И. Экзистенциальные мотивы в творчестве М. Ханафи: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2009. 26 с.

Мифтахова М.А. Поэзия Хасана Туфана 60–80 гг. XX века: автореф. дис. ... канд. филол. наук: 10.01.02: 13.00.02 / ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ; науч. рук.: Н.Ш. Хисамов, С.Г. Исмагилова. Казань, 2004. 27 с.

Мифтахова М.А. Поэзия Хасана Туфана 60–80-х гг. XX века: пробл. лирич. героя: методика изучения в татар. шк. / АН РТ, ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова. Казань: Алма-Лит, 2005. 203 с.

Михайлов А.В. Методы и стили литературы // Теория литературы. Т. 1. Литература. М.: ИМЛИ им. М. Горького РАН, 2005. С. 142–182.

Морат Г.В. Җәяүле кошлар: публицистик мәкаләләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. 223 б.

Мостафин Р. Гадел булыйк // Казан утлары. 2005. № 5. Б. 148–151.

Мостафин Р.Ә. Гомер агачы // Татарстан. 2003. № 2. Б. 146–148.

Мостафин Р.Ә. Чорлар чатындагы үзгәрешләр // Казан утлары. 2004. № 5. Б. 146–150.

Мөхәммәдиев Р.С. Әгәр без янмасак. Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. 144 б.

Мөхәммәтшин З.Г. Фатих Халидинең иҗат мирасы. Казан: Таң-Заря, 2001. 159 б.

Мөхәммәтшин З.Г. Чит илләрдә татар әдәбияты // Казан утлары. 2008. № 6. Б. 123–126.

Мусабекова Р.Р. Сагит Сунчелей: судьба и творчество. Казань: Школа, 1999. 189 с.

Мусин Ф.М. Әдәби хәрәкәт // Мирас. 1996. № 5–6. Б. 104–124

Мусин Ф.М. Әдәбият фәне һәм тәнкыйть // Мирас. 1996. № 12. Б. 38–47.

Мусин Ф.М. Әдәбият фәне һәм тәнкыйть // Татар әдәбияты тарихы: алты томда: 6 т.: 60–90 еллар әдәбияты. Казан: Раннур, 2001. Б. 458–479.

Мусин Ф.М. Әдәбиятны ничек өйрәнергә? // Мәдәни җомга. 1995. 22 декабрь.

Мусин Ф.М. Вакыт үзе куя бәһане // Мәдәни җомга. 2004. 7 май.

Мусин Ф.М. Гаяз Исхакый: (тормышы һәм эшчәнлеге). Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 191 б.

Мусин Ф.М. Көмеш көзге: әдәби-тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 256 б.

Мусин Ф.М. Рухи әләм менсен биеккә // Шәһри Казан. 1996. 24 май.

Мусин Ф.М. Связь времен: об историзме современной татарской прозы. Казань: Татар. кн. изд-во, 1979. 224 с.

Мусин Ф.М. Татар әдәбияты тарихы һәм заман // Мирас. 1996. № 1–2. Б. 18–29.

Мусин Ф.М. Чор белән аваздаш: әдәбият фәне һәм тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. 240 б.

Мустафин Р.А. По следам оборванной песни. Изд. перераб. и доп. Казань: Татар. кн. изд-во, 2004. 399 с.

Мустафин Р.А. Силуэты: Литературные портреты писателей Татарстана. Казань: Татар. кн. изд-во, 2006. 351 с.

Мухамадиев Р.С. Проблемы формирования татарской литературной критики (1900–1917). Казань: Татар. кн. изд-во, 1982. 143с.

Мухаметдинов Р. Татарские диссиденты // Звезда Поволжья. 2004. 14–20 октября.

Мухаметзянова Л.Х. Татарские книжные дастаны: история становления жанра и поэтика: автореф. дис. ... докт. филол. наук. Казань, 2015. 45 с.

Надиров И. Финляндия татарлары // Мирас. 1992. № 2. Б. 73–81.

Насибуллина Н.Ш. Типология жанров и систематизация художественных образов в поэзии Роберта Миннуллина: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2013. 22 с.

Насрутдинова Л. «Новый реализм» в русской прозе 1980–90-х годов (концепция человека и мира): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1999. 21 с.

Насыйри К. Сайланма әсәрләр: 4 томда. 1 нче һәм 2 нче томнар / төзүчесе, гарәп графикасында сакланган текстларны гамәлдәге язуга күчерүче – Мәсгуд Гайнетдин). Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 368 б. ; 2004. 400 б.

Недзвецкий В.А. Русская литературная критика XVIII–XIX веков: курс лекций. М.: Изд-во МГУ, 1994. 182 с.

Нигматуллин Э.Г. Диалог литератур. Казань: Унипресс, 2002. 175 с.

Нигматуллин Э.Г. Раздвигая века и границы: К вопросу о связах татарской литературы первой трети XX в. с литературой Западной Европы. Казань: Татар. кн. изд-во, 1977. 136 с.

Нигматуллин Э.Г. Татарская литература начала XX века (до 1917 г.) в ее отношении к западноевропейской литературе и философско-эстетической мысли: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1972. 17 с.

Нигматуллин Э.Г. Татарская литература начала XX века (до 1917 г.) в ее отношении к западноевропейской литературе и философско-эстетической мысли: дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1972. 232 с.

Нигматуллина Ю.Г. «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. Казань: Фэн, 2002. 167 с.

Нигматуллина Ю.Г. И.С. Тургенев и татарская литература начала XX века (Тургенев и Ф. Амирхан). Казань: Изд-во Казан.ун-та, 1961. 59 с.

Нигматуллина Ю.Г. Изучение русской литературы в КГУ // Ученые записки Казанского государственного университета. Серия Гуманитарные науки. 2009. Т. 151, кн. 3. С. 7–20.

Нигматуллина Ю.Г. Национальное своеобразие эстетического идеала. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1970. 212 с.

Нигматуллина Ю.Г. Системно-комплексное исследование художественного творчества: история научного направления в Казанском университете. Казань: Фэн, 2004. 251 с.

Нигматуллина Ю.Г. Татавангард и современный цивилизационный процесс. Казань: Фэн, 2011. 56 с.

Нигматуллина Ю.Г. Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. Казань: Фэн, 1997. 190 с.

Низами Р. Тәнкыйть тә – тирән дәрьядыр // Казан утлары. 2007. № 6. Б. 169–172.

Низамов И.М. Эссе жанры: «Әдәби-публицистик жанрлар» курсыннан журналистика факультеты студентлары, аспирантларына уку кулланмасы. Яр Чаллы: Оператив полиграфия лабораториясе, 2007. 80 б.

Ногманов Р.Г., Хәсәнов М.Х. XX йөз татар әдәбиятына культуранализ. Казан: Дом печати, 2008. 224 б.

Нуруллин И. Акыл һәм күңел кушканча // Соц. Татарстан. 1990. 25 март.

Нуруллин И. Булган ул тәнкыйди реализм! // Казан утлары. 1995. № 2. Б. 176–180.

Нуруллин И.З ХХ йөз башы татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. 288 б.

Нуруллин И.З. Агач аяклардан төшү хәерле (Төрки телле әдәбиятларда реализм мәсьәләсе) // Тормыш һәм сәнгать чынлыгы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. Б. 152–173.

Нуруллин И.З. Әдәбият теориясе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 89 б.

Нуруллин И.З. Путь к зрелости: Формирование и развитие критического реализма в татарской литературе. Казань: Татар. кн. изд-во, 1971. 271 с.

Нуруллин И.З. Реализм турында. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. 93 б.

Олуг әдибебез бар! (Татарстанның халык язучысы Ә. Еникигә 90 яшь) // Казан утлары. 1999. № 3. Б. 49–50.

Основы литературоведения: учебное пособие для филологических факультетов пед.ун-тов / под общей ред. В.П. Мещерякова. М.: Московский Лицей, 2000. 372 с.

Основы сравнительного и сопоставительного литературоведения: учеб. пособ. по спецкурсу для студентов специализации «Русский язык и лит-ра в межнациональном общении» / авт.-сост. В.Р. Аминева; научн. ред. Д.Ф. Загидуллина. Казань: Казан. гос.ун-т, 2007. 48 с.

Очерки истории татарской общественной мысли. Казань: Татар. кн. изд-во, 2000. 191 с.

Палиевский П.В. Внутренняя структура образа // Теория литературы: Основные проблемы в историческом освещении. Кн. 1. М.: Просвещение, 1962. С. 72–114.

Поварисов С. Моң эчендә асылташ (татар халык шагыйре И. Юзеевка 70 яшь) // Казан утлары. 2003. № 1. Б. 145–149

Поляков М.Я. В мире идей и образов: историческая поэтика и теория жанров. М.: Сов.писатель, 1983. 367 с.

Программа. 1980–2000 елларда татар әдәбияты (Проза һәм драматургия) / төзүчесе А. Шәмсутова. Казан: Гуманитария, 2002. 23 б.

Раков Р. Укыр җаннар бетмәсен! // Казан утлары. 2004. № 9. Б. 158–160.

Рахман Р. «Горький цвет» // Звезда Поволжья. 2007. 22–28 ноября.

Рахман Р. Иң кирәктән ни кирәк? // Мәдәни җомга. 2003. 18 апрель.

Рахмани Р. «Татар әдәбияты тарихы»ның сигезтомлыгына гомуми күзәтү // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда / төз. Р.Ф. Рахмани. 1 т.: Борынгы чор һәм Урта гасырлар / фәнни мөх. М.Х. Бакиров. Казан: 2014. Б. 5–13.

Рахмани Р. Кыйблабызга тугрылык // Казан утлары. 2002. № 4. Б. 170–184.

Рахмани Р. Шагыйрьнең язмыш келәме // Казан утлары. 2003. № 4. Б. 121–134.

Рәмиев З.З. Тукай энциклопедиясе хакында // Фәнни Татарстан. 2016. № 2. Б. 38–42.

Рәмиев З.З. ХХ йөз башы татар әдәбияты: авторлык, төп текст һәм хронология мәсьәләләре. Казан: Школа, 2000. 180 б.

Рәмиева И.Р. Рус, татар, төрек әдәбиятларында ханбикә Сөембикә образы. Казан, 2009. 244 б.

Рәшит Ә. Зурдан кубып сөйләшкәндә // Казан утлары. 2004. № 4. Б. 132–139.

Рейнольдс Э. Научный труд татарского ученого в восприятии английского слависта // Научный Татарстан. 1998. № 2. С. 94.

Романтизм: Теория. История и критика / науч.ред. Л.И. Савельева. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1976. 183 с.

Русская литературная критика: учеб. пособие для вузов по направлению «Филология», спец. «Рус. яз. и лит.». Саратов: Изд-во Сарат. ун-та, 1994. 189 с.

Русская советская литературная критика (1917–1934): хрестоматия. М.: Советский писатель, 1981. 297 с.

Русско-татарские литературные связи (проблемы сопоставительного исследования): библиографический указатель / сост А.З. Хабибуллина, М.М. Сидорова. Казань: Изд-во Казан.ун-та, 1999. 184 с.

Сабиров Р.Р. «Шигырьләрдә – минем йөрәгем...»: (Хәсән Туфан поэзиясендә автор образы). Казань: Школа, 2006. 187 б.

Сабиров Р.Р. Образ автора в поэзии Хасана Туфана: автореф. дис. . канд. филол. наук: 10.01.02 / Казан. гос. ун-т. Казань, 2004. 28 с.

Садекова А.Х. Фольклор в эстетике Галимджана Ибрагимова. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 1995. 103 с.

Садретдинов Ш.А. Сәгыйть Рәмиев иҗаты. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1973. 162 б.

Сайганов А.Дж. У истоков эстетики реализма. Эстетика Ф. Амирхана и ее место в развитии татарской реалистической литературы. Казань: Татар. кн. изд-во, 1982. 168 с.

Салихов Р.Г. Герой и эпоха (концепция героя в татарском литературоведении). Казань: Мастер Лайн, 1999. 352 с.

Салихов Р.Г. Концепция героя в татарском литературоведении: автореф. дис. … докт. филол. наук. Казань, 1999. 58 с.

Саляхова З.Г. Натурализм в творчестве Галимджана Ибрагимова: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2004. 23 с.

Самигуллина Л.М. Концепция героя в период зарождения и становления татарской драматургии (1887–1910): автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2004. 22 с.

Сарчин Р.Ш. Поэзия Фатиха Карима в историко-литературном контексте 1930-х – 1945 годов: Монография. Казань: Бриг, 2015. 270 с.

Саттарова А.М. Современная татарская драматургия (1985–2000 гг.): Концепция эпохи и героя. Казань: Гуманитария, 2003. 152 с.

Сафин Ф. Гыйбрәт алыйм дисәң... // Казан утлары. 2002. № 9. Б. 131–140.

Сафиуллин Ю. Сәхнә әсәрләребез нинди? // Казан утлары. 2000. № 2. Б. 138–144.

Сафиуллина Р.Ф. Традиции фольклора в творчестве Габдельджаббара Кандалый: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2007. 21 с.

Сафиуллина Ф.С. Хәзерге әдәби телебез үсеше // Казан утлары. 2002. № 11. Б. 151–159.

Сахапов М.Ж. Вестник Возрождения. Монография. Казань: Центр инновационных технологий, 2001. 528 с.

Сахапов М.Ж. Золотая эпоха татрского ренессанса. Казань: Татар. кн. изд-во, 2004. 320 с.

Сахапов М.Ж. Исхаки и татарская литература XX века: монография. Казань: Дом печати, 2003. 608 с.

Саяпова А.М. Дардменд и проблема символизма в татарской литературе. Казань: Издательство «Алма-Лит», 2006. 246 с.

Саяпова А.М. Поэзия Дардменда и символизм. Казань: Изд-во КГПИ, 1997. 210 с.

Сәгъди Габдрахман: фәнни-биографик җыентык / төзүчеләре Д. Заһидуллина, Ч. Гыйлаҗева. Казан: Җыен, 2008. 416 б.

Сәхапов Ә.Җ. Исхакый иҗаты. Монография. Казан: Мирас, 1997. 368 б.

Сәхапов Ә.Җ. Исхакый һәм ХХ гасыр татар әдәбияты. Казан: Мирас, 1997. 528 б.

Сәхапов М.Җ. Баш редактор сүзе // Мирас. 2007. № 10. Б. 3–14

Сәхапов М.Җ. Бердәм агым. Казан: Рухият, 2005. 320 б.

Сәхапов М.Җ. Кырыс чынбарлык. Казан: Мирас, 1995. 144 б.

Сәхапов М.Җ. Яңарыш хәбәрчесе: Г. Исхакый иҗаты турында. Казан: Мәгариф, 2003. 367 б.

Сверигин Р. Яңа замана, яңа геройлар // Казан утлары. 2004. № 11. Б. 159–168.

Сверигин Р.Х. Аны беләбезме? (Ф. Яруллинга 65 яшь тулу уңаеннан) // Казан утлары. 2003. № 2. Б. 130–137

Сверигин Р.Х. Гасырлар чатында // Казан утлары. 2002. № 4. Б. 145–154.

Сверигин Р.Х. Нурзилә новеллалары... // Казан утлары. 2003. № 6. Б. 174–176.

Сверигин Р.Х. Туксанынчы еллар әдәбияты // Казан утлары. 1999. № 6. Б. 126–128.

Сверигин Р.Х. Үткән ел прозасына бер караш // Казан утлары. 2000. № 7. Б. 132–137

Сверигин Р.Х. Фатих Хөсни. Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. 152 б.

Сверигин Р.Х. Яңа герой һәм яңа алымнар: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 120 б.

Сибат Р. «Йәгез бер дога!» // Казан утлары. 2001. № 10. Б. 121–131.

Сибат Р. Гаташ – мәхәббәт җырчысы // Казан утлары. 1998. № 3. Б. 134–150.

Сибат Р. Өчтомлыкны укыгач өч сүз (Р. Фәйзуллин өчтомлыгын укыгач туган уйлар) // Казан утлары. 1996. № 10. Б. 133–148.

Сибат Р. Прозабыз Ахуны // Казан утлары. 2000. № 9. Б. 131–147.

Сибгатуллина А.Т. В поисках человека (концепция личности в поэзии XIX века). Елабуга: Изд-во ЕГПИ, 2001. 142 с.

Сибгатуллина А.Т. Эволюция концепции личности в татарской поэзии XIX века: дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1990. 191 с.

Сибгатуллина Ә.Т. Илаһи гашыйклар юлыннан. Казан: Кыйбла, 1999. 144 б.

Сибгатуллина Ә.Т. Суфичылык серләре. Казан: Матбугат йорты, 1998. 368 б.

Сибгатуллина Ә.Т. Татар әдәбиятында суфичылык: чыганаклар, тематика һәм жанр үзенчәлекләре: филол. фән. д-ры ... дис.; Казан дәүл.ун-ты. Алабуга, 2000. 380 б.

Сибгатуллина М.Р. Идейно-эстетическая направленность творчества Ф. Карими: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2008. 23 с.

Сквозников В. К понятию творческого метода // Теория литературы. Т. 1. Литература. М.: ИМЛИ им. М. Горького РАН, 2005. С. 302–334.

Скоропанова И.С. Русская постмодернистская литература: учеб. пособие. 2-е изд., испр. М.: 2000. 608 с.

Словарь литературоведческих терминов / ред.-сост. Л.И. Тимофеев и С.В. Тураев. М.: Просвещение, 1974. 509 с.

Современная литературная теория: антология / сост. И.В. Кабанова. М.: Флинта: Наука, 2004. 344 с.

Современное литературоведение (страны Западной Европы и США): концепции, школы, термины. Энциклопедический справочник. 2-е изд., испр.и дополн. М.: Интрада. ИНИОН, 1999. 315 с.

Современные философские проблемы естественных, технических и социально-гуманитарных наук: учебник для аспирантов и соискателей ученой степени кандидата наук / под общ. ред. д-ра филос. наук, проф. В.В. Миронова. М.: Гардарики, 2007. 639 с.

Средневековая татарская литература (VIII–XVIII вв). Казань: Фэн, 1999. 240 с.

Тамарченко Н.Д. Методологические проблемы теории рода и жанра в поэтике XX века // Теория литературы. Т. III. Роды и жанры (основные проблемы в историческом освещении). М.: ИМЛИ им. М. Горького РАН, 2003. С. 81–98.

Тарихыбыз тулымы? («Татар әдәбияты тарихы» ның 6 нчы томы басылып чыгу уңаеннан фикер алышу) // Казан утлары. 2003. № 5. Б. 126–137.

Татар әдәби тәнкыйте тарихы (1900–1925). Махсус курс программасы / төзүчесе – доц. Т.Ш. Гыйлаҗев. Казан: КДУ, 1999. 42 б.

Татар әдәби тәнкыйте тарихы: программа / төзүчеләре – М.С. Мәһдиев, З.М. Мәҗитов. Казан: КДУ, 1986. 20 б.

Татар әдәбияты (1917–1990): программа / төзүчеләре – Ф.Г. Галимуллин, Р.Х. Сверигин. Казан: КДПИ, 1994. 46 б.

Татар әдәбияты тарихы (20–30 нчы еллар) / төзүчесе – доц. А.Г. Яхин. Казан: КДУ, 2001. 20 б.

Татар әдәбияты тарихы: алты томда. 1 т. Борынгы һәм урта гасырлар дәвере. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 567 б.

Татар әдәбияты тарихы: алты томда. 2 т. XIX йөз әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 563 б.

Татар әдәбияты тарихы: алты томда. 3 т. XX гасыр башы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 598 б.

Татар әдәбияты тарихы: алты томда. 4 т. Татар совет әдәбияты (1917–1941). Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 567 б.

Татар әдәбияты тарихы: алты томда. 5 т. Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы еллар әдәбияты (1941–1960). Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 543 б.

Татар әдәбияты тарихы: алты томда. 6 т. Казан: Раннур нәшр., 2001. 544 б.

Татар әдәбиятында постмодернистик концепция чагылышы: махсус курсның уку-укыту һәм гамәли дәресләр программасы / төзүчесе А.А. Шәмсутова. Казан: Гуманитария, 2003. 36 б.

Татар әдипләре, мәгърифәтчеләре (XX йөз башы): биобиблиографик сүзлек / Кереш сүз авт., фәнни ред. З.З. Рәмиев. Казан, 2005. 276 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: өч томда. 3 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. 831 б.

Татар урта мәктәпләре өчен әдәбият программалары (5–11 сыйныфлар) / төзүчеләре: А.Г. Әхмәдуллин, Ф.М. Хатипов. Казан: Мәгариф, 2000. 55 б.

Татарский энциклопедический словарь. Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 1998. 703 с.

Татарча-русча-инглизчә әдәбият белеме терминнары сүзлекчәсе / төз-авт.: Ф.С. Сәйфуллина, Ә.М. Закирҗанов, Л.И. Минһаҗева һ.б. Казан: Казан. ун-ты нәшр., 2014. 160 б.

Таһирҗанов Г.Т. Тарихтан – әдәбиятка. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 168 б.

«Таяныч ул – халык...» (шагыйрь Р. Фәйзуллинның драматург Т. Миңнуллин белән әңгәмәсе) // Казан утлары. 2005. № 9. Б. 87.

Творчество Тукая в контексте евразийской культуры: материалы конференции. Казань: Фикер, 2002. 176 с.

Теория литературы. Т. 1. Литература. М.: ИМЛИ им. М. Горького РАН, 2005. 336 с.

Теория литературы. Т. III. Роды и жанры (основные проблемы в историческом освещении). М.: ИМЛИ им. М. Горького РАН, 2003. 592 с.

Теория литературы: учеб. пособие для студ. филол. фак. высш. учеб. заведений: в 2 т. / под ред. Н.Д. Тамарченко. Т. 1: Н.Д. Тамарченко, В.И. Тюпа, С.Н. Бройтман. Теория художественного дискурса. Теоретическая поэтика. М.: Академия, 2004. 512 с.

Тимбикова К. Шагыйрьнең хыялында йөрткән китабы // Казан утлары. 2000. № 6. Б. 166–169.

Томашевский Б.В. Теория литературы. Поэтика: учеб. пособие / вступ. статья Н.Д. Тамарченко; комм. С.Н. Бройтмана при участии Н.Д. Тамарченко. М.: Аспект Пресс, 1999. 334 с.

Укмаси М. Интикад // Гыйлаҗев Т.Ш. Рецензияләрдән – тәгъзияләргә. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. Б. 231–233.

Урманче Ф.И. «Олыгайгач бер дога» («Борынгы миф һәм бүгенге шигырь» циклыннан: Рәдиф Гаташ иҗаты турында) // Казан утлары. 2003. № 4. Б. 135–142.

Урманче Ф.И. Борынгы миф һәм бүгенге шигырь (Татарстанның халык шагыйре Р. Фәйзуллин шигъриятенә бер караш). Казан: Школа, 2002. 260 б.

Урманче Ф.И. Ераклардан килгән чишмәләр // Мирас. 1995. № 1–2. Б. 280–282.

Урманче Ф.И. Роберт Миңнуллин: шигъри осталык серләре. Казан: Мәгариф, 2005. 335 б.

Урманчеев Ф.И. Волшебный клубок: Муса Джалиль и народное творчество. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 1995. 184 с.

Урманчеев Ф.И. Дастаннарга лаек замана (Борынгы фольклор һәм хәзерге поэзия). Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. 222 б.

Урманчеев Ф.И. Лиро-эпос татар Среднего Поволжья: основные проблемы изучения баитов. Казань: Татар. кн. изд-во, 2002. 256 с

Фаттах Н.С. Язык богов и фараонов. Казань: Татар. кн. изд-во, 1999. 488 с.

Фаттахов И.Ф. Татарская повесть 80–90-х гг. XX века (эпоха и образ автора): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2002. 29 с.

Фатхрахманов Р.Г. Творческая лаборатория прозаика (на материале произведений А. Еники, М. Магдеева, А. Гилязова, Н. Фаттаха и др.): автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2000. 32 с.

Фәизов Р. Алар безнең арада // Казан утлары. 2004. № 2. Б. 149–154.

Фәйзуллин Р. Яңа елда яңарган уйлар // Казан утлары. 2002. № 1. Б. 5–7.
Фәйзуллин Р.Г. Гыйбрәтләр алырлык үткән юл: фәнни-публицистик язма. Казан: Идел-Пресс, 2004. 152 б.
Фәйзуллин Р.Г. Сайланма әсәрләр. 4 т. (Әдәби-публицистик уйланулар, иҗат портретлары, эссе-уйланулар). Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 384 б.
Фәттах Н. Гаделлек – нигез булсын! // Казан утлары. 1989. № 11. Б. 160–161.
Фәттах Н.С. Шәҗәрә. Тарихи-лингвистик эзләнүләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. 325 б.
Фәтхрахманов Р.Г. Йөрәкнең җеназасы (Татар тормышына Айдар Хәлим прозасы аша бер караш) // Казан утлары. 2003. № 11. Б. 132–138.
Фәтхрахманов Р.Г. Кальбендә ни сер бар, каләм? (Прозаикның иҗат лабораториясе). Казан: Мәгариф, 2009. 175 б.
Фәтхрахманов Р.Г. Татарга сатма матбугат... // Казан утлары. 2004. № 3. Б. 158–162.
Фәхреддин Р. Асар. 2 т. Казан: Рухият, 2009. 309 б.
Фәхреддин Р. Асар. 3 һәм 4 т. Казан: Рухият, 2010. 648 б.
Федотов О.И. Основы теории литературы: учеб. пособие для студ. высш. учеб. заведений: в 2 ч. М.: Гуманит. изд.центр ВЛАДОС, 2003. Ч. 1: Литературное творчество и литературное произведение. 272 с.
Федотов О.И. Основы теории литературы: учеб. пособие для студ. высш. учеб. заведений: в 2 ч. М.: Гуманит. изд.центр ВЛАДОС, 2003. Ч. 2: Стихосложение и литературный процесс. 240 с.
Фрейд З. Психология бессознательного: сб. произведений / сост., науч.ред., авт. вступ. ст. М.Г. Ярошевский. М.: Просвещение, 1989. 448 с.
Хабутдинова М.М. Проблема личности в творчестве Хади Такташ: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1998. 19 с.
Хайдаров Л.И. Вопросы арабской литературы в татарском литературоведении начала XX века: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2004. 27 с.
Хайруллина Д.М. Образ женщины в русской и татарской литературе 1890–1917 годов на примере творчества Г. Исхаки и М. Горького: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2005. 20 с.
Хакимова С.Г. Проза Фаниса Яруллина (эволюция творчества): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2004. 23 с.
Хализев В.Е. Драма как род литературы (поэтика, генезис, функционирование). М.: Изд-во МГУ, 1986. 260 с.
Хализев В.Е. Интерпретация и литературная критика // Проблемы теории литературной критики: сб. статей. М.: Изд-во Моск.ун-та, 1980. С. 49–92.
Хализев В.Е. Теория литературы. Учеб. 2-е изд. М.: Высш. шк., 2000. 398 с.
Халикова З.А. XX йөз башы – татар әдәби тәнкыйте формалашу чоры // Милли мәдәният. 2003. № 3. Б. 21–26.
Халит Г.М. Кешегә һәм чынлыкка мәхәббәт белән. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. 375 б.
Халит Г.М. Портреты и проблемы. Казань: Татар. кн. изд-во, 1985. 344 с.
Халит Г.М. Поэзия дерзаний: творчество Хади Такташа и вопросы метода, героя и стиля в татарской поэзии 20-х годов. Казань: Татар. кн. изд-во, 1980. 258 с.

Халит Г.М. Яңа гасыр поэзиясе: XX йөз башы (1905–1917 еллар) татар поэзиясендә иҗат методы, лирик герой, традиция һәм новаторлык мәсьәләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 166 б.

Ханзафаров Н.Г. Татарская комедия. Казань: Фэн, 1996. 189 с.

Ханнанов Р.Г. Татарская сценическая литература в контексте тюркской драматургии (конца XIX – начало XX веков): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2009. 22 с.

Ханнанов Р.Г. Татарская сценическая литература в контексте тюркской драматургии (конца XIX – начало XX веков): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2009. 22 с.

Ханнанова-Галимҗанова Э.М. Фазыл Туйкин: язучы, телче һәм фольклорчы. Казан, 2006. 156 б.

Харис Р. Әйтәсе сүзебез соңармасын // Казан утлары. 1989. №11. Б. 133–135.

Харис Р. Төрки Йосыфнамәнең чишмә башы // Мәдәни җомга. 2006. 3 ноябрь.

Харрасова Р.Ф. Әдәби бәйләнешләр яктылыгында. Казан: Гарт, 2002. 261 б.

Харрасова Р.Ф. Әдәби тәнкыйть нигезләре. Казан: ТӘһСИ, 2017. 312 б.

Харрасова Р.Ф. Иҗат лабораториясе (Икенче кисәк: Поэтик иҗат). Казан: КДУ, 2004. 228 б.

Харрасова Р.Ф. Иҗат лабораториясе: дәреслек-кулланма. Беренче кисәк. Казан: РПФ ГАРТ, 2004. 136 б.

Харрасова Р.Ф. Ранняя проза Гаяза Исхаки в контексте литературных взаимосвязей (1895–1905): автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2002. 24 с.

Хасавнех А.А. Этико-эстетические воззрения поэта-суфия XIX века Ахметзяна Тубыли: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2002. 28 с.

Хатипов Ф.М. Әдәбият теориясе. Казан: Мәгариф, 2000. 351 б.

Хатипов Ф.М. Духовный мир героя: Психологизм в современной татарской прозе. Казань: Татар. кн. изд-во, 1981. 223 с.

Хатипов Ф.М. Иҗат серләре // Мөлкәтебезне барлаганда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. Б. 220–243.

Хатипов Ф.М. Классик реализм (Тәнкыйть реализмы булганмы?) // Мөлкәтебезне барлаганда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. Б. 184–197.

Хатипов Ф.М. Мөлкәтебезне барлаганда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 272 б.

Хатипов Ф.М. Рәшәле дөнья (Р. Сверигин белән берлектә) // Мөлкәтебезне барлаганда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. Б. 23–69.

Хатипов Ф.М. Романнарда – Сөембикә образы // Мөлкәтебезне барлаганда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. Б. 172–183.

Хатипов Ф.М. Якты җирлектәге һәлакәт // Казан утлары. 2000. № 3. Б. 137–141.

Хатипов Ф.М., Сверигин Р.Х. Әмирхан Еники (Әдипнең тормыш һәм иҗат юлы): монография. Казан: ТДГПУ, 2009. 114 б.

Хафизов С. Әдәбиятта базар заманы // Казан утлары. 1998. № 8. Б. 148–162.

Хафизов С. Ислах, яки яманаттан ярлыкау // Казан утлары. 1994. №4. Б. 129–138.

Хафизов С. Кайда безнең рыцарьлар? // Казан утлары. 2004. № 11. Б. 153–157.

Хафизов С. Очмыйча син түзеп кара... // Казан утлары. 2002. № 7. Б. 133–143.

Хафизов С. Сәясәтче хакимнәр килер дә китәр... // Шәһри Казан. 1995. 7 апрель.

Хафизов С. Туксанынчы еллар әдәбияты // Казан утлары. 1999. № 12. Б. 144–147.

Хәзерге татар әдәбияты программасы (1941–2000 еллар) / төзүчеләре: А.И. Даутов, Г.Р. Гайнуллина. Казан: КДУ, 2000. 35 б.

Хәзерге татар әдәбиятында әхлакый эзләнүләр. Казан: Г. Ибраһимов исем. ТӘТИ, 1989. 144 б.

Хәйретдинова-Карюкова С. Әсәрләрендә якты нур бар // Мәйдан. 2005. № 3. Б. 143.

Хәлим А. Сез беләмсез кая барганны? // Казан утлары. 2005. № 1. Б. 109–136.

Хәлим А. Сез беләмсез кая барганны? // Казан утлары. 2005. № 2. Б. 96–120.

Хәлим А. Туксанынчы еллар әдәбияты // Казан утлары. 1999. № 4. Б. 137–140.

Хәмид Р. Татар драматургиясе миллиме? // Казан утлары. 2002. № 4. Б. 155–163.

Хәсәнов М. Милли яңарыш хәбәрчесе // Сәхапов М.Җ. Яңарыш хәбәрчесе: Г. Исхакый иҗаты турында / М.Х. Хәсәнов кереш сүзе белән. Казан: Мәгариф, 2003. Б. 3–9.

Хәсәнов М. Татар әдәбияты тарихын өйрәнүнең кайбер методологик мәсьәләләре // Казан утлары. 1992. №1. Б. 141–147.

Хәсәнова Ф.Ф. Ренат Харис шигърияте // Казан утлары. 2000. № 5. Б. 155–170.

Хәсәнова Ф.Ф. Ренат Харис шигърияте. Казан: Школа, 2005. 260 б.

Хисамов Н.Ш. Бөек язмышлы әсәр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 336 б.

Хисамов Н.Ш. Кол Гали һәм төрки «Йосыфнамә». Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 208 б.

Хисамов Н.Ш. Поэма «Кысса-и Йусуф» Кул Али: Анализ источников сюжета и авторского творчества. М.: Наука, 1979. 254 с.

Хисамов Н.Ш. Тамырларны барлап // Хәтер сагында. Казан: Мәгариф, 2003. 424–427 б.

Хисамов Н.Ш. Татар шагыйрьләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. 287 б.

Хисамов Н.Ш. Хәтер сагында. Казан: Мәгариф, 2004. 641 б.

Хисамов Н.Ш. Яңача фикерләү һәм татар әдәбияты тарихы концепциясе // Хәтер сагында. Казан: Мәгариф, 2004. Б. 9–12.

Хисмәтова Э. Фәүзия Бәйрәмова әсәрләрендә психологизм күренешләре // Фән һәм тел. 2005. № 1. Б. 19–22.

Хузина М.К. Поэтический мир Равиля Файзуллина: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2005. 26 с.

Һөвәйдә (Мулла Хуҗа-Нәзәр бине Гаиб-Нәзәр Җәмйани). Рәхәте-дил – җан рәхәте / текстологик әзерләү, сүз башы авторы – профессор Ф.З. Яхин. Казан: ТӘһСИ, 2018. 268 б.

Шаехов Л.М. Трагедия в стихах в татарской драматургии: зарождение и развитие: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2012. 22 с.

Шакирова Г.А. Драматургия Туфана Миннуллина 80–90-х годов: автореф. дис. ... канд. филол. наук.: 10.01.02; 13.00.02. Казань, 2000. 19с.

Шамсетдинова Л.Ш. «Рисаляи Газиза» Таджетдина Ялчыгула: проблематика и поэтика: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2002. 24 с.

Шарипов А.М. Зарождение и становление системы стихотворных жанров в древнетюркской и тюрко-татарской литературе (VIII–XIV вв.). Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2001. 364 с.

Шарипов А.М. Система стихотворных жанров в древнетюрской и тюрко-татарской литературе VIII–XIV вв. (зарождение, становление и функционирование): автореф. дис. … докт. филол. наук. Казань, 2001. 81 с.

Шарипов М. Драматургия Туфана Миннуллина. Проблемы героя и его художественное воплощение: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Уфа 1989. 20 с.

Шарипова А.С. Морально-этическая концепция в драматургии Юнуса Аминева: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2007. 29 с.

Шәйхелисламов З.Р. Аңлыем дип шагыйрь җанын... (Әхмәт Фәйзи иҗатында Тукай). Казан: Фикер, 2001. 144 б. һ.б.

Шәмсутова А.А. «Җан сурәте» // Мәйдан. 2007. № 4. Б. 140–143.

Шәмсутова А.А. Гаяз Исхакый иҗатында феминистик проблемаларның идея-эстетик эволюциясе (1897–1954). Казан: Гуманитария, 2003. 192 б.

Шәмсутова А.А. Татар әдәбиятында «постмодернистик концепция» // Гыйльми язмалар. 2003. № 11. Б. 12–14.

Шәмсутова А.А. Фәүзия Бәйрәмова прозасы (фәлсәфи-эстетик карашлар, образлар системасы, психологизм һәм мотивлар). Казан: Гуманитария, 2004. 120 б.

Шәмсутова А.А. Хәзерге татар әдәбиятында яңарыш: фәнни мәкаләләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. 205 б.

Шәрәфиев Р. Ак казлар чакыруы // Казан утлары. 2002. № 12. Б. 151–155

Шәрәфиев Р. Бәндәләр хатасы – бәндәгә сабак // Казан утлары. 2004. № 9. Б. 178–181.

Шәрәфиев Р. Безнең дә әниләр бар иде... // Казан утлары. 2002. № 3. Б. 171–175.

Шәрәфиев Р. Киләме, күрәбезме? // Казан утлары. 2004. № 1. Б. 161–163. (164)

Шәрәфиев Р. Хакны әйтүчеләр илдә бар // Казан утлары. 2003. № 8. Б. 153–159.

Шәрәфиев Р.К. Уйлы күңел: тәнкыйть мәкаләләре, әдәби-публицистик язмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 141 б.

Шәрипов Ә.М. Кадыйр Сибгатуллин шигъриятенең сәнгатьчә эшләнеше // XX гасырның 70–90 нчы еллар татар поэзиясе контекстында Кадыйр Сибгатуллин иҗаты. Чаллы: Набережночелнинская типография, 2008. Б. 17–19.

Шеллинг Ф.В. Философия искусства / под общ. ред. М.Ф. Овсянникова; пер. с нем. П.С. Попова. М.: Мысль, 1999. 608 б.

Шиһапов И. Матурлыкка омтылабызмы? // Казан утлары. 2004. № 12. Б. 136–138.

Эсалнек А.Я. Архетип // Введение в литературоведение. Литературное произведение: Основные понятия и термины: учеб. пособие / Л.В. Чернец, В.Е. Хализев, С.Н. Бройтман и др.; под ред. Л.В. Чернец. М.: Высш. шк.; Академия, 1999. С. 30–37.

Эсалнек А.Я. Основы литературоведения. Анализ художественного произведения: Практикум. 2-е изд. М.: Флинта: Наука, 2004. 216 с.

Юзеев А.Н. Татарская философская мысль конца XVIII–XIX вв. Казань: Татар. кн. изд-во, 2001. 192 с.

Юзиев Н.Г. Сәнгатьчә матурлык һәм осталык. Казан: Татар. кит. нәшр., 1969. 272 б.

Юзиев Н.Г. Татар шигыре: тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. 303 б.

Юзиев Н.Г. Традицияләр яңарганда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1966. 171 б.

Юзиев Н.Г. Хәзерге татар поэтикасы: (поэзия теориясенә кереш). Казан: Татар. кит. нәшр., 1973. 351 б.

Юзиев Н.Г. Шигърият дөньясы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. 312 б.

Юзиев Н.Г. Шигырь гармониясе: татар шигыре поэтикасы. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1972. 220 б.

Юзмухаметова Л.Н. Новые явления в татарской прозе рубежа XX–XXI веков: постмодернизм. Казан: Изд-во Казан. ун-та, 2016. 220 с.

Якупова Г.Х. Дискуссии писателей в контексте татарской духовной жизни начала XX века (на примере Г. Исхаки, Ф. Карими и др.): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2006. 25 с.

Яңа гасыр, иске проблемалар... («Казан утлары» журналы редакциясенең киңәйтелгән утырышыннан) // Казан утлары. 2002. № 2. Б. 113–121.

Ярошевский М.Г. Зигмунд Фрейд – выдающийся исследователь психической жизни человека // Фрейд З. Психология бессознательного. СПб.: Питер, 2002. С. 7–29.

Яруллина Р.А. Идейно-эстетическое своеобразие творчества Гаяза Исхаки (1897–1906 гг.): автореф. дис. ... канд. филол. наук.: 10.01.02. Казань, 1998. 22 с.

Яруллина Р.Ә. Гаяз Исхакый иҗаты (1897–1906). Казан: Гуманитария, 2003. 192 б.

Яхин А.Г. Әдәбият дәресләре: укытучылар, югары уку йортлары студентлары һәм укучылар өчен методик кулланма. Казан: Мәгариф, 2003. 159 б.

Яхин А.Г. Әдәбият: унберьеллык мәктәпнең 10 нчы сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия. Казан: Мәгариф, 1995. 70 б.

Яхин Ф.З. Әдәбият укыганда: фәнни тикшеренүләр. Казан: Сүз, 2014. 236 б.

Яхин Ф.З. Гасырдан – гасырга: Яңа заман әдәбиятына. Казан: Сүз, 2014. 215 б.

Яхин Ф.З. Татар әдәбияты тарихын өйрәнү мәсьәләсе // Гыйльми язмалар. Казан: Татар дәүләт гуманитар институты, 2003. Б. 119–121.

Яхин Ф.З. Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология. Казан: ТДГИ нәшр., 2000. 268 б.

ЭЧТӘЛЕК


Кереш . . . 3

**I бүлек. Ике гасыр чигендә татар әдәбият белеменең актуаль мәсьәләләре** . . . 7

1.1. Татар әдәбият белемендәге үзгәрешләрнең социаль-мәдәни шартлары . . . 7

1.2. Әдәбият фәненең теоретик һәм методологик мәсьәләләре . . . 14

I бүлек нәтиҗәләре . . . 33

**II бүлек. Әдәбият теориясе: традицияләр һәм яңа тенденцияләр** . . . 35

2.1. Татар әдәбият теориясен өйрәнү мәсьәләләре . . . 35

2.2. Татар әдәбият теориясендә әдәби юнәлешләр мәсьәләсе . . . 51

2.2.1. Татар әдәбиятында классицизм традицияләре турында . . . 55

2.2.2. Татар әдәбият фәненең модернизм һәм постмодернизмга мөнәсәбәте . . . 64

2.3. Әдәбиятта иҗат методы: аны аңлау-аңлатуның үзгәрүе . . . 74

2.4. Хәзерге әдәби процесс үзенчәлекләре . . . 88

2.4.1. Әдәби агымнар яңарышы турында . . . 88

2.4.2. Әдәби жанрлар трансформациясе турында (трагедия мисалында) . . . 110

II бүлек нәтиҗәләре . . . 124

**III бүлек. Татар әдәбият тарихын өйрәнүгә яңача якын килү** . . . 128

3.1. Әдәбият тарихын өйрәнүнең теоретик һәм методологик нигезләре . . . 128

3.2. Әдәбият тарихын чорларга бүлү мәсьәләсе . . . 143

3.3. Татар әдәбияты тарихын өйрәнүнең төп аспектлары . . . 161

3.3.1. Борынгы һәм урта гасырлар әдәбияты . . . 163

3.3.2. XIX йөз әдәбияты . . . 184

3.3.3. XX йөз башы сүз сәнгате . . . 190

3.3.4. Совет чоры әдәбияты . . . 207

III бүлек нәтиҗәләре . . . 237

**IV бүлек. Хәзерге әдәби тәнкыйтьнең торышы һәм үсеш перспективалары** . . . 240

4.1. Хәзерге әдәби барышта тәнкыйтьнең урыны . . . 240

4.2. Тәнкыйтьтә торгынлык һәм аннан чыгу юлларын эзләү . . . 248

4.3. Хәзерге әдәби тәнкыйтьтә фәнни-теоретик һәм фәлсәфи-эстетик карашлар . . . 259

4.4. Әдәби тәнкыйть жанрлары системасы . . . 292

IV бүлек нәтиҗәләре . . . 312

**Йомгак** . . . 315

Файдаланылган әдәбият . . . 321

Научное издание

**Закирзянов Альфат Магсумзянович**

**ТАТАРСКОЕ ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ:
ТРАДИЦИИ И ТЕНДЕНЦИИ РАЗВИТИЯ
(конец XX – начало XXI века)**

(на татарском языке)

Редактор *Я.М. Абдулкадырова*
Компьютерная верстка *Н.Т. Абдуллиной*
Дизайн обложки *А.В. Булатова*

Печать офсетная. Гарнитура «Times».
Формат: 60×84 1/16.
Усл.-печ. л. 23,7. Уч.-изд. л. 25,2. Тираж 300 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен в Институте языка, литературы
и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12